# ЯРУЛЛИН ФӘНИС

# ӘСӘРЛӘР

Өч томда

## II
## том

*Повесть, пьесалар*

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2008

УДК 821.512.145-31:2
ББК 84(2Рос=Тат)-44:6
Я74

РЕДКОЛЛЕГИЯ:

*З.Р.Вәлиева, Р.И.Вәлиев, Т.А.Миңнуллин, И.М.Ибраһимов, Д.С.Шакиров, Р.Х.Корбанов, Х.Г.Әюпов*

**Яруллин Ф.Г.**

Әсәрләр: 3 томда / Фәнис Яруллин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.

ISBN 978–5–298–01617–9
2 т.: повесть, пьесалар. — 2008. — 462 б. — 2000 д. —ISBN 978–5–298–01619–3
ISBN 978–5–298–01619–3(2 т.)
ISBN 978–5–298–01617–9

© Татарстан китап нәшрияты, 2008

© Яруллин Ф.Г., 2008

## КЫЙБЛАСЫЗЛАР

Фатыйма юлга бик ныклап әзерләнде. Чәчтарашка барып чәчләрен матурлатты, тырнакларын буятты. Өстенә яңа спорт костюмы киде. Бу костюмны ире Илсур күптән түгел генә Чехиядән алып кайткан иде. Фатыйма аны бик яратты, чөнки аның дус хатыннары арасында мондый костюм киюче юк иде. Фатыйма, яраткан костюмын киеп, гаражда һәрвакыт үзен көтеп ачкычын бер боруга кабынып китәргә әзер торган кара «Форд»ы янына килде. «Нихәл, дускай?» — дип машинасына кагылып, чәнчә бармагы белән аның өстен сыпырып алды. Бармак тигән урында эз күргәч, зәңгәрле-яшелле тавыш белән кычкырып җибәрде: «Сабина! Сабина, дим, чык әле монда!»

Ике катлы йортның коймасы артында посып утырган кечкенә өйдән ашыга-ашыга аксак хатын килеп чыкты. Фатыйма, аны күрүгә: «Нигә машинаның тузанын сөртмәдең?» — дип, ачулы тавыш белән кычкырып җибәрде. Юкса аның бер ачуы да юк, күңеле күтәренке иде. Тик үзенең — хуҗа, ә

Сабинаның хезмәтче икәненә басым ясамаса, күтәренке күңелнең төшүе мөмкин. Ә Фатыймага бүген көн буена җитәрлек кәеф кирәк. Ул бик мөһим юлга чыгарга җыена. Ә мондый чакларда хезмәтчеңне кимсетүдән дә рәхәт ни бар?!

Сабина, телсез кеше кебек, тузанны үзенә җыя һәм буяуны тырнамый торган чүпрәк белән эһ дигәнче машинаны сөртеп алды. Фатыйма, аңа рәхмәт әйтеп тормыйча, машинасын кабызды. «Форд», көтмәгәндә сыртына тимер чуклы каеш камчы төшкән айгырдай, кинәт кузгалып китте. Гараж эчендә әчкелтем төтенгә күмелеп хезмәтче хатын Сабина гына калды. Әллә машина төтененнән, әллә язмышына рәнҗүдән аның күзләре яшьләнде. «Йөриләр шунда әллә кем булып!» — дип сукрана-сукрана гараждан чыгып капкасын бикләп куйды.

Фатыйма шәһәрнең иң бай кибетенә юнәлде. Ире Илсурны үзе моннан алты ел элек ташлап киткән малаен алып кайтырга ризалата алуына, улын алып кайткан очракта байлыкка күмеләчәгенә ышану аның күңелен күтәргән иде.

Фатыйма башта ук малаен яратмады. Авырга узуын белгәннән бирле ул аңа үзенең иркен чикләүче, матурлыгын урлаучы итеп карады. Фатыйманың күргәне бар: күп кенә сылу кызлар бала табуга солы капчыгына әверелә. Күкрәкләре асылынып төшә, билләре юаная. Ә Фатыйманың үз байлыгын югалтасы килмәде. Ярый инде вакытында «мунча пәрие» очрап куйды. Бөтенләй чит кешене «әти» дип йөри башлагач, малаена карата тагын да нәфрәте арта төште. Шуңа күрә ул Илсурга чыккач малае турында искә төшермәскә тырышты. Ә менә бүген ул кинәт кенә бик кирәк булды.

— Ай-һай, хәзер аны әтисе сиңа бирер микән? Мин булсам, бирмәс идем, — диде Илсур Мансурович.

— Бирмәскә аның хакы юк.

— Балага атаның да, ананың да хокукы тигез. Ярар, кайтып карарсың. Дөресен әйткәндә, мин үз улыбыз булуын теләгән идем. Булмады бит. — Илсур Мансурович үкенүле тавыш белән әйтте бу сүзләрне.

Фатыйма аны юатырга теләгәндәй:

— Син яратачаксың аны, Илсур, — диде.

— Ярар, ярар, күрербез. Ләкин алдан кисәтеп куям: малаең килергә теләмәсә, көчләмә.

— Ничек теләмәсен! Күрү белән кочагыма ташланачак, — диде Фатыйма һәм ирен үбеп алды. — Бөтенесе әйбәт булыр.

— Тик кара аны, улыңның берәр кыек эшен сизсәм, икегезне дә куып чыгарачакмын.

Фатыйма бу сүзләрне ишетмәде дә кебек. Аның уйлары күптән инде үзе укыган, шунда яшьлегенең иң татлы җимешләрен койган Н. шәһәрендә иде.

Кара «Форд» кибет янына килеп туктады. Кибеттә җаның ни тели, шул бар, әмма Фатыйма гомерендә беренче мәртәбә үзенә ни кирәген белми аптырап калды. Аның бу халәтен сизгер сатучылар бик тиз күрде.

— Чибәр ханымга ни кирәк икән? — диде берсе һәм: — Әйдәгез, кызлар, сайлашыйк чибәр ханымга кирәк әйберләрен, — дип, кызларга дәште.

— Үзегезгәме, әллә улыгыз яки кызыгызгамы? — дип сорады арадан берсе.

Кибеттә эшләүчеләрнең артык кызыксынуы Фатыйманың ачуын чыгарды. Хәер, монда ачу килерлек нәрсә юклыгын Фатыйма аңлый, әмма бай кеше сәбәпсез дә кызып китәргә, теләсә кемне кимсетергә хаклы дип саный иде ул. Кешедә яшеренеп яткан әрсезлек, әдәпсезлек байлык арткан саен өскәрәк калка һәм кешенең холкын үзгәртә. Кайчандыр сукыр тычкан кебек тавышсыз-тынсыз гына йөргән Фатыйма хәзер сүзләрен бөердән чыгарып әйтә башлады. Кешеләрне кимсетү күңеленә рәхәтлек бирде. Менә әле дә кибетчеләрнең: «Чибәр ханым, нәрсә алырга телисез?» — дип бөтерелеп йөрүләре җанын назлап торды. Башка вакыт булса, бәлки, ул кибетчеләрне үз тирәсендә бераз биеткәннән соң: «Бу хәерчеләр кибете икән, монда миңа ошардай әйбер юк», — дип, берни алмый чыгып киткән булыр иде. Кулыңдагы калын кәшилүкне сикертә-сикертә сатучыларны тәмам ымсындырып бетергәч, аларның әйберләрен хурлап чыгып китүдән дә рәхәт ни бар соң? Бу гамәлең сине алар алдында әллә ничә баскычка күтәрә. Алар бит синең ике катлы, зиннәтле җиһазлар тутырылган өйдә кая барып бәрелергә белмичә, көннәр буе япа-ялгыз саргаеп ятучы гап-гади бер хатын икәнеңне белмиләр. Хәер, гап-гади хатынмы соң ул? Кесәсенә акча күбрәк керә барган саен, күңелдәге гадилек кими бара түгелме? Хәзер ул үзен ниндидер биеклектә сизә. Ә биеккә чыпчыклар түгел, бөркетләр генә оялый. Әнә шулай Фатыйма биеклек белән түбәнлекне бутый башлады.

— Ярый! — диде Фатыйма, күңелендәге уйларын куарга теләп. — Унбер яшьлек малай өчен киемнәр сайлагыз.

— Үзен күрмәгән кешегә кием сайлау авыр инде. Мөмкин булса, әйтегез әле: малаегызның буе ниндирәк? Ябыкмы, тазамы?

Сатучыларның бу сораулары Фатыйманың саруын кайнатты. Шулай да ул ярсып китмәде: чынлап та, аның Заһиты ниндирәк икән хәзер? Аның бит инде улын күрмәгәненә күпме! Атасына охшаса...

Фатыйманың күз алдына ире Гыймай килеп басты. «Фу!» — дип куып җибәргәндәй селтәнгәләп

алды Фатыйма. Аның селтәнүеннән курыккандай, Гыймай юкка чыкты, һәм аның урынына биш ел бергә укыган классташы Заһит пәйда булды. Ул астыртын елмаеп Фатыймага карап тора башлады. «Малайның миннән икәнен онытма!» — дип әйтә иде кебек ул.

Заһит — озын буйлы чибәр егет. Фатыйманы кайда гына ялгыз очратса да, кызның төрле җирләрен чеметкәли, кайвакыт алар әүмәкләшеп китәләр. Андый чакта Фатыйма да кимен куймый: Заһитның кайсы җиреннән эләктерсә, шуннан умырып ала. Көче җитмәгәндә тешләшергә үк тотына. Аларның шаярганын карап торган кеше кыргый җәнлекләр сугыша дип уйлар иде. Бер-берләрен яратудан түгел, ә шушылай котырып үртәшү күп вакыт, әдәп чикләреннән чыгып, азгынлык юлына алып кереп китә. Яшь кан тиз генә сүрелми. Тыелган сызыкны үтеп чыгу аларның йөрәгенә җиңү хисе буып тоела. Шаулап аккан елганың агымына кызыгып һаман эчкәрәк кергәнеңне сизми калган кебек, ике кайнар йөрәк торган саен тирәнгәрәк керергә омтылды. Хәлең барында дулкыннар сине назлый, ә инде көчең кими барган саен алар усаллана, ярсый, ачулана һәм авырттырып-авырттырып кыйный. Суның агымы көтмәгәндә шаярып кына сине бөтереп ала да төпкә суыра. Аң томалана, акыл сизгерлеген югалта.

Фатыйма белән Заһит күп мәртәбә шундый хәлдә калдылар. Калкып чыгуга тагын төпкә чумасылары килде. Төпкәрәк төшкән саен асылташлар күбрәк табылыр төсле тоелды. Әмма көннәрдән бер көнне кыз үзенең «ятьмәсенә чуртан» кереп оялаганын аңлады. Билгеле, бу аңа шатлык китермәде. Кыз бу хакта Заһитка әйткәч, чумышлы уйнаган батыр егеттән җилләр исте.

...Фатыймага кыска буйлы, олы башлы Гыймай күптән кызыгып йөри иде. Кайвакыт кызны туктатып нидер әйтергә тели, әмма Фатыйма өчен Гыймай дигән егет әллә бар, әллә юк. Гыймайның үзен күзәтүе аның ачуын гына китерә.

— Мине сагалап йөрмә, карт пәри, — ди аңа кыз һәм «карт пәри»нең башына кулында ни бар, шуның белән берне менеп төшә.

Гыймайның моңа ачуы килми. Чынлап та, ул Фатыймадан берничә яшькә өлкән һәм кыяфәте белән дә мактанырлыгы юк. Бәлки, пәри Гыймай төсле буладыр?.. Кыска авыр гәүдә, көрәктәй куллар.

«Ятьмәдәге балык» үзен сиздергәли башлагач, Фатыйманың ачуы чыкты. Ничә ел буе Заһит белән шул «елгада» коенып мондый хәлгә юлыкканы булмаганлыктан, ул инде Заһит белән коенган «күлдә» «балык» юктыр дип йөри иде. Менә сиңа мә! Бу «балык» чәбәләнә башлаганчы котылырга кирәк моннан!

Фатыйма табибка китте. Табибә картаеп беткән, өрсәң җаны чыгарга торган сөйкемсез бер ханым иде. Ул, Фатыйманы караганнан соң:

— Сиңа, һичшиксез, табарга кирәк. Котылу турында сүз дә булырга мөмкин түгел, — диде.

— Миңа кирәкми ул. Аны табып сездә калдырып чыгыйммы?

— Үзегез карап үстерерсез.

— Кирәкми! Үгетләмәгез мине.

— Мин үгетләмим. Менә миңа карагыз әле.

Фатыйма аңа текәлебрәк карады. Һәм аның тәне буйлап салкын елан шуышып үткәндәй булды. Табибәнең йөзендә нур юк, күзләре хәрәкәтсез диярлек. Табибә үзенең кыяфәте кызга ничек тәэсир иткәнен күрде.

— Менә сезнең кебек чагымда мин дә «артык йөгем»нән котылырга килдем. Мине үгетләп тормадылар, «йөгем»не, ә «йөгем» белән бергә күзләремнең нурын, йөземнең яктылыгын да суырып алдылар. Күп котыласың — бер тотыласың.

— Бөтен кызлар сезнең кебек булмый бит, — диде Фатыйма. — Бушанучылар дөнья тулы, өр-яңадан тугандай йөриләр.

— Ямьсезләрнең — матурлыгын, тинтәкләрнең акылын суырып алып булмый. Сез чибәр һәм юләр дә түгелдер дип уйлыйм. Сезнең күңел түрегездә яңа җан яралып ята. Җан кыюның зур гөнаһ икәнен әйтеп тормыйм. Ул гөнаһ йөзгә бәреп чыгачак. Төшләрегезгә кереп йокыгыздан уятачак...

— Җитте, сөйләмәгез, — диде Фатыйма һәм бу убырлы карчык яныннан тизрәк чыгып качу ягын карады. Табибәнең сүзләренә ышанмаса да, эченә шом йөгерде.

Ә «ятьмәдәге балык», үзенә куркыныч янавын сизгән кебек, күпмедер вакытка тынып калды.

Фатыйма тизрәк тормышка чыгарга кирәк дигән максат куйды. Шунда ул Гыймайны исенә төшерде. Юри генә Гыймайның юлында очраган булды, юри генә: «Нихәл, мунча пәрие?» — дип чытлыкланып алды. «Мунча пәрие», кызның үзенә мөнәсәбәте үзгәрә баруын сизеп, күңеленнән зур өметләр баглап йөри башлады.

Гыймай гадәттә урынга барып яту белән йоклап китә иде. Әйтерсең киселгән агач — кайсы ягы белән ятса, шул ягы белән тора. Тау күкрәгеннән һәр көн саен ташлар актарып ала-ала аның хәле калмый. Ләкин хөкүмәт таш кисүчеләргә караганда юкны бушка әйләндереп йөрүчеләргә күбрәк түли. Дәүләт өчен чиновниклар кадерлерәк. Алар машинада гына йөри. Эшкә килүгә «каядыр чыккан» була.

Артык арып кайтмаган көннәрдә Гыймай дөньядагы гаделсезлек турында уйланып ята. Менә бүген дә борынын мендәргә төртү белән йоклап китмәде, уйланып ятты. Ә уйлары матур иде аның: Фатыймага өйләнеп үз тормышыңны корып җибәрү. Фатыйма аңа «мунча пәрие» дигән кушамат

таккач, кызны тагын да якынрак күрә башлады. «Яратканга әйтә, яратканга! Яраткан кешеләрне генә шулай үртиләр. Димәк, мин әле кызлар яратырлык егет!»

Гыймай шундый якты, өметле уйлар белән йокыга китте. Әмма йокысы бик тынычсыз булды. Имеш, ул якты алан буйлап, андагы чәчәкләргә сокланып бара. Хозурланып йөрү озакка сузылмый. Ниндидер бер болыт күкнең зәңгәр диңгезеннән агып килә дә Гыймайның баш очында эленеп кала. Кояш сүнә. Гыймайның бөтен тәне буйлап салкын агым агып үтә. Карга өерен кугандай, Гыймай: «Көш! Көш!» — дип болытны куарга тели: куллары белән селтәнә, аланда аунап яткан агач ботакларын ыргыта. Болыт кузгалмый, әйтерсең аны күккә кадаклаганнар. Гыймай кояшлы аланга чыкмакчы була, тик аяклары бик авыр кузгала. Хәле бетеп кояшлы аланга чыгып җиткәндә генә теге болыт тагын да куера төшеп егетнең түбәсенә эленә. Курку белмәгән Гыймайның йөрәгенә шом йөгерә. Ул калтырана башлый.

— Кит әле, болыт, кит моннан! Нигә мине эзәрлеклисең болай? Каплама кояшны, миңа яктылык, җылылык кирәк, — дип кычкыра Гыймай болытка.

Гыймайның тавыш дулкыннары болытка килеп бәрелә, һәм болыт төрле рәвешкә кереп таркала, ә берсе — иң тыгызы, иң авыры — егетнең җилкәсенә менеп атлана. Күпме генә көчәнмәсен, егет болытны иңнәреннән алып ташлый алмый.

Гыймай шабыр тиргә батып уянып китә. Төшен нәрсәгә юрарга да белми, аптырап, миңгерәүләнеп йөри. Бөтенесе әйбәт бара бит югыйсә. Гомергә янына якын җибәрмәгән Фатыйма аңа егет кеше итеп карый башлады. Тынычланырга гына да бит. Эштә вакытларда бераз онытылып торса да, өйгә кайтып ял итәргә яттымы, уйлар болытына урала. Ниһаять, уйлар тоткынлыгыннан арынгандай була егет. Ләкин тынычлыгы озакка бармый, берничә көннән соң икенче бер төш кереп аны аптырашка сала. Бу юлы ул үзенең таудан таш чыгарганын күрә. Ташлар шундый ап-аклар.

— Бу ташлардан өй салып куйсаң, бөтен урамны балкытып торыр иде, — дип уйлый Гыймай һәм беркемгә әйтмичә бу ташларны аерым җыя. Кеше күрмәсен дип, өстен үләннәр белән каплый. Берничә көн җыйган ташларны үзләренә машина белән алып кайтыйм дисә, ни күрә — таш өеме өстендә пычрак итекле кемдер йөри. Ул кешенең итеге тигән ташлар пычранып кына калмый, уала. Тагын шунсы бик гаҗәп: уалгач алар үзләренең аклыгын югалталар. Димәк, эче кара булган.

Уянгач Гыймай: «Бусы нәрсә икән инде тагын? — дип уйлана һәм шундый нәтиҗәгә килә: — Тизрәк өйләнергә кирәк! Тәндәге көч саташтыра мине. Таш кисү ничек авыр булмасын, тәндәге икенче көч үзенекен итә: котырына, куркыта, шомландыра. Шушы котырган көчне чыгармыйча торып тынычлана алмастыр ул, мөгаен».

* * *

Фатыйма, кибеттә малаена кием сайлаганда, озынча буйлы, ябык гәүдәле Заһитны күз алдында тотты. Нинди киемнәр алырга икән дип торганда, кибеткә туптай атылып бер малай килеп керде. Ул нидер алырга кергән идеме икән, ләкин малай авызын ачканчы сатучыларның берсе: «Үскәнем, сиңа ничә яшь әле?» — диде.

— Унбер яшь. Исемем Тимур.

— Әйбәт, әйбәт! — диде сатучы кызлар һәм Фатыймага карадылар.

Фатыйма: «Минем Заһитым нәкъ шушы Тимур кадәр булырга тиеш», — дип уйлады.

— Менә шушы малайга ярарлык киемнәр сайлагыз, — диде ул сатучы кызларга.

— Кышкы киемнәрме, җәйгелектә кияргәме?

— Кышкы да, җәйге дә, яз һәм көзге дә, — диде Фатыйма.

Сатучылар төрлесе төрле якка таралышты. Берсе — спорт костюмы, икенчесе — ботинкалар, өченчесе пальто белән бүрек алып Фатыймага төреп тоттырды. Шунда сатучы кызларның берсе Тимурдан сорап куйды:

— Тимур, синең кебек малайларга иң кирәкле әйбер ни була?

— Туп! — диде малай.

— Туп? Нинди туп?

— Футбол тубы инде, — диде Тимур, шуны да белмисез дигән сыман.

Фатыйма кызларга ымлады: ике туп!

Сатучылар Фатыймага ике туп китереп тоттырдылар. Фатыйма бер тубын Тимурга бирде:

— Мә, рәхәтләнеп уйнагыз!

Малай рәхмәт әйтергә дә онытып чыгып китте. Алган әйберләрен Фатыйманың машинасына төяп җибәрделәр. Фатыйма олы юлга чыгып китте.

* * *

Фатыйма үзенә сөйкемлерәк карый башлауга, Гыймай кыюланып китте. Беркөнне ул Фатыймага: «Чибәркәй, чык миңа кияүгә, кулларымда гына күтәреп йөртермен», — диде. Фатыйма уйга калды.

Аның бу беркатлы «мунча пәрие»н алдыйсы килми иде. Егетнең күзенә карап торганнан соң:
— Кулларыңда күтәреп йөртергә көчең җитәрме соң? — диде. — Без бит...
— Җитәр! — диде Гыймай, кызның сүзен әйттереп бетермичә. — Мин ташчы егет.
— Таштан да авыррак нәрсәләр була.
— Таштан авыррагын да күтәрербез.
— Алайса бел: мин үзем генә түгел...
Гыймай берни аңламады.
— Минем йөгем бар.
— Нинди йөк? — Гыймай һаман берни төшенмәде.
— Хатын-кызда нинди йөк булырга мөмкин соң?
Шуннан соң гына егетнең башына барып җитте. Ул маңгаена күсәк белән тондыргандай аңгыраеп калды. Фатыйма инде китеп барырга уйлаган иде, Гыймай аңына килеп өлгерде.
— Туктале, Фатыйма, — диде ул. — Китмә! Мин сине йөгең белән күтәрәм. — Һәм Гыймай кызны кулларына күтәреп өенә таба атлады.

* * *

Фатыйманың күзләре — юлда, уе — үткәннәрдә. Ә үткәннәр әле Заһитка, әле Гыймайга килеп тоташа. Заһит, Фатыйманың Гыймайга кияүгә чыкканын ишетү белән, качкан җиреннән кире кайтты. Ул Фатыйманы очратырга теләп, бәбкә сагалаган тилгәндәй, Гыймайлар өе тирәсендә әйләнде. Беркөнне Гыймайның эшкә киткәнен күреп, ялт кына ишегалдына сикерде. Фатыйманың болдырга ниндидер савыт күтәреп чыгуы иде. Чит кешенең ишегалдына керүен күреп, чылбырга бәйләнгән Сарбай өрергә тотынды.
— Сарбай, нишләп тавыш куптарасың? Менә бит үзеңә ашарга алып чыктым, — диде Фатыйма, ләкин эт бер генә секундка туктап торды да тагын өрергә тотынды. Фатыйма тыкрык ягына күз салды. Аннан әрекмәннәр арасыннан аксый-аксый Заһит килеп чыкты.
— Заһит? — Фатыйманың күзләре шар булды.
— Аягымны сындырдым, ахры, — диде Заһит, мескен тавыш белән.
— Нишләп йөрисең соң син монда?
— Менә үтеп бара идем, кинәт бер чокырга бастым... Шунда шартлап аяк сынды.
— Сынган аяк белән ничек безнең ишегалдына керә алдың соң син?
— Әй, күп сорашма әле. — Заһит җиргә утырды. Эт тә өрүдән туктады. Фатыйма алып чыккан ашын аның алдына куйды.
— Әйдә, өйгә кер. Аягыңны бәйләргә кирәктер бит, — диде Фатыйма.
Бу сүзләр Заһитның йөрәгенә ефәк булып уралды. Ул аксаклый-аксаклый болдыр баскычыннан менеп өйгә керде. Һәм Фатыйма аны-моны уйлап өлгергәнче, хатынны күтәреп тә алды.
— Ә аяк? — диде Фатыйма.
— Аякка берни булмаган аңа. Сине сагынып кайттым мин, Фатыймам.
Фатыйма Заһитка үпкәле иде. Күңеленнән аны мәңге кичермәскә антлар итте. Ләкин Заһитның куллары үзенең биленә уралуга антлар онытылды, үпкә рәшә булып таралды. Заһит аны караватка күтәреп салды да шашынып үбәргә тотынды. Куллар-аяклар үрелеште. Өй эче мышнаган, чинаган һәм тагын ниндидер ят өннәр белән тулды. Караваттан мендәрләр тәгәрәде. Юрганнар бозау чәйнәгән чүпрәк хәленә керде.
Бераз сөйләшерлек хәлгә килгәч, Фатыйма:
— Нигә теге вакыт качтың син? — диде.
— Качмадым. Срочно военкоматка чакырдылар.
— Сине армиягә алдылармыни?
— Юк. Әтиләр акча түләп ансын җайлады.
— Алайса син хәзер иректә?
— Ничек «иректә»?
— Соң, армиягә китәсең юк. — Фатыйма бераз сүзсез торды. — Мин бит Гыймайга бала ятим тумасын дип кенә чыктым.
— Дура! — диде Заһит. — Аңардан котылу бер тапкыр бәдрәфкә барып килү кебек кенә бит. Котылырга кирәк иде.
— Син бит мине яратасың, Заһит. Әйдә, хәзер үк үзегезгә алып кит мине.
— Ярату ул — язучылар уйлап чыгарган әкият. Шул әкияткә кешеләр үзләрен ышандырырга тели.
— Алайса, ни пычагыма минем яныма килеп йөрисең?
— Синең җенең тарта мине. Шул җенгә иләштем.
— Син әйткән җен, бәлки, минем мәхәббәтемдер.
— Бәлки. Минем мондый сорауларга җавап эзләп утырасым килми.

— Яратасың, яратасың. Миннән башка тора алмаганга киләсең син, — дип, Фатыйма сүзне шаяруга күчерергә тырышты. Заһитның да бу мәсьәләдә тирәнгә керәсе килми иде. Ул Фатыйманы күтәреп алды.

— Фатыймакай, мин сине беркайчан да ташламаячакмын. Тормышым бераз көйләнү белән, үземә алып китәрмен. Ә хәзергә... — Заһит китәргә җыена башлады, Фатыйма, аңа ябышып:

— Тормышны бергә җайларбыз. Алып кит мине моннан. Минем «мунча пәрие» белән яшисем килми.

— Ни бит... — Заһит ни әйтергә белми торды. — Ни бит, Фатыймакай. Мин сине бу йортта бер көн тотмас идем. Мин бит армиядән качып йөрим.

— Әниләр акча түләп алып калдылар, дигән идең түгелме?

— Бу алып калулар вакытлыча гына булды. Теләсә кайсы көнне муеныма камыт кидерергә мөмкиннәр минем. Бер-беребезне төрле сораулар белән интектермик әле, Фатыймакай-гөлкәй. — Заһит Фатыйманы өр-яңадан үзенең назларына күмеп ташлады. Заһит кочагында Фатыйма тәмам эреде. — Һәрвакыт ирекле булып калыйк. Ир белән тору иркеңне авызлыклау түгел. Сусаган саен су эчерергә Гыймаең кирәк сиңа. Артык сусатып интектермиме соң «мунча пәрием»?

Фатыйма Заһитның колагына нидер әйтте. Алар икесе дә көләргә тотындылар. Көлүдән туктагач, Заһит:

— Алайса, ул яктан уңгансың икән, — диде.

— Әйе. Мунчага барсам, бөтен кеше миңа карый, дип, ул шәһәр мунчасына да йөрми. Әтиләренең мунчасына йөрибез.

Заһит әкрен-әкрен Фатыйманың күңел серләрен суырды. Китәр алдыннан ул, бик кыенсынган рәвешкә кереп:

— Фатыймакай-гөлкәй, әгәр синнән бер әйбер сорасам, арабызга күләгә төшмәс микән?

— Нәрсә сорамакчы буласың?

— Аны әйтергә дә кыен инде. — Заһит оятлы эш эшләгәндәй түбән карап, аягының баш бармагы белән идәнне «чокып» торды, аннары, Фатыйманың күзләренә карап: — Бик кыен хәлдә калдым бит әле мин, Фатыймакай, — диде.

— Нинди кыен хәл?

— Акча кирәгие.

— Бик күп кирәкмени?

— Кемгә күп, кемгә әз.

— Шулай да?..

— Ун мең!

— Әстәгъфирулла! Нишлисең ул кадәр акча белән?

— Әтиләр мине армиядән коткарыр өчен бик күп әҗәт җыйганнар. Хәзер акча биреп торучылар шуларны тыкырдаталар. Җитмәсә, процент белән. Тиз арада табып бирмәсәң, берәр караңгы почмакта тончыктырабыз, диләр. Әле бу түлисе акчаның уннан бере генә.

Фатыйма уйга калды. Ире аның эштән соң кешеләргә рамнар ясап шактый акча таба. Ләкин аны аңардан ничек сорарга?! Хәер, Фатыймага бит ул: «Үз кирәгеңә тотарсың», — дип, ай саен шактый акча биреп бара. Туктале... Фатыйма, урындыкка басып, шкаф өстенә куелган бер тартма алып төште. Анда биш меңләп акча бар икән. Ике уйлап тормастан шуларны Заһитка тоттырды. Заһит бик тиз генә акчаларны йомарлап кесәсенә тыкты, ә үзенең күзләре тартмадагы алтын муенсага төште.

— Бик кыен инде миңа синең алда, Фатыймам минем. Әмма ләкин бу биш мең генә безнең әтине үлемнән коткармас шул... — Заһит Фатыйманың алтын чылбырын кулына алды.

— Нинди матур. Бик кыйбаттыр инде бу?

— Кыйбат! Аны туй бүләге итеп миңа Гыймай алып бирде. Менә балдак белән. — Фатыйма Заһитка кулындагы алтын балдагын күрсәтте.

— Киеп карыйм әле шул балдагыңны, мөмкин булса, — диде Заһит. — Юкса минем андый кыйбатлы әйберләрне тотып караган юк.

Фатыйма балдагын Заһитның учына салды. Заһит әле алтын чылбырга, әле балдакка карап сокланып торды. Хәер, бу соклану түгел, корбанына караган ерткыч карашы иде.

— Боларын да миңа биреп тормассыңмы, дисәм, оятсызлыкка китәр инде.

— Синең өчен берни җәл түгел, Заһиткаем. Тик Гыймай, теге алтын әйберләреңне нигә кимисең, дип сораса?

— Юк, алмыйм! — диде Заһит. — Акчаларыңны да кире кайтарам. — Ул хатын-кызның психологиясен шактый нык белә иде. Шуңа күрә кесәсендәге акчаларын Фатыймага кайтарып бирде. Заһит бу гамәле белән Фатыйманың мин-минлегенә тиячәген аңлый иде. Һәм ул Фатыймага тагын да ныграк басым ясарга теләп, чыгып китәргә ашыккан кеше кебек, нәрсәдер эзләде, кабаланды. Аннары кырт кына: — Йә, хуш! — диде.

— Туктале, — диде Фатыйма. — Әтиләрең җәл түгелмени?

— Җәл, конечно. Ну син, Фатыймакай, минем өчен бөтен кешедән дә кадерле. Минем аркада Гыймаең белән арагыз бозылып китсә...

— Гыймай бичара бер бозау ул. Мә, ал акчаларны, алтын әйберләрне.

— Юк, юк, — дип каршы төшкән булды Заһит. Ә үзенең йөрәге доң-доң тибә, күзләре яна иде. Әмма Фатыйманың күңелен тагын бер айкап алуны кирәк тапты: — Җанымнан артык күргән кешедән ничек шулкадәр байлык алыйм? Ничек оялмыйча синнән сорый алдым икән дип шаккатып утырам әле. Ахмак мин. Синең исеңнән исереп башын җуйган ахмак.

Әле генә мәхәббәт юк ул дип бәхәсләшеп утырганын онытып, Заһит бөтенләй башкача сайрый башлады. Бер мизгел эчендә ул үзенең үткән тормышын, Фатыйма белән танышуларын хәтер сукмагы аша уздырып алды. Әтисе аварриягә эләгеп үлгәннән соң, кырыгын уздыруга ук әнисе килмешәк бер үзбәккә кияүгә чыкты. Малай тәртипсезләнде. Үги әтисенең ботинкаларына яки куртка кесәләренә бака салып куя иде. Үзбәк Заһитның ыштанын төшереп каеш белән каезлый. Әнисе үзбәктән әллә курка, әллә улын яратып бетерми — иренә каршы төшми. Ә бер елдан үз балалары тугач, Заһитка өйдә урын калмады. Аны балалар йортына тапшырдылар. Балалар йортында Заһит бөтенләй азды: урлашу дисеңме, үзеннән кечеләрне кыйнау дисеңме — берсе дә калмады. Тәрбиячеләр, улыңны моннан ал, дип, әнисенә әйтеп-әйтеп карадылар. Ләкин ана үзбәк сүзеннән чыга алмады. Өч елдан соң Заһитны әтисенең энесе Сәгыйть, үзләренә алдырып, интернат-мәктәпкә урнаштырды. Бу интернатта укучыларның күпчелеге авыл балалары булганлыктан, басынкылар, йомшаклар иде. Заһит беренче мәртәбә Фатыйманы шунда очратты. Кыз, башкалар кебек авылдан килсә дә, үзен шактый иркле тота иде.

— Һәй, сары чыпчык, исемең ничек синең?

— Синеке кебек Заһит-маһит түгел инде, — диде кыз һәм классына йөгереп кереп китте.

— Кара син аны, минем исемне белә! — дип горурланды Заһит.

...Фатыйманың да йөрәге аша үткәннәрнең кайнар агымы узды, ахры. Ул һич икеләнмичә әйберләрен Заһитка сузды.

— Мә, ал, йә кире уйлый башлармын.

Фатыйма акчаларын һәм алтын әйберләрен бер кулъяулыкка төреп Заһитның кесәсенә салды.

— Мин аларны бик тиз кайтарачакмын сиңа. Себердә безнең әтинең энесе нефть эшендә эшли. Аңардан берәр атна эчендә йөз мең сум акча килеп төшәргә тиеш. Шул килеп җитү белән...

Заһит чыгып китәргә торганда гына эт өрергә тотынды. Икесе дә сагаеп калды. Фатыйма әллә Гыймай кайттымы дип пошамаңга төште, чөнки Сарбай Гыймайны шулай шатланып каршы ала иде. Фатыйма сак кына ишекне ачып тышка чыкты. Гыймайның әтисе үтеп бара, эт шуңа өргән икән. Эшнең нәрсәдә икәнен белгәч, һәр икесе җиңел сулап куйды. Аласын алган Заһит тиз арада чыгып китү ягын карады.

Шул китүдән Заһит айдан артык күренмәде. Менә ул беркөнне тагын Фатыймалар өе тирәсендә әйләнеп йөри башлады. Өйдә Гыймай юкмы — шуны тикшерүе иде аның. Койма ярыгына авызын куеп әкрен генә Сарбайга дәште: «Сарбай җанаш, өйдә кемнәр барын әйтмәссеңме?»

Заһитның тавышына эт өрергә тотынды. Өйдән Фатыйма чыкты.

— Фатыймакай, мин синең Заһитың. Өйдә үзең генәме?

— Әйе.

Шул сүзне ишетүгә, Заһит койма аша ишегалдына сикерде. Ул колачын җәеп Фатыймага таба килә башлаган иде, хатын артка чигенде. Заһитның өс-башы пычрак, күз төпләре күгәргән, битендә ниндидер яра эзе.

— Курыктыңмы, кадерлем? Әйе, минем кыяфәттән куркырлык шул.

— Нәрсә булды, Заһит?

— Әй, сорама, Фатыймакай.

— Шулай да?..

— Сиңа теге акчаларны китергәндә ниндидер шайка юлыма каршы төште дә тартырга сорады. Тартмыйм, дигәч, икесе килеп кулларымны тотты, берсе битемә пычак очы терәп торды, калганнары кесәләремне актарырга тотынды. Кесәмдә синең алтын әйберләрең белән бергә теге Себердә эшләүче абзый җибәргән йөз мең акчаның илле меңе бар иде.

— Нишләп кесәңә шулкадәр акча салып йөрисең? Безнең шәһәр шпаналар шәһәре икәнен белмисеңмени?

— Беләм, җаным, беләм. Син миңа шулкадәр яхшылык эшләгәч, минем дә бурычлы булып каласым килмәде. Мин яхшылыкны бише белән кайтара торган кеше.

— И җүләрем минем! Нигә миңа шулкадәр акча? Әтиләреңнең әҗәтен түләргә идең.

Фатыйма Заһитның әтисе күптән вафат булганлыгын, әнисенең ниндидер билгесез эш белән шөгыльләнүче үзбәккә чыгуын, Заһитның күпмедер вакыт балалар йортында тәрбияләнүен белми иде. Заһит үзенең эчке дөньясын иң якын дусларына да ачмады. Сәгыйть абзыйсы интернат-мәктәпкә урнаштыргач та әти-әниләре турында сораштыручы булса: «Алар Америкага акча эшләргә киттеләр»,

— дия иде. Күпләр моңа ышана, чөнки ял көннәрендә бик шәп импортный «джип» Заһитны абыйларына алып кайта иде. Егетнең: «Армиядән коткарып калырга эти-әниләр йөз мең акча түләделәр», — диюе Фатыйманың күңелен йомшартып акча алу һәм шуның белән уен автоматларында оттырган бурычын түләү иде. Теге вакыт Фатыйма акчалары аны афәттән коткарып калган иде, ләкин яңадан зур сумма оттырып түләми йөри башлагач, беренче юлга кисәтү йөзеннән бик каты тәпәләп ташладылар. Заһитның канлы күлмәкләре белән Фатыймаларга килүе үзенең «дуслары»ннан качуы иде.

Фатыйма Заһитны өенә чакырды.

— Урман — колак, кыр — күз, ишегалдының да күзе булырга мөмкин, — диде ул.

Фатыйма Заһитка булган хисләрен аңлатып та бирә алмый. Заһит югында ул аны онытып тора: әйтерсең Заһит — конфет, ә Фатыйма — кечкенә бала. Бала бит конфет булмаганда аны уйлап та карамый, ә инде матур кәгазьгә төрелгән конфет күрсә, тәкатьсезләнеп әти-әнисеннән шул мәмине сорый.

Фатыйма өчен Заһит — матур кәгазьгә төрелгән конфет. Ләкин ул ялтыравыклы кәгазь эчендә нәрсә икәнлеген һич белә алмый, чөнки Заһит һәр килүендә башка «кәгазьгә төрелгән» була. Егет артык оялчанмы, куркакмы — һич аңларлык түгел. Өйгә керергә чакыргач та, ул шактый ялындырды.

— Мондый пычрак өс-башым белән ничек синең кершәндәй ак идәнеңә басыйм?

— Әйдә, әйдә, идән пычранса, тагын юармын.

— Юк инде, Фатыйма, мин китим генә.

— Шушы килеш урамга чыгасыңмы?

— Миннән шакшылар да йөри әле.

— Минем сине чип-чиста йөртәсем килә. Син бит минем туачак улымның атасы. — Фатыйма шактый тулыланып килгән корсагын ышкып куйды.

— Йә, ярар алайса, керәм.

Заһитның бала турында ишетәсе килми иде, ул сүзне икенчегә борырга ашыкты:

— Өегез бигрәк нурлы сезнең, Фатыйма. Синең йөзең төсле.

Егетнең мактавы Фатыйма күңеленә сары май булып ятты.

Өйгә кергәч, ул Заһитны анадан тума чишендерде.

— Мин хәзер синең бу шакшы киемнәреңне тиз генә машинага салып алам.

— О-о! — диде Заһит, ризасызлык күрсәтеп. — Синең ул машинаң минем әйберләрне ике-өч сәгать болгатачак. Мин сездә ике-өч сәгать ыштансыз утырырмынмы?

— Ә нигә? Утырырсың, утырасың килмәсә, ятып торырсың.

— Ирең кайтып керсә?

— Әй куркак та инде үзең.

— Мин синең өчен куркам, җүләр. Минем аркада арагыз бозылмасын дим.

— Бозылмас! — диде Фатыйма, катгый итеп, һәм Заһитның киемнәрен кер юу машинасына чумдырды.

— Бер сәгатьтән киемнәрең юылган һәм кипкән булыр. Ә син өстеңә менә бу халатны киеп тор, күрше-күлән керүе мөмкин.

Заһит Фатыйма биргән халатны киеп куйды. Ул хатын-кыз халаты булып чыкты. Өстәвенә берничә төймәсе дә юк икән. Заһит көзге каршына килеп басты да үзеннән-үзе көләргә тотынды.

— Нәрсә бар? — диде Фатыйма.

— Кил әле, кил. Ни барын үзең күрерсең.

Фатыйма Заһит янына килде һәм ул да көләргә тотынды. Анда көзгедә халатның төймәсез урыныннан мәче башлы ябалак карап тора иде.

— Каян кергән ул анда, әллә урманда йөрдеңме? — дигән булды Фатыйма.

— Урман аша үткән идем шул, — диде Заһит, шаяруга каршы шаяру белән.

— Гадәттә, ябалаклар төнлә генә оча торган иде. Яктыда бит алар күрмиләр.

— Ә без хәзер төн ясыйбыз. — Заһит калын пәрдәләрне төшерде. Өй караңгыланып китте. — Менә караңгы төште, ябалак очар вакыт җитте.

— Кара син нинди тылсымчы икәнсең. Бу һөнәреңне белми идем әле.

Шулай шаярыша-шаярыша караватка аудылар.

Тагын мендәрләр ишелеп төште, тагын бөтен нәрсә йомарланып бетте. Фатыйма башта саграк кыланырга маташкан иде, ләкин кызып киткәч, кабара башлаган корсак онытылды.

Вакыт бик аз үткән кебек тоелган иде, тик кер юу машинасы үзенең эше беткәнен белгертеп сызгырып куйды. Фатыйма сикереп торып машинадан керләрне алды. Алар юылган, кипкән иде. Фатыйма аларны үтүкли башлады. Заһитның карыны бик ачкан иде, кухняга кереп суыткычта актарынырга кереште. Суыткыч бай булып чыкты. Заһит, гомергә ризык күрмәгән кешедәй, бер кулына — казылык, икенче кулына кыйммәтле сыр эләктерде. Ризыкларның әле берсен, әле икенчесен авызына дөмбәсләп маташканда, аның күзе бер шешәгә төште. Шешәне ачып башта иснәде (уксус-

мазар түгелме). Юк, түгел икән — спирт исе килә. Заһит голт-голт итеп эчемлекне йотты. Шешәдә аракы түгел, чын спирт булып чыкты. Заһит исерә башлаганын сизде, ә аңа исерергә ярамый, юкса кармакка кабуы бар.

Ул, бераз капкалагач, Фатыйманың халатын салып ташлап, әрле-бирле йөренә башлады. Киемнәрен үтүкләп маташкан Фатыйма янына чыкты.

— Мә, чалбарыңны кия тор.

Чалбар артыннан башкалары әзер булды.

— Бигрәк уңган хатын син. Әгәр мөмкинлегем булса, сине беркемгә бирмәс идем. Наз белән күмеп тотар идем үзеңне. Кочагымнан чыгармас идем.

— Тел бар инде үзеңдә.

— Тел генә түгел бит, Фатыймам. — Заһит Фатыйманың корсагын сыйпап: — Менә моны бит тел белән кабартып булмый.

— Җитте инде, мактанма. Ул ишәктә дә бар.

Заһит ашыга иде, сүз куертып маташмады. Ашыгуына карамастан, ул һаман ишек төбендә таптанды. Нәрсәдер сорыйсы килгәнлеге әллә каян күренеп тора иде.

— Фатыймакай-җанкай, — диде хатынга сырпаланып. — Бу дөньяда синнән шәп кеше юктыр, валлаһи. Матурлыгыңны әйтмим, ансы болай да күренеп тора. Хәзерге хатын-кызларда сирәк очрый торган йомшаклык, шәфкатьлелек, юмартлык бар синдә. Художник булсам, мин синең портретыңны ясар һәм аны «Гүзәллек» дип атар идем.

Фатыйма Заһитны бераз аңлый башлаган иде инде: бу мактау артында нәрсә яшеренгәнен көтте. Заһит озак көттермәде, Фатыйманы кочаклап алып мышный башлады. Хатын, аның чәчләреннән сыйпап:

— Нәрсә булды? — диде.

— Соң, әйттем бит: сиңа акча китергәндә бандитлар таладылар, дип. Менә хәзер бер тиенсез калдым. Автобуска түләргә дә акчам юк. Ә күпме әҗәт түлисебез бар.

— Әҗәтле үлми, — диде Фатыйма. — Озаграк яшәрсең.

— Фатыймакай-җанкай, беләсең килсә, минем дөньяда яшисем килми. Әгәр син бумасаң, әллә кайчан үземне-үзем буып үтерә идем инде. — Заһит рольгә кергәннән керә барып, ике кулы белән бугазын буа башлады. Егетнең күзләре акайды. Фатыйма куркып Заһитның кулларына килеп ябышты.

— Җүләрләнмә, Заһитым. Менә бит синең яраткан Фатыймаң янында. Әҗәт дип инде. Табарбыз. Түләрбез.

Акча бит ул — мунчала,
Юынабыз, сөртенәбез
Акча белән мунчада, —

дип җырлый иде безнең авылда бер карт. Шул мунчада сөртенә торган мунчала өчен үлеп торалармы?! Күпме кирәк?

— Күп түгел, бер-ике мең генә.

Кичә генә Гыймайга кемнеңдер бакчасында парник ясаган өчен шактый акча китергәннәр иде. Гыймай, ул акчаларны Фатыймага биргәндә:

— Тиздән малай туар вакыт җитә. Бишекле арбалар караштырып йөри башладым инде, ә син вак-төякләр алгала, — дигән иде. Фатыйма ике уйлап тормастан шул акчаларны Заһитка китереп тоттырды:

— Мә, саграк йөр!

— Рәхмәт, кадерлем. Мин синең алдыңда гомерем белән бурычлы. — Ул пафоска бирелеп Фатыйма алдында тезләнде дә хатынның аякларын үбәргә тотынды.

Фатыйма, кыенсынып:

— Кирәкми, Заһит, алай түбәнсенмә, — дип аякларын кымшата башлаган иде, Заһит, аларны тагын да катырак кысып, тубыктан — тезгә, тездән тагын да өскәрәк менә башлады:

— Син фәрештә бит, Фатыймакай. Фәрештәнең кай җирен үпсәң дә савап кына.

Бөтен тәне һәрвакыт наз сорап торган хатынга җитә калды. Ул бөтенләй эреп төште. Хәтта өстендәге күлмәген кайчан салып ташлаганын да хәтерләмәде. Үзе дә ниндидер хайвани комсызлык белән Заһитны үбә башлады. Заһит Фатыймадан бу кадәрлесен үк көтмәгән иде: гаҗәпләнү катыш рәхәтлек тоеп басып торды.

— Син минем мәңгелек мәхәббәтем, Фатыймакай, — диде чыгып киткәндә Заһит. — Озаграк килә алмый торсам, онытты дип уйлама. Син онытыла торган кеше түгел.

— Мине дә ал үзең белән. Ни күрсәк тә, бергә күрербез, Заһит, — диде Фатыйма.

— Юк, кадерлем. Сине куркыныч астына куйсам, мин кем булам. Хәзер бит безнең малаебыз туарга тора. Ә минем сине апкайтырлык шалашым да юк. Йә, хуш, җаныем. Дөньям рәтләнгәч, барыбер эзләп табачакмын, ансына шикләнмә!

Заһит шулай дип чыгып китте һәм шул китүдән юк булды.

Фатыйма гел Заһитны көтте. Заһит турында төрле хәбәрләр йөрде. Имеш, ул фатирлар басып йөргәндә тотылган һәм хәзер төрмәдә утыра. Икенче берәүләр аны урамда хатын-кызларның алка, йөзек, муенса ише кыйммәтле әйберләрен талаганда күргән. Фатыйма боларның берсенә дә ышанмады. Заһит — хатын-кызга илаһилаштырып караучы зат. Әгәр аның турында берәр хатын-кызны артык иркәләп интектергән дисәләр, ышаныр иде. Теге көнне Фатыйманың аяк бармакларыннан алып борын очына кадәр үбеп чыкты бит.

* * *

Гыймай хатыны үзенә хыянәт итәдер дип башына да китермәде. Авырлы килеш алгач, Фатыйма рәхмәт укыйдыр дип йөрде. Үзе һичбер вакыт бу турыда сүз кузгатмады. Хәтта карашы белән дә хатынын рәнҗетмәде. Бүген кайтып кергәндә хатынының эчтән генә җырлап йөрүен ишетеп:

— Минем хатынкайның күңеле күтәренке. Әллә берәр шатлыклы хәбәр бармы?

— Бар, — диде Фатыйма.

— Бәлки, миңа да әйтерсең, икәүләп шатланырбыз.

— Әйтәм, нигә әйтмәскә! — Фатыйма корсагын уып алды. — Улым тыпырчына башлады.

— Улыбыз, диген.

— Улыбыз, алайса.

— Кая әле, кая, мин дә тыңлап карыйм. — Гыймай хатынының эченә башын куйды. Тик бернинди тыпырчыну тоймады. — Халатың кыштырдый, кая, чишик әле төймәләрен.

— Көпә-көндез! Мин оялам.

— Нигә оялырга? Без бит ир белән хатын.

— Юк, юк, салмыйм. Төнлә тыңларсың. — Фатыйма Заһит котырып үпкән урыннарда эз калгандыр дип курыкканлыктан халатына чат ябышты. Әмма Гыймай үҗәт булып чыкты. Ул, ярым көчләп, ярым үгетләп, Фатыйманың халат төймәләрен ычкындырды. Ул тезләнеп Фатыйманың корсагына колагын куйды. Озак кына тыңлаганнан соң: «Ишетелә!» — диде һәм хатынын күтәреп алды. Шунда, гөнаһ шомлыгына каршы, барлык төймәләр ычкынып китте. Гыймай хатынының тәненә текәлеп карарга ояла иде, ләкин бүген аның карашы хатынының бөтен тәне буйлап йөгереп үтте.

— Бу ни? — диде Фатыйманың чуарланып беткән тәненә карап.

— Үзем дә белмим, — диде хатыны, — аллергия, ахрысы.

— Нәрсә ашаган идең соң?

— Хәтерләмим дә инде. Бакчада кишерләр бик матур үсеп килә икән. Шуларны ашаган идем. Көндез лимонлы чәй эчтем. Көне буе нәрсә ашаганыңны хәтерләп бетереп буламыни?

— Бөтен тәнеңне баскан бит бу, — диде беркатлы Гыймай.

— Бетәр әле, кайгырма! — Фатыйма халат төймәләрен каптырмакчы иде, ләкин бик борчылган ир хатынының бөтен җирен тикшереп чыкмыйча туктамады.

— Ими башларыңа кадәр кызарган бит, бәлки, экземадыр бу.

Фатыйманың ачуы килде. Ул Гыймайны читкәрәк этте.

— Җитте, тикшеренмә, йөкле хатында нинди үзгәрешләр булмас.

— Менә шуның өчен әйтәм бит: табибка барырга кирәк.

— Ярар, барырмын.

— Иртәгә үк бар.

Сүз бу хакта яңадан кузгатылмады. Гыймай үзенең мастерскоена чыгып китте. Бетерәсе эшләре бар иде. Ләкин ничек кенә тырышмасын, бүген аның эше бармады. Кулыннан әле бер, әле икенче коралы төшеп китте. Күз алдыннан һаман Фатыйманың чуарланган тәне китмәде. Өйләнгәнче аның хатын-кыз тәне күргәне булмады. Хәер, бер мәртәбә үзләре белән бергә эшли торган дусты аны үзенең туган көненә чакырган иде. Аракы өстәл тулы. Хатын-кызлар да рюмкаларын каплап кына куялар. Шунда берсе: «Уф, мин кыздым. Чишенәм әле», — дип, түшендәге төймәләрен ычкындыра башлады. Аңа икенче бүлмәгә кереп чишенергә куштылар. Ул кереп китте, ләкин бераздан аның кычкырганы ишетелде: «Берәрегез керегез әле, юбкамның молниясе ватылган. Ни өстән салып булмый, ни астан».

Мәҗлестә бөтенесе парлашып беткәннәр иде, Гыймайны кертеп җибәрделәр. Гыймай кергәндә, хатын ярым чишенгән, бары тик шул каһәр төшкән юбкасын гына сала алмый иде. Гыймай кызның ачык күкрәгенә күз салмаска тырышты. Итәкнең замогы чынлап та ватылган. Ни өскә, ни аска төшми. Мондый эшләрдә Гыймайның маһирлыгы юк иде. Ул тегеләй маташты, болай азапланды — булдыра алмады. Исерүе җиткән кыз Гыймайны этеп җибәрде дә итәк молниясен аерып җибәрде. Һәм үзе әллә башы әйләнеп, әллә исереп идәнгә егылды. Гыймай аны караватка күтәреп салмакчы булган иде, кыз аның муеныннан эләктереп алды. Хатын-кыз тәне кагылгач, Гыймайда егетлек хисләре калкып куйды, тик ул үзенең нәфесен тыя алды.

— Пешмәгән нәрсә! — дип калды аның артыннан кыз.

Шуннан башка Гыймайга хатын-кыз тәне күрергә туры килмәде. Тик, бер генә күрүгә карамастан,

күп мәртәбә егетнең күз алдына килеп йөдәтте ул.

Ул мәҗлестә тәне экземалы бер егет бар иде. Өй бөркүләнгәч ул да күлмәген салып атты. Аның экземасы ничектер болай кызармаган, ә Фатыйманыкы бит... Тфү, тфү, әстәгъфирулла, әллә нинди гөнаһлы уйлар килә башка. Әйе, Фатыйманың тәне суырып үпкәнгә охшый. Алай дисәң, нигә ул кызыл эзләр ботларда бар? Ботны үпмиләр бит инде. Юк, юк. Фатыйма — әйбәт хатын. Тегендә-монда чыгып йөрми, гел өйдә. Җитмәсә, болдырда эт ята. Сарбай бик усал. Фатыйма турында начар уйлап гөнаһлы булырсың, валлаһи!

Вакыт үзенекен итте. Гөнаһ эзләре юкка чыкты. Озакламый ул малай тапты. Аңа Заһит дип исем куштылар. Малайны Гыймай да, аның әти-әниләре дә бик яратты. Заһит бик тере малай булып үсте. Урамга чыгып йөри башлауга, берәрсе белән сугышып кайтты.

— Кемгә охшаган бу малай? — дип аптырашты әби-бабасы.

— Үземә охшаган, — диде Гыймай, сүзне озакка сузмас өчен.

Улының сүзен әтисе эләктереп алды.

— Әле беркөнне телевизордан күрсәттеләр, — диде ул, — сап-сары урыс белән марҗадан кап-кара негр малае туган.

— Ахырзаман галәмәте, — дип кушылды картына Әдибә карчык.

Заһит турында сүзләр шактый куерырга мөмкин иде, ләкин Гыймай бу әңгәмәгә нокта куйды.

— Малайга күз тидерәсез, җитте! — диде ул, кискен итеп. — Яңадан бу турыда сүз кузгатмагыз.

Малайның үзенеке булмавы вакыт-вакыт Гыймайның йөрәген чеметеп ала иде. Ләкин җанындагы рәнҗүне һичбер вакыт тышка чыгармады. Фатыймасын артык ярата иде шул.

Хәтергә Фатыймага кызыгып, сокланып йөргән чаклар төшә. Фатыйма кибеттә эшли. Гыймай эштән кайтышлый, һәр көнне шул кибеткә кереп, ипидер, сөттер ише ризыклар ала. Дөрес, бу кибет ул кайта торган юл өстендә түгел, ләкин анда Фатыйма эшли. Гыймай читтән генә Фатыйманың җитез хәрәкәтләрен карап торырга ярата. Әйберне ул һәрвакыт Фатыймадан ала. Кайвакыт Гыймайга ипи яки сөт сузганда, сатучы кызның ап-ак куллары аңа тиеп китә. Ул көнне Гыймай бәхетле. Күңеленә генә сыймаган бәхет сөенеч һәм җыр булып тышка бәреп чыга.

Ал да булырбыз әле,
Гөл дә булырбыз әле;
Алда бәхеткәйләр булса,
Бергә булырбыз әле.

Гыймайны барлык сатучылар танып бетерде. Товарны гел Фатыймадан алганга, кибеттә Гыймайның пәке белән кырылган олы башы күренүгә:

— Фатыйма, синең кавалерың килгән, йөгереп чыгып хезмәт күрсәт үзенә, — дип, кызны үртиләр.

Фатыйма иптәшләренә:

— Нинди кавалер? Мунча пәрие бит ул. Андый кавалерың булудан Аллам сакласын, — ди. Ләкин кибеткә кергән кешене елмаеп каршы алмый хәлең юк.

Тора-бара кушаматы «мунча пәрие» икәнен Гыймай үзе дә белеп алды. Ләкин мондый кушамат тагуларына һич үпкәләмәде. «Ә нигә? — дип уйлады ул. — Мунча пәрие булу начармыни? Мунча — чистарыну урыны. Кешеләр юынганнан соң, мунча пәриләре үзләре хуҗа булып кала. Юыналардыр, чистарыналардыр. Ә инде кыяфәткә килгәндә, берни эшләп булмый. Ходай шулай яраткан. Матурлык төшенчәсен һәркем үзенчә аңлый бит. Гыймай гарип-гораба түгел. Тазалыгы Аллага шөкер. Бервакыт авылдан кайтканда дустының машинасы баткан иде. Буксовать иттерә-иттерә тәгәрмәч асларыннан төтеннәр чыга башлады. Шунда Гыймай сүзсез-нисез генә төште дә машинаның арт ягыннан күтәрде. Баткан җиреннән машина выжлап чыгып китте.

* * *

Без ир-атлар хатын-кызның нәфис зат икәнен онытып җибәрәбез. Аларны үзебезгә караганда икеләтә күбрәк эшләтәбез. Эштән кайткач керен юа, ашарга пешерә. Ни генә эшләмә — химия. Көзге чистартсаң да, тәрәзә юсаң да, химиядән ясалган порошок. Бәлки, әнә шул порошокның берәрсе аңа ярамагандыр.

Гыймай хатынын шулай үзенчә акларга тырышты. Заһит тугач, Фатыйма күбрәк вакытын бала карауга бирде. Анда-монда чыкмады, ят кешеләр белән очрашканы сизелмәде. Димәк, азгынлык түгел, белмәгән-күрмәгән килеш гөнаһлы булырга ярамый. Дөрес, балага бишекле арба алырга дип, теге вакыт биргән акчаларны сорагач, Фатыйма кинәт коелып төште, ләкин үзен тиз кулга алды: акчаны шкаф тартмаларыннан, сандык төпләреннән эзләп маташты. Аннары исенә нидер төшергәндәй:

— Әй, бөтенләй онытып торам икән: беркөн өйгә көтүләре белән чегәннәр кергән иде. Берсенең кечкенә баласы бар иде. Ул баласын диванга салды да: «Баланың асты юешләнгән икән, алыштырырга берәр чүпрәгең юкмы?» — диде. Мин теге якка чүпрәк эзләргә чыгып киттем. Кабаланганда тиз генә әйбере табыламы соң аның?! Байтак эзләнеп йөргәч, үземнең иске халатны чыгарып бирдем. Шул

чакта актарганнардыр инде. Югыйсә өйгә ят кешеләр кергәне юк.

— Рәзе чегән өерен өйгә кертергә ярый?! — диде Гыймай, кызмый гына.

— Балалары да булгач керткән идем шул.

— Бигрәк киң күңелле инде үзең. Минем кебек мунча пәриенә кияүгә чыгуың гына да сине барлык хатын-кыздан югары күтәрә.

Сүз шуның белән бетте, ләкин Фатыйманың күңелендә бер уй яктырып китте: «Бу бит бик шәп дәлил, бөтен нәрсәне чегәннәргә сылтарга була».

Һәм ул сикереп торып үзенең алтын әйберләре саклана торган кечкенә тартманы диван астыннан тартып чыгарды. Билгеле инде, анда берни дә юк иде. Фатыйма кычкырып еларга тотынды: «Ах, кабахәтләр. Минем бөтен алтын әйберләремне чәлгәннәр. Син алып биргән муенса гына калган булса да, бу кадәр йөрәгем янмас иде».

Гыймай бер сүз дәшми идән уртасында басып торды. Күңелендә нindидер давыл кузгалам-кузгалам дип торды. Беренче мәртәбә хатынына ышанып бетмәде. Әмма Фатыйма шулкадәр гөнаһсыз төстә елый, күкрәгеңә кысып юатмый һич мөмкин түгел.

— Ярар, — диде ул, — дөнья малы — дуңгыз каны. Алтынсыз яшәрбез. Ә балага бишеккә әҗәткә керергә туры килер.

Давыл кубар дип көткәндә җил дә исми калгач, Фатыйма күңеленнән тантана итте. Заһит ул алтын муенсаларны, йөзекләрне сатып эчкәндер инде. Бик җайлы котылды бит әле бу бәладән.

Ә бала арбасы алырга әҗәткә керергә туры килмәде. Фатыйма ире өйдә юк көнне үзе эшләгән кибеткә китте. Туры директор кабинетына узды.

— О-о, — диде директор, ачык йөз белән, — безне искә төшерүең өчен рәхмәт. Әйдә, диванга рәхим ит. Кайчандыр без аны икебез яхшы ук йомшарткан идек.

— Әллә кайчандагыларны искә алып тормыйк әле, Сәгыйть абый. Үпкән-кочкан җилгә очкан, диләр бит.

— Дөрес, йомшагым, үткәннәрне искә алмыйча, яңа танышкан кешеләр булып бер сөялеп алыйк әле яраткан диваныбызга. Аннары йомышыңны әйтерсең. Болай гына яныма килмәгәнеңне күзләреңнән күреп торам.

Фатыйма Сәгыйтьнең һәрвакыт тирләп тора торган олы корсагыннан, йон баскан күкрәгеннән бик туйган һәм Гыймайга чыккач бераз болардан котылып торган иде. Козгынны үләксә ымсындырган кебек, нигәдер күңеле тагын шушында тартылды. Күрәсең, пычраклыкның да үзенә тарту көче бардыр.

Сәгыйть Фатыйманың зифа гәүдәсенә соклануын белдерде.

— Бала тапкач, тагын да сылуланып киткәнсең, — диде ул, Фатыймага сасы сулышын өрә-өрә.

Хатын аның сасы тынын суламас өчен башын читкәрәк борды.

— Нәрсә, әллә миннән җирәнәсеңме?

Фатыйма дәшмәде. Сәгыйтьнең барлык кыланышларына сабыр гына торды.

— Суына башлагансың син, — диде Сәгыйть, бераз канәгатьсезлек белдереп. — Нәрсәгә килгәниең? — диде.

— Балага бишекле арба кирәк иде. Арбага дигән акчаны чегәннәр урлап чыккан.

— Бала арбасы дисең инде алайса?

— Әйе.

— Арба дүрт тәгәрмәчле була бит.

Фатыйма Сәгыйтьнең тел төбен аңламады.

— Тәгәрмәч санынча килеп китәрсең, — диде Сәгыйть һәм хатынның йөзенә карады.

Фатыйманың нindидер мизгел эчендә бит тиресе тартышып куйды. Сәгыйть моны күрде, ләкин аны-моны әйтмәде.

— Арбаны алып китәрсең, ләкин декреттан соң монда эшкә чыгасы барын онытма.

— Онытмам.

Сәгыйть сатучы кызларны үз кабинетына чакырып кертте.

— Менә нәрсә, кызлар. Фатыйма апагызга бәби арбасы кирәк икән. — Сәгыйть «апагыз» сүзенә юри басым ясап әйтте. — Һәрберегез үзегезнең зарплаталарыгыздан күпме кирәк акча туплагыз да менә бу гүзәл апабызның малаен арбалы итик әле.

Сатучылар һәммәсе Фатыймага борылды. Аларның күзләрендә ачу чаткылары чагыла иде. Фатыйма үзе дә эшнең мондый юнәлеш алырын һич көтмәде. Директор кабинетыннан чыккач, алар элеккеге ахириләренә ташландылар.

— Кәнтәй! Аны директор аша соратмыйча, үзебезгә генә әйтеп булмый идемени?

— Мин Сәгыйть абый алай эшләр дип уйламаган идем.

Кызлар арасында шактый тарткалаш булып алды. Чөнки моннан өч атна элек кенә директор үзенең бер сөяркәсенә кыйммәтле тузан суырткыч бүләк иткән иде. Аның акчасын да сатучы кызларның хезмәт хакыннан тотып калды. Әмма никадәр тузынмасыннар, хуҗа әйткәнне эшләми хәлләре юк.

Фатыймага бишекне үзенә сайлап алырга куштылар. Фатыйма арбаның иң кыйммәтлесен сайлады.

Аннары ул кызларга:

— Кызлар, миңа үпкәләмәгез инде, — диде. — Ә бу бишекле арбаны сез үзегез безгә китерсәгез, әйбәт булыр иде. Сезнең бүләк бит бу. Шунда безнең тормышны да күреп китәрсез. Сөйләшеп утырырбыз. Малайның тәпиен юарбыз.

Кызлар тәпи һәм тагын әллә нәрсәләр юарга остарып җиткәннәр иде, Фатыйманың чакыруын шатланып кабул иттеләр.

Алар дуслар булып аерылыштылар.

Заһиттан туган Заһит ай үсәсен көн үсте. Тәпи баса башлауга бишекле арбаны этеп йөри торгач, арба әле тегендә, әле монда бәрелеп ватылып бетте. Аннан аңа өч тәгәрмәчле велосипед алып бирделәр. Малай аны да бик тиз ботарлап атты.

Әтисе аңа:

— Сиңа, улым, биш яшең тулган көнне ике тәгәрмәчле шәп велосипед алып бирермен, — диде.

Ләкин Заһитка биш яшь тулар алдыннан, төрмәдән өлкән Заһит чыккан дигән хәбәр Фатыймага килеп иреште. Фатыйма эчке бер тынгысызлык белән Заһитны көтте. Хыялында аның элекке Заһит яшәде: чиста, матур, таза гәүдәле. Котырып назлый белә. Аның куллары кагылуга тәндәге бөтен күзәнәкләр уяна. Кайчак ул әллә кай җирләрне чәбәкләп, чеметеп, каергалап ала, тәнеңнең бөгелмәс җирләрен бөгә. Фатыйма авыртудан кычкырып-кычкырып куя: «Үтерәсең бит, дурак!» — ди. Ләкин Заһит: «Аңардан хатын-кызның үлгәне юк әле», — дип тагы да ныграк газаплый. Заһит килеп киткәннән соң берничә көн Фатыйма сызлана, ләкин ул шушы сызланудан рәхәтлек табып эчтән елмаеп йөри. Ә Гыймай, тисәм ватылыр дигән сыман, Фатыймага сак кына кагыла. Башта аның ефәктәй чәчләрен сыйпый, тәненә тидерер-тидермәс кенә кулларын йөртеп чыга. Матур сүзләр әйтә. Иренең озак мыштырдавы Фатыйманың ачуын чыгара. Тиресендә каз йоннары кабара. «Аһ!» — дип куя ул ачудан. Ә Гыймай моны үзенең назлары хатынының җанына барып җитте дип аңлый һәм шунда гына төп вазифасына керешә. Ләкин газаплы наз Фатыймага һәр көн эләкми. Гыймай эштән арып кайта. Ашап-эчкәч бераз ял иткәләп ала да мастерскоена чыгып китә. Хатынын ул йөрәк җылысы җитмәүдән түгел, артык иркәләү аны туйдырадыр дип уйлаудан гына бик еш назламый. Юкса ул Фатыйма идән юган яки көзге алдында әле бер, әле икенче күлмәген киеп караган чакларда үзен чак тыеп тора.

Хатын-кызның мондый кыланышы тәннәрендәге барлык күзәнәкләре ир-ат назына сусап «кычкыра башлавы» икәнен Гыймай каян белсен! Ул үзенең тәнендәге бөтен әгъзаларын акылга буйсындыра килде. Моңа Гыймайның гомер буе авыр эштә эшләве, әбиләренең: «Хатын-кызга текәлеп карау да гөнаһ. Ул — күз белән зина кылу», — дип тукып торулары да өстәлгәч, хатынының теге яки бу җире «ялгыш» ачылып киткән чакларда карашын читкә бора иде. Ә хәйләкәр Фатыйма аны барыбер үз кармагына эләктергәләп торды. Бервакыт Фатыйма, урындыкка басып тәрәзә пәрдәләре элеп торганда, ниндидер кинәт хәрәкәт ясады һәм стенадагы кадакка эләгеп күлмәге ертылды. Тәрәзә яңагының буявы кибеп җитмәгән икән, Фатыйма «ялгыш» буяулы яңакка тотынды. «Бөтен нәрсәне буяп бетерәм инде, пәрдәләрне иртәрәк элгәнмен», — диде ул һәм иренең кочагына сикереп төште. Ертыла башлаган күлмәк тагын каядыр эләкте.

— Бар, — диде ул, — миңа әнә тегеннән халатымны алып кил. — Гыймай эчкәргә яктан халатны эзләп табып алып чыкканчы, хатын идәндә торган буяу савытына бармагын тыгып тәненең бөтен җирен буяп бетерде.

— Син бөтенләй буялып беткәнсең икән, — диде Гыймай, — тәнеңне спирт белән сөртергә кирәк. — Ул шкафтан спирт алып Фатыйманың тәнен сөртә башлады. Шунда ул үзен тыеп кала алмады, көпә-көндез Фатыйманың кочагына ауды. Аннан соң гөнаһ эшләгәндәй хатынына туры карарга оялып йөрде.

* * *

Инде уллары Заһит та аякка басты. Ул бик кызыксынучан малай булып чыкты. Бервакыт ул мунчага әнисе белән генә барды. Ләүкәдә әнисе киерелеп-киерелеп чабынган чакта малай әнисенә карап-карап торды да:

— Әни, нигә минә бу әйберләр миндә юк? — дип, әнисенең чабынганда сикереп-сикереп куйган тулы күкрәкләренә күрсәтте.

— Син бит малай кеше, улым. Ә малай кешеләрдә андый нәрсәләр булмый.

— Мондый нәрсәләр генә буламыни?

— Күп сорашырга сиңа иртәрәк әле. Чистый Заһит.

— Соң, мин Заһит бит инде.

— Әйе, улым. Син — Заһит.

Мунчадан кайткач, Фатыйма улының кызыксынуларын Гыймайга сөйләде.

— Моннан соң мунчага үзем белән барыр, болай ярамас, — диде Гыймай.

— Минем арканы кем ышкыр?
— Малайны кайтарып куйгач, үзем ышкырмын.
Йоклаганда өнәп бетермәсә дә, Фатыйма ире белән мунча керергә ярата иде. Гыймай Фатыйманы ләүкәдә тәгәрәтә-тәгәрәтә чаба. Чаба-чаба кызып китә, мондый чакларда ул Заһитка охшап китә: кайнарлана, җитезләнә, кагылсаң ватылыр дип тормый.
Мунчада күңелләре якынаеп алган чакларда, Гыймай:
— Әллә Заһитка иптәшкә тагын берәр малай апкайтыйкмы, әнкәсе, — ди.
Тик иренең соравын Фатыйма күп вакыт ишетмәмешкә салыша яки:
— Бусы да икегә торырлык әле, — дип җавап бирә.
— Бер бала — юк бала, диләр бит, — ди Гыймай.
— Халык нәрсә әйтмәс. «Сигез сыер асраганчы, симез сыер асра» дигән сүзләр дә халыкныкы.
— Сүз сыер турында бармый бит әле.
— Халык маңгайга бәреп әйтми. Балага да кагыла бу сүзләр.
Фатыйма күңеленнән тагын бер малай яки кыз табарга каршы түгел. Ләкин ул: «Гыймай кебек берәр урод туып куйса, — дип уйлый да куркып куя. — Җитмәсә, ул кыз бала булса. Тфү, тфү! Әстәгъфирулла-тәүбә. Аяклары бигрәк этнеке кадәр генә. Утырып торганда кеше төсле, торып басса, маймылның маймылы. Ярый әле Ходай «теге» нәрсәне жәлләмичә чәпәгән. «Бурычын» еш үтәмәсә дә, анысына зарланырлык түгел».
Тик барыбер Заһит истән чыкмый. Хәзер Фатыйма эчке киеренкелек белән Заһитны көтә. Кайда да булса очрашырга тиеш бит инде алар. Өйгә генә килеп чыкмасын. Гыймай аның белән очрашканны белсә, мәңге кичермәячәк. Ә Фатыймага Гыймай бик кирәк. Чөнки ул аның бөтен гөнаһларын каплый.
Заһит белән Фатыйма бөтенләй көтелмәгән җирдә очрашты. Фатыйма кибеттән мәктәп аша кайтып йөри иде. Мәктәп капкасын керүгә, аны бер кул эләктереп алды:
— Фатыйма!
— Заһит! — Алар бер-берләренә карашып тордылар. Заһит әйбәт костюм-чалбардан. Муенына галстук тагып җибәргән. — Әллә берәр начальник булдыңмы?
— Мин һәрвакыт үземә-үзем начальник.
— Сине төрмәдә дигәннәр иде бит әле.
— Кеше ни сөйләмәс.
— Ә монда нишләп йөрисең?
— Яшим.
— Кайда?
— Әйдә күрсәтәм. — Заһит Фатыйманы җитәкләп мәктәп гаражына таба сөйрәде.
Йозак өстән эленеп кенә куелган икән. Заһит йозакны элмәгеннән алды да гаражның кечкенә капкасын ачты. Ут кабызды. Ике машина сыярлык итеп эшләнгән гаражның подвалы бик зур иде.
Заһит, подвал капкачын ачып:
— Әйдә, гүзәл королева, минем апартаментларга да кереп чыгыйк.
— Юк, мин куркам, — диде Фатыйма.
— Мин барында беркемнән дә курыкма, — диде Заһит, күкрәк кагып. — Мин паханның үзеннән фәлән җиремне ялаткан кеше.
Заһит Фатыйманы этеп диярлек төшерде. Утны кабызып җибәрүгә, Фатыйманың күзе дүрт булды. Әйтерсең бу подвал түгел, кибет склады. Монда җаның ни тели, шул бар.
Заһит ниндидер дегетле капчыктан алтын алкалар, йөзек һәм беләзекләр тартып чыгарды.
— Мин бурычымны түләргә яратам. Мә, ал үзеңә ошаганнарын.
Фатыйманың күзләре янды.
— Каян болар?
— Син аның каян икәнен сорама. Бирәләр икән, ал.
Фатыйма йөзекләрнең әле берсен, әле икенчесен киеп карады. Кайсын алмый калдырсаң да жәл. Хатынның комсыз карашын күргән Заһит:
— Ярар, ал барсын да, — диде. — Өеңә алып кайтып берәр җиргә яшереп куй. Кирәге чыгар.
Заһит алтын әйберләрне, чистарак чүпрәккә төреп, Фатыйманың сумкасына чумдырды. Байлыкка табынучы хатын шатлыгыннан сикеренде.
— Рәхмәт, Заһит, мәңге онытмам!
— Рәхмәтен теге вакытта өеңдә әйткәнчә әйтерсең. — Заһит чишенә башлады. Фатыйманың өстендә җиңелчә күлмәк кенә иде. Аны салып ыргыту озакка бармады.
— Һаман чибәр үзең, — диде Заһит, хатынның бар җирен капшап. — Әйдә, менә монда минем йоклый торган урын. Синең караватың түгел түгелен, ләкин шунсы шәп: моннан егылып төшмисең.
Бер почмакта кыйммәтле кием-салымнардан җәелгән урын бар икән, Заһит Фатыйманы шунда күтәреп салды. Фатыйма:
— Шундый кыйммәтле кеш туны өстендә йоклыйсыңмы син? Димәк, син чынлап карак.

— Әйе, кешеләрнең артык әйберләрен алып чыккалыйм. Менә бу тун әле бер дә киелмәгән. Хәтта яка астында этикеткасы да бар. Шкафта аны көя кисеп ятар иде, ә монда мин аның өстендә ауныйм.

— Әллә нинди хатын-кызлар алып керәсеңдер әле.

— Әллә ниндиләрен түгел, шәпләрен генә.

— Әле син миннән шәбрәкләрне таптыңмыни? Мин иремә хыянәт итә-итә сине өемә кертәм. Ә син...

— Сиңа бит ireңә хыянәт итү ошый. Син Гыймайны мыскыл итүдән тәм табасың.

Фатыйма Заһитка каршы әйтә алмады. Дөрестән дә, ул Гыймайга этлек эшләүдән тәм таба. Гыймайның көне буе таш кисеп кайтканнан соң рамнар ясарга чыгып китүе, кулына бераз акча керсә, алтын кош тоткан баладай сөенә-сөенә акчаларын Фатыймага тоттыруы һәм кечкенә сумма өчен дә эчке горурлык кичерүе хатынга һич ошамый. Менә ичмасам Заһит! Алтын өстендә ауный. Урлаган икән, урласын. Бөтен кеше урлаша.

Заһит белән кыйммәтле тун өстендә котырганда, Фатыйма шулай уйлады.

Алар арыганчы әүмәкләштеләр. Затлы тунның йомшак мехы Фатыйманың тәнен иркәләде. Бу иркәләү хәтта Заһитның назларын күмеп китте. Хәер, Заһит иркәли белми иде: ул эт кебек ырлый, мәче кебек тырный, усал тәкә кебек сөзә, Фатыйманы елан кебек итеп бөгәрли. Ә Фатыйма моңа шат. Аны һәрвакыт кайнарлап тору кирәк.

«Эшләп» арыгач, алар икесе ике якка тәгәрәде. Бераз сөйләшерлек хәлгә килгәч, Фатыйма:

— Ничек яшәргә уйлыйсың? — дип сорады.

— Мин уйламый гына яшим, — диде Заһит. — Мине уйларга өйрәтүче булмады. Һәркем үзенә буйсындырырга теләде. Ә хәзер мин буйсынмыйча, уйламыйча яшим. Әнә минем бер дустым бар иде. Университетны кызыл дипломга бетерде. Нәрсәдер уйлап тапты. Ләкин аның уйлап тапкан әйберен алучы булмады. Эш табалмыйча йөрде-йөрде дә Америкага китеп барды. Хәзер аның уйлап тапкан машинасын Америкадан безнең ил сатып алган. Минем дустым анда байлыкка күмелеп яши.

— Синең бу подвалың да ярлы түгел, — диде Фатыйма. — Кем бирде сиңа моны?

— Бу мәктәптә минем дядя завхоз булып эшли. Шәп мужик. Яши белеп яши. Мәктәпкә ни кайтса да, яртысы аныкы. Әллә син бу подвалны болай гына бирделәр дип уйлыйсыңмы? Тоттырырлар. Моның өчен мин аңа гомерлеккә җитәрлек түләдем. Бушка бирсә дә була иде бит. Барыбер җәй көне монда эт тә керми. Җәй генә түгел, кыш көне дә буш тора бу гараж. Мәктәпнең тракторын директор үз малаена алып бирде. Бер алама «Москвич»лары бар иде, ансы минем абзый кулына күчте. Талау, урлау заманы бит. Беркем сүз әйтми. Чөнки беләләр: күрүеңнән күрмәвең яхшы.

Фатыйманың дөньяга үз карашы булмаганлыктан, ул Заһитның кочагында иркәләнеп ятуны гына белде. Дөньяның башка яклары аның өчен кызык түгел иде. Гомумән, ул кешедә тән барлыгын белә, калганы аның өчен түгел. Дөрес, кайвакытта аң дигән нәрсә уянгалап куя. Ләкин андый мизгел яшен кебек тиз узып китә. Заһит аның шундый икәнлеген яхшы аңлый: Фатыймага хайвани тупаслык ошый. Ныграк интектергән саен, ул күбрәк ләззәт алачак. Ләкин хәйләкәр Заһит аны назлаштырып, сыйпаштырып озак котырта. Фатыйманың бөтен тәне калтырый башлый, түзәрлеге калмый. Ә Заһит инде аңа якынаям дигәндә генә, сикереп торып, озаклап су эчкән була йә, аркам кычыта, кашы әле, дип, озак юынмаудан купшаклаган аркасын Фатыймага бора. Фатыйманың түземе бетә: ул тычканга ташланган мәчедәй үз кирәгенә ташлана. Аннары инде ятакта «акулалар сугышы» башлана.

Фатыйма ул көнне өйләренә соң кайтты.

— Нигә бик озакладың? — диде Гыймай.

— Мәскәүдән товар кайтты, шуларны берәмтекләп кабул итәргә кирәк. Безнең хуҗаны беләсең бит: безгә генә ышанмый, бөтенесен үзе саклап тора.

— Мин эштән кайтышлый кибетегезгә сугылдым, — диде Гыймай, — икенче смена кызлары сине өенә кайтып китте диделәр.

— Без бит товарны икенче складка бушаттык, — дип, тиз арада хәйләсен тапты Фатыйма.

— Малай сине көтә-көтә йоклап китте.

— Бик әйбәт.

— Балага ана назы да кирәк бит.

— Атаңнар сүзен сөйлисең.

— Минем атамнар сине начарлыкка өйрәтәмени?

— Аларның фикере искерде инде. Бала барлык кыенлыкларны күреп үсәргә тиеш. Аны назлап утырсаң, үзен-үзе яклый алмый торган мәми авыз булып үсәчәк ул. Тормышның ни икәнен белсен.

Ир белән хатын ул көнне шактый кызышып алдылар. Гыймай балага күбрәк игътибар, наз кирәклеген төшендерергә тырышты. Йомшаклык, иркәләү бала күңеленә мәрхәмәт орлыклары сибә. Киләчәктә без балалар кулына калачак кешеләр, диде. Гыймай хатынына күптән әйтеп килә торган үпкәсен кабатлады:

— Кайчан үзебезнең балабыз була инде?

Фатыймага шул җитә калды:

— Заһит үзебезнеке түгелмени? Яхшы булып кыланыр өчен генә син аны үз исемеңә яздырдыңмыни?

— Заһит үзебезнеке, ләкин бер бала...

Фатыйма Гыймайның авызын тиз томалады:

— Бездә хәерчеләр болай да хәттин ашкан. Табасың килсә, үзең тап. Ә син киләчәктә безне балаларыбыз карар дип өметләнмә. Безнең киләчәгебез — картлар йорты. Хәер, дөньялар болай барса, картлар йортында да урын калмас әле.

Гыймай, бәхәсләшүнең мәгънәсе юк икәнлеген аңлап, ятарга җыена башлады. Хатын икенче бүлмәгә кереп Заһит биреп җибәргән алтын әйберләрне тиз генә диван астына тыкты да, йокы күлмәген кияргә дип, көндезге киемнәрен салды. Шул вакыт шыпырт кына Гыймай пәйда булды. Фатыйма тиз генә утны сүндермәкче иде, Гыймай аның кулларыннан эләктереп алды:

— Ояласыңмыни? — диде ул.

— Оялам шул. Гомумән, мин бәләкәй чактан оялчан булып үстем. Хәтта кызлар белән су коенырга да ояла идем.

— Шуңа күрә үзеңнән олы малайлар белән ерак күлгә барып коена идегезме?

Заһит янында шактый гына коньяк чөмереп кайткан Фатыйма кинәт кыюланды һәм ире каршына килеп басты:

— Әйе шул. Җиткән егетләр белән төнлә су коендым. Шуннан?..

— Шуннанмы? — Гыймай көрәктәй кулы белән Фатыйманың яңагына чабып җибәрде. Һич моны көтмәгән Фатыйма очып барып бүлмә почмагына ауды. — Бусы телең өчен, ә бусы...

Гыймай, хатынының тәнендәге тешләнгән, күгәргән, кызарган җирләренә төрткәләп: «Бусы азгынлыгың өчен», — дип тагын берне өстәде. Аннары ыңгырашып яткан хатынын тартып торгызды да нидер уйлап тиз генә ишегалдына чыгып китте. Кергәндә аның кулында бер учма кычыткан иде. Фатыйма өстенә кимәгән килеш һаман аңгыраеп басып тора иде. Гыймай аны диванга бәреп екты да Фатыйманың гел кычытып торган җирен кычыткан белән чабарга тотынды. Хатын үрле-кырлы сикерде, ләкин кычкырмады.

— Авыртмый, авыртмый, авыртмый, — дип үртәде ул ирен.

— Азуың җиткән икән, оятсыз, — дип, Гыймай хатынын бүлмәсендә калдырып чыгып китте.

Фатыйма: «Заһитка әйтеп моның иманын укыттырмасаммы?» — диде ул, тешен кысып. Кычыткан чапкан җирләр үтереп сызлый иде. Хатын ул җирләрен одеколон белән ышкыды. Гыймайның ачуын чыгара алуына хәтта шатланды ул. Бераздан Фатыйма торып, кием шкафының ишегенә ябыштырылган көзге каршына килеп басты. Заһит үпкән эзләрне кычыткан кызарткан, хәтта кайбер җирләре чабырып чыккан иде.

«Заһит чын-чынлап ярата мине, — дип уйлады ул. — Никадәр алтын әйберләр биреп җибәрде. Гыймай көне-төне рамнар ясап картайса да, моның кадәр байлык туплый алмаячак. Заһит урлаша икән, урлашсын. Безнең кибет хуҗасы урламый гына баеганмы әллә? Бай кешегә беркем берни әйтә алмый. Кибеттә сатучы булып эшләүче күпме кызларны мыскыл итте. Дәшмибез, чөнки эштән куачак. Байлыгы арткан саен әшәкелеге арта. Хәзер аңа гыйффәтле кызлар гына кирәк. Кибеткә эшкә керергә килгән кызларны иң беренче үз кабинетына алып кереп допрос ясый. Алдашканыңны белсәм, эштән куам, дип куркыта. Гыйффәтле кызларга ул тиз генә кагылмый. Алар янына чыгып эшләгәннәрен күзәтә һәм кызлар бераз уяулыкларын югалтып алсалар, берәр кыйммәтле әйберне чәлеп үз кабинетына яшереп куя. Күпмедер вакыт үткәч: «Кызлар, безнең теге кыйммәтле әйберебезне сатып алмадылармы әле? — дип сорый. — Алмаган булсалар, үземә кертегез, берәү шалтыратып шуны сораган иде», — ди».

Әнә Сөмбел белән ни булды. Шундый чибәр, чәчләрен күрсәтмичә ак яулык бәйләп килгән иде беренче көнне. Сәгыйть Хәмитович аңа: «Бу мәчет кибете түгел, син озын итәкле күлмәгең, муеныңнан урап бәйләнгән яулыгың белән минем клиентларымны куркытып бетерәчәксең. Бездә эшләргә теләсәң, киемеңне алыштырырга туры килер, матурым», — диде.

Сөмбел бик озак эзләп, таныш кызлары аша гына тапкан иде бу эшне. Ә ак яулыкны ул әнисе кушуы буенча иптәш кызларына ияреп бәйләгән иде. Кыз аны ничек тиз бәйләсә, шулай салып та атты: «Ходай кичерер. Кием алыштырганга карап кына минем күңелем үзгәрмәс. Аллага шөкер, иманым нык, аны яулык кебек кенә алыштырырлык түгел», — дип, үз-үзен юатты Сөмбел. Ул әле таудан төшә башлагач тукталып калу мөмкин түгеллеген аңламый иде. Башка кызлар кебек киенеп килгәч, Сәгыйть Хәмитович: «Менә бит, ә! Нинди чибәрлекне яулык астына яшереп йөрисең. Матурлык бит ул — Ходай тарафыннан сирәк кешеләргә генә бирелә торган байлык», — диде.

Сөмбел җиңелчә киенеп йөри башлагач, дөрестән дә, аның товарын сатып алучылар күбәйде. Хәтта күптән сатылмый яткан кыйммәтле суыткыч, савыт-саба юу машиналары да хутка китте.

— Менә бит, матурым, — диде хуҗа, кызны хуплап, — бездә кешене киеменә карап бәялиләр.

Һәм Сәгыйть Сөмбелгә: «Бусы лично минем үземнән премия, — дип, аңа зур гына сумма бирде. — Башка сатучыларга әйтмә, юкса көнләшү китәчәк. Ә мин коллективның тату булуын телим».

Сөмбел бу акчаларга бик сөенде. Эшләр шулай әйбәт кенә барганда, Сөмбел эшли торган бүлектән бер кыйммәтле әйбер югалды. Сәгате-минуты белән моны хуҗага җиткерделәр. Сәгыйть кызны үз кабинетына чакыртты.

— Йә, нишлибез инде, — дип, хуҗа Сөмбелгә текәлде.

— Белмим, абый.

— Ничек белмисең? Үзең сата торган һәр нәрсәне барлап торырга тиеш син. Иртән килгәндә бар идеме?

— Белмим, абый.

— Димәк, белмисең. Белмәгәннең беләге авыртмый дисеңдер.

Сөмбел дәшмәде.

— Алай, алай. Син белмисең.

Сәгыйть бүлмә буйлап йөренә башлады. Йөзенә бик уйчан кыяфәт чыгарды, аннары, кызның җилкәсенә үзенең кулын куеп:

— Нишләргә икән соң инде синең белән? — дип, кызның күзләренә карады. — Бик яшь, бик чибәр үзең. Ә чибәр сатучылардан әйберне күбрәк алалар. Хезмәт хакың әйбәт булыр иде. Ләкин берни эшләр хәл юк. Чыгарырга туры килә... — Ул өстәл тартмасыннан кәгазьләр алып нидер язарга тотынды.

Сөмбелнең коты очты. Эш табып өйгә акча кайтара башлагач, әнисе белән сеңелләре ничек сөенгәннәр иде. Теге көнне хуҗа биргән акча ике айга фатирга түләргә җитте. Җитмәсә, Сөмбел иптәш кызлары алдында күп акча алуы белән бераз мактанып та алган иде.

Кыз хуҗаның каршысына килеп башын түбән иде. Аның күзләрендә яшь иде.

— Сәгыйть абый, үтенәм сездән, мине эштән чыгармагыз. Әнием җыештыручы булып эшли. Ә җыештыручыга, үзегез беләсез, күпме генә түлиләр. Ике сеңлемне укытасы бар.

— Мин кибетемдә караклар тота алмыйм, — диде Сәгыйть Хәмитович. — Читтәге карактан котылып була, өйдәгесеннән — юк.

— Мин карак түгел! — диде Сөмбел, күз яшьләрен сөртеп. — Ә югалган әйберне эш хакымнан тотып калырсыз.

— Ничә ай бушка эшләп йөриячәгеңне күз алдыңа китерәсеңме соң син?

— Китерәм.

Сәгыйть йомшаган булып кызның башыннан сыйпады.

— Күңелең сафлыгына ышанам. — Сәгыйть кызның иягреннән тотып башын югары күтәртте. — Шундый матур күзләр алдамаслар дип уйлыйм. Йә, ярый, үзең әйткәнчә, товар бәясен эш хакыңнан тотып калырбыз. Ә хәзер, марш! Үз урыныңа бас. Эшлә!

Сөмбел шатлыгыннан хуҗасының бит очыннан үбеп алды да йөгереп чыгып китте. Сәгыйть исә бу кызны ничек кулга төшерергә икән дип баш ватты.

Оясын яшереп саклаган сандугач кебек, Сөмбел үзенең сафлыгын сакларга тырышты. Сәгыйть Хәмитович аны үзенә ияләштерер өчен еш кына кабинетына чакырып алды. Бергәләп чәй эчкән чаклары да булды. Ләкин Сәгыйть Хәмитович «ялгыш» кына кызның ботына кулын куйса яки кәнәфидән торганда кулын иңнәренә салса, Сөмбел корт чаккандай сикереп тора. Андый чакларда Сәгыйть Хәмитович: «Гафу, матурым, гафу», — дип куя һәм эше турында сораштырырга тотына. Исәбе — кызның сизгерлеген оету, кулга ияләштерү.

— Йә, ничек соң? — дип сүз башлады ул беркөнне. — Безнең кибеткә ияләшеп буламы? Кызлар обижать итмиләрме? Гаиләдә эшләр көйлеме?

— Рәхмәт, Сәгыйть Хәмитович. Кибетегез миңа бик ошый. Сатучылар да әйбәт. Ә гаилә хәлләре... — Кыз җөмләсен тәмамлый алмады, тамагына кайнар төер утырды. Күзләреннән яшьләр тәгәрәп төште.

— Нәрсә, матурым, гаиләгездә берәр бәхетсезлек бармы әллә?

— Әйе, Сәгыйть абый.

— Әниең чирлиме? Сеңелләрең берәр бәлагә юлыкканмы?

— Юк, әни исән-сау, Аллага шөкер. Сеңелләр дә әйбәт кенә.

— Алайса, мин берни аңламыйм.

— Әнине эштән чыгарганнар.

Сәгыйть тозлап-борычлап сүгенеп куйды. Аннары:

— Әниең җыештыручы дигән идең. Нәрсә җыештыра иде ул?

— Теге «Олимпия» кибетен.

— Хуҗасы кем әле аның?

— Мин аны ныклап белмим. Ниндидер хатын-кыз.

— Алай! — Сәгыйть уйланып идән буйлап йөренде, аннары кинәт бер карарга килеп: — Әле әниең өйдәме? — дип сорады.

— Өйдә!

— Әйдә алайса, сезгә киттек. — Сәгыйть Хәмитович машинасын чакыртты. Берничә минут эчендә

алар юлда иде инде. Шәһәр зур түгел, Сөмбелләргә тиз барып җиттеләр.
Сөмбелнең әнисе аларны бераз гаҗәпләнебрәк каршылады.
Сөмбел, ашыга-ашыга:
— Бу безнең хуҗабыз Сәгыйть Хәмитович була, — дип, кунак белән әнисен таныштырды.
— Рәхим итегез, — диде ана һәм тиз генә кухня ягына чыгып китте.
Ләкин аңа Сәгыйть Хәмитович:
— Без озакка түгел, чәйләр куеп тормагыз, ханым. — Ана кухня ягыннан чыкты. Сәгыйть Хәмитович, аны үз янына утыртып: — Сөмбел миңа сезне эштән алганнар дигән иде. Шул дөресме? Мөмкин булса, сәбәбен аңлатыгыз әле.
— Сәбәбен кем белгән инде аның. Пычрак көн иде. Кибеткә кешеләр күп килде. Мин җыештырып өлгерә алмаганмындыр, ахрысы. Октябрина Николаевна үзенә чакырып алды да: «Миңа ташбака кебек кымшаныйммы-юкмы дип йөргән эшчеләр кирәкми. Документларыңны ал да үзеңә башка урын эзлә», — диде.
— Алай, алай, — диде Сәгыйть Хәмитович. — Сезнең хуҗа Октябрина Николаевна бит әле, исемә төште. Әйе, кызу канлы хатын. Тик бер ягы әйбәт: тиз кыза, тиз сүрелә. Шалтыратып карыйм әле, бәлки, кире алыр. Ярамый бит инде артыгын кыланырга.
Сәгыйть Хәмитович кесә телефонынннан Октябрина Николаевнага шалтыратты.
— Алло, алло, Октябрина Николаевна, исәнмесез! Сезгә Сәгыйть Хәмитович шалтырата иде. Нинди Сәгыйть Хәмитович дисезме? Оныттыгызмыни? Предпринимательләр җыелышында бергә утырган идек. Әйе, әйе, хәтерегез яхшы икән. Мин «Алдым-бирдем» кибете хуҗасы. Нинди йомышмы?
Сәгыйть Хәмитович телефоннан сөйләшкәндә, өйдә хәтта йөрәк типкәне дә ишетелерлек тынлык урнашты. Ә Сәгыйть сөйләшүне юри озаккарак сузарга тырышты.
— Йомыш дип, әллә ни йомыш юк инде. Хәлләрегезне беләсем килде. Хәлләр әйбәт дисез инде алайса. Ансына мин шат. Тик сезгә бер кечтеки генә үтенеч барые. Нindime? — Сәгыйть Сөмбелнең әнисенә карады: — Исемегез ничек әле, апа?
— Хәтимә.
— Сездә җыештыручы булып Хәтимә ханым эшләгән икән. Сез аны эштән чыгаргансыз. — Телефонда тавыш яңгырап торды, тик аны аңларлык түгел иде. Сәгыйть сүзен дәвам итте: — Ну, һәрберебез кеше бит. Кайсыбызда андый гына гөнаһ юк, Октябрина Николаевна. Бәлки, кире алырсыз, ә? Мин аларның гаиләсен беләм. Эшчән, тәртипле гаилә. Әле менә бер кызларын үземә эшкә алдым. Нәрсә? Ансы инде әйтмәсәгез дә билгеле. Буш итмәм, әлбәттә. Йә, ярый алайса, килештек. Бик зур рәхмәт сезгә, Октябрина Николаевна. Хәзергә хушыгыз. Бер килеп чыгармын әле сезгә.
Сәгыйть Хәмитович, бик зур эш эшләгәндәй үзеннән канәгать калып:
— Иртәгедән эшкә чыга аласыз, Хәтимә ханым, — диде. — Ә син, Сөмбел, бүген кибеткә барып тормасаң да ярый. Эш вакыты бетеп килә.
— Сезгә нинди рәхмәтләр әйтсәм дә әз булыр инде, — диде Хәтимә.
Алар сөйләшкәндә кухняда чәй кайнап утыра иде, Сәгыйть Хәмитовичны көчләп диярлек табынга утырттылар. Ул үзенең телефонынннан шоферына әмер бирде:
— Ибрай, очып кына «Тәм-том»нан бер торт апкил.
— Кирәкмәс иде инде, Сәгыйть Хәмитович, — диде Сөмбел. — Болай да безнең өчен бик зур эш эшләдегез.
Шофер торт алып килгәнче, табындагы сыйлар белән чәй эчә тордылар.
— Киләсегезне белгән булсам, коймак пешереп торган булыр идем, — диде Хәтимә, өстәлдәге сыйның сыеклыгына кыенсынып.
— Кыенсынмагыз, Хәтимә ханым. Ипи белән май — шул ук коймак инде ул. Без үзебез дә әллә ни ашап үсмәгән.
Чәй эчеп утырганда, Сәгыйть Хәмитовичның шоферы зур каплы торт һәм берничә шоколад алып керде. Үзе шунда ук чыгып китте.
— Мин шоферымны алдан ук кисәтеп куйдым: әгәр мин бер эш кушсам, икеләтә итеп үтә, дип, — диде Сәгыйть Хәмитович.
Болар чәй эчкән арада, ике кыз да кайтып керде.
— Болар минем сеңелләрем, — дип таныштырды Сөмбел.
— Нәселегез белән чибәрләр икән, — диде Сәгыйть Хәмитович.
— Тәүфыйклары булсын инде, — диде Хәтимә. Ә кызларның күзе табындагы тортка төште.
— Сездә утыру күңелле булса да, миңа китәргә вакыт, — дип, Сәгыйть хуҗаларга рәхмәт әйтеп урыныннан кузгалды.
— Нинди әйбәт кеше! — диде Хәтимә.
— Корсагы менә бу табак хәтле, — дип калды кечкенәләр һәм корсакларына табак каплап Сәгыйть Хәмитович кебек итеп йөреп күрсәттеләр.
— Көлмәгез кешедән, — диде әниләре.

— Без бит шаярып кына, — диде кызлар һәм өстәлдәге тортны ботарларга тотындылар. Кызларны кухня ягында калдырып, Сөмбел белән әнисе олы якка чыкты. Алар икәүләшеп Сәгыйть Хәмитовичны мактадылар.
— Байларның бер-берсенә сүзе үтә шул, — диде ана.
— Әйе, Сәгыйть абый бик әйбәт кеше, — дип раслады әнисенең сүзен Сөмбел.
— Син тырышып эшлә инде, кызым. Хәзер эш табулары ай-һай авыр.
Ана белән кыз Сәгыйтьне мактаганда, хуҗа үзенең машинасында эчтән генә елмаеп бара иде. Ул Сөмбелне кулга төшерер өчен тагын ниләр эшләргә икән дип уйлана. Бу эш шәп барып чыкты. Октябрина Николаевна Сәгыйтьнең үтенечен кире какмады: аның соравы буенча Хәтимәне эшеннән чыгарды һәм шул ук кешенең үтенече буенча хатынны эшенә кире кайтарды. Бу кәмитнең Сәгыйть Хәмитовичка нигә кирәген сорап тормады.
Сөмбел иртәгесен эшенә очып баргандай барды. Ул Сәгыйть Хәмитовичка рәхмәт әйтеп чыгарга уйлады. Кыз ишектән күренүгә үк:
— Нишләп кабинетым яктырды дисәм, Сөмбел кергән икән, — дип, кызны каршылады.
— Сәгыйть абый, сезгә барысы өчен дә рәхмәт инде.
— Кунак ашы — кара каршы, диләрме әле. — Сөмбел хуҗаның сүзләреннән сагаебрак калды. Төлкедәй сизгер Сәгыйть, кызның сагайган күзләренә карап:
— Миңа нигәдер ышанып җитмисең, ә мин тырышып йөргән булам... — Сәгыйть үпкәләгән кыяфәткә керде. Сөмбелдән читкә борылып кәгазьләрен актара башлады.
Сөмбел хуҗаның хәтерен калдыруына үз-үзен битәрләде. Аның сүзсез генә чыгып китәсе килмәде.
— Сәгыйть абый, мин сезне рәнҗетергә теләмәгән идем, гафу итегез инде. Ә кунак ашы дигәнегез безнең кулдан килә торган эш булса, без әзер.
Сәгыйть Хәмитович кызга нидер әйтергә теләде, ләкин шул вакыт телефон шалтырады. Аны каядыр чакыралар иде бугай, ул торып басты. Сөмбел дә чыгып китәргә кирәклеген аңлады. Ишектә алар ничектер бергә туры килделәр. Сәгыйть Хәмитович ботинкасына иелгән булып, ялгыш кына кагылгандай, кызның калку күкрәгенә битләре белән ышкылып алды. Сөмбел аны-моны уйлап өлгергәнче, битеннән үпте һәм яшьләрчә җитезлек белән кабинетыннан чыгып китте.
Сөмбел моны аталарча ярату дип кабул итте, ә күкрәкләргә ышкылу — ансы тыгыз җирдә була торган хәл. Әнә автобуста ничек кысмыйлар! Иртәнге сәгатьләрдә бигрәк тә.
Кыз үзен шулай тынычландырып эшкә кереште. Көне буе күтәренке күңел белән эшләде. Хуҗа каядыр китеп юкка чыкты. Сатучы кызлар: «Сине хуҗа кая алып барды?» — дип сорашканнар иде, Сөмбел дөресен әйтмәде: «Складка!» — дип кенә куйды. «Безнең хуҗа төлке кебек ул, син саграк бул», — дип кызны кисәттеләр.
Сөмбел үзе дә ниндидер эчке киеренкелек халәтендә йөрде. Ләкин Сәгыйть Хәмитович берничә көн Сөмбелне бөтенләй күрмәгән-белмәгәндәй йөрде. Бер атналап вакыт үткәч, болай гына сорагандай: «Теге әйбер табылмадымы?» — дип кызыксынып алды. «Юк», — дигән җавап ишеткәч, аны-моны әйтми китеп барды.
Ниһаять, хәйләкәр төлкенең түземлеге бетте: Сөмбелне кабинетына чакыртты. Сөмбел кабаланып кергәч, юри башын калкытмый утырды. Сөмбел ике тапкыр: «Исәнмесез, Сәгыйть Хәмитович!» — дип кабатлагач кына: «Ә-ә, Сөмбел матурым, син икәнсең, — дип әйтеп куйды һәм: — Мин сине ике айга сынау шарты белән алган идем. Сынауны бик әйбәт уздың дип булмый... — Сәгыйть күзлеген күтәреп кызга карады. — Нишләргә инде синең белән. Килешү төзергәме-юкмы?»
Сөмбелнең йөрәк тибеше ешайды. Ул ни дияргә белми хуҗага карады. Хуҗаның йөзе кырыс, карашы ачулы кебек иде.
— Сәгыйть абый, үзегез күрдегез бит безнең тормышны.
— Күргәнгә аптырап утырам менә, юкса бүгеннән куып чыгарыр идем, — диде Сәгыйть Хәмитович.
— Сәгыйть абый, әйбәт кенә эшлим бит инде.
— Начар эшләсәң, сөйләшеп тә тормас идем.
— Калдырыгыз, зинһар, Сәгыйть абый, ни кушсагыз, шуны үтәрмен, — диде кыз.
Сәгыйть озак кына уйланып утырды. Аннары бер карарга килеп сикереп торды.
— Йә, ярар, әниең, сеңелләрең хакына эштә калдырам. Менә бу килешү кәгазенә кул куй.
Сөмбел кәгазьгә язылган сүзләрне укып та тормыйча кул куйды.
— Нишләп укымаган килеш кул куйдың? — дигән булды Сәгыйть.
— Мин сезгә ышанам, Сәгыйть абый, — диде Сөмбел.
Артык киеренкелектән аның тамагы кипте. Ул иреннәрен ялап куйды. Сәгыйть Хәмитович суыткычны ачып бер шешә минераль су алды.
— Берәр стакан эчеп куй әле менә бу шифалы суны, — диде. — Хәл кереп китәр үзеңә.
Стаканга салганда ук күбекләнеп, чыпырдап торган су әчкелтем иде. Кыз тын да алмыйча стаканны бушатып куйды. Тәне буенча рәхәт салкынлык йөгерде. Ул инде чыгып китәргә уйлаган иде, ләкин бер адым атлауга башы әйләнеп чайкалып китте. Шуны гына көткән Сәгыйть Хәмитович аны кочаклап

алып кәнәфигә утыртты.

— Шатлыктан бу, шатлыктан, — дип сөйләнде үзе. — Бераз хәл җыеп ал. Стрессың үтсен.

— Сез миңа аракы эчердегез, ахры, Сәгыйть абый. Мин исердем бугай.

— Миңа мондый яла яксаң, договорны ертып ыргытам. — Сәгыйть Хәмитович килешү кәгазен алды. — Ертып ыргытам да куып чыгарам.

Сөмбелнең аңы аракы кушылган газлы судан бераз томаланган булуга карамастан, хуҗаның ачулы сүзләре акылның бормалы юлларын узып тормыйча йөрәгенә барып җитте.

— Гафу итегез, Сәгыйть абый, — диде ул. — Сез әйткәнчә, шатлыктан исеребрәк киттем бугай.

Сәгыйть газлы су шешәсен цирктагы фокус күрсәтүче тизлегендә икенчесе белән алыштырып куйган иде. Ул Сөмбелнең сүзләренә һаман үпкәләгән булып кыланды.

— Минем бернинди гөнаһым юклыгына сине ышандыру өчен хәзер мин бер кызны чакырам. Ул эчеп карагач ни әйтер икән. Шигең калмасын өчен менә әле генә үзең суын эчкән шешәне тотып теге якка чыгып тор. Мин аны синең кулыңнан алып аңа эчерермен.

Сөмбел:

— Мин болай да ышанам сезгә, — дисә дә, Сәгыйть Хәмитович бер сатучы кызны алып керде.

— Менә бу суны эчеп карагыз әле. Агу дип шикләнсәң, башта үзем эчеп карыйм.

Сәгыйть Хәмитович Сөмбел кулыннан сулы шешәне алып ике стаканга салды. Берсен — үзе, икенчесен сатучы кыз эчте.

— Ну, ничегрәк?

Кыз җилкәләрен сикертеп куйды.

— Миңа калса, газландырылган шифалы су.

— Ярый алайса, — диде хуҗа, — эшегездә булыгыз. Әгәр башыгыз әйләнгәнен тойсагыз, шундук миңа кереп әйтегез.

Сатучы кыз чыгып китте. Сөмбел хуҗаны кыен хәлгә куюыннан уңайсызланып кабинетка чыкты. Аның инде баш әйләнүе узган, күңеле күтәрелеп, моңарчы татып каралмаган җиңеләю халәтенә күчкән иде. Ул тиктомалдан көләргә тотынды. Сәгыйть Хәмитович, «җимеш» өлгереп җитте дип, Сөмбелнең чәчләреннән сыйпады.

— Мин сине үз кызым кебек яратам, — диде ул, кызны куллары белән капшап.

— Мин дә сезне әтием кебек яратам, — диде кыз.

— Кил әле, алдыма утыр. Бер яратыйм үзеңне.

— Ярамый, гөнаһ була.

— Әтинең алдында утыру гөнаһмыни?

Сәгыйть Хәмитович юмалый-юмалый кызны алдына утыртты. Башта аталарча чәчләреннән сыйпады. Әти кочагы күрмәгән кызга назлау ошады. Ә карт төлкенең калын иреннәре әкрен-әкрен кызның муеннарына барып җитте. Түштәге ике төймәнең ничек чишелгәнен дә сизми калды Сөмбел. Иреннәр «оядагы сандугачка» килеп җиткәч кенә айнып китте ул.

— Юк, ярамый, Сәгыйть абый, бу гөнаһ, бик зур гөнаһ.

— Гафу, сеңлем, гафу, син газлы судан исереп киткән кебек, мин дә синең исеңнән исердем.

Кыз инде айнып килә иде. Ул, кинәт ыргылып, Сәгыйть Хәмитовичның кочагыннан чыкты. Сумкасыннан кечкенә көзге белән тарагын алып чәчләрен төзәткәләде. Сәгыйть исә, каймакка тел очын гына тидереп алган мәче сыман, чыгып киткән кызга карап калды.

Сөмбел үз урынына чыгып баскач, иптәшләренең йөзендә ниндидер үзгәреш сизде. Аларның күзләрендә кызгану чагыла иде сыман. Ләкин кыз үзен гаепле тоймады.

Сәгыйть берничә көн Сөмбелне эзәрлекләми йөрде. Ләкин аның түземе озакка җитмәде — кызны чакыртты.

— Кызымны сагындым, — диде ул. — Кил әле, теге көнге кебек бер иркәлим үзеңне.

— Юк, юк, Сәгыйть абый, ярамый. Гөнаһ!

— Синең бар сүзең шул — гөнаһ. Ә бит мин сине бәхетле итәргә генә телим. Ходай ир белән хатынны яраткан икән, димәк, гөнаһ түгел.

— Мин бит сезнең хатыныгыз түгел. Никахка кадәр мин чит-ят ирләргә карамаячакмын. Сафлыгымны никахлы ирем өчен саклыйм.

Шул вакыт Сәгыйтьнең башына бик кыю бер фикер килде.

— Әйдә алайса никах укытабыз, — диде ул, — минем дә гөнаһлы буласым килми.

Сөмбел югалып калды. Сәгыйть, кызның халәтеннән файдаланып, булдыра алган кадәр матуррак сайрарга тырышты:

— Мин сине байлыкта йөздерәчәкмен. Әниеңне дә, үзеңне дә кирәк җиргә машинада гына йөртерләр. Сеңелләреңне престижный мәктәпкә бирербез. Алар укып зур кеше булырлар. Ярлылыктан мәңгегә котылырсыз.

Сөмбел, ниһаять, кирәкле сүзне тапты:

— Сезнең бит хатыныгыз бар, Сәгыйть абый.

Сәгыйть Хәмитович бу сүзне көткән һәм аның җавабы әзер иде.

— Мин мөселман лабаса. Ә мөселманга ике-өч хатынга өйләнү дә хәрам түгел. Аллага шөкер, ике хатынны тотарга хәлемнән килә.

Кыз болай гына котылып булмаячагын аңлады. Ул Сәгыйть Хәмитовичның күлмәген ярып чыгам-чыгам дип торган корсагына, тамчы-тамчы тир бөртекләре тәгәрәгән битенә карап алды. Хәйләкәр һәм сизгер Сәгыйть Хәмитович гүяки кызның фикерләрен укып барган.

Ул, гади генә итеп:

— Карама йөзенә — кара йөрәгенә, диләр түгелме? Ә йөрәк минем, Аллага шөкер, аракы чөмереп, наркотик кадатып йөргән яшьләрнекеннән шәбрәк.

Сөмбел бу «ит тавы» белән яшәүне һич күз алдына китерә алмады. Кабинеттан тизрәк чыгып китәр өчен генә:

— Әни белән киңәшсәм ярыймы? — дип сорады.

— Әлбәттә, — диде Сәгыйть Хәмитович, — рәзе мондый олы эшне әниләр белән киңәшмичә эшлиләр. Уйлашыгыз, киңәшегез. Ризалык бирмәсәң дә үпкәләмим. Тик бер нәрсә... — Сәгыйть чишеп булмаслык мәсьәлә алдында калган укучы кебек бер ноктага карап торды. Аннары авырлык белән генә: — Минем тәкъдим кире кагылган очракта, безгә аерылырга туры килер. Чөнки синең кояшка тиң йөзеңне күреп тә янына якын бара алмау, ефәктәй чәчләреңнән сыйпый алмау минем өчен зур газап булачак.

Киткән чакта Сәгыйть Хәмитович Сөмбелгә бер төргәк бирде.

— Бусы әниеңә күчтәнәч. Теге көнне сездә эчкән чәйнең тәме һаман телемнән китми. Гаиләгезнең татулыгы, гади генә ризыкны да олылап табынга куюю мине сокландырды, — диде ул. — Димәк, ризыкның кадерен беләсез. Ә бит әле бездә бер сынык ипигә тилмереп яшәүчеләр белән бергә, икмәк кадерен белмичә, аны туптай типкәләп йөрүчеләр дә бар.

Сөмбел ул көнне өйләренә уйга батып кайтты. Әнисе аның йөзен күреп куркып китте.

— Әллә эштән чыгардылармы, кызым?

— Юк, аннан да начаррак.

Ана аптыраашта калды. Сөмбел әнисен озак көттереп интектермәде, барысын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Ана башта бик нәфрәтләнде.

— Мин аны юньле кешегә санап калган идем, ә ул азгын җан икән, — диде. Әнисе эчендәге бөтен ачуын чыгарып бетергәч, Сөмбел:

— Онытып торам икән, Сәгыйть Хәмитович сиңа ниндидер күчтәнәч биреп җибәргән иде, менә.

Кыз әнисенә төргәкне сузды. Ана аңа озак кына кагылмады. Ниндидер эшләр эшләп, күңелен бераз баскач кына төргәкне ачты. Ачты да авып китә язды.

— Нәрсә булды, әни? — диде Сөмбел, әнисенең куркулы йөзен күргәч.

— Үзең кара! — Ана төргәкне кызына сузды. Төргәктә бер чүмәлә акча иде. Ана белән кыз бер-берсенә карашып уйга баттылар.

— Сине сатып алырга уйлаган бу! — диде ана, нәфрәтләнеп. — Байлар бөтен нәрсәне акча белән сатып алып була дип уйлыйлар, ахры.

Сөмбел әнисен сүзсез генә тыңлап утырды. Акчаларга карап аптырашып утырганда, кече кызлар — Нәсимә белән Рәсимә кайтып керде. Нәсимә инде сигезенче сыйныфта укый, акчалы классташларына көнләшеп карый иде. Бу кадәр акчаны күргәч, аның күзләре яна башлады.

— О-о! — диде ул. — Әллә берәр банк бастыгызмы?

— Юкны сөйләмә әле, — диде әнисе.

— Әллә күктән фәрештәләр төшердеме безгә бу байлыкны? — диде Рәсимә. — Фәрештәләр бүләге булса, миңа бер сотовый алып бирәсез. Фотоаппаратлысын.

— Сотовыйны башта миңа, — диде Нәсимә. — Безнең класста бер мин генә сотовыйсыз.

— Монда икебезгә дә җитә, — диде Рәсимә. — Бу акчалар чынлап та безнеке булса, мин обедта каткан булка белән салкын компот чөмереп утырмас идем.

— Сиңа, ач тәрегә, ашарга гына булсын.

— Ашау самый главный.

— Матур киенергә, өйгә компьютер алып куярга. Компьютерны Интернетка тоташтырырга. Интернетта шундый кызык әйберләр бар. Әнә Гүзәлләрнең нәрсәсе генә юк!

— Һы, аның әтисе бизнесмен бит.

Кызларның күңеле хыялга бай иде. Әллә нәрсәләр «алып» бетерделәр.

Әгәр әниләре:

— Атмаган куянның тиресен бүлешмәгез әле, — дип туктатмаса, Нәсимә белән Рәсимә байлар кибетендәге яхшы әйберләрнең бөтенесен өйләренә «ташып» бетергән булырлар иде.

Өйдә бераз тынлык урнашкач, бу акчаларның кайдан килгәнлеген һәм артында нәрсә торганлыгын кечкенәләргә дә аңлатып бирергә туры килде. Кызлар башта кычкырып көлделәр, аннары апаларын үртәп алдылар. Бу гаиләдә һәркем тигез хокуклы булганлыктан, тормыштагы барлык мәсьәләләр

уртага салып хәл ителә иде.
Сүзне Нәсимә башлап җибәрде:
— Ә нигә? Начар идея түгел бу. Хуҗаңның яшь хатыны булып, карт хатынга приказ гына биреп ятасың.
— Үзеңә машина алдыр, — диде Рәсимә. — Безне мәктәпкә машинаң белән илтеп куярсың, барып алырсың. Әтиләренең машиналарында түш киереп утыручы Чулпаннарның, Ринатларның күзләре маңгайларына менсен әле.
— Сезгә әйбер булсын, — диде Сөмбел, ачуланып, — минем турыда уйламыйсыз.
— Әле никах укытып алганга рәхмәт әйт. Әнә безнең Рәмзиянең апасы үзенең хуҗасына сөяркә булып яши, — диде Нәсимә. — Картларга кияүгә чыгу хәзер модада. Беренчедән, алар байлар, икенчедән, озак яшәмиләр. Байлыклары сиңа кала.
— Сезнең күңелегездә мондый уйлар бардыр дип башыма да китерми идем, — диде ана. — Апагызны байлыкка сатабызмыни?
— Хәзер кызлар гына түгел, ярлы егетләр дә баерак кызларны сайлый.
Бәхәс озак барды.
Әниләре:
— Актыккы сүзне Сөмбел үзе әйтергә тиеш, — диде.
— Юк, әни, син әйт. Мин гомер буе синең сүзеңнән чыкмадым. Дин юлына бас, дигәч, башыма ак яулык бәйләдем. Догалар өйрәндем. Тик дөресен әйтергә кирәк, дога укый башласам, минем уйларым әллә кая еракка китә. Догамны ялгышып бетәм.
— Күңелеңдә Аллага ныклы ышаныч булмаганлыктан ул, кызым.
— Ышанырга бик тырышсам да, барыбер күңелгә шикләр килә бит. Башка ак яулык бәйләп кенә кара уйлардан котылып булмый икән.
— Моңа озак вакыт кирәк, кызым.
— Менә син Аллага чын күңелеңнән ышанган кеше, әни. Турысын гына әйт: үзеңнән ике тапкыр олы кешегә икенче хатын булып баруны син хуплыйсыңмы?
Хәтимә ни әйтергә белмәде. Әлбәттә, һәр ана кебек, аның да кызын бәхетле итәсе килә. Сөмбел үзе кебек яшь егеткә чыгып, матур-матур балалар үстерсә, ире гаиләне туйдырып тора алса, ни әйтер идең дә бит. Ләкин хәзерге яшьләр өйләнергә атлыгып тормый шул. Рәтләп эшләүчесе дә юк: кайсы эчкече, кайсы наркоман. Акыллыраклары чит илгә китәргә тырыша. Дөньясы болганды шул, дөньясы. Кызы бозык юлга басса нишләрсең? Андыйлар азмыни хәзер. Яхшылык белән яманлык буталган заман.
Ана, шундый уйлар тезмәсен күңеле аша үткәргәннән соң, Сөмбелгә болай диде:
— Кызым, җаным тартканга түгел, бозылып китүеңнән куркып ризалыгымны бирәм. Никах белән яшәсәгез, ичмасам, гөнаһы булмас. Менә минем сүзем шул, калганын үзең кара. Байлыгына кызыгып ризалыгын бирде дип уйлама. Мин ипи белән бәрәңге ашап яшәсәм дә риза. Ә сез яшьләр үзегезнең дусларыгыздан ким буласыгыз килмәгәнне аңлыйм.
Ана соңгы сүзләрен көчкә генә әйтте. Аның тамагында — кайнар төер, күзләрендә яшь иде. Ул бозык дөньядан бераз чистарыну өчен намазлыкка басты.
Бөтен җаваплылыкны үз өстенә алгач, Сөмбелгә авыр булып китте. Армиягә озатып җибәргән егете хезмәт срогын тутыргач, шул хезмәт иткән шәһәрендә марҗа кызына өйләнеп, марҗасын кунакка алып кайткач, шундый авырлык кичергән иде инде ул. Хәзергесе тагын да авыррак булыр сыман. Әгәр хуҗаның тәкъдименнән баш тартса, Сәгыйть Хәмитович аны эзәрлекләячәк, буйсынмасаң, куып чыгарачак.

* * *

Иртәгесен Сөмбел эшкә кәефсез килде. Төн буе йокламыйча уйланып яту үзенекен итте, күрәсең. Сәгыйть Хәмитович кыздагы үзгәрешне шунда ук күреп алды. Ул, Сөмбелне кабинетына чакырып: «Минем матурыма нәрсә булган? Кемнәр рәнҗеткән аны?» — дип, кыз тирәсендә бөтерелгәләде. Сөмбелнең күзләреннән яшь тамчылары чыгып керфекләренә эленде. Әлбәттә, хәйләкәр төлке кызның хәләтен аңлый. Тик җавапны кызның үз авызыннан ишетергә тели иде. Ул Сөмбелне ашыктырмады. Кәнәфиенә утыртты, су тәкъдим итте, ләкин кыз сулы стаканны читкәрәк этеп куйды да елап җибәрде.
Сәгыйть Хәмитович бу елауның артында ни ятканлыгын яхшы аңлады. Йомшак күңелле кызлар, үзләренең иң кыйммәтле байлыклары белән хушлашканда, сабыйларча елап җибәрәләр. Аларның бу күз яшьләре ясалма булмый. Сәгыйть Хәмитовичның яшь чагында моны аңламыйча авызы пешкәне булды. Ул бер кызны яратып йөри, кыз да аңа битараф түгел иде. Бервакыт алар йолдызлы төндә шәһәрдән кайтышлый кинәт кенә яңгырга очрадылар. Ышыкланырга бер салам эскерте янына килделәр. Сәгыйть тиз-тиз генә эскерт эчендә чокыр ясады, кызны да үз янына алып керде. Алар бер-берләренә терәлеп җылынып утырдылар. Ләкин яшь тән, яшь җан бер-беренә тартылмый каламыни?! Сәгыйть ныграк кочкан саен, кызның каршылыгы кими барды. Ул инде Сәгыйтьнең учында өлгергән җимеш кебек иде. «Йотып» җибәрер вакыт җиткәч, кыз мышык-мышык елап җибәрде. Сәгыйть

аптырап кызны кочагыннан ычкындырды. Ә күпмедер вакытлар үтеп, ул чибәркәй тормышка чыккач, аларга тагын бер очрашырга туры килде. Шунда кыз Сәгыйтькә: «Пешмәгән егет идең син, — диде. — Кызларның елавы — яшьлеге белән саубуллашу, ул ризалык билгесе».

Димәк, Сөмбел аның тәкъдименә риза. Ләкин кыз аны үзе әйтергә тиеш.

— Ни булды, матурым? — диде Сәгыйть, «пешкән җимеш» тирәсендә бөтерелеп.

— Әни риза, — диде Сөмбел, пышылдап.

— Нәрсәгә? — дип сораган булды Сәгыйть.

— Сезнең белән никахлашырга.

Сәгыйть Хәмитовичның шатлыктан күзләре ялтырады, йөрәк тибеше ешайды.

— Синең әниең бик акыллы шул. Мин аны бер күрүдә аңладым. Акыллы анадан акыллы бала туачагы билгеле.

— Тик, Сәгыйть Хәмитович, мин сезнең карт хатыныгыз белән бергә торырга риза түгел...

— Әлбәттә, матурым. Кем инде былбыл баласын карга оясына яба?! Без синең белән, сандугачым, аерым фатирда яшәрбез. Син шәһәрнең кай тирәсеннән алырга теләр идең фатирны?

— Әниләргә якынрак җирдә булса...

Сәгыйть Сөмбелнең фикерен күтәреп алды.

— Әлбәттә, матурым. Әниләргә якынрак яшәү яхшырак. Сагынганда йөгереп кенә кереп чыгасың. Әниләр белән киңәшеп эшләү, аралашып яшәү — зур бәхет бит ул. Менә минем үземә андый бәхет тәтемәде. Әни мине бик авыр тапкан, авырып киткән, шуннан терелә алмаган. Миңа ана назы күрергә туры килмәде. Гомерем буе аналы балалардан көнләшеп яшәдем.

Сәгыйть авыр сулап куйды. Сөмбел, Сәгыйть Хәмитовичны кызганып, аның эш өстәлендә ниндидер кәгазьләр өстендә яткан кулын сыйпап алды. Сәгыйть Хәмитовичның эченә җылы йөгерде. Шатлыктан җаны күкләргә ашардай булып бәргәләнде.

Алар никахны Сөмбелләрдә укыттылар. Фатир алуны да бик тизләтте Сәгыйть Хәмитович. Сөмбелләр яши торган микрорайонда биш катлы йорт төзелеп бетеп килә иде. Сөмбелне шул йортка алып кереп:

— Менә шушы йорттан кайсы фатир сиңа ошый, шуны алырбыз, — диде.

Сөмбелгә ике бүлмәле фатир бик ошаган иде, ләкин ул: «Моны әйтсәм, артык комсызлану булыр», — дип, бер бүлмәлене күрсәтте.

Сәгыйть Хәмитович аны тиргәп алды:

— Син нәрсә, матурым. Шушы сыерчык оясына кереп утырыр идеңме? Син хан сарайларын бизәрлек кеше. Аннары, киләчәгебез турында да уйларга тиешле без. Син миңа тупырдап торган ике малай табып бирерсең.

Бу сүзләрдән соң Сөмбел кызарып куйды. Ул әле һаман акылы белән бу хәлләрне кабул итеп бетерә алмый иде. Сәгыйть Хәмитович, аны җитәкләп өч бүлмәле, ике зур балконлы фатирга алып кереп: «Менә шушында булыр безнең оябыз», — диде. Сәгыйть Хәмитович Сөмбелнең бу микрорайоннан фатир сайлавына икеләтә сөенде. Беренчедән, шәһәр читендә фатирлар арзан, икенчедән, беренче хатыныннан шактый ерак. Сөмбел белән никахлашуны ул яшертен эшләде. Эш пешкәч, алма авызга төшкәч, карт хатынны ризалату авыр булмас. Ул тиктомалдан тәртә җимерә торган хатын түгел. Фатирны Сәгыйть Сөмбел исеменә яздырды. Әйдә, күңеле тыныч булсын.

Фатирның эчен ул үз зәвыгы белән эшләтте. Җиһазларны бергәләп сайладылар. Оя корылып беткәч, Сәгыйть Хәмитович Сөмбелгә:

— Матурым, сине һәр көн эшкә машина белән килеп алырлар, илтеп куярлар. Ә миңа беренче хатыным янына да кайткаларга туры килер. Ничек кенә булмасын, мин аны ташлый алмыйм. Анда минем ике кызым үсә. Синең яныңа еш килә алмасам, үпкәләмә.

Кая үпкәләү! Бу сүзләр Сөмбелне сөендерде генә.

Сәгыйть Хәмитович, яңа фатирда яшь бикәч белән берничә көн яшәүгә, ике атналык ял алып Төркиягә китте. Сөмбелнең моңа кадәр чит илләрне түгел, Мәскәүне дә күргәне юк иде. Акчаның нинди көчкә ия икәнен ул шунда аңлады. Сәгыйть Хәмитовичның йонлы түше, гел тирләп торган маңгае да элеккечә ачу китерми, ничектер гадәти булып күренә башлады. Акча, җиңел тормыш, әйтергә теләгән фикереңне ярты сүздән аңлау һәм бар теләгеңне үтәргә торучы барлыгын тою кешене тиз үзгәртә икән.

Сөмбел Төркиядән бөтенләй икенче кеше булып кайтты.

Сәгыйть Хәмитовичның беренче хатыны малайлар тапмады. Сөмбел авырга узып, малай таба калса, Сәгыйтьнең фамилиясен дәвам иттерүче һәм тора-бара эшен үз кулына алып, аның мирасчысы булыр иде. Кыз тапса, өч тапкыр «талак» әйтәсең дә аерылыша аласың. Ә хәзергә әле Сәгыйть бәхетле. Ә Сөмбел яшьтәшләре, кияүгә чыгып та кеше фатирында яки аждаһадай кайнаналары белән бергә яшәгән дуслары алдында мактанырлыгы барлыгын уйлап йөрәк яраларын ямады.

* * *

Заһит гараж подвалын торган саен ныграк баета барды. Төнге ауга ул гел ялгыз йөрде. Артык кеше — артык шаһит. Кешеләрнең берсе сатмаса, икенчесе сата. Үзе озын булса да, гәүдәсе ябык, нечкә иде. Шуңа күрә форточкадан җайлы гына кереп-чыгып йөрү аңа берни түгел. Күп кенә кешеләр форточкаларын төнлә ачык калдырып йоклыйлар. Ә ярлы кешеләр, гадәттә, булган акчаларын яшереп маташмыйлар. Күбесенең булган байлыгы шкаф тартмасында саклана. Ә кайбер карчык-корчыклар, бармаклары шешенмәсен дип, йөзекләрен салып куеп йоклаучан. Әлбәттә, Заһит башта берничә көн үзе төнге «кунак» булып барасы йортны күзәтә. Хуҗаларның кайчан йокыга ятуларын һәм торуларын күңеленә беркетә, шуннан соң гына «ауга» чыга. Шулай да ул бервакыт каба язды.

Бер яшь ханымны шактый озак күзәтте. Урамдагы малайлар белән шаярган булып, ул ханымның ире бармы-юкмы икәнлекне сорашты. Ире юклыгын белгәч, сулышы җиңеләйде. Ханым бай күренә. Муенында алтын чылбыр, колакларында ярым ай рәвешендә ясалган алтын алкалар, бармакларында калын-калын балдаклар. Заһит аның уты кайчан сүнәсен күптән өйрәнеп куйды.

Заһит гадәттә иртәнгә, кешеләр тирән йокыга талгач «эш»кә чыгарга ярата. Бу юлы аның нишләптер озак көтәсе килмәде. Әмма форточка ачык түгел иде. Ишекне ипләп кенә каерырга туры килде. Йорт яңа булганлыктан, ханым әле тимер ишек ясатып өлгермәгән, төзүчеләр куеп киткән ишекне үсмер малайлар да җиңел ача. Заһит ишекне ачканда, шылт иткән тавыш та чыкмады. Хатын ике бүлмәле фатирда яши икән. Заһит, залны актарып берни тапмагач, йокы бүлмәсенә чыкты.

«Ханымның бөтен байлыгы үзендә, ахры, — дип уйлап куйды Заһит һәм карават янына килде. — Аһ, чукынды, сөяркәсе бар икән. Әнә ничек матур итеп йоклап яталар».

Йокы бүлмәсендә тәгәрмәчле кечкенә өстәлдә шампан шешәсе, ашалып бетмәгән тәм-томнар. Заһит шешәне күтәреп карады, шешә буш. Димәк, йоклар алдыннан сыйланып утырганнар. Йокылары каты булырга тиеш. Заһитның башында бер уй туды: чукынып китсен байлыгы, кызык ясап карарга кирәк, дип, ул чишенде дә хатын янына юрган астына чумды. Ир гырылдап йоклый. Заһит юрган астында таралып йоклаучы ханымны ипләп кенә кочагына алды. Кайнар тәнгә куллары тиюгә, аның бөтен күзәнәкләре уянды. Заһит үзен тыя алмаслык хәлгә килде һәм тәвәккәлләде. Хатын йокы аралаш: «Җитте инде, Радик, алай комсызланма», — диде, әмма йокысыннан уянмады. Заһитка бу маҗара бик ошап китте. Ханымның иреннәреннән, муеннарыннан үбә башлады.

— Ну, Радик, нишләвең бу? — диде ханым.

— Тс-с! — диде Заһит, ханымның авызын учы белән каплап. — Радик түгел әле бу, Бишмунча егете.

Ханым шунда гына ныклап уянды.

— Ой, нәрсә бу? — Хатын сикереп тормакчы булды, ләкин Заһит аны караватка кысты:

— Тс-с! Шаулама! — диде ул, хатынның колагына пышылдап. Хатын караватка сеңде. Заһит хатынны шактый аунатканнан соң пышылдавын дәвам итеп: — Ә хәзер бөтен алтын әйберләреңне салып бир. Тик тавыш кубарырга уйлама. Юкса сөяркәң белән икегезне берьюлы кых итәм.

Хатын Заһитка сүзсез буйсынды. Бармагындагы балдакларын салып бирде.

— Тагын, тагын, — дип ашыктырды аны Заһит.

Хатын өстенә халат элмәкче иде, Заһит аны тартып алып Радик өстендәге юрганга ыргытты.

Радик гырылдап йоклый иде. Карават селкенүгә ул икенче якка борылып ятты.

— Акчаларың кая, акчаларың? — диде Заһит хатынның колагына.

Хатын залга таба китте. Заһит аны бик яраткан кешеседәй кысып кочаклап барды. Хатын тавыш кубармасын дип, бер кулы белән аның авызын каплады. Ләкин хатын тавыш кубарырлык хәлдә түгел, ул сөяркәсе Радикка чиктән тыш ачулы. Әгәр икесе генә калырга туры килсә, ничек итеп аннан үч алырга икән дип баш ватты. «Ваемсыз дуңгыз», — дип сүкте ул аны эченнән.

Залга чыккач, Заһит иркенләбрәк сулап куйды. Юкса ул үз нервыларының артык киеренкелегеннән зуррак җинаять эшләп ташламагаем дип курка иде. Хатын исә тәмам роботка әйләнгән. Заһит кая ымласа, шунда бара, ни кушса, шуны үти. Акча уенчык аюның эченә яшерелгән икән, бар байлыгын Заһитка тоттырды. Болар акчалар белән мәш килгәндә, нәрсәдер шапылдап төште. Тавышка Радик дигән бәндә уянып китте. Янында сөяркәсе юклыгын күргәч: «Иркәм, син кайда?» — дип сикереп торды. Утны кабызды. Заһит хатынның колагына: «Бу минем беренче мәхәббәтем, дип әйт, юкса...» — дип, хатынның касыгына берне төртеп алды.

Радик хатынны эзләп залга чыкты һәм телсез калды. Аның иркәсе бер ят ир белән кулга-кул тотынышып тора. Хәтта өсләренә дә кимәгәннәр. Оятсызлар.

Радикның каушап калуын күреп, Заһит батыраеп китте:

— Бу кем? Нишләп синдә кунып ята ул? Әле син ике сөяркә тотасыңмыни? — дип, хатынга бәйләнә башлады.

Хатын:

— Радик, ул бер карак, тизрәк милиция чакыр, — дигән иде, Заһит хатынның яңагына чалтыратып

чабып җибәрде.

— Әле син күзгә карап алдаша да беләсеңмени? — Заһит хатынны диванга төртеп екты.

Хатын Радик аны яклашыр дип көткән иде. Әмма Радик:

— Аһ оятсыз, кабахәт! Мин сиңа күпме бүләкләр ташыдым. Үз хатыныма алмаган алтын-көмешләр алдым. Сиңа берни дә җитми икән: байлык та, ирләр дә. Комсыз фахишә! — дип, диванда үксеп ятучы хатынның артына чалбар каешы белән берне сылады да ишекне шартлатып ябып чыгып китте. Заһит хатынны җәлләп куйды.

— Өеңдә бүтән акчаң калмадымы? — дип сорады.

— Ю-у-ук, — диде хатын, үксүен тыя алмыйча.

Заһит теге аю эченнән чыккан төргәкне сүтте. Анда шактый күләмдә долларлар күреп:

— Оһо, — дип куйды, — әллә чит илгә китәргә җыена идеңме? — Хатын дәшмәде. Заһит, аның янына утырып, куе йомшак чәчләрен сыйпады. — Ярый инде, тукта. Елак хатыннарны яратмыйм мин. Ә байлык өчен кайгырма. Синең кебек чибәр хатыннар байлыкны момент җыя аны. Яңа сөяркәләреңнән ике тапкыр күбрәк сора. Ә бу, — ул Радик чыгып киткән якка ымлап, — бу синең бер тырнагыңа да торырлык түгел. Куркак! Хәзер ул синең фатирның ишеген кагарга да куркачак.

Заһит сөйләнә-сөйләнә төргәктән бер яшел йөзлекне суырып алды да:

— Бусы яши торырыңа, — дип, хатынның тирләгән корсагына чәпәде. Икенче йөзлекне хатынның кендек астына сылады. — Бусы кочагыңда яткырган өчен. Ә менә монсы чибәрлегең өчен. — Заһит яшел йөзлекне төкерекләп ханымның түшендәге алмалары арасына ябыштырды. Аннары Заһит киемнәрен киенеп алды һәм, хатын каршына басып: — Әйдә, дуслар булып аерылышыйк. Саубуллашу йөзеннән бер үп тә, мин китәм. — Заһит хатынга битен сузды.

Рухы сындырылган хатын Заһитның әмерен үтәде: иреннәрен аның битенә тидереп алды.

— Бездә аны менә болай итеп үбәләр, — дип, Заһит хатынны кочагына кысып озаклап үпте. Һәм чыгып киткәндә: — Син миңа бик ошадың, бу безнең соңгы очрашу булмас дип уйлыйм. Артык чибәр син. Мондый чибәрлек күп вакыт хатын-кызга бәхетсезлек китерә. Чөнки матур чәчәкне һәркем өзәргә тели. Шунсы да бар: чибәрлек гомерлек түгел. Аны алтын әйберләрне саклагандай саклап булмый. Шуңа күрә хатын-кыз шушы байлыктан күбрәк файдаланып калырга тырыша, ягъни мәсәлән, үзенең матурлыгын алтын-көмешкә әйләндереп сандыкка сала.

— Сез психологмы әллә? — диде ханым.

— Башында мие булган кеше уйланмый яши алмый, үзеңнең уйларың тормыш тәҗрибәсе белән кушылгач, психолог та, философ та буласың.

— Төрмәдә акыллы кеше белән утыргансыз сез.

Заһит шаккатты.

— Минем төрмәдә утырганны каян белдегез? — диде ул, гаҗәпләнеп.

— Бусы инде минем сер, — диде ханым. — Мин дә үзенә күрә психолог.

— Ярый, — диде Заһит, — җәйге төн тиз үтә. Сездәй чибәрләр янында бигрәк тә. Китәргә кирәк миңа. Ә сез, теләсәгез, ун минут үткәч милиция чакыра аласыз.

Бу чибәр ханымны Заһит озак оныта алмый йөрде. Ләкин Фатыйманы йөрәктән һич куып чыгарып булмый. Әллә өйләренә барырга микән? Шунда, бәлки, малайны да күрермен. Үскәндер инде. Кемгә охшады икән: миңамы, Фатыймагамы?

Моңа кадәр малае турында уйламаган Заһитның күңелендә аталык хисләре кузгалып куйды. Егерме биш яшькә җитеп, ул инде күп кенә кызлар белән булды. Бәлки, ул кызларда да аның малае яки кызы үсәдер?! Хәер, юктыр. Бөтен кызлар Фатыйма түгел бит, бала табарга ашкынып тормыйлар. Ә Фатыйма хәйләкәр генә түгел, дәртле дә булып чыкты. Заһит унынчы класста укыган чакта, Фатыйма әле тугызынчыда гына укый иде. Аларның мәктәбе янында укытучылар өчен дип салына башлаган, ләкин бетеп җитмәгән бер йорт бар иде. Кайбер малай һәм кызлар нindидер дәрескә керергә теләмәсә, шул йортның берәр бүлмәсенә кереп кәрт сугалар яки башка уеннар уйныйлар. Беркөнне Заһит белән Фатыйма бергә туры килделәр. Фатыйманың Заһитка күптән күзе төшеп йөри икән. Ул егетне үртәргә тотынды: «Син мине тоталмыйсың, тоталмыйсың», — диде дә икенче бүлмәгә качты. Озын сыйраклы Заһитка аны куып җитү авыр булмады. Ул Фатыйманы тотып алыйм гына дигәндә, кыз кинәт тартылды да стенадан чыгып торган арматурага күлмәген эләктереп ерттырды. Кызның түшеннән кендегенә кадәр тәне ачылды. Егет кызның тулышып килгән күкрәкләреннән, ап-ак тәненнән күзен ала алмады. Фатыйма тәнен капларга ашыкмады. Фатыйма кебек кызларны аулаграк җирдә «кыскалап» өйрәнгән Заһит Фатыймага ташланды. Ул кыз тарафыннан каршылык көткән иде, ләкин Фатыйма, күптән Заһитның кочагына кереп әвәләнәсе килгәнлектән, егеткә каршылык күрсәтмәде. Заһит корбанын ботарлап ташларга теләгән бүредәй кыланды: үпте, тешләде, куллары белән кызның бөтен җирен капшады. Фатыйманың күп кенә иптәш кызлары үзләренең егетләре белән ни кыланганнарын сөйләп мактаналар. Кызның шушы яшькә җитеп егетләр кочагы татып карамавыннан көләләр, ә Фатыйма дусларының күп сүзләре уйдырма, бары тик аны аздырыр өчен генә әйтелгән икәнлеген күңеленә дә китерми иде. Аның әнә шундый «текә» кызларга охшыйсы, аларга үзенең «мажараларын» сөйләп

мактанасы килә иде. Менә, ниһаять, җае чыкты. Кем белән диген әле? Мәктәптә уннарча кызларның кумиры — Заһит белән бит. Хәзер менә мактанырга була.

Кыз шундый уйлар киеренкелегендә йөзгәндә, Заһит аны катгый кисәтеп куйды:

— Кара аны, кызый, бу турыда ләм-мим. Әгәр берәрсенә сөйләсәң, ботарлап ташлармын үзеңне.

— Ботарла! — диде Фатыйма, Заһитны котыртып.

Заһит кыздан мондый сүз көтмәгән иде, бераз аптырабрак калды. Аннары ул:

— Мин сине әкренләп ботарлармын. Ә бүгенгә өеңә сыпырт.

— Шушы килешме? — Фатыйма үзенең тагын да ертыла төшкән күлмәгенә күрсәтте. Заһит озак уйлап тормастан аңа үзенең спорт костюмын салып бирде.

— Бар, кеше-кара күргәнче тай!

Фатыйма егетнең битеннән үбеп алды да арткы сукмактан гына сыпырды. Шушы көннән башлап әле төзелеп бетмәгән өй аларның мәхәббәт оясына әйләнде.

Заһит, узгандагы шушы хәлләрне хәтер күпере аша үткәргәннән соң, Фатыймаларга яшеренминитми барырга карар кылды. Гыймае өйдә икән, өйдә булсын. Ул бит малайның үзенеке түгеллеген белә, бәлки әле, Фатыйма миннән икәнен әйткәндер. Әйтсә, тагы да шәбрәк, теге «мунча пәрие»нә аңлатып маташудан котылыр.

Һәм Заһит, әйбәт костюмнарын киеп, галстуклар тагып, көпә-көндез Фатыймаларга китте. Фатыйманың кайчан ял көне икәнлеген ул кибеткә бер малай җибәреп белешкән иде. Әлбәттә, төрмәдән яңарак чыккан кешенең башын югары күтәреп шәһәр урамыннан баруы башсызлык. Аны күзәтүләре мөмкин. Чөнки ул элекке «эшен» яңадан башлады. «Эш алымын» да юри үзгәртмәде. Кайвакыт ул: «Милициянең аңгыралыгымы, халыкның куркаклыгымы бу? — дип уйлана иде. — Нишләп кешеләр шулкадәр куркак? Милиция — үз участогында карак йөргәнлеген начальствога әйтүдән, ә халык милициядән курка. Шушы курку чылбыры боҗра булып бер-берсенә тоташкан, һич өзелерлек түгел». Беркөнне Заһит урам уртасында бер кызга бәйләнә башлады. Башта сумкасыннан кесә телефонын алды, аннары кызның кендегендәге алкасын тартты. «Үзең салып бир», — диде ул аңа, ә кырыеннан кешеләр үтә башласа, кызны кочаклап үбәргә тотынды. Үткән-сүткән кешеләр әйтерсең сукыр һәм чукрак, күрмәмешкә салышалар. Кыз кендек алкасын салып Заһитка бирде. Заһит аны тагы да ныграк сынар өчен: «Ә хәзер минем арттан бар, берәр подвалга кереп чыгарбыз», — диде дә үзе алдан китте. Кыз качармы-юкмы дип тикшерүе иде аның. Бераз баргач артына борылса, кыз аның артыннан килә. Шунда кырыйдан бер милиционер да үтеп китте югыйсә. Заһит, кызга борылып: «Ярар, бар, кит инде. Аппетитым бетте», — дип китеп барды.

Заһит милициянең борын төбендә җинаять эшләргә ярата. Чөнки ул милициядә шактый ук туңбашлар утыруын белә. Алар җинаятьчеләрне каяндыр читтән эзли. Тумыштан ук кеше психологиясенең нинди борылышларга сәләтле икәнлеген белүчеләр үсә барган саен моны ныграк үзләштерәләр. Заһит кебек төрмә мәктәбен узганнар дошманыңа никадәр якынрак булсаң, шулкадәр куркынычсызрак икәнен аңлый. Өстәвенә Заһитның кесәсендә «аеруча куркыныч җинаятьләрне ачучы» дигән бик шәп документ бар. Төрмәдә алар Академик кушаматлы бәндә белән бер камерада утырганнар иде. Академик — компьютерлар белгече. Берәр документны кулга төшерсә, теләсә кем исеменә ясап бирә ала. Мөһерләр ясаучы дусты Тәгәрмәч белән алар бергә эшли. Ике дус, шактый ялган документлар ясап, зур байлык туплый. Ләкин ике кеше белгән нәрсәне өченче берәү белми калмый. Боларны да каптыралар. Тик тупланган байлык үзенекен эшли: берничә айдан Академикның адвокаты аны төрмәдән коткаруга ирешә. Заһитка әлеге документны шул дусты эшләп бирә.

Фатыймаларга ул бик батыраеп барып керде. Подвалдан соң хатын моны көтмәгән иде. Гыймай аның бот араларын кычыткан себеркесе белән чапкач, ул үкенү хисе кичермәде, киресенчә, иреннән үч алу турында уйлана башлады. Заһитның һич көтмәгәндә көпә-көндез килеп керүе аны гаҗәпләндерде дә, шатландырды да. Әмма шатлыгын тышка чыгарырга ашыкмады.

— Синең аркаңда мин ничә көн салкын су салынган таста утырдым, — диде ул, үпкәләгән сыман кыланып.

— Нинди салкын су? Нигә утырдың? — дип, Заһит төпчеnә башлады.

— Менә бу җиреңне кычыткан белән чапсыннар әле, син нишләрсең икән?

— Әллә «мунча пәрие» кычыткан белән чапты? — Заһит кычкырып көләргә тотынды. — Башлы адәм икән. Кая, бик нык авырттымы? — Заһит Фатыймага үрелде, тик тегесе аның кулына сукты.

— Кармаларга гына торма әле. Сиңа кызык. Ә миңа бер дә кызык булмады.

— Әйдә алайса тагын бер кызык ясыйк.

— Гыймай кайтып керсә?

— Кайтып керсә, тагын да кызыграк булыр.

— Син, куркак, чыгарсың да качарсың.

— Качмыйм! Мин малайны күрергә килдем.

— Малайны? Синең малаең бармыни?

— Кыланып маташма, югыйсә мин дә кызык ясармын. — Заһит Фатыйманы бөтереп алды.

Түшендәге төймәләрен берьюлы сыдырып төшерде. Күлмәк ертылды. Фатыйма теге вакытта мәктәпнең төзелеп бетмәгән йортында нәкъ шушының төсле иде. Заһит хатынның киемнәрен бөтенләй ертып ыргытты. Ничек кенә сәер тоелмасын, Фатыймага Заһитның шушы кыргыйлыгы ошый иде.

— Малай кая? — диде ул, хатынны караваткa ыргытып.

— Малай синеке түгел инде ул. Аны Гыймай туу белән үз исеменә яздырды. Ул бит синең кебек куркак түгел.

— Мин куркакмы? — Ул ерткычларча Фатыймага ташланды. Ләкин Фатыймага мондый «җәза» тансык кына иде. Юкса Гыймай сыйпаштырып, назлаштырып ярты сәгать кыштырдый. Дөрес, Фатыйманың яратмавын белә, ләкин вакыт һәм йомшаклык үзенекен итәр, хатыны аны ярата башлар дип өметләнә. Наз белән кулга ияләштереп булмый торган җанварларның барлыгын белми иде шул Гыймай. Кайбер җанварлар бары камчыга гына буйсына.

Фатыйма белән Заһит ике ерткыч кебек караватта тәгәрәшеп ятканда, Гыймай кайтып керде. Башта ул берни аңламый торды. Аңлагач, иң беренче хатынын караваттан сөйрәп төшереп, һәрвакыт «кычытып» торган җиренә көрәктәй кулы белән берне чәпәде. Фатыйма почмакка барып сыланды. Чират Заһитка җитте. Гыймай аның «мактанычы»ннан умырып тотты да: «Йолкып ыргытам, кабахәт!» — дип үкерде. Ләкин төрмә «мәктәбе»н үткән Заһит югалып калмады: яшен тизлегендә Гыймайның ияк астына тезе белән китереп бәрде. Имән төбедәй Гыймай чайкалып китте, аңы томалангандай булды. Шушы мизгелдән файдаланып Заһит аңа тагын берне чәпәде. Гыймай гөрселдәп ауды.

— Үтерәсең бит, — дип, Фатыйма арага кермәкче иде, Заһит аңа акырып җибәрде:

— Кит! Урам себеркесе! Юкса үзеңә дә эләгер. — Заһит киенә башлады. Гыймай аңына килгәнче чыгып таюың яхшы. «Мунча пәрие»нең кулы каты. Гыймай аңына тиз килде.

— Алып чыгып кит кәнтәеңне. — Ул Фатыймага борылды. — Бар, эзеңне югалт. Бүтән бу өйгә борылып карыйсы булма.

— Миңа синең себеркең кирәкми. Үзеңдә калсын. Урам себерергә тотарсың. Мин малаемны күрергә генә килгән идем. Кая минем малай?

Гыймай югалыбрак калды. Ләкин бик тиз исенә килеп мич алдында өелеп торган бер утын яркасы алып: «Менә синең малай», — дип, Заһитның йөзенә кулындагы утын яркасын атты. Читкә тайпылып калмаса, Заһитның маңгае ярылачак иде. Ул тизрәк таю ягын карады. Гыймайның кышын өненнән куалап чыгарылган аю хәлендә икәнлеген аңлады ул.

Заһит чыгып киткәч, Гыймай Фатыйманың киемнәрен өстенә атты:

— Бар, өстерәлчек, калма үзеңнең төрмә кандалаңнан. Бергәләп төрмәдә кандала симертерсез.

— Син кумасаң да, бүтән синең өеңә аяк атламаячакмын, — диде Фатыйма. — Синең тәнеңә сеңгән дуңгыз исен иснәп яткан мин дурак.

Гыймай хатынының сүзләрендә күпмедер хаклык барлыгын аңлый, әлбәттә. Эштән кайткач ныклап юынырга күп вакыт өйдә җылы су булмый. Һәр көнне әниләренә мунчага бармассың бит инде. Хәер, күпме генә юынма, тәненнән килә торган әчкелтем ис бетми. Баштарак Фатыйма: «Син әллә фермада дуңгызлар арасында тудыңмы?» — дип, Гыймайның җен ачуларын чыгара иде. Аннары ул иренә кибеттән төрле дезодорантлар алып кайта башлады. Тик нәселдән үк килгән ул исне дезодорантлар гына басмый, киресенчә, тагын да яманрак ис барлыкка китереп Фатыйманың күңелен болгата һәм, бер якынаеп алганнан соң, аерым караватларга күчәргә мәҗбүр булалар иде.

Гыймай беренче мәртәбә Заһиттан көнләште. Иснәп карасаң, бәлки, аңардан тагын да яманрак ис киләдер, ләкин чибәр. Шәһәр егете. Ә Гыймай чынлап та бәләкәйдән дуңгызлар арасында үсте. Әти-әниләре, моңардан барыбер әллә кем чыкмас дип, аның укуына да битараф карадылар. Гыймай үзенең дуңгыз карауны булачагына күнегеп килгәндә, шәһәрдә яшәүче балалары кинәт кенә үлеп китте. Хатынын моннан бер ай чамасы элек кенә җирләгән карт, ялгызлыкны күтәрә алмый, карчыгы артыннан китте. Ушлы карт үзенең өен әллә кайчан улына, ягъни Гыймайның әтисенә яздырган булган икән.

Колхозлар таркалып, авылга төрле яклардан әллә нинди әтрәк-әләмнәр кайта башлаган чак иде. Гыймайның әтиләре Кыргызстаннан кайткан, ни кыргыз, ни татар түгел бер бәндәгә йортларын сатып шәһәргә күчтеләр. Гыймай, русчаны бик үк әйбәт белмәгәнлектән, укуын дәвам итмәде. Әтисе янына таш чыгаручы булып эшкә керде. Авылдагыга караганда монда акча күп төшә, өстәвенә ташны үзенә алып кайтырга яки кирәк кешегә сатып җибәрергә дә мөмкинлек табыла. Әкренләп Гыймайга да йорт тергезделәр. Башта ул кечкенә генә иде, тора-бара зурайттылар. Шәһәр үсә башлагач, өйгә газ һәм су кертергә дә мөмкинлек туды.

Ләкин шәһәрдә яшәүгә карамастан, Гыймай күңеле белән авыл кешесе булып калды. Фатыйманың сүзләрендә хаклык бардыр, күрәсең. Кем белә, бәлки, күңелдәге авыл, төшләргә кереп интектерүче пычрак дуңгыз фермасы аның күзәнәкләре аша тышка чыгадыр. Күңелнең сафлыгын исбатлау кыен, ә начар ис төтен кебек тышка бәреп чыга. Өч буыннан күчкән дуңгыз исен шәһәр сабыннары гына юып төшерә алмый шул.

* * *

Фатыйма бер чемоданга сыярлык кына әйбер алды. Аның Заһит биргән теге алтын әйберләре генә дә Гыймайның бөтен байлыгыннан күбрәк иде.

— Баланы алып китәргә җыенма, — диде Гыймай. — Син бала үстерә ала торган хатын түгел. Гомумән, бу тирәдә күренмәвең яхшы.

— Бала кирәк булса, орлыгы Бохарада түгел, табармын. Заһитны сиңа калдырам. Минем баласыз, сөрсегән ирсез яшәп карыйсым килә.

Фатыйма ишекне шартлатып ябып чыгып китте. «Ярый әле малай өйдә булмады», — дип сөенде Гыймай. Әлбәттә, әнисен сорашачак: әнисенең нинди икәнен белми бит ул. Белгән очракта да бала өчен ана дөньяда иң кадерле, иң әйбәт кеше.

Гыймай, терсәкләре белән өстәлгә таянып, учлары белән башын кысты. Күңеленнән уйлар дулкыны узды. Тормышның таркалуына кем гаепле соң? Фатыйманы корсаклы килеш хатынлыкка алып үзе ялгыштымы? Ә бит авылдагы туганнары Гыймайга менә дигән кызлар яучылап карадылар. Берсе белән Гыймай бераз якыная да башлаган иде. Кыз фермада эшли. Бәлки, ул Гыймай тәненнән килгән искә игътибар итмәгән булыр иде. Ләкин Гыймай аны әниләренә күрсәтергә алып кайтып ялгышты. Дөрес, әниләре кызны бик әйбәт кабул иттеләр. Кыз матур ук булмаса да, ягымлы иде. Тик бөтен эшне Гыймай үзе бозды. Кызны бернинди бүләксез озатып җибәрүне яхшысынмыйча, аны бер кибеткә алып керде. Бу Фатыйма эшли торган кибет иде. Гыймай беренче кат Фатыйманы шунда күрде. Фатыйма аңа фәрештә булып күренде. Ул хәтта кибеткә ни өчен кергәнен онытып торды.

— Бу чибәр парларга ни кирәк икән, белик әле, — дип, Фатыйма болар каршына килеп баскач, Гыймай, кесәсендәге бөтен акчасын чыгарып:

— Шушы акчаларга берәр әйбәт туфли тияме? — дип сорады, чөнки кызның аягындагы туфлиләре нык тузган күренә иде. Аяк киемнәре сайларга кызны эчкә алып кереп киттеләр. Ул аннан өр-яңа туфлиләр киеп чыккан иде. Ул, Гыймайга рәхмәт әйтеп, автовокзалга юл тотты. Ә Гыймай Фатыймадан күзен алалмыйча озак карап торды.

— Кәләшеңне берүзен җибәрдеңмени? — диде Фатыйма. — Авыл кызы шәһәрдә адашырга мөмкин.

Гыймай Фатыйманың күзәтүчәнлегенә шаккатты.

— Каян белдегез аның авыл кызы икәнен? — диде ул.

— Авыл кызларын кояшта янган битеннән, әйбер сайлавыннан һәм тагын әллә нәрсәләрдән белеп була.

— Кызык! — диде Гыймай.

— Кызыгын кызык. Ләкин синең кәләшеңне ялгызын чыгарып җибәрүең бер дә егетлек түгел.

Гыймай үзенең мәгънәсезлегеннән кыенсынып хатасын төзәтергә ашыкты. Тик күпме генә эзләсә дә, кызны тапмады. Ә Гыймай шушы керүдән соң Фатыйма эшли торган кибеткә эзне суытмады. Фатыйманың кешеләр белән сөйләшкәнен, аккош муеныдай кулларының хәрәкәтен күзәтүдән ниндидер ләззәт алды. Ул инде авылдагы теге кызны оныткан иде, тик бермәлне аңа посылка килеп төште. Анда Гыймай алып биргән туфлиләр һәм усал итеп язылган хат бар иде. «Шәһәр егетләрен оятсыз дип әйтәләр иде, дөрес икән. Мине бөтен авыл алдында хур иттең. Ә мин, юләр, ул туфлиләремне иптәш кызларыма күрсәтеп мактанып өлгергән идем. Сиңа актык сүзем шул: мине кимсеткән кебек үзеңне дә кимсетсеннәр, хур итсеннәр. Хуш!»

Гыймай, шушы хәлләрне исенә төшергәч, аның каргышы төшкән миңа дигән нәтиҗә ясады һәм: «Шул кирәк сиңа! Шул кирәк сиңа!» — дип, үз-үзен кыйнады.

Ул шулай бәргәләнеп утырганда, кечкенә Заһит кайтты.

— Уф, ашыйсым килде, әти.

— Хәзер берәр нәрсә әзерләп бирермен, улым.

— Ә әни кайда?

— Әниеңме?

— Әни дим бит инде, — диде малай, кайнарланып.

— Әниең, улым, командировкага китте. Кибетләренә чит илдән товар апкайтырга.

— О-о, — диде Заһит, — чит илдән әни миңа бер малайда да булмаган берәр шәп нәрсә апкайтачак инде алайса, әйеме, әти?

— Әйе, улым.

— Ә беләсеңме нәрсә апкайтачак ул миңа?

— Юк шул, белмим, улым.

— Ул миңа роликлы коньки апкайтачак.

— И-и, алар бит бөтен малайда бар диярлек.

— Аларныкы чит илнеке түгел. Подшипниклары тарала. Бурсыкныкы гына шәп.

— Кем соң ул Бурсык?

— Бурсык Бурсык инде. Әтисе аның гел чит илләргә йөри, ди. Машинасы гына да безнең

бабайларның мунчасы хәтле бар. Үскәч мин дә машина алам, әти.

— Алырсың, улым, алырсың. Ә хәзер аша, колбаса белән ипи бар. Соңыннан тагын берәр нәрсә пешерермен.

Малай колбасаны пычак белән кисеп тормастан сындырып кына алды да умырып ашый башлады.

Гыймай улының комсызланып ашаганын карап торды.

«Фатыйманы куып чыгардым чыгаруын. Тик ул бит: «Ник һаман әни кайтмый?» — дип аптыратачак. Куып чыгармый да мөмкин түгел иде. Гыймайда ирлек горурлыгы дигән нәрсә бар лабаса. Ичмасам, сиздерми эшләсеннәр иде. Хәер, сиздерми эшләгәннәре дә күп булды инде. Кемдер аңа бише белән арттырып сөйләгәндә җир тишегенә кереп китәрдәй буласың. Ә малайны әнисеннән бөтенләй читләштерергә ярамас. Әнисенең эшләгән кибетен белә ич ул. Әйдә, әниләр кибетенә барыйк, дияр. Ә Фатыйма аны күрергә теләмәсә? Ул бит Заһит дип үлеп тормый. Хәер, нинди ана үзенең улын күрергә теләмәс?! Йөгереп кайтып җитәр әле. Тик кайтса нишләргә?»

* * *

Гыймай белән чәкәләшкәч, өлкән Заһит абыйсы Сәгыйть янына китте. Сәгыйть үз кабинетына килеп керүче Заһитны күргәч сагаеп калды.

— Нишләп йөрисең монда?

— Сине сагынып килдем.

— Мин сине бер дә сагынмаган идем әле. Кеше күрсә?..

— Күрсә соң? Син бит минем әтием урынына калган кеше. Аның бертуган энесе. Үз абзаң янына килү гаепмени?

— Төрмә кандаласы белән аралашып пычранасым килми минем.

— Аһ, паразит, күрсәтермен мин сиңа төрмә кандаласын!

Заһит абыйсының якасына барып ябышты. Сәгыйть буыла башлады:

— Җи-и-бәр, үтерәсең.

Заһит кулын бушатты.

— С-син нәрсә? Абзаңны үтерергә килдеңме монда? Кулыңны бик озайтсаң, кыскарттыру юлларын табармын мин.

— Сине үтерүдән миңа ни файда?

Алар тынычрак тонга күчтеләр. Заһит абыйсының кабинетына күз йөртеп чыкты. Җиһазлар гади. «Хәйләкәр төлке. Байлыгын күрсәтергә теләми. Яңа импортный машинасында да сирәк йөри». Заһит ят уйларын читкә куеп, төп мәсьәләгә күчте.

— Менә нәрсә, абзыкай...

— Нәрсә?

— Миндә артык әйберләр күбәеп китте, шуларны үз кибетең аша саттыр әле.

— Каян килде әле сиңа ул артык әйберләр?

— Дусларым китерде.

— Дусларың үзләре сатсын. Нигә сиңа китерәләр? Күңелем сизә: син тагын теге элекке «эшеңә» керешкәнсең. Кара аны, сак бул!

— Син үзеңне бел, — диде Заһит, кыза башлап. — Әллә синең менә бу клуб хәтле кибетең күктән төште дип уйлыйсыңмы?

— Минем бөтен байлыгым — законлы, хәләл.

— Әкият сөйләмә, абзыкай. Иң беренче этине талаудан башладың син. Әти авариягә эләккәч, аның ларегын җайлы гына үзеңнеке итеп куйдың. Мин бәләкәй идем, берни аңламый калдым.

— Мин сиңа йөз кат күрсәттем инде ул документны!

— Нинди документ?

— Әтиеңнән ул ларекны сатып алуым турындагы документ. Әтиеңә, үзең беләсең, кыйммәтле дарулар күп кулланырга туры килде. Даруны бушлай бирмиләр. Менә шунда этиең үзе миңа ялынды: ал инде ларегымны, дип.

— Хәзер син теләсә ничек алдый аласың. Әти юк, әни Үзбәкстаннан килгән килмешәккә кияүгә чыкты. Өйләрен крепость итеп куйдылар. Керә дә алмыйсың аларга.

— Хатын-кыз байлыкка кызыгучан шул, берни эшләр хәл юк. Ә ул әниеңнең «килмешәге» бик хваткий булып чыкты. Хәзер әнә ашханә ачып ята. Әниең балда-майда йөзәчәк.

Заһитның үзеннән-үзе тешләре кысылды.

— Ух! Яратмыйм шул хатын-кызларны. Барысы да бер б...әт.

Сүз икенче темага күчкәч, Сәгыйтьнең нерв киеренкелеге кими төште. Ул астыртын елмаеп Заһитка бармак янады.

— Берсен яратасың, үлеп яратасың...

— Фатыйманымы?

— !

— Ачуымны китермә. Мин гомумән ярата белмим. Мин аларның барсыннан әни үчен алам. Ерткалап, өзгәләп бетерәсем килә шуларның кайбер җирләрен. — Заһит сүгенеп куйды. — Ярар, — диде ул аннары, — баштагы сүзгә күчик: аласыңмы минем әйберләремне?

— Син нәрсә? Минем башымны төрмәгә тыгарга телисеңме әллә? Синең документсыз-нисез әйберләреңне сатарга дурак түгел лә мин.

— Мин сиңа теләсә нинди документ ясап бирермен.

— Андый фальшивкалар тагы да куркынычрак.

— Кем әйтте сиңа фальшивка дип.

— Син ясагач, фальшивка була инде ул.

Заһит кесәсеннән кызыл таныклык алып абыйсына сузды:

— Менә моны кара әле. Берәр хәрефендә фальшивка табарсыңмы?

Сәгыйть Заһитның «Аеруча куркыныч җинаятьчеләрне тикшерүче» дигән таныклыгын төрле яклап тикшерде һәм гаҗәпләнеп тел шартлатып куйды.

— Да-а, егеткәй, төрмәдә юкка гына ятмагансың икән! Үзең эшләдеңме?

— Ансы синең өчен не важно.

— Минем өчен бөтенесе важно, энекәем. Мин хәзер шәһәрдә танылган кеше. Югалтыр әйбереңбулмаганда гына бөтенесе не важно, ә минем югалтыр нәрсәләрем күп. Хәзер минем исемемә тап төшерергә ярамый. Минем исемем үзе кыйммәтле байлык.

— Мактанма әле, яратмыйм шапырынучыларны.

— Ярар, конкрет эшкә күчик. Нәрсәләрең бар?

— Радиоаппаратура, кыйммәтле савыт-саба, алтын-көмеш һәм башка вак-төяк шунда.

— Әгәр тиешле документларны менә бу таныклыгыңдагы кебек пөхтә эшләтеп ала алсаң, товарларыңны әзләп-эзләп китерерсең. Ләкин бер шарт белән.

— Нинди шарт?

— Табышы бермә-бер булса гына.

— Ай-һай комсыз да син, абзыкай. Энеңә үзең ярдәм итәр чагында.

— Менә бит ярдәм итәргә торам.

— Ярар, — дип кул селтәде Заһит, — утыз процентын алып калырсың.

Энесенең бу тәкъдименнән Сәгыйть бик канәгать иде. Алар, ниһаять, тынычланып калдылар. Ләкин Заһитның сүзе бетмәгән иде әле.

— Тагын бер йомыш бар әле сиңа, абзыкай, — диде ул.

— Нинди йомыш? Акча кирәкме?

— Юк, мин үзем акча. Сүз Фатыйма турында.

— Фатыймага ни булган?

Заһит үзенең Гыймай белән сугышуы, Фатыйманы ире куып чыгаруы турында сөйләп бирде.

— Куса, анда синең ни эшең бар. Ир белән хатын бүген сугыша, иртәгә татулаша. Кибеттә Фатыйма әйбәт эшли.

— Эшлидер, ләкин аны берәр җиргә олактырырга кирәк.

— Бу ни дигән сүз тагын?

— Хәзер иреннән аерылгач, Фатыйма миңа сыланачак.

— Сыланса, бик яратыша идегез бит.

— Әйтмә әле шул сүзне. Нинди яратышу булсын?! Миңа аннан тизрәк котылу хәерле. Ире белән торганда ул куркыныч түгел иде, хәзер — куркыныч. Мин бер ялгышлык эшләп ташладым.

— ?

— Үземнең яшеренеп яткан җиргә алып кердем. Шунда минем әйберләр. Ә хатын-кыз авызында сүз тормаганны үзең беләсең.

— Да-а, егеткәй. Ахмаклык эшләгәнсең шул. Болай булгач, Фатыйманы эштә калдырырга һич ярамый. Ләкин эштән куу гына да проблеманы хәл итмәячәк.

— Синең танышларың күп, бәлки, үзең кебек бабник берәр бизнесменга сөяркә кирәктер. Ләкин үзебезнең шәһәрдә түгел.

— Шәп идея бу. Башың эшли, егеткәем.

Алар уртак тел таба алуларына шатланып аерылыштылар.

* * *

Фатыйманың бүген нигәдер эче пошып, күңеле тынычсызланды. Юк, бу Гыймай куып чыгарганнан гына түгел. Әлегә кадәр андый пошыну хисе кичергәне юк иде бугай. Нәрсәдән соң бу? Эше әйбәт бара. Хуҗа аңардан бик канәгать. Башкалар алдында аны гел үрнәк итеп куя. Тик менә Сөмбел эшли башлагач, хуҗа аңардан суына төште. Әмма нишләмәк кирәк? Һәрнәрсә вакытлы була, күрәсең. Боларны гына белә Фатыйма, ләкин эчкә йөгергән тынгысызлык дулкыны нилектән барлыкка килгәнен

генә аңламый. Югыйсә бөтенесе элеккечә кебек. Заһиты Фатыйма дип үлеп тора.

Заһит аны бәхетсез итәр өчен көпә-көндез өйләренә килүен, тату гына яшәп яткан гаилә учагына күкерт салып, үз казанында талгын гына кайнап уртак ботка пешерүчеләрне пыран-заран китерүдән тәм табуын Фатыйма каян белсен. Заһит, оста артист кебек, үз ролен ышандырырлык итеп башкара. Тышкы кыяфәт, кинәт үзгәрүчән йөз, нининдер китаплардан ятланган сүзләр күңелендәге үчне, явызлыкны каплап тора. Дөрес, вакыт-вакыт аңарда кешелек сыйфатлары уянгалап куя, әмма мондый халәт җил өреп сүндергән шырпыдай тиз сүнә.

Фатыйманың бүгенге эч пошуы әллә Заһитны аңлап бетермәүдәнме? Заһит серле. Фатыйманы өзелеп яратуга карамастан усал кылана. Бәлки, пошынуы улын Гыймайда калдыргангадыр? Малайны авылга әбисе янына илтеп куярга микән әллә? Юк, монда әтисе янында аңа яхшырак. Гыймай аны үз улыдай ярата. Ә Фатыймага ул әллә бар, әллә юк. Барлык иркә-назларын Заһитка бирә ул. Әйе, Заһитка, Заһитның өлкәненә.

Заһитны уйлау Фатыйманың күңелен күтәреп җибәрде. «Теге җиренә зыян килмәде микән? Гыймай бик умырып тоткан иде бит. Күрергә иде үзен».

Фатыйма эше беткәч кибеттән чыкты да Гыймайларга таба атлады. Бераз баргач: «Кая барам мин җүләр? Гыймай мине хәзер бусагадан да атлатмаячак».

Фатыйма туктады һәм Заһитның яшеренеп ята торган подвалына барырга ниятләде. Тик адымнары әкренәйгәннән-әкренәйде. Заһит бит аңа үз янына килеп йөрмәскә кушты. Нишләргә?

Шулай уйланып торганда, аның янына бер машина килеп туктады.

— Сезгә кайсы якка? — дип сорады шофер егет, машина тәрәзәсеннән башын ярым чыгарып.

— Бәхет кайда — миңа шул якка.

— Алайса, икебез бер якка икән.

Машина кузгалып китте. Ирек Фатыйманың кибеттән чыкканын ярты сәгатьләп көткән иде. Сәгыйть Хәмитович Иректне Заһит чыгып китүгә үзенә чакырган һәм Фатыйманың документларын тоттырган, ни эшләргә кирәклеген аңлаткан иде. Ирек Фатыйманың кибеттән чыгуын борчылып көтте. Ничегрәк итеп Фатыйманы машинама утыртырмын икән дип баш ватты. Ә асыл кош читлеккә үзе очып керде. Эшләр шулай әйбәт кенә барса, Ирекка шактый зур калҗа эләгәчәк. Аның күңеле шуны уйлап сөенде.

Ә Фатыйма, йомшак машинага кереп утыргач, бар дөньясын онытты. Машина хуҗасы сүзчән кеше түгел. Эч пошканда машина утыргычында тирбәлеп үз уйларыңа чуму рәхәт. Бу тирбәлеш күңелне тынычландыра, аңны йоклата. Фатыймага кая барса да барыбер иде. Хәер, ул әле үзенең эшеннән куылганлыгын, Заһитның аңардан котылырга тырышуын белми, бары тик эчке тоемлау нәтиҗәсендә генә нининдер күңелсезлеккә тарыганын сизә һәм шушы билгесезлектән качарга тели иде.

— Кайтып җиттек, туташ-ханым, — диде Ирек. — Әйдәгез, өйгә керәбез.

— Минем өй башка яктарак иде, сезгә кайтканбыз икән, кереп чыгыйк инде. Байлар ничек яши икән, күрик.

— Байлык дигән нәрсә әлегә безгә койрыгын тоттырмый. Шулай да бер эләктерергә өмет бар.

Алар өйнең эченә уздылар.

Дөрестән дә, монда бай кеше яши диярлек түгел. Җиһаз юк дәрәҗәсендә. Йортның өске каты эшләнә генә башлаган. Бары тик аш пешерү бүлмәсендә генә бөтен нәрсә бар.

Егет Фатыйманы шунда алып керде.

— Нәрсә ашыйбыз? — диде хуҗа.

Фатыйма, юри генә:

— Кызыл балык, — дигән иде, Ирек өй диварының чокырына кертеп куелган ике суыткычның берсеннән пешереп туңдырылган кызыл балык алды. Ул аны микродулкынлы мичтә тиз арада кайнарлады. Табын уртасына бер шешә ят эчемлек менеп утырды.

— Сез каршы булмасагыз, ашар алдыннан бераз гына тамак чылатып алыйк, — диде егет һәм, Фатыйманың рөхсәтен дә көтмичә, юан корсаклы фужерларның төбенә берничә йотым эчемлек тамызды.

— Әйдәгез, танышу хөрмәтенә.

Фатыйма каршы килмәде. Эчемлек тәмле иде, йотып куйды. Аннары өстәлдәге кызыл балыкның тәмен белеп карарга уйлады. Ләкин хуҗа әллә ни арада аның авызына конфетмы-ниме каптырып өлгерде. Аннан алар күптән күзне кызыктырып торган кызыл балык ашадылар. Табында ризыклар күп иде, егет ашау белән мавыкты, ә Фатыйманың тагын бераз теге тәмле эчемлекне эчеп карыйсы килә иде. Хуҗаның күңеле сизгер икән, ул: «О-о, мин каршымда гүзәл ханым утырганны онытып җибәргәнмен ләбаса», — диде. Ул фужерларга тагын бер-ике йотым эчемлек салды. Фатыйма белән чәкештерсә дә, үзе авыз гына тидереп алды.

— Сез бик тәти егет икән, хәтта үз өегездә эчәргә куркасыз. Мин көчләр дип шүрлисезме?

— Юк, мин алай ук изгеләрдән түгел, — диде Ирек. — Ләкин минем рульгә утырасым бар. Ә юл инспекторлары бик бәйләнчек халык бит.

— Шулайдыр, — диде Фатыйма, — минем бит машинам юк. Булмаячак та.

— Алай кырт кисәргә ярамый, Фатыйма туташ.

Фатыйма аңа гаҗәпләнеп карады.

— Сез минем исememне каян беләсез?

— Сезнең кебек чибәрләрнең исемен белмәгәч, мин нинди егет булам ди. Сез бит Сәгыйть Хәмитович кибетендә эшләдегез.

— Ничек инде «эшләдегез»?! Мин хәзер дә шунда эшлим.

— Ә-ә, әйе. Ә минем исемем Игорь.

— Игорь? Сез бит татар баласы.

— Әйе, чеп-чи татар. Ләкин без, татарлар, үзебезгә кем ничек дәшә, шуңа күнегәбез.

Әңгәмә белән вакытның үткәне сизелмәде. Алар күптәнге танышлардай һәрнәрсә турында ачыктан-ачык сөйләштеләр. Фатыйма авылда әнисе барлыгын, аңа ай саен акча салып торганлыгын, атасыз бала буларак шәһәр интернат-мәктәбендә укуын, укуы беткәч сатучы булып эшли башлавын сөйләде.

— Ул яктан без почти туганнар икәнбез, мин дә балалар йортында үстем, — диде Ирек.

Билгеле, Фатыйма моңа ышанып җитмәде. Балалар йортында үскәннәрнең күбесе сукбайлар төркеменә кушыла. Чибәррәк кызлар фахишәлек юлына кереп китә. Безнең илдә картлар белән балалар — иң хокуксыз затлар. Алар җәмгыятькә кирәкми. Әнә Фатыйманың әнисе алган пенсия бер кибеткә чыгып керерлек кенә. Өйләре җимерелеп бара. Ә Фатыйма җибәргән акчалар тишек-тошыкларны гына ямарга җитә. Бу илдә сыртыңа сукканга да рәхмәт әйтеп яшәмәсәң, гомер җебең бик тиз шартлап өзелә. Фатыймадагы горурлык хисен эшкә кергәннең икенче атнасында ук таптап юк иттеләр. Ул вакытта әле Фатыйма башка кибеттә эшли иде. Кибет хуҗасына чибәр яшь кыз бик ошады. Ул Фатыйманы һәр җирдә эзәрлекли башлады. Кызның югалтыр байлыгы булмаса да, хуҗаның үз артыннан чабуы, кыйммәтле бүләкләр алып бирүе аның күңеленә хуш килә һәм бу хәлнең озаккарак сузылуын тели иде. Хуҗа әле яшь, кибете дә зур түгел. Әмма ят кешеләр алдында үзен президенттан ким тотмый. Әллә кемнәргә тау-тау вәгъдәләр бирә. Фатыйманың әнисе авылда иске йортта торуын белгәч, бер көндә аңа «өй салып» бирде. Алдашудан, алдын-артын уйламыйча вәгъдә бирүдән ул ниндидер тәм таба. Зуррак вәгъдә биргән саен, үзен зуррак итеп тоя. Фатыйма белән мактанчык хуҗаның мөнәсәбәтләре ничек бетәр иде, билгесез. Тик көннәрдән бер көнне аны кулга алдылар, кибетен яптылар.

Фатыйма Игорь-Ирекка боларны сөйләп тормады. Бүген Фатыйманың ни өчендер бар нәрсәдән иреклe буласы, хәтта эчеп исерәсе килде. Шуңа күрә егет теге якка чыгып киткән чакларда шешәдәге эчемлекне үз фужерена тутырып салып эчеп куйды. Хуҗа моны күрмәмешкә салышты. Хатынның исерә башлавын күреп, җенси хисләре уянды.

Ирек Илсур Мансурович дигән кешенең шалтыратуын көтә иде. Шул ук вакытта Фатыйма белән бераз кети-мети уйнап аласы да килә. Фатыйма моңа үзе дә каршы түгел шикелле. Әмма иң кирәкле вакытта телефон шалтырап куйса.

Фатыйма исеребрәк китте, аның йокысы килә башлады. Ул изүләрендәге төймәләрне чишеп җибәрде.

— Ярдәм кирәкмиме? — диде Ирек һәм хатынга чишенергә булышты.

Егет аны урынга күтәреп салмакчы иде, шул вакыт Фатыйма аны муеныннан кочып алды.

— Неужели җаныгыз юк сезнең?

Һәм алар икәүләп караватка аудылар.

«Тәне кайнар чукынмышның, — дигән фикер үтте егетнең башыннан. — Шәп!..»

Эшнең нәкъ кызган чагында телефон шалтырады. Егет мендәр кырыена куйган кечкенә телефонын алды.

— Тыңлыйм, Илсур Мансурович.

Телефонда калын тавыш яңгырады:

— Игорь, миңа баярак Сәгыйть Хәмитович шалтыратты. «Сайрар кошны» син эләктерә алмадыңмы әле?

Ирек Фатыйманың иреннәреннән бер үпте дә: «Мин хәзер», — дип, икенче бүлмәгә чыкты.

— Әлү, Илсур Мансурович, сез әйткән «сандугач» кулга төшәргә тора. Сезгә аны кайчангарак китерергә?

— Иртәгә көндезге икедә минем кулда булсын.

— О'кей, Илсур Мансурович.

Ирекнең эченә җылы йөгерде. Ул Илсур Мансуровичның талканы коры икәнлеген белә, шуңа күрә: «Немедленно табып китер», — дип әйтүен көткән иде. Болай булгач, «сайрар кош» белән төне буе сайрашып чыгарга мөмкин икән.

Ул өстәлдә калган эчемлекне фужер тутырып эчте, үзенең кыяфәтен көзгедән карады һәм Фатыйма яткан караватка чумды.

— Тагын бераз телефоннан аерыла алмый торсаң, миннән җилләр искән булыр иде, — диде Фатыйма, үпкәсен белдереп.

Ирек аңа җавап биреп тормады, кочагына алды. Караватта юрган асты көрәше башланды.

Иртән торгач Фатыйма эшкә барырга җыена башлаган иде, Ирек:

— Син кая җыенасың? — дип, аның каршысына басты.

— Кая булсын, эшкә!

— Кичә бит сине Сәгыйть Хәмитович эшеңнән алды.

— Юк белән башымны катырма әле, — дип, Фатыйма Ирекне юлыннан этеп җибәрергә теләде.

— Туктале, кызый, ашыкма.

— Ашыгам, кит юлдан. Әллә син минем белән йоклагач, миңа хуҗа булдым дип уйлыйсыңмы? Чыгар хәзер үк!

Фатыйма йодрыклары белән Ирекнең күкрәген төяргә тотынды, ләкин Ирек — көчле егет, аның ике кулыннан эләктереп алып кәнәфигә утыртты.

— Ә хәзер мине тыңла. Без хәзер Ч. шәһәренә барабыз. Анда безне Илсур Мансурович көтә.

— Миңа синең Илсур Мансуровичларың артымны сөртәргә дә кирәкми. Мин үз эшемә барам.

Шунда Ирек түш кесәсеннән документлар чыгарып Фатыймага күрсәтте. Анда Фатыйманың барлык документлары һәм Сәгыйть Хәмитовичның: «Килешүне бозып, үз эшенә салкын каравы, сатып алучыларга тупаслык күрсәтүе өчен Кадыйрова Фатыйманы бүгеннән эшеннән алам», — дип язылган иде. Һәм Сәгыйтьнең имзасы белән мөһере сугылган. Фатыйманың телен әйтерсең корт чакты. Ул бер сүз дәшә алмады. Менә ни өчен кичә көне буе җаны бәргәләнгән икән. Бу Игорь дигән татардан туган урыс аны очраклы рәвештә генә юлда туры китереп утыртып алып кайтмаган. Алар Сәгыйть Хәмитович кебек бер чыбыктан куалаган кабахәтләр. Бу ирләрнең бөтенесе икейөзле, оятсыз. Эчләре тулы ялган. Аларның тамырларында кан түгел, пычрак судыр. Кеше язмышы белән ничек уйныйлар.

* * *

Фатыйма язмышына буйсынырга мәҗбүр булды. Ул башына төшкән көтелмәгән вакыйгаларны артык тирән кичерми. Киресенчә, аның күңелен тормыштан ниндидер маҗаралар эзләү, шул маҗараларда үзе төп катнашучы булу теләге гел кытыклап тора. Тормышка ул отышлы уен итебрәк карый, ә андый уенда кемдер ота, кемдер оттыра. Бәлки әле, Илсур Мансурович дигәннәре берәр бай кешедер. Ә байларга һәрвакыт сөяркә кирәк. Фатыйманың инде сөяркә булып караганы бар. Тик менә Заһит кына аны эзләп бәргәләнер инде. Бик ярата бит ул Фатыйманы...

Фатыйма юл буе шулай уйланып барды. Күз алдына улы Заһит килеп басса: «Аның әтисе, әби-бабалары бар. Ятим итмәсләр. Бәлки, акылына килеп үз атасы алып китәр. Хәер, кая инде! Ул малае турында сүз чыкса, ишетмәмешкә салыша. Матур кызларның итәк асларын капшарга гына кыю ул. Бүтән эш кушсаң, калтырап төшә. Әй, нигә соң әле алар турында баш ватарга? Башта үз язмышыңны хәл итәргә кирәк, аннан күз күрер!»

Юл шактый озын булса да, вакыт үткәне ничектер сизелмәде. Фатыйманың йокымсырый башлаганын күрүгә, егет, машинасын туктатып, чибәр ханымны саф һавалы чәчәкле болыннар тирәсенә алып чыкты. Анда бераз шаярышкалап, арыганлыкларыннан арындылар, капкалап алдылар.

Илсур Мансурович аларны үзләренең капка төбендә көтеп тора иде. Фатыйманың аны күрүгә күңеле күтәрелеп китте. «Кырык яшь тә юктыр әле монда», — дигән сөенечле уй йөгереп үтте башыннан. Фатыйманы Илсур Мансурович та ошатты. Ул, егетне читкәрәк алып китеп: «Товарның шәбен алып килгәнсең, молодец!» — дип куйды. Алар тагын нидер сөйләштеләр. Күрәсең, сүз Фатыйманың язмышы турында баргандыр. Озакламый Илсур Фатыйма янына килде. Ирек-Игорь боларга кул болгап алды да машинасына утырып сызды.

— Йә, — диде Илсур Мансурович, — ныклап танышыйк. Мин Илсур Мансурович Әптериев булам. Урыслар Андреев дип атый. Эшем турында сөйләп тормыйм. Хатын-кыз өчен ул бик ялыктыргыч нәрсә. Ә сезнең хакта мин бераз беләм. Тик үз авызыгыздан ишетү кызыграк булыр дип уйлыйм.

— Үзем турында сөйли башлаганчы, минем бер нәрсәне беләсем килә иде.

— Ягъни?

— Мине монда нигә китерделәр? Сезгә кол итепме, сөяркә итепме, әллә бөтенләй мин белмәгән сәбәп бармы?

— Сорауны турыдан куюыгыз әйбәт. Тик монда кем булуыгыз күбрәк үзегездән торачак, Фатыйма ханым. Сез миндә эшләячәксез.

— Мин Сәгыйть Хәмитович кибетенә өйрәнгән идем. Анда дуслар, ирем, улым калды.

— Ирегез белән араларыгыз ничек булганын беләм. Улыгызны үзегез калдырып чыгып киттегез. Сез әле, Фатыйма ханым, иң зур бер нәрсәне белмисез.

— Нәрсә ул?

— Сезне китерүнең төп сәбәпчесе — Заһит.

Фатыйманың йөзенә шатлык чаткылары йөгерде: «Димәк, Заһит монда! Бәлки, ул миңа өйләнергә телидер».

— Әйе, Заһит, — дип дәвам итте Илсур Мансурович. — Ләкин әле мин сезгә иң мөһимен әйтеп бетермәдем. Сәгыйть Хәмитович сезне ни өчен һич көтмәгәндә эштән куды дип уйлыйсыз?

Фатыйманың нервлары бер учка сыярлык булып төйнәлде. Ул сүзнең дәвамын көтеп Илсур Мансуровичка текәлде.

— Сезнең җан атып йөргән Заһитыгыз кудыртты сезне.

— Ышанмыйм, бер сүзегезгә дә ышанмыйм. Качачакмын мин сездән. Мине Заһит килеп коткарачак.

— Әгәр Заһитка ышанычыгыз зур икән, ышанып яшәгез. Ә хәзергә сез миндә эшләп торачаксыз.

— Нинди эш?

— Эш дип, эш тә түгел инде ул. Әнигә иптәш кирәк. Ялгызы гына өйдә калырга курка. Ә мин өйгә гел-гел кайтып йөри алмыйм. Кыскасы шул, әйдәгез өйгә. Шунда барысын да аңларсыз.

Алар ак мәрмәр баскычтан менеп өйгә керделәр. Өйнең идәненә паркет җәелгән. Бассаң таеп егылырлык шома. Диварларында картиналар. Алар борынгы булса кирәк. Хәзерге заман рәссамнары ясаганга охшамаган. Хәер, Фатыйма мондый нәрсәләрне аңламый. Картиналарның бик кыйммәт икәнен генә чамалый. Бервакыт әллә Мәскәү, әллә Санкт-Петербургта ниндидер картинаның урланганын һәм аның өч миллион доллар торганлыгын телевизордан әйткәннәр иде. Фатыйманы шаккатырганы картинаның урлануы түгел, ә аның бәясе булды. Телевизордан ул картинаны күргәч: «Мин моны өч тиенгә дә алмас идем», — дип куйды.

Болар керүгә, икенче бүлмәдән 60–65 яшьләр тирәсендәге бер ханым чыкты. Ул күлмәгенең алдын артка кигән, күзләре төрле якка уйнап торган бик хәрәкәтчән ханым иде.

— Бусы нинди кәнтәй тагын? — диде ул, Фатыймага ымлап.

— Ул синең якын дустың — Фатыйма, әллә танымыйсыңмы, әни?

Фатыйманың йөрәге дерт итеп куйды. Менә ул нинди җиргә килеп капты. Димәк, шушы җүләрне карар өчен монда китергәннәр аны.

Хатын Фатыйма янына килеп аны исни башлады.

— Тәмле хушбуй сөртәсең икән. Зәвыгың бар.

Һәм ул шап итеп Фатыйманың җилкәсенә сугып куйды. Шул вакыт Илсур Мансуровичның телефоны шалтырады. Аны каядыр чакырдылар, күрәсең. Ул бераз кабаланып Фатыймага тиз-тиз сөйли башлады:

— Сез, Фатыйма ханым, үзегезне өегездә кебек тотыгыз. Монда сез үзегез генә түгел. Аш пешерүче, өйләрне җыештыручы һәм бакчачы бабай бар. Тора-тора танышырсыз. Ә мине эшкә чакыралар.

Илсур Мансурович чыгып китте. Фатыйма юләр хатын белән икәүдән-икәү калды. Ул инде моннан җиңел генә ычкынып булмаячагын аңлаган һәм тормышның билгесез карурманына кереп китәргә әзер иде.

— Арыган күренәсең, ашыйсың да киләдер, — диде хатын. Һәм кесәсеннән кечкенә кыңгырау алып бер зеңгелдәтте. Ашыга-ашыга аш пешерүче кайсыдыр яктан килеп чыкты.

— Күрәсеңме, өемдә кунак бар. Аның ашыйсы килә, — диде хуҗа хатын.

— Хәзер, Әминә апа, — дип, пешерүче китеп бармакчы иде.

— Тукта! — диде Әминә ханым. — Сиңа, мин Әминә апа түгел, Әминә Хөрмәтовна булам, дип күпме кабатларга була?

— Гафу итегез, Әминә Хөрмәтовна, мин сезне артык якын иткәнгә «апа» дидем.

— Хәзерге заманда беркемнең апасы, сеңлесе юк. Бөтен кешегә акча — апа, акча — сеңел, акча — хуҗа.

Фатыйма бу хатынның үзе уйлаганча ук юләр түгеллеген аңлады. Улы әйткәнчә, ялгызлыктан да интегерлек түгел. Өйләрендә аш пешерүче, җыештыручы булгач, кирәк чакта алар белән сөйләшә алмыймыни?! Хәер, ул авырудыр. Әнә бит нинди затлы күлмәкнең алдын артка кигән.

Пешекче чыгып киткәч, ул:

— Әминә Хөрмәтовна, сез күлмәгегезнең алдын артка кигәнсез. Рөхсәт итсәгез, мин сезгә булышыр идем, — диде.

— Бөтен дөньясының алды артка килде бит. Дөньясына карап җайлашабыз инде.

Әминә Хөрмәтовна шулай дисә дә, Фатыймага карышмады. Күлмәген дөресләп киде. Фатыйма Әминә Хөрмәтовнаның чәчләрен тарамакчы булган иде, ләкин Әминә Хөрмәтовна: «Мин кеше тарагы белән чәчемне тарамыйм. Ирене кызартылган, бите агартылган чибәр кәнтәйләрнең башында ни булмас. Минем үз тарагым бар», — дип тузынып алды.

Әминә Хөрмәтовна Фатыйманы үз бүлмәсенә алып керде. Бүлмә бик пөхтә җыештырылган. Карават өстендә кул белән чигеп эшләнгән гаҗәеп матур җәймә һәм эреле-ваклы берничә мендәр. Аларның тышлары да кулдан чигелгән. Гомумән, монда бар нәрсә кулдан эшләнгән. Карават үзе генә дә сәнгать әсәренә торырлык. Ләкин Фатыйма мондый матурлыкны аңламый, аңа кибет әйбере — фабрикада эшләнгән келәм, фабрикада тукылган җәймә булсын. Кулдан эшләнгән эшне ул зәвыксызлык дип саный иде. Шул хакта әбисе белән дә еш кына бәхәс куба иде.

Фатыйманы әнисе кул эшенә өйрәтергә күп тырышты. Кул белән эшләнгән эштә кешенең күз

нурлары була. Ул нурлар караган саен җанны иркәли, ди торган иде. Әмма Фатыйманың андый нечкә эшләргә күңеле ятмады. Аңа урамда малайлар белән уйнау кызык иде. Малайлардан ишеткән әшәке сүзләрне үз-үзенә кабатлап рәхәтләнеп көлә иде. Әнисе шәһәргә интернат-мәктәпкә җибәргәч, ул бөтенләй иркен сулыш алды. Аңа иң матур нәрсә — үзе, чишенеп ташлап үзен көзгедән озаклап карап тору күңеленә ял бирә иде.

Әминә Хөрмәтовна Фатыймадан үз бүлмәсенә карата берәр сүз көткән иде. Тик сүз ишетелмәде, бары тик күзләрендә бераз сәер, бераз аптырашлы караш кына күрде.

— Йә, ничек? — дип сорарга мәҗбүр булды ул.

— Дөресен әйтсәм ачуланмассызмы?

— Юк, юк, ачуланмыйм. Мин монда дөрес сүзгә сусап яшим.

— Улыгыз, минем белүемчә, бай кеше, бүлмәгезне кибеттән алынган затлы әйберләр белән бизәсә дә харам булмас иде.

Бу сүзләрдән Әминә Хөрмәтовнаның төсе үзгәрде, күзләре элпәләнде. Ул үз-үзенә сөйләнә башлады:

— Зәвыксыз, талымсыз, надан кешеләр басты дөньяны. — Билгеле, бу сүзләрне Фатыйма үзенә карата әйтелә дип башына да китермәде. — Хәзер барсына да акча гына матур. Кодрәтемнән килсә, дөньядагы барлык акчаларны яндырып бетерер идем. Кәнтәйләр, урам себеркеләре, оят җирен иң матур нәрсәгә санаучы азгыннар, караклар, юлбасарлар, дөньяда акча булмаса, үзеннән-үзе бетәр иде.

Фатыйма каршы төшеп нидер әйтергә теләде, тик пешекче аларны ашарга чакырды.

— Кемне ашарга? — диде Әминә Хөрмәтовна.

— Аш ашарга, — диде пешекче, ләкин хуҗабикә аның сүзләренә колак салмады.

— Кешеләр бер-берләрен ашаудан тәм табалар. Кыргыйлыкка таба барабыз. Дөньяны укыган кешеләр боза.

Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, караватына ауды. Фатыйма бу күренешне битараф кына күзәтте. Аш пешерүче тагын бер кат:

— Ашарга иде бит, Әминә Хөрмәтовна, ашым суына, — дип әйтеп караган иде, тик хуҗабикә:

— Мин беркемне дә ашарга теләмим. Әнә бер-берегезне үзегез ашагыз, — дип, аларны бүлмәсеннән куып чыгарды.

Фатыйма күңеленнән: «Бу юләрләр йортыннан тизрәк качарга!» — дигән катгый карарга килде.

Ләкин Әминә Хөрмәтовнаның вакыт-вакыт «юләрләнеп» алуы аның ачуын китерми, ничектер тынычландыра иде.

— Без начар кешеләргә «хайван» дибез. Хайваннар кешеләрдән акыллырак. Кеше бит ул — нәфес корбаны. Башта акчалы буласы килә, акчасы күбәйсә, властька үрмәли, властька үрмәли алса, азгынлык юлына баса. Хәер, азгынлык өчен власть кирәкми. Хатын-кызларның ирләр белән уйнавы хәзер спорт уенына әйләнде. Кем күбрәк...

Фатыйма бу сүзләрне ишетмәде, аның уе Заһитта иде.

* * *

Заһит китергән әйберләрне арзан бәягә алып, кыйммәткә сатып җибәрә башлагач, Сәгыйтьнең кереме күзгә күренеп артты. Ул бу товарларны махсус Сөмбелдән саттырды. Тегеләй-болай тикшерү була калса, Сөмбелгә «талак» әйтеп, бар гаепне аңа аударырга була. Аласын алды бит инде ул Сөмбелдән. Дөрес, Сөмбел аңа бик якын. Карт хатыннан соң сандугач баласы кебек яшь кыз кочагына керү барлык байлыклардан кыйммәтлерәк югыйсә. Ләкин Сәгыйть инде байлыкка күнеккән, байлык булмаса, «сандугач баласы» да аның кочагында сайрамас иде.

* * *

Сөмбел, Сәгыйть Хәмитович белән никахлашып, аерым фатирда яши башлагач, үзендә зур үзгәреш сизде. Башын горур чөеп, элекке дуслары белән аралашмаска тырышты. Сәгыйть Хәмитович аңарга: «Син иске дусларың белән араңны өзәргә тырыш. Һәр хәерче байдан көнләшә. Сине әкренләп үзебезнең мохиткә кертеп җибәрергә кирәк. Тормышта һәркемнең үз урыны булырга тиеш, ә урынны байлык билгели», — дип тукый торгач, Сөмбел Сәгыйть Хәмитовичның шушы фәлсәфәсен тиз үзләштерде. Шәп машинада өйгә кайтып туктау, тегенди-мондый алган әйбереңне үзең түгел, шоферыңа күтәртеп кертү дөнья күрмәгән, бәхетне бары тик матди байлыкта гына дип аңлаган кыз өчен аның тормышы җәннәт булып күренде. Рухи байлык аның өчен бөтенләй юк иде. Мәктәптә көчкә өчкә укып йөргән кыз театрларга йөрүне, китап укуны башына да китермәде. Сөйләшергә кеше кирәк булса, өйдә телефон бар. Үз ишләрең белән дә рәхәтләнеп гайбәт сат. Рухи гарип яки сындырылган кешеләр өчен кеше гайбәте сатудан, шул ук вакытта үзең яңа әйберләрең белән мактанудан шәбрәк ни бар тагын?! Сәгыйть Хәмитович аңа атнага ике-өч килеп кунып китә. Беренче хатыны белән үзара

мөнәсәбәтләре ничектер, Сөмбел аны белми. Белергә дә теләми. Кибеттә ул хәзер үзен хуҗаларча тота: элекке хезмәттәшләренә кычкыргалап алуны, күрсәтмәләр бирүне үзенең бурычы дип саный. Сәгыйть Хәмитович яшь бикәченең кыланышларын хуплап тора.

Ә беркөнне аңа кайчандыр дус булып йөргән, мәктәптә укыганда кача-поса үбешкән Руслан шалтыратты.

— Нихәл, байбикә, акчалар минем кочактан җылыракмы?

— Синең кочагың беркайчан да җылы булмады һәм булмаячак, — диде Сөмбел. — Йоны коелган куртка белән кызлар җылыта алмаячаксың син.

— Синең дә бервакыт иске куртка кебек кирәгең бетәчәк. Байлык — бер айлык.

— Ә синең үз гомереңдә берәр ай бәхетле булып караганың бармы?

— Мин бәхетсез түгел. Бәхет ул ефәккә төренеп әйбәт машинада йөрү генә түгел. Мин ирекле булуым белән бәхетле.

— Нәрсә соң ул ирек?

— Аны сиңа аңлатып булмый. Көннәрдән бер көнне ефәк күлмәкләреңне салдырып урамга куып чыгарылгач аңлый башларсың син аны. Ул чагында синең ефәк күлмәкләрең генә түгел, үзең дә койрыгы йолкынган тутый кош кебек булачаксың. Байлык кешене тиз картайтып кына калмый, аның акылын да ала. Шуны исеңдә тот.

— Акыллы хәерче булуга караганда юләр бай булуың яхшырак. Әллә син власть башында утыручылар бик акыллы дисеңме? Акыллы хәерчеләр аларның кабул итүен сорап еллар буе ишек төпләрен сагалый.

Сөмбел телефоннан сөйләшкәндә, Сәгыйть Хәмитович кайтып керде. Ул Сөмбелнең соңгы сүзләрен ишетеп калган иде.

— Нәрсә, былбылым, әллә күңелеңне рәнҗетерлек сүз әйттеләрме?

— Мәктәптә бергә укыган егет шалтыратты.

— Нәрсә ди?

— Байлык бәхет түгел әле ул, — ди.

— Аныңча бәхет нәрсә соң?

— Ирекле булып яшәү.

— Ярлы кеше ирекле була аламыни? Иң мөһиме: җан ирекле булырга тиеш. Ә җанны ireккә чыгаручы ике нәрсә бар: берсе аның — байлык, икенчесе — власть, — диде Сәгыйть Хәмитович. — Менә шулар гына кешене ирекле итә ала. Без инде бик озак еллар ярлы коллар булып яшәдек. Үзебезне ирекле дип санадык, ә бәхетле идекме соң? Әлбәттә, байлык белән власть бетәргә мөмкин. Әмма кулында власть яки байлыгы барында кеше күпмедер хөрмәт казанып өлгерә. Байлыгын югалткан очракта да аларга ихтирам бетми. Ә күңелендә коллык, хәерчелек яткан кеше байый да, властька да күтәрелә алмый. Беркөн әле бер язучыны күрдем. Өлкән яшьтәге танылган язучы. Мин бер роман язган идем, өч ел инде чыгара алмый йөрим, ди. Өйдә ашарга бетте, хатын ташлады. Шул китапны чыгарырга ярдәм итмәссезме, ди. Минем базада йөк ташучы кирәк, әгәр шунда әйбәт кенә эшләсәң, китабыңны чыгартырмын, дидем. И шатланды инде, бичара. Ә бит ул начар язучы түгел. Әгәр хөкүмәт талантларга ярдәм итсә, ул кешеләр безгә сәлам дә бирмәсләр иде. Дәүләт башында утыручыларның әнә шундый кешеләргә ярдәм итмәве безнең дәрәҗәне күтәрә. Без шушы болганчык елларда алтын балык эләктереп калырга тиеш. Ләкин, матурым, син шуны исеңнән чыгарма: югарыдагыларга бервакытта да начар сүз әйтмә. Аларны гел мактап торырга кирәк. Мактау — кешенең акылын томалый торган иң шәп чара.

Бераз вәгазь укыганнан соң алар иркәләшеп алдылар. Беренче көннәрдә Сөмбелгә Сәгыйть Хәмитович ит чүмәләсе булып күренгән иде, хәзер инде ул аңа күнегә бара.

«Кибән астында тычкан үлми» дигән сүзләрнең хаклыгын Сәгыйть Хәмитович Сөмбелгә үз мисалында раслап килә. Сөмбел инде аның белән шаяра, төрле җирләрен кытыклап Сәгыйть Хәмитовичның йоклый башлаган күзәнәкләрен уята. Сәгыйть моның өчен Сөмбелгә бик рәхмәтле. Сөмбелнең сеңелләренә кесә телефоны алып биргәч, Нәсимә белән Рәсимә дә бу «ит бүкәне»нә башкачарак карый башладылар.

Сөмбел беркөнне, кыюланып китеп:

— Әнине бераз җиңелрәк эшкә урнаштыра алмассызмы икән, Сәгыйть Хәмитович? Гомер буе пычрак җыештырып бик арыды инде ул бичара, — диде.

— Нинди эшкә урнаштырып булыр икән соң аны?

— Бәлки, берәр ашханәгә. Безнең әни заманында поварлыкка укыган. Бераз эшләп тә алган.

— Уйлашырбыз, матурым. Ләкин син моның өчен мине бик-бик каты яратырга тиешсең.

— Яратам бит инде, Сәгыйть Хәмитович.

— Юк әле. Бик үк яратып бетермисең.

— Мин бүтәнчә ярата белмим, Сәгыйть Хәмитович.

— Өйрәтермен.

* * *

Заһит соңгы вакытта үзендә ниндидер үзгәрешләр сизә башлады. Төнге йокысы саташуларга әйләнде. Бигрәк тә аның тынычлыгын алган кеше Радик исемле сөяркәсе белән яткан чибәр ханым булды. Аның иңнәренә таралып төшкән озын кара чәчләре, утлы күмер кебек янып торган күзләре Заһитка һич тынычлык бирмәде. Подвалындагы кыйммәтле туннар өстенә менеп йокларга ятуга саташа башлады. Менә подвалның караңгы идәне буйлап кара елан шуышып килә. Заһит аңардан куркып башын тун белән каплый. Ләкин кара елан тун астына шуышып керә.

— Кит! — дип куалый аны Заһит. — Яныма килмә. Юкса пычак белән кискәләп ташлыйм.

— Ха-ха-ха! — дип көлә башлый елан. — Син бит мине бик яраткан идең.

— Мин сине белмим. Мин мондый хәшәрәтләр белән аралашмыйм.

— Мин хәшәрәтмени? — ди елан һәм кара чәчле, күмер күзле чибәр ханымга әверелә. — Таныдыңмы инде?

— Син? — ди Заһит, гаҗәпләнеп. — Теге көнне сине күргәннән бирле уемда гел син.

— Һәм оныта да алмаячаксың!

— Нигә?

— Чөнки мин синең намусың.

— Юк, юк, син сихерче.

— Сихерче түгел, Иркә исемле мин.

— Иркә?

— Ә нигә аңа аптырыйсың?

— Алайса, үзеңнең Радигың янына кит.

— Аның янына да китә алмыйм, чөнки син мине йоклап яткан килеш көчләдең.

— Кочагыма үзең шуышып кердең.

— Мин йокы исереклегеннән айнымаган идем. Менә хәзер мин синең иркеңдә, дөресрәге, син минем иркемдә.

Хатын, озын кара чәчләрен туздырып, Заһит өстенә ташлана. Аны изә, таптый, нәзек урыннарын тарткалый. Заһит еш-еш сулый, авыртуга түзә алмый кычкырырга тели, тик тавышы чыкмый, чөнки елан хатын әллә нинди сасы исле, лайлалы чүпрәк белән авызын каплый. Заһит бәргәләнә, чәбәләнә. Бик озак бәргәләнгәннән соң гына уянып китә. Уянуга ук утны кабыза. Тезләрен кочаклап уйлап утыра. Ул инде төнге хәлләрнең бер саташу гына икәнлеген аңларлык хәлгә килә.

«Ни өчен соң үзен Иркә дип атаган хатын керә төшемә? Җитмәсә, мин синең намусың, ди. Гомумән, намус нәрсә соң ул? Хатыннар — ирен, ирләр хатыннарын алдый. Ә бәлки, бу Иркә атлы хатын Радигы белән кавышырга уйлаган булгандыр? Кавышканчы бер-берләрен сынашып йөргәннәрдер. Хәзер шулай бит: егет белән кыз бераз яшәп карыйлар да ошашмыйлар икән, ике якка таялар. Әйтерсең кием сайлыйлар. Кием сайлаган кебек үзенә яраклы ир сайлаучы Иркәләрне «намус» дип атап буламы? Юк, монда нәрсәдер аңлашылмый. Мин синең намусың, дип, Фатыйма керергә тиеш иде төшемә. Ә ул төшкә керми, югалды».

Дөрес, Заһит үзе дә Фатыйманы сирәк искә ала. Аның уенда гел Иркә. Берничә мәртәбә Иркә янына барырга да җыенды, әмма йөрәге җитмәде. Шунсы гаҗәп: Заһит аның янына барырга җыенып та бармый калса, ул төшкә керә. Бу юлы ул җиде башлы аждаһа булып килде. «Син килергә курыккач, менә үзем килдем, — диде җиде баш берь-юлы, — әйдә без сине аждаһалар утравына илтеп ташлыйбыз. Анда төрле илләрдән урланган иң матур кызлар яши. Алар сиңа каршылык күрсәтмәсләр, без аларның рухларын сындырдык. Теләсәң, йоклатып алдыңа китерәбез. Син бит йоклаганнарны яратасың».

Шулай диде һәм җиде авыз берьюлы күк күкрәгән тавышлар чыгарып көләргә тотынды: «Ха-ха-ха!»

Һәм җиде авызы көлүдән туктагач, аждаһа койрыгы белән Заһитны урап алды да билгесез тарафка очып китте. Карурман аша үткәндә: «Шушында аю-бүреләр арасына ыргытыйкмы?» — дигән сорау ишетте Заһит. Бу теге чибәр ханым Иркә тавышына охшаган иде. «Юк, юк!» — диде Заһит.

Аждаһа карурманны үтеп диңгез аша оча башлады. «Диңгезгә ыргытыйкмы? Бәлки, шунда бераз гөнаһларыңны юарсың».

Заһит диңгезгә дә төшәргә теләмәде.

Ниһаять, аждаһа бер утрауга килеп җитте. Аждаһаны төрле карчык-корчыклар каршы алды. Алар шундый ябыклар, кабыргалары тиреләрен төртеп чыгар төсле. Аждаһа Заһитны җиргә кую белән, карчыкларның кармактай бармаклары егетнең төрле җиреннән тарткалый, чеметкәли башлады.

— Син минем үлемгә дигән соңгы акчаларымны урлап качтың. Әҗәлем җитүгә карамастан, үлемтеккә җитәрлек акчам булмагач, үлә алмый интегеп йөрим, — диде берсе.

Икенчесе лачкылдатып Заһитның битенә төкерде.

— Бу сиңа оятсызлыгыңның тамгасы. Аны су белән юып булмый.

Заһит боларны күрмәс өчен күзләрен йомды. Ләкин озын тырнаклы бер карт анын күз кабакларын ачып, ниндидер чәнечкеле агач ботагы белән терәтеп куйды.

— Үз корбаннарыңны күр!

Заһитның күз аллары караңгыланды. Утрауга томан төшкәндәй булды. Ул аягөсте йоклап алгандай итте. Күзе тирә-юньдәге хәлләрне аера башлаганда, карт-карчыклар таралышкан, алар урынына яшь кызлар килеп баскан иде. Кызлар күбесе таныш кебек, ләкин күбесенең йөзе кара.

— Сез кемнәр? Нигә сезнең йөзегез кара? — дип сорады Заһит.

Берсе, алгарак чыгып:

— Танымыйсыңмыни? — диде. — Син мине дусларың алдында мәсхәрә иттең. Мин шунда: «Мәхәббәт ул олы сер, аны тик ике генә кеше белергә тиеш», — дидем. Ә син: «Күрсеннәр, нигә куркырга?» — дип, үзеңнең батырлыгың белән мактанырга теләдең.

— Мин бит сине көчләмәдем.

— Әйе! Ләкин синдә ниндидер Иблис тылсымы бар. Мине шул тылсым хурлыкка сөйрәде. Шуннан соң йөзем карала башлады.

Кызлар Заһитны уратып алдылар. Ни өчендер болар арасында Фатыйма юк иде. Шул уй Заһитның миеннән чагылып үтүгә, каяндыр еракτан Фатыйма тавышы яңгырагандай булды:

— Мин үзем сине шул юлга тартып керттем. Чөнки сине дөньямны онытып яраттым. Синең өчен утка да, суга да керергә әзер идем.

— Их, Фатыйма, — диде Заһит.

— Фатыйма дип көрсенмә, син үзең мине коллыкка саттың, — диде бер тавыш. Тик бу тавышны Заһитны боҗрага алган кызлар ишетмәделәр. Ул һава дулкыннары аша Заһитның гына йөрәк ярларына килеп бәрелде. Ә боҗра торган саен ныграк кысылды. Егетнең өстендәге киемнәрен умырып-умырып алдылар. Заһитның кызлар кагылган һәр җире кара көеп чыкты.

— Менә хәзер син дә безнең кебек була башладың.

— Мин бит сезнең күбегезне белмим дә.

— Әйе, белмисеңдер. Чөнки мине син бер кибеттә карашың белән көчләдең. Иң беренче баштанаяк чишендердең, аннары күзләрең белән оят җирләремне айкадың. Мин йөгереп өйгә кайтып сабынлый-сабынлый юындым. Ләкин җаныма сеңеп калган пычрак карашыңны юып бетерә алмадым. Мин синең карашыңнан балага уздым. Менә ул бала. — Кыз әллә нинди җан иясен Заһитның кулына тоттырды: бала дисәң — бала түгел, бака дисәң — бака түгел. Җирәнгеч бернәрсә. — Бу синең әшәкелегеңнең бер төре.

Заһит ул җирәнгеч нәрсәне җиргә ыргытмакчы булды, ләкин әлеге җан иясе ялт кына егетнең куенына чумды.

— Син аннан котыла алмаячаксың, — диде кыз, — чөнки ул синең җаның пычраклыгы.

Кызлар Заһитны егып өстенә менеп атландылар. Безнең каралык сиңа да йоксын, дип, төрлечә мыскылладылар. Бу күренешне карап торган Ай болытлар арасына кереп качты. Шаһит итеп милициягә чакыртуларыннан курыккандыр, ахры.

Заһит тәмам хәлсезләнде. «Җибәрегез, китегез. Әнә теге карчыклардан оялыгыз», — дип, көчсез тавыш белән ялварып карады. Ә кызлар: «Безнең оятны син алдың, хәзер без җен балаларына әйләндек», — дип, Заһитның иң авырткан җирләрен боргычладылар. Заһит авыртуга түзә алмый кычкырып җибәрде һәм үз тавышына уянып китте. Подвал караңгы булганлыктан, озак кына бу хәлләрнең өнме, төшме икәнлеген аңламый ятты. Стенаны кармап утны кабызгач кына үзенең кайда икәнлегенә төшенде. Ул чынбарлыкта көчләгән кеше кебек еш-еш сулый, торып су эчәрлек тә хәле юк. Җитмәсә, нәзек җире үтереп сызлый. Заһит анда кан күрүгә куркып китте. «Әллә соң бу төш кенә булмады микән?» — дигән фикер ми сырлары буйлап йөгереп үтте. Ул озак уйланып ятты. Барсы да теге сөяркәсе белән ятучы чибәр хатыннан башланды. Аңа кадәр үзе талап чыккан өйләр, юха теле белән үзенеке иткән кызлар ике ятып бер төшенә дә керми иде. Бу Иркә сихерче булды, ахры. Күпме изалана — күз алдыннан китми. Елан кебек үзенә суыра. Заһит шул еланның эченә үк кереп бара түгелме? Намусны уятыр өчен, бәлки, әнә шундый Иркә кебек намуссызлар кирәктер! Әшәкелекне әшәкелек чөе белән кагып чыгарырга! Әйе, әйе, бу, мөгаен, шулайдыр. Юкса уянгач та шул Иркә күз алдыннан китми тормас иде. Әнә бит почмакта озын кара чәчләрен таратып ташлаган да чәч учмалары белән Заһитны урый. Уф! Нинди хәл бу? Җитмәсә, әкияттәге убырлы карчык кебек, Заһитның бармагын суыра. Егетнең көче беткәннән-бетә бара. Ул көч-хәл белән урыныннан кузгалып су эчә. Иркә дигәне зур күсе икән, ул кружка шалтыравыннан куркып каядыр кача. «Теге» җирен күселәр тешләгән, ахры. Болай ярамый, больницага барырга кирәк.

Заһитның шушы урынына ятып үләсе килде. Ләкин ничек үләргә?

Ул урынына барып ятмакчы булды, ләкин егылып бетон стенага башын бәрде. Аңын югалтып күпме яткандыр, билгесез. Уянгач: «Тизрәк врачларга күренергә кирәк», — дип, пычрак киемнәрен алыштырды, канаган җирен бәйләде. Больницада аның анализларын тикшергәч:

— Сезгә әле шактый ятарга туры киләчәк, сезне котырган күсе тешләгән, — диделәр.

* * *

Фатыйма Илсур Мансурович белән сирәк очрашты. Ул гел эштә. Өенә кайткан чакларда әнисе янына кереп утырырга ярата. Әминә Хөрмәтовна вакыт-вакыт «ычкынгалап» алса да, зыянлы кеше түгел икән. Аны иң нык интектергән нәрсә ялгызлык булган. Фатыйма башта качам-качам дип яшәсә дә, әкренләп Әминә Хөрмәтовнага ияләште. Бу йорттагы мохит тәэсир иттеме — күңелендә кешеләрне кызгану хисе уяна башлады. Илсур Мансуровичның әнисенә карата булган мөнәсәбәте торып-торып Фатыйманың исен китәрә. Ул эштән кайтып юынуга, әнисенең бүлмәсенә керә дә: «Уф, арыдым, әнием, алдыңа башымны куеп ятып торыйм әле», — дип, кәнәфи янына тезләнә һәм башын әнисе алдына сала. Әнисе улының чәчләреннән сыйпый, битләрен чәбәкләштереп ала. Фатыйма моны «төчеләнү» дип кабул итә иде. Ләкин ана һәм улның бер-берләрен чынлап яратуларын аңлагач, аларга хөрмәте артты. Фатыйманы бервакытта да әнисе үзенең алдына яткырып башыннан сыйпамады. Фатыйма әнисенә килеп сырпалана башласа, ул: «Кит әле, сине сыйпап утырырга вакытым юк, арып кайттым», — дип этеп җибәрә иде. Кыз үпкәли. Ә инде шәһәргә укырга җибәргәч, әнисенә карата бөтенләй суынды. Вакыт-вакыт әнисенә акча җибәрүләр генә бөтенләй аралары өзелүдән саклап торды.

Илсур Мансурович әнисе алдына ятып үзе генә иркәләнми, әнисенә дә үзенең җан җылысын сала.

— Арыйсың инде, балам. Нигә шулкадәр акча артыннан куасыңдыр, — дип шелтәли ана.

— Акча артыннан түгел, дөнья куабыз, әни. Дөньяда һәр адәм баласы нидер эшләргә тиеш. Менә мин ателье ачтым. Кешеләрне киендерәм. Кешеләрнең төрлесе бар бит: кайберләре үзләре заказ биреп тектергән әйберне алмый. Алынмаган киемнәрне өеп яткырып булмый. Сатарга кирәк. Шуннан кибет ачарга туры килде. Менә шулай, әни, ә кибеткә килүчеләргә күп нәрсә кирәк: күлмәге дә, чүлмәге дә. Кешеләрнең хаҗәтен үти алсаң, җан рәхәтләнеп китә. Күпләр бизнесменны акча капчыгы өстендә утыручы дип күз алдына китерә. Андыйлар безнең кесәдә кайвакыт җилләр уйнаганын белми бит.

Әнисе белән эш турында шулай сөйләшеп утырулары, уй-фикерләрен уртаклашуы — анага хөрмәт һәм тынычландыру чарасы. Фатыйма баштарак Илсур Мансуровичны эченнән «робот» дип йөри иде. Хәзер аңа карата фикерләре үзгәрде.

Илсур Мансурович Фатыйманы да игътибарсыз калдырмый:

— Әни белән бик кыен түгелме? Тотарга акчаң бармы? — кебек сорауларны биреп тора. Ә беркөнне: — Син, авылда әнием бар, дигән идең. Авылда бит хәзер хәлләр мөшкел. Әниеңә акча җибәрергә кирәктер, — диде.

Илсур Мансурович Фатыймага бер төргәк акча бирде: «Әниеңә сал. Әгәр мин онытып җибәргәләсәм, исемә төшер. Бушка эшли торган заманнар үтте».

Акча шактый иде. Ә Фатыйма акчаны ярата. Акчалар күбрәк җыелса, бәлки, моннан таяргадыр? Ләкин кая барырга? Авылга әнисе янына кайтсынмы? Элек эшләгән кибеткә керә алмый, анда аны Сәгыйть Хәмитович тотып ашаячак. «Гыймайга кайтсам, бәлки, куып чыгармас иде. Анда улы нишләп йөри икән? Сагына микән? Гыймай өйләнгәндер. Үги әни Заһитны кыерсытмый микән? Кыерсытадыр, туйганчы ашатмыйдыр да әле. Ана назы күрми үскән баладан кем чыгар? Үзем дә аңа карата кырыс булдым. Мине оныткандыр да инде. Бер кайтып күрәсе иде үзен. Улымнан бигрәк Заһитым сагынгандыр. Ул бит минем өчен үлеп тора иде. Мине юксынудан тагын начар юлга кереп китмәде микән? Ир-ат бик түземсез зат бит ул. Бер чиктән икенчесенә ташланырга гына тора».

Мондый уйлар Фатыйманың күңелен торган саен ныграк борчый башлады. Ә Гыймай белән кечкенә Заһит аны бер генә минутка да онытмады. Заһит һәр көнне:

— Әни! Әни кая? — дип уяна.

Гыймай улына ни дип җавап бирергә белми.

— Кайтыр, улым, кайтыр. Әниең дә сине сагынадыр.

— Сагынгач нигә кайтмый?

— Эшкә еракка җибәргәннәрдер.

— Әйдә, әти, әни эшләгән кибеткә тагын барып сорыйк. Андагы апалар әнинең кайда икәнлеген беләләрдер.

— Бардык бит инде, улым, — дип, Гыймай улын күтәреп ала. — Менә бит син нинди зур үстең, башың түшәмгә тия.

— Кибеткә! — ди малай, әтисенең мактавына исе китмичә.

— Бүген минем эшем күп. Өченче көн кергән бабайга тәрәзә рамнары ясап бетерәсем бар. Юкса бабай мине ачуланыр. Тәрәзәсе булмагач, аларның өйләренә суык керә. Ә карт кешегә җылы кирәк.

— Миңа әни кирәк!

— Миңа да кирәк, улым, тик нишлим соң инде.

— Соң, кибетче апалардан сорыйк.

— Йә, ярар алайса, матур күлмәгеңне ки. Бу чалбарыңны алыштыр, тезләре тишелергә тора.

— Әти, мин бу чалбарны алмаштырмыйм, яме?

— Нигә, улым? Яңа чалбарың матуррак бит.
— Юк, бусы матур, моны әни алып бирде.
— Сатучы апалар: «И-и, бу Гыймай абзый бигрәк саран икән, шундый матур улына яңа чалбар да алмый», — димәсләрме соң?
— Дисеннәр.
Малай күлмәген алыштырды, ләкин әни чалбарын салырга теләмәде.
Ата белән ул кибеткә җитәкләшеп киттеләр. Гыймай улыннан башка да кибеткә кергәләп йөри. Фатыйма турында берәр хәбәр ишетсәгез, менә бу адрес белән миңа килеп әйтегез, зинһар, юкса малай әнисен бик сагына, дип, адресын да калдырып киткән иде. Әмма Фатыймадан хәбәр-хәтер булмады.
Бу юлы да ул Заһит өзелеп-өзелеп сораганга гына кибеткә барырга булды.
Сатучылар аларны күптәнге танышлары кебек каршыладылар.
— О-о, менә безгә кемнәр килгән! — дип, кайберләре Заһит тирәсендә бөтерелде. Малайның кесәсе күчтәнәчләр белән тулды.
— Әни кая? — диде Заһит, еламсырап.
— Фатыймадан хәбәр юкмы? — диде Гыймай да.
— Юк шул, — дип көрсенде сатучы кызлар.
— Сез, кызлар, нәрсәнедер яшерәсез бугай, — диде Гыймай. — Берәр кая китсә, сезгә шалтыратыр иде.
— Юк, шалтыратканы юк. Фатыйманың кайда икәнлеген хуҗа яки Заһит кына беләдер.
— Мин белмим, — диде кечкенә Заһит, сүз үзе турында бара дип уйлап. — Белсәм, сездән сорамас идем.
— Сез хуҗа янына кереп карагыз әле, ул белми калмас, — дип киңәш итте арадан берсе.
Гыймай үзе дә шулай уйлый иде. Улын җитәкләп хуҗа кабинетына юнәлде. Сәгыйть Хәмитович кайчан да булса Гыймай килер дип көтә һәм бу очрашуга әзер иде.
— Ниһаять! — диде ул, Гыймайның кулын кысып. — Үзем сезгә барырга дип тора идем. Кая булды безнең Фатыймабыз?
Иң яхшы саклану чарасы башлап үзең һөҗүм итү икәнлеген белгән Сәгыйть Гыймайга авыз ачарга ирек бирмәде. Ул, Заһитның башыннан сыйпап:
— Әниеңне без дә һәр көн көтәбез. — Ул, ниндидер папка алып: — Менә бит документларын да сорап кермәде. Ә без аны бик яраткан идек, — дип, папканы кире урынына куйды. Әгәр Гыймай аны ачып караса, анда бөтенләй башка кеше документлары икәнлеген күрер иде. Сәгыйть, Гыймайның аптырашлы карашын күреп: — Ә-ә, сезгә әйтергә онытып торам икән. Фатыйма соңгы ай өчен зарплатасын алмаган булган. Мин беркөнне бухгалтердан Фатыйманың акчасын алып, үзем илтергә уйлаган идем. Башка эш килеп чыкты да сезгә бара алмадым.
Сәгыйть сейфын ачып бер конверт алып күпмедер уйланып торды да конвертны Заһитка бирде.
— Миңа акча кирәкми, әни кирәк, әни, — дип өзгәләнде малай һәм конвертны идәнгә ыргытты.
Гыймай, идәндәге конвертны алып:
— Бу бит әниеңнең күчтәнәче, улым. Ул аны сиңа берәр нәрсә алырга дип калдыргандыр. Нәрсә алыйк икән, улым?
— Миңа бернәрсә дә кирәкми, — диде Заһит, күзендәге яшьләрне сөртә-сөртә.
Кибеттә эченә кереп утырып, педаль белән йөртә торган машина бар икән, Гыймайның күзе шуңа төште.
— Карале, улым, нинди матур машина. Әллә сиңа шуны сатып алып җибәрәбезме?
Сатучы кызлар эһ дигәнче машинаны малайга китереп тоттырдылар. Заһитның күзләрендә очкыннар кабынды. Малай ике уйлаганчы дип, Гыймай акчасын түләп куйды.
— Әти, — диде Заһит, — бу машинага утырып мин әнине эзләргә китәм.
— Ярар, улым, ярар. Баегач, машинаның олысын алып җибәрербез әле. Хәзергә монысы белән йөри тор.
Малайга машина бик ошады.
— Бабайларга да күрсәтик, әти, яме?! — диде Заһит.
— Күрсәтербез, улым, күрсәтербез. Безнең яраткан оныгыбыз машинада гына йөри икән, дип шатлансыннар.
— Нәчәлник булам мин, әти.
— Ярар, улым.
Малай кибеттән чыгуга ук машинасы эченә кереп утырды. Велосипедта йөреп өйрәнгән малайга педаль әйләндерү авыр булмады.
Алар бабаларына кереп машиналарын күрсәттеләр.
Бабалары:
— Машина тикле машинаны котламый ярамас. Менә бу солдат каешын бүләк итим әле үзеңә. — Бабасы озак билдә йөреп кыршылып беткән солдат каешын үзенең фронт әйберләре саклана торган

сандыгыннан алып бирде. — Бу, улым, — диде ул, — синең машинаң ватылса, буксирга тагарга да ярарлык, бөтен Европаны әйләнеп кайткан шәп каеш!
— Минем машинам ватылмый, бабакай, — диде Заһит. — Выр-выр, выж-выж!
Урамга чыккач та сүз машина турында барды. Әнисен беразга гына булса да оныттыра алуына Гыймай бик шатланды. Заһит рухланып әтисенә машинасы турында сөйләде.
— Әти, моның руле матур, менә монда тормозы да бар.
— Машина бит ул, улым.
Заһит авызыннан төрле-төрле авазлар чыгарды: «чыж-чыж, выр-р, выр-р!». Бу аның үзенчә машинага җан кертүе. Аларның күршесендә Артур исемле бер абый яши, ә аның бер иске «Москвич»ы бар. Артур абый машинасын кабыза башласа, бөтен күрше-тирә уяна. Чөнки яшәсен яшәгән, күрәсен күргән бу «Москвич», кабыза башлауга, салкын тигән сарыктай озаклап төчкерә, аннары өне беткән эт тавышлары чыгарып гырлый, һаваны яңгыратып төчкергәннән һәм гырлаганнан соң гына кабынып китә. Аның кабынуы малайларга зур вакыйга. Алар «ура» кычкырып шатланышалар. Урамга чыккач сүнсә, этеп кабызалар. Артур абыйлары малайларны машинага төяп бер урам урый. Күрше-тирәләрдә юкса өр-яңа импортный машиналар бар, ләкин малайлар никтер Артур абыйларының иске «Москвич»ын яратарак төшә. Дөресен әйткәндә, Артур абыйлары малайлар яратканга гына иске машинасын чүплеккә ыргытмый. Малайларны шатландыру аның җанына рәхәтлек бирә.
— Артур абыйга да машинаны күрсәтеп чыгабыз, яме, әти.
— Ярар, улым.
Артур абыйлары, Заһитның машинасын күргәч:
— О-о, безнең Заһитыбыз өр-яңа машина алган икән. Моны котларга кирәк бит. — Артур, тәрәзәсен тышкы яктан ачып: — Әнкәсе, анда пәрәмәч пешереп маташа идең, бер-икесен чыгар әле, — диде.
Хатыны тәлинкә тотырып пәрәмәч чыгарды. Ул, Гыймай белән Заһитны күреп: «Күршеләр кергән икән, әйдәгез өйгә, чәй эчеп чыгарсыз», — дигән иде, Заһит: «Юк, апа, безнең машинада йөрисе бар. Менә миңа әни машина җибәргән», — дип, машинасын күрсәтте. Боларның тормышларын яхшы белгән хатын «әни» сүзен малайның күңеленнән чыгарыр өчен бөтен игътибарын Заһитның машинасына юнәлтте.
— Бигрәк шәп машина булган бу!
— Әллә безнең «Москвич» белән алышабызмы? — дип, хатыны сүзенә Артур кушылды.
— Юк, алышмыйм. Әни машинасын алышмыйлар.
Заһитны күрше-тирәдә яшәүчеләр ярата һәм кызгана иде. Чөнки Заһитның телендә гел әнисе. Кайвакыт ул әтисенең рамнар ясый торган мастерское түбәсенә менә дә: «Әни, менә мин зур үстем. Кайт инде!» — дип кычкырып утыра, кычкырып арыгач елап җибәрә. Мондый чакларда Гыймай үзен гаепли: «Катырак кыланып ташладым бугай, йөрер-йөрер дә басылыр иде әле. Заһит ничек сагына. Йөрәге телгәләнә балакайның. Чынлап та бу Фатыйма кая китте икән? Моны белсә, бары Заһит беләдер».
Һәм Гыймай өлкән Заһитны эзләп карарга булды. Тик ул аның кайда, кем белән яшәвен белми, бары тик Фатыйма белән бер мәктәптә укыганнарын гына белә иде. Ләкин әле мәктәп ябык, укулар башланмаган. Ә бәлки, милиция идарәсенә барыргадыр. Заһит — утырып чыккан кеше, анда белми калмаслар.
Начальникның үзенә керә алмады Гыймай.
Кабул итү бүлмәсендә бер яшь кыз утыра иде, ул, тупас кына:
— Без беркемгә бернинди информация бирмибез, — дип җавап бирде.
— Минем ни өчен килгәнемне белмисез бит әле сез...
— Дежурный! — дип кычкырды кыз. Тавышка бер сержант йөгереп керде. — Чыгарып җибәрегез менә бу зоопарктан качкан маймылны.
— Туктагыз әле, тукта!..
Сержант Гыймайны өстери башлады. Ләкин Гыймай тамырлары җиргә ябышкан төп кебек урыныннан кымшанмады. Ул арада кулына портфель тоткан пөхтә адәм, шәүлә кебек кенә ишектән кереп, теге кыз янына килде. Портфеленнән ниндидер бүләк алып кызга тоттырды. Кыз аны яшен тизлеге белән өстәл тартмасына чумдырды. Шунда ук бу адәмне начальник бүлмәсенә кертеп җибәрде. Шул мизгелдән файдаланып, Гыймай да ишеккә ыргылды һәм: «Начальник!» — дип кычкырып җибәрде. Аның тавышына начальник кабинетыннан чыкты.
— Что за шум?
— Менә бер хулиган сезгә керергә тели. Чыгып кит, дим, чыкмый.
— Сержант! — диде начальник. — Менә бу кайнар башны «теге бүлмәгә» кертеп бераз суытып чыгарыгыз.
Әллә ни арада тагын бер милиционер кереп җитте. Алар Гыймайны өстерәп диярлек каядыр алып китеп ябып куйдылар.
— Тавышыңны чыгарма, — дип, бераз типкәләп алдылар.

«Менә ни өчен халык милициягә барырга курка икән. Караклар, хулиганнар, юлбасарлар халыкның соңгы тиен акчасын талап ала. Кешеләр башкаларга күрсәтми кан-яшь түгә, ләкин милициягә бармый. Чөнки белә: милициянең хулиганнан яманрак булуы мөмкин. Әнә машинист Миркасыймның машинасы урлангач, шаһит булып Госман барган иде, сорау алып йөрттеләр-йөрттеләр дә үзен ябып куйдылар».

Гыймайны берничә сәгать тоткач чыгарып җибәрделәр. Шуннан соң ул Заһитны да, Фатыйманы да эзләмәскә булды. «Чукынышып бетсеннәр!» — дип, бу эшкә нокта куйды.

Ә кечкенә Заһит әнисен озак сагынды. Тора-бара сагыну, юксыну хисләре малайның йөрәгенә ачу булып утыра башлады. Аның йөрәген ниндидер элпә каплады. Вакыт үткән саен, бу элпә калынайды, катыланды. Әби-бабаларының назлары, әтисенең гел кайгыртып, ни теләсә шуны алып бирүе дә ташбака кабырчыгыдай катыланган бу элпәне кубарып алып ташлый алмады. Малай керпе кебек үз эченә йомылды.

Гыймай авылдан килеп фатир таба алмый йөрүче Дамира исемле кызга өйләнде. Ни гаҗәп, бу кыз да авырлы булып чыкты. Гыймай, эчтән генә сукранып: «Күрәсең, хәзерге кызлар тумыштан авырлы булып туалардыр. Бәхетең кимерелгән сөяктән булса, берни эшләр хәл юк», — дип язмышына буйсынды. Гыймайның әнисе: «Без сыер алсак, кысыр, кызлар алсак, буаз була», — дип авыз эченнән сөйләнеп алгалады.

Кечкенә Заһит үсте, үсә барган саен аңарда әтисенең гадәтләре ныграк чагылды. Ул үзеннән көчсезләрне елатудан тәм тапты. Аеруча кызларга ачулы иде ул. Үги әнисе Дамираның бала табар вакыты җиткәч, Заһит аңа: «Әгәр дә мәгәр кыз тапсаң, кызыңны әнә теге сазлыкка батырып үтерәм», — дип кисәтеп куйды.

Дамира чынлап та кыз бала тапты. Баласының кыз икәнен белгәч, ул бик курыкты. Гыймай да, Заһит берәр нәрсә эшләп ташламагае дип, улын күз уңыннан ычкындырмады. Кызны Заһит барында бик иркәләмәскә тырыштылар. Ә Заһитның яңа туган баланы бер дә күргәне юк иде. Ул бишектә төрелеп яткан кызга гаҗәпләнеп карады.

— Син хәзер абый булдың, улым. Абый булу бик җаваплы эш. Сөйләшә башлау белән ул сиңа «абыем» диячәк. Ә инде тәпи йөри башлагач үзен берәрсе кыерсытса: «Абыема әйтәм», — дип кыерсытучыны куркытачак. Менә бит, улым, сеңлең туу сине никадәр үстерде. Көчле булу, сеңлеңне яклый алу бәхете бөтен кешегә дә эләкми.

Заһитка әтисенең сүзләре тәэсир иттеме, ул бишектәге кызга карап озак-озак уйланып тора башлады. Аның күңелендә нинди хисләр кайнаганын беркем белмәде.

* * *

Фатыйманың җитез машинасы Н. шәһәренә якынайганнан-якынайды. Юл буендагы агачлар машина тизрәк алга барган саен җәһәтрәк артка чигенгән кебек, күңелдәге хатирәләр дә үткәннәргә таба йөгерде. Хәтер күгеннән балачак дигән чор соры болыт булып агылып үтте. Соры болыт артыннан күкрәп-яшьнәп яшьлек яшеннәре ялтырады. Күктәге болытларга ут кабызып йөрүче Заһит күренеп калды. Фатыйма Заһитка кулларын сузды, ләкин аның учларына утлы яшен ташлары гына төште. Тик ни өчендер учка төшкән ташлар кулны түгел, йөрәкне яндырды. Хатирәләр җебе Илсур Мансуровичларга барып ялганды.

Әминә Хөрмәтовна үләр алдыннан улы Илсур белән Фатыйманы чакырып кертте.

— Улым, — диде ул, — соңгы көннәрдә өянәгем бик ешайды. Сиңа шуны әйтергә телим: күктән йолдыз эзләп йөрмә. Өйлән. Күпме тырышып җыйган байлыгыңны мирас итеп алырлык малай тап.

— Малайны мин үзем генә таба алмыйм бит, әни.

— Менә Фатыймага өйлән.

Илсур аптырап әнисенә карады.

— Саташып әйтмим, улым. Әйе, Фатыйма фәрештә түгел. Мин аның бөтен тормышын беләм. Тик кеше кайчан да булса чистарына башларга тиеш. Күпләр пычраклыктан ялгыз гына чыга алмый. Фатыйма күңелен пакьләндерә башларга вакыт.

— Ни өчен мин, әни?

— Чөнки син аның сазлыкка батуына күпмедер гаепле. Кеше тикле кешене үз дөньясыннан умырып алып, бер белмәгән җиргә алып кайту зур гөнаһ.

— Ярату дигән нәрсә дә бар бит, әни.

Әминә Хөрмәтовна улына бармак янады.

— Беләм-беләм. Хәйләкәрләнеп маташма. Фатыймага күз атып йөрүләреңне күрмәскә мин сукыр түгел ләбаса. Фатыйманың да син кайтып кермичә йокларга ятмавын, телефон шалтыраса да сикереп торуларын күреп торам. Озын сүзнең кыскасы шул, балалар, көн озын, гомер кыска, гөнаһлардан арынып матур итеп яши башларга вакыт.

Әминә Хөрмәтовна берничә көннән мәңгегә күзләрен йомды. Илсур Мансурович сабый баладай

үксеп-үксеп елады.

— Якты күңелле кеше иде, — диде Фатыйма. Ул да бу югалтуны авыр кичерде. — Авыр туфрагы җиңел булсын.

Әминә Хөрмәтовнаны җирләгәннән соң, Илсур Мансурович озак вакыт җанына урын таба алмый йөрде. Ул имезлеген югалткан баладай көйсезләнде, берәрсе ялгышрак сүз ычкындырса, кызып китте. Шушындый чакларда әнисенең алдына башын куеп, йөрәктәге сызлауларын баса торган өрлектәй ир, тамырын давыл кубарган имән кебек, кайсы якка аварга белми чайкалып торды. Фатыйма боларның яшәү рәвешен күргәч үзен бөтенләй башка дөньяда хис итте. Ана белән өрлектәй улының үзара самими мөнәсәбәте, Илсур Мансуровичның һәр эшне киңәшеп эшләве Фатыйманы гаҗәпкә калдыра иде. Әминә Хөрмәтовна күп вакыт улы сөйләгәннәрне аңлап та бетерми, өянәге ешайган чакларда ул берничә көн аңкы-миңке йөри. Әнисен шушы халәттән чыгарырга да улы ярдәм итә. Назның, бере-береңә ышанып йөрәгеңне ачуның никадәр кыйммәтле нәрсә икәнен Фатыйма төшенә башлады. Килгәнрәк мәлне ул авызы ныклап тегелгән капчык сыман мөмкин кадәр әзрәк сөйләшергә, үткәннәрне хәтер төбендәге учакта яндырырга тырышты. Ләкин хәтергә сеңгән вакыйгалар янарга теләмәде. Алардан котылыр өчен бушанырга кирәк иде. Әкрен-әкрен Фатыйма үзенең тормышын Әминә Хөрмәтовнага сөйли барды. Әминә Хөрмәтовна аны гаепләмәде дә, хупламады да.

— Безгә һәрвакыт тыелган алма тәмлерәк кебек шул. Синең сүзләреңә караганда, Гыймаең әйбәт кеше булган. Ә Заһитың сине аздырудан тәм тапкан. Гыймайга тормышка чыккач, аның сиңа килеп йөрүләре сине яратудан түгел, азгынлыктан, кешеләрнең арасын бозудан, үзенең бозык җанына рәхәтлек эзләүдән булган. Күпләр хәзер алдашуны, урлашуны, ата-бабаларыбыздан калган әхлак кагыйдәләрен аяк астына салып таптауны батырлыкка саный. Без хәзер авыр заманда: яхшылык белән яманлык буталган чорда яшибез. Нәрсәнең яхшы, нәрсәнең яман икәнен акылыбыз белән төшенгәч кенә без туры юлга чыгачакбыз.

Әминә Хөрмәтовнаның сүзләре Фатыйманың күңеленә сеңә барды. Илсур Мансуровичның үз-үзенә урын тапмый бәргәләнүләрендә Фатыйма үзен күпмедер гаепле сизде. Беркөнне, диванда телевизордан «Җәнлекләр дөньясында» дигән тапшыру караганда, боланнарның бер-берләрен ничек назлашуларын күрсәттеләр. Шунда Фатыйма үзе дә сизмәстән башын Илсур Мансуровичның иңенә салды. Фатыйманың чәчләре Илсур Мансуровичның битләрен кытыклады. Менә шушы бер кагылу Илсур Мансуровичның күңелендә яшеренеп яткан наз чишмәсен ачып җибәрде. Ни Фатыйма, ни Илсур авыз ачып бер сүз әйтмәде. Әмма йөрәкләрдән чыккан хисләр дулкыны, бер-берләренә кушылып, аларны нинди дер тирән кичерешләр дөньясына алып кереп китте. Бу — икесе өчен дә яңа дөнья. Моңарчы татылмаган саф чишмәләрдән, үрләре үзенә чакырып торган урманлы таулардан, таҗларын чыкларда юып утыручы чәчәкле болыннардан торган дөнья иде.

Илсур Мансурович белән Фатыйманың тормышлары шулай башланып китте. Илсур, әнисенең алдына башын куеп ял иткән кебек, арып кайткач Фатыймага сыенды. Фатыйманың тән җылысы аны тынычландыра һәм ул, хыялга бирелеп:

— Кайчанрак бер малай алып кайтабыз инде? — дигән сорауны кабатлый. — Бала тавышы яңгырамаган өй — телсез кыңгырау. Баласыз өй — чәчәксез болын...

Мондый сүзләр ешрак кабатланган саен, хатынның күңелендә элекке Фатыйма калкып чыга һәм Гыймайны искә төшерә. Ул да гел тагын бер бала апкайтыйк дип теңкәгә тия иде. Ләкин Фатыйма Илсурга дөресен әйтергә курка, ә дөреслек Фатыйманың балага уза алмавы иде. Ул инде врачларга да барып карады. Кайсы врачка гына бармасын, һәммәсе сүз берләшкәндәй аңардан Фатыйма моңарчы исемен дә ишетмәгән чир табып, бала таба алмаячаксың, дип тәкрарладылар. Фатыйма врачларны аңлый: ул җенси тормышка бик иртә кереп китте. Анда да гадәти итеп түгел, ниндидер бозыклык, азгынлык юлын сайлады. Болар, билгеле, эзсез калмагандыр. Ә Илсурга мирасын калдырыр, эшен дәвам иттерер кеше кирәк.

Шулчак Фатыйма улы Заһит турында уйлап куйды. Шәп фикер бит бу, шайтан алгыры! Аны Илсур яратыр, үз улы итәр. Ләкин бу фикерне маңгайга бәреп әйтергә ярамас, хыялны эшләтергә кирәк. Һәм Фатыйма бер төш уйлап чыгарды. «Узган төнне бер төш күрдем. Имеш, мин киң бер елганың бер ярында басып торам. Елга ургылып-ургылып ага. Шул ярсып аккан елганың икенче ярында бер малай агымсуга ташланырга тора. «Батып үләсең бит, ярдан читкәрәк кит», — дип кычкыруыма ул: «Батсам, коткарырсың, мин синең улың Заһит», — диде һәм суга ташланды. Мин аңа каршы сикердем. Шунда елга агуыннан туктап торгандай булды. Мин Заһитымны күтәреп ярга чыгардым. Аны җиргә басты-руга, улым: «Әни, анда тагын бер малай бар, ул әле йөзә белми. Аны да алып чыгарга кирәк», — диде. Кабат елгага ташланыйм дигәндә генә уяндым. Төшем шунда бүленде».

Илсур Мансурович төшләргә ышана, аларга югарыдан килгән бер хәбәр дип карый иде.

— Улыңны алып кайтырга кирәк сиңа, шуны алып кайтсаң, Ходай үзебезгә дә бер малай бирәчәк. Төшең бик хикмәтле синең, Фатыйма.

Фатыймага Илсур кебек акыллы ирләрнең дә уйлап чыгарылган төшкә ышануы кызык тоелды. «Акыл ягыннан ирләр хатын-кыздан нык калыша», — дигән фикер башына килгәч, ул үзен чын акыл

иясе итеп тоя башлады. Машинага утырып юлга чыгуга ук Әминә Хөрмәтовналар гаиләсендәге мөнәсәбәт ниндидер ялганга корылгандыр кебек тоелып, һәркем үз мәнфәгатен кайгыртa дигән фикергә килде. Илсурның Фатыйманы ашыктырып юлга чыгаруы да аның күңеле олылыктан түгел, Заһитны алып кайткач үз уллары туар дигән өметтән чыгып эшләнгән эш түгелмени? Дөрес, ул: «Заһитны алып кил», — дип элек тә әйтә иде. Әйтә, ләкин бик тиз оныта иде. Ә бу төшне сөйләгәч әнә ничек кабынды.

Һәркемнең матур сүзе артында ялган яшеренеп ята дигән фикерне күңеленә сеңдереп үскәнгәме Әминә Хөрмәтовна, Илсур Мансуровичларның күңел сафлыгын, беренче карашка кырысрак күренгән йөрәктә салават күперендәге кебек төрле төсләрнең табигый кушылуыннан барлыкка килгән гүзәллек ятканын аңлый алмады шул Фатыйма. Яшьтән үк җанына оялаган шайтани хис: «Беркемгә ышанма. Дөнья ул пычрак сазлык. Кешеләр, бер-берләренең өсләренә басып, шул сазлыктан чыгарга тели. Мөмкинлек барында син дә Илсур Мансуровичның иңнәренә басып югарырак күтәрелеп кал. Улыңны син күптән алып кайта ала идең, ләкин моңа кадәр ул сиңа кирәкмәде. Син үзеңне генә яраттың».

Фатыйма күңелендәге Иблис белән килешергә теләмәде.

— Юк, мин үземнән артыграк Заһитны яраттым.

— Заһитны да яратмадың син. Ул чибәр һәм аның артыннан күп кызлар чаба иде. Башка кызлар өлгергәнче бу калҗаны үзем эләктерим дип, син аны салынып бетмәгән йортның караңгы бүлмәсенә сөйрәдең.

— Дөрес түгел, Заһит мине алдап үзе алып керде. Бер кызык әйбер күрсәтәм, дип.

— Ул «кызык әйбер»нең нәрсә икәнен белеп кердең бит син.

— Белсә соң! Бөтен кызларның да аны беләсе килә. Заһитны яратмасам, мин ул «кызык әйбер»не башка җирдә бүтән кешеләр белән күрер идем.

— Атасын яраткач, улын да ярата лар.

— Мин улымны яраттым.

— Яратмадың. Яратсаң, син аны Илсур Мансуровичларга алып килә ала идең. Син Илсур Мансуровичны үзеңә карату уе белән яшәдең. Әминә Хөрмәтовнага үзеңне тормыш тарафыннан рәнҗетелгән кеше итеп күрсәтергә тырыштың. Син молодец! Максатыңа ирештең.

Фатыйма юл буе үзе белән үзе бәхәсләшеп кайтты. Н. шәһәренә килеп җиткәч, йөрәге ешрак тибә башлады. Иреннәре кипте. Ул су алырга дип бер кибеткә керде. Керү белән кайчандыр бергә укыган, шәһәрнең бөтен гайбәтен белә торган Гөлфияне күрде. Гөлфия сатучы булып эшли икән.

Ул, ахирәтен күрүгә:

— О-о, кемне күрәм! Син кай тарафлардан? Ирдәме? Ирең кем? Заһитың турында беләсеңме? — дигән сораулар белән Фатыйманы күмеп ташлады. Ләкин Фатыйма авызын ачарга өлгергәнче, тагын тел пулеметын хутка җибәрде. — Ишеткәнсеңдер инде, Заһитың җүләрләнде. «Менә мин сезнең алтыннарыгызны китердем. Аларны мин урлаган идем», — дип, кешеләргә кереп йөри икән. Ә кешеләргә алтын дип алып кергән нәрсәсе йә берәр тимерчыбык кисәге, йә ялтыравыклы шешә бөкесе була, ди. Инде үзен әллә ничә тапкыр кыйнап та ташлаганнар. Барыбер йөри, ди. Беркөнне әле аны кемнәрдер ыштансыз күргәннәр, ди. — Гөлфия бер сүзен өзмәстән икенчегә күчә: — Теге син эшләгән кибет хуҗасы Сәгыйть Хәмитович турында ишеттеңме? Ул бит бер яшь кызны икенче хатын итеп алган. Ак яулыклы, гыйффәтле кыз булган, ди. Алтын күргәч, фәрештә азган, диләр бит. Гыйффәтле кыз да ак яулыгын салып ташлап бик тиз «ит бүкәне» астына кереп киткән. — Гөлфия хихылдап көлеп алды һәм сүзен дәвам итте: — Гыйффәтле кызның аппетиты шәп икән. Тиз арада үзенә кибет ачтырган, элитный йорттан ике бүлмәле фатир алдырган. Сәгыйть Хәмитович аның күзләренә генә карап тора, имеш.

Фатыйманың бик эчәсе килә иде, Гөлфиянең бер мизгелгә авызы йомылудан файдаланып су сорап алды да тизрәк китү ягын карады. Ә Гөлфия аны ишеккә кадәр озата барган булып тагын берничә хәбәр әйтергә өлгерде:

— Теге «мунча пәрие» — Гыймаеңның өйләнгәнен әйткәннәрдер инде. Бер авыл кызына өйләнгән. Ансы да корсаклы булган. Тисә дә тия бит бәхет кешегә. Тагын әле...

Фатыйма аның соңгы сүзләрен ишетмәде. Тизрәк машинасына утырып Гыймайларга таба элдертте. Ләкин өйгә якынайган саен, машинасының тизлеге кимеде. Заһитның юләрләнүе турындагы хәбәр аны тетрәндерде. «Мине югалту хәсрәтен күтәрә алмагандыр, бичара. Бигрәк нык ярата иде шул. Ә Гыймайның өйләнүе әйбәт. Яшь хатынга минем Заһитым артык кашык кына. Артык кашыктан һәркем тизрәк котылырга тели».

Шундый уйлар белән Фатыйма Гыймайлар капка төбенә килеп җитте. Урамда берничә малай туп тибә иде. Туп тәгәрәп Фатыйманың машинасы астына кереп шартлады. Малайлар Фатыйманы сырып алдылар.

— Апа, сез бу тупның нинди туп икәнен беләсезме?

— Футбол тубы.

— Шулаен шулай, ләкин безгә бу тупны чемпион Инсаф абый бирде. — Малайлар машина

астыннан тишелгән тупны тартып алдылар. — Менә монда Инсаф абыйның автографы.

— Әйе, сезнең өчен бик кадерле нәрсәне таптаганмын икән. Сезне ничек бәхилләтергә соң инде? Яңа туп бирсәм, риза булырсызмы?

Фатыйма машинасыннан өр-яңа туп алып һавага чөйде. Малайлар — тупны, ә Фатыйма малайларны күзәтте: «Бу малайлар арасында аның улы Заһит булырга тиеш. Кайсы икән? Әнә теге озын торыклысыдыр, мөгаен».

Фатыйма шулай дип уйлауга, Гыймайларның капкасыннан бала күтәргән бер хатын чыкты да:

— Заһит, Заһит, аш пеште, ашарга кер, — дип кычкырды.

Малайлар арасыннан йөреше белән Гыймайга охшаганрак, нык бәдәнле, тәбәнәгрәк буйлы берәү ачык капкага юнәлде. Фатыйманың күңелен нидер чеметеп алды: «Әстәгъфирулла, неужели минем Заһит бу? Нәкъ Гыймай».

Малайга ияреп ачык капкадан Фатыйма да керә башлаган иде, бала күтәргән хатын:

— Сез кемгә? — дип, аны туктатты.

— Гыймайларның өе шушы иде кебек. — Фатыйма теге хатынның җавабын да көтмичә кыю рәвештә өйгә юнәлде.

Бала күтәргән хатынның йөрәгенә ут йөгерде: «Фатыйма! Гыймайның Фатыймасы кайткан. Гөнаһ шомлыгы, Гыймайның өйдә чагы».

Фатыйма килеп кергәндә, Гыймай күкрәгенә терәп ипи кисеп тора иде. Ишектән Фатыйма килеп кергәч, аның кулыннан пычагы төшеп китте.

— Фатыйма?!

— Әйе, синең яраткан Фатыймаң, әйдә күрешик.

Гыймай кулындагы ипине өстәлгә куеп Фатыйма белән күреште. Бала күтәргән хатын Фатыйманы өзгәләп ташлардай булып боларның һәр хәрәкәтен күзәтте.

Өйдә ниндидер авыр тынлык урнашты. Дамира кулындагы кыз шыңшымаса, бу тынлыкның озаккарак сузылуы мөмкин иде.

— Кызыңның исеме ничек? — диде Фатыйма, Дамирага төрттереп.

— Кызыбыз Чәчкә исемле.

— Матур исем кушкансыз. Ә безнең Заһитыбыз кая соң әле?

— Сезнең Заһитыгыз кайдадыр, ә безнеке үзебездә. — Хатын ишекне ачып карады. — Бәй, — диде ул, — артымнан кереп килә иде бит. Мәле, атасы, кызыңны тотып тор, Заһитны эзләп керәм.

Хатын баласын Гыймайның кулына тоттырып чыгып китте.

— Нәрсәгә кайттың? — диде Гыймай, кырыс кына.

— Курыкма, синең янда калырга дип түгел, улым Заһитны алырга кайттым.

— Синең улың бармыни? — диде Гыймай.

— Акыллыланып утырмасана. Сезгә бит хәзер минем улым кирәкми. Әнә Дамираңның Чәчкәсен үстер. Кеше балаларын үстерергә яратасың бит син.

Гыймайның чиктән тыш ачуы кабарды. Ул үзен тыяр өчен өстәл почмагына тотынган иде, өстәл почмагы шартлап сынды. Фатыйма, Гыймайның ярсыган чакларда нәрсәгә сәләтле икәнлеген яхшы белгәнлектән, өй эчендә дулап кубарга торган буранны басарга теләп сүзен йомшарта төште.

— Мин ачуланышырга дип кайтмадым, Гыймай. Әйе, мин сине рәнҗеттем. Сиңа мине кичерүе кыендыр. Ирләр хатыннарын ташлап киткәндә, хатыннары кичерә ала, ә хатыннары ташлаган ирләр гафу итә алмый.

Фатыйманың сүзләрендә күпмедер хаклык барлыгын аңласа да, Гыймайның күңеле йомшамады.

— Ташлау белән ташлауның аермасы бар, — диде ул. — Син минем күңелемдәге иң изге нәрсәләремне (Гыймай хисләрне дияргә теләгән иде дә, мондый сүзләр төчелек була дип хис сүзен кулланмады) мыскыл иттең, таптадың.

Гыймай бик нык ярсуга карамастан, Фатыйманы кимсетерлек сүзләр әйтмәде. Юкса мин сине авырлы килеш алып, дусларыңның мыскыллы карашыннан коткардым. Заман нинди генә якка үзгәрмәсен, кияүгә чыкканчы ук корсак тутыруны беркем дә хупламый, дип әйтә ала иде. Шулай ук, минем йөзем ямьсез булса да, күңелем чиста, син минем пакь күңелемә үзеңнең пычрагыңны йоктырдың. Синең аркаңда мин кешеләр күзенә туры карый алмый башладым, дип әйтә ала иде. Күрәсең, Фатыймага әле аның күпмедер мәхәббәте сакланып калган булгандыр.

Гыймай белән Фатыйма сүзсез генә «сөйләшкән» арада Заһитны җитәкләп Дамира кайтты. Фатыйма тиз генә машинасы янына чыгып китте, аннан бер кочак кием-салым күтәреп керде. Ул киемнәрен Заһитның каршысындагы урындыкка куйды.

— Улым, — диде Фатыйма, — мине танныйсыңмы? Мин кем?

Заһит аны ныклап танымаса да, күңеленең ниндидер күзәнәге белән бу хатынның үз әнисе икәнлеген тоемлый иде. Ләкин ул әнисенең кочагына ташланырга ашыкмады. Аның күңелендә хисләр өермәсе башланды: әтисе белән аны кибеткә барып сорашулар, кайтканда күзләреннән бәреп чыккан күз яшьләрен сөртә-сөртә күлмәк җиңнәренең чыланып бетүе, сатучы кызларның, Фатыйманың кайда

икәнлеген белмибез шул, диюгә әтисенең киң җилкәләре асылынып төшүе, таныш-белешләре сорашмасын өчен урау тыкрыклардан кайтулары Заһитның күңеленнән чөй белән дә бәреп чыгарырлык түгел. Бигрәк тә усал малайларның: «Синең әниең фәлән, синең әниең төгән», — дип кабахәт сүзләр әйтүе, шул сүзләрне әйттермәс өчен канга батканчы сугышуы онытырлыкмыни?

— Йә, улым, нигә бер сүз дә эндәшмисең? Мин бит синең әниең — Фатыйма.

— Минем әнием юк, әтием генә бар, — диде Заһит.

— Менә мин сиңа матур киемнәр алып кайттым. Киеп кара әле, таман микән?

— Минем үз киемнәрем дә җитәрлек. Әти миңа бөтен нәрсәне алып бирә.

Фатыйманың кире малайга ачуы чыга башлады. Заһитның кулыннан тотып үзенәрәк тартты. Киемнәрен салдырырга маташты. Ләкин малай әнисен читкә этеп җибәрде.

— Юк инде, улым, — диде Фатыйма, — мин сине бу хәерчелектә калдыра алмыйм. Әнә капка төбендә «Форд» машинасын күрәсеңме, ул минем машина. Берничә елдан анда син йөри башлаячаксың.

— Безнең үзебезнең машинабыз бар, — диде малай. — Әти мине гел үз машинасында йөртә.

Фатыйманың түземлеге бетә башлады.

— Никадәр генә киреләнмә, барыбер мин сине хәерчеләр арасында калдыра алмыйм.

— Без хәерче түгел. Минем әтием акчаны күп ала.

— Кем соң синең әтиең? «Мунча пәрие» Гыймаймы? Алайга киткәч соңгысын әйтәм: Гыймай синең әтиең түгел. Синең әтиең... — Фатыйма, синең әтиең озын буйлы чибәр Заһит, дип әйтергә авызын ачкан иде дә, Заһитның юләрләнүен күз алдына китереп тыелып калды. Ул инде болай гына улын алып китә алмаячагын аңлаган иде. — Сез аны миңа каршы котырткансыз, — дип, ул Гыймай белән Дамирага ташланды.

Әнисенә Заһитның каты торуы аларны тынычландырган иде. Шуңа күрә алар Фатыйманың кыланышларын сабыр гына карап тордылар. Гыймай Фатыйма килеп керүгә үк Заһит әнисе кочагына ташланыр дип курыккан, чөнки малай юк-юк та әнисе турында сораштырып куйгалый, хәтта бер фоторәсемен китап арасында йөртә иде. Беркөнне ничектер сумкасын актарганда, малайның китаплары таралды һәм берсенең эченнән әнисенең алсу ефәк күлмәк киеп, чәчләрен җилдә җилфердәтеп төшкән фотосурәте килеп чыкты. Фотосурәтне Гыймай алып озак кына карап торды. Заһит, үзен гаепле сизеп:

— Мин аны әнинең альбомыннан алдым, үзе күрмәгәндә, — диде.

— Ярый, улым, мин берни дә әйтмим бит, әниеңне онытмавың әйбәт. Ничек кенә булмасын, әни әни инде ул.

Шунда Заһит:

— Әтием, Дамира апаны «әни» дип әйтмәсәм ярыймы? — дип сорады.

Гыймай, улын күкрәгенә кысып:

— Ярый, улым, ярый. Әни бер генә була, — дигән иде.

Фатыйма бу гаиләнең шактый нык икәнен аңлады һәм хәйләгә күчте:

— Ярый, улым, син минем белән китәргә теләмисең икән инде, һич югы, минем машинага утырып шәһәрне карап йөрик. Алты ел буе читтә яшәп үз шәһәремне оныта башлаганмын. Әйдә, улым, иптәш малайларыңның күзләре янсын әле. Заһит менә нинди машиналарда гына йөри, дисеннәр. Йә, киттекме?

Заһитның шәп импортный машинага утырып шәһәр әйләнәсе бик килә. Берәрсенең капка төбенә ятрак машина туктаганын күрсәләр дә, алар шунда җыелышып, нинди маркалы икәнен укыйлар иде. Улының ул гадәтен Гыймай белә һәм әнисенең машинасына да утырырга теләвен ул яхшы аңлады. «Мәхәббәт нәфрәткә әйләнсә, аны яңадан кайтарып булмый шул», — дип фикер йөртте Гыймай. Гыймай тагын шунысына шат: бөтен мәсьәләне Заһит үзе хәл итте.

— Әти белән әнине дә алсаң гына утырам, — диде ул.

— Нинди әни?! Менә мин бит синең әниең.

— Юк, минем әнием менә! — Заһит Дамираның биленнән кочаклады. Дамираның күзләренә яшьләр килде.

— Рәхмәт, улым! — диде ул, йомшак тавыш белән. Моңа кадәр Дамирага «апа» дип кенә дәшкән Заһитның үзен «әни» дип атавы яшь ананың күңелен йомшартты. Дамира күзләрен алъяпкыч итәгенә сөртте. Ул арада калкандай булып Дамира белән Заһит янына кызын күтәргән Гыймай килеп басты. Фатыйма бу күренешкә түзеп тора алмады, улына дип алып кайткан әйберләрне таптап:

— Җир тараканнары, кадерне белмисез икән, яшәгез шунда пычракка аунап. Ә синең, Заһит, бервакыт исеңә төшәр, ләкин соң булыр. «Әтием» дип атаган «мунча пәрие» кебек надан, аңгыра, киребеткән нәрсә чыгачак синнән. Укырга телерсең, әмма хәерчеләргә уку йортларында урын булмас.

— Сүзең бетсә, чыгып китәргә мөмкин, — диде Гыймай, ишекне ача төшеп.

— Кумасагыз да китәм, сезнең сөрсегән өегезнең исен иснәп торасым килми.

Фатыйма ярым ачык ишеккә китереп типте дә дулап чыгып китте. Ул итәгеннән давыл күтәргәндәй машинасына менеп кунаклады. Фатыйманың «җененнән» курыккан машина алга ыргылды. Машина

астында ике каз ял итеп яткан икән, алардан канлы эз генә калды.

Фатыйманың кайтканын тыкылдык Гөлфия шәһәргә таратып өлгергән, хәтта бу хәбәр юләр Заһитка да барып ирешкән иде. Ул сәләмә киемнәрен җилфердәтеп Гыймайларга юнәлде. Шул вакыт юл чатыннан уктай атылып бер кара машина килеп чыкты да, Заһит юеш борынын җиңенә сөртеп маташканда, аны бәреп тә китте. Заһит юл читендәге бетон баганага сыланды. Кеше таптатканын күргәч, Фатыйма машинасының тизлеген тагын да арттыра төште. Аның күзе-башы тонды. Кул-аяклары акылга буйсынмый башлаган иде. Шулчак кинәт әллә күк күкрәде, әллә Фатыймага гына күкрәү тавышы ишетелде, аның куллары рульдән ычкынды һәм ул текә борылышта упкынга очты.

Әле җаны чыгып җитмәгән Заһитны да, кем икәнлеге танымаслык хәлгә килгән Фатыйманы да «ашыгыч ярдәм» машинасы больницага алып китте.

Алда аларны нәрсә көткәнлеген бер Алла гына белә иде.

*2006*

# МӘХӘББӘТТӘН КӨЧЛЕ ДӘВА ЮК

*(Сценарий ике бүлектә)*

**КАТНАШАЛАР:**

Айсылу — 25–27 яшьләрдә.
Сәрбиназ — 57–60 яшьләрдә, Гәрәйнең өендә аш-су пешерүче.
Гәрәй — 45 яшьләрдә, бай эшмәкәр.
Рәхилә — 43–47 яшьләрдә, Гәрәйнең беренче хатыны.
Альберт — 20 яшьләрдә, Рәхиләнең улы.
Габдулла — таза гәүдәле ир, Гәрәйнең өендә каравылчы.
Ике тән сакчысы — яшьләре билгесез.
Кыска егет (Тәпән).
Озын егет (Карчыга).
Ике кыз.
Семен Петрович — «Горзеленхоз» башлыгы.
Маһруй — Сәрбиназның апасы.
Сәрия — Маһруйның кызы.
Барый — балыкчы.
Мисбах Фәттахович — эшмәкәр.
Күренешләрдә төрле яшьтәге кешеләр.

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шома асфальт юлдан ак «Мерседес» чаба. Юлның ике ягында да агачлар. Көзнең әле башы гына булганлыктан, агачларда сары яфраклар күренми. Руль артында яшь чибәр Айсылу. Аның янында Сәрбиназ. Болар нидер сөйләшәләр, ләкин машинаның магнитофоныннан яңгыраган җыр тавышы аларның сүзләрен ишеттерми. Машинадагылар җырчы Гөлнара Тимерҗанованы тыңлыйлар. Машина үзеннән алда баручыларны уза-уза шәһәр эченә керә. Һәм озак та бармый матур итеп салынган бер коттедж янына килеп туктый. Болар кайтканны капка төбендә ике кеше көтеп тора. Аларның берсе — Рәхилә, икенчесе — Альберт. Машина борыны белән капкага терәлә язып туктауга, Рәхилә белән Альберт машина янына киләләр. «Мерседес»тагыларның боларны күргәч кәефе кырыла. Айсылу кинәт ишекне ачып җибәрә дә машинадан чыга. Ул аларга нәфрәтләнеп, шул УК вакытта кызганып та карый.

Айсылу. Нәрсә кирәк инде сезгә тагын?

Альберт *(ясалма елмаеп)*. Здравствуйте, красавица-мамочка. Неужели не понимаешь, что нам надо?

Айсылу. Мин сиңа нинди мамочка булыйм?

Альберт. Папаняның хатыны миңа мамочка буладыр инде.

Айсылу *(Рәхиләгә күрсәтеп)*. Әнә синең мамочкаң.

Рәхилә *(ялагайланып)*. Минем Альбертчигым хәзер, Айсылу, сине ныграк ярата. Иртән торса — Айсылу, кичен ятса — Айсылу.

Машина эченнән кулына сумкаларын күтәреп Айсылу белән бергә Сәрбиназ төшә. Ул тегеләргә ачулы караш ташлый.

Рәхилә. Гриша үзенең яшь хатынына бик авыр койрык таккан. Миңа алай койрык такмый торган иде. Койрык булып йөрүләре рәхәт түгелдер, Сәрбиназ әби, «туташ»?

Сәрбиназ. Синең ише майлап бирсәң эт ашамас нәмәрсәләргә кем койрык таксын?! Камыт аяк Рәхиләгә койрык та таксаң, ике атлаган саен абыначак бит.

Рәхилә. Ә син картайганчы ир чырае күрмәгән әби-туташ. Ха-ха-ха!

Айсылу алар янына килә.

Айсылу. Нигә болай ямьсезләнәсез?

Альберт. Правильно, мамочка-красавица. Яратмыйм шул хатын-кызның петушиться иткәнен.

Сәрбиназ. Синең кесәң тулы акчаң булса, шул җиткән. Акчаны бик яратасың син.

Альберт. А кто их не любит? Дөньяның тоткасы — акча. *(Айсылуга.)* Акча ул безнең мамочка-красавицага гына кирәкми. Потому что ул үзе золото.

Айсылу. Ялагайланма! Иң яратмаганым ялагайлык.

Сәрбиназ. Каты тор син аларга, балам. Аларга бармагыңны каптырсаң, кулыңны кабып йотарлар.

Альберт. Тише, бабушка. Монда шаулашып безнең мамочка-красавицаның авторитетын төшермәгез. А то папаня сезне не простит.

Айсылу кесәсеннән ниндидер пульт-аппарат чыгарып аның кнопкасына баса. Ул арада зур гәүдәле каравылчы Габдулла чыгып, капкадагы йозакны ача башлый.

Габдулла. Гафу итегез, Айсылу Акбулатовна, кайтканыгызны ишетмичәрәк калдым.

Сәрбиназ. Йокы бүсеп яткансыңдыр әле.

Габдулла. Виноват, Сәрбиназ «туташ».

Сәрбиназның «туташ» сүзе тагын кабатлануына бик ачуы чыга. Чөнки ул кияүгә чыкмый картаеп килүче хатын-кыз. Ул Габдулланың борын төбендә сумкасын селтәп куя.

Сәрбиназ. Җиде хатын аерып, җитмеш җиденчесе турында хыялланып яткан нәмәрсәләр белән сүләшмибез без.

Габдулла бүтән сүз әйтми, капканы ачып куя. Айсылу машинасын кертеп куяр өчен ишегенә тотынуга, Рәхилә белән Альберт мескенләнеп аның каршына килеп баса. Рәхилә күзләрен сөрткәләп ала. Альберт Айсылу алдында тезләнә.

Рәхилә. Айсылу, үтермә безне, коткар. Квартирабыздан куалар. Ничә ай инде квартирага түләргә акчабыз юк. Ашау-эчү турында әйтмим дә.

Альберт. Красавица-мамочка! *(Айсылуның аягын кочакламакчы була, ләкин кыз аны этеп җибәрә.)*

Айсылу. Гәрәй Мингалиевич сезгә ай саен тиешле өлешегезне җибәреп тора бит. Кая куясыз ул акчаларны?

Рәхилә. Акча кулга озак керсә дә, бик тиз чыгып китә. Менә бу шалапай *(Альбертның башына сугып ала)* машинасын бәрдерде, аны төзәттердек. Кием-салымы, башкасы.

Альберт *(Айсылу алдында һаман тезләнеп)*. Мамочка, пожалей нас. Ты же у нас очень добрая.

Айсылу аптырабрак кала.

Сәрбиназ. Жәлләмә шуларны, кызым. Аерылышкан чакта Гәрәй Мингалиевич аларга байлыкны өеп калдырды.

Айсылу. Бирергә теләсәм дә, минем кулымда акча юк.

Альберт. Безгә сумкагыздагысы да җитеп торыр иде бүгенгә. Иначе подохнем с голоду.

Альберт күз яшьләре белән елап җибәрә. Айсылу тап-таза егетнең елап торуын авыр кичерә. Сумкасын актара башлый. Сәрбиназ Айсылуның кулына килеп ябыша.

Сәрбиназ. Бирмә шуларга бер тиен дә. Эшләп ашасыннар.

Рәхилә *(Сәрбиназга)*. Ә син кысылма, хәерче. Ул минем Гришамны тартып алды. Шуның өчен ул безгә гомер буе бурычлы.

Сәрбиназ. Тартып алды, имеш. Син аның бөтен җирдә йөзен каралтып йөрдең. Гәрәй Мингалиевич синең белән аерылышканда дөньяда Айсылу барын белми дә иде. Аерылышып җиде ел үтүгә, дөньягыз пыран-заран килде. Мин ишетеп торам: Гәрәй Мингалиевич биргән бөтен акчаларны Альберт уен автоматларында оттырып бара.

Рәхилә. Акчаны ничек телибез, шулай тотабыз. Аны синең кебек ыштан төбендә сакламыйбыз.

Сәрбиназ. Оятыгызны күсе ашаган нәмәрсәләр. Шулкадәрле акчагыз була торып, хәер сорашып йөрисез. Җирбитләр!

Рәхилә. Без хәер сорашмыйбыз, безгә үз өлешебез кирәк.

Сәрбиназ. Өлешегезне артыгы белән алдыгыз инде. Сез аналы-уллы комсыз сөлек кебек Гәрәй Мингалиевичның канын суырып яттыгыз. Шуңа да мантый алмады, хәзерге байлыгы — Айсылу бәхете.

Айсылу. Ярар, Сәрбиназ апа, монда урамда кеше көлдереп тормыйк.

Айсылу сумкасыннан күпмедер акча алып Рәхиләгә суза. Ләкин аның кулын Альберт эләктереп ала. Акчаларны фокусник тизлегендә кесәсенә чумдыра да Айсылуның кулын үбеп ала. Айсылу аңардан җирәнеп кулын сөртеп куя.

Альберт. Спасибо, мамочка, спасибо.

Рәхилә. Рәхмәт, Айсылу, синең юмартлыгыңа ышанып килгән идек. Тик сиңа бер үтенечем бар.

Айсылу. Нинди?

Рәхилә. Безнең монда килгәнне, акча сораганны Гришага әйтмә, зинһар.

Айсылу. Бездә Гриша юк, Гәрәй генә.

Рәхилә. Ярый, ярый, Гәрәй Мингалиевичка әйтмә. Ул болай да безне дөньядан юк итәргә йөри.

Айсылу. Ничек инде? Ни өчен?

Рәхилә. Аерылган хатын кемгә кирәк. Лишняя обуза. Ә артык йөктән һәркем котылырга тели. Беркөнне өебезгә ике бандит кереп чак үтереп чыгып китмәделәр. Аларны безгә кем җибәргәне ачык инде.

Сәрбиназ. Кирәгегезне алдыгыз, барыгыз, бар. Монда тузга язмаганны сүләп кеше башын катырмагыз.

Рәхилә. Кумасагыз да китәбез. Синең кебек аждаһа янында торганчы, ач бүре авызына керүең яхшырак.

Сәрбиназ. Ач бүре дә ашамас сезне.

Рәхилә белән Альберт бераз читкәрәк китәләр.

Рәхилә. Боларга тыныч кына яшәргә ирек бирмәскә кирәк, улым.

Альберт. Зачем, мама? Молодая мамочка добрая. Пусть живут.

Рәхилә. Аңгыра баш. Каннарына гел тоз салып тормасаң, бер тиен дә тамызмаячаклар алар. Ә бу маңкасы күркәдәй кабара, ханбикә диярсең. Үзен ничек тота! Гәрәйгә килгәнче берәр бетле баш булгандыр әле.

Альберт. Юк, мама, бетле башларда андый осанка, андый гордый взгляд була алмый.

Рәхилә. Кем генә булмасын, син бу йортка ешрак кил. Син килеп киткән саен сугышачаклар алар.

Альберт. А зачем это?

Рәхилә. Зачем, зачем? Аңгыра баш. Нигә алар гына бәхетле булырга тиеш? Мин дә яшь чагымда Айсылудан ким түгел идем.

Альберт. Тоже мне скажешь, она же первая красавица города.

Рәхилә. Өтәләгән тавык, синең кызлар күргәнең бармы соң?

Альберт. А зачем они мне нужны? Я без них хорошо живу.

Рәхилә. Өйләндерергә иде сине берәр бай хатынга.

Альберт. Нәрсә, миннән туйдыңмыни?

Рәхилә *(муенын күрсәтә)*. Менә болай гарык.

Альберт. Тогда найди какую-нибудь богатую бабушку!

Рәхилә. Богатая бабушкалар да җирдә аунап ятмый шул. Синдә хитрость юк. Телең балта белән юнылган. Андый бабушкалар янында сандугач булып сайраргa кирәк.

Альберт. Хватит! Я не хочу больше о бабушках говорить!

Рәхилә. Бабушкалар кирәкмәсә, Айсылу янына ешрак кил.

Альберт. О-о, аның сакчылары күреп алса?

Альберт. Сине Айсылу белән ешрак күрсеннәр. Тормышларын пыран-заран китерергә кирәк аларның. Тамчы тама-тама ташны тишә.

Алар шулай сөйләшә-сөйләшә агач артындагы машиналары янына киләләр һәм тиз генә кузгалып китәләр.
Сәрбиназ Айсылуның юмарт кылануына риза түгел. Ул үзен кая куярга белми йөренә. Өйгә кереп китәләр.

Сәрбиназ. Теге әрәмтамакларга акча биреп бер дә әйбәт эшләмәдең, балам. Алар бит мескенләнәләр генә.

Айсылу. Жәл бит, Сәрбиназ апа.

Сәрбиназ. Һы, әйттең сүз, жәл, имеш. Гәрәй Мингалиевич аларга менә дигән фатир алып бирде. Теге сөрхәнтәен армиягә җибәрмәс өчен күпме акча түкте. Җылап сораган саен акча бирә башласаң, алар әллә нәрсәңне дә җылап сорарлар, бирерсеңме?

Айсылу. Син бигрәк инде, Сәрбиназ апа.

Сәрбиназ. Соң, эшләп ашасыннар. Гәрәй Мингалиевич ул Әлбиртне ничә тапкыр эшкә урнаштырды. Юк, эшлисе килми. Ата малы белән типтереп яшәү җиңелрәк шул. Ул бит аракыны да шешәсеннән генә чөмерә. Әнисе дә улыннан калышмый.

Айсылу. Туктатыйк әле бу сүзне, Сәрбиназ апа.

Сәрбиназ. Ярар, ярар. Бүтән авызымны да ачмам. Тик син, кызым, болар белән саграк кылан. Мин

ул Рәхиләне ашханәдә эшләгән чагымнан ук беләм. Пычрак кеше. Аллам сакласын, пычраклары йогуы бар. Акча сорап килүләрен Гәрәй Мингалиевичка әйтмәскә кушуы да мине шиккә салды. Моның төбендә берәр әшәкелек ятмый микән?

Айсылу. Бичара бәндәләр. Җүнле генә эш табуы да кыен бит хәзер. Бөтен кешегә ярдәм итә алсаң иде.

Сәрбиназ. Ышанма шуларның юха телләренә. Мескеннәр, имеш. Бичара түгел алар, аждаһалар.

Айсылу. Ярый, ярый, Сәрбиназ апа, ашарга берәр нәрсә әзерли башла. Урманда төлке күреп кайтканнан гына тамак туймас.

Сәрбиназ. Ярар, балам, мин киттем.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Сәрбиназ кухняга кереп китә. Айсылу әле бер, әле икенче көзгедән үзен карый да берсенең каршысына утырып уйга кала. Уйлары аның Гәрәй белән беренче танышкан вакытны көзгедә чагылдыра. Менә ул егерме яшьлек кыз әтиләренең иске «шестерка»сы белән олы юлда

туктап калган.

Кыз машинаның капотын ачып кайбер чыбыкларын тарткалап карый. Аннары кабызырга теләп шактый вакыт стартерны әйләндерә. Ләкин машина кабынмый. Айсылу ачудан машинага берничә тапкыр тибә, ләкин аякларын гына авырттыра. Нишләргә белми бераз аптырап торганнан соң, юлдан узучы машиналарга кул күтәрә. Тик берсе дә туктамый. Ниһаять, бер «КамАЗ» машинасы туктый һәм шоферы кызга дәшә.

Шофер. Нәрсә, чибәркәй, ишәгең киреләнәмени?

Кызның бу ерык авызлы шоферга ачуы чыга. Ничек кенә иске булмасын, бу машина әтиләреннән калган бердәнбер бүләк. Айсылу үз машинасын ярата, аның белән «сөйләшеп» тә йөри. Тик соңгы вакытларда еш ватылуы гына эчен пошыра. «КамАЗ» шоферы машинасын

нан төшеп кыз янына килә.

Шофер. Кайгырма, чибәркәй, төзәтербез машинаңны. Мин бу «шестерка»ларның холкын беләм, үземнеке шундый.

Айсылу. Рәхмәт инде, абый.

Шофер. Рәхмәте төзәткәч булыр.

Шофер Айсылу машинасының капотын ачып карый да сызгырып куя.

Айсылу. Нәрсә, абый, бик нык ватылганмыни?

Шофер. Нык. Тик син кайгырма. Бәясен түләсәң, эшләрбез.

Айсылу. Кирәкнең кыйммәте юк, диләр бит. Түләрмен.

Шофер. Акыллы кыз икәнең күренеп тора. Ләкин, кызыкай, минем бәягә ризалашырсыңмы икән?

Айсылу. Күпме сорыйсыз?

Шофер. Күп түгел. Миңа акча кирәкми. Менә монда урманга 10–15 минутка минем белән кереп чыксаң, машинаң да эшләп китәр, үзеңә дә җиңелрәк булыр. Йә, килештекме?

Айсылу. Оятсыз!

Шофер. Нәрсә син недотрога булып кыланасың? Хәзер 13–15 яшьлекләр юлга чыгып торалар. Аларга әллә машинада йөрү кирәкме? Юк, җанкисәгем, аларга бүтән «машина» кирәк.

Шофер авызын ерып Айсылу каршысында басып тора. Кыз аның

яңагына чабып җибәрә.

Айсылу. Кабахәт! Җирбит! Оятсыз!

Шофер. Алайса, оятыңны учмарлап юлда кал инде.

«КамАЗ» кызны зәңгәр төтенгә күмеп китеп бара. Айсылу гарьлектән бәреп чыккан күз яшьләрен кул аркасы белән генә сыпырып төшерә. Хәзер инде ул үткәнсүткән машиналарга кул күтәрми. Машинасының «аварийный» утларын кабызып куя да юл читенә барып утыра. Күп тә үтми, Айсылу машинасы артына «джип» килеп туктый. Аның эчендә ике тән сакчысы белән Гәрәй утыра. Шофер кырыендагы уң як утыргычта кырык биш яшьләр тирәсендәге пөхтә киенгән, ягымлы йөзле Гәрәй машина туктауга сикереп төшә. Төрле хәрәкәтләр ясап тәннәрен язгалап ала.

Гәрәй. Нәрсә, үскәнем, аргамагың киреләнәме әллә?

Айсылу *(теләр-теләмәс)*. Әйе.

Гәрәй. Бер дә борчылма, үскәнем, минем егетләр җайлап бирер машинаңны.

Айсылу *(ирония белән)*. Әле генә берәү җайлап бирмәкче булган иде...

Гәрәй. Шуннан?

Айсылу. Бәяне бик зурдан каермакчы булды.

Гәрәй. Ничек? Юлда бәлагә юлыккан кыз баладан акча сорадымы?
Айсылу. Сез нәрсә? Айдан төштегезме әллә? Ир-ат хатын-кыз күрсә, иң беренче нәрсә сорый?
Гәрәй. Белмим шул. Исемендер. Чибәр кыз белән танышырга теләгәндер.
Айсылу. Әйе, урман эченә алып кереп «танышмакчы» иде. Яңагына берне сылагач тиз тайды үзе.
Гәрәй. Аһ, кабахәт!
Айсылу. Сезгә дә шундый түләү кирәк булса, вакытыгызны әрәм итмәгез.

Гәрәй Айсылуның сүзләренә бераз үпкәләсә дә, кызга аны-моны әйтми. Үз машинасы янына килә.

Гәрәй. Егетләр, сезнең ярдәм кирәк менә бу чибәр туташка. Карагыз машинасын. Әгәр рәтләрлек булмаса, эвакуатор чакыртып автосервиска илтегез.
Егетләрнең берсе. Була ул, Гәрәй Мингалиевич.
Икенче егет. Гәрәй Мингалиевич, әгәр без монда тоткарлансак, акционерлар җыелышына сезне кайтарып өлгерә алырбызмы соң?
Гәрәй. Сез эшкә тотыныгыз. Өлгерү-өлгермәү минем кайгы.

Егетләр Айсылуның машинасында казына башлыйлар. Гәрәй кыз янына чүгәли. Шунда ул аны танып ала һәм шатлыктан кычкырып җибәрә.

Гәрәй. Менә ичмасам очрашу бу!
Айсылу. Сез, абый, мине кем беләндер бутыйсыз, ахры.
Гәрәй. Юк, бутамыйм. Сез бит безнең яраткан футболчыбыз Акбулат кызы. Мин сезне подиумнарда еш күргәнем бар. Исемегез Айсылу бит әле?
Айсылу. Әйе. Тик хәзер сезнең яраткан футболчыгыз Акбулат белән теннисистка Ләйсән чит илдә инде.
Гәрәй. Беләм, беләм. Ялгышмасам, Австралиягә китте бугай алар.
Айсылу. Ялгышмыйсыз. Әни дә, эти дә Австралиядә. *(Сагыш белән.)* Очты алар, океаннар аша очты.
Гәрәй. Ә сез?
Айсылу. Бераз мая туплап, анда гражданлык алып, өйләр салып җибәргәч, мине дә үз яннарына алмакчылар. Баерга күп калмаган бугай инде. 10 ел да үтмәс, кайтып төшәрләр. Алтын тутырылган капчыкларын асып.
Гәрәй. Чит җирләрдә тамыр җәю җиңел түгелдер. Син аларга рәнҗү саклама, балакай. Дөньялар бик буталды бит. Үзебезнең милләттән менә дигән спортчылар үстерәсе урынга, аларны чит илдән сатып алабыз. Ә бит Акбулат бик әйбәт тренер була алыр иде.
Айсылу. Әти-әниләргә рәнҗемим мин. Алтынны бакырдан аера алмаган җитәкчеләргә шаккатам.
Гәрәй. Сезнең күңелегездә ни барын күзләрегез әйтеп тора.
Айсылу. Сез берәр психологмы әллә?
Гәрәй. Каян килеп психолог булыйм ди мин. Просто без күп вакыт кешегә кеше итеп карый белмибез. Күңел тәрәзәләребез тимер капкачлы.
Айсылу. Юк, абый, сез психолог булмасагыз да, простой кеше түгел.
Гәрәй. Миңа Гәрәй абый яки Гәрәй Мингалиевич дип дәшә аласыз. Менә визиткам.

Айсылу Гәрәй биргән визиткага күз төшереп ала да: «О-һо!» — дип куя. Шунда болар янына кызның машинасында казынучы егетләрнең берсе килә.

Егет. Гәрәй Мингалиевич, бу туташның машинасын автосервиска илтми булмас. Эвакуатор чакырттык.
Гәрәй. Алайса, бу эшне сезгә тапшырам, егетләр, барыгыз. Үземнең машинага үземә утырырга туры килер. Әгәр, чибәр туташ, миңа ышанасыз икән, рәхим итегез. Өегезгә илтеп куярмын.

Кызның күзләрендә икеләнү билгеләре чагылып уза. Гәрәй ул карашны бик тиз тотып ала.

Гәрәй. Күңелегезгә авыр алмагыз, Айсылу туташ. Әгәр мин дөрес аңлаган булсам, сезнең күңелегездә кешеләргә ышанмау, бар нәрсәгә шикләнеп карау ташы ята. Ничектер бу ташны алып ташлыйсы иде бит.
Айсылу. Ярый алайса, ул ташны кубара башлап карыйк. Утырам мин сезнең машинага.

Гәрәйнең егетләре, машина ишеген ачып, Айсылу утырганны көтәләр. Кыз үз машинасыннан сумкасын ала да җәһәт кенә шофер ягындагы утыргычка менеп утыра. Кузгалып китәләр. Күпмедер вакыт сүзсез баралар.
Гәрәй. Бәлки, музыка җибәрергәдер?
Айсылу. Мөмкин булса, уйланып кына кайтыйк әле.
Гәрәй. Юлда уйланып йөрергә мин дә яратам. Шәһәргә кайтуга эш бөтереп ала.

Гәрәй машинасын әкрен генә алып кайта. Юлдан читтәрәк урман ачыклыгында зәңгәр чәчәкләр күреп туктый да йөгереп чәчәклеккә китә. Бу саз чәчәге люпиннар икән. Гәрәй аны учы тулганчы җыеп кызның алдына сала.

Айсылу. Рәхмәт, Гәрәй Мингалиевич. Чәчәкләрегез өчен түгел, игътибарыгыз өчен. Тик мин сезнең бүләгегезгә җавап итеп берни дә бирә алмыйм.

Гәрәй. Сез миңа әллә кайчан бик зур бүләк ясадыгыз инде.

Айсылу. Нинди бүләк?

Гәрәй. Мине сокландыруыгыз бүләк түгелмени? Әйе, әйе, мин сезгә күптән сокланып йөрим. Сез подиумнарда катнашасы көнне көтеп интегеп бетәм. Сезнең җаныгыздан нindидер җылылык, яктылык бөркелеп тора. Матурлык бит ул үзе бик зур байлык.

Айсылу. Әллә сез шигырьләр дә язасызмы, Гәрәй Мингалиевич?

Гәрәй. Юк, язмыйм, ләкин укыштырам. Университетны бетергәч, берничә ел миңа мәктәп директоры булып эшләргә туры килде. Ә матурлыкка соклану чире тумыштан киләдер, мөгаен.

Айсылу. Мин матур түгел, Гәрәй Мингалиевич. Сез йомшак җәеп катыга утыртырга яратасыз, ахры.

Гәрәй. Ни өчендер бездә бер начар фикер йөри: әгәр кеше бай икән яки югары постта утыра икән, димәк, аның бәгыре таш, күңелендә кайнар хисләр урынына бозлар эленеп торырга тиеш. Сизеп торам, бу абзыйда хәзер нинди хис, нинди соклану булырга мөмкин, дип барасыз, әйеме?

Айсылу. Шулайрак.

Гәрәй. Дөресен әйтүегез өчен рәхмәт. Ә матурлыкка соклануга килгәндә, дөньяны күбрәк күргән саен ул хис көчәя генә бара. Чөнки кешедә чагыштырып карау, яхшы белән яманны үз күңелең аша үткәрү мөмкинлекләре арта. Яшь чакта йөрәк белән гашыйк буласың, ә өлкәнәя төшкәч акыл белән.

Айсылу. Кызык. Сез миңа гашыйк булдым дип әйтергә җыенмыйсыздыр ич.

Гәрәй. Юк. Гашыйк булган очракта да әйтмәс идем.

Айсылу. Нигә?

Гәрәй. Чөнки сез аңа барыбер ышанмас идегез.

Айсылу. Сез бик хәйләкәр кешегә охшагансыз. Минем салпы якка салам кыстырып «КамАЗ» шоферы чакырган җиргә чакырмакчы бугай.

Гәрәйнең бу сүзләргә бераз кәефе китә. Ләкин ул аны йөзенә чыгармаска тырыша. Әмма кыз машинаның кинәт тизлеге артуыннан ук бу абзыйның кәефе бозылганын сизә. Кызның күңелендә бу абзыйга карата ышанмау юк, киресенчә, ул аңарда ниндидер яшерен матурлык күрә. Ләкин Гәрәй Мингалиевич чынбарлыктагыдан кырысрак булып күренергә, үзенең хисләрен белгертмәскә тырыша.

Айсылу. Сез тиз үпкәлисез икән.

Гәрәй. Кем әйтте?

Айсылу. Әнә спидометрыгыз сезнең йөрәк тибеше көчәюен күрсәтә.

Гәрәй. Чибәр генә түгел, сизгер күңелле дә икәнсез.

Айсылу. Сез ир-атлар чибәр кызларның бөтенесен җилбәзәккә санап йөргәч тә...

Гәрәй көлеп куя. Машинасын әкренәйтә. Сиздермәскә тырышып Айсылуга карап куюлары аның кызга битараф түгеллеген күрсәтә. Бу карашларны кыз да тоеп бара. Аның әлеге акыллы әңгәмәдәше белән юлны озынайтасы килә. Гәрәй, әллә кызның уйларын сизеп, әллә күңел таләбенә буйсынып, уравыч юлга кереп китә.

Айсылу. Сез ничек уйлыйсыз, Гәрәй Мингалиевич, дөньяда кеше өчен иң мөһим нәрсә: байлыкмы, властьмы, мәхәббәтме, бәхетме? Шулар арасыннан сез кайсын сайлап алыр идегез?

Гәрәй. Кемгә нәрсә бит.

Айсылу. Сезгә байлыктыр дип уйлыйм.

Гәрәй. Байлык, әгәр гадел хезмәт белән килсә, бик кадерле. Ул кешеләр алдында синең дәрәҗәңне күтәрә. Менә мин, мәктәп директоры булып эшләгәндә, һәр җитәкчегә бүрегемне салып, билемне бөгеп керә идем. Чөнки мин мәктәп өчен йә буяу, йә такта, йә башка нәрсә сорап керәм. Ә сораганнарны кем ярата. Бирердәй нәрсәң булганда гына яраталар, хөрмәт итәләр.

Айсылу. Ә акыл белән генә хөрмәт иттереп булмыймы?

Гәрәй. Юк! Һәрхәлдә, безнең илдә юк. Акыллы икәнеңне күрсәтер өчен дә күпмедер байлык кирәк.

Айсылу. Димәк, сезнең өчен беренче урында байлык һәм дәрәҗә тора?

Гәрәй. Мин алай димәдем. Әйе, байлык та, дәрәҗә дә кирәк, ләкин минем өчен иң мөһиме ул түгел.

Айсылу. Нәрсә соң?

Гәрәй. Тормышта үз урыныңны табу.

Айсылу. Таптыгызмы соң?

Гәрәй. Табуын таптым, ләкин әлегә тормышым ут кертелмәгән йорт кебегрәк. Бөтен нәрсә бар, караңгы булгач күренми.

Айсылу. Ничек була инде ул алай?

Гәрәй. Мәхәббәт юк. Ә мәхәббәтсез тормыш — утсыз йорт ул. Мин тормышта мәхәббәт беренче

урынны алып торырга тиеш дип саныйм.

Айсылу. Байларга да мәхәббәт кирәкмени?

Гәрәй. Байларның да җаны бар бит. Әллә сезнеңчә алар җансыз кешеләрме?

Айсылу. Уйлаганым юк.

Гәрәй. Уйламый әйтәбез шул күп сүзне.

Айсылу. Хәтерегезне калдырсам, гафу итегез.

Гәрәй. Эш гафу итү-итмәүдә түгел. Сез минем тормышка карашымны сорадыгыз. Мин аңлатып бетермәдем. Байлык, дәрәҗә турында иде бит сүзебез. Байлык белән власть ул кием кебек: бүген сатып алып киясең, иртәгесен сине чишендерергә мөмкиннәр. Ә мәхәббәтне бары тик йөрәк белән генә умырып алып була.

Айсылу. Теләгән кеше мәхәббәтне дә урлый ала.

Гәрәй *(гаҗәпләнеп Айсылуга карый. Кызның күзләрендә рәшә булып ниндидер сагышмы, моңмы чагылганын күрә).* Сез акыллы кыз, ләкин фикерегезгә төшенеп җитмәдем: мәхәббәтне ничек урларга мөмкин соң?

Айсылу. Үзегез әйттегез бит: йөрәк белән умырып алып була, дидегез. Бәгырьсез кеше өчен моны эшләү берни тормый: мәхәббәтен үзенә ала да йөрәген җиргә салып таптый.

Гәрәй. Күрәсең, сезнең дә җаныгызда канлы яра ята.

Айсылу. Ярасыз җаннар бар микән соң бу дөньяда? Булган очракта да, аның ярасыз икәнен белсәләр, яраларга тырышалар.

Гәрәй. Ансы дөрес. Бәхетле кешеләрнең дошманнары күп була. Шуңа күрә күп очракта бәхетлеләр үзләренең бәхетләрен яшеребрәк сакларга тырышалар. Гомумән, акыллы кеше үз байлыгын сакларга тиеш. Байлыкны, бу очракта мәхәббәтне дип әйтсәк тә ярыйдыр, табуга караганда саклау авыррак.

Гәрәй Айсылуга күз салып ала. Кыз уйчан. Ул үзенең күңелендәге тирән яшеренгән вакыйгаларны актару белән мәшгуль. Гәрәй аны уйлар чытырманыннан тартып чыгарыр өчен әңгәмәне дәвам итә. Хәер,бу чибәр туташ белән сөйләшү аңа рәхәтлек кенә бирә.

Гәрәй. Күрәм, сезне ниндидер уйлар борчый.

Айсылу. Мин ир-егетләрнең берсенә дә ышанмый башладым. Сез бик белдекле булып сүздән ятьмә корып барасыз түгелме икән?

Гәрәй. Моны ничек аңларга?

Айсылу. Әнә бит егетләрегезгә минем машинаны төзәттереп китерергә куштыгыз. Мин ышанам, алар аны төзәтеп китерерләр.

Гәрәй. Ә нәрсәгә ышанмыйсыз?

Айсылу. Моның болай мәрхәмәт йөзеннән генә эшләнүенә ышанмыйм. Артында нидер ятмагае дип шикләнәм.

Гәрәй. Мәсәлән?

Айсылу. Мәсәлән, моны бер кулга төшереп булмасмы дигән уегыз маңгаегызга язылган.

Гәрәй. Үзегез әйтмешли, сез дә психолог икән. Минем сезгә, чибәр туташ, байтактан бирле күзем төшеп йөри. Ләкин бер нәрсәдә ялгыштыгыз: кулга төшерү ниятем юк. Кулга алтын-көмешләр, әллә нинди байлыклар төшерергә мөмкин. Ләкин...

Айсылу. Нәрсә «ләкин»?

Гәрәй. Сез бит алтын-көмеш түгел.

Айсылу. Бакырмыни?

Гәрәй. Кешене бәяли торган үлчәүләр юк.

Айсылу. Ник булмасын, бар.

Гәрәй. Нәрсә соң ул?

Айсылу. Кешенең эше аның кыйммәтен бәяли алмыймыни?

Гәрәй. Аладыр, ләкин тулаем түгел. Һәр кеше — үзе бер дөнья. Ә дөньяны кем бизмәнгә салып караган.

Айсылу. Кызык. Сез акыллы, хәйләкәр һәм үзегезнең теләгегезгә ирешер өчен хәйләкәрлегегезне дә, акылыгызны да, тормыш тәҗрибәгезне дә эшкә җигәсез.

Гәрәй. Болай усалдырсыз дип уйламый идем. Тик мин үпкәләмим. Сез бу сүзләрне миңа түгел, үзегезнең күңелегезне рәнҗеткән кешегә адреслыйсыз.

Айсылу. Мине беркем дә рәнҗетмәде. Мин үзем теләсә кемне рәнҗетә алам.

Гәрәй. Юк инде, үскәнем, бездә дә күңел күзе бар. Сезнең яшьтә мәхәббәттә алданулар, янулар гадәти хәл.

Айсылу. Алай бик акыллы булгач, әйтегез, ни өчен алданабыз соң без?

Гәрәй. Мин мәхәббәт белгече түгел, үзем дә алданган кеше. Ләкин соравыгызга җавап биреп карыйм.

Барган уңайга машина юлның төзәтер өчен дип шакмаклап-шакмаклап казып куелган урынына килеп керә. Юлның кайбер урыннарында таратылмыйча каткан асфальт өемнәре бар. Шулар өстенә барып менмәс өчен ул машинасын әле уңга, әле сулга бора. Машина кинәт борылганда, кыз белән Гәрәйнең иңнәре иңгә тиеп киткәли. Гәрәй моны юри эшләми, ләкин үзеннән-үзе килеп туган бу ситуация аңарда ниндидер хис уятып җибәрә, һәм ул сүзен дәвам итә.

Гәрәй. Мәхәббәттә ни өчен алданабызмы? Без бит, Айсылу туташ, үз күңелебездә яраткан кешебезнең моделен тудырабыз. Аны иң шәп сыйфатлар белән шыплап тутырабыз: ул матур да, батыр да, акыллы да, эшлекле дә, ярата белүче дә була. Шушы сыйфатларның берәрсенә ия булган кешене очратсак, аның без ясаган модельдәге башка сыйфатлары үзеннән-үзе булырга тиеш дип уйлыйбыз... һәм гашыйк булабыз. Якынрак танышып киткәч, безнең идеалыбыз моторсыз машина булып чыга. Әйе, әйе, тәгәрмәче, кузовы өр-яңа, матур, ләкин двигателе юк. Машинабыз кабынмый.

Айсылу. Двигателе дип кешенең кай җирен атыйсыз инде сез?

Гәрәй. Әйтик, йөрәген. Ләкин бу йөрәк кенә дә булмаска мөмкин. Кешенең юләрлеге йөзенә чыкса да, ялкаулыгы, кирелеге, саранлыгы яки башка шундый сыйфатлары йөзенә чыкмый. Без аларны тормыш куйган киртәләргә килеп бәрелгәч кенә белә башлыйбыз. Шуңа безнең хыялларыбыз чәлпәрәмә килә. Мондый очракта безне оптимизм һәм яраткан эшебез коткара. Минемчә, мәхәббәт гаиләнең төп учагы булса да, тормышның тоткасы булырга тиеш түгел. Мәхәббәт булырга тиеш. Ләкин ул үзенә табындырмасын. Табыну хәленә җиткерә икән, аннан котылырга кирәк.

Айсылу. Сезнеңчә, мәхәббәт берничәмени?

Гәрәй. Юк, мәхәббәт бер. Ләкин яраткан кешеләр берәү генә булмаска мөмкин.

Айсылу. Монсын ничек аңларга тагын?

Гәрәй. Бая әйткәнемчә, үз моделебезгә туры килә торган кеше эзләү дип. Эзли-эзли, ялгыша-ялгыша гына без идеалдагы моделебезгә якынлашабыз.

Айсылу. Сез андый акыллы булгач, идеал моделегезне тапкансыздыр дип уйлыйм.

Гәрәй. Тапкан кебек идем дә. Ләкин...

Айсылу. Ләкин ялгыштым, хәзер аерылыштым, дияргә уйлыйсызмы?

Гәрәй. Нигә алай дисез?

Айсылу. Ир-ат хатын-кыз күрсә, йә өйләнмәгән, йә аерылган, яки яратышып тормавы турында сайрый. Шулай итеп үзен жәлләтергә тели.

Гәрәй. Юк, үскәнем, мин үземне жәлләтергә теләмим. Әгәр кем дә булса мине ярата икән, бөтен кимчелегем белән яратсын. Әллә, сезнеңчә, мин ярату яшеннән чыкканмы инде?

Айсылу. Юк, ярату яшеннән чыкмаган гына түгел, нәкъ шул яшькә килеп кенә кергәнсез әле сез. Хәзерге кызлар үзләреннән өлкәнрәкләрне сайлый.

Гәрәй. Шулаймыни?

Айсылу. Шулай шул.

Гәрәй. Бәлки, аңлатып та бирерсез. Без бит хатын-кызларның логикасын белеп бетермибез.

Айсылу. Логика монда бик гади: чит ил киноларындагы матур тормышны күрәбез. Ә егерме-егерме ике яшьтәге егет әле тормышка җиңел карый. Яшәү өчен, бигрәк тә өйләнер өчен, аның бернәрсәсе дә юк. Бу безнең илдә бигрәк тә шулай. Ата-анадан калырлык мирас юк. Бер бүлмәле квартир өчен дә сугышып бетәләр. Ә кызлар, үзегез беләсез, егерме өчкә җитә башласа, үзләрен карт кызга саный. Ә инде егерме биштән дә узса, ул үз яшьтәшләренә чыга алмый. Чыкса да, фатирлы, дәрәҗәле, бай кешегә чыгарга тырышачак.

Гәрәй. Сезнеңчә, бу исәп-хисапка корылган никах була инде?

Айсылу. Тормыш корганда исәп-хисапсыз гына булмыйдыр шул.

Гәрәй. Сезнеңчә, мәхәббәт тә исәп-хисапмы?

Айсылу. Ә нигә аптырадыгыз аңа? Бер-берләрен өзелеп яратышкан кешеләр дә нәрсәгәдер исәп тота, минемчә.

Гәрәй. Мәсәлән?

Айсылу. Мәсәлән, кыз үзенә таяныч, тормыш алып барырлык яр эзли. Ә егеткә кызның назы, иренең күзләренә генә карап торуы кирәк. Тора-бара бер-берсен: кыз — егетне, егет кызны үзенең шәхси милке итеп саный башлый. Аның егете беркемгә дә карамасын, яки аның кызы ялгыш та беркемгә елмаймасын.

Гәрәй. Сезнең фикерләрне кире кагу кыен. Дөрестән дә, мәхәббәттә эгоизм өстенлек итә. Ләкин бит әле дөньяда альтруистлар да бар, алар ярата белмиләрмени?

Айсылу. Беләләрдер, ләкин альтруизмның үзендә дә эгоизм чагылышлары юкмыни? Әйтик, жанытәне белән башкалар өчен тырышып йөргән кеше бүтәннәргә яхшылык эшләүдән тәм тапмыймыни? Дөрес, альтруистлар байлыкка омтылмый. Ләкин бит кешене олы итүче нәрсә — рухи байлык. Альтруистларда эгоизм тирәндәрәк ята, бары шул гына.

Гәрәй. Сезнең логика шактый тирән катламнарны сөрә. Сезнең белән бик озак бәхәсләшергә була. Әйтик, берәү кемнедер жәлләп соңгы телем икмәген бирә.

Айсылу. Һәм үзе ач кала, әйеме?

Гәрәй. Әйе.

Айсылу. Бу дураклык була. Бары шул. Сез килешмәгез, бәхәсләшегез. Сез бит минем күңелне төшермәс өчен генә сүзләремә каршы килмисез. Атаклы бизнесмен, миллионнар белән эш йөртүче кешенең фикерләре иске «шестерка»да йөрүче ярлы бер кызның фикерләре белән бертөсле була алмый.

Гәрәй. Ансы дөрес. Дөньяга һәркемнең үз карашы, үз фикере булырга тиеш. Ләкин күңелендә иманы булганнарны байлык кына боза алмый.

Айсылу *(кайнарланып каршы төшә)*. Юк, юк, тагын бер кат юк! Байлык булган җирдә власть була. Ә байлык белән власть икесе бергә килеп кушылгач, күңелдәге фәрештә урынын Иблис биләп ала.

Гәрәй. Сез шундый усал дамыни әле?

Айсылу. Койрыгына бассаң, юаш мәче дә тешли.

Гәрәй. Димәк, мин сезнең авырткан җирегезгә кагылдым? *(Пауза.)* Бәлки, күңелегезне бушатырсыз?

Айсылу. Бәлки, ләкин әле түгел. Мөмкин булса, машинагызны туктатыгыз әле. Озак йөрүдән башым әйләнә башлады.

Гәрәй машинасын урман ягына таба бора. Юл аларны бик матур каенлыкка китереп чыгара.

Гәрәй. Шушында туктасак, ничегрәк булыр?

Айсылу. Матур урын.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гәрәй машинасын кечерәк кенә аланга туктата. Икесе дә машинадан төшәләр. Сүзсез генә табигать хозурында йөриләр. Шул вакыт болардан бераз читкәрәк ике мотоцикл килеп туктый. Һәрберсендә бер кыз белән бер егет. Алар кычкырып көләләр, сүгенәләр. Егетләр кызларның теләсә кайсы җирен тоталар. Кызлар берничди каршылык күрсәтми. Киресенчә, алар көлә-көлә чишенә башлыйлар. Гәрәй түзми, алар янына китә. Кызларның берсе шунда Гәрәйне күреп ала.

Чырылдап кычкырып җибәрә.

Беренче кыз. Әй, егетләр, безнең биләмәбезгә кемнәрдер керергә батырчылык иткән.

Кызның тавышына башкалар да игътибар итә. Дүртәүләп Гәрәйгә таба килә башлыйлар. Егетләрнең берсе төп кебек таза, икенчесе киртәдәй озын.

Кыска егет. Нәрсә, картлач, әҗәлеңне эзләп килдеңме?

Гәрәй. Сопляк!

Озын егет. Теле озын икән моның, әллә кисеп алып кырмыскалар оясына ыргытабызмы? *(Кесәсеннән пычак чыгара.)* Мин өчкә кадәр санаганчы моннан эзеңне себерәсеңме, әллә...

Гәрәй. Әллә?

Шул вакыт Гәрәй янына Айсылу килә. Кызны күргәч, барсының да игътибары аңа юнәлә.

Айсылу. Бәйләнмәгез шуларга, Гәрәй Мингалиевич. Китик моннан.

Яшьләр боларның каршысына килеп басалар.

Кыска егет. Юк шул, хәзер моннан тиз генә ычкына алмассыз.

Озын егет *(кызларга)*. Йә, кызлар, нишләтәбез боларны, сез ни әйтсәгез, шул булыр.

Беренче кыз. Кызы чибәр күренә, пробасын алыгыз.

Кыска егет. Браво, браво! Пробасын алырга. Башта мин!

Озын егет. Нигә син? Мин башлыйм.

Кыска егет. Юк инде, башта мин. *(Чалбарын сала башлый.)*

Озын егет. Юк, үзем. *(Ул да чалбарын сала. Аннары Айсылуга кычкыра.)* Нәрсә карап каттың, чишенә башла.

Беренче кыз. Сез аны аерым-аерым түгел, икегез берьюлы маташтырыгыз.

Икенче кыз. Картлач карап торсын, авызыннан селәгәен агызып. Аны әнә теге каенга бәйләп куегыз.

Егетләр Айсылу янына килеп басалар.

Кыска егет. Үзең чишенәсеңме, әллә ярдәм итешикме?

Айсылуның йөзенә курку йөгерә, ул Гәрәйгә карый. Ә Гәрәй юлбарыс җитезлегендә Айсылу янына килә һәм Айсылуга үрелеп маташучы егетнең аяк астына тондыра. Егет берничә метр читкә барып төшә.

Гәрәй. Әгәр берәрегез кызга тырнак белән генә кагылса яки яман сүз әйтсә, авызларыгызга

кырмыска тутырып, мәңге ачылмаслык итеп бәйләп җибәрәчәкмен.

Ул, аяк астындагы кырмыска оясына иелеп, ике кулына да эре сары кырмыскалар ала һәм үзләренә таба ажгырып килүче егетләрнең күзенә сибә. Тегеләр күзләрен угалап туктап калалар. Әмма шул арада кызларның берсе җирдә аунап яткан каен ботагын күтәреп Гәрәйнең арт чүмеченә кундырмакчы була. Гәрәй әйтерсең арты белән күрә, кыз күсәге белән селтәнүгә ул читкә тайпыла һәм аның күсәген тартып ала.

Гәрәй. Йә, кайсыгызның менә бу күсәкне татып карыйсы килә?

Ул арада егетләр күзләрен сөртеп өлгерә. Кыска егет үзенең өстендәге күлмәген умырып ыргыта.

Кыска егет. Падла буду, әгәр шушы паразиттан барыбызның да күтен ялатмасам.

Ул да җирдән бер күсәк алып Гәрәйгә ыргыла. Гәрәй түш кесәсеннән пистолет тартып чыгара да шартлатып атып җибәрә. Күсәк тоткан егет егыла. Калганнары баскан урыннарында катып кала. Кызларның берсе чәрелдәп кычкырып җибәрә.

Беренче кыз. Милиция! Үтерәләр!

Гәрәй аны күтәреп ала да кырмыска оясына утырта.

Гәрәй. Кузгаласы булма!

Озын егет белән икенче кыз калтырап басып торалар. Гәрәй үз машинасыннан канистр белән су алып килә дә җирдә егылып яткан егетнең өстенә сибә.

Гәрәй. Тор, тор, үлгәнгә сабышып ятма! *(Егетнең якасыннан тартып торгыза. Ул аңа газ пистолетыннан аткан була.)* Ә хәзер немедленно моннан таегыз. Юкса менә монда икенче төрле пистолет та бар.

Ул кесәсеннән икенче пистолет ала һәм бер агачның нечкә генә коры ботагына ата. Ботак шартлап сынып төшә. Яшьләр, моның белән шаяру куркыныч икәнен аңлап, тизрәк таю ягын карыйлар. Ераккарак
киткәч, кыска егет туктап Гәрәйгә кычкыра.

Кыска егет. Казан урамында очратып, башыңны кулыңа тоттырып җибәрәчәкбез. Шуны истә тот.

Әшәке итеп сүгенә һәм Гәрәйләр ягына карап төкерә.
Яшьләр китеп баргач, Гәрәй белән Айсылу шактый вакыт сүзсез торалар. Икесенең дә кәефләре бозыла.

Айсылу. Сез куркыныч кеше икәнсез, Гәрәй Мингалиевич.

Гәрәй. Әйе. Кеше — иң куркыныч җанвар ул. Чөнки кешегә Алла акыл биргән. Акыл белән кешеләр бер-берсен үтерү өчен корал ясыйлар. Хайваннарда бары инстинкт кына. Аларда нәфес юк, көнчелек юк. Алар тамак туйдыру өчен көрәшә. Ә бүгенге хәлгә килгәндә, бу кемнедер куркыту түгел, ә үз-үзеңне саклау чарасы. Шунда әз генә югалып калсам, алар сезне мәсхәрә итеп ташлаячаклар иде. Кеше белән ерткыч хайваннарның тагын бер аермасы шунда: җанварлар бер-берсен мәсхәрәләмиләр. Ә бу егет аламаларын бераз шүрләтеп алу кирәк иде. Бәлки, акыл керер. Акыл кермәсә, һич югы, уйланырлар. Күп вакыт без андыйларны битарафлыгыбыз яки куркаклыгыбыз белән азындырабыз. Бер малай-шалай гына килеп бәйләнсә дә, моның артында кемдер торадыр, дип калтырап төшәбез. Ә аларның күбесе куркаклар. Алар безнең шушы психологияне яхшы белә.

Айсылу. Әгәр шунда берәрсе килеп миңа ябышса, чынлап та атар идегезме?

Гәрәй. Болар әле көчекләр генә. Мондыйларны бер өркетеп алу да җитә.

Гәрәйнең кесә телефоны шылтырый. Ул аны алып сөйләшә башлый.

Гәрәй. Тыңлыйм. Фәттәховмы? Нишләргә уйлыйлар соң? Бишкә кадәр? Ярый, ярый, совет утырышын бишкә күчерүләре әйбәт булган. Йә, ярый, рәхмәт яхшы хәбәрең өчен. Теге кызның «шестерка»сын сервиска илттегезме? Ярый, әйбәт булган. Хәзергә хуш!

Телефонын кесәсенә салып куя. Аның күңеле күтәрелеп китә.

Айсылу. Күңелле хәбәр әйттеләр, ахры.

Гәрәй. Әйе. Утырыш бер сәгать соңрак башланачак. Димәк, безнең әле сезнең белән табигать хозурында тагын бераз йөрергә мөмкинчелегебез бар.

Айсылу. Юк, Гәрәй Мингалиевич, миңа кайтырга вакыт. Юкса ападан эләгәчәк.

Гәрәй. Апагызда торасызмыни?

Айсылу. Әтиләр квартираны сатып Австралиягә киткәч, Рәйсә апаларда калдым.

Гәрәй. Әтиләрегезнең Австралиягә киткәнен ишеткән идем. Монда да бик хөрмәтле кеше иде бит Акбулат. Футболда төп бомбардир.

Айсылу. Син инде картайдың, диделәр дә артына типтеләр.

Гәрәй. Сез арттырасыз, Айсылу туташ. Акбулат кебек уенчылар картаймый. Әнә Мәскәү «Спартагы»нда уйнаучы Галимҗан Хөсәенов ничә яшькә кадәр уйнады.

Айсылу. Уйнавын уйнады да, кайнарлыгы сүрелә башлауга, аңарга да, үз ягыңны үзең кара, диделәр.

Гәрәй. Ансы шулай. Безнең илгә талантлы кешеләр кирәкми. Сезнең әтиегезне үзебезнең командага тренер итеп калдырырга була иде.

Айсылу. Әти үзе дә шулайрак уйлап йөри иде. Ләкин югарыдан күрсәтмә булган, күрәсең, тренер итеп Мәскәүдән исеме дә таныш булмаган берәүне китереп куйдылар. Әти безнең кайнар кеше, Австралиядән чакыру килеп төшкәч, ике уйлап тормастан китте дә барды. Аннары әнине чакырды. Эшләре бераз җайлангач, мине дә чакыртачаклар. Чит ил паспорты артыннан йөри башладым инде.

Гәрәй. Димәк, океан артына очарга җыенасыз?

Айсылу. Исәп шулайрак.

Гәрәй көрсенеп куя. Алар ике яшүсмер кебек гамьсез күренергә тырышып каеннар арасыннан атлыйлар. Сүз үзеннән-үзе икенче юнәлеш ала.

Гәрәй. Бу каеннарның бер гөнаһлары да юктыр инде, шуңа ап-аклардыр.

Айсылу. Кайрыларында тирән кара эзләр бар бит. Бәлки, алар уртаклашмаган мәхәббәт яраларыдыр.

Гәрәй. Каеннар да ярата белә микән?

Айсылу. Ярата белмәсәләр, үрчемәсләр иде. Җиргә һәрбер яңа тереклек иясен мәхәббәт тудыра бит. Каеннарны мин бик яратам. Мөмкинлегем булса, үз бакчама каен утыртыр идем.

Гәрәй. Әйе, каеннар матур, аларны яратмый мөмкин түгел. Тик бер гаҗәп нәрсә бар.

Айсылу. Нәрсә?

Гәрәй. Без каеннарны гел рәнҗетеп торабыз. Яз җитүгә, аларның нәфис ботакларын сындырып, мунча себеркесе ясыйбыз.

Айсылу. Әйе, тормышта гел шулай: яраткан кешеләребезне, хәтта яраткан гөлләребезне дә күбрәк җәберлибез.

Гәрәй. Әйе, гаҗәп парадокслар бар инде. Имәннәрне иң нык агачка саныйлар. Ә бит алар салкыннарга ныграк бирешә. Хәтерлисезме, бер салкын кышта бөтен имәннәр корыды. Ә нәфис каеннарыбыз калды.

Айсылу. Ирләр дә бит үзләрен дөньяның кендеге дип саныйлар. Башларына берәр авырлык төштеме, үзләрен югалталар. Әнә Германия белән кырык беренче елда кем җиңде дип беләсез? Хатын-кызлар җиңде ул сугышны.

Гәрәй. Ныклабрак уйлап карасаң, шулай шул. Хатын-кыз биш-алты баласын да ач-ялангач итмәде, игенен дә үстерде, йортын да тәртиптә тотты.

Айсылу. Без сезнең белән әллә нәрсәләргә кереп киттек.

Бераз уйланып йөриләр. Берсе бер якка, икенчесе икенче якка китә. Гәрәй челтерәп агып яткан бер чишмәгә юлыга. Ул Айсылуга кычкыра.

Гәрәй. Айсылу! Ай-сы-лу!

Айсылу. Әү!

Гәрәй. Эчәсегез килмиме? Менә бер чишмә таптым.

Айсылу *(шатланып)*. О-о, чишмә! Битләрне юып алсаң да зыян итмәс. Юл тузаны, көн кызуы, кайнар җил бит тиресен арыта. Дөнья судан яратылган, дип, бәлки, дөрес әйтәләрдер.

Икесе дә юыналар. Гәрәй йөгереп кенә машинасыннан ике сөлге алып килә. Сөлгесенең берсен Айсылуга бирә, икенчесе белән үзе сөртенә.

Гәрәй. Бүген минем бик бәхетле көнем.

Айсылу. Нәрсәдән чыгып әйтәсез?

Гәрәй. Менә сезне очраттым, инде килеп шундый шәп чишмә таптым. Ә бит хәзер чиста чишмәләр дә сирәгәя бара. Минемчә, бу саф чишмә язмышның бер ишарәсе.

Айсылу. Мин дә сезнең белән очрашуыма шатмын.

Гәрәй. Чынлапмы, Айсылу?

Айсылу. Чынлап. Сезнең күңелегез бай булырга охшый. Миңа соңгы вакытта куркак җанлы кешеләр генә очрый башлаган иде. Күп кенә әшәкелекләр куркаклыктан килә бит.

Гәрәй Айсылуның үзенә ышана башлавына чиксез куана. Аның шушы матур чишмә буенда озаклап йөрисе килә. Ләкин шул вакыт аның кесә телефоны шылтырый.

Гәрәй. Әйе, Камил Шәрипович, бу мин. Җыелыша башладылар? Ә дәүләт эшлеклеләреннән, аппараттан вәкилләр буламы? Простой гына җыелыш түгел бит. Первый зам? Оһо! Ә аппараттан? Ярый, ярый, әйбәт. Бая әйткәнчә, сәгать биштәме? Ярый, ярый.

Гәрәй сәгатенә карый. Ашыгырга кирәклекне аңлый һәм кызга бу фикерне әйтергә кыймый тора. Ләкин Айсылу аның ашыкканын төшенеп ала.

Айсылу. Кайтабыз, Гәрәй Мингалиевич. Минем аркада эшегезгә соңга калмагыз.
Гәрәй. И акыллым минем, бигрәк сизгер күңелле кыз сез. *(Айсылуның битеннән үбеп ала.)*

Йөгерә-атлый «джип» янына китәләр. Гәрәй яшьләрчә җитезлек белән машинага Айсылуны күтәреп утырта да үзе рульгә утыра. Машина ыргылып кузгала. Айсылу спидометрга күз сала, анда 180 км тизлекне күрсәтә. Машинаның кызу йөрүеннәнме, аның күңеле күтәрелеп китә.

Гәрәй. Сезне кая илтергә, Айсылу туташ?
Айсылу. Шәһәргә кергәч, трамвайга утырам инде мин.
Гәрәй. Әле минем егерме биш минут вакытым бар. Адресыгыз?
Айсылу. Пушкин урамы.
Гәрәй. Юллар бер яккарак икән. Димәк, тагын бер биш минут отарга мөмкинчелек бар.

Гәрәй зур кызулык белән Пушкин урамына килеп керә. Юлда торган постовойларга ул тәрәзә аша кул гына болгап китә. Айсылу яшәгән йорт янына килеп туктыйлар.

Гәрәй. Әгәр рөхсәт итсәгез, бер минутка гына сезгә кереп чыгар идем.
Айсылу. Рәхим итегез.

Өйгә керәләр. Ләкин керә-керүгә аларны Айсылуның апасы Рәйсә зарланып каршы ала.

Рәйсә. Сез ЖЭУданмы? Менә, күрәсезме, түшәм ярык, стеналардан штукатуркалар коела. Тәрәзәләр рәтләп ябылмый. Кайчан башлыйсыз инде ремонтны? Мин реабилитированный кеше баласы. Минем льготаларым бар. Казанның меңьеллыгына безнең йортларны сүтәрләрме әллә дип көткән идем, урам ягын буяштырдылар да киттеләр. Бездә һәрвакыт эштер-өштер инде.

Рәйсә льгота бирүче кәгазьләрен актара башлый. Кыз шул арада шыпырт кына Гәрәйне ишектән чыгарып җибәрмәкче була, ләкин Рәйсә моны күреп ала.

Рәйсә. Курыктыгызмы, качасызмы?

Гәрәйнең пинжәк чабуына барып ябыша. Әмма Айсылу аның кулын тота.

Айсылу. Ул ЖЭУдан түгел, апа, һәм бик ашыга. Җибәрегез аны.
Рәйсә. Барсы да ашыгалар шул алар. Менә мин дә ашыгам да, тыңлаучы гына юк. Ә син көне буе әллә кайда трай тибәсең.
Айсылу. Барыгыз, Гәрәй Мингалиевич, юкса соңарырсыз. Болай да сезне бик озак тоткарладым.
Гәрәй. Ярый, Айсылу туташ. Насыйп булса, бәлки, тагын очрашырбыз әле. Ә сез, апа, квартирагыз өчен борчылмагыз. Ремонтларлар. Әйбәт урында яшисез икән. Хушыгыз.
Рәйсә. Тел белән юарга сез барыгыз да оста. Эшкә килгәндә генә берегезнең дә кулыгызны пычратасы килми. Сталин заманнары булса, Мәскәүгә барып җиткән булыр идем инде, ә монда үз президентыңа керә алмыйсың. Бөтен нәрсәне байлар умырып бетерде дә безгә — реабилитированныйларга — кукиш калды.

Рәйсә өйдә ялгыз гына калганын да абайламый шактый озак сөйләнә. Айсылу Гәрәй Мингалиевичны озатырга чыгып китә.

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гәрәйләрнең коттеджы матурлап эшләнгән тимер койма белән әйләндереп алынган. Анда төрле җимеш агачлары үсә, ә күзне иң тартканы — бакчадагы гүзәл чәчәкләр. Караган саен алар карашны иркәләп торалар. Үткән-сүткән кешеләр ялгыш капкага яки коймага бәрелеп китсә, эт өрергә тотына. Этне үртәргә теләпме, бер малай капкага таяк белән суга. Чылбырдагы эт ыргылып-ыргылып өрергә тотына. Эт тавышын ишетеп, балконга Айсылу чыга. Ул озын буйлы, чибәр. Тәннәрен
язар өчен киерелә-сузыла. Ул әле йокыдан яңа торган.

Айсылу. Нигә өрәсең, Матуркай? Берәрсе үртәдеме үзеңне? *(Айсылу эт янына төшә. Башыннан сыйпый. Эт чиный, койрык болгап ялагайлана. Айсылу аңа иелгән арада, битен ялап ала.*) Чылбырыңнан ычкынасың килә инде синең, әйеме? Иреккә чыгасың? Әмма, Матуркай, бу дөньяда беркем дә тулы ирекле түгел. Ирек ул – чагыштырма төшенчә. Кечерәкләр зурракларга буйсына, зурраклар үзләреннән өстенрәкләргә. Урамга чыгарып җибәрсәм дә, син ирекле булмаячаксың. Урам шартлары сине үзенә буйсындырачак. *(Эт чылбырыннан тартылып куя.)* Менә мин сине хәзер ычкындырдым ди. Шуннан ни була? Син бит бөтен бакчаны таптап бетерәчәксең. Минем буйсынасым килми дисеңме? Әмма бит, Матурым, дәүләтләр дә үз халкын буйсындырыр өчен законнар чыгара. Менә шулай, Матурым, буйсынмый ярамый. Сиңа да, миңа да. Кемдер күбрәк буйсына, кемдер әзрәк. Бары шул гына.

Айсылу бакча буйлап китә. Чәчәкләрнең башларыннан сыйпый, кайберләрен иелеп иснәп-иснәп ала. Чәчәкләргә дәшә.

Айсылу. Гүзәлкәйләрем, иркә гөлләрем минем. *(Җырлый.)*

Әй гөлләр, гөлләр, гөлләр,
Ромашкалар, сиреньнәр,
Бакчабызның яме сез,
Күңелемнең җәе сез.
Яратам алларын да,
Яратам акларын да.
Ак чәчәккә әйләнәм
Бәхетле чакларымда.
Әй гөлләр, гөлләр, гөлләр,
Резедәләр, сөмбелләр,
Сез — җирнең мәхәббәте,
Сез — җирнең мәрхәмәте.
Әй гөлләр, гөлләр, гөлләр,
Кыңгыраулар, сиреньнәр,
Бакчабызның яме сез,
Күңелемнең җәе сез.

Сезнең карашыгыз гел күктә. *(Шаярып бармак янаган була. Үзе дә күккә карап ала. Ә анда офык читеннән кояш күтәрелеп килә.)* Әллә кояшка гашыйк булдыгыз инде? Көн бик кызу булырга охшый. Иртәдән үк кыздыра. Коенып алырга кирәктер, ахрысы.

Айсылу бассейн янына килеп чишенә. Үзенең калку күкрәкләрен, сылу гәүдәсен сыйпый.

Айсылу. Рәхмәт сиңа, Аллам, мине шундый матур итеп ясатканың өчен. Рәхмәт, Кояш, үзеңнең йомшак нурларың белән тәнемне назлаганың өчен. Рәхмәт, Дөнья, шундый киң һәм иркен булганың өчен. Рәхмәт, Язмыш, миңа мәрхәмәтле булганың өчен. Мондый бассейннарда коенып, ханбикәдәй яшәрмен дип уйламаган идем. Рәхмәт сиңа, Тормыш, сагыш баскычлары аша бәхет тауларына менгергәнең өчен.

Ул янә үзенең тәнен сыйпап ала да бассейнга чума. Пырхылдап йөзеп китә. Су эчендә ләззәтләнеп туйгач, баскыч буйлап өскә күтәрелә.

Айсылу коенып чыгып дөньяга һәм үзенә сокланып торган арада, боларның бакча коймалары артына бер машина килеп туктаганы ишетелә. Машина монтерлар йөртә торган икән. Тиздән күтәрчекнең түгәрәк мәйданчыгында бер егет күренә. Ул уртача буйлы, ләкин йөзгә чибәр. Иңендә инструментлар сумкасы. Югарыга күтәрелүгә үк, егетнең күзе бассейн янында басып торучы Айсылуга төшә.

Монтер. О-о, бу бакчада гөлләр патшабикәсе яши икән! Бәлки, гөлләрегезнең берәрсен миңа бүләк итәрсез?

Айсылу. Үзегезнең берәр кызга чәчәк бүләк иткәнегез бармы соң?

Монтер. Безнең кызлар чәчәкне сыерларына гына ашаталар.

Айсылу. Алайса, сөйгән кызларыгызның сыерларын чәчәк белән сыйлагыз.

Монтер. Авыл кызлары андый нечкәлекне аңламаслар шул.

Айсылу. Аңларлар. Аңлатырлык итеп илтерсез.

Монтер. Кочак беләнме, арба яки трактор беләнме?

Айсылу. Тупас кеше сез. Тупасларны кызлар яратмый.

Монтер. Сез яратсын өчен бассейныгызга төшеп аккошка әверелимме?

Айсылу. Мәшәкатьләнмәгез. Бөтенләйгә батып калуыгыз бар. Әгәр булдыра алсагыз, бөркеткә әйләнеп, урманнан куяннар аулагыз.

Монтер. Бөркеткә әверелсәм, үзегезне күтәреп китүдән курыкмыйсызмы?
Айсылу. Юк, чөнки минем үз бөркетем бар. Ул сезне бик тиз өзгәләп атар.
Монтер. Беләм. Сакчыларыгыз барын да беләм.
Айсылу. Бар шул.
Монтер. Сезне сак астында тоталар икән, димәк, сезгә ышанмыйлар.
Айсылу. Сүзләрегез белән килешә алмыйм.
Монтер. Нишләп?
Айсылу. Менә сез өегезне бикләми чыгып китәсезме?
Монтер. Нишләп мин аны бикләми чыгып китим? Анда бит минем бар булган әйберем.
Айсылу. Бәлки, мин дә кем өчендер бик кадерле байлыктыр. Нигә сакламасын ул үзенең кадерле байлыгын?!
Монтер. Оhо, үзегез турында сез бик югары фикердә икәнсез.
Айсылу. Без һәрберебез үзебез турында югары фикердә. Сез дә үзегезне егетләрнең первый сорты дип саныйсыздыр әле.
Монтер. Ә нигә санамаска? Мин бер сызгырсам, утыз тугыз кыз йөгереп киләчәк.
Айсылу. Сызгырып карагыз әле алайса, кайсы яклардан чабышып килерләр икән.
Монтер. Кичә генә тешне алдырганыем, башка вакытта сызгырып күрсәтермен инде.
Айсылу. Бик кирәк.
Монтер. Кирәк шул. Сезнең монда сөйләшер кешегез юк, шуңа күрә мине күргәч шатландыгыз.
Айсылу. И бичара. Үзегезнең пәри табагачы икәнлегегезне белмисезмени соң?
Монтер. Ә сез үзегезнең читлектәге кош икәнлегегезне беләсезме?
Айсылу. Мин оҗмах кошы.
Монтер. Оҗмах кошы! Оҗмах шулай төрле яктан коймалап алынамыни ул?
Айсылу. Бик мөмкин. Һәрнәрсәнең чиге булырга тиеш. Юкса тәмугка керергә тиешлеләр дә оҗмахка керергә мөмкин бит.
Монтер. Сезнең фикерләрегез шушы коймадан читкә чыга алмый, ахрысы. Ә бит койманың теге ягында да дөнья бар.
Айсылу. Миңа бу яктагысы күбрәк ошый.
Монтер. Ай-һай, ышанасы килми.
Айсылу. Килмәсә, ышанмагыз. Әмма ләкин сез әйткән, койманың теге ягындагы ирекле дөньяны күргән бар минем. Теләгән сүзеңне әйтергә авызыңнан телеңне чыгарырга да курыккан ирек минем бакчамдагы бер чәчәккә дә тормый. Мескеннәрнең, хәерчеләрнең, бомжларның, эшсезләрнең, ачларның иреге була аламы?
Монтер. Дөньяда алар гына яшәми бит.
Айсылу. Яшәми, ләкин һәркемнең шундый хәлгә төшүе бар.
Монтер. Сезнеке юкмы?
Айсылу. Юк.
Монтер. Болай дип ничек ышанып әйтә аласыз?
Айсылу. Мәхәббәтебезгә ышанып әйтә алам.
Монтер. Мәхәббәткә ышанып бетәргә ярамый. Мәхәббәт ул — күзне каплаучы алсу пәрдә генә. Ул пәрдәне җил күтәреп китсә, күзләрегез дөньяның чынбарлыгын күрә башлар.
Айсылу. Башымны катырмагыз әле. Дөньяның төрле ягын күргән бар, шөкер.
Монтер. Ярый алайса, ярый. Сүзем бетте.

Монтер багана башындагы лампочканы алыштыра. Эш бетүгә, егет янына ике кара шәүлә килеп баса. Ул аларның бу өйне саклаучылар икәнен аңлый.
Кыз бассейн читендәге басмага басып уйлана. Бер генә минутка эти-әнисе чагылып китә. Алар иркен генә бер йортта. Өйдә әнисе тузан суырта. Әтисе кайтып керә. Ул спорт костюмыннан. Хатыны аның кайтканын күрми.

Ир. Ташлап тор әле шул нәмәрсәңне. Күпме тырышсаң да, барыбер бөтен Австралия тузанын җыештырып бетерә алмассың. *(Розеткадан шнурны тартып ала.)*
Хатын. Нәрсә, әтисе, эшеңдә берәр күңелсез хәл булмагандыр бит?
Ир. Эштә Аллага шөкер. Монда тырышкан кешене күрә беләләр ансы. Менә әйткән иде диярсең, бер ел да үтмәс, команданы беренче лигага чыгарачакмын. Шул чагында без бөтенләй башкача яши башлаячакбыз.
Хатын. Ә нәрсәгә кәефсезләнеп кайттың соң?
Ир. Бүген Казаннан апа шылтыраткан иде. Айсылуыбыз бер карт бүрегә кияүгә чыкты, ди.
Хатын. Әстәгъфирулла! Нинди карт бүре икән ул? Аңлатыбрак әйтмәдеме?
Ир. Аңлатты. Безнең апаны беләсең бит, күпертергә ярата.
Хатын. Йә, йә, шуннан?
Ир. Имеш, Айсылу байлыгына кызыгып үзеннән ике тапкыр олы кешегә кияүгә чыккан. Кияве

моны сак астында гына тота икән. Ике ягында да мылтыклы кешеләр йөри, ди.

Хатын. Ай Аллам. Кызыбыз шундый юләрлек эшләде микәнни? Бәлки, Рәйсә апа бераз арттырадыр. Аның бит андый гадәте бар.

Ир. Арттырырга яратмаган хатын-кыз бармыни? Без киткәндә Айсылуны үзләрендә калдыруыбызны белгәч, йөзләре күгәргән иде. Бәлки, шул ачудандыр.

Хатын *(җанланып)*. Әлбәттә, шул ачудан. Югыйсә Айсылуны бер дә күпсенерлек түгел әле аңа. Айсылу хезмәт хакын әйбәт ала. Рәйсә апа да үзенең бөтен пенсиясен оек кунычына гына тутырып бара. Мескенләнүдән тәм таба ул.

Ир. Ничек кенә булмасын, Айсылуның кияүгә чыгуы дөрес. Мин үзебезнең элекке команда капитаны Рамайга шылтыраткан идем. Ул да раслады.

Хатын. Рамай ничегрәк әйтте соң бу хәбәрне?

Ир. Айсылуга бәхет ишелеп төште, ди. Ул, ди, Казанның атаклы бизнесмены Гәрәй Мингалиевичка кияүгә чыкты, ди.

Хатын. Гәрәй Мингалиевичка?

Ир. Әйе, Гәрәй Мингалиевичка.

Хатын. Соң, без беләбез бит аны. Совет чорында мәктәп директоры булып эшләде. Намуслы кеше.

Ир. Ярлы чакта, мәктәп директоры чакта, бәлки, намуслы булгандыр. Мәктәптә урлар нәрсә юк бит анда.

Хатын. Син нәрсә, әтисе, Гәрәй Мингалиевич урлашып баегандыр дисеңме?

Ир. Россиядә урлашмаган кеше байый аламы?

Хатын. Алай кырт кисмик әле. Җае чыккандыр. Әкренләп намуслы рәвештә өскә үрмәләгәндер.

Ир. Гадел эштә баеса да, баегач кешенең психологиясе үзгәрә. Андыйлар үзләрен җирнең кендеге дип саныйлар. Байлык эгоизмны үстереп җибәрә.

Хатын. Ныклап белмәгән кешегә әллә нинди гаепләр такмыйк әле. Тынычланыйк. Хәзер кызларның күбесе үзеннән өлкән кешегә чыга. Бу безнең илдә гадәти хәл. Өлкән дә булып, ярлы да булса, нишләр идең?

Ир. Хатын-кызның бөтен уе байлык инде.

Хатын. Ирләрнеке дә шул түгелмени? Монда Австралиягә безне кешечә яшәү теләге алып килмәдемени?

Өйдә беразга тынлык урнаша. Ерактан музыка тавышы ишетелә. Ир идән буйлап йөри һәм шул вакыт болар каршысына Айсылу килеп баса.

Айсылу. Әтием, әнием! Мин сезне шундый сагындым! Шундый сагындым! *(Әти-әниләренең кочакларына ташлана.)*

Әтисе. Кызым! *(Башыннан сыйпый.)* Без дә сине бик сагындык.

Әнисе. Кызым, күз нурым! Анда синең ялгызыңны калдырдык та киттек. Безгә рәнҗемисеңме?

Айсылу. Әти-әниләргә рәнҗеп буламыни? Мин бит инде балигъ булган кыз. Югары белем алырга ярдәм иттегез. Гел-гел сезнең кочакта яшәп булмас бит.

Әтисе. Кызым, синең хакта төрле сүзләр йөри. Дөресме шулар?

Айсылу. Апа шылтыраткандыр инде, ул гайбәт таратырга ярата.

Әнисе. Гәрәй Мингалиевичка кияүгә чыгуың дөресме?

Айсылу. Дөрес.

Әнисе. И балам, байлыгына кызыккансыңдыр инде?

Айсылу. Әйе, байлыгына, ләкин сез уйлаган байлыкка түгел.

Әтисе. Ансы нинди байлык тагын?

Айсылу. Күңел байлыгы! Әйе, аның матди байлыгы да зур. Ләкин хатын-кызны олылый, кадерли белүе белән бай ул. Нинди генә хатын-кыз үзен кадерләгәнне, үзенә чын кеше итеп караган ирләрне яратмый.

Әнисе. Ансы шулай.

Айсылу. Һәр җан иясе гомере буе назга сусап яши. Наз тапмаган җаннар таштай ката.

Әнисе. Бәхетлеме соң син, кызым? Үзеңнән ике тапкыр өлкән кеше белән бәхетле була алуыңа ышанып җитәсе килми.

Айсылу. Бәхетне еллар белән дә, байлык белән дә үлчәп булмый, әни. Бәхет үлчәме — йөрәк. Ә йөрәгем миңа: «син бәхетле» ди.

Әтисе. Әгәр тормышыгыз барып чыкмаса, сине бер-ике елдан үзебезнең янга алдырабыз, кызым.

Айсылу. Ә сез үзегез монда бәхетлеме соң?

Әтисе. Без әниең белән бергә, кызым. Шатлыгын-кайгысын бергә күтәрәбез. Акча ягына килсәң дә, Аллага шөкер. Тырышкан кешенең кадерен беләләр, сәләтен ачарга мөмкинчелек бирәләр монда.

Айсылу *(әниләренең кулларыннан алып)*. Сез дә бәхетле, мин дә бәхетле. Барыбыз да бәхетле.

Баягы музыка яңгырый. Айсылу эти-энисе түгәрәгендә әйләнә дә юкка чыга. Ул бассейнның мәрмәр баскычында үзен күреп, айнып киткәндәй була. Теге монтер кызның суга карап уйланып торганын үзенчә аңлый.

Монтер. Үткәннәрегез өчен үкенәсезме әллә?

Айсылу сискәнеп китә.

Айсылу. Син һаман мондамыни әле?

Монтер. Һушыгызны югалтып суга тәгәрәп төшмәгәе бу дип күзәттем. Хушыгыз! Мине сагынсагыз, лампочкагызны бәреп ватыгыз да тагын чакыртыгыз. Без алай тәкәббер түгел, килербез. Алтын читлектән чыгасыгыз килсә, хәбәр бирерсез. Хуш, чибәркәй!

Айсылу. Бар, бар, алдыңнан артың хәерле.

Егет баскан кран мәйданчыгы әкрен-әкрен аска төшә башлый. Кыз бакчадан каткан балчык кисәге алып койманың теге ягына ыргыта.

Егет китүгә, теге ике әзмәвер дә юкка чыга. Алар шәүлә кебек гел тавышсыз гына йөриләр. Кыз үз-үзенә сөйләнә.

Айсылу. Менә син тычкан тәбесе кадәрле квартирада яшәп кара. Җитмәсә, ансы да үзеңнеке түгел, апаңныкы булганда. Нindирәк ирек турында сайрар идең икән. Ярый әле теге вакыт Гәрәй апаның фатирына ремонт ясатты. Юкса шул ремонт белән апам күпме колак итемне ашады. Бу Гәрәй Хозыр Ильяс кебек көтмәгәндә минем бәхетемә килеп чыккандыр, валлаһи. Мактанмый, шапырынмый, алдан вәгъдәләр бирми генә үз эшен эшли. Апаның квартирасын ЖЭУдан килеп ремонтладылар дисәк, ул Гәрәй эше икән. Шоферы ялгыш ычкындырмаган булса, белми дә йөрер идек. Минем «шестерка»ны да өр-яңа кебек иттергән. Хәзер мин аның белән нишлим инде? Сатарга җәл — этиләр истәлеге. Сатмасаң, череп кенә ята. Кызык, машина да кызлар кебек икән: озак саклаган саен бәяң төшә. *(Уйга кала.)*

Өйдән Сәрбиназ чыга.

Сәрбиназ. Кызым, Айсылу, әйдә, душта юынып ал да ашарга кер. Син яраткан бер әйбер пешердем. Телеңне йотарсың.

Айсылу. Ашыйсым килми әле, Сәрбиназ апа, нигәдер аппетитым качты.

Сәрбиназ. Кай тирәгәрәк качты икән соң ул? Әллә эзләшимме?

Айсылу. Нәрсәне?

Сәрбиназ. Соң, үзең бит, әппититем качты, дидең. Качканны табарга кирәк бит инде.

Айсылу. Бераз соңрак, Сәрбиназ апа, ярыймы?

Сәрбиназ. Әгәр хәзер Гәрәй Мингалиевич кайтып керсә?

Айсылу. Ашады, диярсең.

Сәрбиназ. Аллам сакласын, алдашаммы соң?!

Айсылу Сәрбиназның сүзен тыңлап бетерми, аргта, бакча почмагында үсеп утыручы куш каен янына китә. Каен җирдән ярты метрдан күтәрелгәч икегә аерыла. Аның тармаклары тигез һәм төзләр. Бу — аның яраткан урыны. Ул һәр иртә каен янына килеп исәнләшеп китә. Менә бүген дә: «Исәнме, каенкаем!» — дип, каенны барып коча.

Айсылу. Каенкаем, син бүген тагын да матурлангансың, һәрвакыт шулай матур булып калу серләрен өйрәтче миңа.

Каен яфраклары җил белән лепердәшеп ала. Айсылу каенның кәүсәсен бер кулы белән әләктереп, каен белән вальс әйләнгәндәй, әкрен генә җырлый. Моңы искитәрлек булмаса да, хис белән җырлагач, җыры йөрәккә барып җитә.

Айсылу. Куш каеным, аппаккаем,
Ни сөйли яфракларың?
Шатлыктанмы, кайгыданмы
Чыланган яңакларың?
Каенкаем, гүзәлкәем,
Килдең кайсы урманнан?
Кемнәрне карыйсың шулай,
Үрелә-үрелә юллардан.
Каенкаем, матуркаем,
Тирәнме тамырларың?
Күтәрдең күпме елларның
Карларын, яңгырларын?
Куш каеным, каенкаем...

Айсылу җырын тәмамлый алмый, яшенле яңгыр килгәнен күреп ала. Аклы-каралы болытлар арасыннан яшен сызыклары ялтырый. Күк күкри. Яфраклар шомлы шаулаша башлый. Сәрбиназ йөгереп Айсылу янына килә. Эт тә ярсып өргәргә тотына.

Сәрбиназ. Әйдә, кызым, яшен вакытында агач янында торырга ярамый.

Сәрбиназ Айсылуны җитәкләп каен яныннан алып китәргә тырыша.Коеп яңгыр ява башлый.

Сәрбиназ. Чыланасың бит, балакай. Салкын тияр. Әйдә, кызым, әйдә. Аш та суына торгандыр.

Айсылуны көчләп диярлек каен яныннан алып китә. Болар өй янына килеп җитүгә, дөбердәп күк күкри, каенны яшен суга. Ул дөрләп яна башлый. Айсылу «Ah!» итеп куя һәм битләрен каплап баскычка утыра. Ул тавышсыз гына елый. Аның бите буйлап яшьләр агып төшә. Сакчылар, каенда беренче ялкын күренүгә үк, янгын сүндерүчеләргә хәбәр итәләр. Янгын сүндерүчеләр тиз килеп җитәләр. Алар иң беренче эш итеп утның юлын кисәләр. Машина белән бакчага кермәсәләр дә, шлангларын сөйрәп мунча, гараж өсләренә күбекле су сиптерәләр. Бакчадагы чәчәкләр таптала. Бу хәлләрне күреп, Айсылуның үзәге өзгәләнә. Сәрбиназ аны көчләп диярлек өйгә алып кереп китә.

Айсылу. Бер минутта куш каеным дөрләп янды да бетте. Мин бит аны Гәрәйгә ялына-ялына өйләнешкән көнебездә утырттырган идем. Безнең мәхәббәтебезнең бер чагылышы иде бит ул. Куш каеным... *(Елый.)* Әгәр бәхетебезне кинәт яшен сукса?

Сәрбиназ. Син, кызым, алай тирәнгә алма әле. Бернәрсәне дә яманга юрарга ярамый.

Капка төбенә бер «джип» килеп туктый. Ул — өйнең хуҗасы Гәрәй Мингалиевич. Атлап йөрүендә үк үзенең бу йортка хуҗа икәнлеге сизелә. Ул кайтканда инде янгын бөтенләй диярлек сүндерелә. Шулай да хуҗа бакча читендәге каенга кадәр бара. Каенның кап-кара кәүсәсе генә сөрәеп калган. Янгын сүндерүчеләргә ниндидер күрсәтмәләр бирә дә өенә кереп китә.

Гәрәй. Минем Айсылуымның хәле ничек? *(Айсылу диванда мышык-мышык елап утыра. Гәрәй хатынын кочып ала.)* Елама, аппагым, дөньяда бер генә нәрсә дә синең күз яшеңә тормый. Синең күз яшеңне күрсәм, йөрәгем телгәләнә. Үзем дә йомшый башлыйм.

Гәрәй кесәсеннән кульяулык алып «лач!» иттереп борынын сеңгерә. Сеңгерү төчкерүгә әверелә. Аның һәр төчкергәненә Сәрбиназ: «Сәламәт бул, Гәрәй Мингалиевич!» — дип тора. Төчкерү тукталгач, Гәрәй Сәрбиназ белән Айсылуга берьюлы дәшә.

Гәрәй. Нәрсә, кызлар, сез тамак туйдырдыгызмы әле?

Сәрбиназ *(ык-мык килеп).* Менә Айсылу иртәдән бирле бер тәгам ризык капмады.

Гәрәй. Чирләмисеңдер бит, чәчәгем? *(Хатынының башын тота. Башы кайнар.)* Син уттай янасың бит, алмагачым. Болай ярамый. Каен янды дип шулхәтле кайгырырга?!

Гәрәй Мингалиевич кесәсеннән телефонын алып номер җыя.

Гәрәй. Алло, Сергей Ивановичмы бу? Срочно бер шәп врачыңны миңа җибәр. Шофер барып алыр. Юк, үзем түгел, хатын чирли. Температурасы бар. Прямо уттай яна.

Айсылу. Тән кызышкан саен врач чакыртырга!

Гәрәй. Кирәк, чәчәгем, кирәк! Үзебез турында үзебез кайгыртмасак, кем кайгыртыр.

Айсылу. Мин бит чирләмим.

Гәрәй. Чирләмә. Ләкин врачка күренеп алу зыян итмәс. Мөмкинлегебез барында. Юкса күпме кешеләрнең ютәл даруы алырлык та рәтләре юк.

Айсылу. Моңа кем гаепле соң? Бәлки, менә сезнең кебек байлар булмаса, мондый хәл килеп чыкмас иде.

Гәрәй *(Айсылуны кочаклап).* Байлар юк чакларда да яшәп карадык. Талонга тиешле майга чират торганда, минем әниемне изеп гомерлек гарип иттеләр. Мин әниемне өч ел карадым. Ул минем кулымда үлгәч, үз-үземә ант бирдем: ничек кенә булса да бу ярлылыктан котылырга. Юклык — кешене кол итүче иң зур нәрсә. Имәндәй ирләр бер телем ипи өчен билләрен бөгәләр. Коточкыч бит бу, акыллым. Кеше — байлык колы, диләр. Юк, кешене мескенләндерүче, иң горурларны да тезләндерә торган нәрсә — хәерчелек.

Айсылу. Ярлыларның да һәммәсе мескен түгел.

Гәрәй. Әйе, килешәм. Мескен хәлгә төшмәс өчен үз-үзләрен яндырган кешеләрне дә күргән бар.

Тышта машина моторлары гүләгәне ишетелә. Янгын сүндерүчеләр китеп бара. Гәрәй тәрәзәне ачып аларга кул болгап рәхмәтен белдерә. Янгын сүндерүчеләр китеп баруга, хуҗаның «джибы»нда Сәлимә Галимовна килеп җитә. Ул урта яшьләрдәге ханым. Кулында кызыл хач төшерелгән кечкенә чемодан.

Гәрәй. О-о, Сәлимә Галимовна, үзегез килгәнсез, рәхмәт, рәхмәт.

Сәлимә Галимовна. Нәрсә булды безнең Айсылуыбызга?

Гәрәй. Кызышып тора.

Сәлимә Галимовна. Кая, карыйк әле.

Айсылу янына килә. Аның өстендә юеш күлмәк күреп, куркып китә.

Сәлимә Галимовна. Карагыз инде боларны!

Гәрәй. Нәрсә, Сәлимә Галимовна?

Сәлимә Галимовна. Соң, күрмисезмени? Хатыныгыз өстендә юеш күлмәк.

Гәрәй кырыс караш белән Сәрбиназга карый. Сәрбиназ аның карашын яхшы аңлый.

Сәрбиназ. Гаеп миндә, Гәрәй Мингалиевич. Дөрләп каен яна башлагач, Айсылуның өстен алыштырырга да онытканмын. Бигрәк кинәт булды бит.

Гәрәй. Хәзер аклану файдасыз. Әйдә, чәчәгем, өс-башларыңны алыштыр.

Хатынын күтәреп алып икенче бүлмәгә кереп китә. Үзе шунда «безнең арттан ияр» дигәнне аңлатып врачка ымлый. Сәлимә Галимовна кечкенә чемоданын күтәреп алар артыннан китә. Озакламый Гәрәй чыга.

Гәрәй. Сәрбиназ апа!

Сәрбиназ. Нәрсә, Гәрәй Мингалиевич?

Гәрәй. Бүген безнең тирәдә ниндидер ала карга әйләнгәләп йөргән икән. Нәрсәләр сөйләштеләр алар Айсылу белән?

Сәрбиназ Гәрәйнең күзләренә гаҗәпләнеп карый. Ул аның соравын аңлап җиткерми.

Сәрбиназ. Гәрәй Мингалиевич, мин, үзегез беләсез, гомерем буе рестораннарда аш пешереп йөрдем. Казанымда ни кайнаса, шуны гына күрдем. Сез нинди ала карга турында әйтәсездер, аңламыйм.

Гәрәй. Ә теге монтер?

Сәрбиназ *(җанланып).* Аның койрыгын гына күреп калдым мин, Гәрәй Мингалиевич.

Гәрәй. Койрыклы идемени?

Сәрбиназ. Юк инде, Гәрәй Мингалиевич. Киткәнен генә күреп калдым, диюем.

Гәрәй. Күзәтүчәнрәк булырга кирәк, Сәрбиназ апа.

Сәрбиназ. Соң бит, Гәрәй Мингалиевич, сезнең күзәтүчеләрегез...

Гәрәй. Аларга Айсылу артыннан тагылып йөрергә кушылмаган. Аларның үз вазифалары. Карагыз аны, моннан соң күзегезне ачыбрак йөрегез. Бәлки, каен януда теге монтерның гаебе бардыр.

Сәрбиназ Гәрәйнең сүзләрен кире кагырга теләп авызын ача, ләкин сүзен әйтеп өлгерми, эчкәрге бүлмәдән врач Сәлимә Галимовна чыга.

Гәрәй. Йә, ничек, Сәлимә Галимовна?

Сәлимә Галимовна. Куркыныч нәрсә юк, Гәрәй Мингалиевич. Кайнарлыгы бүген үк үтәр дип уйлыйм. Тиешле даруларны калдырдым. Тик... *(Ул туктап кала.)*

Гәрәй. Нәрсә, Сәлимә Галимовна?

Сәлимә Галимовна. Сез, Гәрәй Мингалиевич, Айсылуны артыграк иркәләп җибәрдегез бугай.

Гәрәй. Моның белән нәрсә әйтмәкче буласыз, Сәлимә Галимовна?

Сәлимә Галимовна. Артык наз кешедә булган үз-үзен саклау иммунитетын киметә. Мин бу нәрсәне күптәнге күзәтүләремә таянып әйтәм.

Гәрәй. Юк, сез хаклы түгел, Сәлимә Галимовна. Назлау, ярату кешедә үз-үзенә ышану тудыра. Дөньяда үзен кирәкле дип санаган кешенең иммун системасы да ныгый. Аннары, Айсылуны назлау, аның турында кайгыртып тору минем үземә рәхәтлек бирә. Айсылу моны яхшы аңлый, минем назларыма наз белән җавап бирә.

Сәлимә Галимовна. Шулайдыр, ышанам. Ләкин аны бераз иреккәрәк җибәрергә кирәкмиме икән?

Гәрәй. Сез нәрсә, Сәлимә Галимовна, мин аның һич иреген чикләмим. Кая барырга тели — барсын. Гаражда машинасы көтеп тора.

Сәлимә Галимовна. Машина гына әле ул ирек дигән сүз түгел. Кеше үзенең җаны белән иреклe булырга тиеш.

Гәрәй. Мин аның җанын бәйләп куйганым юк.

Сәлимә Галимовна. Ансы шулайдыр, ләкин мин Айсылуның күңелендә ниндидер курку күрәм. *(Сәлимә Галимовна әйтер сүзен әйтеп бетерми.)* Йә, ярый, ансы минем эш түгел. Ә чибәркәегез терелер. Хушыгыз!

Сәлимә Галимовна китәргә җыена башлый. Гәрәй Мингалиевич аңа йөз доллар суза.

Сәлимә Галимовна. Алай ук кирәкмәс иде, Гәрәй Мингалиевич.

Гәрәй. Кайсылай кирәген мин үзем беләм. *(Акчаны врачның халат кесәсенә сала.)* Минем шофер сезне өегезгә илтеп куяр. Хушыгыз!

Сәлимә Галимовна. Хушыгыз! Бераздан Айсылуның хәлен белешеп шылтыратырмын әле.

Врач чыгып китүгә үк, Айсылу ире янына төшә. Озын ефәк халаттан. Айсылуны күрүгә, Гәрәй куркып кала.

Гәрәй. Нигә тордың, чәчәгем?

Айсылу. Әй, тәнем кызыша дип тә урында ят, башым авырта дип тә.

Гәрәй. Бераз ятарга идең. Син бүген зур стресс кичергәнсең. Тынычланырга кирәк сиңа.

Айсылу. Бакчага чыгып теге каенны карыйм әле. Ул мескенкәйнең кара кәүсәсе генә калгандыр инде.

Гәрәйнең Айсылуны янган каен янына чыгарасы килми. Айсылуның өр-яңадан хисләргә бирелеп авыруы көчәеп китүдән курка ул.

Гәрәй. Юк, сөеклем, син анда бүген чыкмый тор инде. Нигә җан җәрәхәтләрен яңартырга?

Айсылу. Ул кадәрле саклама инде син мине, Гәрәй Мингалиевич.

Гәрәй. Саклыйм һәм саклаячакмын.

Айсылу. Баштарак алай түгел кебек идең.

Гәрәй. Кулда югалтырлык бәхет булмаганда, без барыбыз да ваемсыз. Ә бәхет килеп кердеме, аны югалтасыбыз килми. Димәк, баштарак бәяли алмаганмын. Менә синең белән дүрт елдан артык яшибез. Шул дүрт елда син миңа кырык биш ел яшәү дәверемдә күрмәгән бәхет бирдең.

Айсылу. Мине идеаллаштырма, Гәрәй Мингалиевич. Берәр вакыт идеалың кысасына сыешмам да соңыннан үзеңә кыен булыр.

Гәрәй. Идеал кысаларын киңәйтербез, бер дә борчылма, аппагым. Ә хәзер бер-ике сәгатькә ятып тор. Менә бу тынычландыргыч даруны эчеп куй.

Гәрәй Айсылуга тынычландыргыч дару эчерә һәм сабый баладай аны күтәреп йөртә. Айсылу рәхәтлектән күзләрен йома һәм бераздан йоклап китә. Гәрәй аны урынга салып, өстенә яба. Үзе аяк очларына гына басып бакчага чыга. Янган каен янына килә. Озак кына кап-кара булып калган каенга карап торганнан соң, кесәсеннән телефон чыгарып номер җыя.

Гәрәй. Горзеленхозмы бу? Мине срочно Семен Петрович белән тоташтырыгыз. Гәрәй Мингалиевич бу. Алло, алло, Семен Петрович, теге особый бригадаңны миңа җибәр һәм бик тиз. Үзең дә кил. Килә алмыйсың? Мин андый сүзне кабул итмим. Нәрсә булдымы? Ансын килгәч күрерсең. Бетте. Ярты сәгатьтән көтәм. Әгәр биш кенә минутка соңарсагыз да, Йошкар-Ола горзеленхозын чакыртам. *(Гәрәй үзенең эшеннән канәгать булып кала.)* Өр-яңа каен утырттырачакмын. Нәкъ шундыйны. Шәп идея башка килде бит әле, шайтан алгыры. Кайчакта минем баш шәрифләренә дә акыллы уйлар килеп куйгалый шул. Айсылуга күрсәтми генә эшләп, бер күңелле сюрприз ясыйсы иде үзенә. Ә нигә? Эшләмәслек эш түгел бу. Бүген горзеленхоз кешеләре тапталган бакчаны рәткә кертеп, каен кәүсәсен алып китәрләр. Айсылу белән Сәрбиназ апаны иртәгә берәр җиргә җибәреп торырга була. Сәрбиназ апаның Көмеш Чишмәм дип әллә кайчаннан авыз сулары корый. Күреп килсен туган якларын.

Урамда машина гөрелтеләре ишетелә. Горзеленхоздан икән. Семен Петрович үзе дә бар. Капка төбенә машиналар туктауга, Матуркай өрергә тотына. Семен Петрович керә алмый тора. Ул кесәсеннән телефон чыгарып Гәрәй Мингалиевичка шылтырата.

Семен Петрович. Без килдек, Гәрәй Мингалиевич, ләкин сезнең крепостька үтеп булмый.

Гәрәй. Мин хәзер.

Ашап утырган чагы булган, күрәсең, капкалый-капкалый чыга. Килгән кешеләргә сәлам бирә һәм Матуркайның башыннан сыйпап тынычландыра. Семен Петрович капкадан керә.

Семен Петрович. Нәрсә, ут чыкмагандыр бит, шулхәтле ашыктырып чакырдың.

Гәрәй. Ут чыкты шул.

Семен Петрович. Без бит пожарниклар түгел.

Гәрәй. Беләм. Әнә пожарниклар бөтен бакчадагы чәчәкләрне егып-сындырып бетергәннәр. Бакчабыз сугыш кырына охшап калган.

Семен Петрович *(бакчага күз салып)*. Мин кызларны алып килдем. Бакчаңны рәткә кертерләр.

Гәрәй. Ләкин иң мөһиме ул түгел әле. Әнә күрәсеңме, бакча түрендәге куш каеныбызның кара кәүсәсе генә калды. Менә шуның көйгән кәүсәсен төпләп алып, нәкъ шундый зурлыктагы куш каен утыртасы иде.

Семен Петрович. Бусы катлаулырак, Гәрәй Мингалиевич. Техника юк. Зур каенны көрәк белән генә казып алып булмаганны беләсең.

Гәрәй. Техниканы үзем табармын. Хәзер кызларың кереп чәчәк түтәлләрен рәтли торсыннар. Яңа чәчәкләр утыртырга кирәк булса, алып килергә машина бирәм.

Гәрәй кемгәдер шылтыратып ала. Ул арада көрәк, тырма, секатор эше коралларын күтәреп берничә кыз керә. Алар түтәлләргә күз салу белән ни кирәген аңлап эшкә тотыналар. Бакчада эш гөрли. Вакыт-вакыт Сәрбиназ чыгып кызларның җитез эшләгәненә сокланып карый. Сынган, тапталган чәчәкләр урынына Гәрәй Мингалиевич биргән машина белән икенче машина чәчәкләр китерә. Артта торфмы, тиресме төягән машина да бар икән. Кызлар аны кулларында йомшартып кына чәчәк төпләренә сибәләр.

Гәрәй. Капкалап алмыйсызмы, Семен Петрович?

Семен Петрович. Юк, әле генә ашап чыктым. Аннары, аппетит та юк. Өч көн менә бу бригада главаның бакчасында эшләде. Кичә хатынының туган көне иде. Бакчаны эшләп бетерүне дә, туган көнен дә бәйрәм иттек. Аның хатыны белән минем хатын ике туган сестралар. Бармый булмады.

Гәрәй. Мине дә чакырган иде. Безнең акционерлар җыелышы как раз шул вакытка туры килде. Кемнәр бар иде соң?

Семен Петрович. Барлык главалар диярлек. Ләкин мин ансына шаккатмадым. Дәүләт аппаратыннан йогынтылы кешеләр булуы бераз аптыратты.

Гәрәй. Димәк, безнең Андрей Антоновичны югарырак пост көтә.

Болар сөйләшеп торган арада, кызлар бакчаны рәткә китерәләр. Чәчәкләрнең күбесе ауган гына булып чыга. Үз урынына утыртып, тиресле туфрак белән төпләрен ныгытып, су сибеп җибәргәч, бакча үз хәленә килә. Сынган, имгәнгән чәчәкләр алыштырыла. Әйтерсең бакчага бернинди афәт килмәгән. Янган каенны да төбе-тамыры белән алып киткәч, бакча бөтенләй ямьләнә төшә. Эш беткәч, Гәрәй чәчәк утыртучы кызларга һәм каенны төпләп алучы егетләргә үз кулы белән һәрберсенә акча биреп чыга. Ә Семен Петровичка: «Без синең белән исәп-хисапны башкачарак ясарбыз»,— дип кулын кыса.

Эш беткәч, барсы да машиналарга төялеп китә. Гәрәй Мингалиевич бармак белән генә Сәрбиназны чакырып ала.

Гәрәй. Айсылу уянгач аның белән берәр яры барып кайтыгыз. Үзеңнең Көмеш Чишмәңне бик сагына идең, анда барып кайтсагыз да ярый. Айсылуга бераз вакытка бу авыр хәлләрне оныттырып торыйк без.

Сәрбиназ. Айсылуны бигрәк яратасыз инде. Аңа өйләнгәч, бакчагыз оҗмах бакчасына әйләнде.

Гәрәй. Әйбәт кеше өчен бернәрсә дә жәл түгел.

Сәрбиназ. Әйе, Айсылу да сезнең өчен җан атып тора шул.

Гәрәй. Озын сүзнең кыскасы шул, Сәрбиназ апа, бер-ике көнгә Айсылуны үзегезгә алып кайтып тор. Апаңнарда кунак булып килерсез.

Сәрбиназ. Үземнең дә бик кайтасым килә иде, ай рәхмәт, Гәрәй Мингалиевич!

Гәрәй. Уянгач, температурасын үлчәргә онытма. Әгәр тәне кайнар булса, беркая бармыйсыз.

Болар сөйләшкән арада, Айсылу уяна. Ул Гәрәйнең соңгы сүзләрен ишеткән икән.

Айсылу. Бернинди температурам да юк, Гәрәй Мингалиевич. Менә башны тотып кара.

Гәрәй Айсылуның маңгаен үзенең битенә тидерә. Температурасы юк икәненә ышана.

Гәрәй. Батырым минем. Тормышны яраткан кешеләр генә шулай тиз терелә.

Айсылу *(хисләнеп).* Тормышны яратмаска мөмкинме соң?

Безнең өчен һәр көн кояш чыга,
Безнең өчен һәр көн таң ата.
Безнең өчен Ходай һәрбер төнне
Күк йөзенә йолдыз тарата.

Шунда Айсылуның бакчага күзе төшә. Ул аһ итә. Гәрәй янына килеп иңе белән аңа сылана.

Айсылу. Мин шулай озак йокладыммы, син бакчаны шул арада эшләттеңме? И сөйкемле тылсымчым минем! *(Гәрәйнең яңагыннан үбеп ала.)*

Гәрәй. Ярар, чәчәгем, мин киттем. Ә сез бераз Сәрбиназ апа белән җилләнеп кайтыгыз. Сәрбиназ апа күптән авылына кайтып килмәкче иде. Барып бераз кунак булып кайтыгыз.

Сәрбиназ. Мең рәхмәт, Гәрәй Мингалиевич. *(Айсылуга карап.)* Син безгә кунакка кайтырга каршы түгелсеңдер бит, Айсылу?

Айсылу. Түгел, тик бер шарт белән.

Сәрбиназ. Нинди шартыңа да риза.

Айсылу. Син шартымны белмичә ризалашырга ашыкма әле. Бәлки, мин сиңа, берәр егет белән

таныштыр әле, диярмен.

Сәрбиназ *(кул селтәп).* Мин җитди сүз күтәм тагы, син шаярасың икән. Син бит Гәрәй Мингалиевичтан бүтән кешене күрмисең дә.

Гәрәй. Ярый, Сәрбиназ апа, җыена башлагыз. *(Айсылуга.)* Ә син, чәчәгем, бик кызу чапма.

Айсылу. Юк инде, утыздан арттыру юк.

Икесе дә көләләр. Гәрәй чыгып китә. Айсылу Сәрбиназга күрсәтмәләр бирә башлый.

Айсылу. Сәрбиназ апа, күчтәнәчләрне күбрәк ал, саранланма. Мин өс-башларны алыштырып чыкканчы, олы бүксәле сумкаң туп-тулы булсын.

Сәрбиназ. Булыр, булыр, чәчәгем.

**БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Икесе ике бүлмәгә кереп китәләр. Болар югында Гәрәйнең беренче хатыны Рәхилә капка төбенә килеп эчкә карап тора башлый. Ят кешене күреп, эт өрергә тотына. Эт өргән тавышка Габдулла чыга. Каравылчы хатынны таный.

Габдулла. Нишләп йөрисез монда, сезне кертмәскә кушканнарын белмисезмени?

Рәхилә. Беләм. Хуҗа үзе өйдәме?

Габдулла. Юк.

Рәхилә. Алайса, аның яшь бикәчен чакыр әле.

Габдулла. Чакырмыйм. Аның хәсрәтле чагы.

Рәхилә. Нинди хәсрәт?

Габдулла. Бакчадагы каеннарын яшен сукты.

Рәхилә. Кит аннан! *(Үрелеп карый, ләкин каен урынында берни күрми.)* Менә шәп булган. Монда ниндидер хикмәт бар. Ходай күрсәтә ул. Киң дөньяга сыймаган кешеләрне тар кабергә сыйдыра. Ха-ха-ха! Менә бит, ә?! Аларның каеннарын яшен суккан! *(Үзенең күкрәгенә суга.)* Ә менә минем тормышымны яшен сукты. Беләсеңме син шуны, карт шүрәле.

Габдулла. Син маеңа чыдаша алмыйча үз тормышыңны үзең боздың.

Рәхилә *(Габдуллага түшен терәп).* Ничек боздым, ничек?

Габдулла *(Рәхиләне читкәрәк этеп).* Синнән сасыган аракы исе килә. Йөрмә бу тирәдә. Юкса Гәрәй Мингалиевичның сакчылары итәк астыңа кычыткан кыстырып җибәрергә дә күп сорамаслар.

Рәхилә. Якын килеп кенә карасыннар!

Габдулла. Якын да килерләр, иманыңны да укытырлар. Авызыңны да ачарга өлгермәссең.

Рәхилә. Өркетмә. Менә монда *(күкрәгенә суга)* курка торган җан түгел. Рәхилә әйтте диярсең, мин бу ояны туздырмый туктамаячакмын.

Габдулла. Синең ишеләр туздырырлык итеп эшләнмәгән шул ул.

Ишек ачылган тавыш ишетелә. Рәхилә капка артынарак поса. Өйдән Сәрбиназ белән Айсылу чыга. Айсылуның кулында кечкенә генә ак сумка. Ул спорт костюмыннан. Сәрбиназ өйдән буш кул белән чыга.

Сәрбиназ. Әйберләрне машинаңны гараждан чыгаргач алып чыгарбыз инде.

Айсылу. Ярый, Сәрбиназ апа. Анда синең сумкаң шактый авырайды бугай. Бергә алып чыгарбыз. *(Каравылчыга.)* Матуркай нигә бик ярсып өрде, әллә берәр ят кеше бар идеме?

Габдулла. Бер малай таяк белән коймага сукты. Малайларны үзегез беләсез бит инде, Айсылу Акбулатовна.

Айсылу. Әйе.

Айсылу кулындагы идарә пульты белән гараж капкасын ача. Машина эченә кереп утыра. Стартерны бер боруга, машина кабына, гараждан чыга. Ул чыгуга, урам капкасын каравылчы Габдулла ачып куйган була. Айсылу машинасын ишек төбенә үк китереп куя. Аннары алар Сәрбиназ белән машинага сумкалар, төенчекләр ташыйлар. Аларның һәрбер хәрәкәтен Рәхилә койма ярыгыннан күзәтеп тора. Әйберләр салынып бетүгә, Айсылуның машинасы ыргылып капкадан чыгып китә. Олы юлга чыгуга, Айсылу машинасын куа башлый. Сирәк-мирәк кырыйдагы көзгегә күз сала. Машинасындагы магнитофонын кабыза. Җыр агыла.

Айсылуларның машинасы күздән югалуга, Габдулла янына Рәхилә килеп баса.

Рәхилә. Кая киттеләр алар болай төянеп?

Габдулла. Мин каян белим. Саф һава суларгадыр.

Рәхилә. Саф һава суларга шуның кадәр әйбер төяп китмиләр. Йә, әйт, кая киттеләр?

Габдулла. Каймалы базарынадыр алайса.

Рәхилә. Белмәгәнгә салынып маташма, кая киткәннәрен әйтмәсәң, мин моннан китмәячәкмен.

Габдулла. Китмә алайса, мин киттем.

Габдулла капканы ябып кереп китмәкче була, ләкин Рәхилә тычканга ташланган мәче тизлегендә Габдулла ябарга теләгән

капкага барыпябыша. Габдулла аны этеп җибәрергә тели, ләкин хатын капканы яптырмас өчен бар көчен куя.

Рәхилә *(хәйлә юлына баса).* Габдулла, дөресен әйтим, миңа аларның кая киткәне пычагыма да кирәкми.

Габдулла. Алайса, нигә сорашасың?

Рәхилә. И беркатлы да инде син, Габдулла. Менә шул беркатлылыгың өчен яратам бит мин сине. *(Габдулланың чәчен сыйпап куя.)*

Габдулла. Хәйләләмә.

Рәхилә. И Габдуллаҗан, мин бу йортка сине күрер өчен генә киләм, юләр баш.

Габдулла. Элек башкачарак сайрый идең.

Рәхилә. Кошлар да төрле вакытта төрлечә сайрый. Аларның телен аңларга гына кирәк.

Габдулла. Мин каргалар телен аңламыйм шул.

Рәхилә. Син барсын да бик яхшы аңлыйсың, Габдуллаҗан бәгърем. Мин менә дөньяда синең кебек кешеләр барына куанып яшим.

Габдулла. Сине куандырган юк бит әле.

Рәхилә. И-и, хатын-кызга күп кирәкмени? Синдәй ирләрнең бер караш ташлавы җитә безгә. Син әле үзеңнең арыслан икәнеңне белмисең.

Габдулла *(тураебрак китә. Үзенең төшеп калганнардан түгел икәнен белгертеп тамак кыргалап куя).* Әйе, ул яктан син хаклы. Беләкләрдә гайрәт бераз кимесә дә, кайбер җирләр... *(Ул хатынның колагына нидер әйтә. Аның сүзләреннән Рәхилә шырык-шырык көлә.)*

Рәхилә. Менә-менә, бөтен хикмәт шунда шул. Сынап карыйсы килә иде шуны.

Габдулла. Бик хәйләкәр хатын икәнеңне беләм. Монда нидер бар. Сиңа тегеләрнең серен белү кирәк. Син шуның өчен бөтенесенә әзер.

Рәхилә. Тегеләрне сорашу, Габдуллаҗан бәгърем, синең белән сөйләшеп алыр өчен бер хәйлә генә. Хатын-кыз ир-атка тора салып сиңа күзем төште, дип әйтә алмый бит инде, син миңа бераз гына булса да игътибар итсен өчен тегеләрнең канына тоз салып маташкан булам.

Габдулла. Кхм! Кхм! *(Тамак кыра.)* Нишләптер тамак кибеп китте.

Рәхилә. Соң, алайса, Габдуллаҗан бәгърем, нәрсә карап торабыз. Хуҗалар өйдә югында бераз тамак чылатып чыгыйк.

Габдулла. Юк, ул өйгә безнең өчен юл ябык. Ачкычны хуҗалар үзләре белән йөртәләр.

Рәхилә. Синдә профессор башы бар бит. Теләсәң, керү юлын табарсың.

Габдулла. Теләсәң, әллә кайларга керергә юл табып була ансы. Хи-хи-хи!

Рәхилә. Менә-менә! Теге җирем Аллага шөкер, дигән идең.

Габдулла *(җанланып).* Ә, әйе, теге нәрсә... Подвал аша кереп карасак кына инде. Әй, юк, ярамый. Хуҗалар белсә...

Рәхилә. Теге нәрсәң белән мактангансың гына икән. *(Кулын селтәп китә башлаган була. Ул инде Габдулланың йөрәгенә ут салуын аңлый.)* Йә, хуш, Габдуллаҗан бәгърем! Тик мәңгегә хушлашканчы, арысланымның иреннәреннән бер суырып үбим әле.

Рәхилә Габдулланың муенына сарылып, иреннәреннән үбә. Үзе әкрен генә ишегалды ягына кереп капканы яба. Капка шартлап ябылып, үзләре ишегалдында калгач кына Габдулла уянып киткәндәй була.

Габдулла. Хуҗалар кайтып керсә...

Рәхилә. Керсә, бер дә аптырап калма. Бу минем сөяркәм, диген. Хәзер бит сөяркәләр заманы.

Габдулла. Сөяркәм?..

Рәхилә. Ә нигә? Минем дә бит ул нәрсә бар.

Габдулла. Барын бардыр. Тик хуҗа белә калса...

Рәхилә. Белсен. Алар гына бәхетле булырга димәгән. *(Шаярган булып.)* Безнең фәлән нәрсәләребезгә алар хуҗа түгел бит әле.

Габдулла. Ансы шулай. Бәхетнең шулпасының шулпасы безгә дә тиешле.

Рәхилә. Син, Габдуллаҗан, үзеңне дә, мине дә алай кечерәйтмә. Без дә Алла бәндәләре. Безнең байлыгыбыз үзебездә. Җанымны күптән ачарга кирәк иде сиңа. Һаман шул тыйнаклыгым тыя килде. Йә, кил әле, кер әле кочагыма. *(Габдуллага айнырга ирек бирмичә тагын кочаклап үбә.)* Өйгә подвал аша кереп була диденме әле?

Габдулла *(еш-еш сулап).* Әйе.

Рәхилә *(Габдулланы сөйрәп диярлек).* Әйдә, Габдуллаҗан бәгърем, подвалга! Кая ачкычларың?

Габдулла кесәсеннән ачкычлар чыгара. Ачкычларны Габдулла кулыннан Рәхилә тартып диярлек ала. Подвалны ачмакчы булып, әле бер, әле икенче ачкычны йозак тишегенә тыгып карый. Ләкин ачкычларның берсе дә ярамый.

Мә, үзең ач.

Габдулла *(ачкычларны карый).* Монда подвал ачкычы юк икән. Кая куйдым икән мин аны?!

*(Уйланып тора. Рәхилә аның кесәләрен капшый. Бот араларын да калдырмый.)*

Рәхилә. Сине иң акыллы, иң башлы, иң кыю иргә санап, синең белән очрашуны күз алдыма китереп күпме хыялландым. Булмады... Юк икән...

Габдулла. Булыр, булыр. Булдырырбыз. Әйдә үземә апкерәм, анда тынычрак. *(Рәхиләнең җиңеннән тарта.)* Әйдә, әйдә. Иң тыныч урын минем үземдә.

Рәхилә. Керүен керербез, тик... Гәрәйнең яшь кәнтәе кайтып керсә, капка ачарга йөгерәсең булыр.

Габдулла. Ансы өчен кайгырма. Алар бүген кайтмыйлар. Алар Сәрбиназларга кунакка киттеләр.

Рәхилә *(бармак янап).* Ну хәйләкәр дә үзең, белмим дип маташкан була.

Габдулла. Мин бит Сәрбиназның кайсы авылдан икәнен белмим.

Рәхилә. Син белмәсәң, мин беләм. Аңгыра.

Рәхилә капкага таба китә. Габдулла аптырап карап тора.

Габдулла. Безгә кермибезмени?

Рәхилә. Синең сасыган ятагыңда аунаргамы?

Капканы ачып чыгып китә. Тиз-тиз өенә таба атлый. Юлда аңа улы Альберт очрый. Аның кулында литр ярымлы сыра шешәсе. Ул аны атлаган саен йотып бик ләззәтләнеп эчә. Әнисен күрми.

Рәхилә. Альберт!

Альберт *(туктап әнисенә карый, ул ачулы).* Нәрсә монда мине сагалап йөрисең? Сөяк сагалаган карга сыман.

Рәхилә. Сагалап түгел, кайгыртып йөрим мин сине, аңгыра баш.

Альберт. Бик кайгыртсаң, әнә Гәрәй Мингалиевичыңнан миңа яңа машина алдырт. А то бу барахло белән йөрү миңа стыдно.

Рәхилә. Син бераз акыллырак булсаң, яңа машинаны Гәрәй Мингалиевичтан үзең сорар идең. Атаң бит ул синең.

Альберт. Атам или не атам, черт вас знает. Все перепутано.

Рәхилә. Юкны сөйләмә, улым. Ничего не перепутано.

Альберт. Тогда зачем же он выгнал тебя из своего дома? По-моему, син анда минем атам өйдә юк чакларда кемнәр беләндер гоголь-мугель уйнаштыргансың бугай.

Рәхилә. Син, улым, урам хатыннары кебек теләсә ни сөйләмә. Мин бит синең анаң.

Альберт. А кто тебя знает, анам ты или не анам?

Рәхилә. Син бүген кире ягың белән торгансың бугай. Ә мин сиңа яхшы хәбәр әйтермен дигән идем.

Альберт. Ну?

Рәхилә. Нәрсә «ну»?

Альберт. Ну, скажи быстрее яхшы хәбәреңне.

Рәхилә. Гәрәй Мингалиевичның яшь бикәче Сәрбиназ белән авылга киткән. Кунып кайталар, ди.

Альберт. Ну что из этого?

Рәхилә. Машина кирәк, дисең бит. Ә бикәчнең машинасы шәп чаба. Авылда каравылчы юк. Машиналары да, бәлки, урамдадыр.

Альберт *(җанланып китә).* У тебя не голова, а Госдума. Яхшы хәбәрне сразу әйтмичә, мораль читать начала.

Рәхилә. Мондый эшне ашыгып эшләмиләр. Уйла, үзеңнең дружокларың белән. Авылда бер эт тә сизмәслек итеп эшләргә кирәк бу эшне. Яшь бикәчнең машинасын алып китә алсагыз... О-о! Яшь бикәчкә көн калмаячак.

Альберт. Алып китәрбез, ләкин безне каптырачаклар.

Рәхилә. Башсыз. Аны бит сатып була. Хәзер башыңны бераз уйлатсаң, әллә ниләр эшләргә мөмкин.

Альберт. Да, дөрес калякаешь. Теләгәндә машинаның төсен үзгәртеп җибәрергә, двигательгә башка номер суктырырга, аннары өр-яңа техпаспорт ясатырга була. В крайнем случае башка шәһәргә илтеп сатарга була. Только...

Рәхилә. Нәрсә «только»?

Альберт. Болар өчен акча кирәк, мамань. Акчасыз хәзер туалетка да барып булмый. Ә безгә Сәрбиназ авылына барырга кирәк. Ничә километр ул Чишмәле от Казани?

Рәхилә. Егерме йә егерме биштер. Каян белим мин аны.

Альберт. Ну, ладно. Ансын үзебез белербез. Син миңа акча бир.

Рәхилә. Күпме кирәк?

Альберт. Чем больше, тем лучше.

Рәхилә *(сумкасын актара).* Менә монда бар булган акчам. Мә!

Альберт әнисенең кулыннан акчаны ала да кесәсенә салып куя. Аннары әнисенең сумкасын тартып алып эчен актара.

Рәхилә *(сумканы үзенә тарта)*. Бүтән акчам юк, китер сумкамны.
Альберт. Если нет — все твое, а что найду — все мое.

Ул сумканың эчке кесәсеннән бер меңлек тартып ала. Рәхилә улының кулыннан акчаны алмакчы була, ләкин Альберт оста фокусчыдай әллә ни арада акчаны яшереп өлгерә.

У тебя же ничего не было, мамань.
Рәхилә. Квартирага түләргә дигән акчам бит ул. Китер. *(Мышкылдый, күзләрен сөртеп ала.)*
Альберт. Москва слезам не верит, диләр. В том числе я тоже. Син бик хитрый, мамань. Гәрәй Мингалиевичтан суырып кына торасың.
Рәхилә. Ул жмуттан алырсың, бар.
Альберт. Если захочешь, син аждаһаның авызыннан телен дә тартып алырсың.
Рәхилә. Үз анаң турында шулай дип әйтергә ничек телең бара?
Альберт. Потому что я тебя хорошо знаю. Синең анда ике книжкаңда яткан акчалар целый мешок.
Рәхилә. Үлем-китемгә дигән бер-ике мең инде анда.
Альберт. Үлем-китем? Когда это еще будет.
Рәхилә. Оятсыз. Син минем тизрәк үлүемне телисеңмени әле?
Альберт. Я ничего не хочу. Я хочу свободно, богато жить.
Рәхилә. Богато жить итәр өчен эшләргә кирәк.
Альберт *(көлеп)*. Ха-ха-ха! Эшләргә? Бездә эшләп кем байый ала? Это дурацкая философия.
Рәхилә. Гомер буе эшләмичә генә йөрермен дисеңме?
Альберт. Пусть работают дураки. Ә мин баер өчен башка юллар табармын.

Сөйләшә-сөйләшә алар өйләренә кайтып җитәләр. Улының мондый фикер йөртүенә ана кеше бер дә гаҗәпләнми. Аның үзенең акылы да улыныкыннан ерак китмәгән. Күңелендә аның ачу ята. Бай тормышлы кешеләрне, гомумән, күралмый. Кулыннан килсә, ул аларның өйләрен яндырып, байлыкларын урам каракларыннан талатып бетерер иде.

Рәхилә. Авызыңны ачып калма. Яшь бикәч авылда бер кичтән артык кунмас, мөгаен.
Альберт. Не беспокойся, мамань. Без дә төшеп калганнардан түгел. Найдем способ. Вот увидишь, мамань, яшь бикәчнең «Мерседес»ы иртәгәдән минеке булачак. Теге карт дурочкасы белән моя молодая мамочка, капчыкларын сыртларына асып, Казанга җәяү кайтачаклар.

Икесе дә көләләр. Альберт үзенең пинжәген капчык итеп җилкәсенә сала да бөкрәеп атлый.
Альберт. Вот так, мамань! Тырык-тырык! Тырык-тырык!
Рәхилә *(ул да яулыгын Сәрбиназ кебек артка чөеп бәйли һәм аның төсле итеп йөрергә тырыша. Артистлыгы бар икән: йөрешен, сөйләмен Сәрбиназныкына шактый охшата).* Айсылушка, алай тиз атлама, минем аякларым авырта. *(Маңгаеннан тирен сөртеп алган була.)* Ничекләр генә Гәрәй Мингалиевичның йөзенә күренербез икән. Ух!
Альберт *(Айсылу булып кылана).* Мине Гәрәйчигем куып чыгарыр инде. Икенче яшь хатын алып кайтыр.
Рәхилә. Андый ачыгавызларны яратмый ул Гәрәй Мингалиевич. Аның талканы...
Альберт. Что такое «талкан»?
Рәхилә. Талкан талкан инде, башымны катырма әле. Эшкә тотынырга вакыт. Монда трай тибеп йөрсәң, «Мерседес»ны төшеңдә дә күрә алмассың.
Альберт. В этом ты права. Миңа срочно Карчыганы эзләп табарга кирәк. Ладно, мамань, я пошел.

Альберт китә. Әнисе аның артыннан нидер әйтеп кала, ләкин улы аны тыңлап тормый. Күздән югала.

**АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Кечкенә генә авыл. Җыйнак кына бер йортның капка төбендә Айсылуның ак «Мерседес»ы. Аның янында берничә малай әйләнгәләп йөри. Өйнең эчендә Айсылу, Сәрбиназ һәм аның апасы Маһруй шәһәр кунакларына белән чәй эчеп утыралар. Ул ике сүзнең берсендә «җаныкайларым» дип сөйләшә.

Маһруй. И-и, җаныкайларым, кайтып төшүегез әйбәт булды әле. *(Өстәлгә ымлап.)* Бу хәтле нигъмәтне кайчан авыз итәр идем. Виноградлары ни арада өлгергән тагын. Бигрәкләр дә тәмле икән, җанкисәкләрем, телгә салуга авызда эреп тора.
Сәрбиназ. Менә монда грушалар, апа. Озак саклама, аша. Синең әйберләрне сандыкка салып кую гадәтең бар. Череп китүләре мөмкин.
Маһруй. Син саклыйсың ул иң кыйммәтле әйбереңне яшереп. Сасып беткәндер инде.
Сәрбиназ. Әстәгъфирулла-тәүбә, диген. Карт башың белән әллә ниләр сүләп утырасың.
Маһруй. Сеңлем җаным, син тормыштан артта калгансың. Күбрәк тилибизор карарга кирәк. И-и,

анда төн урталарында әкәмәтләр күрергә була.

Айсылу *(боларның сүзләрен башка якка борырга теләп)*. Әйдәгез әле, ашап утырыйк. Сүз белән ризык бер авызга сыймый, диләр.

Мәһруй. Безнең авызга бар да сыя. *(Ул зур гына грушаның яртысын тешләп ала. Груша тамагына утыра. Ул көчкә тын ала. Күзләреннән яшьләр чыга. Сәрбиназ аның аркасына суга. Шуннан соң гына Мәһруй грушасын йотып җибәрә.)* Уф, үләм дип торам.

Айсылу *(урыныннан торып)*. Әгәр сез каршы килмәсәгез, машина тирәсендә кайнашучы малайларга бер-ике уч чикләвек биреп керим әле.

Мәһруй. Бар, җаныкаем, бар. Матур апа чикләвек биргәние, дип гомерләре буе сөйләрләр.

Айсылу бер сумкадан өстәлдәге тәлинкәгә чикләвек төше сала.

Айсылу. Чәй белән эчәргә тәмле ул. Табынга куярга оныткanбыз. Ашагыз әле.

Мәһруй чикләвекне күреп аһ итә.

Мәһруй. Әллә, җаныкайларым, ашаган өрекләрегезнең төшен җыя бардыгызмы? Чүкеч белән ваткансыздыр инде.

Айсылу *(көлемсерәп)*. Хәзер, апа, кибетләрдә кабыксыз чикләвекләр саталар. Менә монда эрбет чикләвеге дә бар. Бәлки, ансы ошыйрак төшәр. Тегесе аның миндаль чикләвеге. Кабыксыз булса да, катырак.

Мәһруй. И-и, әстәгъфирулла, кичә үлгән булсам, белмәгән булыр идем. Чикләвекнең төшен чыгарып утыручылар бар диген, ә? Ничек төшен чәрдәкләп бетермиләр икән моның. Һәр чикләвеккә чүкеч белән сугып утыр инде.

Айсылу. Тегермәне бар аның, апа.

Айсылу, төрле чикләвекләр салынган тәлинкә тотып, малайлар янына чыгып китә. Ул чыгып киткәч тә Сәрбиназ белән Мәһруй табын янында утырып калалар.

Мәһруй *(Айсылу ягына ымлап)*. Бу бала бик яшь күренә. Синең хуҗаң кырыктан узган кеше. Үзе өйдә югында яшь егетләр килгәлиләрме?

Сәрбиназ. Олы башың белән тузга язмаганны сүләмә әле, апа. Ире аның бер дә карт түгел.

Мәһруй. Шулайдыр, сеңлем җаным. Байлар картаймыйдыр. Менә безнең авылның Минушы барые бит. Шул Казанда кибет ачып баеп киткән, карт хатынын аерып яшь хатынга өйләнгән. Монда яшь марҗасын күрсәтергә апкайтты. Ул да шулай: йөрәк картаймый, Мәһруй апа, ди. Ирләрне байлык яшәртәдер, югыйсә элекке хатыннарын аерып яшькә өйләнмәсләр ие.

Сәрбиназ. Кеше тикшерү синең белән минем эш түгел, апа җаным. Үзләрен-үзләре беләләрдер. Ә Гәрәй Мингалиевичның беренче хатыны аждаһаның да аждаһасы иде.

Мәһруй. Шулайдыр, сеңлем җаным. Аерган хатын аждаһа була инде ул.

Сәрбиназ үз сүзләреннән кыенсынып китә.
Мәһруй, аның уңайсызлануын күреп, сүзне икенчегә борып җибәрә.

Мәһруй. Озакка кайттыгызмы?

Сәрбиназ. Юк, берне кунабыз да китәбез.

Мәһруй. Синең шул инде, Гәрәең ачка үләр дип куркасыңдыр. Үлмиләр алар, ресторанга барып ашыйлар да кайталар. Көнлек хатыннар да күбәйде хәзер.

Сәрбиназ. Уч төбе хәтле авылда ятып каян беләсең син барсын да?

Мәһруй. Белмәскә! Әнә бит *(телевизорга ымлый)* көне-төне күрсәтеп тора. Үзең беләсең инде, минем йокы гомер буе начар булды. Көндезләрен бераз черем итеп алам да төнлә тилибизор карыйм. И-и, без яшь чакта кайсы җиребездә нәрсә барын да белмәгәнбез икән.

Сәрбиназ. Син, апай җаным, әллә ниләр сөйли башлагансың. Элек алай түгел идең бер дә.

Мәһруй. Элек надан булганбыз, сеңлем җаным. Сыерны сатып менә бу тилибизорны алгач, рәхәтләндем. Бөтенесен пудрәт карыйм. Без яшь чакта мондый нәрсәләрне күрсәтсәләр, мал-туар асрап та азапланмаган булыр идек. Ярык итәкле күлмәк киеп, ирен кызартып ирләребезнең эштән кайтуын караватка ятып кына көтәр идек.

Сәрбиназ. Син бигрәк инде, апай. Аза башлагансың.

Мәһруй. Андый хатыннарны ирләре ташламый. Авыр эш эшләп куллары сөялләнгән, киеменнән дуңгыз фермасы исе килгән хатыннарны ирләр нишләп яратсын? Мин тилибизор карый башлагач, иремнең нигә ташлаганын аңладым. Без ирләргә эшләп ярарга тырыштык. Әнә минем Минһаҗның яңа хатыны төшкә хәтле йоклый. Төнлә ирен иркәли.

Сәрбиназ *(бераз дорфа итеп)*. Син беләсең инде барсын да.

Маһруй. Беләм шул. Беркөннәрне, персидәтелгә йомышым барые дип, өйләренә кердем мин боларның. Яшь хатын анадан тума шәрә караватында аяк бармакларын кызартып утыра, җаныкаем. Аяк тырнагын кызартыр өчен нигә чишенеп ташлау кирәк булгандыр.

Сәрбиназ. Җитәр, апай, җитәр. Кешеләрдә безнең эшебез юк.

Маһруй. Без наданнар шул, сеңлем җаным. Менә син дә Казанга китеп казан астына ягудан ерак китмәдең.

Сәрбиназ. Мин тормышымнан зарланмыйм.

Маһруй. Зарланып нишлисең? Гомер узган, күлмәк тузган. Әгәр дә мәгәр мин шундый олы түрәдә эшләсәм, берәрсен эләктерми калмас идем. Андый кешеләргә кемнәр генә килми, җаныкаем. Әнә бит киноларда күрсәтеп торалар: «ялгыш кына» түшләре ачылып китә, юынган җирләренә «ялгыш кына» ирләр килеп керә, «ялгыш кына» караватка егылалар. Сиңа да «ялгышкалау» гөнаһ булмас иде.

Сәрбиназ, апасының сүзләрен килештермичә, әңгәмәне башка юнәлешкә борырга теләп, тәрәзәгә карый. Анда Айсылу берничә баланы машинасына утыртып урам әйләндерә. Балалар, машинаның тәрәзәләрен ачып, шатланып кычкырышалар. Авыл кечкенә. Урамда пычрак вакытта авыр машиналар йөрүдән тирән эзләр калган. Айсылу кайвакыт тирән эзгә төшә дә, машинаның төбе җиргә тиеп туктап кала. Андый чакларда балалар машинадан сикереп төшәләр дә «Мерседес»ның бер як кырыеннан күтәрешәләр. Балаларга олыраклар да кушыла. Машина чокырлы юлдан чыга. Сәрбиназ үзе чокырдан чыккандай җиңел сулап куя. Ул урамга карап утырган арада, Маһруй шкафтан бер шешә чыгарып өстәлгә куя.

Маһруй. Сеңлем җаным, менә монда минем бик шифалы бәлзәмем барые. Килен югында шуны бераз кабып куйыйк әле.

Сәрбиназ. Әстәгъфирулла! Нишләвең бу, апай җаным?

Маһруй. Кибеткә беркөннәрне шушы бәлзәмне кайтарганнарые. Күп кенә карчыклар алды. Бөтен җиргә файдасы бар.

Сәрбиназ. Шаяруыңмы, мине сынап карарга теләвеңме бу, апай?

Маһруй. Сез анда Казанда моннан хәтәррәкләрен дә капкалыйсыздыр.

Сәрбиназ. Юк-юк. Айсылу кергәнче алып куй моны.

Маһруй. Айсылуың Алланың кашка тәкәсе түгелдер әле.

Сәрбиназ. Айсылуга сүз әйтмә.

Маһруй. Ярый, ярый. Айсылуга сүз әйтмәм, ә менә сиңа әйтәм. Яши белеп яшәмисең син. Ни ир рәхәте күрмәдең, ни корган дөньяң юк. Менә моннан да *(бәлзәмгә ымлап)* йөз чөерәсең. Беләсең килсә, сеңлем җаным, хәзер авылда карчыклар да типтереп яшиләр. Пинсе килеп тора. Эшләр чакта дуракланып эшләдек. Ирләр белеп эчә икән. Бөтен кайгы-хәсрәтләреңне оныттыра бу, җаныкаем.

Сәрбиназ. Кайгысы белән бергә шатлыгы да онытылмыймы соң?

Маһруй. Онытылсын. *(Бер чынаякка бәлзәм сала да эчеп җибәрә һәм тиз-тиз генә авызына берничә виноград ыргыта.)*

Сәрбиназ. Чын алкашларча кыланасың син, апай.

Маһруй. Без берни белми яшәгәнбез икән. Их-ма! *(Кикереп куя. Җырлап та җибәрә.)*

Әнә килә автомобиль,
Ник безгә утырмаска?
Бөтен дөнья котырганда,
Ник безгә котырмаска?

Сәрбиназ. Ярар, апай, табынны җыештырыйк. Юкса Айсылу керә башлар. Яхшы түгел.

Маһруй. Җыен маңкадан куркып яшәр вакыт узган инде.

Сәрбиназ табынны җыештыра. Маһруй бәлзәмне тагын бер-ике йотып куя. Сәрбиназ өстәлдәге шешәне дә ала.

Сәрбиназ. Зинһар, апа, кеше алдында оятка калдырма.

Маһруй. Ай, Аллам, чебеннән дә куркып яшәдең инде. Синең урыныңда булсам, мин дөньясын җимертеп яшәр идем. Әй, сүләгән булам тагы, син дә тик кенә ятмыйсыңдыр әле, җаныкаем. Гәрәең ни гомер хатынсыз яшәде. Чеметкәләми калмагандыр. Син астыртын. Без генә ул бөтенесен кычкырабыз. Әйт дөресен, Гәрәең кергәли бит яныңа?

Сәрбиназ. Оятсыз да икәнсең, апай.

Маһруй. Нәрсә соң ул оят? Ул кайда була?

Сәрбиназ. Мондый көфер сүзләр сөйләргә ничек телең бара? Алладан куркыр идең.

Маһруй. Мин совет тәрбиясе алган кеше. Безне, Алла юк, дип үстерделәр.

Сәрбиназ. Әтиләр гомер буе биш вакыт намаз укыдылар, җәйнең иң кызу көннәрендә дә уразасын тоттылар.

Маһруй. Синең атаң укыгандыр...

Сәрбиназ. Безнең әтиләр бертуганнар. Бертөрле тәрбия алганнар. Бабаларыбыз динле булган.

Маһруй. Бертөсле тәрбия алсалар да, икесе ике юлдан киткән. Синең атаң көтү көткәндә, безнең атабыз, картайган көнендә партиягә кереп, склад мөдире булып эшләде. Сугышка да китмәде. Кешеләр

ачка шешенгәндә, без авыз тутырып ипи ашадык.

Сәрбиназ. Бу мактана торган нәрсә түгел. Моңа хурланырга кирәк.

Маһруй. Хурланучылар күптән үлеп бетте. Заман һәрвакыт көчленеке.

Айсылу керә. Аның битләре кызарган. Күзләреннән нурлар сибелеп тора.

Айсылу. И апакайларым! Авыл балалары бөтенләй икенче инде. Кечкенә генә нәрсә өчен дә очына-очына шатлана беләләр.

Сәрбиназ. Син авыл урамында чокыр-чакырларга төшеп машинаңны ватма тагын. Кайта алмый калуыбыз бар.

Айсылу. Ватылмас. Алар бит машинаны күтәреп йөртергә әзерләр. Бер шәп урын табып машинаны юып кайттык. *(Тәрәзәгә ымлап.)* Әнә ялтырап тора.

Маһруй *(эре генә)*. Хәзер авылда да кеше саен машина. Берәр җирдән урап кайтсалар, чишмә буена машиналарын юарга чабалар. Чишмәләрне пычратып бетерделәр инде. Авылыбызның исеме генә калып бара.

Айсылу. Без Аю чокыры дигән җирдә юдык, апа. Чокырның төбендә бераз су бар икән, малайлар шуннан полиэтилен капчык белән су ташыдылар.

Маһруй ни өчендер Айсылуны яратмый. Кызның артык чибәрлегеннән көнләшәме, әллә Гәрәй Мингалиевичка тормышка чыкканга ачуы киләме. Мөгаен, шулайдыр. Гәрәй Мингалиевич беренче хатынын аерып җибәргәч, Маһруй, бу хәбәрне Сәрбиназ аша ишетеп, үзенең олы кызы Сәрияне ияртеп Гәрәйләргә барган иде. Гәрәйнең аларны ничек каршы алуы Маһруйның әле дә исендә. Шул вакыйганы искә төшерү күренеше.

**ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Гәрәйләргә кызы Сәрияне җитәкләп Маһруй керә.

Маһруй. Исәннәрмесез, Гәрәй Мингалиевич. Менә сезгә кызым белән кунакка килгәниек әле.

Гәрәй. Кунакларның күңелен әнә Сәрбиназ күрер. Мин ашыгам.

Ул кунаклар килгәндә кырынып утырган була. Эшен бетереп, чистарынгач, өс-башларын алыштырырга икенче бүлмәгә чыгып китә башлый. Ләкин Маһруй аның каршысына төшә.

Маһруй *(Сәрияне алгарак этеп)*. Менә бу минем кызым Сәрия була.

Гәрәй. Ярый, әйбәт.

Маһруй. Кызыма быел егерме ике яшь тулды. Бер кашык суга салып йотарлык.

Сәрия. Егерме ике түгел, егерме җиде тулды.

Маһруй *(кызының кабыргасына төртеп)*. Шәһәр кызлары кебек азып-тузып йөрмәде. Бер тапкыр да кияүгә чыгып карамады.

Сәрия *(беркатлы кыз. Ул «Беренче театр»дагы Биби кебегрәк)*. Нишләп чыкмыйм ди. Ике тапкыр чыгып карадым бит инде.

Маһруй *(Сәриягә ыслап)*. Дәшмә! Ә сез, Гәрәй Мингалиевич, аның сүзен чынга алмагыз. Яшьләр шаяртырга яратучан була.

Сәрия. Нишләп шаяртыйм? Сул күзенә ак төшкән завскладка бирдегез. Миңа гел шул күрми торган күзе белән генә карый башлагач, кайтып киттем. Ул күзе аның минем бер җиремне дә күрмәде. Бәлки, ике күзенә дә ак төшкән булгандыр. Әйе. Аннары дуңгыз фермасында эшләүче Зарифҗанга бирдегез. Дуңгыз булып чыкты, куып җибәрде.

Маһруй. Юкны сөйләмә әле, кызым.

Сәрия. Нишләп юк булсын. Синең белән йоклаганчы, дуңгыз белән йоклыйм, дип, үз алдыңда әйтте бит.

Гәрәйгә боларның сүзләре кызык булып китә.

Гәрәй. Хөрмәтле кунаклар, сезнең белән сөйләшү бик кызыклы булды, ләкин минем вакытым юк. *(Сәриягә күз кысып.)* Молодец, һәрвакыт шулай дөресен сөйләргә кирәк.

Сәрия. Ә мин гел дөресен сөйлим. Бервакыт көтүче абзыйга ашарга илтергә баргач, минем су коенганны карап торды да: «О, син нинди матур. Яңа өлгергән алма кебек. Минем сине ашап карыйсым килә», — диде.

Маһруй. Туктыйсыңмы-юкмы син юк-барны лыгырдавыңнан?

Сәрия. Нишләп юк-бар булсын? Булды бит. Бик яратып ашады ул минем «алмамны». Миңа да аның «бананы» ошады.

Гәрәй рәхәтләнеп көлә.

Маһруй. Сезне күргәч, һушын җуебрак җибәрде ул. Сез аңа ышанмагыз. Сезнең кебекләр алдында кем генә югалып калмас икән?

Сәрия. Бу абзый миңа ошамый да, беләсегез килсә.

Гәрәй *(шаяруга җитди төс биреп)*. Минем кай җирем ошамый сезгә?

Сәрия. Муеныңа муенчак бәйләвең ошамый.

Гәрәй. Ә-ә, галстукмы? Хәзер салып ташлыйбыз аны. *(Галстугын сала.)* Йә, хәзер ошыйммы инде?

Сәрия *(Гәрәйне әйләнеп чыга)*. Юк, муенчагыңны салгач, тагын да ямьсезләндең.

Маһруй. Тыңламагыз шуны, Гәрәй Мингалиевич. Килеп керү белән аның сезгә күзе төште.

Сәрия. Әстәгъфирулла! Минем аңа күзем төшмәде. Мондый абзыйлар безнең авылда да җитәрлек. Беркөннәрдә бригадир Зариф үзләренә апкереп...

Маһруй. Җитте! Бүтән авызыңны ачасы булма. Башыңны дуракка саласың, юньсез.

Сәрбиназ керә.

Гәрәй. Кунакларны синең кулга тапшырам, сыйла, булдыра алган кадәр хөрмәт ит. Ә мин киттем. *(Чыгып китә.)*

Сәрбиназ. Нишләп киләсе иттегез, апа?

Маһруй. Тоттык та килдек.

Сәрбиназ. Килгәч әйбәт булган.

Маһруй. Безне күргәч, Гәрәең качты, күреп торам.

Сәрбиназ. Көтмәгәндә-уйламаганда бит.

Маһруй. Безне бер җирдә дә көтеп тормыйлар. Шуңа күрә көтмәгәндә-уйламаганда килергә туры килә.

Сәрбиназ. Әйдәгез, минем якка керик. Шунда сөйләшербез.

Маһруй. Кереп торырга микән? Менә бу *(Сәриягә күрсәтә)* аңгыра сарык бөтен планны бозды.

Сәрбиназ. Ничек?

Маһруй. Шушы аңгыра сарыкны синең Гәрәеңә сылап булмас микән дип йөридерием.

Сәрбиназ. Гәрәй Мингалиевичның күзе бик очлы. Кешенең тышындагысын гына түгел, эчендәгесен дә күрә ул.

Маһруй. Кемгә охшап шушы кадәр аңгыра булып тугандыр, ис-акылым китә.

Сәрия. Кемгә охшап булсын. *(Сәрия әнисенә карап куя.)*

Маһруй. Җирбит!

Сәрия. Син аңгыра булмасаң, мине Гәрәй абзыйга бирергә йөрмәсиең. Ул кем дә мин кем?

Маһруй. Акыллы ир-атка синең кебек аңгыра хатын кирәк. Кем белән йөрсә дә — күрмәскә, кайда булса да — сорашмаска.

Сәрия. Юк, мин сорашырга яратам. Минем «алмамны ашаган» көтүчедән дә: «Алмам тәмле булдымы?» — дип сорадым. «Тәмле булды, ешрак ашат», — диде.

Маһруй. И-и, мәнсез, оялмыйча нәрсә сөйләп тора.

Сәрия. Ә мин дуңгыз караучы Зарифҗан берәр җирдә кунып кайтса: «Аның «алмасы» тәмлерәкме, минекеме?» — дип сорый идем.

Сәрбиназ. Җитте инде, әйдәгез, миңа кереп чәй эчеп алырсыз.

Сәрия. Минем банан ашыйсым килә.

Сәрбиназ аларны үз бүлмәсенә алып кереп китә. Вакыйга яңадан Маһруйлар өенә күчә. Тышта кич җитеп килә. Көтү кайткан тавышлар ишетелә. Маһруй тәрәзәгә күз салып ала.

Маһруй. Аллага шөкер, атым юк урамда, кайгым юк буранда. *(Караватка урын җәя башлый.)* Сезгә бүген урын җәеп торыргамы, юкмы?

Сәрбиназ. Безне йоклатмаскамыни исәбең?

Маһруй. Капка төбендә шундый машина торганда, барыбер йоклап ята алмассыз дим.

Сәрбиназ. Авыл җирендә машинага тиюче булмас, шәт.

Маһруй. Капка төбендәге машинаны гына түгел, хәзер бикле абзардан сыерыңны алып чыгып китәләр. Хәзер бит дөнья тулы алкаш та наркоман.

Сәрбиназ. Ишегалдына кертеп булмый, капкаң тар.

Маһруй. Сез кайтасын белмәдем бит, киңәйттергән булыр идем.

Айсылу. Кайгырмагыз, Маһруй апа. Минем машинаның сигнализациясе ышанычлы.

Маһруй. Ансын үзегез беләсездер инде, әйттем исә кайттым. Минем караватка икегез сыйсагыз, урынны бергә генә җәям. А то бер кич кунак артыннан да бер йөк кер юарга туры килә.

Айсылу. Без Сәрбиназ апа белән идәндә йокларга да риза.

Йөгереп машинасына чыгып китә. Анда кабартмалы зур матрас һәм җаймә, одеял ише нәрсәләр бар икән. Кабартмалы матраска насос тоташтырып аягы белән качать итеп тын кертә, матрас тигез булып кабара. Айсылу аның өстенә ак җаймә җәя. Үзләре белән кечкенә мендәрләре дә бар икән. Берничә минуттан урын әзер була.

Маһруй. Минем караватта ятарга җирәндегез инде алайса?

Айсылу. Эш җирәнүдә түгел, Маһруй апа. Сезгә мәшәкать ясыйсыбыз килми. Менә бит әле савыт-сабаларны сезгә юарга калдырганбыз икән.

Айсылу җитез хәрәкәтләр белән савыт-сабалар юа. Сәрбиназ аңа сокланып карап тора. Маһруй да кырын-кырын күз ташлап ала. Савытлар юылып бетә.

Айсылу. Мин машина янына чыгып керәм, сез ята торыгыз. *(Чыгып китә. Башкалар йокларга ята.)*

**СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Авылдан ерак түгел урман аланы. Аланга кара машина килеп туктый, аннан өч кеше төшә. Алар тирә-якны күзәтәләр. Шикләнерлек нәрсә күрмәгәч, тынычланып калалар. Бу өч кешенең берсе — Альберт, икенчесе, озын буйлысы, Карчыга. Кыска буйлысы — Тәпән. Карчыганың кулында караңгыда күрсәтә торган бинокль. Ул агач ботагына менеп утырган да Айсылулар машинасы килеп туктаган өйне күзәтә.

Альберт. Йә, нәрсә анда?
Карчыга. Чибәр ханым бала-чагалар белән мәш килә.
Альберт. Әйдә уйнасын. Бу аның соңгы уйнавы булыр.
Тәпән. Нәрсә, без аны кых итәбезмени?
Карчыга. Без канлы уен уйнамыйбыз.
Альберт. Әйе, безгә аның машинасы җитеп торыр.
Тәпән. Хәзергә.
Альберт. Әйе, хәзергә. Ә соңыннан, бәлки, кети-мети уйнарга үзе дә кирәк булыр.
Карчыга. Хыялга бирелүне туктатырга! Атакага әзерләнә башлыйбыз!
Альберт. Нәрсә, әллә өйдә ут сүндеме?
Карчыга. Юк, сүнмәде әле. Чибәр ханым машинасын бикләп кереп китте.
Тәпән. Авылда башка машиналар күренмиме?
Карчыга *(бинокленнән аерылмый гына)*. Урамда агачлар күп. Шулар арасында гына булмаса!
Альберт. Әйдә, караңгылык куерганчы, очып кына авылны урап килик. *(Машинасының капотына суккалап ала.)* Минем бахбай авыл юлларында да шәп чаба.
Карчыга *(ботактан сикереп төшә)*. Чапмый гына тор. Урланган атның юлда усыруы бар.
Тәпән. Нәрсәгә әкият сатабыз соң? Әйдәгез, бара торыйк.
Карчыга. Баш урынында кабак булса да, кайвакыт җүнле сүз чыгып куя үзеңнән.
Тәпән. Ха-ха-ха!
Карчыга. Кешнәмә, яратмыйм шул кешнәвеңне.
Тәпән. Кирәк җирдә кешнибез, кирәк җирдә тешлибез. Ха-ха...
Альберт. Әйдәгез, атлый башлыйк.
Карчыга. Әйдәгез. *(Китәләр. Карчыга Тәпәнгә аңлата башлый.)* Машинасы сигнализациягә куелган булса, барлык чыбыкларны өз.
Тәпән. Ә ничек кабызабыз?
Карчыга. Кабызмыйбыз. Бераз этеп барабыз да үзебезнең машинага тагып китәбез.
Альберт. Алайса, нигә соң без сразы машина белән бармыйбыз?
Карчыга. Тегенди-мондый хәл булса, төрлебез төрле якка таярга кирәк булачак. Аңгыра.
Альберт. Машинаны калдырып таяргамы? Юк инде, кәкре танау, мондый җай гел чыгып тормас.
Карчыга *(Альбертның авызына менеп төшә)*. Бирермен мин сиңа кәкре танавыңны!
Тәпән. Авылга якынлашабыз. Нәрсәгә каркылдашасыз?

Барсы да беразга тынып кала. Адымнары сагая. Менә алар машина янына килеп җитәләр. Машинага кагылмыйча гына аны урап чыгалар. Шунда берсе машинага әкрен генә сугып куя. Берниндн тавыштин чыкмый. Димәк, сигнализациягә куелмаган.

Карчыга *(коймадан үрелеп тәрәзәгә күз сала. Өйдә тын һәм караңгы)*. Әйдәгез, машинаны этеп карыйк. *(Этәләр, машина кузгалмый.)*
Тәпән. Тормозга куйган. *(Куенынннан монтировка чыгарып ишекне шылт кына итеп ача. Тормоздан ычкындыра.)* Хәзер этәргә була.
Альберт. Нигә этеп җәфаланырга? Чыбыкларны тоташтырып ялт кына кабызабыз да әллүк!

Карчыга. Ашыккан ашка пешкән, ди. Әйдәгез, этәбез.

Альберт белән Карчыга этә башлый. Тәпән рульгә утыра. Авыл юлы дөмбәскәле, машина бик авыр тәгәри.

Карчыга *(Тәпәнгә)*. Төш! Этеш! Һоп-па, киттек!
Барсы бергә. Киттек!

Альберт белән Карчыга машинаны арттан, ә Тәпән алгы сул ишекне ачып алдан этә. Машина шактый җиңел бара. Ләкин караңгыда Тәпән алдагы чокырны күреп җиткерми, машинаның бер тәгәрмәче чокырга төшә. Карчыга белән Альберт Тәпәнне читкә этеп җибәрәләр.

Карчыга. Сукыр тәре, нәрсә карап бардың?
Тәпән. Анаңныкын!
Карчыга. Ә, шулаймыни?! *(Тәпәннең касыгына тибә, Тәпән бөгелеп төшә.)*
Альберт. Болай булмый бу. Мин кабызам машинамны.
Карчыга. Машинаңны? Менә синең машинаң кайда! *(Альбертның аяк астына тондыра.)*

Болар тарткалашкан арада, әллә каян гына омончы киемендәге ике таза егет килеп чыга да берсе рульгә утырырга маташкан Карчыганың борын төбенә саллы гына менеп төшә, икенчесе Альбертны дөмбәсләп ташлый. Тәпән качмакчы була, ләкин кыска аяклының өч адымын бер генә сикереп теге таза егетләрнең берсе каптыра. Яшен тизлегендә эшләнгән бу хәлдән каракларның рухы сына. Алар хәтта омончы киемендәге егетләрнең ничәү икәнен санарга да өлгермиләр.

Беренче сакчы *(Карчыганың чигәсенә пистолет терәп)*. Илтеп куегыз машинаны үз урынына!
Карчыга. Булмый. Алгы тәгәрмәч чокырга төште.
Икенче сакчы. Күтәреп чыгарыгыз. А ну-ка, Тәпән!

Тәпән болар авызыннан үз исемен ишетүгә калтырап төшә. Караклар машинаны чокырдан чыгарып үз урынына илтеп куялар. Алар качарга омтылыш ясыйлар, ләкин шул вакыт фараларын ялтыратып болар өстенә менәрдәй булып, урамның каршы ягындагы тыкрыктан бер машина килеп чыга. Аның рулендәге егет тә омончы киеменнән. Аларның барсының да йөзендә кара битлек. Алар тәмам мәлҗерәп төшкән каракларның кулларын артка каерып бәйләп, артларына тибәтибә машинага утырталар.

Карчыга. Күреп торам, сез дә ак «Мерседес»ны урларга килгәнсез. Әйбәт кенә эшләсәк, табышны бүлешер идек.
Беренче сакчы *(йодрыгын йомарлап)*. Менә моны күрәсеңме?
Карчыга *(мыгырдап)*. Күрәм.
Беренче сакчы. Күрсәң, бүтән авызыңны ачма.
Тәпән. Без сезне судка бирәбез. Ак «Мерседес» безнең үзебезнеке.
Икенче сакчы. Сезнеке урман аланында калды.
Тәпән. Урласалар, сез гаепле булачаксыз.
Беренче сакчы. Урламаслар. Бүген үк без аны хуҗасына тапшырачакбыз.

Караклар бер-берләренә карашып алалар. Машина текә борылышта боларны бер-берләренә кыса. Шунда Карчыга башы белән янында утырган сакчыны сөзә. Сакчы шоферга ым кага. Машина кинәт туктый. Карчыганың артына тибеп машинадан төшереп калдыралар. Бераз баргач, Тәпәнне типкәләп аталар.

Беренче сакчы *(Альбертка)*. Ә син милиция идарәсендә җавап бирерсең.
Альберт. Сез минем папаняның кем икәнлеген беләсезме?

Сакчылар үзара карашып алалар.

Альберт. Ул сезне кандала кебек сытачак.
Икенче сакчы. Аларын милициягә сөйләрсең инде.
Беренче сакчы. Шунда беррәттән наркотикларны каян алганыңны да әйтерсең.

Альбертның эченә ут йөгерә. Димәк, болар бөтенесен белә. Ул ыргыла, бәргәләнә башлый. Сакчыларга аны йодрык белән бераз тынычландырып алырга туры килә.

Озакламый алар шәһәрнең милиция идарәсенә кайтып җитәләр. Альбертны бер камерага ябып калдыралар.

**ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Авыл иртәсе. Сирәк-мирәк әтәчләр кычкыра, этләр өрә. Көтү күптән киткән. Бала-чагалар әле уянмаган. Айсылуның машинасы тирәсендә кайнашучы юк. Мәһруйлар өендәге кунаклардан иң беренче Сәрбиназ уяна.

Сәрбиназ. И-и, бик озак йоклаганбыз түгелме соң? Юынып керергә кирәк. *(Сәрбиназ сумкасыннан*

*сөлге алып иңенә сала. Ишегалдына чыгу белән, Айсылуның машинасына күз сала.)* Шөкер, тимәгәннәр. Хәзер угрылар авылда да җитәрлек. Айсылуның фәрештәләре саклагандыр инде. *(Юынгыч янына килә.)*

Айсылу торып чыга.

Айсылу. Хәерле иртә, Сәрбиназ апа!

Сәрбиназ. Хәерле иртә, сандугачым. Йокылар ничек булды, сандугачым?

Айсылу. Үлеп йоклаганмын.

Сәрбиназ. Мин дә. Уянып китеп сәгатькә карауга йөрәгем жу итеп китте. Гәрәй Мингалиевичка ашарга әзерләмәгәнмен бит, дим. Янәшәдә син ятканны күргәч кенә авылда икәнлегебезне төшендем. Ничек соң, кызым, бүген кайтабызмы?

Айсылу. Белмим әле, Сәрбиназ апа. Бәлки, иртәнге ашны ашагач, урманга менеп төшәрбез.

Сәрбиназ. Гәрәй Мингалиевич сагынгандыр инде үзеңне.

Айсылу. Сагынсын. Кадерлерәк булырмын.

Сәрбиназ. Болай да инде ул син дип җан атып йөри.

Сәрбиназ кычкырып көлә. Аның көлүе бөтен ишегалдына ишетелә. Көлү авазы Маһруйны да уята. Ул киерелеп-сузылып болар янына чыга.

Маһруй. Нәрсәгә бөтен авылны яңгыратып шаркылдыйсыз? Әллә әтәчегез күкәй салдымы?

Сәрбиназ. Кызык булганга көләбез.

Маһруй. Бәлки, миңа да әйтеп көләрсез.

Сәрбиназ. Шатлыкны әйтеп аңлатып булмый аны, апа.

Маһруй *(ачуланып)*. Шулай инде, кызлар ярыктан да көлә.

Сәрбиназ апасының сүзләре үзенә төбәлгәнен аңлый, ләкин иртән үк кәеф бозасы килмәгәнлектән, апасына җавап биреп тормый.

Барысы да юынып беткәч, ашарга утыралар. Газда чәй кайный. Чынаяклар чылтырый. Иртәнге аш озакка бармый. Айсылу машина ачкычларын алып урамга чыгарга җыена.

Айсылу. Көн бик матур булырга охшый. Бәлки, җыйнаулашып урманга менеп төшәрбез?

Маһруй. Ә нигә? Гүләйт итеп кайту мешать итмәс. Синең импортный машинаңда урам урыйк әле. Күрсеннәр Маһруйның кемлеген.

Башкалар җыенып кала, Айсылу машинасы янына чыга. Ул, ишеген ачарга теләп, йозак тишегенә ачкыч тыгарга тели, шунда ишекнең каерылганлыгын күрә.

Айсылу. Ой! Кичә бала-чагалар белән мәшәләнеп сигнализациягә куймаганмын икән. Берәр исерекнең кулы кычыткандыр. Ярый әле артык беленеп тормый.

Сәрбиназ белән Маһруй сумкалар күтәреп Айсылу янына чыгалар. Сәрбиназ Айсылуның кәефе төшүеннән үк нидер булганын аңлый.

Сәрбиназ. Нәрсә, кызым?

Айсылу. Менә ишекне каерганнар!

Маһруй. Ха-ха-ха! Әйттем мин сезгә! Каяле, кая? Нык каерганнармы? *(Ишекне карый.)* И-и, шуны сүз итеп сөйләп торасыз. Бернәрсә булмаган бит. Трусигын тарткалап караганнар, кызына тимәгәннәр.

Сәрбиназ. Син, апа, бөтенләй азып беткәнсең монда. Авызың тулы ямьсез сүзләр.

Айсылу ишекнең йозагын тикшерә. Йозак бикләнә дә, ачыла да икән.

Маһруй. Йә, ач инде машинаңны. Кататься итеп кайтыйк.

Айсылу. Урманга менеп йөрмәбез, ахры. Безгә Казанга кайтып берәр автосервиска кереп чыгарга туры килер. Бу килеш Гәрәй Мингалиевич күзенә ничек күренәсең?!

Маһруй сумкасын җиргә ыргыта.

Маһруй. Шул Гәрәй дип калтырап яшисез инде. Ул сезне тәмам колга әйләндергән.

Сәрбиназ. Бәйләндең инде шул Гәрәй Мингалиевичка! Машинасын югалтып кайтса да, ул Айсылуга сүз әйтмәс иде.

Маһруй. Әйтмәс! Югалтып карагыз әле. Шул көнне үк икегезне тиң өеннән куып чыгарыр. Кеше баеган саен комсызлана. Бер тиен өчен чукынырга тора алар.

Айсылу *(Маһруйга ачу сакламый)*. Маһруй апа, без китәбез инде. Сый-хөрмәтегез өчен рәхмәт.

Маһруй. Кәнтәйләнеп рәхмәт әйтеп маташмасана. Эчеңнән мине буып үтерергә торганыңны

күрмиммени мин?

Айсылу. Кайчагында күзләр дә ялгыша, Маһруй апа.

Маһруй. Күзләрем ялгышырга тилебәрән орлыгы ашамадым бит әле мин.

Сәрбиназ. Әнә шул шешәдәге «яшел елан» нәкъ шул тилебәрән орлыгыннан ясала.

Маһруй. Мине үрәткәнче, күтеңне үрәт. Ир-ат күрми корып бетмәсен.

Айсылу. Әйдә, Сәрбиназ апа, өйдәге әйберләрне алып чыгыйк. Давыл килә бугай.

Айсылу белән Сәрбиназ өйгә кермәкче булалар, ләкин Маһруй ишекне бикләгән икән.

Маһруй. Керегез, кер, ватып керегез.

Сәрбиназ. Ватып тормыйбыз инде, апа, үзең генә ачарсың.

Маһруй. Берегез, бер, икенчегез икенче табанымны яласагыз — ачармын. *(Маһруй туфлиләрен салып ташлый. Эскәмиягә утыра һәм аякларын алга суза.)* Йә, кайсыгызга кайсы табаным ошый. Башлагыз. Ә-ә, теләмисезме? Теләмәссез шул. Сез симез байлар табанын гына яларга өйрәнгән. Минем табанны ялаганга сезгә берни дә тәтеми, шуңа яламыйсыз.

Сәрбиназ. Сине ташлап җизни дөрес эшләгән икән. Әйдә киттек, Айсылу кызым.

Айсылу. Киттек!

Алар машина эченә кереп утыралар да ялт кына кузгалып китәләр. Икесе дә кәефсез.

Айсылу. Түбәнлеккә төшү бик тиз, күтәрелү генә авыр.

Сәрбиназ. Ул яшьтән үк холыксызрак иде. Ире ташлагач, бөтенләй азды. Җизни, үзен гаепле сизепме, ай саен аңа акча биреп тора. Пенсиясен дә кабат каратты. Эше юк, ә хатын-кызны эштән аердыңмы, бозылды диген инде. Намаз укып, Аллага шөкрана итеп утырырга да бит.

Айсылу. Аның сүзләрендә дә күпмедер хаклык бар. Күбебез акчалы ирләр эзлибез.

Сәрбиназ. Син үзеңне дә әллә шундыйлар рәтенә кертмәкчеме?

Айсылу. Мин дә шундыйлардан ерак китмәгән.

Сәрбиназ. Андый гөнаһлы сүзләр сөйләмә әле, Айсылу кызым. Сез яратышып өйләнештегез.

Айсылу *(уйланып)*. Ансы шулай, Сәрбиназ апа. Тик сезгә дөресен әйтәм, күңелне нииндидер шик кимереп куйгалый.

Сәрбиназ. Нинди шик?

Айсылу. Әгәр, мин әйтәм, Гәрәй Мингалиевич бер көтүче булса, мин аны яратыр идем микән?

Сәрбиназ *(ачуланып)*. Әйттең тагы!

Айсылу. Йә, көтүче булмасын ди. Әнә теге тасма телле кара-чутыр монтерны ярата аламмы мин?

Сәрбиназ. Син артыгын эчкә кермә, кызым. Ходай сиңа Гәрәй Мингалиевич белән очрашырга язган икән, ызначит, язмыш шулай кушкан.

Айсылу. Бәлки, язмыштыр. Ләкин бит миңа караучылар булмады түгел.

Сәрбиназ. Сиңа әле дә бөтен егетләр карап китә.

Айсылу *(көрсенеп)*. Карадылар да, таладылар да...

Сәрбиназ. Нәрсә, кызым? Әллә?..

Айсылу. Әлләсе дә, әлбәсе дә булды. Тик миннән үткәннәрне сорашма, Сәрбиназ апа. Юкса чыгырымнан чыга башлыйм.

Сәрбиназ. Ярар, сорашмам. Тик шуны гына беләсем килә: синең үткәннәреңне Гәрәй Мингалиевич беләме?

Айсылу. Белә.

Шактый вакыт сөйләшми кайталар. Юл кырыенда уңга борылып өч йөз метр үткәч, автосервис барлыгын күрсәтүче билге күреп, Айсылу машинасын шунда бора.

Айсылу. Кереп чыгыйк әле, бәлки, тиз генә эшләп бирерләр.

Машина автосервиска кереп туктый. Ул туктауга ук Айсылулар янына ике егет йөгереп килә. Айсылу машинасыннан төшеп аларга нидер әйтә. Егетләр машинаның ишеген карыйлар. Сәрбиназ да машинадан төшә. Егетләрнең берсе машинаны бокска алып кереп китә. Икенчесе кунакларны кафега чакыра.

Егет. Сез, туташ-ханымнар, тыныч кына чәй эчеп алыгыз. Машинагызны тиз эшләрләр, борчылмагыз.

Сәрбиназ. Без эчеп кенә чыккан идек, энем.

Егет. Эчәсегез килмәсә, ял итеп утырырсыз.

Егет аларны култыклап кафега алып керә. Кафеда кеше шактый күп. Тавышлар куелыгы, әле ачылып, әле ябылып торган ишек шыгырдавы мондагы сүзләрне ишетергә мөмкинлек бирми. Сәрбиназ белән Айсылу кешеләр арасында күпмедер вакыт югалып тора. Бераздан аларның сулъяк почмактагы бер өстәл янында чәй эчеп утырганнары күренә. Кәефләре күтәрелә төшкән.

Сәрбиназ нәрсәдәндер кычкырып-кычкырып көлә. Болар чәй эчкән арада, мастерскойда эш кайный. Бераздан машинаны бокстан чыгаралар. Егетләрнең икенчесе кафеда утыручы Айсылулар янына килеп, машинаның әзер икәнлеген әйтә. Сәрбиназ белән Айсылу урыннарыннан сикереп торалар. Айсылу машинасының ишеген карый. Ишектә бернинди эз калмаган.

Айсылу. Молодцы, егетләр! Кулларыгыз алтын икән. *(Сумкасын чыгарып кәшилүген ала. Егетләр акчаны кассага түләргә кирәклеген әйтәләр. Айсылу барып түли.)*

Сәрбиназ *(машинага кереп утыргач)*. Кара инде, бездә дә эш белүче кешеләр бар икән.

Айсылу. Хәзер бит конкуренция. Начар эшләсәң, бик тиз бөләсең.

Сәрбиназ. Үзләре нинди культурныйлар.

Айсылу. Тупас булсалар, аларга яңадан кем килә соң? Хәзер бит адым саен автосервис.

Сәрбиназ. Карале, Айсылу кызым, Гәрәй Мингалиевич белән подиумда очрашканыгызны сөйлә әле.

**УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Айсылу үзенең подиумнан чыгып буш бүлмәдә елап торган чагын күз алдына китерә. Ул көзгегә карап киемнәрен салырга торганда, Гәрәй керә. Айсылу аны дорфа каршы ала.

Айсылу. Нәрсә, миннән көләргә кердегезме?

Гәрәй. Юк, матурым, көчем җитсә, сезнең бераз кәефегезне күтәрергә дип кердем.

Айсылу. Кирәкми миңа кәеф күтәрүчеләр. Минем елыйсым килә.

Гәрәй. Елагыз алайса. Бераз бушанырсыз.

Айсылу шактый вакыт мышкылдый. Керфекләреннән күз яше белән агып төшкән керфек буявы битен ямьсезли.

Гәрәй. Сезгә елау килешми, чибәр туташ. Сезгә көлү ныграк килешә.

Айсылу. Әгәр сезнең иң яхшы эшегезне бракка чыгарсалар, көләр идегезме?

Гәрәй. Белмим. Мөгаен, көлеп булмас иде.

Айсылу. Ә бит башта минем бу моделемне барсы да мактаган иде. Людмила Максимовна үзе үк: «Син, Айсылу, бу моделең белән Татарстанны гына түгел, Россияне буйсындырып кайтачаксың әле»,— дигән иде.

Гәрәй. Фикере үзгәрергә берәр сәбәп булгандыр.

Айсылу. Сәбәбен бик яхшы беләм мин аның. Әтинең артыннан күпме чапты. Әтиләр Австралиягә китүгә, кинәт кенә мин иң начар модель булып калдым.

Гәрәй. Алай ук кайгырмагыз, Айсылу туташ.

Айсылу. Ничек инде кайгырмыйм? Ул бит минем подиумнан китүемне тели.

Гәрәй. Ә сез китегез.

Айсылу. Кая китим? Кайда соң ул мине көтеп торучылар?..

Гәрәй. Менә мин көтәм сезне, Айсылу туташ. Унҗиде яшьлек егетләрдәй яратып көтәм. Дөресен әйтим, мин инде үземне сүнгән вулкан дип уйлый идем. Сез шул вулкан өстенә китереп бастыгыз. Хәзер аннан кайнар лава менә атылам, менә атылам дип тора.

Айсылу. Сез бик әйбәт кеше, Гәрәй Мингалиевич, ләкин...

Гәрәй. Ләкин хисләрнең нечкәлеген тоярлык, күңел түрендәге якты аланнарыгызда үскән чәчәкләрне күрерлек түгел, дисезме?

Айсылу. Киресенчә, мин бер җебегән нәрсә. Аннары...

Гәрәй. Аннары нәрсә?

Айсылу. Сез бит инде өйләнгән кеше.

Гәрәй. Аерылган кеше дисәгез, дөресрәк булыр.

Айсылу. Өйләнеп аерылганнарның яңадан кушылганнары да җитәрлек.

Гәрәй. Айсылу туташ, җай чыгып без бу турыда сөйләшә башлаганбыз икән инде, шуны белегез: мин беренче хатыныма беркайчан да кире кайтмаячакмын. Чөнки ул мине бик җитди мәсьәләдә алдады. Ә мин алдаган кешеләрне кичерә алмыйм.

Айсылу. Карагыз әле, мине юатырга дип кердегез дә инде хатынлыкка димлисезме?

Гәрәй. Хисләремне теге вакытта да аңлатырга тырышкан идем. Бәлки, аңлатып бетерә алмаганмындыр. Мин сезне күргәнче чын яратуның ни икәнен бөтенләй белмәгәнмен икән. Хәзер сезнең турыда уйлый башласам, уйларым учак булып яна. Тел белән аңлатып бетерә алмаслык халәттә мин, Айсылу туташ. Сездән шактый өлкән икәнемне дә аңлыйм. Ләкин уч төбе кадәрле йөрәгемне җиңә алмыйм. Әйдәгез, бүген үк тотабыз да безгә кайтабыз. Мин сезне мәхәббәтем белән күмеп ташлармын.

Айсылу уйга кала. Чөнки ул инде монда эшли алмаячагын аңлаган. Апасы янына да кайтасы килми. Чөнки апасы, Айсылу

кайтып керүгә, нәрсәдән булса да зарлана башлый.

Айсылу. Ярый алайса, ышанып карыйк.

Гәрәй шатлыгыннан аны күтәреп ала.

Гәрәй. Ай, Айсылуым, серле чәчәгем минем. Син беркайчан да үкенмәячәксең. Мин сиңа моны ныклап ышандырып әйтәм.

Айсылуның уйлары шунда өзелә. Чөнки алар инде кайтып җитәләр. Алар килеп туктаганны да көтмичә, Габдулла капканы ача. Айсылу туктап тормастан диярлек гаражга кереп китә. Айсылу машинасын куеп чыгуга, Габдулла аны шатландырырга тели.

Габдулла. Айсылу Акбулатовна!
Айсылу. Нәрсә, Габдулла абый?
Габдулла. Бакчагызга күз төшерергә уйламыйсызмы?
Айсылу. Ә нәрсә бар?
Габдулла *(дулкынланып).* Теге ни... Теге нине ниттеләр, Айсылу Акбулатовна!
Айсылу. Сез исерек түгелсездер бит, Габдулла абый.
Габдулла. Юк-юк. Ә-әнә каенны к-карагыз әле.

Айсылу яшен суккан каен ягына карарга да курка. Шулай да аның күзенә элекке каен урынында нәкъ шундый гөрләп үсеп утыручы куш каен чагыла. Ул күзләрен угалап ала һәм каенга таба йөгерә. Каен чынлап та әллә кайчаннан үсеп утырган шикелле, яфракларын җилдә таратып утыра. Хәтта каен төбендә үләннәр дә ямь-яшел.

Айсылу. Сәрбиназ апа, мине чеметеп кара әле. Әллә мин саташаммы?

Ашыга-ашыга Айсылу янына Сәрбиназ килә.

Сәрбиназ. Әстәгъфирулла, син генә түгел, мин дә саташам бугай, әллә безнең каеныбызны яшен сукмаган иде микән?
Айсылу. Күз алдыбызда дөрләп янды бит.
Сәрбиназ. Гәрәй Мингалиевич эше бу, бер дә бүтән түгел. Ул гына эшне шапырынмыйча эшли белә. Сине яратканга ул. Ирләр яраткан кешеләре өчен ни генә эшләми!
Айсылу. Нәкъ элекке куш каен.
Сәрбиназ. Тфү, тфү, диген. Күзең тимәсен.
Айсылу. Тфү, тфү!
Сәрбиназ. Менә шулай. Бернәрсәгә дә артыгын сокланып карарга ярамый.
Айсылу. Үсеп-тернәкләнеп китәр микән бу, Сәрбиназ апа?
Сәрбиназ. Үсәр, Алла боерса. Мәхәббәт белән эшләнгән эш хәерле була ул. Ә яшен сугу язмышның бер кисәтүе булгандыр.

Болар каен янында мәш килгәндә, Гәрәй кайтып төшә. Ул туры Айсылулар янына килә.

Айсылу *(Гәрәйнең кочагына ташланып).* Рәхмәт, кадерлем минем. Мәхәббәтебезне олылый белгәнең өчен рәхмәт.

Гәрәй бераз югалыбрак кала. Чөнки Айсылу күңелендәге хисләрне тышка чыгарырга яратмый. Аның мәхәббәте тыенкы, тыйнак. Җанында кайнаган хисләр өермәсен ул бик нык шатланганда гына чыгара. Димәк, бу каен Айсылу өчен чиксез кадерле һәм аерым мәгънәгә ия.

Гәрәй. Сине шатландыра алу минем өчен иң зур бәхет, кадерлем. Әйдә, юынып алыйк, син дә юлдан, мин дә юлдан.

Юынгыч янына киләләр. Шунда Гәрәйнең башына бер уй килә.

Гәрәй. Карале, Айсылуым, безгә комган алырга кирәк икән.
Айсылу. Комган? Бу юынгыч начармыни?
Гәрәй. Комганны безнең бабайлар юкка гына уйлап тапмагандыр. Бер-береңнең кулына су салып юындыру кешеләрне тагын да якынайтып җибәрә. Җылысын күбрәк тоясың кебек.

Гәрәй йөгереп бакча уртасындагы лейканы алып килә. Аның борынына кидергән сиптергечен алып ташлый һәм лейкага су тутыра.

Гәрәй. Бүгенгә безнең комганыбыз шушы булыр. Кил әле, аппагым, юл тузаннарыңны юып төшерик

әле.

Айсылуның кулына Гәрәй су салып тора. Айсылу битен, муенын юа. Гәрәй шаярып аның яка астына бераз су сала.

Айсылу. Ә-ә, син шулаймыни әле. Комган хәзер безнең кулга күчәчәк, белеп тор.

Айсылу сөлге алып сөртенә дә лейка-комганны үз кулына ала. Гәрәй биленә кадәр чишенә.

Гәрәй. Кой әйдә рәхәтләндереп.

Айсылу Гәрәйнең кулларына су сала. Тегесе пошкырына-пошкырына юына. Гәрәй битен ышкып маташканда, Айсылу аның култык астын кытыклап ала.

Гәрәй. Ә-ә, син шулаймы әле?!
Айсылу. Шулай шул.

Гәрәй аны сөлгесе белән урап ала да үзенә якын китерә. Сәрбиназ сиздерми генә кереп китә. Гәрәй Айсылуны үбә. Айсылуга рәхәт, ләкин ул читкә тартылмакчы була.

Айсылу. Яхшы түгел, Гәрәй, кешеләр карап торуы бар.
Гәрәй. Карасыннар, көнләшсеннәр. Мин кеше хатынын үпмим, үз хатынымны үбәм бит.
Айсылу. Булса да...
Гәрәй. Ә беләсеңме, бүген син миңа бик кадерле сүз әйттең.
Айсылу *(уйланып).* Нинди сүз икән ул? Һич хәтерләмим.
Гәрәй. Уйлап башыңны авырттырма: син миңа бүген просто Гәрәй дип әйттең. Юкса үзенең начальнигына секретарь дәшкән кебек Гәрәй Мингалиевич та Гәрәй Мингалиевич дия идең.
Айсылу. Зурлап әйткәч әйбәтрәк түгелмени?
Гәрәй. Түгел. Мәхәббәттә без тигез булырга тиеш. Беребез кече, беребез зур булсак, ул буйсындыруга әйләнеп кала. Әгәр мине ярата аласың икән, моннан соң просто Гәрәй генә диген.
Айсылу. Ярар, просто Гәрәй диярмен.

Икесе дә көләләр. Куш каен янына киләләр.

Айсылу. Беләсеңме, Гәрәй, миңа бу куш каен бик кадерле.
Гәрәй. Әйтеп кара.
Айсылу. Бу безнең мәхәббәтебез. Безне ниндидер явыз көчләр аерырга теләде, ахры. Каеныбызны яшен сукты. Ә син мәхәббәтебезне саклап калыр өчен ничек тырышкансың. Рәхмәт, просто Гәрәйчигем. *(Үбеп ала.)*
Гәрәй *(хискә бирелеп).* Моңа кадәр синсез ничек яшәдем икән?! Син бит минем бөтен дөньямны матурлыкка күмдең, чәчәгем. Мин соңгы вакытта бакчадагы менә бу чәчәкләрне дә күрми, кошлар сайраганын да ишетми башлаган идем. Син минем күзләремне ачтың, аппагым. Бердәнберем минем.

Шушы вакытта Хәйдәр Бигичев башкаруында «Җыр калдырыйк» дигән җыр яңгырый.

Кеше китә — җыры кала, диләр,
Бер җыр калсын әле бездән дә.
Ул җыр җанга шатлык булып керсен,
Кояш булып тулсын йөзләргә.

Без һәммәбез җирдә берәү генә,
Беркемнең юк җирдә алмашы.
Кабатланмас үз язмышы белән
Туа җиргә адәм баласы.

Җыр калдырыйк җирдә, нур калдырыйк,
Җырда калсын безнең гомерләр.
Безнең дөрләү, безнең януларны
Киләчәккә җырлар илтерләр.

Җыр икесен дә хисләндерә. Алар бер-берләренә тагын да ныграк сыеналар. Кинәт эт өрә башлый.

Гәрәй. Кирәкмәгән вакытта кайсы анда ашка таракан булып төшмәкче икән инде.

Капкага таба китә. Аңа Айсылу дә ияре. Гәрәй барышлый Матуркай-
нның башыннан сыйпый.

Гәрәй. Кемгә өрәсең, Матуркай? Син яратмаган кем килгән анда, карыйк әле.

Капка төбенә килә. Анда Гәрәйнең беренче хатыны Рәхилә. Ул ыспай гына киенсә дә, киемнәре ничектер килешсез тора. Чырае да караңгы.

Рәхилә. Синең белән бик җитди нәрсә турында сөйләшәсе барые.
Гәрәй. Тагын акча кирәкме?
Рәхилә. Бәлки, эчкә кертерсең. Урамда сөйләшә торган сүз генә түгел.
Гәрәй. Әйдә, кер. Ләкин минем биш минуттан артык вакытым юк.
Рәхилә. Биш минутта хәл итсәң, миңа шул вакыт та җитә.

Гәрәй үзенең беренче хатыны белән сөйләшкәндә, Айсылу нишләргә белми таптанып тора.

Гәрәй. Бар, матурым, Сәрбиназ апа белән ашый торыгыз.

Айсылу чыгып китә.

Гәрәй. Йә, нәрсә булды?
Рәхилә. Малайны эләктерделәр, Гриша.
Гәрәй. Гриша түгел, Гәрәй. Күпме тукырга була?
Рәхилә. Ярар, Гәрәй икән Гәрәй. Малай белән нишлибез?
Гәрәй. Тагын нәрсә эшләгән инде?
Рәхилә. Кемнеңдер машинасын урларга маташканда эләккән.
Гәрәй. Ах, сволочь! Йөз машина алып бирсәң дә җитмәс аңа.
Рәхилә. Машина гына булса тагын бер хәл. Кесәсеннән наркотиклар тапканнар. Өйгә тентү белән килделәр.
Гәрәй. Өйдән дә таптылармы?
Рәхилә. Эзләгән кеше таба инде ул. Наркотиклар сатуда гаеплиләр малаеңны. Шаһитлар да бар.
Гәрәй. Уф! Нишләргә сезнең белән? Син өйрәттең аны этлеккә. Ни сораса алып биреп.
Рәхилә. Юк инде, җаныкаем. Караклык ата каныннан килә.
Гәрәй *(ачуы килеп)*. Нәрсә, мине карак димәкче буласыңмы әллә?
Рәхилә. Аны әйтеп торасы юк. Моның кадәр байлыкны эшләп табып булмый. Мәктәп директоры чагында чалбарыңның төбе тишелгәнче кия идең.
Гәрәй. Җитте! Мин баер өчен тырышмыйм. Кешеләргә күбрәк файда китерер өчен эшлим. Һәр елны шәһәрнең ике мәктәбен ремонтлатам. Ярлылар өчен ашханә салдырдым. *(Кул селтәп.)* Хәер, сиңа — аңгыра башка сөйләдең ни, сөйләмәдең ни!
Рәхилә. Шулай инде, карт хатыннар аңгыра, надан, сукыр була.
Гәрәй. Авызыңны ябасыңмы, юкмы? Юкса этне бәйдән ычкындырам.
Рәхилә. Ычкындыр. Этең белән икәүләп талагыз. Ичмасам, малаең янына сине илтеп ябарлар. Наркотикларны бер-берегезгә кадашып ятарсыз шунда.
Гәрәй *(капканы ачып)*. Чыгып кит хәзер үк!
Рәхилә. Китмим әле. Әйтәсе сүзем бетмәде.
Гәрәй. Тагын нәрсә?
Рәхилә. Малаең анда, наркотикларны әти алып кайтып бирә иде, дигән. Так что, малаеңны коткармасаң, үзең дә кабачаксың.
Гәрәй. Ах, кабахәт! Эт симерсә, хуҗасын тешли, ди. Артык симертеп җибәрдем шул сезне. Авызыгыз сөйләгәнне колагыгыз ишетми.
Рәхилә. Синең җаныңны мүк баскан. Юньле ата мондый хәбәрне ишетүгә үк малаен коткарырга чабар иде.
Гәрәй. Утырсын әле, бәлки, бераз акыл керер. Ә син тай моннан.

Гәрәй хатынны төрткәләп диярлек капкадан чыгарып җибәрә. Үзе өйгә керә. Ул кергәндә, Айсылу ишек яңагына сөялеп басып тора. Гәрәй Айсылуның бөтенесен ишетеп торганын аңлый.

Гәрәй. Сиңа, сандугачым, кайбер нәрсәләргә кимрәк колак салырга киңәш итәр идем.
Айсылу. Малаең жәл бит, Гәрәй. Булдыралсаң, ярдәм ит син аңа. Бер бозылса, аны кеше итү кыен булачак. Наркотиклар эзләп безгә дә килсәләр?
Гәрәй. Килсәләр, тикшерерләр дә китәрләр.
Айсылу. Альберт сезнең өйнең барлык яшерен юлларын беләдер дип уйлыйм. Наркотикларын Габдулла абзый аша кертергә мөмкин. Ул абзый миңа ошамый.

Гәрәй *(уйланып).* Акыллы фикер әйттең, матурым. Андый хәл дә булуы мөмкин. Бөтен җирне карап чыгарга булыр.

Айсылу. Минем бер дустымның өйрәтелгән эте бар. Әтисе кайчандыр милициядә эшләгән. Этләре теләсә нинди наркотикны таба, ди. Шуны чакырсам?

Гәрәй. Чакырырсың. Ләкин моны төнлә эшләү яхшырак булыр. Юкса күршеләр безнең кая басканга кадәр тикшереп торалар.

Айсылу. Шулай да Ходай сакланганны саклармын дигән.

Гәрәй. Ярый, матурым, син бу эшне үз өстеңә ал. Ә малайны коткарырга килгәндә, ни әйтергә дә белмим. Яңадан бу эшен кабатламас дип кем әйтә ала?

Айсылу. Яхшылыкны хайван да аңлый.

Гәрәй. Кеше бер бозылса, хайваннан да хужелана. Вәт паразит малай! Наркотикларны эти алып кайтып бирә иде, дигән бит.

Айсылу. Бәлки, улыгыз алай димәгәндер. Аерылган хатының сине куркытыр өчен шундый шантажга барадыр.

Гәрәй. Әйе. Дөрестән дә шулай булуы мөмкин.

Айсылу. Шулай да улыгызны коткарырга кирәк. Юкса ул тагын да тирәнрәк упкынга тәгәрәр.

Гәрәй. Коткаруын коткарырмын ансы, ләкин бит аны әнисе боза. Армиягә җибәрик, дидем — җибәрттермәде. Эшкә керттем — эшлисе килмәде. Наркоманнар әллә каян түгел, әнә шундый иркә әниләр кочагыннан үсеп чыга.

Айсылу. Әгәр болай итсәң...

Гәрәй. Ничек?

Айсылу. Бераз үзебездә тотсаң. Монда аның һәр адымын күзәтерлек кешеләрең бар. Иптәшләре белән аралаштырмаслар.

Гәрәй. Сүзләреңдә хаклык бар. Әмма бүре баласын бүреккә салсаң да урманга карый.

Гәрәй Айсылуны кочып ала. Аның күңелендә хисләр ташыганы күренә. Малае аның үзенә дә жәл, ләкин бирегә алып кайтып кына туры юлга бастырып булмас дип тә курка. Ниһаять, ул бер карарга килә.

Гәрәй. Күңелең тулы мәрхәмәт шул синең, чәчәгем. Ә теге эшне озакка сузмаска кирәк. Әгәр чынлап тапсагыз, яндырыгыз.

Айсылу *(назланып).* Ярый, борчылма, барсы да о,кей була.

Гәрәй. Альбертны алып кайтсам, өстәге теге бүлмәгә урнаштырырбыз. Анда кош та очып керә ала торган түгел. Ишегенең йозаклары да хикмәтле. Ятарына караваттише нәрсәләр кертсеннәр.

Айсылу. Ә ашарга безнең янга төшеп йөрерме? Аерым ашатсаң, үпкәләячәк инде ул.

Гәрәй. Менә син аның белән бер табында утырып ашар идеңме?

Айсылу *(аптырап кала).* Дөресен генә әйткәндә, мин аны үземә якынайтасым килми. Арабызны бозуы бар.

Гәрәй. Дөрес уйлыйсың, сандугачым. Без йомшаклык күрсәткән саен, ул аза барачак. Ашарына каравылчы Габдулла абзый кертер. Бүлмәсендә бәдрәфе бар, суы бар. Ятсын шунда. Бераз уйланып ятса, акыл кермәсме.

Чыгып китә. Машина тавышы ишетелеп кала.

Бераздан капка төбенә ике машина килеп туктый. Берсе Гәрәйнеке, икенчесе теге вакыт Айсылуның машинасын урларга теләүче каракларны тотучы омончылар машинасына охшаган. Гәрәй машинасыннан төшүгә, каравылчы Габдулла йөгереп чыга.

Габдулла. Капканы ачаргамы, Гәрәй Мингалиевич?

Гәрәй. Ачарга! Живо!

Әллә ашыгудан Габдулланың куллары калтырый. Кулындагы ачкычын йозак тишегенә кертә алмый азаплана. Гәрәй аның кулыннан ачкычны тартып ала да йозакны ача һәм үзеннән артта кайткан машинага эчкә керергә башы белән генә ым кага. Машина эчкә керә. Аннан бер таза егет төшә дә арткы утыргычта утырган Альбертны тартып төшерә. Альбертны машинадан тартып төшерүгә, машина эченнән тагын бер таза егет чыга.

Гәрәй *(Габдуллага).* Урын әзерме?

Габдулла. Әзер, әзер, Гәрәй Мингалиевич.

Гәрәй *(егетләргә).* Өске катка алып менегез. *(Габдуллага.)* Бар, бүлмәне ач.

Альберт әтисенә бүре кебек карап куя.

Альберт *(әтисенә).* Кунакка алып килдеңме, папаня. Ладно, и на этом спасибо.

Гәрәй *(егетләргә).* Барыгыз, бар. Ә син, Габдулла абзый, монда иң җаваплы кеше булачаксың. Менә бу селәгәй егет кисәгенә ашарга кертерсең. Кирәк булса, бүлмәсен җыештырырсың.

Егетләр Альбертны җилтерәтеп өскә алып менеп китәләр. Баскычтан менеп барганда, аларга аска төшеп килүче Айсылу очрый.

Альберт. Здрасте, мамочка-красавица! Вот сезгә кунакка пришел.

Һәркем үз юлыннан китә. Айсылу бераз кәефсез күренә. Бу хәлләрнең килеп чыгуына үзен гаепле саный кебек. Югарыдагы ишек шарт итеп бикләнгәч, ул сискәнеп китә. Айсылу янына Сәрбиназ чыга.

Сәрбиназ. Теге бандитны монда кайтарттың кайтартуын, Айсылу кызым. Тик күңелем сизә, моннан соң безнең тынычлык бетәчәк.

Айсылу. Нинди бандит инде ул, Сәрбиназ апа? Әтисе тәрбияләмәсә, аны кем туры юлга кертә алсын.

Сәрбиназ. Теге җебегәне бозды аны.

Айсылу. Кем ул?

Сәрбиназ. Әнисен әйтүем. Ул һәрвакыт Гәрәй Мингалиевичка каршы барды.

Айсылу. Сез монда ничә ел эшлисез соң инде, Сәрбиназ апа?

Сәрбиназ. Эшләвен мин монда җиде генә ел эшлим. Әмма Рәхиләне яхшы беләм. Гәрәйнең аңа өйләнгәнен белгәч, бөтен кеше шаккатты.

Айсылу. Гәрәй шундый акыллы кеше, ничек шундый сукырлык күрсәтте икән соң ул?

Сәрбиназ. Мин бөтенесен белеп бетермим. Әмма Гәрәй Мингалиевич аңа җәлләп өйләнгән, диләр.

Айсылу. Ничек «җәлләп»?

Сәрбиназ. Дөрес булса, Гәрәй Мингалиевичлар ниндидер бәйрәм көнне су буена пикникка төшкәннәр. Аш пешерергә Рәхиләне алганнар. Пикник, үзең беләсең, эчүсез булмый. Менә шунда, имештер, Гәрәй Мингалиевич кармак салып утырганда, бер исерекбаш Гәрәй Мингалиевичның кабыргасына пычак тыкмакчы булган. Ә Рәхилә шуны күреп алган да тегенең пычагын кулындагы чүмече белән бәреп төшергән. Аннары Рәхилә Гәрәй Мингалиевичны күргән саен, синең миңа мәңгелек бурычың бар, дип бәйләнә башлаган.

Айсылу. Түләсен иде бурычын акча белән.

Сәрбиназ. Гәрәй Мингалиевич аңа акча да, әтисеннән калган өйне дә биреп караган, ләкин хәйләкәр Рәхиләгә акча түгел, Гәрәйнең үзе кирәк булган.

Айсылу. Гәрәйгә кадауны һәм Рәхиләнең коткарып калуларын алдан ук оештырып куйганнардыр әле.

Сәрбиназ. Мин дә нәкъ шулай уйлыйм, Айсылу кызым. Юкса бөтен кеше каядыр киткәч, тыныч кына кармак салып утырган кешегә кем ташлансын. Сугыш-талаш чыга икән, шул эчеп утырганда була инде ул.

Айсылу. Шундый акыллы Гәрәй нишләп гап-гади кармакка капты икән?

Сәрбиназ. Әнә судагы балыклар да үзләренчә бик акыллы, ләкин кабалар шул, наный. Гәрәйнең намуслы икәнен дә истән чыгармаска кирәк. Ә Рәхилә юха елан белән бер. Ул шундый беркатлы, наивный булып кылана белә: карап торсаң, моннан да гөнаһсыз кеше юктыр дисең. Яшь чакта чибәрлеге дә бар иде. Гәрәй Мингалиевич чибәрләрне яратучан бит. Ансы сиңа яшерен-батырын түгел.

Айсылу *(ачуланып).* Син нәрсә, Сәрбиназ апа, Гәрәй миннән чибәррәк кыз күрсә, миңа хыянәт итә башлар дисеңме?

Сәрбиназ. Аллам сакласын. Синең өчен утка да, суга да керергә әзер бит ул. Аннан, синнән чибәр кыз була димени?

Айсылу. Ялагайланма. Чибәрдән чибәррәкләр, акыллыдан акыллыраклар һәрвакыт табылып тора.

Сәрбиназ. Юк инде, юк. Синнән чибәррәге, синнән акыллырагы булса да күрми ул хәзер. Аның бөтен дөньясы синнән һәм эшеннән тора. Әнә үзеңә кара да аңа кара. Ул бит инде олыгаюга таба бара.

Айсылу. Гәрәй әле миннән башка тагын ике кызны картайтырлык. Аңардагы көч. Эше бик мөһим булганда, ул тәүлекләр буе йокламаска мөмкин. Ә икенче көнне салкын су белән юынып алса, йокламаганлыгы чыраена да чыкмый.

Сәрбиназ. Сине яратканга ул, наный. Аңа яңа бер дәрт керде. Синең белән яши башлагач, тормышның мәгънәсен ныграк аңлый төште.

Сәрбиназның бу сүзләренә Айсылуның күңеле була. Ул хисләнеп Сәрбиназны кочып ала.

Айсылу. Әй, әйбәт кеше дә инде син, Сәрбиназ апа. Коеп куйган дипломат. Гәрәй Мингалиевичка әйтергә кирәк әле, сине үзенең киңәшчесе итеп алсын.

Сәрбиназ. Әстәгъфирулла-тәүбә, диген. Мин бу эшемнән дә бик канәгать.

Айсылуның күңеленә шаянлык йөгерә. Ул Сәрбиназны үзенчә үртәргә тотына.

Айсылу. Гәрәй Мингалиевич президент булгач, беренче киңәшчесе итеп сине алдыртачакмын.
Сәрбиназ. Ә, алайса, куркыныч юк икән әле.
Айсылу. Нигә?
Сәрбиназ. Президентыбыз, Аллага шөкер, әйбәт эшли бит.
Айсылу. Синеңчә, Гәрәй Мингалиевич бервакытта да президент булмасмыни?
Сәрбиназ. Мин алай димәдем.
Айсылу. Әйттең, әйттең. Гәрәйне озакламый ассоциациянең президенты итәчәкләр. Сүзләр бара инде. Шунда сине киңәшче итеп Гәрәйгә төртәбез.

Сәрбиназ Айсылуның шаярып әйткән сүзләренә ышана һәм куркып кала. Аның борчылганы йөзенә чыга. Шунда аның башына акыллы фикер килә.

Сәрбиназ. Ә ашны кем пешерер?
Айсылу *(уйга калган булып).* Менә ансы бар икән, Сәрбиназ апа. Киңәшчеләр табылыр, синең кебек аш остасы табылмас.
Сәрбиназ. Менә шул шул. Тамак туйдыру киңәш бирүдән файдалырак. Ярый, мин ашарга пешерергә киттем.

Сәрбиназ кухняга кереп китә. Айсылу бакчага чыга. Куш каен янына килә. Ул сыңар кулы белән каенның кәүсәсен эләктереп әкрен генә җырлый.

Айсылу. Каенкаем, матуркаем,
Килдең кайсы урманнан?
Нинди җепләр белән язмыш
Безне бергә ураган?

Каенкаем, гүзәлкәем,
Мине ят итмәссеңме?
Бакчабызны ятим итеп
Калдырып китмәссеңме?

Айсылу каенны кочып җырлап әйләнгәндә, агач башында бер кош сайрап җибәрә. Айсылу шатланып өскә карый, ләкин кош күренми. Айсылу тагын җырлый.

Айсылу. Каенкаем, аппаккаем,
Былбылың булыр идем.
Былбылың булыр идем дә
Гел сайрап торыр идем.

Кош яңадан сайрый башлагач, Айсылу башын югары күтәрә һәм шунда ботаклар арасында качып утыручы теге монтер егетне күреп ала. Кош булып сайраучы ул икәнен аңлый.

Айсылу. Аһ, оятсыз! Нишләп утырасың монда? Хәзер үк төш тә табаныңны ялтырат.
Монтер. Мин бит былбыл.
Айсылу. Нинди былбыл? Карга дисәң дөресрәк булыр. Бәбкә сагалап йөрүче карга.
Монтер. Бәбкәсе бик матур шул.
Айсылу. Матур бәбкәләр күп булыр ул.
Монтер. Алай ук димәс идем.

Айсылу як-ягына карана. Тик беркем дә күренми.

Монтер. Каранма, каранма. Сакчыларың өегезнең теге ягында.
Айсылу. Минем бернинди сакчыларым да юк. Мин ирекле кеше.
Монтер. Ирекле кеше икәнеңне беләм. Шул ирегеңне урламасыннар дип саклыйлар, димәк. Тик син әлегә тыныч бул, сакчыларың наркоман улыгызны күзәтә.

Бу егетнең бөтен нәрсәне белеп торуына Айсылуның чиксез ачуы килә. Ул бакчадан каткан балчык алып агач өстенә ыргыта.

Айсылу. Карале, дегет чүлмәге, нигә бәйләнәсең син миңа, ә?
Монтер. Бәйләнмим. Мин сине бәләкәй чагыңнан ук беләм бит.
Айсылу *(мыскыллап).* И-и, алама дегет чүлмәге! Бәләкәй чагымнан ук белә, имеш.
Монтер. Беләм шул. Син бит атаклы футболчы Акбулат Ихтыяров кызы. Әтиеңнәрнең Австралиягә китеп баруларын да беләм.

Айсылу беразга аптырап кала. Шулай да монтер егеткә ышанмыйчарак карый.

Айсылу. Әтиемне белү әле ул монда минем тормышыма тыгылырга ярый дигән сүз түгел.
Монтер. Ә мин тыгылмыйм. Сиңа сокланып карап кына торам.
Айсылу. Минем үз соклanучым бар.
Монтер. Ансын беләм, ләкин синнән бер нәрсә сорыйсым килә: син бу оҗмахка үз ирегең белән килеп кердеңме?
Айсылу. Оҗмахка көчләп кертмиләр.
Монтер. Оҗмахны күргәнем юк иде, димәк, оҗмах шушындый була?!

Айсылу дәшми.

Монтер. Болай начар түгел үзе. Балдан, майдан аккан чишмәләре күренмәсә дә, гаражыңда ак «Мерседес»ың торганын беләм. Шәп йөрисең. Современный оҗмахта машинасыз булмыйдыр ул.
Айсылу. Нинди тел бистәсе син?
Монтер. Чибәрләрне күрсәм, тел бәйдән ычкына шул.
Айсылу. Китегез моннан. Кеше тормышын бозып йөрмәгез.
Монтер. Шуңарга да бозылган тормыш нинди була инде ул?!
Айсылу. Сандугач оясын туздырырга бер карга җитә.

Монтерның бу сүзләргә ачуы килә. Ул Айсылуны үртәп карга булып каркылдый башлый. Айсылу түзми, идарә пультын алып кнопкасына баса. Бу аның сакчыларны чакыруы. Ул арада бер сакчы килеп, монтер егетне каен башыннан тартып төшерә. Бәргәләп тә ала, койманың тышкы ягында дөпелдәгән тавышлар ишетелә. Айсылу үрелеп карый, ләкин беркемне дә күрми.
Өйдән Сәрбиназ чыга. Аның йөзендә борчу бар шикелле. Ул Айсылу янына килә. Кыз бассейн янындагы гамакка барып ята.

Сәрбиназ. Бетте, балам, бар да бетте.
Айсылу. Нәрсә бетте? Аңлатыбрак сөйлә әле, Сәрбиназ апа? Теге зәңгәр чынаягымны ваттыңмы әллә?
Сәрбиназ. И-и, ул гына булса.
Айсылу. Тагын нәрсә?
Сәрбиназ. Теге кытайча башын тере калдырып, койрык өлешен генә кыздыра торган карп үлде.
Айсылу *(көлә)*. Ул балыкны алай тере килеш табынга бирүне бер дә яратмыйм, Сәрбиназ апа. Балыклар сулап ята, без аларның кыздырылган койрыкларын ашыйбыз. Варварлык.
Сәрбиназ. Соң, үскәнем, Гәрәй Мингалиевич, бер зур кунак алып кайтам, диде бит. Шулай итеп кыздырырга кушты.
Айсылу. Ярый, борчылма, балыгын табарбыз.
Сәрбиназ. Ничә ел ресторанда эшләп шуны да булдыра алмагансың, дисә, үл дә кит.

Айсылу кесә телефонын алып кемгәдер шылтырата.

Айсылу. Алло, Барый абый. Бу Айсылу Акбулатовна әле. Синең теге утта янмый, суда батмый торган особый балыгың бармы әле? Шәп, шәп! Алайса, берничәсен тиз генә безгә кертеп чык әле.
Сәрбиназ. Китерәме?
Айсылу. Китерә. Бар, өйгә кереп тыныч кына үз эшеңне эшлә.
Сәрбиназ. Рәхмәт, балам. Мине бу юлы да коткардың. Ярый әле син бар, фәрештәм минем.
Айсылу. Алай изгеләштермә әле мине. *(Бераз сүзсез торгач.)* Гәрәй Мингалиевичның малае бик тавышланмыйммы?
Сәрбиназ. Кайбер көннәрдә төне буе ишеккә тибеп чыга. Кемнәрдер килгәләп тә китәләр.
Айсылу. Ә сакчылар?
Сәрбиназ. Алар үз эшләрен шыпырт кына эшли. Килгән кешеләрне ишек төбендә берәм-берәм эләктереп алып кара капрон капчык эченә тыгалар да каядыр илтеп ташлыйлар. Тегеләрнең тыннары да чыкмый.
Айсылу. Шулай биздермәсәң аларны.
Сәрбиназ. Әле шулай саклап та бер чукынмышы йозак тишеге эченнән теге агуын ыргытып киткән. Узган кич малаеның тавыш-тыны булмагач, Гәрәй Мингалиевич кереп караган иде, лыкын булып ята, ди. *(Көрсенеп.)* Нинди әйбәт кешедән шундый имгәк тусын инде.

Беразга сүзсез калалар. Ул арада сулы чиләккә берничә карп салып балыкчы Барый керә. Балыгын чиләктән алып Сәрбиназга күрсәтә.

Барый. Ярарлыкларммы?
Сәрбиназ. Нәкъ шундыйлары кирәк иде. Артык эреләрен кыздырып булмый, вагракллары

койрыкларын кайнар табага салуга тона.

Айсылу *(Сәрбиназга).* Көндәлек тотарга дигән акча шунда комод тартмасында. Барый абыйны обижать итәрлек итеп түләмә. Кайвакыт саранлана торган гадәтең дә бар.

Бераздан балыкчы Сәрбиназга рәхмәт әйтә-әйтә чыгып китә. Айсылу бассейн янындагы гамакта ятып кала. Сәрбиназ янына Габдулла керә.

Габдулла. Ни бит, Сәрбиназ туташ-мадам. Безнең Альбертның ашыйсы килгән. Баядән бирле ишеккә тибә. Тиз генә бирәр нәрсә әзерләп бир әле.

Сәрбиназ кунакка дип кыздырып та яраксызга чыккан балыкларын табадан алып бер тәлинкәгә салып бирә. Балык өстенә ипи куя.

Габдулла. Ә чәй?

Сәрбиназ. Аңа салкын су да җәл. Ну ярар инде, минем юмартлыгымнан файдаланыгыз.

Чәйнектәге чәйне банкага салып Габдуллага тоттыра. Габдулла, ризыкларны күтәреп, Альберт янына менеп китә. Аның билендә ачкычлар бәйләме. Кирәклесен сайлап ишекне ача. Ишек ачылуга, Альберт Габдулланы этеп тышка чыкмакчы була, ләкин Габдулла, карт булса да, хәйләгә оста, Альбертның йөзенә үк балыклы тәлинкәне күтәрә. Тәмле балык исе борынына бәрелүгә, Альберт артка чигенә. Габдулла Альбертның ашаганын көтеп эчкә керә. Альберт балыкны комсызланып ашый. Үзенең күзе Габдулла карт билендәге ачкычларда. Ашап, бер банка чәйне чөмереп куйгач, ул Габдуллага дәшә.

Альберт. Синең ачыгавызлыгыңнан файдаланып мин хәзер моннан тая алыр идем. Но пока рановато. Знаешь, Габдулла абзый, син миңа срочно фотоаппарат купи. Акчасын минем егетләр түләр. Менә мин сиңа записка язып бирәм. Егетләр сине таный. Таярга не вздумай.

Габдулла. Кая соң ул синең егетләр? Сине монда китереп ябуга, алар кандала кебек ярыкларга посып беткәндер инде.

Альберт *(кискен).* Я сказал найдут, значит, найдут. Только побыстрей шевелись. Миңа фотоаппарат кирәк, кстати, заодно минем бүлмәгә бер ачкыч та ясатып алып кил.

Габдулла. Булмый, Альберт энем. Ансын эшли алмыйм.

Альберт. Ә яшисең киләме соң?

Габдулла. Кем инде бу дөньядан туйган?!

Альберт. Раз так, сделай все так, как я сказал. Акчасын сиңа егетләр сколько захочешь бирерләр. Монда каравылда торып интегергә дә туры килмәс. Гомереңә җитәр.

Габдулла. Юк, барыбер булмый. Куркам.

Альберт. Үлемнән курыкмыйсыңмы?

Габдулла. Үлемнән дә куркам.

Альберт. Курыксаң, бар, тизрәк мин әйткәннәрне эшлә. Юкса башыңны бер җирдән, гәүдәңне икенче җирдән табачаклар.

Габдулла. Нинди фотоаппарат алырга соң?

Альберт. Вовремя напомнил. «Кодак»ны алсыннар. Пленканы җәлләмәсеннәр.

Габдулла чыгып китә башлый, Альберт аңа бармак янап кисәтә.

Альберт. Әгәр бу сүзләрне минем чибәр мамашага яки Гәрәй Мингалиевичка әйтсәң, телеңне кисеп алачакмын. Знай об этом.

Габдулла чыгып китә.

Ул Сәрбиназга күтәрелеп карарга да курка. Альберт белән сөйләшкән сүзләрне бөтен кеше беләдер кебек тоела аңа. Ул башын түбән иеп урамга чыга. Гәрәйләр өеннән бер йөз метрлап китүгә үк, аның каршысына өрәктәй төссез, битләрен сирәк сакал баскан ике кеше килеп баса. Алар Габдулланы икесе ике яктан җитәкләп каядыр алып китәләр. Габдулла суярга алып барган сарыктай өстерәлеп диярлек бара.

Айсылу бассейн янындагы гамакта бераз йокымсырап ала. Аның йокымсыравын күргән монтер егет мәче җитезлеге белән коймага менә дә куеныннан йомшак яшькелт мамыклы үрдәк бәбкәсе чыгарып бассейнга җибәрә. Үзе шунда ук койма аша сикереп юкка чыга. Бераздан Айсылу гамактан тора. Киерелә-сузыла бассейнга килә. Шунда аның күзе суда йөзеп йөрүче үрдәк бәбкәсенә төшә.

Айсылу. Сәрбиназ апа күрсә, фәрештәләр ташлаган моны сиңа, дияр иде. Ә мин фәрештәләргә бик ышанып җитмим. Шулай да каян килеп төште икән бу җан иясе?

Айсылу бассейнда йөзеп йөргән үрдәк бәбкәсен тотып ала. Аның йомшак мамыкларын битенә тидерә.

Айсылу. Әллә соң син тилгән тырнагыннан төшеп калдыңмы, йомшагым минем? Сине дә әниең ай буе утырып чыгаргандыр. Сез берәү генә түгелдер. Ә син адашып монда килеп чыккансың. *(Бәбкәне үбеп ала.)* Язмыш безне кая илтеп ташларын белмибез шул. Ә син миннән курыкма, яме. Мин сине яратырмын. Бәлки, сине әниең эзлидер. Әнкәләреңне эзләп очып китәрсең. Әнкәләр... Әнкәләр...

Минем әни-әтиләрем кайларда икән хәзер? Атаклы спортчылар. Гомер буе ил данын күтәрәбез дип йөрделәр дә чит җирләргә киттеләр дә бардылар. Без юк җирдә генә әйбәт шул ул тормыш.

Айсылуның уйларын Сәрбиназ бүлә.

Сәрбиназ. Айсылу кызым, Гәрәй Мингалиевичларга шылтыратып алмыйсыңмы? Юкса балыкларым да, үзем дә харап булачакмын.
Айсылу. Ярый, Сәрбиназ апа, шылтыратырмын. Хәзер телефонны алып чыгам да...
Сәрбиназ. Юк, юк, син ял ит. Телефоныңны үзем алып чыгам.
Айсылу. Олы кешене йөрткәнче...
Сәрбиназ. Олы кеше дип әле ул хәтле картайтма. Минем әле, Аллага шөкер, тазалыгымнан зарланырлык түгел.

Сәрбиназ тиз-тиз атлап өйгә кереп китә. Шул вакыт капкада Гәрәй белән 55–60 яшьләр тирәсендәге таза гәүдәле, бик ыспай киемле Мисбах Фәттахович күренә. Айсылу йөгереп өйгә кереп китә дә тиз арада килешле матур күлмәктән болар каршысына чыга.

Айсылу. Исәнмесез! Хуш киләсез! Әйдәгез, өйгә рәхим итегез!
Гәрәй *(Айсылуга).* Менә безнең Мисбах Фәттахович шушы була инде.

Айсылу нәзакәтле итеп реверанс ясый. Мисбах Фәттахович Айсылуның кулын үбә. Ул мутланып Гәрәйгә бармак яный.

Мисбах Фәттахович. Шушындый оҗмах кошын миннән яшереп ятасың икән, Гәрәй Мингалиевич. Моның өчен сезне наказать итми ярамый.

Гәрәй акланырга теләп нидер әйтмәкче була, ләкин Мисбах Фәттахович аңа сүз әйтергә ирек бирми.

Мисбах Фәттахович. Бернинди акланулар да кабул ителми, Гәрәй Мингалиевич. Бары тик тере килеш кыздырылган карп белән генә котыла аласың. Обожаю шул ярты ягы кызган килеш синең күзләреңә карап көчкә-көчкә тын алып яткан балыкларны ашарга.
Гәрәй. Алары булыр, Мисбах Фәттахович.

Айсылуга сораулы караш ташлый. Айсылу сүз әйтергә өлгерми, өйдән Сәрбиназ чыга. Аның кәефе күтәренке. Кунак белән исәнләшә.

Сәрбиназ. Бик вакытлы кайттыгыз, Гәрәй Мингалиевич. Карплар сезне көтә.

Гәрәй канәгать елмаеп кунакка карый.

Гәрәй. Болай булгач, Мисбах Фәттахович, наказание отменяется.
Мисбах Фәттахович *(Гәрәйгә бармак янап).* Ну хитрый син, Гәрәй Мингалиевич, минем йомшак якны беләсең.
Гәрәй. Хәйләсез дөнья файдасыз, диләр бит, Мисбах Фәттахович.

Эчкә үтәләр. Анда бик матур итеп табын әзерләнгән.

Мисбах Фәттахович. Күрәм, матур яшисез. Тик менә җәмәгатегез белән таныштырырга оныттыгыз.

Гәрәй кыенсынып кала.

Гәрәй. Өебезнең чәчәге Айсылу Акбулатовна.
Мисбах Фәттахович. Исеме җисеменә бик туры килә икән. *(Айсылуга.)* Әйдәгез әле, Айсылу Акбулатовна, табынга — безнең янга утырыгыз.
Айсылу. Эш кешеләренең үз серләре булырга мөмкин. Комачауламаммы соң?
Мисбах Фәттахович. Бу нинди сүз? Өстәлдәге матур чәчәкнең кемгә комачаулаганы бар?!
Айсылу. Сез, Мисбах Фәттахович, мине артыгын мактарга ашыкмагыз әле.
Мисбах Фәттахович. Ашыгам, Айсылу Акбулатовна. Без эшмәкәрләр һәрвакыт үткен кылыч йөзеннән яланаяк йөрибез. Шуңа күрә эшлисе эшләребезне, якын иткән кешеләребезгә матур сүзләребезне әйтеп калырга кирәк. Соң булуы бар.
Айсылу. Алай куркытмагыз инде, Мисбах Фәттахович. Болай да Гәрәй Мингалиевич берәр җирдә озаграк тоткарланса, йөрәгем табан астына төшә.

Бу сөйләшүләр, билгеле, ашый-ашый үтә. Табында аракы юк, бары минераль су гына.

Мисбах Фәттахович. Сезнең кебек кайгыртучылар, борчылып торучылар булганда яшибез әле, Айсылу Акбулатовна. Әйбәт кешеләрнең хәер-фатихасы яшәтә безне.

Ниһаять, Сәрбиназ табынга балык чыгара. Мисбах Фәттахович аһ итеп куя.

Гәрәй. Бәлки, балык белән бер илле грамм коньяк йотып куярбыз, Мисбах Фәттахович.

Мисбах Фәттахович. Юк, юк, Гәрәй Мингалиевич, күрмәгән коньяк түгел. Авызның тәмен җибәрмик. Аннары минем кабминга кереп чыгасы бар. Ә коньякның исе ярты чакрымнан аңкып тора. Ә балык шәп. *(Сәрбиназга карый. Гәрәй Сәрбиназның исемен атый.)* Сәрбиназ ханым, әллә кытай ресторанында эшләдегезме?

Сәрбиназ. Хәзер бит, Мисбах әфәнде, үзебезнең Казанда да кытай, япон, итальян һәм тагын әллә кемнәр ресторан ачып бетерде. Миңа төрлесендә эшләргә туры килде.

Мисбах Фәттахович *(портфеленнән бер кәгазь чыгарып Гәрәйгә бирә).* Менә, Гәрәй Мингалиевич, теге эш барып чыкты.

Гәрәй. Ай рәхмәт, Мисбах Фәттахович, бергә-бергә куанычын күрергә язсын. Болай булгач, дуслар гына түгел, компаньоннар да булдык.

Мисбах Фәттахович. Башлы кешеләр белән эшләргә яратам мин.

Гәрәй. Рәхмәт, Мисбах Фәттахович.

Шул вакыт Мисбах Фәттаховичның кесәсендәге телефон шылтырый.

Мисбах Фәттахович. Әйе, тыңлыйм. Ыһы-ыһы. Очрашу ничәгә билгеләнгән? Дүрткә? Юк, дүрткә бара алмыйм, кабминда эшләрем бар. Очрашуны берәр сәгатькә кичектерсеннәр. Мин хәзер Гәрәй Мингалиевичларда. Әйе, әйе. Алайса, хәзер мин кузгалам. Ун-унбиш минуттан анда булырмын.

Мисбах Фәттахович рәхмәт әйтеп табыннан кузгала. Гәрәй дә тора. Мисбах Фәттахович Айсылуның кулын үбә.

Мисбах Фәттахович. Рәхмәт, Айсылу Акбулатовна! Сезнең белән утыру бик күңелле, әмма эш көтә.

Гәрәй. Миңа да кузгалырга вакыт.

Барсы да табыннан кузгалалар. Айсылу аларны капка төбенә кадәр озата чыга. Сәрбиназ өстәлләрне җыештырганда, Габдулла керә.

Габдулла. Гәрәй Мингалиевичның улы Альбертны онытып җибәрмик. Яшь кешенең еш ашыйсы киләдер.

Сәрбиназ. Әрәмтамак. Шуңа биргән ризык җәл.

Габдулла. Үзеңнекен бирмисең әле.

Сәрбиназ. Үземнеке булса, мин аны таракандай ачка катырыр идем.

Габдулла. Әйдә, артыгын сөйләнмә. Хуҗалар югында тәмлерәк нәрсәләреңне күбрәк тондыр. Ул да адәм баласы.

Сәрбиназ бер кәстрүлгә аш, икенче тәлинкәгә балык белән ипи салып Габдуллага бирә. Габдулла ризыкларны күтәреп баскыч буйлап өскә менеп китә. Альберт янына керә.

Альберт. Йә, булдымы?

Габдулла. Нәрсә?

Альберт. Не морочь мне голову. Фотоаппарат алып килдеңме?

Габдулла. Мә! *(Түш кесәсеннән фотоаппарат алып бирә.)* Дусларың бар икән.

Альберт. Ачкыч ясаттыңмы?

Габдулла. Бигрәк сабырсыз син.

Альберт. Менә монда сине ябып куйсалар, нинди булырсың икән?

Габдулла. Ачкычын ясатуын ясаттым, әмма ләкин син качсаң, минем баш бетәчәк.

Альберт. Мин качарга җыенмыйм.

Габдулла. Алайса, нигә сиңа ачкыч?

Альберт. Папаня өйдә юк чакларда красавица-мамочка белән бераз кети-мети уйнап аласым килә. В крайнем случае аның нервыларында уйнарга.

Габдулла. Ай-һай, җегет, ут белән уйнасаң, пешмәссең микән?

Альберт. Ә мин ут белән уйнарга люблю. Это моя стихия. Между прочим, минем акыллы башка бер уй килде әле.

Габдулла. Нинди уй тагын?

Альберт. Мамочка-красавицаны үзе генә өйдә калган чакта мин эләктереп алырмын. Ә син безне фотога снимешь. Төшерә беләсеңдер бит?

Габдулла. Хәзерге фотоаппарат белән дурак та төшерә.

Альберт. У меня есть грандиозные планы.

Габдулла. Грандиоз планнарың белән капкынга килеп капма. Урамда сакчылар барын онытма.

Альберт. Кстати, өйдә кемнәр бар икән хәзер? Если Айсылу үзе генә булса, эшне бүген үк башлыйбыз.

Габдулла аска төшеп китә. Альберт ашап кала. Габдулла төшкәндә үк Сәрбиназга юлыга. Алар әйткәләшеп алалар.

Сәрбиназ. Нишләп, тычкан сагалаган мәчедәй, гел мине сагалап йөрисең?
Габдулла. Яратам бит мин сине, Сәрбиназ туташ.
Сәрбиназ. Карт алаша.
Габдулла. Бер дә алаша түгел. Әле сине хатынлыкка алырга исәп бар.
Сәрбиназ. И-и, сүләнгән була бит, мич башы тараканы.
Габдулла. Менә күрсәтәм әле мин сиңа мич башы тараканын.

Габдулла Сәрбиназга барып ябыша. Кочакларга маташа.

Сәрбиназ. Бүгеннән кудырам мин сине бу өйдән.
Габдулла. Ә-ә, шулаймыни? Алайса күрсәтим әле мин сиңа үземнең нинди алаша икәнемне.

Сәрбиназның кулларын каерып тота. Сәрбиназ кычкыра, ләкин өйдә кеше юклыгын Габдулла белә. Ул Сәрбиназның башындагы яулыгын салдырып ала да аның авызын томалый.

Габдулла. Ә хәзер синең бүлмәңне күреп чыгыйк.

Сәрбиназны өстери. Сәрбиназ каршылык күрсәтә, ләкин аның Габдуллага көче җитми. Шул вакыт бакчада Айсылуның җырлаганы ишетелә: «Каенкаем, каенкаем, Килдең кайсы урманнан?» Айсылуның тавышы Габдулланы айнытып җибәрә. Шулай да ул кулына эләккән корбанын тиз генә ычкындырмый. Сәрбиназның түшләрен капшый. Тагын Айсылу тавышы ишетелә.

Габдулла. Мин сине әле бу килеш кенә калдырмыйм, Сәрбиназ туташ-ханым. Ә хәзер, бар, бүлмәңә кереп биклән дә тавыш-тыныңны чыгармыйча ят. Әгәр тавыш-тының чыкса, үзеңә үпкәлә. Үлгәндә кыз булып үлмәссең бит инде.

Габдулла Сәрбиназны этеп бүлмәсенә кертеп җибәрә. Рухы сындырылган Сәрбиназ шым гына кереп бикләнә. Габдулла еш-еш сулап Альберт бүлмәсенә керә.

Альберт. Нәрсә, әллә җен-пәриләр кудымы?
Габдулла. Теге дурочканың котын алып бүлмәсенә яптым. Айсылу өйдә үзе генә. Хәзер ул бакчада. Пожалуй, озакламый керер. Чәчәкләр җыеп йөри.
Альберт. Oho, вот эта удача! Молодец, дядя Габдулла!

Габдулла Альберт ашаган савытларны җыештыра. Идәндә аунап яткан ипи кисәкләрен җыя.

Габдулла. Бигрәк шапшак ашыйсың инде.
Альберт. Не ворчи. А то күтеңә типтем чыгардым булыр. Моннан кусалар, каян эш табасың син?
Габдулла. Син табып бирерсең.
Альберт. Ладно, пошли.

Габдулланы ашыктырып бүлмәдән алып чыга. Алар аяк очларына гына басып баскычтан түбәнгә төшәләр. Алар төшкәндә, Айсылу кермәгән була. Альберт тәрәзә пәрдәсенең почмагын ачып Айсылуга күз салып ала. Габдулла иң беренче эш итеп савыт-сабаларны урынына куя. Аннары фотога төшерер өчен яшерен почмак сайлый. Альберт шкафны ачып карый. Анда Айсылуның коену кастюмын күреп түшенә тыгып куя. Айсылуның аяк тавышлары ишетелүгә, икесе ике почмакка посалар. Айсылуның күңеле күтәренке. Ул авыз эченнән ниндидер җыр шыңшый. Кулындагы чәчәкләрен җилпәзә итеп битен җилләтеп ала.

Айсылу. Өсне алыштырмый булмас, ахры.

Шкафтан берничә күлмәк арасыннан майка белән шорты ала да күлмәген сала. Ул купальниктан калуга, кулына кара авторучкамы-нидер тотып Айсылу каршына Альберт килеп чыга. Айсылу каушап кала. Шул хәлдән файдаланып, Альберт Айсылуны кочып ала. Айсылу аны бар көченә этә.

Айсылу *(кычкырып)*. Габдулла абзый, Сәрбиназ апа! Бүре читлегеннән качкан! Керегез тизрәк! Керегез!

Айсылу белән Альберт шактый көрмәкләшеп алалар. Айсылу ишек төбендә яткан туфли белән Альбертның маңгаена да менеп төшә. Альберт әллә ни каршылык күрсәтми генә, җае чыккан саен Айсылуны кочарга тырыша, бер тапкыр үбеп алырга да өлгерә. Тартыша торгач, Альберт Айсылуның лифчик бавын өзә. Айсылу оялудан кулы белән күкрәген каплый. Альберт аның күкрәген теше белән каптырырга тырыша.

Айсылу. Шакшы авызың белән миңа үреләсең. Әтиеңә әйтеп тиреңне каезлатачакмын. Бетле тәре.

Хәзер этиеңә шылтыратам.

Альберт Айсылуның сүзләреннән куркып калган булып кылана һәм качарга тели. Айсылу аны җибәрмәс өчен Альбертка барып ябыша. Альберт көтмәгәндә генә аңа борыла да Айсылуны күтәреп алып диванга сала һәм өстенә ятмакчы була. Айсылу чәбәләнә, кычкыра, ләкин аның тавышы көчсез чыга. Бу хәрәкәтләрнең һәрберсен почмакка поскан Габдулла фотога төшереп бара. Ниһаять, Айсылу Альберт кулыннан ычкынып тышка йөгереп чыга. Ул арада каравылчы Габдулла фотоаппарат белән карточкаларны Альбертка биреп өлгерә. Үзе шыпырт кына бүлмәсенә тая. Альберт яшь юлбарыс кебек өскә сикерә һәм берни булмагандай бүлмәсенә кереп бикләнә. Айсылу белән өйгә ике сакчы керә.

Беренче сакчы. Кая ул, Айсылу Акбулатовна?

Айсылу. Әле генә менә шушында иде. Качмакчы булды.

Икенче сакчы. Качып әллә кая китә алмас.

Беренче сакчы Альберт бүлмәсенә менеп китә. Анда Альберт берни булмагандай гырылдап йоклап ята. Сакчы аңа китереп тибә. Альберт сикереп тора.

Альберт. Ты что, падла?! На кого поднимаешь руку?

Беренче сакчы. Ачкычны сиңа кем бирде?

Альберт. Нинди ачкыч? Сез әллә исерекме? Эш вакытында эчеп йөргәнегезне папаняга әйтсәм, знаете, что он с вами сделает?!

Беренче сакчы. Не валяй дурака. Габдулла ачып чыгардымы?

Альберт. Әгәр чыккан булсам, мин монда кереп ятмас идем, дурак баш.

Беренче сакчы. Айсылу Акбулатовнага кем ташланды?

Альберт. Померещелось наверно. Көн буе одна. Тут с ума сойти можно.

Беренче сакчы Альбертка тагын бер тибеп ала да аска төшә. Икенче сакчы белән Айсылу каравылчыны эзлиләр. Габдулланың бүлмәсенә сугылалар. Ул эчке яктан бикле. Сакчы аны тибеп ача. Габдулла үз бүлмәсендә караватта ята. Өстәлдә шешә. Шешә төбендә йөз граммлап аракы калган. Сакчы Габдулланы җилтерәтеп торгыза.

Икенче сакчы. Син ачып чыгардыңмы Альбертны?

Габдулла исереккә салыша. Юкса ул авызыннан ис килерлек кенә эчкән була.

Габдулла. Альберт, нинди Альберт?

Икенче сакчы *(тибеп җибәрә)*. Не валяй дурака. Синнән башка кешедә ачкыч юк.

Габдулла *(айнып киткәндәй булып)*. Ә-ә, ачкыч?! Сезгә ачкыч кирәкмени? Менә алар.

Габдулла мендәр астыннан ачкычлар бәйләмен алып сакчының аяк астына ыргыта. Үзе чын артистларча күз яшьләре белән елый башлый.

Габдулла. Миңа доверие юк икән, китәм. Хәзер үк әйберләремне җыям да...

Айсылу. Туктале, Габдулла абзый. Алар бит сораша гына.

Габдулла *(сакчыларга ымлап)*. Кабып йотарга тели алар. Китәм, бер көн дә тормыйм. Вокзалда яшәрмен.

Айсылу. Туктале, Габдулла абзый, Гәрәй Мингалиевич кайтсын. Ул үзе хәл итәр.

Гәрәй исемен ишетүгә, сакчылар коелып төшә.

Беренче сакчы. Бәлки, Айсылу Акбулатовна...

Икенче сакчы. Әллә күзегезгә генә күренде микән, Айсылу Акбулатовна?

Айсылу. Сез мине акылдан язган дип уйлыйсызмы әллә?

Сакчылар. Алла сакласын.

Сәрбиназ бүлмәсендә шыңшыган тавыш ишетелә. Сакчылар да, Айсылу да аның бүлмәсенә юнәлә.

Айсылу. Ни булды, Сәрбиназ апа?

Сәрбиназ *(күз яшьләрен сөртә)*. Булды инде.

Айсылу *(сакчыларга чыгып китәргә ым кага. Алар чыгып китә)*. Йә, Сәрбиназ апа, сөйлә инде.

Сәрбиназ. Аны сүләргә дә оят, кызым.

Айсылу. Юк инде, Сәрбиназ апа, өйдәге хәлләрне мин белергә тиеш. Йә-йә, тынычлан да сөйлә.

Сәрбиназ. Сүләрлек нәрсә дә түгел инде ул...

Айсылу. Алайса, нишләп болай елап ятасың?

Сәрбиназ. Айсылу кызым, ярар, әйтсәм әйтим инде. *(Айсылу Сәрбиназның күзләренә карый.)* Ни бит, Айсылу кызым, Габдулланың котыра торган чире бар икән.

Айсылу. Ничек?

Сәрбиназ. Тиктомалдан миңа ташланды.

Айсылу. Бер дә андый эшләре күренми иде бит.

Сәрбиназ. Минем әллә кай җирләремә үрелә.

Айсылу. Ах, оятсыз! Исерек булгандыр ул. Аның шулай салгалый торган гадәте бар шул. Гәрәйгә әйтермен мин, Сәрбиназ апа, ул берәр чарасын күрер. Ә хәзер битләреңне юып ал да үз эшеңә кереш. Юк-бар өчен елап торырга без бит инде бала-чага түгел. Шулаймы?

Сәрбиназ аның белән килешеп башын кага. Ул урыннарын җыештыра. Айсылу сакчылар янына чыга. Сакчылар бер-берләренә карашып ала. Алар Айсылуга нидер әйтергә җыена. Айсылу аларны аңлый һәм сорау бирә.

Айсылу. Ни әйтергә телисез?

Беренче сакчы. Бу инцидентны, Айсылу Акбулатовна, Гәрәй Мингалиевичка ничек аңлатырбыз икән?

Икенче сакчы. Һәм ул бу хәбәрне ничек кабул итәр?

Айсылу. Ничек булган, шулай әйтергә кирәк. Хуҗадан яшерен эш булырга тиеш түгел.

Беренче сакчы. Ул вакытта безнең беребезгә дә рәхим-шәфкать булмаячак.

Икенче сакчы. Әйе, Гәрәй Мингалиевичның ачуы чыкса, ул аюны сугып үтерә ала.

Габдулла керә. Ул сакчыларның сүзен ишетә.

Габдулла. Раз ачкычлар минем кулда икән, гаеп миндә. Чыгып китеп, кереп ятканын күрми калганмындыр. Иелгән башны кылыч кисмәс. Гәрәй Мингалиевич кайту белән үзем сөйләп бирәм. Эштән куса куар, минем болай да үләр вакыт җиткән.

Айсылу аптырашта кала. Аңа сакчылар да, Габдулла абзый да жәл. Һәм ул бер карарга килә.

Айсылу. Ярый алайса, бу хәлне булмаган дип саныйбыз. Гәрәй Мингалиевичка бу хакта теш арасыннан да чыгарасы булмагыз.

Сакчылар икесе бергә. Рус әйтмешли, могила!

Айсылу. Ишетелә калса, күсәкнең юан башы Альбертка төшәчәк. Ә Альберт, ничек кенә булмасын, Гәрәй Мингалиевичның бердәнбер улы. Ул аның төзәлеренә ышана. Наркоман бит ул, бәлки, үз-үзен белештермичә йөргән чагы булгандыр.

Сәрбиназ бүлмәсеннән чыга.

Сәрбиназ. Бигрәк шәфкатьле күңелле кеше син, Айсылу балам. Ләкин шәфкать кайчакта башка күсәк булып төшә.

Сакчылар да Айсылу каршына килеп баш ияләр. Рәхмәт әйтәләр. Хәтта Габдулла күзләрен төкерек белән чылатып Айсылу янында тезләнә.

Габдулла. Фәрештәләр токымыннандырсың син. Бу хәтле изге булмас идең.

Айсылу. Йә, ярый, бераз сентиментальничать итеп алдык. Хәзер һәрберебез үз урынына! Карагыз аны, бер секундка да Альберт бүлмәсен күздән ычкындырмагыз.

Барсы да җиңел сулап үз урынына китә. Айсылу да авыр уйларыннан бушанырга дип бакчага чыга. Гамакка ятып уйга чума. Бераздан Айсылуның телефонын күтәреп Сәрбиназ йөгереп чыга.

Сәрбиназ. Мә тизрәк, әтиләрең шылтырата.

Айсылу телефонны ала.

Айсылу. Алло, тыңлыйм. Әтием, синме? Ә әни кайда? Эштә? Шундый сагындым мин сезне! Хәзерге акылым булса, сезне әллә кая җәһәннәм артына җибәрмәгән булыр идем. Ничек соң анда тормыш итү яклары? Әй, сез һәрвакыт яхшы дисез инде. Нигә соң бер кайтып китмисез? И-и, ул йортыгызны салып бетергәнче әле без картаербыз. Дөнья без юк җирдә генә әйбәт, диләр түгелме соң? Минеке? Минеке Аллага шөкер. Гәрәй белән бик тату яшибез, күз генә тимәсен. Ул мине бик ярата. Гомердә беркем әйтмәгән матур сүзләр әйтә. Ни теләсәм, шуны ала. Әле менә икебез утырткан куш каенны яшен суккан иде. Нәкъ шундый каен утырттырды. Тик яфраклары бераз шәлперәеп тора. Минем синнән сер яшергәнем булмады, эти, үзең беләсең. Әнигә сөйләмәгәннәрне мин сиңа кайтып сөйли идем. Бала? *(Айсылу уйланып тора.)* Вакыты житкәч булыр, эти. Ярый, эти, ярый. Әнигә күп сәлам әйт. Безнең өчен борчылмагыз. Әле үзем дә шылтыратырга дип тора идем. Рәхмәт, сау бул. Океаннар аша кочаклап үбәм.

Әтисе белән сөйләшкәч, Айсылуның күңеле күтәрелеп китә. Бакчадагы каен янына барып килә. Айсылу каенны кочаклап назлаган чагында, коймадан сикереп монтер керә. Ул бер кулына кәгазь белән төреп чәчәк тоткан. Исәбе — тиз генә чәчәген утыртып чыгып китү.

Айсылу. Берүк шиңмә, каенкаем. Син бит безнең мәхәббәтебезнең символы. Су сибим әле үзеңә. Хәзер чиләк белән су алып килəм дә... *(Айсылу, борылуга, монтер егетне күреп ала.)* Әй, нишлисең анда? Чәчкә урларга кердеңме?

Монтер. Юк, урларга түгел, киресенчә, утыртырга.

Шунда аны Айсылу танып ала.

Айсылу. Уф Алла, син генә җитмәгән идең.

Монтер. Мин хәзер китәм. Менә бу мәхәббәт чәчәген генә утыртам да.

Айсылу. Мәхәббәт чәчәге? Шундый чәчәк тә буламыни?

Монтер. Була икән шул.

Монтер кәгазен сүтә. Анда ялкын кебек кып-кызыл чәчәк. Ул тамырдагы балчыгы белән алынган. Айсылу аңа сокланып карый.

Айсылу. Матур икән үзе. Ул шундый була микәнни?

Монтер. Бәлки, мәхәббәт чәчәге төрле җирдә төрлечә буладыр, ә безнең якта менә шушыны мәхәббәт чәчәге дип атыйлар. Мин аны бөтен урманны айкап таптым. Кая, берәр көрәк ише нәрсә бармы?

Айсылу гаражга сөяп куелган көрәкне алып бирә.

Айсылу. Тиз бул түлке.

Монтер. Ирең бик корымыни?

Айсылу. Анда синең эшең юк.

Монтер. Ә сакчыларың күрер дип курыкма. Әле генә алар кем беләндер телефоннан сөйләштеләр дә машиналарына утырып сыпырдылар. Хуҗа үзе чакырткандыр, ахры, ут капкандай кыланмаслар иде.

Айсылу. Ничек кенә булмасын, синең моннан тизрәк таюың хәерле, һәм яңадан күренмәвең.

Монтер. Ярар, бүтән килмәм, мин бәхетле кешене күрер өчен киләм бит монда. Юкса бәхетлеләр сирәгәя бара.

Айсылу. Теге үрдәк бәбкәсен дә бассейнга син җибәргәнсеңдер әле.

Монтер. Үрдәк бәбкәсе?

Айсылу. Белмәгән булып кыланмасана, ачу китереп. Нишләп кысылып йөрисең син безнең тормышка?

Монтер. Бетте, бетте. Мин киттем. Бәхетле кешегә ачулану килешми. Юкка ачуың килә икән, димәк, син дә бәхетле түгел.

Айсылу. Тәмам туйдырдың. *(Капка ягына карап ала.)* Бар әле, табаныңны ялтырат. Юкса...

Монтер. Юкса ирем кайтып җитәр дип куркасыңмы?

Айсылу. Куркам шул.

Монтер. Куркасың икән, димәк, сез бер-берегезгә ышанмыйсыз.

Айсылу. Җитте, фәлсәфә сатма.

Монтер. Бәхет төшенчәсен мин ялгыш аңлаганмын, ахры. Хуш, чибәркәй. Мин яңадан килмәм. Бәхетле бул!

Китеп бара. Айсылу уйланып кала. Сәрбиназның үз янына килеп басканын да сизми.

Сәрбиназ. Нинди егет булды ул?

Айсылу сискәнеп китә.

Айсылу. Нәрсә?

Сәрбиназ. Теге койма аша сикергән егет кем иде ул, дим?

Айсылу. Сакчылар гына җитмәгән, син дә мине күзәтәсеңме?

Сәрбиназ. Нишләп күзәтим? Гәрәй Мингалиевичка җиткерсәләр, күңелсезлек килеп чыкмасын дим.

Айсылу *(катгый итеп)*. Чыкмас! Бүген бөтен кеше минем кәефемне кырырга әзерләнеп торган диярсең.

Сәрбиназ. Мин, кызым, киресенчә, сине юк-бар гайбәтләрдән саклар өчен тырышам. Теге карачкыга *(Габдуллага күрсәтә)* ышанып җитмә син. Аның авызы тишек, эче кара. Ул сезнең сөйләшкәнегезне тыңлап торды.

Айсылу. Шпион өстенә шпион икән бездә.

Сәрбиназ *(үпкәли)*. Мин сак бул дип әйтергә генә теләгән идем.

Айсылу. Әллә нинди күңелсез көн булды бүген. Альберт төшеп котны алды. Хәзер син күңелгә шик саласың.

Сәрбиназ. Айсылу балам, сине бик яратам бит мин. Бәхетегезгә кара тап төшә күрмәсен дип кенә әйтүем иде.

Айсылу. Ярый, әйткән-беткән. Иң яхшысы, бер җилләнеп кайтырга кирәк. Шактыйдан табигатькә чыккан юк.

Сәрбиназ. Теге төлке күргән җиргә барырбыз, яме.

Айсылу. Ярар.

Боларның сөйләшкәнен каравылчы Габдулла ишетеп ала да йөгереп Альберт бүлмәсенә менеп китә. Ачып керә.

Габдулла. Чибәр анаң машинасы белән каядыр барырга җыена.

Альберт. Качарга дисеңме? Юк, качмыйм әле. Минем үз планнарым бар.

Габдулла. Ярый алайса.

Шул вакыт Альбертның башына ниндидер уй килә. Һәм ул ыргылып ишектән чыга.

Альберт. Батсак, бергә батабыз, смотри.

Габдулла. Нигә мин батарга тиеш. Минем Гәрәйдә үз ачуым бар. Сине чыгарам икән — шуның өчен генә.

Альберт. Нинди ачу?

Габдулла. Әтиең мәктәп директоры булып эшләгәндә, мин мәктәптә завхоз идем. Завхозны үзең беләсең, бөтен нәрсә минем кулда. Бер укытучының өен сиплэтергә дигән бүрәнәләрдән мин үземә мунча салып куйган идем. Әтиең мунчаны мәктәпкә илттереп, балаларга мастерской иттерде.

Альберт. Да, этинең крутойлыгы бар. Ничек сине үзенә алды соң?

Габдулла. Жәлләгәндер, бәлки. Заманалар болганып китте. Ул мәктәп иске иде, ябылды. Шунда этиең аны үзенә эләктереп калды.

Альберт. Понятно, мин киттем.

Аска төшеп китә. Анда Айсылу белән Сәрбиназ гөрләшеп сөйләшә.Альберт качып тыңлап тора.

Айсылу. Нишләптер вакыт-вакыт минем кош булып очасым, үзебез яшәгән җирләрне биектән күрәсем килә.

Сәрбиназ. Бәлки әле, очкан кошлар менә безгә — кешеләргә кызыгалардыр.

Айсылу. Нигә?

Сәрбиназ. Боларның язларын-көзләрен бер яктан икенче якка очып йөриселәре, һәр елны яңа оя корасылары юк, диләрдер.

Айсылу Сәрбиназның иңеннән кага.

Айсылу. Акыллы да инде син, Сәрбиназ апа. Философ булып тугансың син.

Сәрбиназ. Бәрәңге философы.

Айсылу. Нигә алай дисең?

Сәрбиназ. Соң, аш пешерүче кем булсын инде.

Айсылу. Алай димә, Сәрбиназ апа. Дөньяда цивилизация нәкъ аш пешерүчедән башланган. Ашны пешермичә ашасак, һаман кыргый хәлдә яшәр идек.

Сәрбиназ. Син әллә ниләр беләсең, Айсылу кызым.

Айсылу. Ялагайланма, Сәрбиназ апа. Мин бит болай да сине яратам. Әйдә, җыенып беттеңме?

Сәрбиназ. Сумкаларны тутырдым.

Айсылу. Әйдә алайса, китик. Гәрәй Мингалиевичка записка калдырыйм әле. Хәер, шылтыратырга телефон бар бит. Һаман шуны онытып җибәргәлим.

Телефоннан номер җыя. Ләкин Гәрәйнең мобильный телефоны «Абонент временно отключен» дип җавап бирә.

Айсылу. Тоташып булмады, Сәрбиназ апа. Гәрәйнең эше тыгыздыр, күрәсең. Андый чакларда ул телефонын сүндереп куя. Ярар, китик. Без озак йөрмибез бит.

Идарә пульты белән гаражны ача. Шул вакыт Габдулла йөгереп чыга.

Габдулла. Берәр яры барырга җыендыгызмы әллә, Айсылу Акбулатовна?

Айсылу. Әйе, бераз һавада йөреп кайтабыз. Син Альбертны күз уңыннан ычкындырма. Юкса Гәрәй Мингалиевичтан беребезгә дә пощада булмаячак.

Габдулла. Ишеген йозаклап кына түгел, терәтеп үк куярмын. Тыныч йөреп кайтыгыз, Айсылу Акбулатовна.

Машина ачкычын бармагында бөтерә-бөтерә Айсылу гаражга кереп китә. Сәрбиназ тышкы якта машина чыкканны көтә. Кабызу ачкычын бер боруга ук машинаның моторы тигез гүләп эшли башлый. Айсылу капкадан чыга. Идарә пульты белән гаражны бикли. Сәрбиназ олы сумкасын арткы утыргычка куя. Айсылу янындагы алгы утыргычка Сәрбиназ кереп утырам гына дигәндә өйдән өермәдәй атылып Альберт килеп чыга. Каравылчы карт тизрәк капканы ачарга йөгерә, ләкин Альберт аның башына Сәрбиназның кулындагы сумкасын алып каты гына тондыра. Габдулла ава. Айсылу белән Сәрбиназ бу хәлләрне аңлап өлгергәнче, Альберт рульдән Айсылуны тартып төшерә дә арткы утыргычка ыргыта. Сәрбиназны да шунда төртеп кертә һәм ыргылып кузгалып китә. Айсылу эшнең мондый юнәлеш алуын күреп кесәсеннән тиз генә телефон алып номер җыймакчы була. Ләкин Альберт көзге аша аны күзәтеп бара икән. Тиз генә тормозга баса да артка борылып Айсылуның кулыннан телефонын тартып ала.

Альберт *(усалланып).* Кара аны, мин синең белән шаярырга җыенмыйм. Кымшанганыңны гына күрсәм дә, машинадан ыргытам.

Альберт машинаны бөтен көченә куа. Бик күп машиналарны узып китә. Сәрбиназ нидер әйтергә омтылып берничә мәртәбә урыныннан кузгалмакчы була, ләкин Айсылу аны тыеп кала.

Альберт. Пышылдашкалап, этлек уйлап бармагыз, юкса бик каты үкенерсез. Ә бәлки, үкенеп торырлыгыгыз да калмас.

Сәрбиназ *(бөтен батырлыгын җыеп).* Альберт улым, мин бит сине унбиш яшеңнән үк беләм.

Альберт. Ну и что же?

Сәрбиназ. Син бит болай миһербансыз бала түгел идең. Төшереп калдыр безне.

Альберт. Ха-ха-ха! Син, тетя Сәрбиназ, за дурака, что ли, меня считаешь? Разве шушындый ценный грузны төшереп калдыралар? Сезне папаня бик кыйммәткә сатып алачак.

Сәрбиназ. Сатылырга без бит коллар түгел.

Альберт. Бу дөньяда һәркем кемнеңдер колы.

Сәрбиназ. Ярар, без бәләкәй кеше инде, коллар булыйк ди. Син әтиеңне дә кол дияргә уйламыйсыңдыр бит.

Альберт. Папаня колның да колы. Папаня сезне генә кол итеп тора, ә аның үзен — десятки людей. Да, ладно уж... Чего вам говорить.

Сәрбиназ Альбертның сүзләреннән соң гаҗәпләнеп, кулларын ботына сугып куя. Айсылу аңа ым белән генә тынычланырга, артыгын сөйләшмәскә куша. Машина выжлап олы юл буйлап оча.

Сәрбиназ. Альберт улым...

Альберт. Әле улың булдыммыни? Теге көнне миннән җирәнеп төкереп калган идең бит.

Сәрбиназ. Син мине кем беләндер бутыйсың, улым.

Альберт. Син ведьманы беркем белән дә бутап булмый.

Айсылу. Тел әрәм итмә шуңа, Сәрбиназ апа. Ул бит яхшылыкны аңлый белми.

Альберт. Какой яхшылык? Кем миңа яхшылык итте?

Сәрбиназ. Синең бөтен этлекләреңне Гәрәй Мингалиевичка әйтә барырга кирәк булган.

Айсылу. Нинди икәнен бик яхшы беләсең, клоунланып маташма.

Альберт *(ыржаеп).* Ха-ха! Нинди яхшы кешеләр! Если хотите знать, сез үзегезнең шкурагыз өчен курыктыгыз. Сез бөтенегез дә бер-берегездән куркып яшисез.

Сәрбиназ. Синең «батырлыкларыңны» да беләбез инде. Әтиеңнең кесәсеннән акча чәлүеңне белгәч, Гәрәй Мингалиевич сине бакалы базга ябып куйган иде. Менә әлеге «батырлыгың» өчен дә башыңнан сыйпамас.

Альберт. Как сказать. Бәлки әле, каршыма килеп тезләнер.

Сәрбиназ. Гәрәй Мингалиевичны тезләндерер өчен борының кипмәгән әле.

Альберт боларны куркытыр өчен түш кесәсеннән пистолет чыгарып, машинасының приборлар панеле өстенә куя. Егетнең бу хәрәкәте арттагыларга нык кына психологик тәэсир ясый. Алар аның газ пистолеты икәнлеген һәм күптән баллоны беткәнлеген белмиләр.

Альберт. Мин сезне урман эчендәге бер подвалга ябып куячакмын. *(Ул үзеннән бик канәгать. Йә шаркылдап көлә, йә кулларын угалап куя.)* Папаня үзенең оҗмах кошын бик кыйммәт бәягә сатып алачак. Акча кирәк миңа, акча. Ничек җырлыйлар әле? «Яшел акча, күк акча, Миңа кирәк күп акча»,— диләрме? Дөрес җырлыйлар. Барыбызга да күп акча кирәк. Башта әтинең матур курчагы белән подвалда кети-мети уйнап алырбыз.

Айсылу. Синең кебек рухи гарипләргә үземә кул тидерткәнче, егылып үләм мин.

Альберт. Ха-ха-ха! Недотрога, имеш. Менә хәзер үк мин синең ботыңнан умырып тотам. Нишләрсең икән?

Альберт рульне сыңар кулы белән генә тотып Айсылуның ботына үрелә. Айсылу аның кулына чәчен кыстырган шпилькасы белән кадый. Альберт кинәт кулын тартып ала. Машинасын туктатып, Айсылуны бераз тәпәләп алмакчы була. Ләкин арттан кызу гына килгән ике машинаны күреп, аларны үзләрен куып килүчеләр дип уйлый.

Альберт *(Айсылуга).* Сука! Миннән болай гына ычкынырмын димә. Иң беренче итеңне, маеңны үзем кимерәм. Аннары чиратлап другларга. Папаня куып чыгаргач, может, мине ярата башларсың.

Айсылу. Кабахәт! Синең ишеләрне ничек җир күтәрә икән?

Альберт. Әйе, мин кабахәт һәм аны яшермим дә. Ә сез папаня белән спектакль уйнап йөрисез. Мәхәббәт спектакле.

Айсылу. Нинди спектакль?

Альберт. Теге монтер белән крутить иткәнеңне белми дисеңме әллә? Папаня белән водевиль уйныйсыз да монтер егет белән мунчага кереп шурый-мурый кыланасыз. Сиңа папаняныкы гына җитми. Менә мин сине рәхәтләнеп каезлаячакмын.

Айсылу. Кулың кыскарак!

Альберт. Сиңа гына буем җитәр. Үзең үк миңа рәхмәт укырсың. Ха-ха-ха! Рәхәт үлем белән үтерәчәкбез без сине.

Айсылу сумкасыннан сулы шешә алып Альбертның башына сукмакчы була, ләкин Альберт көзге аша аның кизәнүен күреп ялт кына бер якка авыша. Машина чайкалып китә. Сулы шешә машинаның алгы тәрәзәсенә тия. Шешә юка полиэтиленнан эшләнгәнлектән, тәрәзә ватылмый. Альберт тиз генә һушка килеп бардачок өстендәге пистолетын ала.

Альберт. Хәзер атып үтерәм, юха елан!

Айсылу. Үтер, куркак җан!

Альберт. Синең ише сукалар аркасында картаеп беткән ирләр аза.

Сәрбиназ. Әллә этиләреңнең аерылышуларын Айсылудан күрәсеңме?

Альберт. Күрәм.

Сәрбиназ. Алар әллә кайчан аерылышканнар иде бит инде.

Альберт. Менә мондый кәнтәйләр барлыгын белгәнгә.

Айсылу. Тел әрәм итмә шуңарга, Сәрбиназ апа. Безнең сүгүебез дә аның өчен бүләк.

Альберт. Ненавижу мин сезнең ишеләрне. Бөтенегезне тураклап бетерәсем килә.

Сәрбиназ. Әстәгъфирулла-тәүбә! Гәрәй Мингалиевичтан шушындый бала тусын инде.

Альберт. Идиотлар.

Альберт тагын көзгегә күз сала. Теге машиналар якынайган кебек тоела аңа. Тизлекне тагын да арттыра. Инде арттагы машиналардан бераз ераклаштым дип тынычлангач кына, асфальт аркылы сыер көтүе чыга башлый. Көтүчеләр юлның ике ягына да басканнар, «һоп, һоп» дип сыерларын тизрәк бу афәтле юлдан чыгарып бетерергә теләсәләр дә, сыерлар әкрен генә баруларын белә. Альберт сүгенә. Юл читенә дә төшеп булмый, канау шактый тирән. Ул бер ала сыерның кабыргасына килеп бәрелә. Сыер егыла, машина туктый. Шуны гына көткән Айсылу белән Сәрбиназ арткы ишекләрнең икесен ике якка ачып юлга сикерәләр.

Сәрбиназ. Коткарыгыз!

Айсылу. Ярдәм итегез, ярдәм! *(Кул күтәрә.)*

Ул арада арттагы машиналар да килеп җитә. Алар Альбертны куучылар булмый. Сәрбиназ бер машина янына килеп ярдәм сорый.

Сәрбиназ. Коткарыгыз, зинһар, безне менә бу явыз бәндәдән.

Машинадагы кеше башын чыгарып карый.

Машина йөртүче. Нәрсә, бу кызны урлап алып баралармы әллә?

Сәрбиназ. Әйе.

Машина йөртүче. Мондый кызны мин дә урлар идем. Ха-ха-ха!

Көтүчеләр егылган сыерны өстерәп юл читенә чыгаралар. Альберт яңадан кузгала, ләкин тагын бер сыерга барып төртелә. Көтүчеләрнең моңа ачуы чыга. Берсе йөгереп килеп аның алгы капотына ятып тәрәзәсен каплый, икенчесе Альбертны машинасыннан тартып төшерә. Ләкин Альберт үзе белән пистолетын эләктереп өлгерә. Көтүчеләр каушап кала. Шул вакыт арттан килгән икенче машинадагы урта яшьләрдәге ир, Альберт пистолетын көтүчеләргә төзәп торган арада, арттан килеп аның кулына суга. Пистолет төшеп китә. Болар Альберт белән мәш килеп ятканда, артта шактый машина җыела. Ут көйләүчеләрнең линиягә чыгышлары икән. Монтер Айсылуны шундук танып ала.

Монтер. Нәрсә булды?

Сәрбиназ. Менә бу адәм актыгы Айсылуның машинасына кереп утырды да безне әллә кая апкитмәкче.

Көтүчеләр инде Альбертның кулларын артка каерып бәйләргә дә өлгергән, алар Сәрбиназ белән Айсылуга карый.

Көтүчеләр. Йә, нишләтергә моны?

Сәрбиназ. Милиция чакыртырга кирәк. Пусть хөкем итсеннәр.

Көтүче. Дөрес, милиция чакыртырга. Сыер хакын түләсен.

Айсылу. Юк, җәмәгать, аны әтисе хөкем итсен. Ул әтисен хурлыкка калдырмакчы иде бит. Әнә машинаның арткы утыргычына кертеп салыгыз. Ә сыер хакын түләр ул. Менә минем визит карточкам, шуның белән шылтыратырсыз.

Көтүчеләр Альбертны бераз бәргәләп арткы утыргычка тыгып куялар. Машиналар китә, юл ачыла. Ләкин монтер егетнең Айсылуларны ташлап китәсе килми.

Монтер. Нәрсә эшләмәкче булды соң ул сезнең белән?

Айсылу. Заложник итеп, безне әтисенә сатмакчы иде исәбе. Йә, ярый, без кузгалабыз. Рәхмәт сезнең барыгызга да.

Монтер. Теге наркоман, димәк, шушы була?

Сәрбиназ. Шушы.

Айсылу машинасына кереп утыра. Кабыза. Аның кузгалып китәргә җыенганлыгын күреп, монтер егет йөгереп килә.

Монтер. Сез нәрсә, ханым, әллә бу хәшәрәтне үзегез генә алып кайтмакчы буласызмы?

Айсылу. Бәйләнгән бит ул.

Монтер. Бүре баласын бүреккә салсаң да урманга карый. Юк, мин сезне җибәрә алмыйм. Үзем илтешәм. Мин хәзер...

Монтер егет Айсылулар машинасы янына килә. Сәрбиназ Альберт чәбәләнмәсен өчен аның аяклары өстенә үзенең олы сумкасын куеп, гәүдәсе белән Альбертны утыргыч артына кыса.

Монтер. Апа, сез үзегезнең хуҗабикәгез янына, алга утырыгыз. Олы кешегә болай җайсыз булыр.

Сәрбиназ. За то ышанычлырак.

Монтер. Ярый алайса. Без аны ике яклап кочаклап кайтырбыз.

Айсылу кузгалып китә. Альберт, уңгарак авышканнан файдаланып, Сәрбиназның җилкәсен тешли. Ул кычкырып җибәрә. Айсылу тормозга баса.

Айсылу. Нәрсә булды?

Сәрбиназ. Җилкәмне умырып тешләп алды, чабата авыз.

Монтер. Хәзер без аны тешләшмәслек итәрбез.

Машина идәнендә аунап ятучы бер чүпрәкне алып Альбертның авызына тыга.

Айсылу. Карале, егет, синең исемең ничек соң?

Монтер. Лимон.

Сәрбиназ. Менә тагы иске авызга яңа бәрәңге! Шундый исем дә буламыни?

Айсылу кузгалып китә.

Монтер. Мин бит совет чорында туган малай. Ул чагында лимоннар булмаган. Миңа авырга узгач, әнкәйнең бик каты лимон ашыйсы килгән. Киткән әти Казанга. Йөргән магазиннарда. Ләкин аның лимон сораганын ишеткәч, кычкырып көлгәннәр генә. Шулай да йөри торгач, базардан бер-ике лимон тапкан бу. Тик, хәерчегә җил каршы дигәндәй, электричкада кайтканда, әтинең сумкасын чәлгәннәр. Шуннан инде мин тугач, миңа Лимон дип исем кушканнар. Ичмасам, үз лимоныбыз булыр ди-гәннәрдер.

## УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Болар шулай юлда сөйләшеп кайта, ә вакыйгалар яңадан Гәрәй Мингалиевичлар йортына күчә. Чөнки Гәрәйгә ашыгыч рәвештә өйгә кайтырга туры килә. Капка төбендә Гәрәйне Габдулла каршылый. Хуҗа машинасыннан төшүгә, каравылчыга Айсылуны чакырырга куша. Габдулла сүзне ничек башларга белмичә таптангалап тора.

Гәрәй. Нәрсә карап каттың? Бар, чакыр Айсылуны.

Габдулла. Ни бит әле, Гәрәй Мингалиевич...

Гәрәй. Нәрсә ни?

Габдулланы этеп җибәрә дә өйгә кереп китә. Өйдә бөтен бүлмәләрне айкый, ләкин беркем юк. Альберт бүлмәсенә менеп төшә — ул да ачык.

Гәрәй. Нишләп өйдә беркем юк? Альберт бүлмәсе нигә ачык?

Габдулла. Әйтсәм әйтим инде, Гәрәй Мингалиевич, малаегыз белән Айсылу Акбулатовна гыйшык-

мыйшык уйныйлар бит.

Гәрәй. Нинди әкият сөйлисең, дурак!

Габдулла. Мин моны сездән яшерә алмыйм, Гәрәй Мингалиевич. Намусым кушмый.

Гәрәй. Намус? Булганы бармы соң аның синдә?

Габдулла аны ишетмәгәндәй үзенекен сөйли бирә.

Габдулла. Менә бүген дә Альбертны кыстый-кыстый машинасына утыртып алып чыгып китте.

Гәрәй. Берәр хәйлә корып маташасың бит, хәшәрәт.

Габдулла. Айсылу Акбулатовнага бер Альберт кына да җитми. Әле аның янына көн саен бер монтер егет килеп йөри.

Гәрәй. Нинди монтер тагы?

Габдулла. Ике аяклы, ике куллы.

Гәрәй. Җитте! Юкны сөйләмә. Йә ачудан изеп ташлармын.

Габдулла. Сүзләремә генә ышанмасагыз, әнә бакчагызга чыгып карагыз. Ул сезнең сөекле хатыныгызга әллә нәрсәләр китерә.

Гәрәй ачуланып бакчага чыгып китә. Бассейнда йөзеп йөрүче үрдәк бәбкәсен күреп ала.

Гәрәй. Бу үрдәк бәбкәсе каян килгән монда?

Габдулла. Шул монтер егет сөекле хатыныгызга китерде. Үз күзләрем белән күрдем.

Гәрәй. Булмас. Нигә кирәк Айсылуга үрдәк бәбкәсе?

Габдулла. Сезнең балагыз юклыкка ишарә. Беркөн сөйләнгәннәрен ишетеп тордым.

Гәрәй. Нәрсә тагын?

Габдулла. Теге монтер аламасы Айсылу ханымны кочып алды да: «Кайгырма, мәхәббәтем, баланы мин сиңа үзем ясап бирермен», — диде. Аннары икесе дә көлештеләр.

Гәрәй *(Габдулланы этеп җибәрә)*. Әкиятеңне берәр мунча пәриенә сөйләрсең.

Габдулла. Теге монтер белән синең гүзәл хатының мунчагызның пәриләрен качырып бетергәннәрдер инде. Алар кешечә генә кыланмыйлар бит. Ә беркөнне мунчадан чыккач, Айсылу Акбулатовна белән чүкердәшеп менә бу чәчәкне утырттылар.

Гәрәй. Нинди чәчәк?

Габдулла. Мәхәббәт чәчәге. Монтер егет хәләл җефетегезгә шулай дип аңлатты.

Гәрәй Габдулла күрсәткән чәчәкне барып карый. Ачуы бик чыга, ләкин әле Айсылуның үзен күрми торып берни дә эшләми. Гәрәй кесәсеннән телефонын алып номер җыя башлый, ләкин шул вакыт Айсылуның машинасы капка төбенә килеп туктый. Гәрәй эре-эре атлап алар янына килә. Машина эченә күз сала, Айсылуны күрә.

Гәрәй. Бу ни дигән сүз? Нинди спектакль оештырдыгыз сез?

Айсылу. Менә улыгызны алып кайттык.

Гәрәй *(салкын)*. Рәхмәт.

Машинадан Сәрбиназ белән монтер төшә.

Сәрбиназ. Гәрәй Мингалиевич, бу безнең коткаручыбыз. *(Монтерга күрсәтә.)* Исеме дә бик кызык — Лимон.

Гәрәй. Ярар, лимон булгач, без аны чәйгә салып эчәрбез. Яки болай гына ашап куярбыз. Безнең аппетит яхшы.

Гәрәй машина эченнән куллары бәйләнгән Альбертны тартып чыгара. Күпмедер вакыт барсы да сүзсез тора.

Гәрәй. Йә, кайсыгыз башлый?

Айсылу. Эш болай булды, Гәрәй Мингалиевич. Без Сәрбиназ апа белән бераз прогулкада йөреп кайтмакчы идек. Машинаны гараждан чыгаруга, өстән атылып улыгыз килеп төште дә иң беренче каравылчы Габдулла абзыйның башына ни беләндер тондырды. Аннары рульдән мине тартып чыгарып, үзе кереп утырды.

Гәрәй. Син шунда миңа шылтырата алмадыңмы?

Айсылу. Мин номер җыя башлауга, телефонны тартып алды. Сәрбиназ апа белән икебезне бәргәләп арткы утыргычка ыргытты.

Гәрәй. Шунда берегез йөгереп кереп өй телефоныннан пожарникларга гына булса да шылтырата алмадыгызмы?

Айсылу. Каушап, аптырап калдык.

Гәрәй *(Габдуллага)*. Синең кай җиреңә сукты Альберт?

Габдулла юләр кешедәй озак кына көлә. Көлүдән туктагач, Гәрәй Мингалиевичның күзләренә туры карап сөйли башлый.

Габдулла. Миңа беркем берни белән дә сукмады, Гәрәй Мингалиевич! Айсылу Акбулатовна капканы ачарга кушкач, ачтым. Алар Альберт белән үбешә-үбешә өйдән килеп чыктылар да машинаны чыгарырга гаражга кереп киттеләр. Бик озак торгач, нишләп чыкмыйлар инде дип бара башлаган идем, менә бу симез туташ мине ул тирәгә җибәрмәде. Шулай да мин һаман үземнекен иткәч, «күпне күрмә» дип, туфли үкчәсе белән берне тондырып алды. Менә монда эзе дә бардыр әле. Шулай да мин эчкә күз ташлап өлгердем. Сезнең гүзәл хатыныгыз күкрәкләрен ачып Альбертка үптереп тора иде.

Гәрәй хатынына һәм Сәрбиназга карый.

Гәрәй. Инде ни диярсез?

Айсылу. Мин мондый оятсызлыкка сүз таба алмыйм, Габдулла абзый. Дөрес, әз-мәз урлашканыңны, кирәкмәгәндә дә ялганларга яратуыңны белә идем. Карт кеше дип жәлләп андый гөнаһларыңны Гәрәй Мингалиевичка әйтми килдем. Ләкин мондый ук кабахәттерсең дип башыма да килми иде.

Сәрбиназ Габдулланың битенә төкерә.

Сәрбиназ. Җирбит. Телең корыр.

Габдулла. Турысын әйткән туганына ярамаган дип, дөрес әйткәннәр шул.

Альберт. Папаня, инде мине тыңла. Синең фәрештәгә санап йөргән Айсылуың сука. Да, да, настоящая сука!

Гәрәй Альбертның яңагына чабып җибәрә.

Гәрәй. Не сметь Айсылу турында алай дияргә.

Альберт. А я смею, даже могу доказать. Твоя сука каждый день в мою комнату ходила. Сейчас принесу доказательство.

Йөгереп үз бүлмәсенә менеп китә. Аннан Айсылуның коену костюмын, эчке күлмәген һәм бер кочак фотокарточкалар алып төшә.

Альберт. Вот вещественные доказательства. Ул һәр кергән саен йә трусигын, йә эчке күлмәген онытып калдыра иде. А эта старая карга *(Сәрбиназга күрсәтә)* нас охраняла. Вот так, мой дорогой папаша! Любуйся менә бу фотолар белән.

Альберт фотоларны машина капотына җәеп сала. Анда Альбертның ерткычларча Айсылуга ташлануы, кызны диванга бәреп егып өстенә атланган моментлары бик ачык чагылдырылган. Җитмәсә, Альберт өске каттан теге монтер егет белән Айсылуның бакчага мәхәббәт чәчәге утыртып йөрүләрен дә төшереп алган. Фотокарточкаларны күргәч, Гәрәйнең йөзе агарып китә. Димәк, Габдулла сөйләгәннәр дөрес.

Ул капкадан эчкә кереп китә. Бассейн янына килә. Анда үрдәк бәбкәсе йөзеп йөри. Аңа башкалар да иярә. Альберт җиңүче кыяфәтендә башын югары тотып йөри.

Альберт. Вот тот үрдәк бәбкәсе. Знаешь, папаня, это какой намек? Будто бы ты яшь хатынга бала ясарга не в состоянии. Если Айсуле нужен ребенок, тогда этот монтер поможет. Вот они чего замышляли.

Гәрәй. Җитте! Хәзер үк урынына кертеп ябыгыз! Габдулла, бар, кертеп яп та ачкычларны миңа тапшыр.

Габдулла белән Альберт бер-берләренә карашып алалар. Аларның серле генә эчтән елмаеп карашып алуларын Гәрәй күрә, ләкин күрмәмешкә салыша. Габдулла Альбертны өскә алып менеп китә.

Монтер. Әйе, бу үрдәк бәбкәсен мин китергән идем. Ләкин бернинди мәкерле уйлар белән түгел. Бассейныгызда бер тере җан иясе йөзеп йөрсен дип кенә.

Гәрәй. Сездән аңлатма сорамыйлар.

Монтер. Сорамасалар да аңлатам, чөнки монда астыртын рәвештә Айсылу Акбулатовнага яла ягу бара. Аның гаебе юк. Монда мин гаепле. Кирәкмәгән җиргә мин тыгылып йөрдем. Юкса Айсылу Акбулатовна гел куа торды.

Гәрәй. Вон! Хәзер үк моннан чыгып китегез, юкса ахыры начар булуы бар.

Монтер бассейндагы үрдәк бәбкәсен тотып ала, аннары мәхәббәт чәчәген йолкып алырга килә, ләкин аның юлына Гәрәй килеп баса.

Гәрәй. Күпме әйтергә була чыгып китегез дип.

Монтер бер урында таптанып торганнан соң Гәрәйнең учына үрдәк бәбкәсен сала.

Монтер. Сезнең Альбертыгыз сүзләрендә бөтенләй хаклык юк түгел. Айсылу Акбулатовнага күзем төшеп йөрде минем. Аны үземә каратмакчы булдым, юләр. Ә ул миңа бер түмгәккә караган кебек кенә карады. Вәт шул!

Гәрәй *(түземсезләнеп).* Китегез, дим! *(Монтерны бер читкә этә.)*

Монтер. Сез Айсылу Акбулатовнага ышанмый торып мин моннан китә алмыйм.

Гәрәй. Уф! Ә син Аллага ышанасыңмы соң?

Монтер аның тел төбен төшенеп җитми.

Монтер. Причем монда Алла! Ышанам, әлбәттә.

Гәрәй. Ә аның барлыгын ничек исбат итә аласың?

Монтер. Күңелемдәге иманым белән.

Гәрәй. Кая соң синең иманың? Күренми шул. Синең иманыңны күреп булмаган кебек, хатын-кызның күңел төбендә ни ятканын да күреп булмый. Бәлки, анда шайтаннар оясыдыр. Булдыра алсаң, ачып күрсәт миңа кеше күңелен.

Монтер. Сез шундый зур кеше, Гәрәй Мингалиевич, кайбер нәрсәләрдә артык түбәнәясез. Китим әле, йә сезгә ихтирамым бетә башлар.

Китеп бара. Гәрәй учындагы үрдәк бәбкәсе «пип-пип» дип кычкыра башлый. Гәрәй аны җиргә җибәрә.

Гәрәй. Син дә бит җан иясе. Бәлки әле, акылың да бардыр. Без бер-беребезне аңламыйбыз гынадыр. Хәер, кешеләр булып кешеләр аңлаша алмаганда... *(Кул селтәп куя.)*

Монтер китүгә, Габдулла ачкычлар тотып Гәрәй каршына килә. Гәрәй аның ачкычларын алып кесәсенә салып куя.

Гәрәй. Ә хәзер биш минут эчендә барлык шмоткаларыңны җый да тай, чтобы эзең булмасын.

Габдулла. Хакыйкатьне әйтү ярамадымыни?

Гәрәй. Синең фикереңне сорамыйлар. Вон!

Габдулла тагын да тоткарланса, эшнең хәтәргә әйләнүен аңлап, тиз-тиз атлап бүлмәсенә керә. Һәм бер-ике минут та үтми, чемоданын күтәреп чыга.

Габдулла. Мин моңа алдан ук әзер идем. Чөнки без барыбыз да алданып яшәргә яратабыз. Алданып яшәү рәхәтрәк. Кеше баеса, тем более дөреслекне күтәрми. *(Китеп бара.)*

Сәрбиназ. Оятсыз кеше икәнсең.

Сәрбиназ Габдулла артыннан капканы ябарга бара. Шунда машина капоты өстендә ятучы фотосурәтләрне күреп, аларны ерткалый башлый. Айсылу белән Гәрәй генә бакчада кала. Алар мәхәббәт чәчәге янында басып калалар. Гәрәй ботинка башы белән мәхәббәт чәчәгенә басам-басам дигәндә, аны нәрсәдер тыеп кала. Мәхәббәт чәчәге әллә җилдән, әллә Гәрәйнең туфлиләре кагылудан калтырап-калтырап куя. Теге үрдәк бәбкәсе дә алпан-тилпән атлап болар янына килә. Гәрәйнең эчке киеренкелектән маңгаена эре-эре тирләр бәреп чыккан. Айсылу кульяулыгы белән ул тирләрне сөртеп ала. Гәрәй хатынының бу эшен бөтенләй күрмәгән кебек өй янындагы эскәмиягә барып утыра.

Гәрәй. Уф! *(Учлары белән чигәләрен кысып тота. Аның янына Айсылу килеп утыра. Айсылу йөзенә болытлар күләгәсе төшә.)*

Айсылу. Син ышанасыңмы шушыларга, Гәрәй?

Гәрәй. Ә син нишләр идең?

Айсылу. Белмим, Гәрәй. Артыгын оста корылган ятьмә бу. Фотокарточкалар, Альбертның сүзләре. Аннан да яманы Габдулла абзыйның шушыларны раслап торуы. Ышанмас җиреңнән ышанырсың.

Гәрәй *(эскәмиягә йодрыгы белән суга).* Ә кая соң ул безнең мәхәббәт? Йә әйт, Айсылу, кайда югалттык без мәхәббәтне?

Айсылу. Югалтмадык. Беркая да китмәде, ул, безгә рәнҗеп, йөрәк түрләребезгә посты гына.

Гәрәй. Ник качырдык без аны? Нигә куркыттык?

Айсылу. Гәрәй, бәгърем, бераз тынычлан әле. Уйлашып карыйк, кайсыбыз гаепле икән?

Гәрәй. Әллә мине гаепләр идеңме? Күзләреңә карап табынып яшәдем. Бөтен шатлыгым син идең.

Айсылу. Ансы шулай, Гәрәй. Син мине, русча әйтсәк, артыгын баловать иттең. Мин эшсезлектән көннәр буе үземә урын тапмый йөри идем. Юк, юк, Гәрәй, син уйлаганча бозык кеше түгел мин. Теге монтерның бассейнга үрдәк бәбкәсе җибәрүе, мәхәббәт чәчәге утыртуы — алар барсы да пүчтәк. Бәлки, ул миңа күз атып йөргәндер, әмма, Гәрәй, синең каршыңда, мәхәббәтебез каршында намусым чиста. Сине очратканнан бирле минем бер генә ир-атка да күз салганым булмады. Син көтмәгәндә килеп чыккан өермәдәй мине бөтереп күккә алып менеп киттең дә шуннан яңадан төшермәдең.

Гәрәй. Сүзләр... сүзләр. Ә фотокарточкалар: «Сүзләргә түгел, чынбарлыкка ышан», — дип кычкырып яталар.

Айсылу. Алар Габдулла абзый белән Альбертның алдан корылган хәйләсе. Альберт бит көне-төне үз бүлмәсендә генә бикләнеп ятмады. Син өйдә югында аска төшеп-менеп йөрде. Кайвакыт безнең белән табында да утырды. Ә беркөнне ул ерткычларча миңа ташланды. Мин бассейнга чыгарга торам. Өстемдә коену костюмы гына иде. Ул баскычтан атылып төшеп ишеккә ташланды. Мин, аны качарга җыена дип уйлап, җилкәсенә барыпябыштым. Ул шуны гына көткән, ахры. Мине үз кочагында әвәләргә тотынды. Күрәсең, бу тамаша безне шундый хәлдә фотога төшерү өчен кирәк булгандыр.

Айсылу боларны сөйләгән чакта, Альберт белән Айсылуның тарткалашуы кабатлап күрсәтелә. Гәрәй акылы белән Айсылуның гаепсез икәнен аңлый, ләкин йөрәге акылга каршы килә.

Гәрәй. Ә нигә шул көнне үк моны миңа әйтмәдең? Ябып куйган наркоманның җайлы гына чыгып, кире урынына кереп ятулары сине бер дә шиккә салмадымы?

Айсылу. Салды, Гәрәй. Ләкин бит Габдулла абзый Сәрбиназ апа белән миңа: «Альбертны чыгаргаларга Гәрәй Мингалиевич үзе кушты»,— диде.

Гәрәй. Сез шуңа ышандыгызмы?

Айсылу. Ничек ышанмыйк инде? Альберт синең улың, кызгангандыр дип уйладык. Синең мәрхәмәтле икәнеңне белгәнгә, моңа һич шигебез булмады. Ни генә әйтмә, читлеккә ябып кешене тәрбияләп булмый, дип уйлыйм.

Гәрәй. Куркыныч җанварларның урыны читлектә. Ярты дөнья наркоманга әйләнеп бара.

Айсылу. Сиңа шуны да әйтергә онытып торам икән.

Гәрәй. Нәрсәне?

Айсылу. Теге кинолог белән бөтен җирне карап чыктык. Чынлап та, Альберт бүлмәсендәге ванна кырыена кыстырылып куелган героин таптык һәм аны шунда ук унитазга салып суга агыздык.

Гәрәй. Ярый... Сүзең хак булса, рәхмәт. Ләкин бу хәлләрдән соң...

Айсылу башын түбән ия. Аның күзләреннән яшьләр тәгәрәп төшә.

Айсылу. Нишләргә соң безгә хәзер, Гәрәй?

Гәрәй. Белмим, белмим. Беләсем дә килми. Үз гомеремдә беренче тапкыр минем яшисем килми башлады. Гомерем буе һәр эштән тәм табып яшәдем. Кулымда бер тиен акча булмаганда да өметем сүнмәде. Менә бу өйләр, бакчалар әфсен белән генә калкып чыкмады. Мин аларга бөтен җан җылымны бирдем. Ә дөньяма син килеп кергәч, мин өр-яңадан егерме яшьлек егеткә әйләндем. Ни генә эшләсәм дә, ул эшемә синең күзләрең аша карадым. Синең соклануың, эшләремне хуплап торуың миңа көч бирде. Сиңа кадәрге тормышым бәхеткә юл салу гына булган икән дип уйладым. Ә хәзер синең белән тулы дөньямны мин җимереп ташлыйммы? Их, Айсылу! Нишләттең син мине? Күгемнең бер чите кителде бит бүген. Җимерелгән күк кыйпылчыклары ватылган чынаяк кыйпылчыклары гына түгел бит.

Эскәмиядән сикереп тора. Капкага таба бара башлый.

Айсылу. Гәрәй... Гәрәй Мингалиевич...

Сәрбиназ чыга.

Сәрбиназ. Гәрәй Мингалиевич, ашарга әзер иде, әллә капкалап чыгасызмы? Ач кешенең ачуы яман, диләр.

Гәрәй. Бүген мин үз гомеремә җитәрлек ашадым инде. Шуннан артыгы сыймас.

Сәрбиназ. Кичкелеккә нәрсә әзерлим, Гәрәй Мингалиевич?

Гәрәй. Әнә бакчадагы мәхәббәт чәчәген кайнатып компот ясарсың.

Гәрәй шалт итеп машинасын яба да кузгалып китә. Сәрбиназ янына күзләрен сөртә-сөртә Айсылу килә дә аның күкрәгенә капланып елый.Сәрбиназ, аны юатырга теләп, Айсылуның башыннан сыйпый.

Сәрбиназ. Кайтыр, Айсылу кызым. Ирләр кызулыгы белән шыртлатып ишекне ябып чыгып китәләр дә, хаталарын аңлагач, мыштым гына кайтып киләләр.

Айсылу. Ай-һай! Гәрәй бик горур кеше.

Сәрбиназ. Горур булса да, акылсыз түгел. Бер акылына килер.

Болар капканы ябып кереп китәргә торганда, Гәрәйнең беренче хатыны Рәхилә пәйда була.

Рәхилә. Ә-ә, менә шәп булган, оҗмах кошларын оҗмахтан сөргәннәр. Ха-ха-ха! Шулай булырын мин аны алдан ук белеп тордым. Бүтәннәр бәхетсезлегендә бәхет сарае салып булмый ул.

Сәрбиназ *(аны читкә этеп)*. Үләксә күргән козгын кебек йөрмә монда иснәнеп. Нинди оҗмахтан куылу? Безне бервакытта да оҗмахтан кумаслар. Менә син имансызны кудылар.

Рәхилә. Хәзер бу йортка мин үзем кайтып утырачакмын. Оҗмахтан сөрелгәннәрнең эзләрен пычрак пумала белән себерттерәчәкмен. Гәрәй миндә утыра. Гафу итүемне сорый. Тезләнеп сорый. Юха еланга алданып харап булдым, ди.

Сәрбиназ. Бар, бар, каркылдап йөрмә. Синең авызың гайбәт, чүп савыты. Гәрәй Мингалиевич үлгәндә дә сиңа бармаячак.

Рәхилә. Сез ирләрне белмисез әле. *(Сәрбиназга.)* Сиңа урамда аунап ятучы бомж да карамый.

Айсылу белән Сәрбиназ Рәхиләне төрткәләп диярлек чыгарып җибәрмәкчеләр. Ләкин ул капкага ике куллап ябышкан. Аяклары белән әле Сәрбиназга, әле Айсылуга тибәргә омтыла.

Рәхилә. Берегез ир күрмичә корыган агачка әйләнгән, икенчегез ирләрдән туя белмәгән мәлгунь аждаһа. Ничава, бу өйдә ята алмассыз. Ярыктан чыккан кандалалар кебек безнең якларга да чыгарсыз. Чыгасыгыз килмәсә дә, чыгарттырырбыз.

Ниһаять, Рәхиләне төрткәләп чыгарып капканы ябалар. Бераздан хатынның тавышы ерагая. Эт тә өрүдән туктый.

Гәрәй өеннән чыгып киткәч, машинасын олы юлга бора. Ул башыннан барлык уйларны җилгә очырырга теләгәндәй бөтен көчкә машинасын куа. Музыка кабызып карый, ләкин анда карлыккан тавышлы бер җырчының әллә русча, әллә татарча акыруын ошатмыйча радиоланы туктата. Бераздан ул үзе дә сизмәстән Айсылу белән беренче очрашкан урынга килеп чыга. Юлга озак кына карап тора. Анда Айсылуныкы шикелле иске «шестерка»лар да үтә. Гәрәй аларга ымсынып карап кала. Аннары машинасын урман юлына бора да бер каен төбенә чалкан ята. Шунда аның Айсылу белән юлда очрашулары хәтере аша үтә.

Гәрәй. Нәрсә, үскәнем, аргамагың киреләндеме әллә?

Айсылу. Әйе.

Гәрәй. Бер дә борчылма, үскәнем, минем егетләр җайлап бирер машинаңны.

Айсылу. Әле генә берәү җайлап бирмәкче булган иде.

Гәрәй. Шуннан?

Айсылу. Бәяне бик зурдан каермакчы булды.

Гәрәй. Ничек? Юлда бәлагә юлыккан кыз баладан акча сорадымы?

Айсылу. Юк, акча түгел.

Гәрәй. Нәрсә соң?

Айсылу. Әнә теге урманга кереп чыгыйк, диде.

Гәрәй. Аһ, кабахәт!

Айсылу. Сезгә дә шундый түләү кирәк булса, вакытыгызны әрәм итмәгез.

Гәрәйнең уйлары шул урында өзелә. «Дурак мин! — дип, үзенең маңгаена сугып куя. — Чеп-чи дурак. Айсылуның җаны саф икәнен белә торып, пычрак гайбәтләргә кереп баттым. Үземне акыллы кешегә санап йөргән булам тагын. Кешеләр белән җитәкчелек итәм. Киләчәккә грандиозный планнар корам». Гәрәй шул вакыт икегә бүленә.

Икенче Гәрәй. Син үз-үзеңне юкка битәрләмә. Безнең һәрберебездә Иблис белән фәрештә яши. Беркөнне Иблис җиңсә, икенче көнне фәрештә өстен чыга.

Беренче Гәрәй. Мин ул Иблисне күңелемнән куган идем бит инде. Тагын ничек килеп кергән ул анда?

Икенче Гәрәй. Димәк, чын күңелдән кумагансың.

Беренче Гәрәй. Юри-мыри эшләргә мин бала-чагамыни?

Икенче Гәрәй. Киресенчә, син артык зураеп киттең. Бала-чага ул һәр эшне, хәтта уенны да, чын күңеленнән эшли. Син мәктәп директоры чагында гына Иблисеңнән ераклаша алган идең, ләкин анда завхоз итеп Габдулла абзыйны эшкә алуга, вөҗданыңны саклаучы фәрештәң артка чигенде.

Беренче Гәрәй. Причем монда Габдулла абзый? Ул бит ни әйтсәң, шунда чабарга әзер торучы гөнаһсыз бер мәхлук җан.

Икенче Гәрәй. Әйе, мәхлук җан. Ул да үзгәрде. Урлаша башлады. Бер такта, бер килограмм кадак алуын күрмәмешкә салыштың. Зуррак нәрсәләр ташый башлагач кына күрдең. Бәлки, ансын да күрмәмешкә салышыр идең, ләкин син аңардан көнләштең.

Беренче Гәрәй. Көнләштем? Нәрсәсеннән көнләшим мин аның?

Икенче Гәрәй. Җырлавыннан.

Беренче Гәрәй. Җырлавыннан? Шул бетәшкән картның җырлавыннан көнләшергә син мине кем дип белдең? Әгәр мин җырчы булырга хыялланган кеше булсам, тагын бер хәл.

Икенче Гәрәй. Эш синең кем булуыңда түгел.

Беренче Гәрәй. Нәрсәдә соң?

Икенче Гәрәй. Син булдыра алмаганны аның булдыруында.

Беренче Гәрәй. Чепуха!

Икенче Гәрәй. Бер дә чепуха түгел. Сине бит мин яхшы беләм. Син гел югарырак калкырга, бар эшне булдырып чыгарга яраттың.

Беренче Гәрәй. Бу начармыни?

Икенче Гәрәй. Начар түгел, тик монда бер ләкин бар.

Беренче Гәрәй. Әйт алайса.

Икенче Гәрәй. Кеше югарыга калыкканда башкаларның башына басмый гына калыксын.

Беренче Гәрәй. Мин кемнең башына бастым соң?

Икенче Гәрәй. Шул ук Габдулланың.

Беренче Гәрәй. Ничек?

Икенче Гәрәй. Бер вагон тактаны оныттыңмы? Ул бит мәктәпне ремонтлатырга дип кайтартылган иде. Ул бер төндә юкка чыкты. Син завхоз Габдулланы гаепләдең. Ә бит ул такталарны колхоз председателенең улы чәлгән иде. Син аларга барып тавыш куптардың. Ләкин кирәге чыгар дип, чүпне читкә чыгармадың. Өстәвенә алар синең сумкаңа шактый күләмдә акча салып җибәргәннәр иде. Син аны өеңә кайткач кына күрдең.

Беренче Гәрәй. Мине намусым гел борчып йөрде.

Икенче Гәрәй. Ансы шулай. Син ул акчаларны кире илтеп бирергә дә уйладың. Ләкин заманалар үзгәреп китте.

Беренче Гәрәй. Колхоз таркала башлады. Мәктәптә укытырга бала калмады диярлек.

Икенче Гәрәй. Әйе, син шуннан файдаланып, иске мәктәп бернигә яраксыз дип, сүзеңне раслатырга комиссия җыйдырттың. Аларны бик әйбәтләп сыйладың. Комиссия мәктәпне карамаган да килеш актка кул куеп китте.

Беренче Гәрәй. Чынлап та ишелеп төшәргә тора иде бит ул мәктәп.

Икенче Гәрәй. Ә бит син аны ишмәдең. Төзәттердең дә бер башына кибет ачтың, икенче башына фатирлар ясап читтән кайткан кешеләрне керттең.

Беренче Гәрәй. Мин яхшылык эшләдем. Авылга кибет тә, фатирлар да кирәк иде.

Икенче Гәрәй. Син бит шуннан табыш ала башладың. Кибетең дә, фатирда торучылар да сиңа зур табыш китерде.

Беренче Гәрәй. Мин бит анда күпме хезмәт куйдым.

Икенче Гәрәй. Ансы дөрес, нык тырыштың, ләкин беренче маяң теге такталардан кергән акча иде.

Беренче Гәрәй. Башлангыч капитал беркемнеке дә чиста юл белән генә эшләнми. Мин ул такталарның бәясен бише белән түләдем инде. Инвалидлар йортын шефлыкка алдым. Больницага «ашыгыч ярдәм» машинасы бүләк иттем.

Икенче Гәрәй. Боларны син үзеңне тагын да күтәрер өчен эшләдең. Газеталар синең турыда яздылар, радио-телевидение сине телдән төшермәде.

Беренче Гәрәй. Мин шулкадәр начар кешемени?

Икенче Гәрәй. Юк, бик начар түгел. Хәтта синең бик яхшы якларың да бар.

Беренче Гәрәй. Мәсәлән?

Икенче Гәрәй. Мәсәлән, син һәр эшне булсынга эшлисең. Партнерларыңны бервакытта да авыр хәлгә куймыйсың. Чын ирләрчә ярата беләсең. Бу заманда ярата, аңлый белүчеләр артык күп түгел.

Беренче Гәрәй. Нәрсәдә ялгыштым соң мин? Шундый матур мәхәббәтебез нилектән җимерелде?

Икенче Гәрәй. Күп нәрсә безнең үзебездән генә тормый. Үзебезне дөньяның кендеге дип санап, бездән башкалар барын онытып җибәрәбез. Дөньяга күбрәк маңгай күзе аша карыйбыз. Ә маңгай күзләребездә Иблис утыра. Беренче тәэсирләрне безгә шул бирә. Без аның тәэсиренә бик тиз биреләбез. Чөнки ул дөньяның өске катламын, без ияләшкән һәм матур дип күнеккән өлешен генә күрсәтә.

Беренче Гәрәй. Мин бер генә эшне дә күңелем белән киңәшми эшләмәдем.

Икенче Гәрәй. Киңәштең, ләкин аның киңәшләрен тотмадың.

Беренче Гәрәй. Ничек? Кайчан тотмадым?

Икенче Гәрәй. Габдулланы үзеңә эшкә алганда күңелең сиңа берни дә әйтмәдемени?

Беренче Гәрәй. Әйтте. Ул кайчан да булса синнән үч алырга тырышачак, диде.

Икенче Гәрәй. Ә син күңелеңне тыңламадың.

Беренче Гәрәй. Көтмәгәндә тез астыма китереп типмәсен дип, гел үз тирәмдә тоттым мин аны. Дошманың якында булса, куркыныч кимрәк дип уйладым.

Икенче Гәрәй. Ә ул барыбер типте, һәм ничек кенә әле.

Беренче Гәрәй. Монда аның кулы уйнагандыр дисеңме?

Икенче Гәрәй. Аның кулы белән башкалар уйнаган уен булуы мөмкин.

Беренче Гәрәй. Димәк, төп кабахәтлекне Альберт эшләгән.

Икенче Гәрәй. Ансын үзең ныклап уйла инде.

Ике Гәрәй шунда бергә кушыла. Гәрәй тиз-тиз атлап машинасына таба китә, утырып кайтыр юлга чыга. Шәһәргә кергәч, иске йорт күзенә чагыла. «Бу Габдуллалар өе бит!» дигән уй күңелен кисеп үтә. Гәрәйдә эчке кызыксыну уяна һәм ул Габдуллаларга кереп чыгарга уйлый. Өйалды ишеген ачуга, аның колагына сагышлы җыр дулкыннары килеп бәрелә. Габдулла «Олы юлның тузаны»н җырлый.

Габдулла. Олы юлның тузанын
Үзем күрдем тузганын.
Белми калдым, сизми калдым
Яшь гомеремнең узганын.

Гәрәй сак кына ишекне ачып керә. Габдулла аның кергәнен ишетми. Җырлавын дәвам итә.

Габдулла. Олы юлның тузанында
Калды минем эзләрем.
Кайда минем яшьлегем, дип,
Шул юллардан эзләдем.

Гәрәй *(эченнән)*. Шушындый матур моң яткан күңелдә әшәкелеккә нишләп урын кала икән?

Гәрәй үзенең монда икәнлеген белдереп тамак кыра.

Габдулла. Эзәрлеклибезме?

Гәрәй. Юк, болай гына, үтеп барышлый гына сугылмакчы идем. Җырыңны ишеттем дә янына кереп сөйләшәсем килде.

Габдулла. Син бит минем җырлавымны яратмыйсың. Гомер буе мине шуңа эзәрлекләдең. Чөнки бар нәрсәне дә үзең генә иң шәп башкарырга тиешле дип санадың. Мин-минлек көчле синдә. Килгән-килгән әйт әле: минем җырлавым сиңа нәрсәсе белән мешайть итте?

Гәрәй. Үзең әйттең бит инде.

Габдулла. Минем моңа җавапны синең авызыңнан ишетәсем килә.

Гәрәй күпмедер вакыт ишекле-түрле йөри. Тәрәзәгә карап алгалый. Аннары бер карарга килеп Габдулла каршысындагы урындыкка барып утыра.

Гәрәй. Ирләрчә, ачыктан-ачык сөйләшик. Ничек кенә юләрлек булмасын, көнләштем мин синең җырлавыңнан. Юк, үзем җырчы булырга теләүдән түгел. Синең җырың, Габдулла абзый, үтеп барган кешеләрне юлыннан туктата иде. Ә бервакыт сабан туенда бөтен мәйданны син авызыңа каратып тоттың. Кызлар синең иңеңә чиккән сөлгеләр салып киттеләр. Ә мин ничә ел сабан туе батыры булып калган Гәрәй шул көнне җиңелдем. Хурлыгымнан җирне йодрыгым белән төя-төя ярсыдым. Мине ул көнне мәйдандагы батыр түгел, син җиңдең. Шул көннән син минем дошманыма әверелдең.

Габдулла. Сине болай ук акылсыз дип уйламый идем.

Гәрәй. Әйе, бер карасаң, бу бөтенләй абсурд. Ләкин кеше күп вакыт акылына түгел, ә ниндидер тәэсирләргә карап гамәл кыла.

Габдулла. Нәрсә генә димә, миңа синең сүзләрең аңлашылмый.

Гәрәй. Син түгел, мин аны үзем дә аңламый идем. Менә бүген генә төшендем кебек.

Габдулла. Мин сиңа ышанмыйм. Син, нәрсәнедер төшендем дигән булып, минем күңелне актарырга кергәнсең. Хатыныңның гаепleme-түгелме икәнен беләсең килә.

Гәрәй. Юк, Габдулла абзый, Айсылуның гаепле-гаепсез булуы турында бармый сүз. Айсылу да безнең кебек үк кеше. Кемдер белән мавыгып алуы, ялгышуы, хәтта чып-чынлап башканы яратуы мөмкин. Ничек кенә булмасын, мин Айсылуны кичердем инде. Хәер, монда кичердем дию дә дөрес булмас. Аңладым дию кирәктер. Айсылуга мин ничектер шәхси милек итебрәк карый башлаганмын икән.

Габдулла. Менә монсы дөрес. Аңа тән сакчылары куюыңны да хуплап булмый. Син бит болай эшләп аны кимсетәсең. Айсылу урынында булсам, мин күптән синең чәчәкле төрмәңнән чыгып качар идем. Ә ул сине артык яратуы аркасында гына син урап алган бофраларны күрми яшәде.

Гәрәй. Дөрес әйтәсең, Габдулла абзый. Мин дә шуны аңлавым турында әйтергә уйлаган идем. Дөресрәге, сиңа карата дошманлыгымның ничек тууы турында иде сүзем. Яшерен-батырын түгел, Габдулла абзый, кеше җанында көнчелек дигән шайтан ята. Юкса синең җырлавың миңа нәрсә инде. Җырлый бир идең. Ләкин сабантуй кадәр сабантуйда мине сыртка салырга булышкач, андый җырдан ничек көнләшмисең.

Гәрәй тынып кала. Габдулла да ияген учларына куеп уйлана. Шактый гына шулай утыралар.

Габдулла. Көнчелек турында дөрес әйтәсең. Мин дә бит сиңа гел көнләшеп карадым. Син кинәт кенә баеп киткәч бигрәк тә. Картая-картая ул вак-төяк үчләр онытыла да башлаган иде. Малаең Альберт котыртып, йөрәкне өр-яңадан кузгатып җибәрде.

Гәрәй. Аһ, кабахәт, бу интриганың башында шул торадыр дип шикләнгән идем аны.

Габдулла. Альбертыңны өеңә китертеп ялгыштың, ә бәлки, ялгышың — өйгә китерткәч үзеннән-үзе төзәлер бу дип уйлавыңдадыр.

Гәрәй. Миңа нишләргә соң, Габдулла абзый?

Габдулла. Иң беренче өеңә кайт. Айсылуыңны ул ерткычтан сакла. Юкса ул аны да үзе кебек наркоман итәргә күп сорамас.

Гәрәй. Әллә?..

Габдулла. Мин әләкче малай, син мәктәп директоры түгел. Тик шуны исеңнән чыгарма: Альбертың төзәлерлек хәлдә түгел. Аңа һәр көнне иптәшләре килеп теге нәмәрсәкәйне китереп тордылар.

Гәрәй. Ә син шуны белә торып...

Габдулла. Әйе, белә торып әйтмәдем. Миңа син җәл түгел, Гәрәй. Син шома балык. Теләсә нинди хәлдән оста шуып чыга аласың. Әмма дә ләкин малаеңның ятьмәләре урап алса, пәрәвез җепләренә эләккән чебен хәлендә калуың мөмкин. Үзеңне наркоман итәрләр.

Гәрәй *(өстәлгә сугып)*. Юк, мин ул паразит малайны үз кулларым белән буып үтерәчәкмен.

Габдулла. Ансы синең эш.

Гәрәй. Әйдә, Габдулла абзый, кайт безгә.

Габдулла. Юк инде. Менә шушы ярым җимерек өемә бер такта гына кагып куйсам да, җаным җиңеләеп китә. Үзем өчен эшлим дип күкрәк кагып куям.

Гәрәй. Ансы дөрес. Үзең өчен дип эшләгәндә генә җанга рәхәт. Йә, ярый, мин киттем алайса, миңа рәнҗеп калма.

Гәрәй ишеккә таба китә дә туктап кала. Аннары кесәләрен актара башлый. Кесә төбеннән долларлар килеп чыккач, сөенеп куя.

Гәрәй. Менә, Габдулла абзый, синең эшләгәнеңә хезмәт хакы. Үзеңчә яшә, ярдәм кирәк булса, кыенсынма — кил.

Габдулла. Долларларыңны кире ал. Миңа алар тегендә барыбер кирәк булмаслар.

Габдулла акчаларны кире Гәрәйгә суза. Гәрәй алмый.

Гәрәй. Тегендә китәргә ашыкмыйк әле, Габдулла абзый. Ә бу дөньяга хәзер шушы «яшел шайтан» хуҗа.

Гәрәй долларларны Габдулланың чөйдә эленеп торган иске пальто кесәсенә салып чыгып китә. Машина ул кереп утыруга ук кабынып китә. Юл кагыйдәләрен боза-боза бар көченә машинасын куа. Юлдагы патрульләр аңа сыбызгы сызгыртып кала. Капка төпләренә тузан туздырып килеп туктый. Чабып өйгә кереп китә.

Гәрәй. Айсылу, Айсылуым минем.

Бүлмәдән бүлмәгә йөри. Йөгереп югары катка менә. Альберт бүлмәсен ачып карый. Аның ишекләре ачык, Альберт юк. Йөгерә-сикерә баскычтан аска төшә. Әле бер, әле икенче бүлмәнең ишеген ачып карый.

Гәрәй. Айсылу! Кадерлем, син кайда?

Айсылуның йокы бүлмәсендә ыңгырашкан тавышын ишетеп шунда атыла. Күзе караватта ятучы Айсылуга һәм аның тирәсендә мәш килүче Сәрбиназга төшә.

Гәрәй. Айсылуым, кадерлем, ни булды? Ни булды, Сәрбиназ апа?

Айсылу ыңгырашып куя. Аның муены һәм бер як бите бинт белән бәйләнгән. Гәрәй Айсылу караваты янына килеп тезләнә.

Гәрәй. Ни булды, чәчәгем?

Сәрбиназ. Теге котырган ерткыч Айсылуның йөзенә кислота сибеп чыгып китте.

Гәрәй. Кем, Альбертмы?

Сәрбиназ. Шул булмый, кем булсын.

Гәрәй. Ах, сволочь! Күрсәтермен әле мин аңа күрмәгәнен.

Сәрбиназ. Үпкәләсәгез үпкәләгез, Гәрәй Мингалиевич, ләкин монда сезнең дә гаеп бар. Шул ерткычның сүзенә ышанып өйдән чыгып китү акыллы кеше эшеме? Мин сезне төпле, акыллы кеше дип йөри идем...

Гәрәй Айсылуның күкрәгенә капланып үкси. Аннары ул Айсылуны яшь баланы күтәргәндәй күтәреп ала да кулларында тирбәтеп йөри.

Гәрәй. Кичерә алсаң, кичер мине, кадерлем. Барсы да минем дуамаллык аркасында.

Айсылу. Минем яшисем килми, Гәрәй.

Гәрәй. Син яшәргә тиеш, Айсылуым. Мәхәббәтебез хакына яшәргә тиеш. Ә хәзер мин сине хастаханәгә алып китәм. Иң яхшы специалистларга күрсәтәм. Кирәк булса, чит илгә дә алып барырмын. Тик син яшә генә, Айсылуым.

Сәрбиназ. Бәхеткә, теге явызның кислотасы Айсылуның муенына һәм уң як яңагына гына тиде, күзләре исән калды. Алай куркыныч кебек түгел. Мин сыргаанак мае белән бәйләдем.

Гәрәй. Бик сызлыймы, кадерлем?

Айсылу. Сызлый. Ләкин биткә караганда йөрәк сызлавы ныграк. Альберт кислотаны битемә сипсә, син, ышанмавың белән, йөрәгемә сиптең. Ә минем бөтен дөньям синнән һәм сиңа булган мәхәббәттән тора иде. Яшәр өчен мәхәббәт кенә җитми икән. Мин эшемне ташлап ялгыштым. *(Елый.)*

Гәрәй. Әгәр мин гаепле диюдән генә сиңа җиңеллек килсә, мин иң тапкыр гаепле. Ләкин эшләнгән дуамаллык эшләнгән. Ә хәзер, әйдә, тизрәк хастаханәгә. Сиңа пластик операция ясатырга кирәк.

Айсылу. Кирәкми, мин бернинди хастаханәгә дә бармыйм. Минем җаным үлде инде, җан булмагач, тәнне дәвалаудан ни файда?

Гәрәй. Юк, матурым, барабыз.

Айсылу. Син бит йөзең матур булганга түгел, җаның саф, күңелең матур булганга яратам, дия идең. Минем бит җаныма кислота сипмәделәр.

Гәрәй. Ул турыда шигем юк, кадерлем. Җаның синең бай, матур. Мин сине нинди булсаң да яратачакмын. Ләкин, чәчәгем, дәваланырга кирәк. Пластик операцияләр ясатмабыз. Ләкин дәваланмыйча булмый. Синең газапларыңны күрү йөрәгемне телгәли.

Айсылу. Йөрәк әрнүенең нәрсә икәнен син дә белергә тиеш.

Гәрәй. Ярый, акыллым, әгәр сиңа шул җиңеллек китерсә, сине үзем дәвалыйм. Чынлап та җибәрмим мин сине хастаханәгә. Миңа сине үз янымда тою җан рәхәте бирә.

Сәрбиназ. Шулай да хастаханәгә алып барырга кирәк, Гәрәй Мингалиевич.

Гәрәй. Юк, үзем дәвалыйм. Мөмкин булса, яраңны бераз гына ачып карыйк әле.

Айсылу. Кирәкми, авырта.

Гәрәй аны сабый баладай күтәреп йөри.

Гәрәй. Синең газапларыңа мин гаепле. Мин дә газапланырга тиеш.

Айсылу. Юк, кирәкми, Гәрәй, синең эшләрең бар.

Гәрәй. Эш бүре түгел, урманга качмас.

Айсылу. Качар да. Сиңа эшеңне ташларга ярамый. Чибәр, яшь кызлар дөнья тулы. Алырсың берәрсен.

Гәрәй. Миңа синнән башка беркем дә кирәкми.

Айсылу. Муеным кәкрәеп, битем җыерчыкланып калса, бу сүзләр онытылыр.

Гәрәй. Их, нишләп сине ышандыра алмыйм икән?! Яратам бит мин сине, Айсылу, яратам. Мин аңладым инде: син минем җаныма әверелгәнсең, ә җансыз мин ничек яшим?

Айсылу. Юк, юк, син әле генә шулай дисең. Ә терелеп чыккач, иптәшләреңә күрсәтергә дә хурланачаксың.

Гәрәй. Әгәр син ышанмыйсың икән, мин дә битемә кислота сибәм. *(Чабып кухняга кереп китә.)*

Аның артыннан Сәрбиназ белән Айсылу йөгереп керә. Гәрәй бар нәрсәне туздырып кислота савытын эзли. Аның бер кулына Сәрбиназ, икенчесенә Айсылу барып ябыша.

Айсылу. Юләрләнмә, Гәрәй. Мин сине ташлап кая китим инде?

Гәрәй *(шатланып Айсылуны коча)*. Акыллым минем! Рәхмәт. Ә хастаханә чукынып китсен. Үзем терелтәм мин сине. Мәхәббәтем белән терелтәм. Мәхәббәттән көчле дәва юк!

Пәрдә.

*2006*

## ЯЗМЫШЛАРНЫ КАБАТ ЯЗЫП БУЛМЫЙ

*(Ике пәрдәле драма)*

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

#### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Автор.

Барган идем авылым зиратына,
Йөрәгемне чолгап ут алды.
Янам, янам — бәргәләнеп янам,
Көнем белән төнем буталды.

Йөгереп карыйм йөзне җилгә куеп,
Ут ялмаган ләкин җилне дә.
Кычкырмакчы булам — тавышым чыкмый,
Сүзләр яна минем телемдә.

Әллә инде тәмуг утларының
Бер катрәсе төшкән ярама:
Янам, янам — күз яшьләрем яна,
Кабер өсләренә тама да.

Яна уйлар, яна зиһен дөрләп,
Тамырларда кайнап кан яна.
Үлгәннәр шул кире кайтмый, диеп,
Әрнеп-сыкрап эчтә җан яна.

Яна ташлар, яна баскан эзләр,
Яна дөньям — барысын ут алган.
Яна хәтер, яна истәлекләр,
Кошлар хәтта җырдан тукталган.

Сәхнәгә Хәерче керә. Ул кергәч, Автор күләгәдәрәк кала. Хәерче — сәләмә киенгән, таякка таянган бетәшкән бер карчык.

Хәерче.

Тимер акча, бакыр акча, көмеш акча,
Җанга рәхәт, учта акча чылтыраса.
Ярый әле бу дөньяда зиратлар бар,
Зират безгә җимеш бирә торган бакча.

Бу дөньяда берәм-берәм бар да үләр,
Соңгы кеше булып калыр хәерчеләр.
Ачлар белән хәерчеләр җирне басар,
Җирне каргап фәрештәләр ташлап качар,
Тимер акча, бакыр акча, көмеш акча.

Сәхнәгә Бай керә. Ул да карт. Ләкин өсте-башы бик пөхтә. Күзендә алтын чылбырлы пенсне. Кесәсеннән сәгатенең алтын чылбыры күренеп тора. Ул шактый арыган кыяфәтле. Шунда бер агач төбенә утыра.

Бай.

Тибелдем, сөрелдем, куылдым,
Көч бетсә, гел җиргә сыендым.
Байлыкны алсалар алдылар,
Эш белгән колларым калдылар.

Җирдән бер уч туфрак алып исни.

Иң тәмле ис икән җир исе,
Җирдә бар меңнәрнең тир исе.

Тагын туфракны исни. Шунда аның янына Хәерче килә.

Хәерче.

Нәрсә таптың? Акча мәллә? Бирче, бирче!
Мин дөньяда мескен бәндә — бер хәерче.

Бай.

Юк, акчадан зуррак байлык минем монда,
Ул байлыкка урын җитмәс капчыгыңда.

Хәерче.

Җитәр, җитәр, капчыгым зур, менә кара,
Ул капчыкка ни салсаң да сыеп бара.
Ач елда да халык мине ач итмәде,
Бирде миңа соңгы кабымлык икмәген.
Бай Хәерченең йөзенә күтәрелеп карый. Нәрсәнедер исенә төшерергә тырыша.

Бай.

Тукта, тукта, син кем әле, тавышың таныш?
Ишетәмме тавышыңны әллә ялгыш?

Хәерче.

Хи-хи-хи-хи, танымыйсың, үзгәргәнмен?
Ныклабрак кара миңа — күләгәң мин.
Эзәрлекләп йөрим сине гомер бакый,
Батырам-талыйм, син яшисең һаман батмый.

Бай.

Тукта, тукта, кем син, кортка, ник син усал?

Хәерче.

Мәрхәмәтле булып булмый, ярлы булсаң.

Бай.

Кем гаепле синең ярлы булуыңда?
Һәркемнең бит үз бәхете үз кулында.

Хәерче.

Син гаепле! Чөнки син бай, ә мин ярлы,
Минем байлык гел-гел сиңа күчә барды.

Бай.

Тукта, тукта! Ни сөйлисең, исәр кортка,
Кул сузмадым мин бервакыт чит байлыкка.

Хәерче.

Ә кулыңда нинди байлык, каян таптың?
Ул минеке, кичә аны мин югалттым.

Бай.

Югалткансың, анысы дөрес, мә, ал, бирәм,
Тик югалтма аны бүтән, кабат бирмәм.

Хәерченең учына үзенең учындагы туфрагын сала. Хәерче туфракны җиргә ыргытып таптый.

Хәерче.

Аһ, оятсыз, төшсен сиңа минем каргыш,
Үлалмыйча интегеп ят, сызлан, тартыш.

Чыгып китә.

Бай.

Аһ, каһәре, бу бит үзе, шул ук тавыш,
Шул ук каһәр, шул ук ачу, шул ук каргыш.
Күп эзләдем дөнья буйлап сине, елан,
Менә кайда очраштырды безне язмыш.

Чыгып китә.

Автор.

Берсе ярлы, берсе бай боларның,
Нигә килгән алар бирегә?
Әллә инде тарих тәгәрмәче
Әйләнәме икән кирегә?

Зиратларга кеше юкка килми,
Зиратларда күпме сер ята.
Серләр алар ачылырга тиеш,
Кешеләрнең җанын шул тарта.

Мин дә менә эчтән яна-яна
Эзлимен бер нәсел агачын.
Яфраклары аның кая төшкән,
Кәүсәләре аның кая соң?

Эзлим-эзлим, яфракларын эзлим,
Күмерләрен эзлим мин аның:
Һәрбер агач — бер терәге бит ул
Фаҗигаләр тулы дөньяның.

Дөнья кинәт упкыннарга чумар,
Сирәкләнсә әгәр терәге.
Эзлимен бер нәсел агачының,
Кайнар көлен эзлим җирдәге.

Мине монда хәтер алып килде,
Мәңгелек тик хәтер агачы.
Кайта-кайта үткәннәрдән эзли
Киләчәген адәм баласы.

Менә кабер. Зәйнәп әби кабере.
Янәшәдә Рәмиз, Риф ята.
Зәйнәп әби үзенең оныкларын
Гүя шулай карап йоклата.

Автор үзенең монологын сөйләп торганда, ерактан матәм маршы ишетелә башлый. Озакламый тимер табут күтәргән кешеләр күренә. Әкрен генә атлап алар сәхнәнең бер ягыннан икенче ягына үтәләр.

Автор
*(Ачынып.)*

Менә тагын тимер табут кайткан,
Кем газизе, кемнең баласы?
Үлгәннәргә түгел, калганнарга
Тәмуг утларында янасы.

Дөнья, дөнья! Мондый гаделсезлек
Кайда туа, кемнәр күңелендә?
Ник берәүләр ләззәт таба икән
Башка берәүләрнең үлемендә?

Сугыш уты кабызучыларның
Кайда икән газиз уллары?
Тираннар да елый белә микән,
Бер күрәсе килә шуларны.

Яна йөрәк, әллә нинди уклар
Кадалалар килеп бәгырьгә.
Тираннар бит мәңге яшәмәкче,
Башкаларны тыгып кабергә.

Зәйнәп әби тавышы.

Сабыррак бул, балам, өзгәләнмә,
Беребез дә бакый түгел без.
Бу дөньяда яхшылыклар белән
Яманлыклар гына үлемсез.

Кеше китә — җыры кала, диләр,
Бу бәхет тә тими күпләргә.
Нәселебездә хәзер беркем дә юк
Җырыбызны дәвам итәргә.

Китеп бардык җирдән берәм-берәм,
Кабат язып булмый язмышны.
Кемнәр сөйләр икән бар дөньяга
Безнең кайгы, безнең сагышны?

Автор.

Зур бер нәсел агачында
Җиде алма үскән иде.
Алмаларның җидесе дә
Матур булып пешкән иде.

Тәгәрәтте алмаларны
Язмыш җиле төрле җиргә:
Кайсыларын ачлык йотты,
Кайсын сугыш тыкты гүргә.

Шушы җиде алманың мин
Язып китәм әле берсен:
Зәйнәп әбинең төпчеге
Чибәр булып үсте Гөлсем.

Аның йөргән юлларында
Гөлләр үсеп чыга иде.
Бер караса, ун егетне
Аягыннан ега иде.

Тик берәүне яратты ул,
Күңелендә булды Вәгыйз.
Бу дөньяда нәрсә бар соң
Мәхәббәттән бөек, газиз?!

Оя корды алар бергә,
Күркәм иде оялары —
Ярлылыкны һәм юклыкны
Матурлады хыяллары.

Озакламый Рәмиз туды,
Шатлык өстәп шатлыкларга.
Ул көннәрдә дөньялары
Күмелде гел аклыкларга.

Хәер, бу бәхетле парның
Сүзне бирик үзләренә.
Аларның бар бәхетләре
Язылган бит күзләренә.

Вәгыйз белән Гөлсем керә.

Вәгыйз.

Гөлсем бәгърем, ак канатым,
Рәхмәт сиңа, малай таптың.
Сөенчегә миннән бүләк —
Мәхәббәтем тулы йөрәк.

Гөлсем.

Уртак бала, уртак бәхет,
Җаныбызның бер өлеше.

Вәгыйз.

Шушы уртак зур бәхетнең
Ул алтыны, без көмеше.

Гөлсем.

Улыбыз үсәр, улыбыз белән
Бәхете һәм даны үсәр.

Вәгыйз.

Яшәү серен аңлар өчен
Диңгезләр һәм дәрья кичәр.

Гөлсем.

Ул куркусыз, батыр булыр,
Зирәк булыр, тапкыр булыр.

Вәгыйз.

Нәселебез агачында
Иң-иң ныклы тамыр булыр.

Гөлсем.

Ай үсәсен атна үсәр.

Вәгыйз.

Җитмеш дәрья суын эчәр.

Гөлсем.

Уллар үсәр, кызлар үсәр
Бу ояда гөлдер-гөлдер.

Вәгыйз.

Шулар аша бу дөньяда
Дәвам итәр безнең гомер.

Автор.

Әй ул бәхет-шатлыкларның
Гомерләре бик кыска шул:
Сугыш чыкты. Китте Вәгыйз.
Озатып калды ана һәм ул.

Шул китүдән Вәгыйз бүтән
Кайталмады туган якка.
Күмелеп калды гәүдәсе дә
Әллә кайда, чит туфракта.

Зәйнәп әби су буенда
Эзләп калды бәбкәләрен.
Бәбкә түгел, яуда үлгән
Улларын һәм әткәләрен.

Ул аларны гомере буе
Эзләр, ләкин таба алмас.
Елый-елый яше кибәр,
Күзеннән яшь тама алмас.

Җиде башлы аждаһа да
Җиңелә батыр кылычыннан.
Сугыш бетте, тик батырлар
Көйде аның сулышыннан.

Кемнең башы, кемнең кулы
Өзелеп калды чит җирләрдә.
Гөлләр янды, ирләр калды,
Тик җиңү кайтты илләргә.

Ничек кенә булмасын ул,
Җиңү барыбер җиңү инде.
Җиңү белән күңелләргә
Зур сөенеч, өмет килде.

Бәлки, еллар үткән саен
Тоныкланыр бу бәйрәм дә.
Ләкин бүген бәйләде ул
Кешеләрне бер бәйләмгә.

Пәрдә.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Пәрдә ачылганда, сәхнәдә фейерверклар атыла. Бер төркем кешеләр, шатланып, сәхнәгә кереп тула. Алар арасында картлар да, яшьләр дә, бала-чагалар да бар. Алгы планга ике култык таягына таянган сыңар аяклы бер солдат чыга.

Солдат.

Урра! Җиңү! Бу көнне дә күрдек.
Инде хәзер дөнья үзгәрер.
Бәхет йөрер өйдән өйгә кереп,
Хәерчелек җиңелеп тезләнер.

Карчыклар.

Амин! Амин!

Ике кулсыз солдат алга чыга.

Кулсыз солдат.

Сугыш сүзен җирдә онытырлар,
Һәркем булыр куллы-аяклы.
Безнең түккән каннар гөлләр булып
Шытып чыгар. Моңа без хаклы.

Карчыклар.

Амин! Амин!

Өченче солдат.

Бер күземне, бер кулымны бирдем
Иминлеге өчен илемнең.
Киләчәкнең матур, тыныч көне
Гел түрендә йөрде күңелнең.
Без сугыштык, көчне аямадык,
Намусыбыз шулай кушканга.
Кулны бирдек, күзне бирдек, ләкин
Илне бирмәдек без дошманга.

Ярлы карчык керә.

Ярлы карчык.

Җиңү, җиңү, дисез. Нәрсә соң ул?
Ә аңардан миңа ни файда?
Түшегездә орден барын бар да,
Ярлыларга дигән ипи кайда?
Ипи кирәк миңа, ипи, ипи,
Гомер буе безгә ипи җитми.
Алып кайтсак кырдан сыңар башак,
Утырттылар, бездән карак ясап.

Балаларым өйдә ач утыра,
Ничек карыйм алар күзләренә?
Ышанмыйлар алар киләчәктә
Туклык булыр дигән сүзләремә.

Урта яшьләрдәге кеше.

Булыр, булыр, бөтенесе булыр,
Муллык булыр, булыр тигезлек.
Моннан ары ачлык авызына
Куярбыз без йөгән кигезеп.

Бер колагын алгарак сузып, Саңгырау карт чыга.

Саңгырау карт.

Нәрсә дисез, нәрсә, ишетмәдем,
Кайда саталар, ди, имезлек?
Имезлекләр күбрәк кирәк иде,
Оныкларым минем сигез бит.
Чәйниләр дә йотып җибәрәләр,
Һич җиткереп булмый имезлек.
Имезлеккә бераз сөт салырга
Булмый һаман кәҗә тергезеп.

Яшьләр аңардан көлә.

Яшьләр.

Бар, бабай, кайт, утыр өйдә генә,
Бүген монда берни сатмаслар.
Хәзер инде синең оныкларың
Буш имезлек суырып ятмаслар.

Саңгырау карт.

Алайса соң, нигә җыелдыгыз?
Әллә тагын кемдер үлгәнме?

Яшьләр.

Үлгән, бабай, үлгән. Сугыш үлгән.
Күзәтәбез шуны күмгәнне.

Саңгырау карт.

Сугыш үлгән? Шаярмагыз әле.
Сугыш аждаһасы мең башлы.

Солдатлар.

Ә без аның мең башын да кисеп,
Дөнья буйлап тездек юл ташы.

Берсе.

Сугыш белән без бүген хәерчелекне дә күмәбез.

Хәерче.

Юк, юк, мине күмалмассыз җиргә,
Мин кабердән калкып чыгармын.
Чыгармын да, кулларымны сузып,
Барыбер сездән хәер сорармын.

Кеше заты яшәгәндә, җирдә
Хәерчелек булган, булачак.
Килер бер көн, бөтен дөнья әле
Хәерчеләр белән тулачак.

Яшьләр.

Бетерербез. Күмәрбез.

Икенчесе.

Гаделсезлекне дә күмәрбез.

Өченчесе.

Кайгы-хәсрәтләрне дә.

Дүртенчесе.

Өметсезлекне дә.

Бишенчесе.

Кимсетүләрне дә.

Алтынчысы.

Барлык хурлык-түбәнлекләрне дә.

Җиденчесе.

Моннан соң җирдә бер дә сугыш булмас.

Сигезенчесе.

Улларыбыз, ирләребез чит җирләрдә
ятып калмас.

Тугызынчысы.

Туклык булыр, муллык булыр.

Унынчысы.

Йөзләребезгә нур кунар.

Унберенчесе.

Гаделлеккә юл күрсәтергә безнең
юлбашчыларыбыз бар.

Уникенчесе.

Яшәсен юлбашчылар. Ура!

Бөтенесе бергә.

Ура! Ура!

Карчыклар һәр сүз артыннан: «Амин!», «Амин!» — дип торалар. Халык төркеме әкрен генә ераклаша. Кайберләренең кулларында көрәкләр. Алар зиратка юнәләләр.

Урта яшьләрдәге кеше.

Юлбашчылар әкият батырлары
Булып тоела иде ул чакта.
Алар гадел, алар — яклаучылар
Рәнҗетелгәннәрне нахакка.

Шундый ук яшьтәге икенче кеше.

Бер китаптан бер китапка күчеп,
Бу әкиятләр торды яңарып
Һәм сардылар күңел бакчаларын,
Яман коңгыз кебек таралып.

Беренче кеше.

Дию пәриләре булган икән
Безнең әкият батырларыбыз:
Аларга гел корбан кирәк булган,
Кирәк булган безнең каныбыз.

Икенче кеше.

Илебезнең таза ул-кызларын
Алар һәр көн урлап торганнар.
Кеше каны эчкән бу диюләр
Шулай кәеф-сафа корганнар.

Беренче кеше.

Ә диюләр алар җиде башлы,
Җиде башны кисү — кыен эш.
Шуңа күрә һаман алар белән
Бара көрәш, бара кырылыш.

Икенче кеше.

Әллә инде хаклык кылычыбыз
Безнең бик үк үткен түгелме?
Һаман әле җиңә алмыйбыз без
Җиде башлы шушы диюне.

Беренче кеше.

Әллә инде иске әкиятләргә
Ышанамы һаман күбебез?
Һәр урманның әле диюе бар,
Аждаһалы һәрбер күлебез.

Автор.

Бәйрәм итә халык шаулап-гөрләп,
Җиңелдекме соң без, җиңдекме?
Бер гаепсез миллион корбаннарны
Шушы көннәр өчен бирдекме?

Әй сөендек сугыш бетте диеп,
Бармы аның берәр беткәне?
Канлы сугышлардан гына тора
Илебезнең бөтен үткәне.

Явызлык бар җирдә көрәш бетми.
Явызлыкка юк бит авызлык.
Кемдер яши яраларын ялап,
Кемдер яши яшен агызып.

Үзләренең канлы язмышында
Тоеп яши моны һәммәбез.
Героебыз Рәмиз язмышына
Бер күз ташлап үтик, әйдәгез.

Пәрдә төшеп ала.

Рәмиз пәйда була.

Рәмиз.

Кырык бишнең шаулы язы!
Җиңүчеләр өйгә кайта.
Солдат кайткан һәрбер йортта
Кочак булып ачыла капка.

Менә безнең капканы да
Яңа хәбәр килеп какты:
Әтиебез кайтмаса да,
Даны кайтты — орден кайтты.

Әй сөендек, әй сөендек!
Шатлык күргән бармы безнең?!
Инде авыр болытлары
Таралыр, шәт, күгебезнең.

Качар өйдән хәерчелек —
Бәхетебез йөрер алдан.
Бу орденны әткәбез бит
Үз гомерен биреп алган.

Кем керсә дә, күрсәтәбез,
Мактанырга хакыбыз бар.
Әйтерсең лә кулыбызда
Орден түгел, атыбыз бар.

Кем уйлаган ул орденның
Безгәниләр китерәсен:
Тереклек сулары биргән
Чишмәбезне киптерәсен.

Истә әле, кичкә таба
Килеп керде ике кеше.
Хәлне язып аңлатырга
Җитәр микән каләм көче.

Әни, мескен, кабаланып,
Нидер куйды, нидер алды.
Ә аннары, исенә төшеп,
Самавырга күмер салды.

Кем керсә дә чәен куя —
Шундый инде безнең халык:
Дошманымы, дустымы ул —
Сыйлый соңгы сыен салып.

Безгә кергән бәндәләрнең
Карашлары чалыш иде.
Кулларында кара сумка,
Шунда безнең язмыш иде.

Өйгә кергән бәндәләр, кара сумкаларын өстәлгә куеп, утыралар. Алар өстәлдәге ризыкларны комсызланып ашыйлар. Рәмиз аларга авыз суларын корытып карап тора. Чөнки белә: бу ризыклар — иң кадерле кунаклар өчен дип саклап тоткан ризыклар.

Беренче бәндә.

Кара, ничек шәп яшисең —
Өстәлеңдә ипиең бар.
Үзең налог түләмисең,
Болай булса, озакламый
Себерләргә китүең бар.

Икенче бәндә.

Әйе, әйе, саботаж бу,
Син бай хатын, корма хәйлә.
Ач та яшел сандыгыңны,
Акчаларың чыгар, әйдә.

Беренче бәндә.

Безнең бөек юлбашчыбыз
Кайгырта гел сезнең хакта.

Икенче бәндә.

Алар монда, понимаешь,
Байлыкларын яшереп ята.

Беренче бәндә.

Менә налог кәгазьләре,
Чыгар акчаң, давай, ашык.
Юкса Себер якларына
Сездәйләргә юллар ачык.

Рәмиз.

Әни кинәт бу сүзләрдән
Бөгелеп төште, хәлсезләнде.
Һәм бу явыз бәндәләрнең
Каршыларына тезләнде.

Ана.

Коткарыгыз, зинһар өчен,
Бу налоглар җәбереннән.
Үлгәч тә рәхмәт укырмын,
Торып-торып каберемнән.

Теге бәндәләр ыржаеп көләләр.

Беренче бәндә.

Ха-ха-ха-ха, ха-ха-ха-ха,
Үлгәч рәхмәт укый, имеш!

Икенче бәндә.

Әллә үләр идеңме син,
Налог түләмәгән килеш?

Ана.

Коткарыгыз, коткар, зинһар,
Шушы балам хакы өчен.
Иремнең иленә кайткан
Батыр дигән аты өчен.

Күрәсез бит: һичнәрсәм юк —
Карап торган бер сыерым.
Ул да быел бозау салды,
Килсә килә бит ул кырын.

Беренче бәндә.

Китер тизрәк ачкычыңны,
Сандыгыңны күрсәт, әйдә.

Ана сандыкны барып ача. Ул бикле булмый. Теге бәндәләр комсызланып сандыкны актарырга тотыналар. Сандыктан Вәгыйзнең фронтка киткәнче кешелеккә генә кия торган костюм-чалбары килеп чыга. Берсе аны үзенә үлчәп карый, ләкин Рәмиз килеп, аны тартып ала.

Беренче бәндә.

Ах син, көчек! *(Тибеп җибәрә.)*

Теге бәндәләр, яңадан сандыкка икесе берьюлы башларын тыгып, һаман актарыналар. Ниһаять, сандык төбеннән бер төргәк табып алалар.

Беренче бәндә

*(төргәкне кулында сикертеп).*

Менә без эзләгән байлык,
Шактый авыр, ахры, алтын.

Икенчесе

*(төргәкне анның кулыннан алып).*

Шайтан елап ышандыра,
Аһ, оятсыз — шайтан хатын.

Болар төргәкне сүтәләр. Төргәк эченнән Вәгыйзнең ордены килеп чыга. Тегеләр башта бераз аптырап калалар, ләкин бик тиз һушларына киләләр.

Беренче бәндә.

Юлбашчыбыз сезне зурлап
Нинди орден бүләк иткән.
Кешеләргә мондый хөрмәт
Бездә генә — онытма бүтән.

Икенче бәндә.

Әгәр белсәң, бу орденга
Тигән юлбашчыбыз кулы.
Бу — байлыкларның байлыгы,
Бу — мең алтыннан да олы.

Ана.

Алай булгач, шушы орден
Налогларны каплый, димәк?
Мә, алыгыз, сезгә бирәм,
Алыгыз, ал, кемгә кирәк?

Теге бәндәләр Анага ташлана.

Беренче бәндә.

Аһ, оятсыз, аһ, намуссыз,
Орден белән налог түли!

Икенче бәндә.

Әнә анда безне көтеп
Абзарында сыерың мөгри.

Шул вакыт бер кочак чытыр күтәреп Зәйнәп әби кайтып керә. Ул бик тиз эшнең нәрсәдә икәнен аңлап ала.

Зәйнәп әби.

Кагылмагыз сыерыбызга,
Ятимнәрнең яше төшәр.

Алар Зәйнәп әбине читкә этеп җибәрәләр.

Беренче бәндә.

Каркылдама син, карт карга.
Синнән башка да күп эшләр.

Зәйнәп әби.

Ятимнәрне рәнҗетсәгез,
Үзегезне сугар Алла.

Тегеләр.

Бар әле, бар мич башыңа,
Монда торма, ала карга.

Тегеләр ишегалдына сыерны алырга чыгып китәләр.

Автор.

Ничә еллар илем бугазына
Басып торды авыр күн итек.
Ыңгырашты илем
Тын җитмәүдән,
Төрмә диварларын селкетеп.

Рәмиз пәйда була.

Рәмиз.

Ыңгырашты җирләр,
Хуҗаларын
Куган чакта ерак Себергә,
Чәчелмәгән «кулак җирләрендә»
Уйнады тик усал өермә.

Автор.

Ыңгырашты сабый-нарасыйлар,
Ә күпләре әле, мөгаен,
Күрми үлгәннәрдер
Үз гомрендә
Бер тапкыр да ипи чыраен.

Рәмиз.

Ыңгырашты япь-яшь хатын-кызлар,
Кара төндә кереп,
Ирләрен
Кочаклардан суырып алган чакта,
Ыңгырашты тешләп телләрен.

Автор.

Ыңгырашты халык төрмәләрдә,
Чәйни-чәйни тимер богавын.
Кыю ирләр тез чүктеләр кайчак,
Үтә алмый тормыш сынавын.

Рәмиз.

Мин һаман бер сыкрау ишетәм кебек
Һәм тыңлыймын аны тын калып.
Каберсезләр әллә урын тапмый
Йөриләрме шулай шом салып?

Автор.

Әллә алар мәңге мәңгелеккә
Исемнәрен җуйган ирләрме?
Җилләр миңа ерак-ераклардан
Алып килә нинди өннәрне?

Бай пәйда була. Ул әле яшьрәк.

Ил барыбер баемады,

Җирдән аерып «кулак»ларны.
Үрчеттек тик, таракандай,
Ялкауларны, куркакларны.

Һөнәрлеләр үлмәделәр
Тайгада да, Себердә дә.
Кулың белән башың булса,
Яшәп була һәр җирдә дә.

Кеше талап яшәүчеләр
Мантый алмый һичбер вакыт.
Ташлый заман аларны бер
Тарих чүплегенә атып.

Бай чыгып китә.

Рәмиз.

Сыерны алып киттеләр,
Без өчәүләп калдык елап.
Дөньяда күп нәрсәләрне
Аңладык шул артык соңлап.

Намусларын бу бәндәләр
Күптән сатып эчкән инде,
Вөҗданнары ишелеп торган
Корсак булып үскән инде.

Сине сыту, таптау, изү
Алар өчен ләззәт кенә.
Ашый алар үз корбанын
Әкрен генә, тәмләп кенә.

Заманы шул: куркак җаннар
Җанын сатып батырлана.
Һәм яманлык ил буенча
Миллионнарга тапкырлана.

Автор.

Алыйм дисәң куркакларның
Соңгы тамчы кешелеген,
Кулларына власть тоттыр,
Власть яшерер мескенлеген.

Кемдә власть — ул гел хаклы,
Ялагайлар алар яклы.
Аңлау кыен кешеләрне,
Күңелләр шул катлы-катлы.

Кем булса да илдә хаким,
Ярлыларны талап килгән.
Ә ярлылар дәшми генә
Яраларын ялап килгән.

Рәмиз.

Әнә алар бау салалар
Сыерыбыз муенына.
Сыер мөгрәп безгә карый.

Сыер.

Яклагызчы, кыен миңа.
Сукаларга җиккәндә дә
Карышмадым — тарттым, сөрдем.
Җаныгызны асрарлык
Һәр көн саен сөтен бирдем.

Заем, налог ишеләрне
Түләргә дә кирәк булдым.
Мин бит сезгә ничә еллар
Иң-иң ныклы терәк булдым.

Быел менә бозау салдым,
Рәнҗетәсез болай соң ник?
Колхоз җирен сөргән чакта
Өзлеккәнне беләсез бит.

Рәмиз.

Әни шунда әллә нишләп китте,
Орденны ул җиргә ташлады.
Күзләреннән очкын чәчә-чәчә
Аны изә, таптый башлады.

Күргәнем юк иде һичбер вакыт
Әниемнең болай ярсуын.
Шул орденнан алмакчы булды ул
Бу дөньяга булган ачуын.

Ана.

Ил өчен дип бирдең җаның —
Менә сиңа, менә сиңа.
Җан урынына кайтты даның —
Менә сиңа, менә сиңа!

Җан сатканнар майда йөзә —
Менә сиңа, менә сиңа!
Көчсезләрне бар да изә —
Менә сиңа, менә сиңа!

Ләгънәтле ил бүләге —
Менә сиңа, менә сиңа!
Кимсетелгән ир йөрәге —
Менә сиңа, менә сиңа!

Ипи булсаң — ашар идек,
Менә сиңа, менә сиңа!
Утын булсаң — ягар идек,
Менә сиңа, менә сиңа!

Рәмиз.

...Әни арып туктап калды
Һәм елады ятып җиргә.
Әнкәм яше тамган җирләр
Яшәрмәде кабат бер дә.

Автор.

Күз алдымда шәүлә йөри,
Бу нинди котсыз шәүлә?
Үткән көннәр өрәк булып
Әйләнеп кайткан мәллә?

Рәмиз.

Юл тузанына күмелеп,
Бәргәләнеп кем елый? —
Рәнҗетелгән бер сабый да
Аңа кушылып гел елый.

Автор.

Иелә башы, түгелә яше,
Сүнеп бара кояшы.
Кулларында бер чыбыркы —
Тик шул аның юлдашы.

Орденны хурлаган өчен
Утыртканнар әнкәсен.
Әнкәсеннән мәхрүм итеп,
Җәзалыйлар бәбкәсен.

Рәмиз.

Агыла болыт, агыла болыт,
Агыла болыт ишелеп;
Бу кадәрле хаксызлыкны
Ник күрмисең, Кешелек?

Автор.

Тибелә кеше, сүгелә кеше,
Чайкала уңга-сулга:
Бу кадәрле хурлауларга
Ничек түзәсең, дөнья?

Рәмиз.

Кимсетелә гүзәл җаннар,
Тезләнә горур ирләр:
Бу кадәрле күз яшьләрен
Ничек күтәрә җирләр?!

Автор.

Су бирегез, су бирегез,
Сулар бирегезсәнә.
Шулар искә төшкән саен,
Йөрәккәйләрем яна.

Рәмиз.

Уф, түзалмыйм, тавыш килә,
Чыңлый хәтта колаклар.
Ыңгырашып ята бугай
Мең корбанлы зиратлар.

Автор.

Су бирегез, су бирегез —

Кирәк миңа Иделләр.
Җир йөзендә миллион әле
Яраланган күңелләр.

Йә, кайсыгыз тылсым белә?
Дәвалагыз шуларны.
Әллә инде ялварыйммы,
Күккә сузып кулларны.

Рәмиз.

Инде кабат җир йөзендә
Булмас микән ГУЛАГлар?
Кара төндә ыңгырашып
Ятмас микән зиратлар?

Автор.

Җаным кайный, каным кайный,
Уйлар мине тилертә.
Йөрәгемә әллә кемнәр
Һаман йөгән кигертә.

Рәмиз.

Чаң бирегез, чаң бирегез,
Чаң бирегез сез миңа;
Даң-доң иткән чаң тавышын
Ишетсен әле дөнья.

Автор.

Чукраклар да ишетсеннәр
Бу тавышны җирдәге.
Аң уянсын, җан уянсын,
Сүз уянсын телдәге.

Рәмиз.

Ут бирегез, ут бирегез —
Бушады шәмдәлләрем:
Яктыртыйм әле йөзләрен
Мин явыз бәндәләрнең.

Автор.

Күрсен дөнья, белсен дөнья
Кемнең кем икәнлеген:
Беркем яшереп калалмасын
Үзенең түбәнлеген.

Рәмиз.

Ут бирегез, ут бирегез,
Ут бирегез, ут кирәк:
Кара төннәрне яндырып,
Җирне яктыртыйк тизрәк.

Автор.

Шул яктылык сукырларның

Күзен ачып җибәрсен.
Күрсен кеше үзен-үзе,
Әйтсен: ә без кемнәр соң?

Рәмиз.

Ут бирегез, ут бирегез,
Ут бирегез кулларга.
Маяк тезеп чыгыйм әле
Әнкәм кайтыр юлларга.

Ана белән ул сәхнәнең икесе ике ягында.

Рәмиз.

Хатлар язып торды әни
Миңа ерак-еректан.

Ана.

«Монда да шул ук эш икән,
Шул ук көн дә, шул ук таң.

Рәмиз.

Их, әнием, мин дә шунда
Синең яныңда булсам.

Ана.

Юк, юк, улым, юк, кирәкми,
Уйлама андый уйлар.
Бәлки әле, бәхет кошы
Синең иңеңә кунар.

Рәмиз.

Юк, әнием, бәхет түгел,
Бүген миңа син кирәк.
Йә, сөйлә инде хәлләрең,
Ишетим мин дә тизрәк.

Ана.

Без, улым, күптәннән бирле
Төрмәдә икәнбез бит.
Тик шуны үзебез генә
Белмәгән икәнбез бит.

Төрмәнең дә иң катысы,
Иң яманы, иң зуры —
Колхоз дип аталган икән,
Белмәгәнбез тик шуны.

Сыртыбызда уйнап торды
Бригадирның камчысы.
Анда ашалган икән бит
Икмәкнең иң ачысы.

Китәр идең — паспортың юк,

Син хокуксыз мәхлук җан.
Әзме каннарны суырды
Ул каторга, ул зиндан.

Туды авыл кешеләре
Тик налог түләр өчен.
Гомере буе налог түләп,
Бурычлы үләр өчен.

Автор.

Әй изелдек, әй изелдек!
Көлчә булып изелдек.
Гомер буе изелүгә
Ничек җитсен түземлек?

Әй тапталдык, әй тапталдык,
Тузан булып тапталдык.
Калмады һичбер көчебез
Үзебезне якларлык.

Әй кысылдык, әй кысылдык,
Кысылып та карадык!
Кысыла торгач, такта булдык
Тик табутка ярарлык.

Рәмиз.

Иң авыры безгә төште —
Ятимнәргә һәрвакыт.
Җәйделәр безнең юлларга,
Ташлар итеп тараттык.

Ыргыттылар уттан алып
Безне аккан суларга.
Күпме мөмкин икән шулай
Язмыш белән уйнарга?

Ана.

Мин кайчак уйлап та куям,
Дөрес, ми сыек минем:
Коммунизм дигәннәре
Әллә шушымы, димен.

Беркемнең бернәрсәсе юк —
Бар да шәрә, бар да ач:
Эшләр өчен куллар бар да
Иелер өчен мескен баш.

Без, улым, изүләргә
Тәмам күнегеп беттек.
Әз генә изми торсалар,
Шуны торабыз көтеп.

Гүя «тиешле норма»ның
Алмый калсаң ярамый.
Менә шушы нәрсә бигрәк
Йөрәкләрне яралый.

Рәмиз.

Әнкәм, синең сүзләреңне
Аңладым артык соңлап.
Сыртка төшкән чыбыркыга
Яшәдем сүзсез чыдап.

Ана.

Түбәнгә төшү бер нәрсә —
Анысы бары бер яман.
Түбәнлеккә күнегеп китү —
Анысы инде мең яман.

Өч нәрсәдән саклан, балам,
Киңәшемне ташлама:
Беренчесе — бер кабым да
Хәрам ризык ашама.

Икенчесе — күңелеңә
Ояламасын ялган.
Ялган бар җирдә хаклык юк,
Шуны онытма, балам.

Өченчесе — иң мөһиме —
Шәфкатьсез була күрмә.
Шәфкатьсез кеше — тиран ул.
Шәфкатьсез дөнья — төрмә».

Рәмиз.

Әниемнең бу хатлары
Беткән инде, сакланмаган.
Хәер, алар хәтерләрдән
Җуелырлык ятланмаган!

Ул хатларны укыр өчен
Күпме чыра яндырдым мин.
Әниемне көтә-көтә
Күпме күзләр талдырдым мин.

Ул кайтмады, төрмә йотты,
Төрмәгә бит кирәк корбан.
Төрмә — җиде башлы Дию —
Кеше канын суыра торган.

Калтыранып уянам гел
Бик күп кара төннәрдә мин:
Хәер сорап йөрим, имеш,
Әллә кайсы җирләрдә мин.

Кулда капчык — киндер капчык,
Әнкәемнең соңгы төсе.
Ачлардан икмәк сорарга
Күзләремнең җитми көче.

Борылам да китеп барам,
Тотынмыйча ишекләргә.
Суык җилләр керә эчкә

Күлмәктәге тишекләрдән.

Һәр авылда, һәр урамда
Өреп кала явыз этләр...
Хәтер җебем нык тартылды,
Йә өзелер, туктыйм, җитәр!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Автор.

Зәйнәп әби чыгып күккә карый
Җидегән йолдыз янган чагында.
Җанын өткән кайгы сөремнәре
Күзләрендә аның чагыла.

Еламый ул, тик ялвара гына,
Күккә карап һаман ялвара.
Бала хәсрәтләре искерми шул,
Торган саен бары яңара.

Зәйнәп әби.

Безне бу кадәр кемнәр каргады?
Җиде баламның берсе калмады.
Уйларым минем ут булып яна,
Янган утлардан тик күмер кала.

Табып үстердем мин җиде бала,
Калды йөрәктә тик җиде яра.
Җидесе җиде юл табар, дидем,
Җидесе җитмеш ул багар, дидем.
Каберләре дә кайдадыр читтә,
Җаннары гына очадыр күктә.
Әй кошлар, кошлар, тыңлагыз мине:
Аларның җаны сездә түгелме?

Кулларым сузам, куныгыз учка,
Әверелде алар нindирәк кошка?
Бер генә тапкыр күрәсе иде,
Тыныч җан белән үләсе иде.

Әй болыт, болыт, миңа сөйләче:
Синдә түгелме алар күз яше?
Күз яше булсаң, там туган җиргә,
Балакайларым әверелсен гөлгә.

Әй яшен, яшен, яшьнәмә, тукта:
Янды соң алар нindирәк утта?
Бәлки, суларга аккандыр алар,
Әҗәлне шунда тапкандыр алар.

Туктап тор, елга, ярсыма, акма,
Дулкыннарыңнан сөйләт шул хакта.
Сиңа эндәшәм, җиһан, киң җиһан:

Балаларымның җанын кем кыйган?

Җиде баламнан бер онык калды.
Бөтен икмәктән бер сынык калды.
Инде аңарга гомер бир, Аллам,
Нәселемә, бәлки, шул бирер дәвам.

Автор.

Изге кешеләрнең теләкләре
Кабул була, диләр халыкта.
Ләкин иң-иң изге кешегә дә
Каныга икән язмыш, каныкса.

Рәмизне дә язмыш аямады,
Тәмуг утларына ыргытты.
Ялкын үрләп өске ботаккача
Нәсел агачларын корытты.

Хәер, барысын тәртип белән языйм,
Рәнҗемәсен миңа Рәмиз дус.
Без бит аның белән бергә-бергә
Күпме җәйләр кичтек, күпме кыш!

Рәмиз пәйда була.

Рәмиз.

Бер үк тауның ташы булдык,
Бер елгада дулкын булдык,
Ятимлекнең кулларында
Бер үк төсле тоткын булдык.
...Мин әнисез.

Автор.

Мин әтисез.
Ятимлекме дуслаштырды?!
Шушы дуслык гомерләрне
Мәңгелеккә тоташтырды.

Рәмиз.

Уйлар уртак, сыйлар уртак,
Бар нәрсәне бүлешәбез.
Аерым-аерым елыйбыз да
Бергә-бергә көлешәбез.

Автор.

Ач-ялангач яшәсәк тә,
Бик бай идек хыялларга.
Мескенлеккә юл куймадык
Җаныбызга ояларга.

Рәмиз.

Язмыш күпме кыйнамасын,
Үсә бирдек ныгый-ныгый.
Арыды дөнья безне кыйнап,
Әйтте: болар барыбер сынмый.

Автор.

Рәмиз бигрәк таза булды —
Арысландай күкрәкләре.
Бер карауда күпме кызның
Яулый иде йөрәкләрен.
Ә бит әле бөтенесе
Яңа гына сыман иде.

Рәмиз.

Мин яшь шофер.

Автор.

Ә мин монтер.

Рәмиз.

Иңгә бәхет кунган иде.

Автор.

Кичләр саен Рәмиз дусның
Кабинасын юа идек.
Матур кызлы авылларга
Машинасын куа идек.

Рәмиз.

Юлларыбыз уңа иде,
Икәү бергә булган чакта.

Автор.

Машинаңда сыпыра идек,
Чит егетләр куган чакта.

Рәмиз.

Ә бервакыт гашыйк булдык
Икебез дә бер үк кызга.
Мондый чакта дуслык бетә,
Сүз бирәбез кулыбызга.

Автор.

Кыз минеке!

Рәмиз.

Юк, минеке!

Автор.

Ул күз кысып үтте миңа.

Рәмиз.

Ә ул миңа су эчерә,
Барган саен кичен суга.

Автор.

Булмас, булмас, ялганлама.

Ул кыз бары мине сөя!

Рәмиз.

Ә мин әйтәм, минем өчен
Төн йокламый яна-көя.

Автор.

Синең өчен?

Рәмиз.

Минем өчен!

Автор.

Мә, алайса, шуның өчен!

Якалашып китәләр. Изүләр ертыла. Яка умырыла.

Автор.

Күпме дәвам итәр иде
Безнең көрәш, безнең тартыш —
Ләкин безнең бу бәхәсне
Хәл итте дә куйды язмыш.

Рәмиз.

Без яратып йөргән чибәр
Очты-китте еракларга —
Сөйгән яры иңнәренә
Былбыл булып кунакларга.

Автор.

Әй көлдек без тәгәрәшеп
Үзебезнең юләрлектән.
Каты төеннәрне дөнья
Кайчак үзе чишә икән.

Рәмиз.

Ха-ха-ха-ха! Көлеп үләм,
Сиңа күз сирпегән, имеш.

Автор.

Көлмә, көлмә, үзеңне күр,
Үзеңә дә шул ук өлеш.

Рәмиз.

Армиягә киттек бергә
Җырлый-җырлый урам урап.
Әллә кемнәр булмасак та,
Калучылар булды елап.

Икесе бергә җырлый.

Без урамнан үткән чакта
Күтәрелде тузаннар.
Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз —
Сау булыгыз, туганнар.

Солдат булып кайтырбыз без,
Каеш буып билләргә.
Башка куллар үрелмәсен
Без яраткан гөлләргә.

Арба җиксәк тә ярый,
Чана җиксәк тә ярый.
Безнең әле яшь чагыбыз,
Кая китсәк тә ярый.

Автор.

Җырлап киттек әнә шулай,
Җилкендереп йөрәкләрне.
Урамнардан үткән чакта
Киереп йөрдек күкрәкләрне.

Армиягә китү безгә
Бер егетлек кенә иде.
Анда бармый калганнардан
Бөтен кызлар көлә иде.

Ләкин безнең язмышларда
Ниндидер көч уйнап торды.
Бераз калка башладыкмы —
Түбәбезне кыйнап торды.
Иң беренче мин егылдым,
Давыл бәргән имән кебек.
«Ха-ха-ха»лап көлде язмыш,
Барыбер сезне җиңәм, диеп.

Ә бераздан син хат яздың
Хезмәт иткән якларыңнан.

Рәмиз.

Мин дә очып төштем, дускай,
Яшьлекнең ак чаптарыннан.

Мин хәзер элекке түгел.
Янда бар да, дөрләп янды:
Ракеталар сынаганда,
Ниндидер җил өтте җанны.

Хәзер мин мескен алаша,
Уйнап торган айгыр түгел.
Күзләрнең дә нуры сүнде,
Алар җәйге җәйгор түгел.

Ярый әле өйләнгәнмен,
Шөкер, минем малай үсә...

Автор.

Әй, бу нәсел агачларын
Һич көтмәгән җилләр кисә...
Истә, дустым, өйләнүең,
Язның матур көне иде.
Синең кәләш шушы язның

Иң-иң гүзәл гөле иде.

Рәмиз.

Әби, кара, менә бу кыз
Булыр сезнең киленегез.

Зәйнәп әби аларның аркаларыннан кага.

Рәхмәт, балам, гомер буе
Сөегез һәм сөелегез.

Рәмиз.

Рәхмәт, әби.

Зәйнәп әби.

Киленем түгел, кызым итеп
Каршы алам сине, балам.
Якты булсын йөзең айдан,
Татлы булсын телең балдан.

Яшәгез сез үрелеп үскән,
Җилдә аумас тирәк булып.
Купса тормыш давыллары,
Бер-берегезгә терәк булып.

Автор.

Ул көннәрнең матурлыгы
Онытылмый, һаман истә.
Йөзләр якты, дөнья якты —
Йолдыз яуды гүя өскә.

Шаулап үтте сезнең туйлар,
Яңгырады өйдә җырлар:
«Әй икегез, икегез,
Икегезнең битегез;
Берегез — былбыл,
Берегез — чәчәк,
Тигез гомер итегез.

Әй аландыр, аландыр,
Аланнарда баландыр.
Егет — алу, кызлар — бару,
Борынгыдан калгандыр».

Яшьләр.

Әйдәгез, биеп алабыз.
Тарт әле гармуныңны.

Гармунчы гармунын уйнап җибәрә. Бер кыз уртага чыгып бии, үзе үк такмак әйтә.

Аклы күлмәкләр тектердем,
Итәген сырлап-сырлап.
Үзем җырлап биим әле,
Кешедән тормыйм сорап.

Аңа бер егет чыга.

Тыпыр-тыпыр басуларың

Бик килешә үзеңә.
Нишләп әле моңа кадәр
Күренмәдең күземә?

Кыз.

Агыйделгә агып китте
Кер юа торган тактам;
Син йөргәнсең теге яктан,
Мин йөргәнмен бу яктан.

Егет.

Актыр кәҗә җоннары,
Күктер кәҗә җоннары;
Кунаклары биеп йөри,
Кайда хәҗәеннары?

Арадан берсе.

Әйдәгез, яшь кияү белән яшь
кәләшне биетәбез!

Боларны уртага тартып чыгаралар. Яшьләр такмак әйтеп тора, яшь  парлар бии.

Бас, бас, басыгыз,
Әйләнмәсен башыгыз;
Бал булса да, май булса да,
Уртак булсын ашыгыз.

Бас, бас, басыгыз,
Идәннәре селкенсен;
Сезгә карап яшь кызларның
Йөрәкләре җилкенсен.

Җыр, бию тына.

Автор.

Туйлар үтте. Әйтерсең лә
Яшен яшьнәп алды күктә.
Язгы яшеннәр шикелле,
Гомерләр дә бик тиз үтә.

Рәмиз.

Исеңдәме, Риф тугачтын
Аңа исем кушкан идек?

Рәмиз күңелендә ул көнге хатирәләр яңара. Бала котлап боларга күрше-тирәләр керә. Һәркемнең кулында бәби ашы. Баланы матур келәмгә салалар да, төрле кеше келәмнең төрле ягыннан күтәреп, үз теләкләрен әйтәләр.

Беренче күрше.

Котлы булсын, котлы булсын,
Аяк-кулы ныклы булсын.
Йөзләрендә шәфәкъ булсын,
Күңелендә шәфкать булсын.

Икенче күрше.

Бөркетләрдән канат ал,
Болыннардан аяк ал;

Арысланнан йөрәк ал,
Юлбарыстан куәт ал.

Баланың анасы.

Тургай дәртле моң бирсен,
Имән таза сын бирсен.
Кояш якты йөз бирсен,
Лачын үткен күз бирсен.

Баланың атасы Рәмиз.

Батыр булып үс, улым,
Җитмеш дәрья кич, улым!
Җитмеш юлның төенен
Акыл белән чиш, улым!

Беренче күрше.

Кулларың уңган булсын,
Күңелеңдә иман булсын!

Икенче күрше.

Иңнәреңә бәхетнең
Пар кошы кунган булсын!

Ата.

Күктә яшен булып ян!

Ана.

Җиргә тамчы булып там!

Ата.

Җаның һәрчак хөр булсын!

Ана.

Иманың нык, бер булсын!

Барысы бергә.

Бул акыллы, бул зирәк,
Үс син гөлләргә үрләп.
Сандугачлар тирбәтсен
Бишегең көйләр көйләп.
Әлли-бәлли! Әлли-бәлли!

Күрше-тирәләр таралыша. Өйдә Ата белән Ана гына кала.

Ана.

Әй, атасы, күрче улыбызны,
Бишегендә ята елмаеп.

Ата.

Елар өчен түгел, көләр өчен
Туган баладыр ул, мөгаен.

Ана.

Шулай булсын, амин, бәхете аның
Алданрак йөрсен үзеннән.

Ата.

Юллар аны алып китмәсеннәр
Тарих ялгышлары эзеннән.

Ана.

Әй, атасы, безнең улыбызның
Юлларында үсәр гөл-чәчәк.

Ата.

Кем булса да шатландырсын безне,
Шат, ирекле, азат, хөр яшәп.

Автор.

Шулай, дустым, без болай да инде
Коллык белән озак чирләдек.
Рифләр белән яңа буын тусын,
Шул коллыкны мәңге җиңәрлек.

Рәмиз.

Туды инде, туды. Безнең уллар
Юләр әмерләргә буйсынмас.
Тимер богауларны өзәр алар,
Тик үзләре сынмас, сыгылмас.

Автор.

Амин, дускай! Безнең язмышларны
Кабатламасыннар бүтәннәр.
Киләчәккә ачы сабак булып
Калсын бары безнең үткәннәр.

Ата һәм Ана.

Амин! Амин!

Пәрдә төшеп ала яки ут сүнеп яна. Автор һәм Рәмиз алгы планда.

Автор.

Сизелми дә гомер үтте,
Армиягә китә улың.
Улың дәвам итәр синең
Киселеп калган гомер юлың.

Рәмиз.

Әйе, Рифтә бар өметләр,
Калганнары күптән янды.
Риф бит нәсел агачында
Сыңар яфрак булып калды.

Автор.

Яфрак түгел, дускай, җимеш,
Ә җимештән агач үсәр.
Тагын сезнең алмагачта
Җиде алма тулып пешәр.

Рәмиз.

Амин, шулай була күрсен,

Тик шулай да эчтә шом бар.
Бәгырьләрне телә торган
Җанда таныш түгел моң бар.

Чыгып китәләр. Кыз белән Егет керә.

Кыз.

Аерылышыр көн дә җиттемени?
Аһ, сөюне соңрак аңладым.
Мин бит синең кара күзләреңә
Туйганчы да карый алмадым.
Татымадым иреннәрең тәмен,
Оялчанлык тыйды һәрвакыт.
Әй яшисе килә, әй яшисе,
Таһир-Зөһрәләрдәй яратып.

Егет.

Минем өчен сакла, бәгърем, сафлыгыңны,
Сафлыгыңны, күңелеңдәге аклыгыңны.

Кыз.

Аклыгымны һичбер вакыт каралтмамын,
Миңа булган өметеңне таратмамын.

Егет.

Минем өчен сакла бөтен ялкыныңны,
Ялкыныңны — сөю дигән алтыныңны.

Кыз.

Ялкынымны һичбер вакыт сүндермәмен,
Алтыныма ятлардан кул тидермәмен.

Егет.

Минем өчен сакла яшьлек гөлләреңне,
Гөлләреңне, ай-йолдызлы төннәреңне.

Кыз.

Гөлләремне беркемнән дә өздермәмен,
Күңелеңне үземнән һич биздермәмен.

Егет.

Минем өчен сакла якты таңнарыңны,
Хисләр белән мөлдерәмә җаннарыңны.

Кыз.

Хисләремнең тамчысын да түктермәмен,
Ятлардан күз яшьләремне сөрттермәмен.

Егет белән Кыз бер-берләренә якынаялар. Кочаклашырга дип торганда гына болар янына бер төркем яшьләр килеп керә. Кайсының кулында гитара, кайсыныкында магнитофон. Магнитофонда ямьсез, карлыккан тавышлы җырчының җыры яңгырый. Җыр әллә нинди чит телдә башкарыла. Яшьләр үзләре дә магнитофондагы музыка көенә акырышалар, бииләр. Биюләре төрлесе төрле якка иелү-бөгелүдән, көтмәгәндә бер-берләренә килеп сарылудан, төрле килешсез хәрәкәтләрдән тора. Акырыш-бакырыш шактый дәвам итә. Алар Егет белән Кызны да үз түгәрәкләренә өстериләр. Кызлар — Егетне, егетләр Кызны тарткалый. Болар карыша. Егет тегеләргә нидер әйтә, ләкин магнитофондагы тавыш аларның сүзен ишеттерми. Шактый шау-шудан соң магнитофонның тасмасы бетеп, тавыш тынып кала. Яшьләр бу га- шыйк парлардан көләргә тотыналар.

Беренчесе.

Ромео һәм Джульетта, ха-ха-ха!

Икенчесе.

Таһир-Зөһрә, хи-хи-хи!

Өченчесе.

Мәхәббәт уены, ха-ха-ха!

Дүртенчесе.

Мәхәббәт юк, секс кына бар. Шулаймы, кызлар?

Музыка белән исәрләнгән кызлар «шулай, шулай» дип кычкыралар.

Кызлар.

Кирәкми мәхәббәт. Яшәсен секс!

Егетләр.

Тилереп яшәү җиңелрәк. Әйдәгез, тилерәбез!

Кызлар.

Тилерәбез, тилерәбез!

Егетләр.

Долой чалбар!

Кызлар.

Долой күлмәк!

Егетләр.

Долой акыл!

Кызлар.

Долой мәхәббәт!

Барысы бергә.

Долой оят!

Кызлар, егетләр бер-берләренә ташланалар. Чишенеп ташлыйлар. Бер-берләренең төрле җирләрен тоталар. Кыргый бер мәхшәр башлана. Гитаралы егет идәнгә аркасы белән ятып, аякларын өскә күтәреп, ги- тарасын чиртә. Үзе җырлый.

Гитаралы егет.

Янсын, бетсен дөньясы,
Дөнья — елан оясы.
Шушы елан оясына
Килә таяк тыгасы.

Их-ма, их-ма, их-мая,
Кичә ыштаның бар иде,
Бүген ыштаның кая?

Әй еланнар, еланнар,
Бар дөньяга тулганнар.
Кысыла тыннар, өзелә җырлар,
Үрчи һаман еланнар.

Их-ма, их-ма, их-мая,

Кичә ыштаның бар иде,
Бүген ыштаның кая?

*(Сикереп тора. Башкаларга эндәшә.)*

Киттек моннан. Монда һич кызык юк.
Бу гашыйклар безгә пар түгел.
Мәхәббәт ул күптән үлгән инде,
Кабере аның кысан, тар күңел.

Икенче егет.

Бу дөньяда бары азгынлык бар,
Яшәүнең бар яме шуңарда.
Кызлар алар тере курчак кына,
Теләк булган чакта уйнарга.

Егетләр, кызлар чыгып китәләр. Гашыйк парлар гына сәхнәдә кала. Алар бераз сүзсез торалар.

Кыз.

Аңлый алмыйм. Давыл булдымы бу?
Күңелемдә кинәт шәм сүнде.
Багышлармын дигән идем бит мин
Мәхәббәткә генә бу көнне.

Пауза.

Егет.

Әзмени соң җирдә хәшәрәтләр,
Төкер, бәгърем, аңа карама.
Җырлыйк әле, күңелләрне бәйләп
Бер җыр калсын безнең арада.

Яхшылык һәм яманлыкның аның
Юлы була һаман гел бергә.
Җырлыйк әле икәү, бу җыр безне
Озатып йөрсен гомер-гомергә.

Кызның кулыннан ала да әкрен генә җыр башлый.

Ачарбыз җиде кат күкләрнең ишеген,
Эләрбез йолдызга бәхетебез бишеген.

Кыз.

Тирбәтер бишекне йолдызның җилләре,
Сибәрбез дөньяга мәхәббәт гөлләре.

Икесе бергә.

Мәхәббәт гөлләрен гашыйклар җыярлар,
Сөюгә чәчәктән һәйкәлләр куярлар.
Без мәңге биектә, йолдызда калырбыз,
Яктыбыз сүрелсә, йөрәктән алырбыз.

Җыр астында пәрдә ябыла.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Өченче күренештән соң шактый вакыт үткән. Рәмизләр өе. Өйдәгеләр кара кайгыда. Чөнки моннан күпмедер вакыт элек армиягә киткән Рәмизләрнең улы чит җирләрдә билгесез сәбәпләр аркасында һәлак булган. Бүген аның табутын кайтарырга тиешләр. Зәйнәп әби кайгысыннан түшәккә үк ауган. Рәмизнең хатыны Галиябану үз-үзен өзгәләрдәй булып ишекле-түрле йөри.

Автор.

Авыр хәсрәт бәгырьләрне
Пычак белән ала телеп:
Тимер табут белән кайтты
Армиягә киткән егет.

Язмыш диләр, язмыш диләр,
Язмышларны кемнәр яза?
Берәү өчен тормыш — бүләк,
Берәү өчен тормыш — җәза.

Рәмиз дускай, бар өметең
Улың Рифтә иде, беләм.
Әй бу дөнья! Әй бу дөнья! —
Һәр бәбкәгә өчәр тилгән.

Күтәрә дә китә алар
Эләктереп тырнагына.
Өзелә өмет, киселә гомер —
Чыда гына, чыда гына.

Рәмиз.

Башым катты, аңлый алмыйм:
Ник соң болай, ник соң болай?
Нигә җирдә гел үтереш,
Әгәр белсәң, әйтче, Ходай!

Үләр өчен генәмени
Туа кеше дөньяларга?
Кайгыларым ташка бәйләп
Атыйм нинди елгаларга?

Автор.

Кайгы кара ут, кара күмерле,
Күзләргә керә аның сөреме.
Елады ана ачынып, әрнеп,
Кайгысы чыкты йөрәктән бәреп.

Ана.

Әй балам, балам, бәгырь кисәгем,
Нинди илләрдә, ниләр эшләдең?
Йөрәккәемнең тибеше идең,
Мәхәббәтемнең җимеше идең.
Кемнәр кул сузды бердәнберемә? —
Назлап үстергән иркә гөлемә.

«Әнием» диеп ачылды телең,
Актык сүзләрең ни булды синең?
Әй балам, балам, күзем карасы —
Күзем карасы, күңелем ярасы.

Карынымда йөртеп, сиңа җан бирдем,
Тамырларыңа кайнар кан бирдем.
Сугышлар да юк, илләр дә тыныч,
Җанны түләрлек юк безнең бурыч.

Зәйнәп әби.

Кем өчен койдың кайнар каныңны?
Кем өчен бирдең газиз җаныңны?

Ана.

Ике күз бирдем, күпне күр, диеп,
Акны карадан аера бел, диеп.
Ике күзең дә йомылган инде,
Җылы тәннәрең суынган инде.
Кыяга баскан бөркетем идең,
Чикләрдән ашкан өметем идең.

Зәйнәп әби.

Бөркетебезне харап иттеләр,
Өметебезне таптап киттеләр.

Ана.

Ике кул бирдем, таза, нык куллар,
Матур дөньяны корыр дип шулар.

Зәйнәп әби.

Кем мылтык бирде ул кулларыңа?
Төзәдең аны кем улларына?

Ана.

Әй балам, балам, күзем карасы —
Күзем карасы, күңелем ярасы.

Болын түрендә шат таем идең,
Күңелем түрендә шат аем идең.
Бүреләр буды уйнак таемны,
Болытлар япты ап-ак аемны.

Әй балам, балам, йөрәк парәсе —
Күземнең яше, күңелем ярасы.
Гомер чишмәмнең агышы идең,
Җәйге төннәрнең балкышы идең.

Зәйнәп әби.

Җәйге төннәрнең сүнде балкышы,
Соңгы чишмәнең тынды агышы...

Ана.

Әй балам, балам, күзем карасы —
Күзем карасы, күңелем ярасы.

Зәйнәп әби.

Синең урынга үзем үлсәмче,
Кара гүрләргә үзем керсәмче.

Автор.

Ачтырмадылар табутны,
Саклап торды ике солдат.
Йөрде алар итек белән
Гүя йөрәкләрне таптап.

Рәмиз.

Ачыйк, зинһар, бу табутны,
Соңгы тапкыр күрик йөзен.
Әйбәт итеп юып күмик,
Гореф-гадәт шундый безнең.

Зәйнәп әби.

Чиста кием кидерербез,
Гүргә үзебез иңдерербез.

Ана.

Зинһар, күмик үзебезчә,
Ул безнең бердәнберебез.

Автор.

Юк, солдатлар ишетмәде
Эндәшкәнне иңрәп-иңрәп.
Ашыктырды алар барсын.

Солдатлар.

Кыймшаныгыз, тизрәк, тизрәк!

Автор.

Бирде алар хушлашырга
Нибарысы ике сәгать.
Алар бары әмер үти,
Аларга ни гореф-гадәт.

Рәмиз.

Әмер төшә югарыдан,
Охшап тәгәрәгән ташка.
Төшкән саен кызулый да
Килеп бәрелә безнең башка.

Автор.

Коела ташлар, ярыла башлар,
Упкын йота сөякләрен.
Ташлар белән, башлар белән
Күмелә изге ниятләрең.

Рәмиз.

Сүнә өмет, үлә хыял,
Җаннар оча җәһәннәмгә.
Хыялыңнан аердыңмы —
Бер табутка сыя бәндә.

Автор.

Күпме куллар үрелә дә
Безнең изге хыялларга —
Йөрәк белән умырып алып,
Ата упкын-кыяларга.

Рәмиз.

Тели алар сыйдырырга
Һәммәбезне бер калыпка.
Әмер булса, дөньясын да
Тыгарлар иде табутка.

Автор.

Әмер, әмер! Өйрәндек без
Уйсыз әмер үтәүләргә.
Әмер әйбәт — аударасың
Кансызлыкны бүтәннәргә.

Ә без әйбәт, без бит бары
Чит кулларда корал гына —
Үзебезнең кол икәнне
Белми йөргән коллар гына.

Гел тыңлаучан, күндәм булдык,
Үрмәләдек, түштә шудык.
Шик-шөбһәләр килсә — кудык,
Якты уйлар туса — будык.

Автор.

«Ат!» дисәләр — тотып аттык.

Рәмиз.

«Ват!» дисәләр — тотып ваттык.

Автор.

«Сыт!» дисәләр — тотып сыттык.

Рәмиз.

«Яп!» дисәләр — тотып яптык.

Автор.

«Ас!» дисәләр — тотып астык.

Рәмиз.

«Шаш!» дисәләр — котырып шаштык.

Автор.

«Тот!» дисәләр — барып тоттык.

Рәмиз.

«Ек!» дисәләр — бәреп ектык.

Автор.

Әмер булды — утка кердек,
Чит җирләрдә башлар салдык.
Баш хакына кургаш табут
Һәм кабергә ташлар алдык.

Рәмиз.

Улыбыз бит бик хөр җанлы иде,
Буйсынучы түгел әмергә.

Автор.

Әмерләргә буйсынмаган өчен
Кергәндер ул, бәлки, кабергә.
Горурларга һәрчак пуля әзер,

Акыллылар кирәк кемнәргә?
Пычрак куллар һәрчак үрелә бит
Иң матур, иң гүзәл гөлләргә.

Рәмиз.

Шушы ачы хакыйкатьне, дустым,
Аңламадык ник соң иртәрәк?
Бәреп чыккан ачу ташкыннарын
Нигә тордык гел-гел киртәләп?

Автор.

Нигә дисең, син беләсең аны —
Карышырга чөнки курыктык.
Кешеләрнең өнен алыр өчен
Күп кирәкми — җитә бер мылтык.

Рәмиз.

Власть кулында шул һәрчак мылтык,
Яки кылыч, яки нык элмәк.

Автор.

Мылтык, элмәк, кылыч һәрвакытта
Йөри үзенә корбаннар эзләп.
Шуңа һаман куркып яшәдек без,
Үз-үзебездән хәтта курыктык.
Гел калтырап яши торгач, тәмам
Кеше икәнлекне оныттык.

Рәмиз.

Егылганны күрсәк, кулыбыз сузмый,
Читтән-читтән генә юл тоттык:
Ярдәм итсәк, безне «өстәгеләр»
Ошатмаслар диеп куркыттык.

Автор.

Дус-иш белән кунак йөрешмәдек,
Тамыр җәйде эчтә мокытлык:
Кунакларга йөрсәк, әшнәлектә
Гаепләрләр диеп курыктык.

Рәмиз.

Туган телдә — ана телебездә
Сөйләшергә хәтта курыктык.
Милли хисне күңелләребездән
Чүплекләргә чыгарып ыргыттык.

Автор.

Иелеп йөрдек, бездән өстәгеләр
Булган өчен эттән тәбәнәк.
Торып бассак, яратмаслар диеп,
Алларына килдек мәрәләп.

Рәмиз.

Югалтканны табу авыр,
Күп нәрсәне югалттык:
Асыл сыйфатларыбызны
Чүплеккә илтеп аттык.

Автор.

Әйтегез, әгәр белсәгез,
Әйтсәгез — сезгә рәхмәт:
Кайларда йөри каңгырап
Җаннан куылган шәфкать?

Рәмиз.

Чырайлар шундый караңгы,
Елмаюны югалттык.
Кайсы елгаларда акты
Йөздән юылган шатлык?

Автор.

Әйтегез, кайда югалды
Инсафлы гореф-гадәт?
Кемнәр почмагында үлде
Өйдән куылган әдәп?

Рәмиз.

Тәннәр керле, җаннар керле,
Пычракка тәмам баттык.
Нинди юллар тузанында
Күмелеп калды пакьлек?

Автор.

Көн тудымы, күңелләрдә
Сораулар тора артып:
Ник бу җитмәүчән дөньяда
Бердәнбер вөҗдан артык,
Бердәнбер намус артык?

Пәрдә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хәерче керә.

Хәерче.

Кемдер үлгән, дип әйткәннәр иде,
Барыйм әле тизрәк зиратка.
Мондый чакта җаннар йомшаралар,
Юмартлана саран ир-ат та.

*(Кесәсендәге янчыкларын карап куя.)*

Бәлки әле, янчыкларым тулыр,
Кайгы бирсен Ходай кешегә.
Күз яше бар җирдә чылтыр-чылтыр
Акча ява безнең ишегә.

Бай керә.

Бай.

Кара козгын, тагын ул бередә.
Кайда кара кайгы — шунда ул.
Мин таныдым сине. Син бит миңа
Ялган яла яккан комсомол.
Озаттырдың мине Себергә син,
Хуҗа булыр өчен йортыма.
Йортың тузган, үзең әверелгәнсең
Җирнең хәшәрәт бер кортына.

Хәерче ыржаеп көлә.

Хәерче.

Олактырдым, әйе, олактырдым,
Мин бүген дә шуңа куанам.
Артык көчле, артык эшчән идең,
Көчлеләрдән мин гел үч алам.

Бай.

Чагар өчен телең генә бар шул,
Эшләр өчен эшчән кул кирәк.
Син байлыкны җыймак булган идең,
Кеше кайгысыннан мул көрәп.

Тик булмады. Бер хәерче булдың,
Шулай идең чөнки тумыштан.
Үлгәндә дә кулың сузган килеш
Китеп барачаксың тормыштан.

Ә мин менә шушы куллар белән
Гел эшләдем, байлык арттырдым.
Себер сазлыкларын бакча ясап,
Аланнарда чәчәк аттырдым.

Хәерче.

Алай булгач, нигә монда кайттың,
Ни телисең моннан табарга?

Бай.

Ә син мине барыбер аңламассың,
Синең акылың сыек аңарга.

Хәерче.

Акылың сыек, имеш! Акыл миндә
Барыгызның башына җитәрлек.
Заман гына ялгыш юлдан китте,
Тормыш кына китте үзгәреп.

Без барыбер бер калкырбыз әле,
Әйттерербез нишләп йөргәнең.
Бик шатланма, әле төрмәләрдә
Көтеп тора тимер йөгәнең.

Бай.

Ник син усал, нигә үчле болай,
Тудыңмы син әллә Иблистән?

Үз дөньясын һәркем үзе кора —
Ә син куркып йөрдең һәр эштән.

Хәерче.

Әйе, Иблис, сине эзәрлеклим.
Син бай һаман, ә мин хәерче.
Бу дөньяны тигезләргә диеп
Бар сәләтем куйдым, бар көчне.

Бай.

Ялкау белән эшчән тигез булмый,
Куркак белән батыр шулай ук.
Син урманны кара, урманда да
Тигез генә үскән агач юк.

Хәерче.

Килешалмыйм, юк, юк, синең белән,
Тигез булсын тавы, кыясы.
Хәерчеләр белән тулса тулсын,
Тигез генә булсын дөньясы.

Чыгып китә.
Бай авыр көрсенеп куя.

Бай.

Мескен бәндә һаман үзгәрмәгән,
Ачу йөртә һаман эчендә.
Елан елан инде, нишлисең бит,
Ә бит үзе кеше төсендә.
Ә мин монда байлык эзләп түгел,
Урын эзләп кайттым зиратта.
Тәнем минем күмелергә тиеш
Туган җиргә, туган туфракка.

Чыгып китә.

Пәрдә.

**АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Автор.

Кайберәүләрнең ялгышын
Бары тик бер иң күтәрә.
Кайберәүләрнең ялгышын
Күп миллионлы ил күтәрә.

Башка килә шундый уйлар,
Аңлый алмыйм мин бу хәлне:
Ник соң кайгы ныграк кыйный
Олы җанлы кешеләрне?

Акыллыларның башына
Төшә һәрчак авыр күсәк.
Телләреңә төер чыгар,

Еламыйм дип тешләп-тешләп.

Рәмиз.

Ир йөрәге чыдам була,
Түзә, диләр, барчасына.
Тик телсезләр дә кычкыра,
Китереп бассаң ярасына.

Автор.

Авырттырып, ачыттырып
Таптадылар Рәмиз җанын.
Күмдерделәр улы Рифне,
Ачтырмыйча табутларын.

Кемнең килмәс газизенә
Соңгы тапкыр күз саласы?
Кайгыларның иң ачысын
Сыйдыра тик күз карасы.

Рәмиз.

Юк, мин моңа түзә алмыйм,
Тыя алмас мине чурт та.
Ачам, карыйм. Бәлки әле,
Улым түгелдер табутта.

Минем улым үлмәгәндер,
Ул бит безнең соңгы тамыр.
Ул да үлсә, нәселебез
Мәңгелеккә корып калыр.

Юк, бүгеннән мин кол түгел,
Буйсынудан туктыйм, җитәр.
Баш күтәрәм дөньясына,
Башым Себер китсә китәр.

Автор.

Төн уртасы. Зират тып-тын,
Әрвахлар да йоклый күптән.
Рәмизнең ни эшләгәнен
Күзәтә тик фонарь читтән.

Җәйге төннәр тик бер тотам,
Ашыга ул: тизрәк, тизрәк.
Нәрсә анда дөп-дөп итә? —
Әллә җил ул, әллә йөрәк.

Кара кабер туфрагына
Шыбыр-шыбыр тирләр тама.
Якынлаша бара ата
Улына таба, улына таба.

Менә җитә, менә җитә,
Ярты колач ара кала.
Сүнәм-сүнәм дигән кебек,
Сүрән генә фонарь яна.

Шул вакыт ерактан кыз җыры ишетелә.

Кыз.

Җиде кат күкләрнең ябылды ишеге.
Тибрәнми йолдызда бәхетебез бишеге.
Аттылар, аттылар мәхәббәт кошына,
Кан тама болыттан керфекләр очына.

Рәмиз, казуыннан туктап, җырны тыңлый. Җыр аның бәгырен тел- гәли. Җыр якыная.

Рәмиз.

Тукта, тукта, әй, кызыкай,
Йөрәгемне телгәләмә!
Болай да ул, урын тапмый,
Күкрәгемдә бәргәләнә.

Кызның җыры тагы да якыная.

Кыз.

Яралы җанымны юардай сулар юк,
Алга да, артка да барырга юллар юк.
Син — Таһир, мин — Зөһрә, яшәү юк аерым,
Мин барам яныңа, мин барам, бәгърем.

Кыз хыялында Егет пәйда була.

Кыз.

Сине үлгән дигәннәр иде бит,
Син исән икән бит, син исән!

Егет.

Мин бит — Сөю, мин — Мәхәббәт, бәгърем,
Нәрсә калыр җирдә, мин үлсәм.

Кыз.

Без тизрәк кавышырга тиеш,
Шунсыз җанга тынгы тапмамын.

Егет.

Мин бит, бәгърем, һәр көн синең белән,
Мин һәр таңда сиңа кайтамын.

Кыз.

Без Сак белән Соклар кебек булдык.
Аларга бит юктыр кавышу.

Егет.

Кавышырбыз әле, кавышырбыз,
Сак-Соклар да куя ялгышып.

Егет юкка чыга.

Кыз.

Җирдә, суда, бәлки, серле күктә
Безнең җаннар барыбер берләшер.
Синсез яшәү миңа яшәү түгел,
Кайдан эзлим сине, эндәш бер!

Егеттән аваз килә.

Егет.

Мин әлегә сине чакыра алмыйм,
Җаным әле урын тапмаган.
Күккә менсәм — аның ишеге ябык,
Җиргә карыйм — сөрем каплаган.

Кыз җырлый.

Кыз.

Яралы җанымны юарлык сулар юк,
Алга да, артка да барырлык юллар юк.
Син — Таһир, мин — Зөһрә, яшәү юк аерым,
Мин барам яныңа, мин барам, бәгърем.

Кызның тавышы ераклаша.

Автор.

Бу җыр Рәмизнең йөрәген
Алды шундый телеп-телеп.
Белештермәде ул үзен —
Әллә тере, әллә үлек.

Ачты шунда табутны ул,
Булмый хәтта моны сөйләп.
Фонарь уты эчкә үтте
Һәм... ярылды шунда йөрәк.

Ата һәм ул — ике корбан,
Күз яшедәй ачы язмыш. —
Кабынды да сүнде кинәт,
Кеше гомере тик бер балкыш.

Зәйнәп әби.

Сагышларым бирдем җилләргә,
Алып кит, дип, ерак илләргә.
Канатлары җилнең сыгылды.
Сагышларым җиргә,
Таралышып җилдә,
Сары чәчәк булып коелды.

Сагышларым салдым суларга,
Адашсын дип ерак юлларда, —
Елга туктап калды ярсудан.
Сагышларым бар да
Утырып калды ярда,
Ташулардан калган боз сыман.

Сагышларым аттым яшенгә,
Яндыр, дидем, җиргә төшермә.
Яшен сүнде күкләр йөзендә, —
Синнән башка беркем
Күтәралмый, диеп,
Сагышларым кайтты үземә.

Автор.

Зәйнәп әби, нишләп йөрисең,
Су буйларын инде томан сарган.

Зәйнәп әби.

Куе томаннарны ера-ера
Үлememне эзләп йөрим, балам.

Эзлим, эзлим, ә ул качып йөри,
Качу ансаттыр шул карт кешедән.
Җылынырга соңгы учак сүнде,
Бик өшим бит, балам, бик күшегәм.

Йөрәгем дә күптән үлде инде,
Йөрәк урынында кара күмер.
Иң зур җәза икән бу дөньяда
Балаларың үлгәч калган гомер.

Автор.

Карыймын күккә дә, карыймын җиргә дә,
Ишетәм нindидер тавышлар.
Кайларда языла икән соң
Безнең бу каргышлы язмышлар?

*(Күккә күтәрелеп карый.)*

Ирләрен сугышта югалткан
Толларның күзләре шикелле,
Төн буе яналар йолдызлар,
Үзләре яшьле һәм өметле.

Ана.

Улларын чит җирдә югалткан
Аналар йөздәй сары ай,
Карап шул йолдызлар ягына:
«Бирешмә, түз инде», — ди бугай.

Рәмиз.

Күп яулар кичергән җиремнең
Йөрәге шикелле сискәнеп,
Дерт итеп кабына яшеннәр,
Уяу бул, дигән күк, искәреп.

Зәйнәп әби.

Әй, галәм, йолдызлар, якты ай,
Мине дә яныгызга алыгыз.
Улларым, кызларым шунда бит —
Кушылсын күкләрдә җаныбыз.

Автор.

Әҗәл килде Зәйнәп әбигә дә
Җил-давылсыз көнне тын гына.
Нәсел бетте. Искә төшерергә
Күңелләрдә калды моң гына.

Шул сагыш-моң килеп сарыла да
Каеннарның яшел иңенә,
Әкрен генә кыйсса сөйли миңа
Кушылып талгын шәфәкъ җиленә.

Сорый җилләр Зәйнәп әби булып:

Зәйнәп әби.

Бу дөньялар кая бара соң?
Киләчәктә, алгы көннәрендә
Нәрсә көтә адәм баласын?

Нәрсә көтә? Җавап сорыйм сездән,
Барыр юлларыгыз еракмы?
Йә, әйтегез, гавам язмышының
Киләчәге әллә зиратмы?

Автор.

Җавап эзлим мин дә бу сорауга,
Күңел төпкелләрен актарам.
Үз-үземне юатмакчы булам,
Ә күңелдә тынгы юк һаман.

Дөнья бит ул тик бер бакча гына,
Кеше анда бары бер алма.
Алмаларның бөтенесен дә бит
Өзеп бармый ласа бер Алла.

Яфракларын җил-давыллар коя,
Көтеп тормый алар көзләрне.
Һаман безгә мылтык көпшәсеннән
Карый әле заман күзләре.

Әле һаман төрле биеклектән
Явып тора күпме әмерләр.
Юләр әмерләргә шаһит булып
Зиратларда калка каберләр.

Яңгыр булып җиргә күз-яшь ява,
Ал таңнарда тама ал каннар.
Афәтләрдән җирне саклар өчен
Йөрәкләрдән коела калканнар.

**СОҢГЫ КҮРЕНЕШ**

Артистларның барысы да сәхнәгә чыгып баса.

Автор.

Мин зираттан кайтам. Чү, нәрсә бу?
Ишетәм соң нинди өннәрне?
Әллә инде шулай җилләр елый,
Үксеп утыра әллә гөлләрме?

Сискәндерде җилне нинди тавыш,
Әллә юкса берәр баламы? —
Каеннарның шаулавына кушылып,
Киләчәккә аваз саламы?

Ишетелә авыл ягыннанмы,
Йолдызлардан әллә килгәнме?
Әллә инде Зәйнәп әби оныгы
Феникстай туган көлдәнме?

Ишетәм аны, ишетәм. Бу тавышны
Торган саен ныграк ишетәм.
«Кешелекнең киләчәге мин!» — дип

Аваз сала бала бишектән.

Зәйнәп әби.

Тик кем булыр икән бу бала,
Кай якларга бара замана?

Вәгыйз.

Без сугыштык Ватан, Ватан диеп,
Йә, әйтегез, кая ул Ватан?
Мин һәр төнне Ватан өчен үлгән
Туганнарны сагынып бер кайтам.

Рәмиз.

Ул Ватанның соңгы байракларын
Декабрьнең җиле аударды.
Күлмәк тегә яшьләр ул байрактан,
Байрагы да илнең калмады.

Риф.

Бетсен әйдә, бетсен андый Ватан,
Империя бетсен кырылып.
Яңа буын туар хәрабәдән
Яңа матур дөнья корырлык.

Без ирекле, матур дөнья өчен
Шәһит киттек, бирдек җаннарны.
Шул җаннардан очкын алып, хәзер
Кабызасы калды таңнарны.

Зәйнәп әби кызы Гөлсем.

Авыр, авыр, хәзергесе авыр,
Авыр, авыр, яшәү бик авыр.
Соңгы өметләрне базарларда
Кем сатар да безнең, кем алыр?

Вәгыйз.

Авыр, авыр, туры калу авыр,
Җанны саклап калу бик авыр.
Җаннарны да базарларда сатсак,
Киләчәктә бездән ни калыр?

Автор.

Халкым, сиңа нинди сыйфатлар хас,
Сабырлыкмы, әллә ярсумы?
Ярсу булсаң, ярсыр вакыт җитте,
Таләп итә һәрбер җан шуны.

Рәмиз.

Халкым, сиңа нинди сыйфатлар хас,
Түбәнлекме, әллә зурлыкмы?
Зур икәнсең, әйдә, тураеп бас,
Алып ташла иңнән хурлыкны.

Гөлсем.

Халкым, сиңа нинди сыйфатлар хас,

Турылыкмы, әллә ялганмы?
Туры булсаң, турылыгың белән
Турайтырга кирәк заманны.

Риф.

Халкым, сиңа нинди сыйфатлар хас,
Мескенлекме, әллә хөрлекме?
Хөр икәнсең, дөнья белән сөйләш,
Баштан салмый гына бүрекне.

Кыз.

Дөньяга без яшәр өчен диеп,
Сөяр өчен диеп яралдык.
Сөю тәмен ләкин татымыйча,
Кайгылардан көйдек, каралдык.

Зәйнәп әби.

Кемнәр уйный безнең язмыш белән,
Кая бара соң бу замана?
Дөньялар бит һаман үзгәрмиләр,
Тик ялганнар гына яңара.

Автор.

Без мәңгелек, диеп йөргәннәргә
Тик шул гына безнең сүзебез:
Хакыйкатьне ныграк аңлар өчен
Зиратларга ешрак килегез.

Озак еллар кирәк кешеләргә
Аерыр өчен акны карадан.
Йә, кайсыбыз әйтә ала, тарих
Кабатланмас диеп яңадан?

Риф.

Бу ялгышлар кабатланмас өчен,
Даулау кирәк безгә ирекне.
Беркем безгә тәлинкәгә салып
Китереп бирмәс азат, хөрлекне.

Тормыш — көрәш.
Һәрчак шулай булган.
Тормыш — ургып аккан бер елга.
Үткәннәрдән сабак ала-ала
Киләчәккә бара бу дөнья.

Пәрдә.

*1995*

# КЫЗЛАР КҮҢЕЛЕ — ТИРӘН СЕР

*(Ике пәрдәле лирик драма)*

**КАТНАШАЛАР:**

Гөлназ — комсорг.
Мансур.
Зөфәр.
Флюра.
Рәҗибә.
Фирая.
Кирам.
Тагын берничә егет һәм кыз. Вакыйга безнең көннәрдә бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Су буе. Яшьләр чыгарылыш кичәсеннән соң таң каршыларга җыелган. Музыка, җыр, мәзәк сүзләр яңгырый. Яшьләр җырлап вальс әйләнәләр.

Күңелләрдә безнең ак хыял,
Ашкындырып тора гел алга.
Тапланмаслык булсын гомергә,
Лаек юллар сайлыйк хыялга.

Ак хыяллар ап-ак канатлы,
Күтәрсен ул гел-гел югары.
Кошлар юлы белән янәшә
Үтсен безнең яшьлек юллары.

Кайдадыр әтәч кычкырган тавыш ишетелә.

Зөфәр. Таң ата, таң!

Барсының да игътибары таң яктысы төшкән якка юнәлә. Сәхнәгә төшкән ут көлтәсе һаман саен зурая бара. Бераздан су буенда көяз өянкеләр, ерактарак таулар күренә башлый.

Мансур. Менә ул безнең өлгереп җиткәч, ягъни мәсәлән, кулга аттестат алгач бергә каршылаган тәүге таңыбыз!

Гөлназ. Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата...

Флюра. Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата...

Кирам. Бер-бер артлы юк булып, күкләрдә йолдызлар сүнә...

Фирая. Таң җиле куйды исеп, яфраклар аз-аз селкенә...

Рәҗибә. Пәрдәдән чыкты, ачылды ямь-яшел кыр һәм япан...

Зөфәр. Китте инде кап-кара каплап ята торган чапан...

Гөлназ. Каршыларга иң садә чак, иң матур чак җәйге таң!

Зөфәр. Җәйге таңга дан!

Барсы бергә. Дан, дан, дан!

Сәхнә тәмам яктыра. Агачларда сирәк-мирәк кошлар сайрашканы ишетелә башлый. Яктыра төшкәч, тирә-юньдә табигать тагын да мәһабәт булып күренә.

Зөфәр. Дуслар, ә, дуслар! Укулар беткәч, аттестат эләккәч, үзебезнең шушы яраткан урыныбызда баш белән йөрермен дигән идем, сүземне үтим әле. *(Аякларын өскә күтәреп кулларында йөри.)*

Гөлназ. Син бит баш белән түгел, ә кул белән йөрисең, алай сүз биргәч, әйдә баш белән йөре.

Зөфәр башында гына тормакчы була, ләкин бик тиз авып төшә. Иптәш- ләре аңардан көләләр.

Кирам. Безнең авылда баш белән йөри белүче Имам абзый гына инде. Кибетләрдә теге зәхмәт беткәннән соң ул да аяк белән йөрүгә күчте.

Мансур. Ә мин, укулар беткәч, монда килеп бер җырлармын дигән идем.

Биек тауның башларыннан
Йөзеп бара пароход.
Әгәр, җаныем, бик сагынсаң,
Аягыңны суга тык.

Яшьләр шаулашып, көлешеп алалар.

Зөфәр. Ә син, Гөлназ, укулар беткәч нишләмәкче идең?

Кирам *(шаярып).* Улмы? Ул менә бу талларга лекция укып китмәкче булгандыр. Политграмотага өйрәтеп.

Гөлназ. Молодец! Менә ичмасам әйттең! Иске сөялгә бастың.

Көлешеп алалар.

Гөлназ *(җитдиләнеп).* Изге урын бу, дуслар. Менә бу талларны, безнең авылда урта мәктәп ачылгач, беренче чыгарылыш яшьләре утырткан. Алар ике класс, ягъни төгәл илле кеше булган, һәм алар илле елдан соң шушында бергәләшеп таң каршыларга сүз куешканнар. Әмма ләкин...

Кирам. Әйе, безнең бабаларыбыз шушыннан, таң каршылаган җирдән, туп-туры фронтка киткәннәр. Һәм күпләр әйләнеп кайта алмаган.

Фирая. Тол хатыннар ирләрен сагынганда шушында килеп күңелләрен бушатканнар.

Зөфәр. Табигать сүзсез генә һәркемне тыңлаган. Җилләре белән башларыннан сыйпап юаткан. Кешеләр шатланганда шатланган, кешеләр кайгырганда кайгырган.

Флюра. Әйе, туган җирләр — безнең хәтеребез ул. Анда бөтенесе язылып бара.

Кирам. Кинәт кенә җитдиләнеп киттек әле.

Флюра. Өлгереп киләбез, җитлегеп киләбез.

Флюра. Ә мин язмышларны яза башлаганчы шушы яшел чирәмдә тәгәрәп, өстән унъеллык мәктәп тузанын кагыйм әле. *(Чирәмгә ташлана.)*

Зөфәр. Күлмәгегезне пычратмагыз, мадемуазель. *(Пинжәген салып Флюрага бирә.)*

Рәҗибә. Кара-кара, безнең малайларга да егетлек керә башлаган түгелме?

Мансур. Ә беләсезме, малайлар кайчан егеткә әйләнә башлый?

Тавышлар. Йә, йә, әйтеп кара.

Мансур. Безгә кызларның күзе төшә башлагач.

Фирая. Алай бик акыллы булгач әйтегез: кызлар кайчан балалыктан чыга?

Зөфәр. Без сезнең чәчегездән тартудан туктаган көннән соң сез шыксыз үрдәк бәбкәсеннән сылу аккошка әверелә башлаячаксыз.

Гөлназ. Алайса, бүгеннән сезгә чәчләрне тарттыру бетте.

Рәҗибә. Үрдәк бәбкәсе булып йөрүләр туйдырды, аккошка әверелер чак җитте, шулаймы, кызлар?

Тавышлар. Шулай, шулай.

Фирая. Аккошка әвереләбез, аккошка! *(Кулларын салмак кына хәрәкәтләндереп, эченнән ниндидер көй көйләп, вальс әйләнә башлый.)* Әйдәгез, кызлар, үрдәк бәбкәсе булып су буенда күп чупырдадык, аккошка әверелеп югарыга күтәрелик.

Яшьләр вальс әйләнә. Бию җыр белән бергә башкарыла.

Хыялларга итмик хыянәт,
Ак хыяллар — яшьлек юлдашы.
Яктылыгы белән саклансын
Гомер таңы — безнең юл башы.

Күңелләрдә безнең ак хыял,
Ашкындырып тора гел алга.
Кирәк күпме көч һәм түземлек
Тугры калыр өчен хыялга.

Пәрдә.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Шул ук су буе. Пәрдә ачылганда беркем дә юк. Йөгерә-йөгерә Мансур керә.

Мансур. Уф, чаба-чаба чәчләремә ут капты. *(Ике кулы белән чәчен артка сыпыра, кесәсеннән көзге чыгарып карый.)* Беркем дә килмәгән икән әле, ә мин ашыккан булам. Гөлназ әллә кайчан килгәндер инде дим. Килгән ди менә. Бик сине көтеп тора ди. *(Көрсенеп.)* Их, шушындый заманда да типсәң тимер өзәрдәй булып үсә алма инде. Зөфәрнең әбисе әйтмешли, апельсин суы суырып та. *(Як-ягына карана.)* Әһә, Гөлназ килә. Качыйм әле. *(Тал арасына кереп китә.)*

Гөлназ керә. Кулында китап.

Гөлназ *(сәгатенә карый).* Сигезгә җыелырга дип әйттем бит инде. Берсе дә юк. Кара инде, хәтта Мансур да килмәгән. Әллә соң сәгатем йөрмиме? *(Колагына куеп тыңлап карый.)* Йөри, келтерәп чаба. *(Кулындагы китабын ача, китап эченнән бер кәгазь төшә.)* Бәрәкәт, бу нәрсә? *(Кәгазьне укый.)* «Гөлназ… Гөлназ...» Тагын шул Мансур эше инде бу. Бер бит кәгазьне Гөлназ дип язып тутырган. *(Записканы күкрәгенә яшерә дә хыялга бирелеп үз-үзенә сөйләнә.)* Их, мин дә малай кеше булып туган булсам. Үзем яраткан кызга запискалар язар идем. Ә кемгә язар идем икән? Мансургамы? Тукта, тукта, мин дә, Мансур да малай кеше булгач, записка язышалармыни? Мансур болай әйбәт малай инде. Шулай да бер сыныйсы иде үзен. Мин утка кер дисәм утка, суга кер дисәм суга төшәр иде микән? *(Шул вакыт чулт итеп нәрсәнеңдер суга төшкәне ишетелә. Гөлназ сискәнеп китә.)* Әллә берәрсе тыңлап торган инде. Әй, кем бар анда?

Мансур керә. Чалбары юеш.

Гөлназ. Бәрәкәт, Мансур! Нишләп болай лычма булдың? Чалбарың белән балык сөздеңме әллә?

Мансур. Гөлназ... мин... ни... Тал...

Гөлназ *(көлеп).* Син тал?

Мансур. Гөлназ, мин ни... ялгыш ярдан тәгәрәдем.

Гөлназ *(хафаланып).* Берәр җиреңне авырттырмадыңмы?

Мансур *(кул селтәп).* Юк ла. Юешләндем генә.

Гөлназ. Тал арасында нишли идең соң анда?

Мансур. Сандугач сайравын тыңладым.

Гөлназ. Сандугач? Мин бернинди дә сандугач тавышын ишетмәдем.

Мансур. Мин генә ишетә торган сандугач ул, Гөлназ. Аның сайравын колак белән түгел, йөрәк белән генә ишетеп була.

Гөлназ. Аңламыйм мин сине, Мансур.

Мансур. Әй лә, сары сандугачны койрыгыннан эләктерим дип үрелгән идем, егылдым да төштем.

Гөлназ. Үрелмиләр аны тал башындагы сандугачларга.

Мансур. Бигрәк матур шул ул, үрелмичә түзәрлек түгел.

Гөлназ. Карале, Мансур, бер уйлап карасаң, кеше бик кыргый, әйеме?

Мансур. Нигә, Гөлназ?

Гөлназ. Матур чәчәк күрсә, тизрәк йолкып алырга тырыша, матур сандугачны койрыгыннан эләктермәкче була. Бәлки, ул сандугачның яки чәчәкнең күбрәк кешене сокландырасы киләдер.

Мансур *(Гөлназга карап күрсенә).* Шулайдыр да бит. Минем ул чәчәкне беркемгә дә бирәсем килми шул. Мәңге-мәңге минеке генә булсын иде, дим.

Гөлназ *(оялып).* Әллә ниләр сөйлисең син, Мансур. Сүзләрең серле.

Мансур. Бер хикмәтле төш күрдем мин, Гөлназ. Имеш, күктә барлык төсләре белән балкып салават күпере калыккан. Ул күпернең бер башы сезнең ишегалдына, икенче башы безнең ишегалдына төшкән.

Гөлназ. Син бүген әллә нишләгәнсең, Мансур.

Мансур. Бүген минем малайлыктан чыгып егетлек капкасын шакый торган көнемдер, бәлки. *(Гөлназга якынрак килә.)* Минем сиңа бик күп нәрсәләр сөйлисем килә, Гөлназ.

Гөлназ. Сөйлә, Мансур.

Мансур. Ә-ә, юк, көне буе сине тыңлыйсым килә. Әнә теге сандугачны тыңлаган кебек.

Гөлназ *(бармак янап).* Кара аны, койрыгыннан эләктерим дип тагын суга чумма, егет.

Мансур. Суга гына түгел, упкыннарга чумарга риза.

Гөлназ. Чум алайса.

Мансур. Син кушсаң, һәрвакыт әзер.

Йөгереп чыгып китә. Чулт иткән тавыш ишетелә.

Гөлназ *(хәвефләнеп).* Әллә чынлап чумды инде. Әй юләр, юләр. *(Ярга табарак барып кычкыра.)* Мансур, чык, юләрләнмә. Салкын тидерерсең.

Мансурның суда чупылдаганы ишетелеп куя.

Гөлназ *(Мансур чупылдаган якка карап).* Кара аны, мин күз ачып йомганчы каршымда басып тормасаң, үзеңә үпкәлә. *(Шатланып җырлый.)*

Мин бәхетле, шундый бәхетле,
Сөйлим моны зәңгәр күкләргә.
Ак бәхеткә илтер юлларны
Үтәргә дә әле үтәргә.

Мин бәхетле, шундый бәхетле,
Сөйлим моны айлы кичләргә.
Көн-төн аккан бәхет чишмәсен
Эчәргә дә әле эчәргә.

Гөлназ хискә бирелеп җырлап йөргәндә, куаклар арасында Мансур күренә.

Мансур.Гөлназ!

Гөлназ. Абау, Мансур, син лычма бит. Бар, тизрәк киемнәреңне сыгып ки. Әйдә, минем өчен суга сикергәнсең икән инде, үзем сыгышырмын.

Мансур куаклар арасында югала. Аның артыннан Гөлназ да чыгып китә. Яшьләр җыры ишетелә башлый.

Билгесез әле безнең киләчәк,
Сибелмәс, бәлки, юлларга чәчәк.
Авыр булса да уфтанмабыз без,
Максатка җитми тукталмабыз без.

Сайларбыз юлның хыял кушканын,
Ерак-ерагын, күккә ашканын.
Чакыра безне эшлисе эшләр,
Күзләрдә өмет, йөрәктә хисләр.

Яшьләр җырлый-җырлый сәхнәгә керәләр. Флюраның кулында гармун. Башкалар җырдан туктагач, ул тагын бер аккорд биреп ала да, көйнең ахырын уйнаганнан соң, гармунын җиргә куя.

Рәҗибә. Ашыгып килгәнбез. Гөлназыбызның эзе дә юк.

Флюра *(гармун өстенә утыра).* Килер, безнең комсорг алай сүзендә тормый торган кеше түгел.

Зөфәр. Ә шулай да беләсе иде, Гөлназ безне нәрсәгә чакырды икән?

Рәҗибә. Күп белсәң, тиз картаерсың.

Зөфәр. Ә минем бер генә көнгә булса да картаеп карыйсым килә иде, иптәшләр-товарищлар.

Рәҗибә. Нәрсәгә бик картаясың килә әле алай?

Зөфәр. Менә сезнең іше башында җил уйнаган бала-чагаларның колагын борып акылга утыртырга.

Рәҗибә. Колак борганга гына акыл керсә, безнең кәҗә иң акыллы җан иясе булыр иде. Минем энем мәктәптән икеле алып кайткан саен кәҗәнең колагын бора.

Көлешәләр. Шул вакыт таллар арасыннан Гөлназ белән Мансур чыгалар. Мансур чалбарын сыпыргалый.

Зөфәр. Менә комсоргыбыз да килеп җитте.

Рәҗибә. Бәрәч, Мансур, нишләдең?

Зөфәр. Мәхәббәттән кабынып китмәсен өчен Гөлназ аның өстенә бераз су бөркегән бит, күрмисезмени?

Кирам. Рәхәт кешеләрнең, үзләренең личный пожарниклары бар.

Көлешеп алалар.

Мансур. Тыңлама шуларны, Гөлназ.

Зөфәр *(Мансурга күз кысып).* Әйе, Мансурдан кала бүтән берәүне дә тыңлама син.

Мансур. Кыланмасана. Нихәтле клоунлансаң да синнән барыбер Юрий Никулин чыкмас.

Зөфәр. Ә беләсезме миннән кем чыгар?

Тавышлар. Кем?

Зөфәр *(уйланган булып).* Миннән Зөфәр Фәттахов чыгар.

Көлешәләр.

Гөлназ. Ярый, көлештек, булды.

Зөфәр. Инде елаша башлыйбызмы?

Гөлназ. Башта мине тыңлап карагыз әле.

Зөфәр. Сине тыңлаган өчен Мансур колак төбенә менеп төшмәсме икән соң?

Гөлназ. Җитдирәк булыгыз әле, егетләр, мин сезне җитди сүз сөйләшергә чакырдым.

Тавышлар. Давай, әйтеп җибәр алайса.

Гөлназ *(түмгәк өстенәрәк басып).* Бу турыда, билгеле, сез үзегез дә уйлангансыздыр...

Фирая *(сумкасыннан блокнот чыгарып).* Протокол язаргамы?

Кирам. Яз, яз, бер сүзне дә әрәм итмә.

Зөфәр. Безнең Фирая берәр егет белән очрашуга барса да, блокнотын калдырмас. Егете сине яратам дисә, блокнотына язып куяр.

Фирая *(исе китмичә).* Ә нигә? Язармын шул. Яратам сүзен көн дә әйтмиләр.

Кирам *(Зөфәргә).* Менә чәпәдеме авызыңа? Фирая белән чамалап сөйләшмәсәң, шулай итәр ул. Әйеме, Фирая? *(Фираяның чәченнән тартып куя. Фирая аңа сумкасы белән кундыра.)* Ә, бетте-бетте, ул чорны үттек бит инде без.

Гөлназ *(түземсезләнеп).* Туктагыз инде, сүз беткәч шаярырсыз.

Зөфәр. Тыңлыйбыз, Гөлназ апасы, сөйлә.

Гөлназ. Сөйлә дип... Монда әллә нинди сүз юк та инде. Менә унынчы классны тәмамладык. Кайсыбыз кая китәргә җыена икән? Шуны беләсе иде.

Рәҗибә. Күңелдәгеләрне чишәргә дисең инде алайса.

Гөлназ. Әйе. Тик миндә бер идея бар иде. Бәлки, башта мине тыңлап карарсыз.

Рәҗибә. Синдә «идея»ләр күптер инде ул.

Фирая. Рәҗибә, син эшнең нәрсәдә икәнен белмәс борын кешене бүлмә. Йә, әйт, комсорг. Синең баш йомры.

Гөлназ. Классны таркатмыйча механизаторлар курсына барсак дим. Укып чыккач, малайлар — бер бригада, кызлар бер бригада булып эшләр идек.

Беразга барсы да тын торалар. Әкренләп тавыш куба. Шаулашалар.

Фирая *(блокнотына яза).* Шәп идея бу, комсорг. Молодец! Тарих өчен мин бу сүзләрне язып куйыйм әле.

Зөфәр. Кызлар тракторчылыкка укырга китсә, без сыер саварга китәрбез, егетләр. Шулаймы?

Гөлназ. Көлмә әле син, Зөфәр.

Зөфәр. Көлмим мин. Чынлап та бит хәзер хатын-кызның күбесе ир-ат эшенә тартыла. Аларга син трактор бир, машина бир. Начальник ит. Нилектән бу, ә? Йә, кайсыгыз миңа җавап бирә ала?

Гөлназ. Мин җавап биреп карыйммы соң?

Зөфәр. Әйдәле, иптәш комсорг.

Гөлназ. Минемчә, хатын-кыз гомер-гомергә туган җиренә, үскән нигезенә тугрырак булган. Ирләр авылларын ташлап киткәндә дә хатын-кыз калган. Йөкнең авырына җигелсә җигелгән, әмма түзгән. Нигезен таркатмаган. Хатын-кызның тракторларга, машиналарга тартылуы да әнә шул туган туфрагын хуҗасыз калдырасы килмәүдәндер, бәлки.

Зөфәр. Яз әле, Фирая, бу сүзләрне. Аннары менә болай дип тә өстәрсең.

Фирая. Нәрсә дип?

Зөфәр. Кирам Фираяны ярата дип.

Кирам *(алга чыгып).* Ансын синнән сорамыйлар.

Рәҗибә. Бала-чагалар, һаман шаярырга булсын аларга.

Зөфәр. Шаярудан туктап иген үстерергә китик алайса.

Рәҗибә. Иген үстерү, әлбәттә, начар нәрсә түгел. Әмма ләкин романтикасы бәләкәйрәк.

Гөлназ. Синеңчә романтика кайда соң?

Рәҗибә. Романтика кайдадыр — ансын белмим. Әмма ләкин көлмәсәгез, күңелдәген әйтә алам. *(Хыялланып.)* Их, дусларым. Хәзер менә минем каршыма бер рыцарь килеп: чык миңа кияүгә, дисен иде. Ике дә уйламыйча чыгар идем. Тупырдап торган балалар үстерер идем. Ә сез иген дисез.

Барсы да бер мәлгә тын калалар. Күзләрендә Рәҗибәгә ышанып җитмәү чаткылары күренә.

Флюра. Кияү турында уйларга иртәрәк әле безгә.

Рәҗибә. Ә нигә, без монда күңелдәге хыялларыбыз белән уртаклашырга килмәдекмени? Һөнәрне дә кеше бит кәләш яки кияү сайлаган кебек гомерлеккә сайлый. Уйламый гына эшләсәк, үкенеп куймагаек. Тупырдап торган ун малай үстерсәм, миңа шул җитеп торыр иде.

Флюра. Синеңчә, иген үстергән җирдә балалар үстереп булмыймыни?

Рәҗибә. Буладыр ансы. Ләкин тракторчы булып эшләгән хатын-кызда нинди нәфислек кала? Әнә теге, гомере буена ирләр киеме киенеп, иргә чыга алмый калган Хәбирә апаны гына алыгыз. Аны кем шулай тупаслаткан? Шул трактор түгелмени? *(Барсы да уйга калалар.)* Ә минем нәфис зат булып яшисем килә. Иркәләп һәм иркәләнеп яшисем. Юкса без, хатын-кызлар, хәзер чынлап та күбрәк ирләр һөнәренә үреләбез: сездән ким түгел, янәсе. Ә бит илгә балалар үстерү икмәк үстерүдән кирәклерәк. Балалар булмаса, сезнең икмәгегезне кем ашар?

Гөлназ. Син, Рәҗибә, әллә кайсы якка кереп киттең. Безнең дә бит әле фәрештәлеккә китәргә җыенганыбыз юк.

Рәҗибә. Ансы шулайдыр, дустым. Тик менә сине генә алыйк: мәктәптә комсорг булдыңмы? Булдың. Озак та үтмәс, колхозга комсомол секретаре итеп куярлар. Димәк, тракторчылыкка укып чыксаң да, син аны тиз ташлаячаксың.

Гөлназ. Укыйм икән, мин инде аны күз буяр өчен укымыйм, эшләр өчен укыйм. Ә тупаслануга килгәндә, син юкка куркасың. Бердән, хәзер тракторлар җиңел. Икенчедән, Хәбирә апа иргә чыга алмый калган икән, ул чагында заманы шундый булган. Сугыштан соң кем генә чыккан иргә? Хәбирә апалар язмышы — сугыш чоры тудырган фаҗига нәтиҗәсе.

Фирая. Дөрес әйтәсең, Гөлназ. Әнә Урта Азия якларын гына алыйк: хатын-кызлардан иң күп Социалистик Хезмәт Геройлары кайда? Шунда. Депутатлар да, Геройлар да күп анда, үзләре бер көтү бала да үстерәләр. Тракторда эшләүдән дә курыкмыйлар.

Зөфәр. Карагыз инде боларны. Кулларына өлгергәнлек аттестаты керүгә ничек сайрый башладылар.

Фирая. Әйе, кешедән көлү җиңел ул. Ә син, бик акыллы икәнсең, әйт үз сүзеңне. Уртаклаш үзеңнең «бөек» идеалларың белән.

Зөфәр. Идеаллар белән хыяллар минем бер тирәдәрәк йөри.

Кирам. Әйтеп җиффәр алайса.

Зөфәр *(гади генә нәрсә әйткән кебек).* Айга барып кайтырга иде исәп. Анда бик романтично икән.

Кирам. Каян беләсең? Айга барып кайттыңмыни?

Зөфәр. Юк, мин түгел, әбекәй барып кайтты.

Кирам. Кайчан?

Зөфәр. Беркөнне төшендә. *(Көлеп.)* Әбекәй әйтә, анда зур-зур бәрәңге бакчалары исраф булып ята, ди. Бригадирдан ат сорап, шунда бер ун капчык бәрәңге илтеп ташласаң, Зөфәр улым, мал-туарны кыш буе бәрәңге белән сыйлар идек, ди.

Кирам *(Флюрага).* Флюра, гармуныңны Зөфәрнең авызына каплап торыйк әле. Югыйсә ул туктый белмәс.

Зөфәр. Бетте, бетте.

Кирам. Бетсә, мине тыңлап карагыз.

Зөфәр *(уң колагын алга сузып).* Минем локаторлар сезнең тарафка юнәлтелде, Кираметдин иптәш.

Кирам. Лично мин үзем...

Зөфәр. Синең бөтен нәрсәң лично, ансын беләбез.

Кирам *(Зөфәрне этеп җибәрә).* Ат аягын дагалаганда, бакалар ботын кыстырмый торсын иде.

Зөфәр. Бетте, бетте.

Кирам. Лично мин үзем тракторга караганда атны артыграк күрәм. Атның бит аның җаны бар.

Зөфәр. Җаны бардыр, ләкин аты юк бит әле аның. Менә шул атны каян алмакчы буласың?

Кирам. Колхозда калам икән — минем телэгемне дә канәгатьләндерсеннәр.

Гөлназ. Карагыз әле, без «конфет бирсәң, яратам» дигән балалар сыман кыланмыйк инде. Авылга ат та кирәк, ансына мин дә каршы түгел. Әмма хәзер авылны тартып баручы көч — трактор, машина. Ә бит берничә елдан без колхозның төп таянычы булырга тиешле кешеләр. Сезнең берегезнең дә менә шушы таулар, менә шушы таллар, менә шушы кырлар өчен җаныгыз әрнемимени? Яратабыз дип йөрисез түгелме соң сез авылны?

Мансур. Яратабыз, әлбәттә.

Гөлназ. Яраткач, яраткан төбәгең өчен нәрсә дә булса эшләргә кирәктер бит. Ел саен шәһәрдән килеп бәрәңгебезне алышып китәләр, икмәгебезне урышалар. Бер уйласаң, оят бит бу. Без гамьсезләнгәннән-гамьсезләнә барабыз. Кемгә карата диген? Менә шушы җир-суларыбызга карата бит. Ничә ел буе безнең серләребезгә шаһит булган шушы өянкеләрне, шушы хозурлыкны һич кызганмыйча ташлап китәргә җыенабыз. Авылны пенсиядәге карт-корылар кулына калдырмакчы булабыз. Авыл тегеләй, авыл болай дибез. Авылны үзебез теләгәнчә итү безнең кулда түгелмени?

Пауза.

Рәҗибә *(Гөлназга).* Карап-карап торам да сиңа, Гөлназ, тагын бер карап куям.

Гөлназ. Шуның белән ни әйтмәкче буласың?

Рәҗибә. Шәп сөйлисең, дим.

Мансур. Минем бер соравым бар иде, дуслар.

Зөфәр. Рәхим ит, Мансур әфәнде.

Мансур. Без булмасак, колхоз егылып үләр дип куркудан гына тракторчылыкка укырга китәбезме без, әллә бу һөнәрне чын күңелдән яратучылар бармы? Минем менә шуны беләсем килә иде.

Гөлназ *(бераз үпкәләп).* Ничек шулай дип әйтә аласың, Мансур?

Мансур. Ә нигә? Бая Рәҗибә дөрес әйтте бит: һөнәрне сөйгән яр кебек гомерлеккә сайлыйлар. Әгәр безнең бу ашкынуларыбыз коры бер энтузиазм гына булса, соңыннан үзебезгә авырга киләчәк.

Гөлназ. Авырлыктан курыкканнарны көчләмибез бит.

Фирая. Ә нигә Эльмира, Дания, Аliклар юк?

Гөлназ. Данияне үзегез беләсез, аның әнисе авырый. Дания әнисен терелтерлек врач булырга хыяллана. Ул инде, әгәр имтиханнар тапшыра алмасам, больницага санитарка рәвешендә булса да урнашам дип йөри. Ә Эльмира, Аликлар белән соңыннан сөйләшербез. Килмәгәннәр бит.

Фирая. Мин, алайса, исемлек төзим. Кем дә кем механизаторлыкка укырга телим ди, ике кулын да күтәреп каршыма тезләнсен. Шунда, бәлки, мин аны исемлеккә теркәрмен.

Гөлназ. Яз мине беренче итеп.

Фирая *(язып куя).* Яздык. Ягез, ягез. Яңа тракторларны алып калырга ашыгыгыз. Юкса үкенерсез. Әгәр сез икеләнеп торсагыз, үземне язам. *(Каләменең башын ялап ала.)* Фирая Фазылҗанова дип языйк әле. *(Хыялланып.)* Апагыз укып чыккач күрсәтер әле үзегезгә. Иң беренче итеп мотоцикл алып җибәрәм. Выжлап урамнан үткәндә, күзләрегезне елтыратып калырсыз.

Флюра. Алай бик кызыктыргач, мине дә яз.

Фирая. Язабыз. Сиңа тракторның гармун кебек кайсы төймәсенә бассаң да кычкыра торганын бирергә дип язып куям.

Гөлназ. Монда егетләр ни өчендер авызларына су кабып торалар әле.

Зөфәр. Ярый алайса, авыздан суны түгеп ташладык һәм Мансурның сүзен көтә башладык.

Мансур. Мин бер якка да катнашмыйм. Минем кая китәсем билгеле инде.

Зөфәр. Сер булмаса, безгә дә әйт.

Мансур. Хәрби училищега, офицерлыкка.

Берничә тавыш. Офицерлыкка?

Мансур. Әйе, Алик белән.

Гөлназ *(гаҗәпләнеп).* Алик белән? Алик белән син офицерлыкка китәсеңме?

Мансур *(бераз кыенсынып).* Ә нигә шаккаттыгыз? Офицерлыкка мөгезле кешеләр генә укыймыни?

Гөлназ. Мөгезле кешеләр түгел дә... Синең бит... Синең бит...

Мансур *(бераз үпкәләп).* Нәрсә, синең тазалыгың да шуның хәтле генә дияргә телисеңме?

Гөлназ. Алай ук дип әйтергә теләмәгән идем. Алырлармы дип әйтүем иде.

Мансур. Суворов та пәһлеван булмаган.

Гөлназ. Ансы шулай. Тик егетләрне болай да армиягә алалар бит. Әле генә үзең авылны яратуыңны әйттең.

Мансур *(хыялга бирелеп).* Әйе, авылны яратам мин. Менә шушы өянкеләрне, тургайлы кырларны, хыялыбызга биеклек биргән тауларны мәңге онытачагым юк.

Гөлназ. Соң, шулай булгач?

Мансур. Нәкъ менә авылны ятатканга күрә дә гомеремне хәрби хезмәткә багышлыйсым килә. Син, Гөлназ, күңелдән әрнеп авылны якладың. Минемчә, хәрби хезмәткә җирне, кешеләрне яраткан кешеләр китәргә тиешләр дә. Әйе, син дөрес әйттең, егетләрне болай да армиягә алалар. Ләкин, алайга китсә, икмәкне дә безнең надан бабаларыбыз да үстергән. Әмма без бит хәзер алар белән генә чикләнергә теләмибез. Һаман күбрәк укыйбыз, җирнең серләренә тирәнрәк төшенергә тырышабыз. Минем дә менә үземнең яраткан авылымны, үстергән җиремне яклыйсым килә. Җирнең чын хуҗасы булып яклыйсым. Ә җирне аңлау өчен дә, яклау өчен дә уку кирәк. Аккан суларыбызның чиста, аткан таңнарыбызның тыныч булуын телим мин. Гомерем буе шуңа хыялланып яшәдем.

Пауза.

Рәҗибә. Яратам шул хәрби кешеләрне. Молодец, Мансур! Шәп юл сайлагансың. Алик та, син дә менә дигән егетләр икәнсез.

Зөфәр *(шигырь укый).*

Без торабыз җиде юл чатында,
Һәрбер юл да тарта үзенә.
Егылмыйча бара алырбызмы
Язмышларның карап күзенә?!

Сәхнә караңгылана. Әкрен генә уйнаган гармун тавышы ишетелә. Бераздан ул да ишетелми башлый. Сәхнә яктыра. Шул ук су буе. Бераз вакыт үткән. Кошлар сайраган тавыш ишетелә. Пәрдә ачылганда сәхнәдә беркем дә юк. Кулына тал ботагы тотып Рәҗибә керә.

Рәҗибә. Их, көне дә көне! Бигрәк матур бит! Хәзер менә шул тал арасыннан урта гасыр рыцаре килсен иде дә, минем каршыма тезләнеп: «Яратам сине, Рәҗибә», — дисен иде. Мин аның башыннан сыйпап: «Мин дә», — дияр идем. *(Көрсенеп куя.)* Юк шул. Ни өчендер егетләрнең күзләре Гөлназларда, Флюраларда. Әллә соң мин бик ямьсез микән? *(Кесәсеннән көзге алып карый.)* Борыным да үз урынында, авызым да кыек түгел. Сукырдыр бу егетләр. Сукыр булмасалар, минем дә Гөлназлардан ким түгеллегемне күрерләр иде. *(Уйланып кала.)* Их, бәхетле буласы килә. Сөясе, сөеләсе килә. Унҗиде

тулды бит инде. Ямьсездер мин. *(Яңадан көзгесенә карый.)* Әйе, ямьсез! Менә бит борыным ләпшәк, иреннәрем кәгазь калынлыгы гына. Битем дә артык киң. *(Битен кулы белән каплый.)*

Мансур керә.

Мансур *(Рәҗибәгә карый).* Рәҗибә, нишлисең?

Рәҗибә *(сискәнеп).* Ә-ә, ю-ук, берни эшләмим. Просто менә бу ямьсез йөземне якты дөньяга күрсәтәсем килми.

Мансур *(гаҗәпләнеп).* Әллә ниләр сөйлисең син, Рәҗибә. Кем әйтте сине ямьсез дип?

Рәҗибә. Кеше әйтмәсә дә күренеп тора инде ул. Гарипкә дә син гарип димиләр. Ләкин ул үзенең нинди икәнен белмимени?

Мансур. Матурлыкны һәркем үзенчә аңлый.

Рәҗибә. Син мине юатып маташкан буласың, үзеңнең дә эчеңне корт кимерә бит. Буең бәләкәй булганга әллә кимсенмисеңме?

Мансур. Әйе, ансын дөрес әйтәсең. Кимсенгән чаклар булмады түгел. Тик хәзер мин ул этапны үттем инде. Шушы буем белән таза гәүдәлеләр эшли ала торган эшкә көчем җитә дип шатланам гына мин.

Рәҗибә. Ышандылар ди сиңа.

Мансур. Ышану-ышанмау синең эш. Әмма матурлык, озын буй тормыш өчен әле ул бернәрсә дә түгел. Кеше матур яшәве белән күрсәтергә тиеш үзенең матурлыгын. Ә табигать биргән байлык белән мактанасы юк.

Рәҗибә. Табигать тарафыннан матурлыклары белән нигә, алайса, кайберәүләр мактаналар?

Мансур. Ансы инде һәркемнең үз эше.

Рәҗибә. Үз эше генә түгел шул. Матурлар әнә шул матурлыкларын үз файдаларына җигәләр.

Мансур. Кем турында әйтәсең?

Рәҗибә. Кем турында әйтсәм дә барыбер түгелмени?

Мансур. Түгел.

Рәҗибә. Син артык идейный кеше, барыбер миңа ышанмассың.

Мансур. Дөрес булса, ышанырмын.

Рәҗибә. Ишет алайса: Гөлназың классның барлык егетләрен үз ягына аударып бетергән.

Мансур. Бик әйбәт.

Рәҗибә. Әллә син аны җирне яратканнан агитацияләп йөри дип беләсеңме? Аңа бит дан кирәк. Ул шуның өчен тырыша.

Мансур. Ну, Рәҗибә, авызыңны үлчәп ач. Гөлназга карата ничек шулай әйтә аласың?

Рәҗибә. Гөлназны синнән яхшырак белгәнгә әйтәм. Оныттыңмыни, сигезенче классны бетергәч тә ул районга механизаторлар курсына киткән иде. Укымый кайтты.

Мансур. Ул бит аягын авырттырды, шуңа күрә аны курслардан кайтарып җибәрделәр.

Рәҗибә. Качкач, җибәрәләр инде ул.

Мансур. Сөйләмә юкны. Качарлык булса, ул анда китмәс тә иде.

Рәҗибә. Бигрәк беркатлы син, Мансур. Беләсең килсә, Гөлназ ул чакта әниләренә ачу итеп киткән иде.

Мансур. Әнисенә нинди ачуы булсын аның?

Рәҗибә. Модный күлмәк алып бирмәгәнгә. Әнисе күлмәк алып бирү белән кире кайтты. Сезне ышандырыр өчен тезен бәйләп йөрде.

Мансур. Кеше ышанмастай сүзне чын булса да сөйләмә.

Рәҗибә. Йә, ярый алайса, бетте. Мин синең Гөлназыңны хурларга теләмәгән идем.

Мансур. Кайчаннан бирле минеке әле ул?

Рәҗибә. Синең күзең кызларны егетләрдән аера башлаганнан бирле. Әйе, Гөлназ әйбәт кыз. Үзенең хыяллары бар, омтылышы бар. Чибәрлек ягыннан да Ходай ким-хур итмәгән үзен. Тик менә... *(Сүзен тәмамламыйча туктап кала.)*

Мансур. Башлагач әйтеп бетер.

Рәҗибә. Арагызны бозасым килми, Мансур. Бигрәк матур парлар бит сез.

Мансур *(Рәҗибәнең кулларыннан каты итеп тотып).* Әйт! Мин Гөлназ турында барын да белергә тиеш.

Рәҗибә. Абау, Мансур, авырттырасың ич.

Мансур. Авырттырам.

Рәҗибә. Әй, әллә нәрсә түгел лә инде. Гөлназ синең хәрби училищега китәсеңне белгәч, Мансур бүтән минем янга килеп йөрмәсен, ди.

Мансур *(агарынып).* Ялган! Нишләп ул аны сиңа әйткән, үземә әйтмәгән?

Рәҗибә. Мин дә, арагызга мине кыстырмагыз, әйтәсе сүзеңне Мансурга үзең әйт, дигән идем. Ә ул

әйтә: Мансурны күрәсем дә, ишетәсем дә килми, ди. Менә запискаларыңны да үзеңә бирергә кушты. *(Мансурга бер уч кәгазь бирә.)* Болар синең җиденче класстан бирле аңа язганнарың.

Мансур хатларны ала. Аларны ерткалый, аннары аяклары белән таптый. Ул чиктән тыш аптыраган.

Рәҗибә. Син, Мансур, ул кадәр йөрәгеңә каты алма инде. Мин сезнең арагызны бутарга теләмәгән идем. Бәлки, килешерсез әле.

Мансур. Юк инде. Ансы булмас. Бездә дә горурлык бар.

Йөренә башлый. Әрле-бирле йөренгәннән соң, ике учы белән башын кысып, киселгән өянке төбенә утыра. Рәҗибә Мансурның каршысына чүгәли. Мансурның йөзенә ниндидер кызгану катыш ярату белән карап торганнан соң, маңгаен аның күкрәгенә төртеп үксергә тотына.

Егет аптырап кала.

Мансур. Рәҗибә, Рәҗибә, нәрсә булды? Газаплама үзеңне, монда син гаепле түгел. *(Ул Рәҗибәне юатып башыннан сыйпый.)*

Рәҗибә. Начар хәбәр китерүче һәрвакыт гаепле. Җиңелү хәбәрен китерүчеләрнең патшалар хәтта башын кискәннәр.

Мансур. Мин патша түгел һәм синең башыңны кисәргә җыенмыйм.

Рәҗибә. Ә бәлки, башымны киссәң, җиңелрәк булыр иде. Яратам бит мин сине, Мансур. Әллә кайчаннан бирле яратам. Әгәр Гөлназ белән арагызда шушындый нәрсә килеп чыкмаган булса, ратуымны сиңа мәңге әйтмәгән булыр идем. Гафу ит, Мансур.

Мансур. Ә нигә гафу үтенергә? Яратырга һәркемнең хакы юкмыни?

Рәҗибә. Беләм, Мансур. Минем сине ратуым иң урынсыз вакытта әйтелде.

Мансур *(Рәҗибәне этеп җибәрергә дә, кочагында тотарга да кыенсынып)*. Без бүгенгә бу турыда сөйләшмик әле, Рәҗибә.

Рәҗибә. Син тиздән училищега китәсең. Офицер булачаксың. Бөтенләйгә аерылышканчы күңелдәгесен әйтеп калыйм. Әйе, Мансур, бөтен кызлардан көнләшә-көнләшә яратам мин сине. Хәтерлисеңме, сигезенче классны бетергәч, Өемташ тавына менгән идек, шунда син каты ташка чукып Гөлназ исемен язып куйдың. Менә шул көнне мин көнләшүнең ни икәнен аңладым. Ләкин көнләшүдән үлсәм дә, яратуымны әйтмәм дигән идем. Менә... Үзеннән-үзе килеп чыкты. Тик нишлим соң?

Мансур. Туктале, Рәҗибә, нишләп әле син үзеңне бик кечерәйттең? Мин ямьсез дигән сүзне каян алдың син? Кем әйтте сиңа аны?

Мансур Рәҗибәнең йөзен ике кулы белән тота да кызның күзләренә карап тора. Шул вакыт йөгереп Гөлназ керә, ләкин Мансурның Рәҗибә күзләренә карап торганын күреп туктап кала. Рәҗибә Гөлназны күз кырые белән генә күреп ала һәм юри Мансурга елышарак төшә.

Мансур. Әнә ич нинди матур синең күзләрең. Күзләрең генә түгел, үзең дә матур. Гәүдәң дә очып китәргә тора.

Рәҗибә. Чынлап әйтәсеңме, Мансур?

Мансур. Кайчан минем ялганлаганым бар?

Рәҗибә. Мансур! *(Мансурны кочып ала, боларны күрмәс өчен Гөлназ йөгереп чыгып китә. Аның аяк тавышларын ишетеп икесе дә сикереп торалар.)*

Мансур. Монда кемдер булдымы әллә?

Рәҗибә. Гөлназ булды, ахрысы.

Мансур. Гөлназ?

Рәҗибә. Чакырып китеримме?

Мансур. Юк, кирәкмәс. Мин монда Аликны эзләп кенә килгән идем. Күрмәдеңме син аны?

Рәҗибә. Нәрсәгә ул?

Мансур. Военкомат өчен дип карточкага төшкән идек. Шуларны илтәсе бар иде.

Рәҗибә. Кая әле, күрсәт әле. *(Мансур фотолар күрсәтә.)* О! Баһадир син монда. Чып-чын баһадир. Кая, берсен бир әле. Монда күп ич.

Мансур. Нәрсәгә инде ул?

Рәҗибә. Сагынганда карарга.

Мансур фото бирә.

Рәҗибә. Язып та бир инде.

Мансур әһәмиятсез генә ниндидер сүзләр яза да фотосын Рәҗибәгә бирә. Аннары тиз-тиз атлап чыгып китә. Рәҗибә, фотоны йә күзенә якынрак китереп, йә ераккарак сузып карый-карый, Мансур артын- нан иярә. Флюра белән Зөфәр керәләр.

Зөфәр. Йә, булачак тракторчы, әйтеп җибәр әле: трактор нинди май ашый?

Флюра. Ак май!
Зөфәр. Минем төсле икән.
Флюра. Шулай шул.
Зөфәр. Тракторны син холкы миңа охшаганга яратасың икән.
Флюра. Каян беләсең?
Зөфәр. Әүлия бит мин.
Флюра. Әүлия? Син бит хыяллана да белмисең. Ашкыну юк синең җаныңда.
Зөфәр. О-о, ашкыну миндә бер пот. Беләсеңме, мин хәзер әнә теге болыт өстенә менеп ятар идем. Йомшактыр ул, әйеме?
Флюра. Сиңа, йокы чүлмәгенә, менеп ятарга урын гына булсын.
Зөфәр. Яратам йомшакны, җылыны, тәмлене.
Флюра. Песи баласы.
Зөфәр. Менә хәзер песи баласы булып синең алдыңа кереп ятсам, бер кайгым да калмас иде. Син минем колак артымнан кашып кына йоклатыр идең. Бәлки әле, борын очымнан үбеп тә алыр идең.
Флюра. Абау, мәхәббәтсез.
Зөфәр. «Абау, мәхәббәтсез» дидең,
Үзең сөеп карадың.
Күзләреңдә сөю күргәч,
Мин киресен аңладым.
Флюра. Кем шигыре бу?
Зөфәр *(шигырь укуын дәвам итеп).*
«Турыбыздан үтмә» дидең,
Мин «үт» диеп аңладым.
«Су буенда көтмә» дидең,
Мин «көт» диеп аңладым.
Флюра. Дөрес аңламагансың.
Зөфәр. Алайса, дөресен аңлат.
Флюра. Дөресе: мин әйткән сүзләрнең киресенең киресенең киресе була.
Зөфәр *(Флюраның сүзләрен кабатлап).* Киресенең киресенең киресе: «Мәхәббәтсез» сүзенең беренче киресе — мәхәббәтле, икенче киресе — мәхәббәтсез, өченче киресе — тагын мәхәббәтле булып чыга. Дөрес аңлаганмын бит.
Флюра. Алайса, дүртенче киресе.
Зөфәр. Ярар, мин кире булыйм. Ансына да риза. Бер абый әйткән бит: балаларым начар булсалар да, әйбәт начар, дип. Шуның сыман мин дә әйбәт кире.
Флюра *(үпкәләгән булып).* Ә мин синең эше киребеткәннәр белән сөйләшмим.
Зөфәр. Яраткан кешең белән сөйләшми утыруы да рәхәт.
Флюра. Кем кемне ярата?
Зөфәр. Син мине, билгеле.
Флюра *(гармун өстеннән этеп).* Бик кирәгең барые. Минем сиңа әйләнеп карыйсым да килми.
Зөфәр. Чөнки мине карамасаң да күрәсең. Менә хәзер әйтеп кара: мин нишлим?
Флюра *(күзләрен йома. Зөфәр аның бит очыннан үбеп ала).* Абау, мәхәббәтсез, нишлисең?
Зөфәр *(оялып).* Мин ни... борын комачау итми микән дип кенә караган идем. Чынлап...
Флюра *(Зөфәрне этә).* Аю, кит моннан. Гармунны сытасың бит.
Зөфәр. Беренче зарплатага алып бирермен.
Флюра. Болай икеләнеп йөрсәң, син эшли башлаганчы кызыл кар явар. *(Гармунының каешыннан тарта.)*
Зөфәр. Тартма, өзәсең.
Флюра. Өзелсен, синеке түгел. Тор, мин китәм.
Зөфәр. Бәлки, гармуныңны миңа калдырырсың?
Флюра. Синең эше киребеткәннәр кулында гармуным җырлыйсы урында ишәк булып кычкыра башлар йә.
Зөфәр. Мал хуҗасына охшар, ди.
Флюра. Гармун мал түгел ул, җан. Җанны теләсә кем аңламый.
Зөфәр *(көрсенеп).* Минем җанны да аңлаучы юк шул. Беләсеңме, Флюра...
Флюра. Белмим, белергә дә теләмим.
Зөфәр. Теләмим дип киресен әйтәсеңме?
Флюра. Теләсәң ничек аңла.
Зөфәр. Алайса, мин: «Сөйлә, синең җаныңны белергә телим», — дип аңладым. *(Флюра дәшми.)* Дәшмәү ризалык билгесе, диләр. Бер шигырь укыйм әле үзеңә.
Дөнья, дөнья! Нинди гүзәл син,

Сокланмыйча ничек түзәрсең;
Болыннарда кошлар тавышы,
Елгаларда җикән камышы,
Күкләр зәңгәр, аяз офыклар,
Офыкларда йөзми болытлар.
Табигатьнең телен аңласам,
Камышлардан каләм ясасам,
Зәңгәр күккә шигырь язармын,
Мактый-мактый авылым язларын.

Флюра *(үпкәләвен онытып сикереп тора).* Әллә үзең яздыңмы, Зөфәр?

Зөфәр. Юк, әбекәй язып бирде. Менә шушы шигырьне, Зөфәр бәбекәем, дөньядагы иң матур, иң акыллы, иң-иң-иң... бер кызга укып күрсәт әле, ди.

Флюра. Алайса, нигә син аны миңа укыйсың! «Иң-иң-иң» кызны эзлә.

Зөфәр. Ә мин болытларга утырып дөньяны гизеп чыктым да менә шушы салам чәчле, яшел күзле кыздан да яхшырагы юктыр диган уйга килдем. *(Флюраның кабыргасына терсәге белән төртеп куя.)*

Флюра *(терсәге белән Зөфәрне читкәрәк этә).* Кит әле. Әллә ниләр сөйләмә.

Зөфәр *(шигырь укый).*

Әллә ниләр сөйләтүче — мәхәббәттер.
Күктән йолдыз чүпләтүче — мәхәббәттер.
Җырсызларны җырлаткан да — мәхәббәттер.
Моңсызларны елаткан да — мәхәббәттер.

Флюра *(сокланып).* Әллә монсын да үзең яздыңмы, Зөфәр?

Зөфәр. Бусын да әбекәй язып бирде.

Флюра. Шәп яза икән әбиең.

Зөфәр. Булдыра минем әбекәй.

Флюра. Их, минем дә шундый әбием булса.

Зөфәр. Нишләр идең?

Флюра. Синең әбиеңә үземнең әбиемнән шигырь яздырыр идем.

Зөфәр. Чынлап та ошадымы шигырь, Флюра?

Флюра. Ошады, чынлап ошады.

Зөфәр. Минем күңелемне төшермәс өчен генә шулай дисең. Бик әйбәт шул син.

Флюра. Кем әйбәт, минме? Беләсең килсә, мин бик начар.

Зөфәр. Юк, син һәр кешедән дә әйбәтрәк.

Флюра. Син үзең әйбәт.

Зөфәр. Мин дөньяда иң начар кеше.

Флюра. Начар кеше әйбәт шигырь яза алмый.

Зөфәр. И-и, Флюра, әгәр син әйбәт кеше булмасаң, хәзер минем шигыремне тетеп салыр идең. Беләсең килсә, миңа редакциядән әллә нинди хатлар килә, шигырьләремне пыран-заран китереп язалар.

Флюра. Юк, Зөфәр, синең шигырьләрең матур.

Зөфәр. Син күңелең теләгәнне гармунда әйтә аласың, мин гармунда уйный белмим.

Флюра. Гармунны аны теләгән кеше өйрәнә ала. Ә шигырь язарга кешене өйрәтеп булмый.

Зөфәр. Әйе, шигырь язарга кешене өйрәтеп булмый. Ә мин, юләр, университетка керсәм, шигырь язарга өйрәнер идем дип йөрим.

Флюра. Юк, Зөфәр, мин дөрес әйтмәдем. Күңелендә шагыйрьлек булган кешене шигырь язарга өйрәтеп буладыр. Нинди талантлы кеше дә укымыйча гына шагыйрь булалмыйдыр.

Зөфәр *(шатланып).* Син, Флюра, минем укырга китүемә каршы түгел, әйеме?

Флюра. И-и, юләр, нишләп каршы булыйм.

Зөфәр. Бүгеннән документларымны университетка җибәрәм.

Флюра. Яңадан да шигырьләрең бармы, Зөфәр?

Зөфәр. Бар да. Бөтенесе дә шундый инде алар.

Флюра. Укы әле тагын бер-икене.

Зөфәр *(шигырь сөйли).*

Гармун булсам синең кулдагы,
Күңелемдәген сөйләр идем мин.
Чәчәк булсам синең юлдагы,
Юлыңа нур сибәр идем мин.

Флюра *(кыенсынып чәчен бөтергәли).* Син әллә ниләр язып бетергәнсең, Зөфәр. Бусы бигрәк матур. Тагын укы әле.

Зөфәр. Җилләр булсам әгәр кырдагы,
Чәчләреңә кагылыр идем мин.

Мәхәббәткә, җырга, яшьлеккә
Гомер буе табыныр идем мин.

Пауза.

Флюра. Әйе, Зөфәр, син һичшиксез шагыйрь булырсың. Безнең игеннәрне мактап поэма язарсың. Поэмаңның төп герое Гөлназ булыр.

Зөфәр. Кемнең герой икәнен вакыт күрсәтер.

«Күңелләрдә безнең ак хыял» көе яңгырый.

Пәрдә.

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Шул ук урын. Элекке күренештән соң берничә көн вакыт үткән. Пәрдә ачылганда, Кирам белән Фирая чыбык-чабыклар җыеп уха пешерергә әзерләнәләр. Чиләк асарга таган корылган. Кирам учак ягасы урынга килеп-китеп йөри. Чөнки аның салынган кармаклары бар.

Кирам. Башкалар җыелганчы, бер ухалык балыкны каптырам әле мин, син бер дә курыкма, Фирая.

Фирая. Ә мин куркып утыра идем. Кирамга балык эләксә, ничек чистартырга инде, мин әйтәм. Балыкны иң кыены чистарту бит.

Кирам. Иң кыены ашау диген.

Фирая. Дөрес әйтәсең, ашавы да җиңел түгел. Яратмыйм шундый вак-төяк эшне.

Кирам. Менә, тракторчылыкка укып чыксаң, ике кулыңа бер эре эш булыр әле. *(Кармагына карап ала.)* Ай, чиртә.

Йөгереп чыгып китә дә бер маймыч тотып керә.

Кирам. Менә берәү эләккән!

Фирая. О-о, ничек тартып чыгардың аны?

Кирам. Тырыштым инде.

Фирая. Яңадан мондые эләксә, тартып чыгарырга ат яллarбыз.

Кирам. Ә нигә? Ат шәп нәрсә ул.

Фирая. Ат? Нәрсәсе бар соң шуның: дүрт аяк та бер койрык. Дүрт аяк белән бер койрык кәҗәдә дә бар.

Кирам. Ат булмаганга, авылның яме бетте. Әти әйтә, элек сабан туйларында уникешәр тройка җигеп авылны урый идек, ди. Их, авылга егерме-утыз гына ат кайтарсаңмы? Ул чагында инде мәктәп бетергән малайларны авылда калыгыз дип үгетләп йөрисе булмас иде.

Фирая. Кешеләр бит инде беренче булып атлы заманда авылдан кача башлаганнар Авыл малайларын шәһәрдәге машиналар, тракторлар тарткан.

Кирам. Юк, монда эш машинада гына түгел. Балаларын «бүкәй» белән куркыткан кебек кешене гел авыл белән куркытканнар. Авылда иң булдыксыз кешеләр генә кала, рәтлеләр вузларга, һич югы, шәһәргә заводларга китә дип, безнең миебезгә сеңдергәннәр. Әле без бишенчеләрдә укыганда гына укытучылар, начар укучыларны сүккәндә, болай йөрсәгез, гомергә авылда калып чиләнәчәксез, дип сүкмиләр идемени?

Фирая. Ансы шулай. Ләкин авылны авыл итәр өчен күбрәк машиналар кирәк.

Кирам. Юк, атлар кирәк. Синең ул машиналарың авылның авыллыгын бетерә.

Фирая. Соң, алайса, ат белән җир сөр, урман ташы, юллар сал, авылны матурла.

Кирам. Атның болын тутырып кешнәвеннән дә бөтен дөнья ямьләнеп китә. Ә яшь колын? Их! *(Күзләре очкынлана.)*

Фирая *(аны үртәп)*. Ә ялт итеп торган машина?

Кирам *(аның сүзен ишетмәмешкә салынып)*. Яшь тайлар болында ялларын җилфердәтеп чапканда, кошлар да сайравыннан туктап тора.

Фирая. Машинаның стартерына бер бассаң...

Кирам. Аргамакның ялына тотынып бер чапсаң...

Фирая. Аргамакның иң шәбе белән дә әллә кая китә алмыйсың хәзер.

Кирам. Нигә әллә кая китәргә? Мин әллә кая китәргә җыенмыйм. Миңа ат кына тоттырыгыз. *(Кармакка күз ташлый.)* О-о, калкавыч бөтенләй чумган. Җәен капкан, ахрысы. *(Чыгып китә. Шунда ук аның кычкырган тавышы ишетелә.)* Фирая, Фирая, кил әле. Үзем генә тартып алырга куркам.

Төшеп калса, бер кеше булса да артык күрер, ичмасам. Кил инде тизрәк.

Фирая. Берәр тал тамырына эләккәндер әле. *(Чыгып китә.)*

Рәҗибә керә. Кулында китап.

Рәҗибә *(таганга эленгән чиләккә карап).* И-и, уха ашатабыз дип йөргән булалар. Монда балыкның шулпасының шулпасы да юк әле.

Гөлназ керә. Ул бик күңелсез.

Гөлназ. Башкалар кая соң?

Рәҗибә. Кирам белән Фирая икесе бер маймычка мөкиббән китеп утыралар. Бик шәп уха белән сыйламакчылар бугай. Мансурны озату кичәсе бит.

Мансур исеме чыгуга, Гөлназ тагын да кәефсезләнә төшә.

Гөлназ. Тәки алырлар микән Мансурны?

Рәҗибә. Һи, Мансурны да алмагач. Ул әле училищеның да тегенди-мондыена түгел, очучылыкка укытканына китәм, ди. Анда гәүдәң бәләкәй булу да файда гына, самолет түбәсенә баш тими, ди. Телисеңме, Гөлназ, сезнең белән механизаторлыкка укырга мин дә китәм? Ничә кеше булдыгыз инде?

Гөлназ. Җиде!

Рәҗибә. Мин сигезенче булырмын. Шәп нәрсә уйладың син. Безгә җирдән аерылырга ярамый шул. Шушында туганбыз, шушында тәпи йөри башлаганбыз. Безнең бабай әйтә: кеше туган ягыннан киткән саен, җир рәнҗеп, елап кала, ди. Җирне елатучылар күп булды, инде без аны сөендереп карыйк, дим.

Гөлназ *(Рәҗибәне кочаклап).* Рәхмәт, дустым, рәхмәт. Гафу ит, Рәҗибә, моңарчы мин сине аңламаганмын икән. Күңелемдә сиңа карата әллә нинди шикле уйлар кузгалып-кузгалып куя иде.

Рәҗибә. Әйе, кешеләрне аңлау җиңел түгел. Без һәркемне үзебезнең үлчәмгә салып үлчәргә яратабыз шул. Безнең бөтен ялгышлыгыбыз шунда.

Гөлназ. Әйе, шушы көннәрдә генә мин ике кешедә ялгыштым. Бер ялгышым бәгыремне көйдерә, икенчесе сөендерә.

Рәҗибә. Бәлки, безне тормыш шулай итеп сыныйдыр.

Гөлназ. Их, авыр шул кайбер сынаулары. *(Чыга башлый.)*

Рәҗибә *(су буенда кармак салучы Кирамга карап).* Боларның ухасын көтсәң... *(Гөлназга.)* Мин егетләрне ашыктырыйм әле. Мә, менә бу китапны тотып тор. *(Китабын Гөлназга бирә, шул вакыт китап ачылып китә дә аның эченнән Мансурның фоторәсеме килеп чыга.)*

Гөлназ *(гаҗәпләнеп).* Мансур?

Рәҗибә. Ә, әйе. Менә истәлек булыр дип Мансур үзенең фотосын бүләк иткән иде. Шәп төшкән бит?!

Рәҗибә фотоны Гөлназга бирә. Гөлназ аны ала да артындагы язуны кычкырып укый: «Якын дустым Рәҗибәгә!»

Гөлназ. Мә! *(Фотоны Рәҗибәгә бирә дә үз-үзен кулга алыр өчен тиз-тиз атлап чыгып китә.)*

Еракта гармун тавышы ишетелә. Гармунга җыр өстәлә.

Күңелләрдә безнең ак хыял,
Ашкындырып тора гел алга.
Тапланмаслык булсын гомергә,
Лаек юллар сайлыйк хыялга.

Хыялларга итмик хыянәт,
Ак хыяллар — яшьлек юлдашы.
Яктылыгы белән саклансын
Гомер таңы безнең — юл башы.

Флюра белән Зөфәр керәләр. Кирам да җепкә тезгән балыклар күтәреп чыга.

Зөфәр. Әллә бу Фирая белән Кирамны чәчкәннәр инде. Кая карама шулар.

Кирам. Кешеләрдән качып кына таллыкта сайрашмакчы идегезмени?

Зөфәр. Безгә хәтле сез сайраша башлагансыз әле монда. Безгә мәхәббәтнең шулпасы гына калганга охшый.

Кирам. Шулпасы эләккәч тә җитеп торыр. Аңа гына риза булмаганнарга менә балык шулпасы әзерлибез. *(Балыкларга күрсәтә.)*

Зөфәр. Ярый инде алайса. Маймыч койрыгын болгаган шулпага риза булырга туры килер.

Мансур белән Рәҗибә керәләр.

Зөфәр. Булачак генерал белән герой анага салют.

Рәҗибә. Ә нигә? Булачак генерал шул. Мансур белән Алик өч көннән училищега китәләр. Чакыру кәгазе килгән.

Флюра. Чынлапмы, Мансур? Котлыйм!

Мансур. Котларлык нәрсә юк әле. Җегерләмәгән-сукмаган, кияү — сиңа ыштанлык.

Фирая. Алик, Эльмиралар кая соң?

Кирам. Менә балык шулпасының исен сизсәләр, килеп җитәрләр. Аңынчы Мансурны күккә чөеп алыйк.

Зөфәр. Юк, күккә чөяргә ярамый. Генерал булгач борынын күтәрмәсен өчен, киресенчә, аны тукмап җибәрергә кирәк.

Зөфәр Мансурны этеп җибәрә. Мансур егыла, Зөфәр шул арада Мансур өстенә менеп атлана. Көрмәкләшү китә. Мансур өскә чыга башласа, Кирам да Зөфәргә булыша.

Рәҗибә. Бала-чага булмагыз инде, егетләр. *(Мансурны егетләрдән араларга килә.)*

Зөфәр. Болай булгач бетте, бетте! Рәҗибә белән көрәшерлек көч юк әле бездә.

Мансурны тартып торгыза. Рәҗибә Мансурның өстендәге тузаннарын кага. Шул вакыт Гөлназ керә.

Зөфәр. Менә безнең лидер да килде, юкса сагына башлаган идек үзен.

Гөлназ аның шаяртуына җавап бирми, ул чиктән тыш күңелсез. Кулында ниндидер кәгазь кисәге бар.

Пауза.

Гөлназ *(аның сүзен ишетмәгәндәй)*. Дуслар, менә бу кәгазьдә ни язылганын беләсезме?

Зөфәр. Мин беләм. Мәхәббәт хаты бу. *(Гөлназ кулындагы хатны исни.)* Әйе, мәхәббәт исе килә аңардан.

Гөлназ. Ялгышасың, Зөфәр. Хыянәт исе аңкый бу хаттан. Бөтенебезгә карата хыянәт.

Тавышлар. Каяле, кая, нинди язу ул? Кем язган?

Гөлназ. Миңа моны идарәдән бирделәр.

Тавышлар. Укы, ни икәнен без дә белик.

Гөлназ. Казаннан корреспондент килгән.

Зөфәр. Оһо, безне Казанда да белә башлаганнар диген.

Гөлназ. Менә монда *(кәгазен селки)* ни язылганын белсәгез шаярасыгыз килмәс.

Тавышлар. Укы, укы, көттермә.

Гөлназ *(укый башлый)*. «Хөрмәтле редакция! Бу хатны сезгә Кызыл Кыя авылыннан бер комсомолец яза. Ни өчен сезгә язарга булдыммы? Чөнки бездә демократияне кысалар. Бөтен классыбыз белән көчләп колхозда калдырмакчы булалар. Бу эштә иң нык тырышып йөрүче кеше Гөлназ Сабитова. Ул беребез белән дә киңәшмәгән килеш, бөтен классыбыз белән авылда калырга телибез дип, район газетасына язып чыкты. Аңарга дан кирәк. Үзенә ияреп механизаторлыкка китмәүчеләрне эзәрлекли, аларны мыскыл итә. Чөнки ул колхоз председателенә яхшы булып күренергә тели. Ә председатель аның туганы. Ә бәлки, безнең галимнәр, язучылар, офицерлар буласыбыз киләдер. Нигә көчләп барыбызны да тракторның тимер кабинасына бикләргә? Шушы хәлне тикшерсәгез иде».

Хат укылып беткәч тә бераз вакыт сүзсез торалар.

Флюра. Кем язган бу әшәке хатны, имзасын куйганмы?

Фирая. Редакциядән килгән корреспондент кая?

Гөлназ. Корреспондент әле районга китте. Бу хатны ул кайткач комсомол җыелышында тикшерергә кирәк булачак.

Зөфәр. Туктагыз әле, товарищлар. Минем бу хатны язучыны беләсем килә. Кулын куйганмы ул Кызыл Кыя авылыннан язган комсомолец?

Гөлназ. Эш кул кую, куймауда гынамыни? Арабызда менә шушындый кешенең булуы үзе хурлык.

Фирая. Бәлки, аны берәр чит кеше язгандыр. Әйтик, олылар. Яшерен-батырын түгел, безнең сайлаган юлыбызны өнәп бетермәүче әти-әниләр бар бит әле.

Гөлназ. Юк, Фирая, моны безнең бер дустыбыз язган.

Фирая. Алай, алай. Заманның бу яман чире безгә дә йокты диген, һич ышанасы килми.

Тавышлар. Гөлназ, әгәр кем язганын белсәң, әйт. Йә, кем?

Гөлназ. Минемчә, ул хәзер безнең каршыбызга үзе чыгачак.

Барсы да бер-берләренә карашып сүзсез калалар.

Зөфәр. Әшәке кеше генә түгел, куркак та икән әле бу. Бир әле, Гөлназ, шул хатыңны, карыйк әле барыбыз да.

Гөлназ. Кәгазьгә караганчы әнә хат язучының үзенә карагыз. Мансур дустыбыз язган ул хатны.

Барысы да аһ итә.

Мансур *(алга чыгып).* Гөлназ! Син нәрсә?

Гөлназ читкә борыла.

Флюра. Юк, юк, мин моңа ышанмыйм.

Кирам. Мин да ышана алмыйм. Син, Гөлназ, ялгышмыйсыңмы? Мансур, Гөлназ, сөйләгез әле. Нәрсә соң бу, ә?

Пауза.

Мансур. Минем сөйләр сүзем юк, әнә Гөлназ сөйләсен.

Гөлназ. Әйе. Минем моны Мансур язганга дәлилләрем бар. *(Кәгазьне селки.)*

Мансур *(ирония белән).* Йә, тыңлап карыйк.

Тавышлар. Әйе, аңлатып сөйлә, Гөлназ.

Гөлназ *(кәгазьне бөкли дә бер җиренә төртеп күрсәтә. Мансурга карап).* Менә күр, болай итеп минем исемне тагын кем яза иде?

Мансур Гөлназ кулындагы кәгазьгә карый да аптырап кала. Ни әйтергә белмичә әле Гөлназга, әле дусларына карый.

Мансур. Тукта, тукта, Гөлназ. Хат бит минем кул белән язылмаган.

Гөлназ. Анонимны бер кеше дә үз кулы белән язмый.

Мансур *(ачуы килеп).* Димәк, мин язганмын? *(Нindидер бер үртәлүле көлү белән көлә башлый.)* Ха-ха-ха! Мин анонимщик диген. Ишетәсезме, мин анонимщик! *(Дусларына карый.)* Йә, күрдегезме инде анонимщикның нинди булганын? Күрмәсәгез, карап калыгыз. *(Үртәлүчән ярсу белән әле бер дустына, әле икенчесенә карый.)* Әйе, әйе, мин яздым моны! Нәрсәгә бәбәкләрегезне чекерәйттегез? Аяк бармагыма ручка кыстырдым да яздым. Менә шулай.

Мансур чыгып китә.

Зөфәр *(алга чыгып шигырь укый).*
Кешене ышаныч яшәтә,
Сиңа да, миңа да ул кирәк.
Күңелдә ышаныч булганда,
Иң авыр юллар да җиңелрәк.

Ышанып кул сузыйк дусларга,
Алар да ышаныр шул чакта.
Ачыйк та җандагы бикләрне,
Шикләрне куалыйк еракка.

Кешене ышаныч яшәтә,
Чыгармыйк шуны без күңелдән.
Ашыгыйк яхшылык эшләргә,
Киләчәк башлана бүгеннән.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук урын. Киселгән өянке төбендә бер-берләренә сыенышып Флюра белән Зөфәр утырган. Чирәмдә Флюраның гармуны. Сирәк-мирәк кошлар сайраган тавыш ишетелеп куя. Ерактан яшьләрнеңгармунга кушылып җырлаганы колакка чалынып китә.

Зөфәр *(көрсенеп).* Их, шәп тә инде безнең авыл кичләре! *(Хискә бирелеп урыныннан тора. Пафос*

*белән шигырь укый.)*

Әй, талларым минем, талларым,
Мәрхәмәтле изге җаннарым.
Табигатьнең тәүге серләрен
Сезнең шаулау аша аңладым.

Әй, суларым минем, суларым,
Еракларга дәшкән юлларым.
Сезнең дулкыннарда тирбәлеп
Ныгыдылар минем кулларым.

Әй, күкләрем минем, күкләрем,
Бигрәк ерак офык чикләрең.
Сиңа карап күпме чапсам да,
Чикләреңә барып җитмәдем.

Флюра. Әйбәт, әйбәт. Менә тиздән шигырьләрең артыннан үзең дә китеп барырсың. Аннары инде шигырьләрең дә, үзең дә кайтмассың.

Зөфәр. Юк, Флюра, мин ике университет бетерсәм дә, авылсыз тора алмам. Авыл мәңге языла торган шигырь бит ул.

Йолдызлары учка коела,
Чәчәкләре җанга сыена.
Былбыллары бер дә туктамый
Сайрап торыр кебек тоела.

Пауза.

Тынлыкны ярып мотоцикл тавышы яңгырый. Зөфәр сикереп тора да мотоцикл тавышы килгән якка омтылып куя.

Зөфәр. Һә-әй, Мансур!

Мотоцикл туктамый, выжлап үтеп китә.

Зөфәр. Туктамады, китте. *(Флюра янына килеп утыра.)*

Флюра. Көне дә шундый матур, тик күңел тыныч түгел. Күзгә матурлык күренми башлады.

Зөфәр. Әйе, күңелнең кайсыдыр җире кителде кебек. Гөлназ жәл. Нигә эшләде икән Мансур андый нәрсәне? Ә бит шундый матур итеп яратышалар иде. Бер-берләреннән күзләрен ала алмыйлар иде.

Флюра. Ә хәзер кайчан карама — Рәҗибә белән. Нигәдер шушы нәрсә сагайта мине. Ярый, Мансур безнең барыбызның механизатор булуы белән килешмәсен ди. Ярый, редакциягә язсын ди. Ләкин нигә Гөлназга, юк, Гөлназга түгел, мәхәббәткә хыянәт итәргә? Менә шуны аңламыйм мин.

Зөфәр. Монда аңламаслык нәрсәләр бар шул. Мин кайчакта хатны әллә Мансур язмады микән дип уйлап куям.

Флюра. Алайса, нигә Гөлназ туп-туры Мансур дип әйтте? Ул бит Мансурның язуын барыбызга караганда да яхшырак белә. Гөлназ Мансур икәнлеккә нык ышанмаса, тиктомалдан кешегә андый гаеп ташлар идемени? Бүтән кешегә түгел бит, Мансурга.

Зөфәр. Әйе, катлаулы эш. *(Шигырь укый.)*

Өлгермәдек юлга чыгарга,
Юлыктык бик авыр сорауга.
Тапканчы без дөрес җавапны,
Сындырмабыз микән канатны?
Көч булырмы җиңеп чыгарлык
Хыянәтне, кара ялганны?
Ә яшисе килә, яшисе,
Шаулатырлык итеп заманны.

Зөфәр шигырь укып бетергәч, бераз тын торалар. Шул вакыт кемнеңдер сагышлы итеп җырлаганы ишетелә.

Зөфәр. Гөлназ тавышы.

Флюра. Бирегә килә, ахры.

Зөфәр. Кешеләргә караганда табигать безне яхшырак аңлый. Ул сүзсез тыңлый белә.

Җыр якыная. Зөфәр белән Флюра бер-берләренә сыенып утырып җыр тыңлыйлар.

Өзелә үзәгем, өзелә,
Кайлардан табыйм соң дәвалар?

Сулышым кагылса гөлләргә,
Гөлләр дә ялкынланып яналар.

Флюра. Гөлназ монда килә. Без китик, җырын бүлдермик. Җырлый алган кеше, елый алган кеше бушана ала. Бушансын, җиңеләйсен.

Флюра белән Зөфәр китәләр. Кулына тал чыбыгы тотып, сагышлы җырлап Гөлназ керә.

Гөлназ. Өзелә үзәгем, өзелә,
Йолдызы коела күгемнең.
Кая соң яп-якты көннәрем,
Ник гамьсез бер сабый түгел мин.

Мансур керә. Ул Гөлназның җырын бүлдермәс өчен кинәт туктап кала. Гөлназ аны күрми, җырлавын дәвам итә.

Гөлназ. Өзелә үзәгем, өзелә,
Хыялның канаты каерылды.
Ничә ел үрелгән сукмаклар
Аерылды, аерылды, аерылды.

Мансур *(алга омтылып).* Гөлназ!

Гөлназ сискәнеп китә. Башта, Мансурны күрү белән, аның йөзендә ниндидер шатлык чаткысы ялтырап ала, ләкин бу чаткы бик тиз сүнә.

Мансур. Гөлназ!

Гөлназ аңа дәшми, икенче якка борыла.

Мансур. Гөлназ, мин иртәгә китәм. *(Гөлназ дәшми.)* Киткәнче синең белән җаннарны учка салып сөйләшәсе бар иде.

Гөлназ. Кирәкмәс, Мансур. Җаннарыбыз пычранды безнең.

Мансур. Тыңла әле, Гөлназ.

Гөлназ. Тыңламыйм, син әйтәсе сүзеңне әйттең инде. Шуннан артыгын барыбер әйтә алмассың.

Мансур *(күңеле төшеп).* Шулаймыни? Ярый алайса, сау бул. Мин киттем.

Гөлназ. Син минем өчен күптән киттең инде, һәм бер дә кайтмаска киттең.

Мансур. Их, Гөлназ, Гөлназ! Аңлашырбызмы әллә дип килгән идем. Горурлыгымны җиңеп.

Гөлназ. Барсын да бик әйбәт аңлаттың, Мансур. Тыныч күңел белән китә аласың. Өч елдан офицер булырсың. Иңеңә ялтыравыклы погоннар тагып җибәрерсең. Безнең кебек җир кортлары белән сөйләшеп телеңне әрәм итмә.

Мансур. Нишләдең син, Гөлназ? Сукырайдыңмы? Саңгыраууландыңмы? Нәрсә булды сиңа?

Гөлназ. Киресенчә, элек сукыр һәм саңгырау булганмын мин. Хәзер күзләрем ачылды. *(Ирония белән дәвам итә.)* Сиңа рәхмәт, бик зур рәхмәт, булачак иптәш генерал. Безнеңише надан авыл балаларына акыл өйрәтүең өчен рәхмәт. Юкса, син өйрәтмәсәң, шушы яшьтән хыянәтнең, ялганның, пычракның нәрсә икәнен белер идекмени? Юләрләнеп мәхәббәт уены уйнап йөрер, бер-беребезгә ялган сүзләр сөйләр идек. Болай, ичмасам, син бер селтәнү белән барыбызның күзләрен ачтың.

Мансур. Ярый алайса. Теге көнге кыланышларың өчен үкенәсеңдер, гафу үтенергә җай бирим дип кенә килгән идем, хуш!

Гөлназ *(ирония белән).* Ха-ха-ха-ха! Менә нинди олы җанлы кеше икәнсең син. Гафу үтенергә миңа җай бирергә уйлаган. Ха-ха-ха!

Мансур. Хуш, Гөлназ! Һәрвакыт шулай көлеп яшә. *(Чыгып китә.)*

Мансур китеп барганнан соң, Гөлназ үзенә урын таба алмый йөри. Ул ярсыган.

Гөлназ. Кара син аны, нинди изге җан! Офицер булып алса, ничек сөйләшмәс. *(Мансур киткән якка карап.)* Ә без барыбер үзебезнекен итәрбез. Туйдырган, үстергән җиренә төкереп киткән кешенең рәхәт күргәне юк әле.

Кирам керә.

Кирам. Кем белән сөйләшәсең? Каргыйсың ук дип әйтергә телем әйләнми. Әле без кеше каргарлык яшькә җитмәгән.

Гөлназ. Каргар өчен картаю кирәкмени?

Кирам. Шулайдыр. Чөнки көчсез кешеләр генә башкаларны каргый. Көчле кешеләр үзләрен рәнҗетүчедән йә үч ала, йә аларны кичерә. Яисә, бөтенләй күрмәмешкә салынып, рәнҗетүчесенең бәгърен кискәли.

Гөлназ. Үзеңне рәнҗетмәгәндә акыллы булып була ул. Ләкин үзеңә кагылса...

Кирам. Аңлыйм мин сине, Гөлназ. Син Мансурга рәнҗисең. Ә бит редакциягә хатны Мансур язмаган.

Гөлназ. Мансур язмаган? *(Бик гаҗәпләнә.)*

Кирам. Әйе, Мансур түгел. Мин менә синең яныңа шуны әйтергә килдем.

Гөлназ. Тукта, тукта! Ә кем язган соң, алайса, ул хатны?

Кирам *(Гөлназ каршына килеп тезләнә.)* Ул хатны мин язган идем, Гөлназ. Теләсәң ас, теләсәң кис, мин язган идем.

Гөлназ. Ни өчен кирәк булды миңа шундый әшәке яла ягу? Минем сиңа яки башкаларга нинди начарлыгым тиде? Йә, әйт күземә карап.

Кирам *(башын иеп)*. Кичер дип әйтмим, Гөлназ, әшәкелекне кичереп булмый. Кичергән очракта да аның җанда ярасы кала. Әйе, мин синең җаныңны яраладым.

Гөлназ *(өзгәләнеп).* Ни өчен, әйт, ни өчен?

Кирам *(аптырабрак).* Минем сүзләрем, бәлки, сине ышандырып та бетермәс, ләкин бары тик Фираяны тракторист итәсем килмәгәнгә генә язган идем. Үзең беләсең, мин бит аны яратам. Вакыты җитәр, өйләнешербез дә.

Гөлназ. Берәүне яратканга, икенче кешегә яла ягу кирәк идеме? Мин бит сине Фираяңнан тартып алырга җыенмадым. Рәхәтләнеп ярат идең.

Кирам. Шулай булган да бит. Кызулык белән язып җибәрелгән инде. Хәзер менә терсәкне тешләп булмый.

Пауза.

Гөлназ *(кинәт нәрсәнедер исенә төшереп).* Алайса, нишләп торабыз соң, Мансур янына барыйк. Ай, нәрсә эшләдем мин?! Мансурга ниләр әйтеп бетермәдем. Тизрәк Мансурны табарга, әйтергә, аңлатырга кирәк. Уф, йөрәгем әллә нишли.

Чыга башлый. Шул вакыт ашыга-ашыга Фирая керә. Алар маңгайг маңгай бәрелешә язалар.

Фирая. Кая ашыгасың, Гөлназ?

Гөлназ кул гына селти.

Фирая. Туктале, сиңа бик зур сүзем барые.

Гөлназ. Соңыннан, соңыннан.

Фирая. Юк, соңыннан соң була. Мин бары тик шушы минутта гына әйтә алам ул сүзне.

Гөлназ китәргә торган җиреннән туктап кала.

Гөлназ. Йә, нәрсә?

Фирая сүзен башлый алмый тора. Кирам аның шулай югалып калуын үзе монда булганлыктан дип уйлый.

Фирая. Гөлназ, беләсеңме, теге нине...

Кирам. Мин китимме әллә?

Фирая. Бар. Хәер, китмә, син да ишет. Чит кешеләр аша гайбәт булып барып җиткәнче, үземнән ишетүең яхшырак булыр.

Кирам. Сүз минем хактамыни?

Фирая. Юк, минем хакта. Ә минем хактагы сүз сине кызыксындырмаса, китә аласың. *(Бераз сүзен әйтә алмый тора. Гөлназ да, Кирам да аңа текәләләр.)* Гөлназ, кичер мине, мин синең алдыңда бик зур гаепле. Редакциягә теге хатны мин язган идем. *(Башын түбән иеп тын кала.)*

Гөлназ. Син?

Фирая. Мин, Гөлназ.

Гөлназ. Бәлки, сәбәбен дә аңлатырсың?

Фирая *(уйланып).* Сәбәбеме? Ә нигә, һәрбер начарлык сәбәп белән генә эшләнәмени? Әйтик, урамда хулиганнар тиктомалдан берәр кешене кыйнап китәләр. Монда нинди сәбәп булырга мөмкин? Бәлки, минем ул көнне кәефем начар булгандыр да берәрсенә этлек эшлисем килгәндер. Шулай мөмкин түгелмени?

Гөлназ. Белмим, белмим.

Фирая. Мөмкин, бик мөмкин. Ә начарлыкны ни өчен миңа эшләдең дип сорасаң, ансына да җавап бирә алам. Без начарлыкны иң яхшы кешеләргә карата эшлибез. Менә теләсә кайсыбызны алыйк: бәләкәй чакта безне кемдер рәнҗетсә, әти-әниләребезгә эндәшмичә йөреп, аларның бәгырьләрен телгәли идек. Дошманыбызга көчебез җитмәсә дә, әти-әниләребезгә көчебез җитә безнең. Якын дусларыбыз белән дә шулай ук. Йә хыянәт итәбез, йә яла ягабыз, йә бүтәнчә рәнҗетәбез. Чөнки якын кешеләребезнең безне кичерәчәкләренә ышанабыз. *(Пауза.)* Менә шулай, Гөлназ. Хатны мин язган идем. Мансурга юкка үпкәлисең.

Пауза.

Кирам гаҗәпләнеп Фираяга карап тора.

Гөлназ. Әле син килер алдыннан гына шушы ук сүзләрне миңа Кирам әйткән иде.

Фирая *(аптырап).* Кирам? Мөмкин түгел.

Кирам. Нигә мөмкин булмасын?

Фирая. Чөнки хатны мин яздым.

Гөлназ. Хәзер Зөфәр яки Флюра килеп шушы ук сүзләрне әйтсә дә, мин гаҗәпләнмәячәкмен.

Флюра керә. Ул нигәдер кәефсез күренә.

Гөлназ. Менә Флюрабыз да килеп җитте.

Фирая. Гомерле булыр, нәкъ үзен сөйләп торганда килде.

Флюра. Нәрсә, мин килмәскә тиеш идеммени?

Гөлназ. Килергә тиеш идең. Тик ни өчендер гармуның юк. Син аны тавыклар ашатканда да калдырмый идең.

Флюра *(көрсенеп).* Гармуным авырая башлады әле, дуслар.

Гөлназ. Гармунның канаты — җыр, җыры бетә башлагандыр.

Флюра. Шулайдыр, мөгаен, гармуным соңгы вакытта элеккечә очынып-очынып җырламый, шыңгырдый да туктый, шыңгырдый да туктый.

Гөлназ. Җырыбызның канатын каердылар шул.

Пауза.

Флюра. Гөлназ! Дуслар. Монда барысына да мин гаепле.

Гөлназ. Син?

Флюра. Әйе, мин.

Гөлназ. Нәрсә, әллә редакциягә хатны мин яздым димәкче буласыңмы?

Флюра *(гаҗәпләнеп).* Мин яздым шул. Менә хәзер шуның өчен барыгыз каршында тезләнеп гафу сорарга килдем.

Гөлназ. Соңардың, дустым. Синнән алдарак Кирам белән Фирая бу сүзләрне әйтеп, минем каршыма тезләнделәр инде.

Флюра. Кирам беләм Фирая?

Гөлназ *(көрсенеп).* Их, дусларым. Әйбәт кешеләр сез, чын дуслар. Мансур белән безнең аралар бозылмасын дип нинди әшәке яланы да үз өстегезгә аласыз. Ә бит мин башта Кирам килеп шул сүзләрне әйткәч ышанып бетә язган идем. Мансурны юкка рәнҗеткәнмен дип йөрәгемне кинәт үкенү уты өтеп алган иде. Хәтта күңелемдә нindидер шатлыкка охшаш хис тә уянып куйган иде.

Шул вакыт мотоцикл тавышы ишетелә башлый.

Кирам. Мансур мотоциклы. Монда килә, ахры.

Мотоцикл тавышы көчәя.

Фирая. Әйе, монда килә.

Флюра. Без китик, Гөлназ.

Гөлназ. Юк, юк, китмәгез. *(Ул ялварулы караш белән дусларына карый.)*

Мотоцикл сүнә. Мансур керә.

Мансур *(ясалма көр тавыш белән).* О-о, монда бөтен компания җыелган, мине генә көтеп торалар икән. Менә мин дә килдем. Тере хыянәтчене тагын бер күреп калсыннар дидем. Юкса андый мөмкинчелек гел булмас. Карагыз миңа туйганчы.

Беркем дә эндәшми.

Мансур. Йә, авызыгызга нигә су каптыгыз? Кайчан котылырбыз икән моңардан дип торасызмы? Котылырсыз, әз генә түзсәгез, котылырсыз. Китәр алдыннан сезнең белән кочаклашып үбешергә генә кергән идем. Бәлки, сез миннән җирәнәсездер, ә? Сез бит чиста затлар.

Гөлназ. Нәрсә әле син клоунланасың?

Мансур. Ә нигә? Безгә хәзер нишләсәк тә ярый. *(Кепкасының алдын артка белән кия дә, юри авызын кыйшайтып, дуслары янынннан кыек-мыек басып үтеп-сүтеп йөри.)*

Кирам *(аның җилкәсенә сугып).* Шамакайланма, Мансур, килешми.

Мансур *(ирония белән).* Шулаймыни? Килешмимени? Сезгә килешмәс шул. Сез бит җитди кешеләр. Ә миңа килешә. *(Юри тыпыр-тыпыр биеп ала, төрлечә юләрләнә.)*

Флюра. Йә, беттеме инде, Мансур?

Фирая. Әйе, җитди сөйләшер вакыт җитте.

Мансур. Хыянәтче белән нинди җитди сүз булырга мөмкин?

Гөлназ *(кызып).* Нәрсә, һаман үзеңне гаепсез дияргә телисеңме? Ә менә бу нәрсә? *(Теге хатны күрсәтә.)* Минем исемемне менә болай итеп «Гөл» артыннан «Н» хәрефен зур белән бары тик син генә язмый идеңмени? Исеңдә булса, бервакыт болай да дигән идең: «Карале, Гөлназ, синең исемең ике матур исемнән тора икән: Гөл һәм Наз. Мин моннан соң Назны да зур хәрефтән язачакмын». Йә, шулай димәгән идеңме?

Мансур башын иеп сүзсез кала. Аннары ул Гөлназ кулындагы хатка үрелә.

Мансур. Каяле, кая?

Гөлназ. Аноним хат язуыңны онытып редакциягә дә исемемне нәкъ запискалардагыча язып җибәргәнсең.

Барсы да тын калып Мансурга текәләләр. Мансур бер хатка, бер иптәшләренә карый. Аның маңгае тирләп чыга. Ул җиңе белән маңга-

ендагы тирләрне сыпырып ташлый.

Мансур *(көчкә телен әйләндереп).* Сез дә моны мин язган дип уйлыйсызмы?

Иптәшләре эндәшми.

Мансур. Дәшмисез, димәк, шулай уйлыйсыз?

Кирам. Туктале, ни, Мансур...

Мансур. Әйе, әйе, шулай уйлыйсыз.

Гөлназ. Менә бит, карасы да син ярата торган яшел кара белән язылган. Бүтәннәрне ярата башладым дип кенә...

Мансур *(Гөлназның сүзен кисәк бүлдереп).* Ансы нәрсә тагын?

Гөлназ. Бәлки, син менә шушында Рәҗибә белән дә кочаклашмагансыңдыр?

Мансур *(гаҗәпләнеп).* Мин? Рәҗибә белән? Ха-ха-ха! Кызык була башлады әле бу.

Гөлназ *(ирония белән).* Әлбәттә. Син әле аңа, бәлки, «якын дустым Рәҗибәгә» дип фоторәсем дә бүләк итмәгәнсеңдер? Салават күпере, имеш, Сандугач, имеш.

Мансур ни әйтергә белми тора. Башкалар да шаккатып калалар. Алар бер-берләренең күзләренә карарга оялалар. Мансур аларның әле бер-

сенә, әле икенчесенә карый да кул селтәп чыгып китә.

Пырлап мотоцикл кабына. Бераздан мотоцикл тавышы ерагая.

Озак кына пауза.

Флюра. Менә аңлаштык та...

Фирая. Син, Гөлназ, катырак бәрелдең бугай.

Гөлназ *(ирония белән).* Бәлки, аның башыннан сыйпап юатырга кирәк булгандыр. И, мескенем минем, тагын шулай берәребез өстенә пычрак ат, тагын берәребезнең яңагына сук, бер яңагыбызга суккач сиңа икенчесен куярбыз дияргә кирәк булгандыр.

Гөлназ әрле-бирле йөренә, дуслары мондый аңлашуга шаһит булганга кыенсыну кичерәләр.

Кирам. Кем уйлаган, кем уйлаган! Кемдер кешегә пычак белән чәнчи, кемдер кылыч белән селтәнә. Әмма яла белән, мәкер белән яраланучылар да бар икән шул әле. Пычаклар, кылычлар гасырлар буе үзгәреш кичермәгән. Аларны таныйбыз, кем кулында икәнен күрү белән үз-үзебезне сакларга тырышабыз. Ә менә мәкергә, әшәкелеккә, ялганга дәва табу кыен. Чөнки аның чын йөзе юк. Ул бүген бер төсле, иртәгә икенче төсле. Заман белән мәкер дә үзгәрә. Астыртын мәкердән дә куркыныч нәрсә юк дөньяда.

Пауза.

Гөлназ *(дусларына).* Миңа ничектер җиңелрәк булып китте әле, дуслар. Рәхмәт сезгә. Сез дә минем турыда Мансур кебек начар уйлыйсыздыр дип җаным әрнеп йөри иде. Ә бит бик тә матур итеп яшисе килә. Кешеләрне сокландырырлык, үкенечләр белән бәгырьне телгәләмәслек итеп яшисе килә. Әмма матур итеп яшәү авыррактыр, күрәсең. Начарлык эшләр өчен, бая Фирая әйткәнчә, хәтта сәбәп тә кирәкми. Ә яхшылыкны үз җаныңның бер кисәген бирми генә эшләп булмый.

Кирам. Уф, әллә артык бөркү, әллә шушы хикмәтләр күкрәкне кыса. Су кереп алыйк. Тукаебыз тәнгә мунча бар, җанга юк, дисә дә, кайвакыт тәнең чистарса да җанга җиңелрәк булып китә. Әйдәгез, киттек су керергә.

Сагышларны салыйк суларга,
Агып китсен ерак юлларга.

Чыгарга дип җыенганда, аларның игътибарын тыр-пыр чапкан мотоцикл тавышы җәлеп итә. Барсы да мотоцикл тавышы килгән якка карыйлар.

Флюра. Нишли ул анда, тиле?
Гөлназ. Батырлыгын күрсәтергә телидер.
Фирая. Ой, тәгәри бит инде. Бар, йөгер, Кирам.
Кирам. Чаптым. *(Йөгереп чыгып китә.)*

Мотоцикл тавышы тагы да көчәя һәм кинәт сүнеп кала.

Барсы да берьюлы. Ах, очты! Тәгәрәде!

Йөгереп чыгып китәләр. Бераздан Зөфәр Мансурны күтәреп керә.
Кирам да алар белән. Зөфәр Мансурны кая куярга белми тора.

Кирам. Хәзер, җиргә куймый тор. Әнә тегендә печән күбәсе бар. Алып киләм. *(Йөгереп чыгып китә. Бераздан бер кочак печән күтәреп керә)*

Мансурны печән күбәсенә сөяп утырталар. Мансур янына Гөлназ йөгереп килә. Ул тезләнеп Мансурның чуалган чәчләрен рәтләп куя. Җиң очыннан кульяулык чыгарып аның тирләрен сөртә. Мансурның күзләре йомык, бары тик авыр-авыр тын алганлыгы ишетелә.

Гөлназ *(өзгәләнеп).* Нәрсә булды соң бу, ә? Күрәләтә кешене һәлак иттек.

Зөфәр. Шунда, кырыенда гына басып тора идем бит. Тотып кала алмадым. Их!

Кирам. Кыядан ташланган бөркетне тотып калып буламыни?

Зөфәр. Кыяга килеп җиткәч тотып калу кыен шул. Безгә аны кыяга китереп җиткермәскә иде.

Гөлназ *(сикереп торып).* Мин гаепле, барысына да — мин! Сезне колхозда калырга котыртучы да, текә ярдан ташланырга мәҗбүр итүче дә мин.

Зөфәр. Туктале, Гөлназ. Беркем дә сине гаепләргә җыенмый. Котыртканга котырырга без бит эт түгел. Без — кешеләр.

Гөлназ *(тагын Мансур янына килеп чүгәли).* Их, Мансур, Мансур, нишләдең син, ә? Карагыз әле, нишләп без врачка чапмыйбыз? Нишләп барыбыз да авызларыбызны ачып торабыз?

Зөфәр. Врачка киттеләр инде. Бер малай велосипед белән чапты.

Флюра. Уф! Авыр, бөркү, һава җитми! *(Косынкасын чишеп ата.)*

Зөфәр *(үз-үзенә сөйләнгәндәй).*
Яшәү авыр, кеше булу авыр,
Җавап табу авыр сорауларга.
Күкрәкләрне киереп кереп киттек
Тормыш тезеп куйган сынауларга.

Ашыга-ашыга Рәҗибә керә. Ул як-ягына карана.

Рәҗибә. Мансур кая, Мансур? Аны ярдан тәгәрәгән дигәннәрие.

Мансур янына җыелган яшьләр читкәрәк китәләр. Рәҗибә Мансурны күреп ала.

Рәҗибә. Мансур, нишләдең син, юләр баш? Йә, әйт, нишләдең?

*Мансурның иңнәреннән тотып селкетә, Мансур шунда күзен ача.*
*Аның күзен ачканын күреп барсы да аңа текәләләр.*

Мансур *(көчкә телен әйләндереп).* Дуслар! Те-ге хат-ны... Теге хатны мин язма... *(Сүзен әйтеп*

*бетерә алмый, хәлсезләнеп күзен йома.)*

Рәҗибә. Әй җүләр, җүләр. Әллә син шул хат өченме? Шул бер пүчтәк шаяру өченме? Соң, аны бит мин яздым. Әйе, мин яздым.

Барысы да гаҗәпләнеп Рәҗибәгә карыйлар.

Гөлназ. Син яздың?

Рәҗибә *(беркемгә дә игътибар итмичә).* Их, Мансур, мин бит сине дөньядагы барлык кызлардан көнләшеп ярата идем. Хатны да сине яратканга, сине башкаларга бирәсе килмәгәнгә яздым. Юкса сине Гөлназ үз ягына аударыр да училищега китә алмассың дип курыктым.

Мансур кузгалып куя. Барсы да аның тирәсенә якынлашалар. Мансур торырга итә. Кемдер аңа торырга булыша, кемдер егылып китмәсен дип якынрак басарга тырыша. Мансур, бераз башы әйләнеп, чайкалып басып тора. Аннары көч-хәл белән сөйли башлый.

Мансур. Дуслар! *(Хәл җыеп тора.)* Гөлназ! Гафу итегез мине! Кичерегез!

Гөлназ. Син үзең гафу ит безне, Мансур. Монда барсына да мин гаепле. Шундый әшәке яла яктым. Синең үзеңә түгел, бер кәгазь кисәгенә ышанып йөзеңә кара яктым. Их, үткәннәрне кайтарып булса.

Пауза.

Зөфәр. Ялкынланып, дөрләп көннәр яна,
Көннәр генә түгел, еллар яна.
Гомер учагында шартлый-шартлый
Җырлар яна безнең, моңнар яна.

Мансур. Дуслар! Гөлназ! Үзегезне гаепләмәгез. Монда күбрәк үзем гаепле. Мин менә бүген үземнең ихтыярсыз бер кеше икәнемне аңладым. Аттестат алу гына җитлегүне белгертми икән. Җитлегеп тормыш итәр өчен өлгереп җитмәгәнбез әле, дуслар.

Башы әйләнеп китә, дуслары аны иплән кенә тотып яткыралар. Мансур аңын җуя.

Гөлназ *(Мансурның маңгаена кулын куеп).* Врачы да нишләптер озаклады.

Рәҗибә. Их, дуслар, ә бит бу нәрсәләр шундый кечкенәдән башланып китте. *(Рәҗибәдән барсы да читкә борылалар).* Кем уйлаган, кем уйлаган? Мин моны бары тик Гөлназның мин-минлегенә сугыйм дип кенә башлаган идем. Мәхәббәтем, бәхетем өчен көрәштем мин. Әллә минем мәхәббәтем өчен көрәшергә хакым юкмы? *(Беркем дә аңа карамый, эндәшми.)* Ягез, яңагыма сугыгыз, битемә төкерегез, ләкин миннән читкә борылмагыз.

Кирам. Биткә төкерер өчен дә ул кешене күпмедер хөрмәт итәргә кирәк.

Рәҗибә. Әйе, сез хәтта минем битемә төкерергә дә җирәнәсез. Чөнки биткә төкергәндә миңа таба борылып карарга туры киләчәк. Ә сез горур рәвештә читкә борыласыз. Хәер, сезнең урыныгызда булсам, мин дә шулай эшләр идем. Горур булып йөзеңне читкә бору җиңел бит ул, ә менә горурлыгыңны җиңеп егылган кешегә кул сузу авыррак.

Еракта «ашыгыч ярдәм» машинасының сиренасы ишетелә.

Гөлназ *(тирән үкенү белән).* Гафу ит мине, Мансур. Барсына да мин гаепле. Хәер, юк, гафу итмә. Мәңге гафу итмә. Җаным өзгәләнсен, бәгърем теткәләнсен. Гафу итмә. Юкса без артык йомшак күңелле. Якыннарыбызның йомшаклыгын белгәнгә, яманлык эшләгәндә артык уйланмыйбыз. Гафу итмә. Намусым минем — палачым. Кискәләсен, туракласын мине.

Тагын машина кычкырта. Егетләр Мансурны күтәреп алып чыгып китәләр. Алар артыннан кызлар да чыга. Ләкин тиздән сәхнәнең бер ягыннан — Гөлназ, икенче ягыннан Рәҗибә чыгалар. Алар бер-берләренә карамыйлар, алар йөзләре белән халыкка борылган, халыктан гүяки алар хөкем карары көтеп торалар. Шул вакыт Зөфәр керә һәмике кыз арасына басып шигырь укый.

Зөфәр. Без һәммәбез яхшылыкка мохтаҗ,
Безнең җаннар бик тиз яралана.
Яклаучысыз йомшак күңелләрне
Ялалардан ничек араларга?

Кайчагында пычрак кулын сузып,
Арабызга килеп керә мәкер.
Кайтмый ләкин, кайтмый һич әйләнеп
Узган гомер белән калган хәтер.

Бәреп егам, бәреп егам диеп,
Бер җай гына көтеп йөри ялган.
Егыл гына, бары егыл гына —
Таптаучылар табыла сине аннан.

Беркемгә дә яшәү җиңел түгел,
Хакыйкать ул бик тирәндә ята.
Яшәү мәгънәсенә төшеник без,
Узганнарга кабат кайта-кайта,
Ялгышларны бәреп вата-вата.

Пәрдә.

*1987*

# ҖИМЕРЕЛГӘН ХЫЯЛЛАР

*(Ике пәрдәле драма)*

**КАТНАШАЛАР:**

Гөлназ.
Мансур.
Зөфәр.
Рәҗибә.
Фирая.
Кирам.
Сәвия — 17 яшьтә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

«Кызлар күңеле — тирән сер» драмасындагы геройлар ун елдан соң очрашырга булганнар. Очрашу Фирая белән Кирамнар өендә. Арткы планда Кирамнарның ике катлы, челтәрле балконлы матур йортлары күренә. Ишегалдында әтәч кычкырган, ат кешнәгән тавышлар ишетелә. Пәрдә ачылганда Фирая берүзе. Ул бакчадан матур чәчәкләр җыеп алып керә. Җырлый-җырлый чәчәк бәйләмен матурлый.

Фирая. Чәчәкләрнең җыйдым төрлесен,
Дусларыма матур күренсен.
Шушы матур гөлләр,
Шушы матур көннәр
Искәртсеннәр туган җир төсен.

Теләгәннәр алын алсыннар,
Теләгәннәр алсын сарысын.
Минем гөлләремнән
Дуслар йөзләренә
Таңнар алсулыгы ягылсын.

Чәчәкләрен эскәмиягә куя да Кирамга кычкыра.

Фирая. Кирам, ә, Кирам?

Кирам тавышы: Нәрсә, әнкәсе, адаштыңмы әллә?

Фирая. Нишлисең син анда? Ташлап тор әле шул эшләреңне.

Кирам күренә. Аның кулында йөгән.

Кирам. Ни булды, әнкәсе?

Фирая. Кунаклар кайта башлар, ә син һаман шул атларыңнан аерыла алмыйсың. Өс-башларыңны алыштыр.

Кирам *(шаярып)*. Мин болай да матур бит. Син кайгырма, әнкәсе. Килгән кунаклар кире борылып китмәсләр.

Фирая. Китмәсәләр дә, болай йөрү яхшы түгел. Дусларыбыз каршында минем сине бөтен кешедән матуррак итеп күрәсем килә.

Кирам. Эш кием алыштыруда гына булса, без хәзер. Солдатта кырык биш секундта киенә торган идек. Сәгатеңә карап тор. *(Тиз генә өйгә кереп китә).*

Фирая *(сәгатенә карап).* Бер, ике, өч... *(Шул вакыт күке кычкырган тавыш ишетелә.)* Ялгыштырма әле, күке. *(Санавын дәвам итә.)* Биш... Алты... Җиде... *(Кинәт әтәч кычкырып җибәрә.)* Нишләп барыгыз да мине буташтырырга торасыз соң әле? *(Санавын дәвам итә.)* Сигез... Тугыз...

Эт өрә башлый. Фирая эт өргән якка борылып караса, анда эт тавышы чыгарып Кирам басып тора. Ул өс-башын алмаштырып өлгергән.

Фирая. Әй, син шаяртып йөрисең икән әле.

Кирам. Минем синең белән гел шаярып торасым килә, матурым.

Фирая. Өйләнешкәнгә сигез ел бит инде. Акыл утыртырга вакыт.

Кирам. Акыллылар шаярырга тиеш түгелмени? *(Фираяны күтәреп ала да бөтерә башлый.)*

Фирая. Төшер, башымны әйләндерәсең.

Кирам. Әйләнсен. Син минем башымны күптән әйләндердең инде. *(Фираяны җиргә бастыра.)*

Фирая. Әйдә утырыйк әле. Кунаклар кайтып җиткәнче, бераз хәл алыйк.

Эскәмиягә утыралар.

Кирам. Ял итү зарар итмәс ансы. Юкса эш атына әверелеп бетүебез бар.

Фирая. Син бигрәк алны-ялны белмисең.

Кирам. Үзең соң, үзең. Юньләп йоклаганың бармы?

Фирая. Картайгач йокларбыз әле.

Кирам. Ансы шулай. *(Йортларына ымлап.)* Карале, әнкәсе, ничек балкып утыра.

Фирая. Нәрсә?

Кирам. Нәрсә булсын! Безнең йортыбыз.

Фирая. Утырмыйча! Без салдык бит аны.

Кирам. Әйе, Фираям, без салдык. Мәңге җимерелмәслек итеп. Нигезен дә, үзен дә таштан. Кем уйлаган фермер булырбыз, үзебезнең ике катлы йортыбыз булыр дип. Элегрәк бу хакта хыялланырга да курка идек бит.

Фирая. Хәтереңдәме, унны бетергәч авылда калам, атлар карыйм, атсыз авыл — хуҗасыз йорт ул, ди идең. Колхозда атлар карыйсың булмады, үзебезнекен карыйбыз.

Кирам. Шулай, Фираям. Ходай безгә бәхетне кушучлап бирде. Күпсенмәсен генә. *(Хискә бирелеп.)*

Төшләремдә дә мин атлар күрәм,
Гел шул тынгы бирми җаннарыма.
Томырылып чапкан яшь тайларның
Барып ябышамын ялларына.

Очам, очам зәңгәр офыкларга,
Күтәреләм ярсу болытларга.
Таш сибелә тояк асларыннан,
Җилләр сыйпый кайнар башларымнан.

Фирая. И-и, хыялый. Әллә шигырьләр дә яза башладың инде.

Кирам. Ат ул — үзе шигырь. Шигырьнең дә иң матуры, иң камиле.

Фирая. Нигә мин дә яхшы токымлы ат булып тумадым икән?

Кирам. Нигә, әнкәсе?

Фирая. Син бит атларыңны шундый иркәлисең. Атларга караганда, «керфегеңнән гөлләр тама». Һәрберсен бала коендыргандай коендырасың, шампуньнар белән юасың, йоннарын, ялларын тарыйсың. Мин синең атларыңнан көнләшәм.

Кирам. Ә мин синең машинаңнан көнләшсәм? Син дә бит машинаңны баладан ким назламыйсың. Көндезләрен басу юлларында чабасың. Синеңчә эшләмәсәләр, кәефең кырыла. Эксплуататорга әйләнеп барабыз түгелме?

Фирая. Без бит элек үзебез каргаган капитализмга барабыз.

Кирам. Әйе.

Фирая. Кайберәүләр уйлаганча, фермер булу мич башында таракан дагалап яту гына түгел икән. *(Сикереп тора.)* Карале, Кирам, бу якка бер машина килә түгелме? Бәлки, безнең кунаклардыр.

Кирам белән Фирая машина тавышы ишетелгән якка карыйлар. Бераздан машина тавышы ераклаша.

Кирам. Юк, безнекеләр булмады.

Фирая. Син ничек уйлыйсың, Кирам, иң беренче кем кайтыр икән?

Кирам. Мансур, әлбәттә.

Фирая. Нигә Мансур?

Кирам. Соң, ерактагы кеше һәрвакыт чабатасын алдарак кия. Якындагылар өлгерермен әле дип яталар.

Фирая. Без хәзер кемнең еракта, кемнең якында икәнен дә ачык кына белмибез. Гөлназлар, Рәҗибәләр бер карыйсың Казанда, икенче карыйсың Төркиядә.

Кирам. Моннан ун ел элек, кулга өлгергәнлек аттестаты алганда заманалар болай үзгәрер дип кем уйлаган.

Фирая. Әйе, бер шагыйрь әйтмешли:

Көтмәгән-уйламаганда,
Үзгәрде куйды дөнья.
Күпләр кыйбласын югалтып,
Адашып йөри юлда.

Кирам. Кыйбласын югалтмаганнар да җитәрлек. Әнә үзебезнең Мансурны гына ал. Тәки үзенекен итте — очучы булды.

Фирая. Карале, Кирам, син ничек уйлыйсың: безнең Мансурыбыз кайларда, ягъни мәсәлән, нинди йолдызлар астында йөри икән? Ул бит өйләренә дә ачык кына язмый, ди. Гөлназ белән дә аралары бозылды. Ә бит берсен- берсе ничек яраталар иде!

Кирам. Кешене түгел, үзеңне дә белеп булмый хәзер. Дөньясын әйтәм: үзе әйбәт, үзе начар, үзе матур, үзе ямьсез. Ничектер кырысландык, үз эчебезгә йомылдык. Безнең Зөфәр ничек яза әле?

Әй бар иде яшь чаклар,
Кесә тулы борчаклар.
Дусларга да, дошманга да
Ачык иде кочаклар.

Үтте-китте ул чаклар,
Коелдылар борчаклар.
Хәзер инде кесәләрдә
Борчак түгел, пычаклар.

Фирая. Үткән заман һәрвакыт матуррак күренә, диләр. Әнә безнең әниләрне генә ал: гомер буе ачлы-
туклы яшәгәннәр. Алмашка рәтле-башлы күлмәкләре булмаган, көне-төне колхозга бил бөккәннәр, ә барыбер элеккене сагыналар. Ленин, Сталин рәсеме күрсәләр, балкып китәләр.

Кирам. Әйе. Үткәннәр сагыныр өчен, киләчәк хыялланыр өчен, диләр бит.

Фирая. Ә бүгенге көн ни өчен?

Кирам. Бүгенге көнме? Бүгенге көн үткәннәрне сагынып, киләчәккә матур өметләр корып көне-төне эшләр өчен.

Көлешеп алалар. Машина тавышы ишетелә.

Фирая. Кунаклар кайтты, ахры. Каршылыйк. *(Капкага таба китәләр. Аларның каршына Рәҗибә белән Гөлназ килә.)*

Кирам *(боларга ымлап).* Бер казанга сыймый торган ике тәкә башы.

Фирая. Заман тәкәләрнең мөгезләрен сындыргандыр, күрәсең.

Рәҗибә белән Гөлназ Фираяларга якынлаша. Рәҗибәнең кулында әллә ничә төенчек. Өстендә бераз зәвыксызрак кием. Гөлназ дин әһелләренә охшатып киенгән. Башында ак яулык, өстендә озын ак
күлмәк. Бу кием аны тагын да матурлатып җибәргән.

Гөлназ. Әссәламәгаләйкем, кардәшләр-милләттәшләр! Исән-сау гына яшисезме? Бала-чагаларыгыз сәламәтләрме?

Кирам. Шөкер әле, Гөлназ абыстай. Тәннәребез сау-сәламәт, күңелләребез тыныч, бала-чагаларыбыз тәгәрәшеп үсә.

Рәҗибә.Балаларыгыз ничәшәр яшьтә?

Фирая. Берсе — җидедә, икенчесе биш яше белән бара. Нигә әле алар кирәк булды?

Рәҗибә *(бер төенчеген актарып).* Менә минем монда бик шәп кәчтүмнәр бар. Төркиянең элитный кибетләреннән сезнең кебек фермер балаларына дип сайлап алган идем. Бәяләре дә кыйммәт түгел. Хәер, сезнең кебек алпавытларны бәя куркытмый торгандыр. Өйләрне әнә ничек салып җибәргәнсез.

*(Кәчтүмнәрен чыгарып күрсәтә.)* Йә, ничек? Аласызмы? Сез алмасагыз, хәзер кулдан йолкып алып бетерәчәкләр аларны.

Гөлназ. Туктагыз әле, кардәшләр-милләттәшләр, башта бер дога кылыйк. *(Утыра.)* Әлләһүммә әнзәлин мүнзәлән мүбәракәү йә әнтә хәйрүл мунзалин. *(Һәммәсе Гөлназ артыннан доганы пышылдап, битләрен сыпырып куялар.)*

Кирам. Кемне-кемне, әмма, Гөлназ, сине абыстай булып китәрсең дип уйламаган идем.

Гөлназ. Дөньядагы барча бәндәләр дә — Алла коллары. Бәндәнең тәкъдиренә ни язылган булса — шуны кылыр. Башыбыздагы бер бөртек сач тә Аллаһы Тәгалә кодрәтеннән башка төшмәс.

Кирам. Алай, алай.

Гөлназ. Ничек соң, мөслимә Фирая, Мансурлар, Зөфәрләр, Флюралар кайтамы?

Фирая. Мансурлар, Зөфәрләр кайтыр, ә менә Флюра...

Гөлназ. Нәрсә Флюра?

Фирая. Флюрабыз бервакытта да кайта алмас шул инде...

Гөлназ. Бик ерак киттемени?

Фирая. Әйе, әйләнеп кайтмый торган җиргә китте безнең Флюрабыз.

Рәҗибә. Бәрәч, мин дә ишетмәгән идем бит әле, Флюра Әмрикәгә киттеме әллә?

Фирая *(көрсенеп)*. Ераккарак, тагы да ераккарак.

Рәҗибә. Башымны катырмагызсана. Үлмәгәндер бит?

Кирам. Юк, үлмәде, шаһит китте.

Рәҗибә. Ансы ничек була тагын?

Кирам. Ансы башкалар тормышы өчен үзен корбан итү була. *(Уйланып.)* Әйе, юләр башлар дөньяга ут төртә, акыллылар юләр башларның хаталарын төзәтәм дип шаһит китә. Их нинди шәп кыз иде бит Флюра. Аның үлемен ишеткәч, Зөфәрнең өзгәләнүләрен күрсәгез... Андый җәзаны Ходай күрсәтмәсен.

Гөлназ. Флюраны андый язмыш көтәдер дип кем уйлаган?! Арабызда иң саф, иң керсез күңелле дустыбыз иде.

Фирая. Ичмасам, гәүдәсен дә алып кайтып күмә алмадылар. Кайдадыр шунда биек таулар өстенә күмелгән, диләр. Ә гармунда ничек уйный иде бит. *(Күзеннән яшьләрен сөртеп ала.)*

Рәҗибә. Флюраның медсестралыкка укыганын беләм идем. Медсестраларны да сугышка, хәзергечә әйтсәк, «кайнар нокта»ларга җибәрәләрмени?

Фирая. Флюра җибәргәнне көтеп тора торган кыз идемени ул.

Кирам. Әйе, гаскәриләр тыныч халык өстенә бомба яудыра, олысын-кечесен кылычтан үткәрә башлагач, минем урыным шунда, диде дә китте дә барды.

Гөлназ. Әйдәгез әле, карендәшләр, үлгәннәр рухына бер дога кылыйк. *(Дога укый.)* Иннәә лилләһи вә иннә иләйһи раажигон, ягъни без барыбыз Аллаһы Тәгаләнекедер вә һәркайсыбыз Аллаһы Тәгаләгә кайтачакбыз. Тәкъдирендә шулай язылган булса, бәндә берни кыла алмый. Шәһит киткәннәрнең урыны җәннәттә булыр, Алла бирсә.

Кирам. Бөтенесен тәкъдиргә сылтау җиңел, әлбәттә. Тып-тыныч халык өстенә бомбалар яудырып, кешеләрне яшәп яткан өйләреннән куып чыгаручыларга, асарга-кисәргә, бер гөнаһсыз балаларны әнкәләренең куенныннан тартып алып утка ыргытырга да тәкъдир кушканмы? Әгәр беләсең икән, әйт, Гөлназ: үтерүчегә кеше үтерү тәкъдирдә язылганмы?

Гөлназ. Көфер сүз сөйлисең, Кирам.

Кирам. Мин сорау гына бирәм һәм шул сорауга җавап эзлим. Нәрсә килеп чыга соң монда: әгәр кешеләрнең кылачак һәр гамәле алдан ук тәкъдирләренә язып куелган икән, димәк, үтерүче үз гамәле өчен Алла каршында да, бәндә каршында да җавап тотмый дигән сүз. Чөнки ул тәкъдирдә язылганнан читкә чыга алмый. Шуңа күрә гөнаһсызларны үтерә, өеннән куып чыгара, соңгы сынык икмәген тартып ала. Шулаймы?

Рәҗибә. Туктатыгыз әле шул фәлсәфә сатуларыгызны. Юкса бөтен дөньяны сүз боткасы басып китеп бара. Телевизорда — шул, гәҗитләрдә — шул. Чүбек чәйнәп тамак туймый. Менә миндә конкретрак әйберләр бар: кайсыгызга нәрсә кирәк, җыелышыгыз минем тирәмәрәк. *(Сумкаларын, капчыкларын чишеп җибәрә. Такмаклап.* )

Бүген бездә ярминкә,
Кала күрмәгез читтә.
Нәрсә кирәк, бар да бар,
Җәй көнендә кар да бар.

Менә монсы күлмәктер,
Товары шәп ефәктер.
Ука белән чигелгән,
Оста кулда тегелгән.

Итәкләре ярыклы,
Путалары койрыклы.
Төймәләре алтыннан,
Курыкмагыз хакыннан.
Алыгыз, ал, дусларым.

*(Әйберләренең кайсын Кирамның иңенә сала, кайберсен Фираяга тоттыра, кайберсен Гөлназ алдына китереп селки.)*

Сәвия керә. Ул кыюсыз гына исәнләшә.

Сәвия. Исәннәрмесез! *(Өйдәгеләр аны күрмиләр.)*
Рәҗибә. Заграничный башмаклар,
Чынаяктай ап-аклар.
Моны киеп җибәрсәң,
Биеп китәр аяклар.

Суыкларда — җылытыр,
Җылыларда — суытыр.
Бу башмакны кигәннәр
Бар кайгысын онытыр.
Сәвия *(тамак кырып).* Исәннәрмесез!
Рәҗибә. Әй, күрми дә торабыз. Ярминкәгә кеше килгән икән. Йә, нәрсә аласың, матурым?

Сәвия нидер әйтмәкче була. Ләкин Рәҗибә аңа авыз ачарга ирек бирми.

Сәвия. Бусы сиңа күлмәклек,
Бусы сиңа итәклек.

Сәвия башын читкә бора.

Рәҗибә. Трусикмы, лифчиклармы? *(Капчыкларын актара.)* Алары да җитәрлек.
Сәвия. Юк, юк, апа. Миңа...
Рәҗибә. Ә белдем, белдем.
Кершән, иннек кирәкме?
Француз хушбуйларымы?
Француз хушбуйлары сөртсәң,
Үстерер буйларыңны.
Сәвия *(куллары белән селтәнеп).* Юк, апа, китегез әле. Мин монда...
Рәҗибә *(Сәвиянең әле алдына, әле артына төшеп).*
Шикәр, димә, бал, диген,
Юк, димә син, бар, диген.
«Бар» диденңме — булачак,
Бөтен эшең уңачак.
Фирая. Интектермә инде баланы, сүзен әйтергә ирек бир.
Рәҗибә. Мин интектермим, сату итәм. Базар мөнәсәбәте диләр аны, җаным. *(Кирамнарга, Гөлназларга.)* Әйдәгез әле, сез дә бераз укаларыгызны коегыз.
Энҗе-мәрҗән алкалар бар,
Асылташлы йөзекләр.
Фермерларда булмый калмас
Яшел башлы йөзлекләр. *(Гөлназга.)*
Әйдә син дә, абыстай,
Актар кесә төбеңне.
Хәер керер дә китәр —
Әллә шулай түгелме?
Фирая, Гөлназ башта теләр-теләмәс кенә әйберләрне актаралар, аннары мавыгып китеп бер-берләренә күрсәтәләр. Ефәкләргә урала-урала әйләнәләр.
Фирая. Әй ярминкә, ярминкә,
Гөлназ. Һәммәбезне бай итә.
Әйрәннәрне май итә,
Кесәләрне сай итә.

Әйләнгән вакытта түгәрәккә Сәвияне дә эләктермәкче булалар, ләкин Сәвия читкә тайпыла.

Сәвия *(ярсып).* Туктатыгыз әле бу ахмак уеннарыгызны.
Рәҗибә. Ахмак уен түгел, тормыш бу, үскәнем. *(Сәвиянең колагына.)* Ә бәлки, сиңа «тегендә»

кыстыра торган нәмәстәкәй кирәктер?
Сәвия. Әйтер идем инде үзегезгә, телем ояла.
Рәҗибә. Ә нигә оялырга? Аларны акыллы капиталистлар уйлап тапкан. Капиталист кирәкмәгән нәрсә чыгармый ул.
Сәвия. Миңа Зөфәр абый кирәк. Ишетәсезме, Зөфәр абый.
Гөлназ. Зөфәр?
Сәвия. Әйе, Зөфәр абый.
Гөлназ. Нигә кирәк сиңа Зөфәр абыең?
Сәвия. Зөфәр абый — бөек шагыйрь. Аны бер күрү — олы бәхет.
Рәҗибә. Китапсыз шагыйрь. Ничә ел шигырь язып йөргән була, чыпчык канаты хәтле китап чыгара алганы юк. Аның бөеклеген ничек белеп була соң?
Сәвия. Кояшның — кояш, йолдызның йолдыз икәнен ничек белеп булса — шулай.
Рәҗибә. Алай әйберне бер карауда аера торган сәләтең булгач, нигә авылда әрәм булып ятасың. Әйдә киттек шәһәргә. Зур бизнеска алып керәм мин сине.
Сәвия. Кем әйтте әле сезгә мин авылда әрәм булып ята дип?
Рәҗибә. Алайса нишлисең соң син авылда?
Сәвия. Бәлки, мин авыл әрәм булмасын өчен монда яшимдер.
Бар да. О-о! Менә әйтте ичмасам.
Кирам *(гаҗәпсенеп).* Нишләптер танып җиткермим, кем кызы әле син? Күргәнем бар төсле үзеңне.
Сәвия. Мин татар кызы!
Кирам. Шулаймыни? Мин сине танымаган идем.
Сәвия. Танымассыз шул. Чөнки сезнең күзләрегезне байлык томалап килә.
Гөлназ. Ничек әле син яп-яшь башың белән үзеңнән өлкән кешегә шулай әйтә аласың?
Сәвия. Яшьлек ул юләрлек дигән сүз түгел. Дөньяның күзен яшьләр ачарга тиеш. Ә бүген дөньяның күзендә канлы яшь. *(Пафос белән шигырь укый.)*

Дөнья үкси шомлы итеп,
Тыңлап ятсаң куркыныч.
Гүя дөньяның өстендә
Эленеп тора зур кылыч.

Таң атса да тынычлык юк,
Таң борынынннан кан тама.
Бәргәләнә кеше җирдә,
Таңнар булып җан яна.

Дөнья авыру, канлы яше
Тама җиргә чулт та чулт.
Дөньяның яшен сөртергә
Кемнәр бирер кулъяулык.

Фирая. Әллә үзең яздыңмы моны, сеңлем?
Сәвия. Их, сез. Әллә үзең яздыңмы дип сорап торасыз. Үзегезнең классташыгыз, авылыбызның даны — Зөфәр Фәттахов шигыре бу.
Рәҗибә. Белмәгән идем.
Сәвия. Сез сату-алуны гына беләсез, ахры.

Чыгып китә.

Кирам. Кара син бу кызыйны. Ничек дип әйтте әле?
Дөнья авыру, канлы яше
Тама җиргә чулт та чулт.
Дөньяның яшен сөртергә
Кемнәр бирер кулъяулык? —
диме?
Рәҗибә. Кулъяулык кирәк булса, менә миндә бик күп. Алыгыз, сөртегез.
Гөлназ. Синең кулъяулыкларың гына җитмәс шул дөньяның күз яшен сөртергә. Ә бит Зөфәрнең мондый шигыре дә бар:

Авыр, авыр, заманалар авыр,

Авыр, авыр, яшәү бик авыр.
Соңгы өметләрне базарларда
Кемнәр сатар безнең, кем алыр?

Кирам *(дәвам итә).*
Авыр, авыр, тугры калу авыр,
Җанны саклап калу бик авыр.
Җаннарны да базарларда сатсак,
Киләчәккә бездән ни калыр?

Һәммәсе бергә. Ни калыр?

Пәрдә.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Арлы-бирле Зөфәр йөри. Ул шигырь укый.

Агыла болытлар, агыла,
Авыры, саллылары!
Болытлар булып агыла
Кемнәрнең кайгылары?!

Коела җиргә йолдызлар,
Күкнең юк терәкләре.
Йолдызлар булып атыла
Кемнәрнең йөрәкләре?!

Өзелә яфраклар җилләрдә,
Өзелмәс кебекләре.
Яфраклар булып сибелә
Кемнәрнең өметләре?!

Китәләр кошлар, китәләр,
Урап-урап күкләрне.
Кошларга ияреп китә
Кемнәрнең яшьлекләре?!

Котыра җил, сүнә учак,
Сибелә көл-күмерләре.
Көл булып җиргә сибелә
Кемнәрнең гомерләре?!

Сәвия керә. Ул кыймшанырга да куркып Зөфәрне тыңлый. Аның кулында чәчәк. Зөфәр шигырь укуыннан туктагач, ул урыныннан кузгалып куя. Зөфәр тавыш килгән якка карый.

Зөфәр. Кем бар монда?
Сәвия. Бу мин — Сәвия.
Зөфәр. Сәвия? Ә-ә, шигырьләр яза торган Сәвия бит әле син, әйеме?
Сәвия. Әй, шигырьләр язуны ташладым инде мин.
Зөфәр. Нишләп?
Сәвия. Бөтен дөньяда афәт, кан, яшь, сугыш. Шундый вакытта шигырьләр язып буламыни?
Зөфәр. Алайса, мин дә шигырь язуны ташларга тиеш буламмы?
Сәвия. Сез нәрсә, Зөфәр абый?! Сез бит шигырь язар өчен яратылган. Сез заманның кыңгыравы, чаңы. Сез йокымсыраган халыкны уятырга тугансыз.
Зөфәр. Бик каты чыңлый башласа, кыңгырауларның да телләрен тартып өзәләр, сеңлем.
Сәвия. Чын шагыйрьләр җырлауның барыбер җаен таба. Сез халыкны уятырга туган. Сезнең миссия пәйгамбәрләрнеке кебек.
Зөфәр. Артык зур таләпләр куясың түгелме син миңа, сеңлем?
Сәвия. Сез үзегезнең мөмкинлекләрегезне белеп бетермисез, Зөфәр абый.
Зөфәр. Бәлки.

Ишәккә әйләнеп беттек,
Ишәктәй эшли-эшли.
Телләргә төерләр чыкты
Телләрне тешли-тешли. *(Зөфәр уйланып йөри.)*

Аттан ишәккә әйләнгәч, яңадан атка әйләнүләр авыррак шул, Сәвия сеңлем.

Сәвия. Ә сез атка әйләнмәгез, сез бит — Кеше! Телләрегездәге төерләрегезне тешегез белән шартлатып өзегез дә горур, мәһабәт, ирекле булыгыз!

Зөфәр. Авызлыкларны өзеп алга чабарга соң түгел микән инде. Безне бит телләрне тешләп яшәргә өйрәттеләр. *(Шигырь укый.)*

Өйрәттеләр уйламаска,
Йөрәк тавышын тыңламаска.
Артык биек үрелмәскә,
Бик зур булып күренмәскә.

Кушмаганны эшләмәскә,
Өстеннәрне тешләмәскә.
Артык туры карамаска,
Шауламаска, дауламаска.

Шауламадык, дауламадык,
Халык телен аңламадык.
Акыллыны — санламадык,
Эшләгәнне — данламадык.
Ашыкмадык, йөгермәдек,
Бик биеккә үрелмәдек.
Шулкадәре кечерәйдек, —
Дөньяга һич күренмәдек.

Сәвия. Сезнең бит мондый шигырегез дә бар, Зөфәр абый.

Горурлыгы олы булса,
Күңелендә җыры булса,
Җырлап атлар җыры булса —
Димәк, әле халык исән.

Тураерга биле булса,
Күтәрергә иңе булса,
Авызында теле булса —
Димәк, әле халык исән.

Зөфәр. Рәхмәт, Сәвия. Минем иҗатны әйбәт беләсең икән.

Сәвия. Сез бит... Сез бит, Зөфәр абый...

Зөфәр. Берүк идеаллаштыра күрмә. Кешеләрнең фаҗигасе — кешеләрне идеаллаштыруда. Идеаллар бервакыт искерә, кумирлар күмергә әйләнә, менә шуннан инде табынучыларның фаҗигасе башлана.

Сәвия. Юк, Зөфәр абый, мин сезнең белән килешмим. Кешеләрнең идеалы булырга тиеш. Кешеләр хәзер ни өчен көтүчесез калган көтү кебек анда-монда бәргәләнәләр дисез? Чөнки аларның идеаллары юк. Кеше һич югы әнә шул күңелендә туган камиллеккә омтылырга тиеш.

Зөфәр. Син үзең үк шул нәтиҗәгә килдең. Кешеләр идеалларын югалттылар, дидең. Булса югалтмаслар иде. Ә без юкка ышанып алдандык.

Зур иде безнең идеаллар,
Зур иде безнең максат.
Яңа тормыш кормак булдык,
Искенең барсын таптап.

«Акка» — «кызылга» аердык
Кылыч белән дөньяны.
Ә бит шул ук кызыл иде
«Ак» дигәннең дә каны.

Атаны улдан аердык,
Аналарны — кызыннан.
Дөньяга кигертергә дип,

Күлмәк тектек кызылдан.

Зөфәр белән Сәвия янына башкалар керә.

Рәҗибә. Менә кайда яталар икән болар бездән качып. Беләсе иде, нишләп йөриләр икән болар?!

Фирая. Егет белән кызның нишләп йөрүе билгеле инде, әлбәттә. Мәхәббәт турында сөйләшәләрдер.

Сәвия *(Фираяга).* Сез ничек шулай әйтә аласыз? Беләсез бит Зөфәр абыйның күңелендә нинди яра ятканын.

Рәҗибә. Чөйне чөй белән чыгаралар, үскәнем.

Сәвия. Зөфәр абыйның шундый дуслары бардыр дип уйламаган идем.

Рәҗибә. Нинди була инде ул шундый дигәнең?

Сәвия. Спекулянтлар, остабикәләр һәм башкалар...

Рәҗибә. Без спекулянт түгел, бизнесмен булабыз.

Гөлназ. Безне хөкем итәргә синең башың яшь әле, сеңлем.

Сәвия. Сезне заман хөкем иткән инде. Сез барыгыз да ярык көймәдә утырып калгансыз. Көймәгез көннән-көн төпкә бата. Үзегез шуны күрмисез. Чукраклар, сукырлар сез. Сезне хәтта батып барган җирегездән коткаручы да юк. Чөнки һәркем үзе белән генә мәшгуль.

Кызып чыгып китә. Пауза.

Зөфәр *(Дәрдемәнднең «Кораб» шигырен укый).*

Шаулый диңгез...
Җил өрәдер...
Җилкәнен киргән кораб!
Төн вә көндез
Ул йөридер
Юл бара ят ил карап.
Чыкты җилләр,
Купты дулкын —
Ил корабын җил сөрә.
Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тарта безне җан сорап.

Кирам. Минемчә, без вакыйгаларны артык драматизировать итәбез.

Фирая. Әйе, җирдә әле икмәк үсә, колыннар кешни, кошлар сайрый.

Гөлназ. Әйдә үзеңнең берәр шигыреңне укы әле, Зөфәр.

Зөфәр. Нинди шигырь укыйм икән соң сезләргә?

Гөлназ. Иң соңгысын укы.

Зөфәр. Соңгы шигырьне язарга иртә әле миңа. Иң яңасын укысам гына инде.

Гөлназ. Иң яңасын укы алайса.

Зөфәр. Ярар, укыйм. Ләкин ул сезнең күңелләрегезне төшермәс микән? *(Укый.)*

Артка карыйм — артта тузан,
Алга карыйм — алда томан.
Туктыймын да уйланамын:
Барабызмы дөрес юлдан?

Уңда бушлык, сулда бушлык,
Ялгыш бассаң — төштең очып.
Тирән упкын төпләрендә
Кемнәр елый мышык-мышык?!

Ай һәм кояш инде сүнгән,
Өмет үлгән, идеал үлгән.
Аера алмый фәрештәләр
Көнне — төннән, төнне — көннән.

Кайда тау һәм кайда диңгез,
Караңгыда бар да тигез.
Кычкырырлык хәле дә юк,
Бәргәләнә — дөнья өнсез.

Беразга бар да тын тора.

Фирая. Әйе. Күңелне күтәрә торган шигырь түгел бу.
Зөфәр. Хәзер мин бер пессимистка әйләнеп барам инде.
Рәҗибә. Сиңа чынлап та Флюраңны оныттырырга бер кыз кирәк.
Кайсыгызның кулы йомшак,
Йөрәгемне бәйләргә! —
дигән бит Хәсән Туфан да.
Зөфәр. Флюраны алыштырырлык кыз юк ул.
Янды-янды, шартлап-шартлап янды
Киләчәккә булган өметләр.
Замананың төпсез казанында
Кайнап акты безнең җелекләр.
Гөлназ. Чынлап та бер пессимистка әйләнгәнсең бит син, Зөфәр.
Зөфәр. Мин кайберәүләр кебек иманымны алыштыра алмыйм.
Гөлназ. Миңа төрттерүең инде бу синең, Зөфәр. Ләкин бит мин иманымны алыштырмадым.

Зөфәр нидер әйтергә тели. Ләкин Гөлназ аны бүлдерә.

Гөлназ. Тукта, тукта, мин әле әйтеп бетермәдем. Син уйлыйсың инде: Гөлназ элек комсомол секретаре иде, хәзер абыстай булган, дип. Беренчедән, мин абыстай түгел, мөгаллимә. Мин мәдрәсәдә шәкертләр укытам. Икенчедән, кеше үткән тормышында ниндидер хаталар табып, тормышын икенче якка бора икән, бу син уйлаганча иман алыштыру түгел, ә яхшылыкка омтылу.
Зөфәр. Ә нәрсә соң ул начарлык һәм яхшылык?
Гөлназ. Син мине алай ук наданга санама, Зөфәр туганым. Мин башта совет университетында дүрт ел укыдым. Аннары Бохарада — өч, Истанбулда ике ел белем эстәдем. Аллага шөкер, начарлыктан яхшылыкны гына аера алам.
Зөфәр. Комсорг чагында да син яхшылыкка омтылдың түгелме? Нәрсә үзгәрде соң?
Гөлназ. Кыйблабыз үзгәрде. Минем генә түгел, бөтен илнең кыйбласы үзгәрде.
Зөфәр. Кыйбла үзгәрергә тиеш түгел. Әгәр син намазыңны бүген бер, иртәгә икенче якка карап укый башласаң, нәрсә килеп чыгар?
Гөлназ. Бәлки, син хаклыдыр, мин бик үк дөрес әйтмәгәнмендер. Әмма мин шуңа нык ышанам: кешеләрнең аңы катып калган бер нәрсә түгел. Без гомер буе эзләнәбез. Хакыйкатькә кайчак бик-бик әкрен якынаябыз, ләкин барыбер якынаябыз. Әгәр без коммунистларның идеалларына табынганбыз икән — бу безнең ялгышуыбыз дип каралырга тиеш түгел.
Зөфәр. Алайса, нәрсә дип каралырга тиеш соң?
Гөлназ. Хакыйкатькә бару юлындагы бер киртә дип. Вакыт җитте, һәм без ул киртәне алып ташладык. Шуңа күрә мин үземне иман алыштырдым дип түгел, ә бәлки иманыма якынайдым дип саныйм.
Зөфәр. Ул киртәләрне алай җайлы алып ташлап булсачы.
Гөлназ. Мәсләгебез шулай тиз үзгәрә алган икән, димәк, ул ныклы булмаган. Шуңа күрә аңа ябышып ятуда мәгънә калмады. Үзебезне акыллырак, мәгънәлерәк, саваплырак эшкә багышлар вакыт җитте.
Зөфәр. Савап... Гөнаһ... Дөнья шулай савап белән гөнаһтан гына торамыни соң? Ләкин гөнаһтан савапны да аерып булмаган чаклар әзмени?
Рәҗибә. Син, Зөфәр, бигрәк инде. Печәннән саламны сыер да аерган кебек, гөнаһтан савапны да һәр җүләр аера.
Зөфәр. Алайса, бер мисал алыйк: әйтик урамда бер хәерче утыра ди. Үткән-сүткән кеше аңа хәер биреп китә. Синеңчә, хәер биргән кеше саваплырак эш эшлиме, әллә алганымы?
Гөлназ *(бераз үпкәләп)*. Биргәне, әлбәттә.
Зөфәр. Ә ни өчен биргәне?
Гөлназ. Соң, бу бит инде юләргә дә ап-ачык.
Зөфәр *(башкаларга)*. Ә сез ничек уйлыйсыз?
Рәҗибә. Син безне дуракка саныйсыңмы, Зөфәр. Хәләл акчаны чыгарып салу җиңел дип беләсеңме әллә?
Фирая. Әйе, тир белән тапкан акчаңны урамдагы хәерчегә өләшәсе килми. Күңел каршылыгын җиңеп кенә бирелә ул хәер акчасы.
Зөфәр. Бәлки, ул эчкечедер, син аның эчәренә акча биреп аны тагын да начарлыкка этәрәсең түгелме? Шулай булгач, син хәер биреп начарлык эшләдең бит.
Гөлназ. Ә бәлки, аның өендә балалары, әнкәбез ипи алып кайтса, бер туйганчы ашар идек, дип зар елап утырадыр.

Зөфәр. Алай да булуы мөмкин. Инде бу мәсьәләнең икенче ягына күчик.
Гөлназ. Нинди ягына тагын?
Зөфәр. Менә без хәерчегә хәер биргәндә нindirәк хисләр кичерәбез?
Рәҗибә. Син, Зөфәр, бигрәк инде. Хәер биргәндә кем әллә ниләр уйлап торсын!
Зөфәр. Ул моментта, бәлки, уйламыйбыздыр, ләкин барыбер безнең күңелебездә үзебез турында кайгырту ята.
Гөлназ. Син изге ниятле кешеләрне мыскыл итәсең, Зөфәр.
Зөфәр. Юк, мыскыл итмим. Сезнең кебек үк мин дә шуны аңларга тырышам. Әйдәгез күңелләрне ачып сөйләшик әле. Без бит хәер биргәндә яки берәрсенә яхшылык эшләгәндә: «И Ходаем, биргән хәерем, эшләгән яхшылыгым теге дөньяларда мине җәһәннәм газапларыннан коткарсын, бу дөньяларда эшләрем уңышлы барсын», — дип уйлыйбыз.
Гөлназ. Уйласа соң. Моңа карап кына безнең яхшылыгыбыз начарлыкка әйләнми бит. Чөнки без кемнедер ач үлемнән коткардык.
Зөфәр. Коткаруын коткардык, ләкин бит без яхшылыкны үзебез өчен эшләдек.
Рәҗибә. Ай Аллам! Яхшылык сиңа да, миңа да яхшылык була алмыймыни? Менә мин, мәсәлән, берәүдән алам, икенчегә сатам. Һичкемне көчләмим. Аласы килгәне ала, килмәгәне — юк. Тегеңә дә яхшы, моңа да яхшы. Бәлки, синеңчә алай түгелдер?
Зөфәр. Без бәхәстән бераз читкәрәк киттек. Сорауны без болай куйган идек. Бирүче савaплырак эш башкарамы, алучымы?
Фирая. Алучы ничек инде саваплы эш башкарсын?
Зөфәр. Алай диярга ашыкмыйк әле. Без биргән хәерне алып ул бит безне гөнаһтан коткара. Ачка үлүчегә бер ипи бирү бәрабәренә без оҗмахта үзебезгә урын әзерлибез түгелме соң?
Гөлназ. Без, Алла коллары, җирдәге тормышыбызның бер мизгел генә икәнен белеп, киләчәк мәңгелек тормышыбыз өчен әзерләнеп яшәргә тиешбез. Ә киләчәк тормышка әзерләнү ул — үзең белеп яки белмичә эшләгән гөнаһлардан арына бару. Шулай булгач, безнең күңелләргә әллә нинди вәсвәсәләр салма.
Зөфәр. Мин үзем аңларга телим. Нәрсә ул яхшылык, нәрсә ул яманлык? Кичә генә яхшы дигән төшенчәләребез бүген начар, бүген яхшы дигәнебез иртәгә яман. Бик белдекле булсагыз, шуны аңлатыгыз миңа? Бармы ул мәңге үзгәрми торган яхшылык яки яманлык? Дөньяга безнең карашларыбыз үзгәргән саен, бу төшенчәләр дә үзгәрә түгелме соң?
Гөлназ. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам хәдисләрендә, Аллаһы Тәгалә дин вә шәригать хөкемнәрен бәян кылып, пәйгамбәрләренә йөз дә дүрт китап иңдермештер. Пәйгамбәрләр шул китаплардагы хөкемнәр илә кавемнәрне иманга вә изге гамәлгә өндәмешләрдер. Шул исәптән Мөхәммәд пәйгамбәребезгә Коръән Кәрим иңмештер. Адәм балалары үзләренең барлык сорауларына шуннан җавап таба алачаклардыр. Син дә шул изге китапка таян, туганым Зөфәр.
Зөфәр. Ансы шулайдыр, мин Коръәнне беләм дип мактана алмыйм. Әмма...

Зөфәр сүзен әйтеп бетерә алмый, кулына газета тотып Кирам керә.

Кирам. Дус-ишләр, товарищлар! Менә минем кулда нәрсә дип уйлыйсыз?
Фирая. Әллә безнең Кашкатаебыз сабан туенда беренчелекне алганмы?
Кирам. Кит әле, былтыр Башкортстанга саткан Кашкатай турында сөйләнеп торма.
Фирая. Ә нигә? Безнең Кашкатаебыз Башкортстанда беренчелекне алса начармыни?
Кирам. Начар түгел, ләкин монда башка берәү башка җирдә беренчелекне алган әле.
Рәҗибә. Әйтерлек булсаң, тизрәк әйт, юкса минем бөтен җирем кычына башлый.
Кирам. Алайса, бераз кычын әле, әйтми торам.
Гөлназ. Кыланма инде, Кирам. Нәрсә бар гәзитеңдә? Шәп фермер дип мактаганнармы әллә үзеңне?
Кирам. Юк, безнең дустыбыз, кемнәрнеңдер *(Гөлназга карый.)* яшьлек мәхәббәте Мансур турында язганнар. Менә карагыз. Мансур герой булган.

Газета кулдан кулга күчә. Бар да аһ итә.

Тавышлар. Герой, Мансур герой! Ур-ра! Ур-ра!
Гөлназ *(газетаны башкалар кулыннан алып укый).* «Ватан алдында күрсәткән батырлыгы өчен Мифтахов Мансур Фатыйх улына Россия Герое дигән мактаулы исем бирергә һәм туган авылында Геройның бронза бюстын куярга!» Россия президенты. Фәләненче число. Фәләненче ел.
Рәҗибә. Их, теге вакыт Мансурны кулдан ычкындырдым, шайтан алгыры. Кыядан мотоциклы белән тәгәрәгәч, үләр дип куркып, дөресен сөйләп ташладым. Син дә, Гөлназ, авызыңны ачып калдың.
Гөлназ. Синең бит дөньяң болай да гөрләп бара. Бизнесмен ирең «Мерседес»та гына йөртә үзеңне. Акчаң капчык белән. Тагын ни кирәк?

Рәҗибә. Шулаен шулай да. Герой хатыны булуның почеты зуррак. Белгәнегезчә, кешегә байлык җитсә, дан җитми.

Зөфәр. Иреңә берәр Герой йолдызы сатып алып бирерсең. Хәзер орденын ыштанга алыштырырга торучы ыштансыз геройлар җитәрлек.

Рәҗибә. Гөрбиян. *(Борылып китеп бара.)*

Кирам. Туктагыз әле, иптәшләр, товарищлар. Безгә хәзер Геройны каршы алырга әзерләнергә кирәк. Йөз кызарырлык булмасын.

Тавышлар. Булмас, булмас! Героебызны кулда гына йөртербез.

Зөфәр. Кулда чөеп мактаргамы, җиргә салып таптаргамы — уйларга кирәк әле.

Рәҗибә. Нәрсәсен уйлыйсың. Герой герой инде ул. Андый исемне юкка гына бирмиләрдер.

Зөфәр. Юкка гына бирмиләр шул.

Рәҗибә. Шулай булгач?

Зөфәр. Шулай булгач уйларга кирәк. Бу батырлыкның төбендә нәрсә ята: яхшылыкмы, яманлыкмы?

Фирая. Нәрсәгә син тырт та пырт торасың, Зөфәр. Дустыбыз батырлык кылып дан казанган икән — моңа шатланырга гына кирәк.

Зөфәр. Ә мин шатлана алмыйм. Безнең герой дустыбыз кайда хезмәт итә? Империя армиясендә? Ә армия бер гөнаһсыз Таулар илен җимерә. *(Шигырьгә күчә.)*

Еракта Таулар илендә
Яшәүче батыр халык
Яраларын ялый-ялый
Көрәшә канга батып.

Өсләренә бомба ява,
Таулар төшә ишелеп.
Мондый вәхшилеге өчен
Оялырмы кешелек?!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Үзләренең капка төбендә Кирам утыра. Арткы планда беренче пәрдәдәге Кирамнар өе күренеше. Төн. Кирам эчке күлмәкыштан өстеннән плащмы, юка пальтомы бөркәнгән. Ул эскәмиядә башын тотып утыра, аннары торып йөренә башлый.

Кирам. Һич аңламыйм, башым катты. Нәрсә булды соң инде бу, ә? Тормыш әйбәт кенә барганда... Зөфәрен әйтер идем. Кеше күңеленә вәсвәсә салып йөрмәсә ярамыйдыр.

Фирая чыга. Ул да өстенә шәл генә бөркәнгән.

Фирая. Син монда икәнсең. Кая китте икән бу дип аптырап беттем. Нишләп йокламыйсың?

Кирам. Син йокламаганга йокламыйм. Менә син нигә йокламыйсың соң?

Фирая. Ә мин син йокламаганга йокламыйм. Зыр-зыр әйләнеп-боргаланып яттың да торып киттең. Ирем йокламагач, мин ничек йоклап ятыйм? Мин бит татар хатыны.

Кирам. Хатын-кызга яшәү җиңелрәк. Тамагы тук, өсте-башы бөтен булса, шул җиткән.

Фирая *(ачуланып)*. Син нәрсә, хатын-кызны сыерга тиңләвеңме бу?

Кирам. Чәпчемә әле. Кешегә уйланырга ирек бир.

Фирая. Кешегә уйланырга... Бәлки, минем җанымда җәһәннәм утлары кайныйдыр. Шул утлар мине үрле-кырлы сикертеп, түшәгемнән кубарып монда чыгаргандыр. Ул гына уйлый, имеш.

Кирам. Тукта инде, Фирая. Мин хатын-кызлар уйламый дияргә теләмәдем. Ил язмышы ирләр кулында димәкче генә идем.

Фирая. Ил язмышы ирләр кулында булуы яман шул. Әгәр дөньяны безнең кулга тапшырсалар, мондый юләр сугышлар булмас иде. Кайсы ананың үз баласын сугышка җибәреп җанын кыйдырасы килсен?

Кирам. Сугышырга хатын-кызлар да оста. Бернәрсә булса, тукмак күтәрергә, бер-берегезнең чәчен йолкышырга гына торасыз.

Фирая. Йолкынган чәчләр үсә, киселгән башлар үсми.

Кирам. Әйе, кеше үлән түгел шул. Чабып алган саен үсеп чыкмый. *(Уйланып.)* Карале, Фирая, Мансурга ни өчен Герой исеме биргәннәр дип уйлыйсың син?

Фирая. Нигә икәнен белсәм, мин монда баш ватып утырмас идем.

Кирам *(уйланып)*. Барыбызга да билгеле — Мансур хәрби очучы. Ә хәрби кешеләр кайда батырлык күрсәтә ала? Сугышта! Димәк...

Фирая. Димәк? Әйдә, әйтеп бетер, нигә туктап калдың?

Кирам. Ашыктырма, Фирая. Мин Мансур турында начар уйларга теләмим.

Фирая. Мин телимме?

Кирам. Син дә теләмисең. Шулай булгач, әйдә, уйламый гына утырыйк әле.

Фирая. Төн уртасында йолдызларга карап утырырга чыктыңмыни?

Кирам. Кайчагында йолдызларга карап утыру да файдалы. Дөнья куабыз: тегесен җиткерергә, бусын булдырырга дип чабабыз. Һәр табыш нинди дә югалту китерә.

Фирая. Нәрсә югалттык соң әле без? Төн йокыларыбызны качырып нәрсә эзләргә чыктык?

Кирам. Тынычлыгыбызны югалттык, әнкәсе.

Фирая. Әй, Зөфәр күңелгә вәсвәсә салмаса, тыныч кына яши идек. Ул бөтен нәрсәне кирегә борырга тора. Яхшылык-яманлыклары белән башны катырып бетерде.

Кирам. Юк, матурым. Эш Зөфәрдә генә булса болай пошыныр идекмени? Безнең күңелләрдә күптән шом яши инде. Мин бит күреп торам: синең җаның да тыныч түгел. Һәр көн төннәрен уянып балаларга карап торуларың юкка дисеңме? Алар бит үсә. Ә илдә тынычлык юк. Менә бу мәңгелеккә дип салып куйган йортыбызда балаларыбыз үз балаларын үстерер дип кем әйтә ала?

Фирая. Син дә шикләрне арттырып утырма әле, атасы. Начар уйны уйламау хәерле. Иң яхшысы, әйдә, кереп ятыйк. Иртәгә иртүк торасы бар. Йә безнең тавышка кунаклар уяна башлар. Әйдә.

Кирамны эскәмиядән торгызырга кулын суза. Шул вакыт караңгылыктан Гөлназ килеп чыга.

Гөлназ. Кунакларны йоклатып, үзегез монда гөрләшәсезме?

Фирая. Без үз өебездә. Гөрләшсәк тә, серләшсәк тә. Ә менә син нигә йокламыйсың?

Гөлназ. Сез нигә йокламасагыз, мин шуңа йокламыйм.

Кирам *(гаҗәпләнгән булып).* Ә без нигә йокламыйбыз соң?

Гөлназ. Кыланма әле, Кирам. Болай да йөрәк яна. Җитмәсә, син башыңны юләргә салып утырасың.

Кирам *(һаман шаярган булып).* Мин башымны үземнең хәләл җефетемнең иңенә салып утырам. Синеңчә, минем хатын юләрмени?

Гөлназ *(үртәлеп).* Җитте, үртәмә. Югыйсә өегезне ташлап кайтырмын да китәрмен.

Кирам *(җитдиләнеп)*. Бездән качып китә алырсың ансы. Ләкин җаныңны эзәрлекләгән сораулардан качып китә алырсыңмы икән?

Гөлназ. Менә шул шул. Шулардан кача алмаганга чыктым мин монда. Догаларымны йөз кат укысам да, күземә йокы кермәде. Уйларым башыма капты. Йә, чын дөресен генә әйтегез әле: сез Мансур турында ни уйлыйсыз? Ни өчен биргәннәр аңа герой исемен?

Фирая. Безнең дә әнә шул ни өченнән ерак китә алганыбыз юк шул.

Гөлназ. Кирам, син бит армиядә булган кеше. Бармы анда батырлык эшләрлек җирләр?

Кирам. Батырлык эшләргә һәркайда урын бар инде ул. Мансур бит хәрби очучы. Бәлки, берәр яңа самолет сынарга туры килгәндер.

Фирая *(бу фикергә тотынып)*. Әйе шул. Нишләп моңарчы безнең башка килмәде соң әле бу фикер?! Безнең Мансур гаделсез сугышта катнашмас. Минем моңа иманым камил.

Кирам. Минем дә Мансурга карата һичбер шигем юк. Ул батырлык күрсәтер өчен генә намусына каршы бармас.

Гөлназ *(сөенеп).* Һай, дусларым, мең-мең рәхмәт сезгә. Күңелемә җиңел булып китте.

Фирая. Ни өчен?

Гөлназ. Мансур турында яман уйламавыгыз өчен. Сездән яшерен серләрем юк, дусларым. Ничек кенә онытырга теләсәм дә, мин Мансурны оныта алмыйм. Аның буе-сыны, һәрбер хәрәкәте, шаяру-әрнүләре минем күз алдымда. Бервакыт ул миңа үзенең төшен сөйләгән иде. Гөлназ, ди, мин бүген бик матур төш күрдем, ди. Нинди төш ул, мин әйтәм. Ул әйтә: күктә искиткеч гүзәл салават күпере чыккан да шул күпернең бер башы сезнең ишегалдына, икенче башы безнең ишегалдына төшкән. Без бер-беребезгә каршы шул күпердән киләбез икән, ди.

Фирая. Нинди матур төш!

Кирам. Әйе, салават күпереннән бер-берегезгә кулларыгызны сузып озак бара алмадыгыз шул. Көнчелек, мәкер бәреп төшерде сезне бу күпердән.

Фирая. Рәҗибә арагызны бутамаган булса, бәлки, бергә булыр идегез. Ул вакытта Рәҗибәне ботарлап атардай булган идек без.

Гөлназ. Мин Рәҗибәдән бигрәк үземне гаепләдем. Ышанмыйча күпме газапладым мин Мансурны. Ә Рәҗибә нәрсә ул... *(Кул селти.)*

Болар янына Рәҗибә килә.

Рәҗибә. Төн уртасында мине чәйнәргә җыелыштыгызмы?

Гөлназ. Син генә ди күз өстендә кара каш.

Рәҗибә. Мин шул. Миннән көнләшәсез.

Гөлназ. Синең нәрсәңнән көнләшерлек соң, чүпрәкләреңнәнме?

Рәҗибә. Синең чүпрәкләрең дә юк. Абыстай булган булып, дога укып күзгә төтен җибәреп йөрисең. Синең җаныңда Алла юк. Әгәр дөньялар үзгәреп, коммунистлар властька кайтса, партиягә алыгыз дип иң беренче гариза күтәреп син йөгерәчәксең. Мин моңа йөз процент ышанам.

Гөлназ. Әгәр сиңа шул рәхәтлек бирә икән — ышан.

Рәҗибә. Әйе, рәхәтлек бирә. Мин сезнең кебек, бүген — бер, иртәгә икенче битлек киеп йөрмим. Минем бөтенесе ачык: рәхәтләнеп сатам, алам...

Гөлназ. Сатарга яшьтән үк оста идең, ансын кире кагып булмый.

Рәҗибә. Моның белән нәрсә әйтмәкче буласың?

Гөлназ. Үзең бик яхшы аңладың бит.

Рәҗибә *(бөеренә таянып).* Алучысы булганда нигә сатмаска? Беләм: сез үзегезне бик акыллыга санап йөрисез. Сез горурлар, сез бөекләр, сез Алланың кашка тәкәләре. Менә Фирая белән Кирам ике катлы таш йорт салып куйганнар. Өйләрендә компьютер бар. Хәзер безнең алда байлыклары белән мактаналар.

Фирая. Безнең мактанырга уйлаганыбыз юк әле.

Рәҗибә. Мактануны тел белән генә әйтергә димәгән. «Менә без кем!» дигән кәпрәюегез сезнең чыраегызга язылган.

Гөлназ. Кирамнарның мактанса мактанырлыклары бар.

Рәҗибә. Ә син абыстай булдым дигәч тә әллә үзеңне бөтен кешедән акыллы дип саныйсыңмы? Имеш, ул Казанда да, Төркиядә дә укыган. Төкерәм мин сезнең укуларыгызга, төкерәм ташпулатларыгызга. Берегез аңгыра шәкертләр сасысы иснәп ятса, икенчегез мал-туар тизәгенә муеннан чумган. Әлбәттә, сез үзегезнең тормышларыгыздан бик канәгать, һәм, тормыш гомергә шушылай барыр дип уйлыйсыз. Юк, җанкисәкләрем, безнең илдә берни дә мәңгелек түгел. Тырышып-тырмашып җыйган байлыгыгызны беркөн тартып алачаклар. Тартып ала алмасалар — ут төртеп яндырачаклар. *(Гөлназга карап.)* Ә синең, абыстай, мәдрәсәңне шартлатып ябып, үзеңнең арт ягыңа тибеп чыгарачаклар. Мин — спекулянт. Спекулянт мәңге бетмәячәк. Без калачакбыз.

Кирам. Карап-карап торам да сиңа, Рәҗибә, тагын бер карап куям: каян килә сиңа мондый усаллык?

Рәҗибә. Тормыштан. Хәзер усаллар заманы. Аягөсте йоклап йөргәннәргә урын юк бу дөньяда.

Фирая. Усал булсаң — асарлар дигән сүзне онытма.

Рәҗибә. Юаш булсаң — басарлар дигәнен дә онытмыйм мин. Астырсам астырырмын, әмма бастырмаячакмын.

Гөлназ. Бастыргансың бит инде.

Рәҗибә. Кемнән?

Гөлназ. Чүпрәкләрдән. Чүп-чар күмеп киткән үзеңне. Ә бит кайчандыр хыялланып йөргән идең. Имеш, ул ун бала таба. Матур гаилә кора.

Рәҗибә. Минем гаиләм матур. Ирем үземне «Мерседес»та гына йөртә. Ә син Бохарага барып берәр карт мулланы үзеңә карата алмаммы дип йөргән идең дә, йөрәгең урынында партбилет икәнен күргәч, карт муллалар да качып бетте кырыеңнан, Кысыр абыстай.

Фирая. Җитте сиңа, Рәҗибә. Кунак булсаң, тыйнак бул.

Зөфәр керә.

Зөфәр. Талашабызмы?

Кирам. Талашмыйбыз, бер-беребезнең йөрәгенә уклар кадашабыз.

Зөфәр. Бу дөньяда гомер буе
Булып тора дуэльләр.
Тик дуэльләр генә хәзер
Элеккечә түгелләр.

Атыш юк, секундантлар юк,
Хәбәр итү юк алдан:
Белмисең кай җирдә сине
Сагалый мәкер, ялган.

Кып-кыска гомер эчендә
Никадәрле дуэльләр:

Үлем ярасын әз-әзләп
Җыеп йөри күңелләр.

Зөфәрнең шигыреннән соң бар да бераз тын торалар.

Гөлназ. Әйе. Без гадәттә: ил башлыкларына нәрсә җитми, нигә алар сугыш ачалар, дибез. Ә бит ил белән ил, халык белән халык кына сугышмый. Кешеләр арасында да нәрсәдер бүлешү бара. Бер-беребездән көнләшәбез, аяк чалабыз.

Зөфәр. Көнчелекләр җирдә күп шул әле,
Санап кына түгел бетәрлек.
Хәерчегә кергән хәергә дә
Көнләп караучылар җитәрлек.

Кирам. Синең эшләр җайлы, Зөфәр. Тормыш куйган һәр сорауга шигырь белән җавап бирәсең. Шуның белән күңелеңне бушатасың. Ә менә без шагыйрь түгел, безгә нишләргә?

Зөфәр. Яши-яши ялганларга, ялганлый-ялганлый яшәргә.

Фирая. Син җитди сораудан качма, Зөфәр. Бая син Мансур турында нәрсә әйтергә теләдең? Бәлки, син без белмәгән берәр нәрсә беләсеңдер? Бәлки, Мансур «тегендә» булгандыр?

Гөлназ. Әйе, турысын әйтеп сөйләшик, Зөфәр.

Зөфәр. Мансур турында нәрсә беләмме? Сезнең кебек үк мин дә Мансурның хәрби очучы икәнен беләм. Таулар илендә сугыш барганлыгын беләм.

Гөлназ. Сугыш туктады бит.

Зөфәр. Кайчанга кадәр? Без яшәгән илдә сугышның берәр вакыт туктаганы бармы соң?
Империяне бүген тулгак тота,
Текәлгәннәр күзләр: кем туар?
Бу күзләрдә өмет белән бергә
Шикләнүләр, шөбһә-куркулар.

Империя анакайның хәле
Җиңел түгел, әгәр аңласаң.
Ярый ла ул көтеп-көтеп тә
Үле бала гына тапмаса.

Яки берәр тиран тудырмаса
Кан коюдан ләззәт табучы.
Җиңүләрдән җиңүләргә безне
Гел җитәкләп алып баручы.

Ә хәзергә бөек империяне
Калтырата тулгак авыруы.
Бик икеле аның бу тулгактан
Үзенең дә исән калуы.

Рәҗибә *(кул чабып)*. Браво, Зөфәр, браво! Кияргә алмаш чалбарың булмаса да, телең бар.

Зөфәр. Нигә кирәк безгә чалбар,
Барыбер салдыралар.
Алдыңа әрекмән каплап
Йөрергә калдыралар.

Гөлназ *(пошынып)*. Җитди сүзне уенга бормагыз әле. Без монда төн уртасында нәрсәгә җыелдык?

Рәҗибә. Мансурны чәйнәргә.

Фирая. Синең телеңдә чәйнәүдән башка сүз юкмы әллә, Рәҗибә? Әле генә «мине чәйнисез» дигән идең, хәзер Мансурны. Чәйнәр өчен сагыз да җитәрлек.

Рәҗибә. «Орбит без сахара»мы? Ләкин сезгә ул гына җитми шул. Сез акыллылар, сез философлар. Һәрнәрсәнең төбенә төшәргә яратасыз. Дөньяны катлауландырасыз. Ә тормыш ул бик гади: аласың һәм сатасың. И вәссәлам!

Кирам. Тормыш алмыш белән сатмыш кына булса, бу дөньяга туып та торасы юк.

Рәҗибә. Алайса, нигә тудыгыз соң? Сезнең дә бөтен тормышыгыз алу белән сатуга корылган лабаса. Сез ат сатасыз, бәрәңге сатасыз, ә мин чүпрәк-чапрак. Сезнең белән минем арада нинди аерма бар?

Кирам. Нигә булмасын? Без үзебез үстергәнне сатабыз. Ә син...

Рәҗибә. Әйберне кем генә җитештермәсен — барыбер сатар өчен җитештерә. Сату-алу тукталдымы — дөнья бетә. Сез бит шагыйрьләр, фермерлар, абыстайлар миннән яхшырак беләсез: ни өчен концлагерьларда, ГУЛАГларда тоткыннар бер-берләре белән алыш-биреш иткән? Ачтан, суыктан

үлмәс өчен түгелмени?

Зөфәр. Синеңчә, шигырьләрне дә сатар өчен язалармы?

Рәҗибә. Әлбәттә. Кемнең нәрсәсе бар — шуны сатып көн күрә бу дөньяда. Бәлки, син үзеңне бөек кеше, ирекле кеше дип йөрисеңдер. Башыңда берсеннән-берсе мәһабәтрәк идеяләр туадыр. Ләкин, дустым, син нинди генә бөек әсәрләр язсаң да — алар бөтенесе акча белән бәяләнә.

Гөлназ. Бәлки, синеңчә, намус та акча белән бәяләнәдер.

Рәҗибә *(Гөлназга үтергеч караш ташлап)*. Акча белән бәяләнмәсә, син иманыңны ыштан кебек алыштырып йөрмәс идең.

Гөлназ. Оятсыз.

Рәҗибә. Оят? Ә нәрсә соң ул оят? Кайда була ул? Күрсәтегез аны, белсәгез.

Фирая. Көлмәк итәген күтәргәнгә генә күренә торган нәрсә түгел ул.

Рәҗибә *(мыскыллап)*. И-и, аннан да өстәрәкмени? Алай эчтә булгач, мин күрә алмам шул аны. Әнә абыстай күрсәтсә генә инде.

Гөлназ. Иблис!

Рәҗибә. Иблисне дә Ходай яраткан. Ә ни өчен яраткан ул аны, уйлап караганыгыз бармы? Син, абыстай, моны белергә тиеш. *(Пауза.)* Беләсегез килсә, җир йөзендә тормыш барлыкка килүгә турыдан-туры Иблис сәбәпче. Әгәр Иблис Анабыз Һаваны котыртып тыелган җимешне ашатмаган булса, Атабыз Адәм белән Анабыз Һава гомер бакый оҗмахта гына яшәп ятарлар һәм җиргә сөрелмәсләр иде. Димәк, җирдә тормыш та булмас иде. Дөньяда яшәвегез өчен Иблискә, ягъни мәсәлән, миңа рәхмәт укыгыз.

Кирам. И-и, туктатыйк әле бу чүп сүзне.

Зөфәр. Һәр күңелдә Иблис тә бар, фәрештә дә,
Бара алар арасында мәңге тартыш.
Иблис белән фәрештәнең тартышында
Газапланып языла шулай безнең язмыш.

Тартышмыйча яши алмый алар һич тә,
Бу икәүгә тар, ахрысы, дөнья-җиһан.
Күңелнең бер почмагында посып кына
Кем җиңәр дип карап тора безнең Иман.

Зөфәр пафос белән шигырь укыганда, Мансур керә. Ул хәрби киемнән. Иңнәрендә капитан погоннары, түшендә Алтын Йолдыз. Зөфәр шигырен укып бетерүгә, ул кул чаба башлый. Бар да Мансурга таба борыла. Рәҗибә беренче булып Мансурның кочагына ташлана.

Рәҗибә. Мансур! Герой кайткан, Герой. *(Мансурның җилкәсенә сугып.)* Карагыз әле нинди килешә аңа капитан погоннары белән Алтын Йолдыз! Коеп куйган лачын.

Мансур. Исәннәрмесез, дусларым!

Барсы да бераз җанлана. Күңелләрендә ниндидер якты өмет, ышаныч уяна. Мансур әле берсен, әле икенчесен кочып ала.

Мансур. Шундый сагындым, дусларым, шундый сагындым. Туган яклардан чыгып киткәнгә ун ел бит. Хәтерегездәме, унынчы классны бетергәч, бергәләп таң каршылаган идек. Хәзер дә таң атып килә түгелме соң?

Барсы да офыкка карый. Анда таңның сызылып атканы күренә.

Гөлназ. Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата...
Фирая. Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата...
Кирам. Бер-бер артлы юк булып, күкләрдә йолдызлар сүнә...
Мансур. Таң җиле куйды исеп, яфраклар аз-аз селкенә...
Рәҗибә. Пәрдәдән чыкты, ачылды яп-якты кыр һәм япан...
Зөфәр. Китте инде кап-кара каплап ята торган чапан...
Мансур. Их, дусларым. Моннан нәкъ ун ел элек шушы шигырь белән таң каршылаган идек.
Зөфәр. Классыбыз белән авылда калырга җыендык.
Гөлназ. Хәтерегездәме менә бу җыр? *(Җырлый башлый, аңа бүтәннәр дә кушыла.)*

Хыялларга итмик хыянәт,
Ак хыяллар — яшьлек юлдашы.
Яктылыгы белән саклансын
Гомер таҗы — безнең юл башы.

Күңелләрдә безнең ак хыял,
Ашкындырып тора гел алга.

Кирәк күпме көч һәм түземлек
Тугры калыр өчен хыялга.

Жыр туктала. Беразга тынлык урнаша.

Гөлназ. Тугры калдыкмы без хыялыбызга?

Рәҗибә. Иблисләнеп маташма әле. Иң беренче хыялга син хыянәт иттең. Имеш, ул авылда кала. Туган-үскән җирне, ата-бабалар нигезен саклый. Ак яулык ябып кына кара йөзеңне каплап йөрмәкче буласың.

Гөлназ. Нинди кара йөз? Минем йөземнең дә, җанымның да кара булганы юк. Син дә теге вакыт редакциягә пычрак яла ягып, бөтенебезнең намусын буядың.

Кирам. Туктагыз әле, дуслар. Хәзерге авыл ул вакытта без хыялланган авыл түгел. Без беребез дә хыялларыбызга хыянәт итмәдек. Зөфәр шагыйрь булырга тели иде. Һәм булды да. Без авылда калырга, атлар карарга хыялландык. Хыялыбыз тормышка ашты. Мансур очучылыкка омтылды — очучы булды.

Зөфәр. Ансы шулай, Кирам. Ләкин бүген сүз ул турыда түгел бит. Без үз намусыбызга, яшьлектәге сафлыгыбызга тугры калдыкмы? Эш менә нәрсәдә! Рас бергә җыелганбыз икән, бушатыйк без күңелләрне. Йә, кайсыбыз башлый? Бәлки, Мансур башлап җибәрер? Аны бит инде ун ел күргән юк. Ирешкәнме ул үзенең хыялларына?

Мансур. Ә нигә? Миннән башларга да була. Мин үземне хыялыма ирештем дип саныйм. Кайчандыр мин тавыш тизлегеннән җитезрәк самолетка утырып иксез-чиксез күкне айкарга хыялланган идем. Самолетым уйлаганнан да шәбрәк булып чыкты. Их, дусларым, белсәгез иде сез очу дигән нәрсәнең рәхәтлеген. Атылган ук кебек җирдән күтәрелеп китәсең. Күк үзенең чиксезлеге белән сине үзенә тарта. Тизлекне арттырганнан арттыра барасың. Тизлек ул — көч, әйтеп аңлата алмаслык шатлык, хәтта матурлык. Тизлек белән ләззәтләнгәннән соң текә пикка керәсең, малай чакта чирәмдә мәтәлчек аткандай, самолетың белән мәтәлчек атасың. Үлем элмәге ясыйсың. Самолетың белән үз күчәреңдә әйләнәсең, ягъни, безнең тел белән әйтсәк, күп әйләнешле бочка ясыйсың. Аннан кинәт түбәнгә очасың. Инде җиргә төшеп челпәрәмә килдем дигәндә, өр-яңадан күккә ыргыласың.

Зөфәр. Әйе, Мансур, син чынлап та бәхетле күренәсең. Очышның тәмен татып өлгергәнсең. Ләкин синең бу бәхетең нәрсә бәрабәренә яуланды? Кулыңа шундый самолетны, бу егет очу ләззәтен татып, янган йөрәген бассын әле дип кенә бирмәгәннәрдер бит.

Мансур *(Зөфәргә)*. Их, дускаем. Син бит шагыйрь кеше. Бәхет нәрсә бәрабәренә генә яуланмасын — барыбер бәхет инде ул.

Гөлназ. Синең сүзләрең белән килешеп булмый, Мансур. Бәхет кешенең эгоизмын басар өчен бирелми. Әзмени кешедә хайвани хисләр!

Мансур *(Гөлназга салкын карап)*. Син, Гөлназ, һаман шул комсорг булып калгансың икән.

Рәҗибә *(ирония белән)*. Безнең Гөлназ хәзер абыстай бит, Мансур, син аны комсорг дип мыскыл итмә.

Мансур *(Рәҗибәнең сүзләренә игътибар итмичә, Гөлназга карап сүзен дәвам итә)*. Беләсеңме, кешеләр ни өчен гомер буе күккә очарга ашкынып яшиләр? Чөнки биеккәрәк менгән саен ераграк күрәсең. Җирдә яшәүнең мәгънәсен ныграк төшенәсең. Җирдә кеше һәрвакыт нәрсәгәдер бәйле. Күккә күтәрелү белән шушы бәйлелек өзелә. Син иреккә чыгасың. Җил-давылларны җиңеп оча алуың, иксез-чиксез күк белән икәүдән-икәү калып куркуны, җирдәге мәгънәсез тормышыңны әзгә генә булса да оныта алуың белән бәхетле син.

Кирам. Синеңчә, җирдәге барлык кешеләрнең тормышы мәгънәсез бер көн үткәрү генә?

Фирая. Шулай булып чыга инде. Без — җир кортлары, тирестә казынучы бөҗәкләр.

Мансур. Мин сезне рәнҗетергә теләмәдем, дусларым. Бәлки, сезнең эшегез дә үзегезгә бәхет китерәдер. Ләкин очышта алган рәхәтлекне җирдә берни дә бирә алмый. Вакытны, пространствоны бары тик күктә генә җиңеп була. Күктә бернинди чикләү юк! Горизонталь очыштан кинәт вертикаль очышка күчәсең. Биеккәрәк менгән саен, җир каршылыгы кими. Бәйләр өзелә. Син үзеңнең ашау өчен, киенү өчен генә тумаганыңны аңлыйсың. Мин — кеше, мин дөньяда иң илаһи зат дип кычкырасы килә.

Гөлназ. Алладан кала илаһи зат юк. Язмыш сиңа нindidер бәхет мизгелләре татырга мөмкинлек биргән икән — бу Аллабызның рәхмәте аркасында гына.

Мансур. Миңа мораль укыма, Гөлназ. Кайчандыр синең күзләреңә карап, һәр дәреслекне синең күзләреңдә генә күреп яшәгән Мансур юк инде. Миңа бәхетне илем, Ватаным бирде.

Зөфәр. Илең? Ватаның? Кайда соң синең илең, Ватаның?

Мансур. Син нәрсә, Зөфәр, мине диванага саныйсыңмы? Яки миннән көлүеңме бу?

Зөфәр. Юк, мин бик җитди сорыйм: син кай җирне үзеңнең Ватаным дип саныйсың?

Мансур. Сез миннән нинди җавап көтәсездер, әмма мин үзебезнең абзар артын гына Ватанга санамыйм. Минем өчен Татарстан да, Россия дә бер. Күккә биегрәк менгән саен, төрле чик кысалары кими бара.

Кирам. Сугыш сөременә күмелгән Таулар иле дә синең өчен Ватанмы? Ватан икән — нигә аңа бомбалар яудырырга?

Һәммәсенең күзе Мансурга текәлә.

Мансур. Ватан! Күкнең чикләре юк. Кая телисең — шунда очасың. Нәрсә кушалар — шуны үтисең.

Зөфәр. Күкнең дә чикләре бар. Һәм син дә кая телисең — шунда оча алмыйсың.

Рәҗибә. Нигә әле бөтенегез Мансурга ябырыласыз? Аның белән горурланырга, аны данларга кирәк безгә. Ул бит Герой. Күрегез аның Алтын Йолдызын. *(Мансурның йолдызын сыпырып куя.)* Күктәге йолдыз кебек җем-җем итеп балкып тора бит.

Гөлназ *(Мансурга).* Күккә менеп рәхәтлек кичергәнгә генә бирмәгәннәрдер ул йолдызны?

Фирая. Гөлназ дөрес әйтә. Безнең һәммәбезне борчый бу сорау: ни өчен бирделәр сиңа Герой исемен? Кайда, нинди батырлык күрсәттең?

Мансур. Сезнең өчен барыбер түгелмени? Менә мин бит сез бу йортны салыр өчен акча каян алдыгыз дип сорамыйм.

Кирам. Ә син сора. Без җавап бирергә әзер.

Мансур. Кирәкми миңа сезнең җавабыгыз. Һәм мин аны сорамыйм да. Теләгәннәр йорт салсын, фермер булсын. Теләгәннәр комсоргтан абыстайга әверелсен. Ә мин менә батыр булырга теләдем. Кайда, нинди батырлык эшләүдә сезнең эшегез юк. Шуның белән вәссәлам!

Зөфәр. Юк инде, җанкисәгем. Кул селтәп кенә котыла торган сорау түгел бу. Кулыңа уенчык тоттырганга куанып йөрергә син бала түгел. Һәммәбезнең үз намусы алдында җавап тотар чагы җитте. Син үзеңнең томанлы бәхетеңә исереп арабызда беребезнең юклыгын да абайламадың.

Мансур. Ә кем юк соң? *(Як-ягына карана, ләкин кем юклыгын хәтерли алмый.)*

Зөфәр. Менә шул шул. Хәтерли дә алмыйсың.

Мансур. Шуннан ни булган? Кем кемне онытмас! Безнең һәрберебезнең кемнәрнедер онытырга, хәтереннән мәңгегә сызып ташларга хакы бар. *(Гөлназга карый.)*

Гөлназ. Тереләрне онытырга, бәлки, хакыбыз бардыр, әмма үлеләрне онытырга хакыбыз юк. Бигрәк тә Флюра кебекләрне.

Мансур *(сискәнеп киткәндәй була).* Нәрсә, Флюра үлдемени?

Гөлназ. Үлмәде, һәлак булды.

Мансур. Ничек? Кайда?

Зөфәр *(уйланып).*

Еракта, Таулар илендә,
Сугышлар барган җирдә,
Күктән яңгырга кушылып
Бомбалар яуган җирдә,

Елгаларда сулар түгел,
Кайнар кан аккан җирдә,
Ташлар янып, ялкыннары
Офыкка капкан җирдә

Калды дустыбыз гәүдәсе,
Мәңгегә ятып калды.
Кайларда очып йөридер
Аның гөнаһсыз җаны.

Барсы да бер мәлгә тын кала.

Мансур *(үзе дә сизмәстән).* Ул да анда булдымыни?

Зөфәр. Кайда анда? Димәк, син дә шунда булдың?

Мансур. Мин анда кешеләр үтерергә бармадым. Мин очтым. Бары тик очышлар гына ясадым.

Кирам. Тавыш тизлегеннән җитезрәк самолетыңа төяп Таулар иленә чәчәкләр илттеңме?

Фирая. Бәлки, син анда ипи-тоз төяп баргансыңдыр.

Гөлназ. Их Мансур, Мансур! Яшьлек хыялларыңа гына түгел, үзеңә тел биргән, җан биргән халкыңа да хыянәт иткәнсең бит син.

Мансур. Халык белән авыз чайкамагыз. Кая ул безнең халык, кая ул безнең Ватан? Мин үз-үземне белә башлаганнан бирле очучы булырга хыялландым. Минем халкым мине очучы итә ала идеме? Ә минем кебек малайлар әзме? Бүгенге көндә йөзләрчә малай ак юл калдырып очып үткән самолетларга карап зәңгәр күккә күтәрелергә хыялланадыр. Бәлки, кемнәрнеңдер йөрәген ерак диңгезләр җилкетәдер. Кем алып чыгар аларны диңгезгә? Сез әйткән халыкмы? Мин дә бер горур халыкның улы

булырга каршы килмәс идем. Кая соң ул халык? Кая?

Зөфәр. Үзеңнең түбәнлегеңне халыкка сылтама. Халкыбызның исеме дөнья каршында Тау халыклары кебек горур яңгырамый икән, аңа сезнең кебек сатлыкҗаннар гаепле.

Мансур. Кем сатлыкҗан? Мин беркемне дә сатмадым.

Зөфәр. Әйе, син базарга чыгып сату итмәдең. Син бары тик гөнаһсыз халыкның өстенә бомба гына яудырдың. Синең бомбаңнан өйләре янган, тәннәре яраланган кешеләр актык сулышларын алганда сине генә түгел, безнең халыкны да каргагандыр. Син койган һәрбер тамчы кан халкыбызның йөзенә юылмаслык хурлык табы булып ягыла барды. Синең кебек сатлыкҗаннары өчен оялудан түбән карап йөри безнең халык.

Мансур. Сез мескеннәр! Үзегезнең борын астыннан ерак күрә алмыйсыз. Фермер булганнар, абыстай булганнар, имеш. Кем бирде соң сезгә боларны? Зөфәр, менә синең авызыңдагы бәйле телеңне кем чиште? Син калкан итеп күтәрүче халкыңмы? Юк бит! Бүген нәрсәгәдер ирешә алгансыз икән — моның өчен бит сез шушы каргалган Россиягә бурычлы.

Гөлназ. Дүрт йөз илле ел кол булып яшәп мескенләнүебез өчен дә без аңа бурычлы.

Кирам. Синең кебек маңкортлар тууга да без аңа бурычлы.

Фирая. Әйе, безнең бурычларыбыз артык күп, шуңа күрә йөзләрчә-меңнәрчә асыл егетләребезнең, Флюра кебек гүзәл җаннарыбызның гомерләре белән көн саен шул бурычларыбызны түләп торабыз.

Рәҗибә. Нәрсәгә әле кайтып кергәннән бирле Мансурга бәйләнәсез? Әллә анда бер Мансур гына сугышканмы? Ул хәрби кеше — нинди приказ бирсәләр, шуны үтәргә тиеш. Шундый батыр дустыбыз белән горурланыр чакта...

Зөфәр. Батыр? Тфү! Түшендәге бу ялтыравык йолдызны батыр булганы өчен түгел, куркак булганы өчен биргәннәр аңа.

Мансур. Минем батырлыгыма кагылма. Югыйсә...

Зөфәр. Нәрсә югыйсә? Син бер гөнаһсыз халыкның җанын кыярга үзеңнең мескен гомереңөчен куркудан бармадыңмыни? Синең бу түшеңдәге калаең батырлык билгесе түгел, хурлык тамгасы.

Мансур. Үзеңә бирсәләр, алай димәс идең, ләкин аны синеңише бушбугазларга бирмиләр шул. Йолдызлар биектә, сезнеңише җирдә шуышучыларның кулы җитәрлек җирдә түгел.

Зөфәр *(Мансурның түшеннән йолдызын йолкып ата).* Менә синең йолдызың кайда!

Зөфәр йолдызны таптый башлый. Мансурның кинәт төсе кача. Ул каядыр эчкә яшерелгән пистолетын тартып чыгара.

Мансур. Атам! Таптама Алтын Йолдызны!

Мансур пистолетны Зөфәргә төзи. Бер мәлгә бар да югалып кала. Ләкин Мансурның янәшәсендә торган Кирам, аның кулына сугып, пистолетын бәреп төшерә.

Кирам. Үз дустыңа кул күтәрәсеңме?

Мансур. Минем дусларым юк.

Фирая. Дусларың булмаса — авылдашың, классташларың.

Мансур. Минем авылым да юк.

Гөлназ. Алайса милләттәшең.

Мансур. Мин мескен милләтнең вәкиле булырга теләмим. Юк минем милләтем.

Зөфәр. Нәрсәң бар соң синең? *(Җирдәге пистолетны ала.)* Менә мондый үтерү коралыңмы? Әлбәттә, үтерүченең милләте дә, дуслары да була алмый. Үтерүчеләрнең шайкасы гына була ала. Синең кебек хәшәрәтнең җирдә яшәргә хакы юк. *(Пистолетны Мансурга төзи. Шул вакыт Сәвия керә һәм хәлне аңлап та бетермәстән Зөфәргә ташлана.)*

Сәвия. Зөфәр абый, нишлисең син?

Сәвия, Зөфәрнең кулыннан пистолетны бәреп төшерергә ниятләп, кулына суга, шунда пистолет атылып китә. Сәвия җиргә егыла.

Зөфәр *(Сәвияне күтәреп).* Сәвия сеңлем, каян килеп чыктың син? Нәрсә булды соң бу, дусларым?

Сәвия. Зөфәр абый, үләм.

Зөфәр. Үлмә, Сәвия. Син бит бу гөнаһлы дөньяның иң садә, нарасый бер баласы. Син түгел, менә кем үләргә тиеш *(Мансурга күрсәтә).*

Кирам *(җирдән пистолетны ала).* Дусларым, инде Мансурның кем икәнен барыбыз да белдек. Халкыбызның битенә төкергән, дөнья каршында аны мәсхәрә иткән кеше яшәргә тиешме? *(Бар да сүзсез тора.)* Без бая яхшылык һәм яманлык турында бәхәсләштек. Менә безнең каршыбызда шушы төшенчәләрнең икесен дә эчкә алган кеше басып тора. Канга сусаган җанварлар аны үзләренең коралы иткәннәр. Ул үзенең куркак җанын саклап калу өчен бер гаепсез сабыйларның, намазлык өстендә утыручы гөнаһсыз картларның канын койган. Коллык чылбырларын өзеп ирекcourses омтылучы горур халыкның кулына богау салышкан. Мондый кеше җирдә яшәргә хаклымы?

Гөлназ. Туктагыз әле, дусларым. Кемнең үләргә, кемнең яшәргә тиешлеген бер Ходай гына хәл итә. Без Ходай эшенә тыгылмыйк.

Фирая. Ходай эшенә тыгылу түгел бу, Гөлназ. Һәр яманлык җәзасын алырга тиеш.

Рәҗибә *(чәчрәп).* Оятсызлар, әллә дустыгызны атар идегезме?

Кирам. Юк, без аның белән кулны пычратмыйбыз. Әгәр әз генә намусы калган булса, ул үзен-үзе атарга тиеш. Мә, Мансур, пистолетыңны! *(Пистолетны Мансурга бирә.)* Югал безнең арадан. Әгәр әз генә намусың калган булса, үз язмышыңны үзең хәл ит.

Мансур пистолетны алып бер читкәрәк китә. Ул үзенең нәрсә эшләгәнен төшенә башлый.

Сәвия. Уф, үләм.

Гөлназ. Менә монда эскәмиягә яткыр, Зөфәр.

Сәвия. Юк, юк, мин Зөфәр абыйның кулында үләргә телим. Флюра апа тегендә һәлак булгач, аны алыштыра алмаммы дип хыялланып йөргән идем. Булмады. *(Башы салынып төшә.)*

Зөфәр. Юк, юк, үлмисең, Сәвия. Синең кебек саф җаннар да үлсә, кем калыр бу дөньяда?!

Кирам. Менә монда, безнең янда гына медпункт. Әйдә, Зөфәр, шунда алып барыйк.

Сәвияне күтәреп чыгып китәләр. Сәхнәдә тынлык урнаша.

Фирая *(Мансурга).* Әгәр Сәвия үлә калса, моның гөнаһысы да синең намусыңда булачак.

Гөлназ. Намусы калмаган инде аның. Намусы булса, ул туган авылына кайтырга оялыр иде. Очыш белән мактана, имеш. Үләксә эзләп козгын да оча. Тфү! Иманлы авызым белән әллә ни әйттерерсең.

Рәҗибә *(сүзсез торган Мансурны култыклый).* Әйдә, Мансур, китик бу тирәдән ераккарак. Абыстайның вәгазеннән туйган. Әйдә!

Мансур *(Рәҗибәне этеп җибәрә).* Саруымны кайнатмагыз әле. Китегез, берегезне дә күрәсем килми.

Мансур дусларын як-якка этәләп чыгып китә башлый. Шул вакыт
ашыгып Зөфәр керә.

Зөфәр. Дуслар, Сәвиягә кан кирәк. Кайсыгызның беренче группа?

Рәҗибә. Минеке өченче, резус отрицательный.

Зөфәр. Кирам бирмәкче иде, аныкы икенче икән.

Гөлназ. Минеке дә икенче.

Фирая. Минеке өченче.

Зөфәр. Минеке дә яраксыз. Инде нишләргә? Күзгә күренеп сула бит Сәвиябез.

Гөлназ. Авыл радиосы аша халыкка мөрәҗәгать итәргә. Әйдәгез!

Чыга башлыйлар, шунда Мансур аларны туктата.

Мансур. Туктагыз, миндә беренче группа кан. Үзем бирәм. Барсы да аңа текәлә.

Зөфәр. Юк! Синең каның беркемгә дә ярамый. Ул гөнаһсыз кешеләрнең кара күз яшьләре белән пычранган.

Мансур. Юк сүз сөйләп вакытны уздырмыйк. Әйдәгез тизрәк.

Гөлназ. Зөфәр дөрес әйтә: синең каның да кирәкми, җаның да. Синең бозык каныңны керсез, садә кешегә җибәреп, дөньяда бозыклык арттырырга ярамый. Әйдәгез, киттек! Китәләр.

Мансур. Туктагыз! Юк, туктамадылар, киттеләр. Хәтта минем канымнан да җирәнәләр. Дусларым, авылдашларым да миннән баш тарткач, яшәүдән ни мәгънә! *(Чигәсенә пистолетын тери һәм курокка баса, әмма пистолет атмый. Мансур кабат-кабат атып карый. Атыла алмый. Ул пистолетын җиргә атып бәрә.)* Хәтта тугры коралым — пистолетым да миңа каршы. Кая барырга, миңа нишләргә?

Мансур чыгып китә. Зөфәр керә.

Зөфәр. Их!
Үксеп-үксеп бер елыйсы килә,
Ир икәнне онытып еласы.
Аксын иде ярларыннан ташып
Күз яшенең кайнар елгасы.

Бу дөньяны бер юасы килә,
Күз яшьләре белән булса да.
Чистарынып калсын иде ул бер,
Юынгандай кайнар мунчада.
Яңа туган сабый бала кебек,
Бер сафлансын иде дөньясы.

Җиргә ятып үксеп елар идем,
Булса әгәр берәр файдасы,
Пычранды бит бигрәк дөньясы.

Пәрдә.

*1997*

# КЫЗЛАРНЫҢ КЫЗГАННАРЫ

*(Ике пәрдәле комедия)*

**КАТНАШАЛАР:**

Сары чәч — Сания, сатучы.
Кара чәч — Гөлсинә, сатучы.
Ир кеше — Сираҗи, 35—40 яшьләрдә.
Әхмәт Имаевич — кибет директоры, 60 лар тирәсендә.
Фатыйма — тетя Фая, җыештыручы, 67 яшьтә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Артык зур булмаган ашамлыклар кибете. Пәрдә ачылганда, Сары чәч белән Кара чәч берсен-берсе уздырып сагыз чәйни.

Сары чәч. Гуля, Гулечкә! Знаешь, кичә, когда эштән кайтып барам, артымнан берәү килеп туктады.

Кара чәч. Шуннан, шуннан? Ниндирәк типчик иде?

Сары чәч. О-о, пальчики оближешь, сразы хисләрем кузгалды. Җырда ничек җырлыйлар әле?

Уф димәс, уфтанмас идем,
Йөрәккәем янмаса, —
диләрме?

Кара чәч. Синең йөрәгеңнең янмаган чагы бармы соң?

Сары чәч. Яна шул, Гүлечкә, яна.

Машинага бер утырсаң,
Бара да бара икән;
Сөю уты бер кабынса,
Яна да яна икән.

Кара чәч. Йөрәкне яндыручылар күп лә ул. Сүндерүчеләр генә аз. Менә минем арттан ике кавалер чаба. Берсе «Запорожец»та, икенчесе «Мерседес»та. Кайсысына карарга да белмим.

Сары чәч. Фу «Запорожец». Шул паршивый «Запорожец»ка үзеңнең артыңнан чабарга позволять итәсеңме?

Кара чәч. «Мерседес»тагы кавалерның комы коелып бара шул. «Запорожец»ныкы сөлек кебек.

Сары чәч. Да, проблема. Ә шул «Запорожец» хуҗасын «Мерседес»ка утыртып булмыймы соң?

Кара чәч. Ничек итеп?

Сары чәч. Ничек икәнен мин каян белим. Миннән — идея, сездән — эш.

Кара чәч. Идея бирүчеләр күп лә ул, эш эшләүче генә юк.

Сары чәч. Йә, ярый, кайгырма. «Запорожец»лар да импортный машина санала ди хәзер. Самый главный — кабындыручысы, яндыручысы булсын.

Кара чәч. Шырпы төрткән саен кабынырга каян ялкын җиткерәсеңдер син, удивляюсь.

Сары чәч. О-о, Гүлечкә. Мин бит йөрәгем белән шагыйрь кеше, артист кеше. Мине һәр гүзәллек кабындыра, яндыра. Мин романтик.

Кара чәч. Ә мин мәхәббәткә не верю. Дөньяда бөтен ир-атлар алдакчы. Үз кирәкләрен алсалар — тизрәк таю ягын карыйлар. Между прочим, мин бер гәзиттә укыдым. Анда язганнар: яратышып өйләнешүчеләргә караганда, по расчету тормыш коручылар кимрәк аерылыша, оказывается. Так что, миңа машиналы, коттеджлы кеше булса, мәхәббәте ерунда.

Сары чәч. Машиналы, коттеджлы егетләргә мин дә не против. Ләкин миңа ул гына җитми: машиналы, коттеджлы кеше мине яндыра алсын. Дөрләгән утларга ташласын.

Кара чәч. Машинасына башка кызларны утыртып йөри башласа, бик тиз янарсың.

Сары чәч. Пускай утыртсын. Хәзер бит свободная любовь. Ул утыртса, мин башкаларга утыра башлармын. Бер кешегә ябышып ятарга мин не собираюсь. Бу бит консерватизм. Минем, ирекле кош

булып, һаваларга очасым килә. *(Кулларын канат итеп җилпеп йөри.)*

Кара чәч. Ә минем очасым килми. Мин җир кешесе. Мәхәббәте пускай ирекле булсын. Ансына мин не против, әмма йортына кайтарып куйган кеше башка юбкаларга карарга тиеш түгел. Ул, хуҗасыннан бер калҗа ит көтеп торган ач эт кебек, минем күзләремә генә карап торсын. Мин шуны телим.

Сары чәч. Аппетит шәп синең.

Кара чәч. Аппетит синдә дә җитәрлек. Между прочим, син теге кавалерың турында сөйли башлаган идең.

Сары чәч. О-о, да, кавалер прямо прелесть. Ул манералары, ул сөйләшүләре.

Кара чәч. Йә, йә. Нәстә ди?

Сары чәч. Сез бу гөнаһлы җирдә түгел, күктә фәрештәләр арасында яшәргә тиеш. Сезнең гүзәллектән күзләр камаша, ди.

Кара чәч. Өенә алып кайтканчы, алар бар да шулай сайрыйлар.

Сары чәч *(сөйләвен дәвам итеп)*. Минем сразы хисләрем кабынды. Йөрәгем советски машина моторыдай шакы-шокы тибә башлады.

Кара чәч. Шуннан, шуннан?

Җыештыручы Фатыйма керә. Аның кулында чиләк белән чүпрәк.

Фатыйма. Хәлләрегез ничек, кызлар?

Сары чәч. Безнең хәлләр һәрвакыт шәп, тетя Фая.

Фатыйма. Шәп булгач ярый. Хәзер бит хәлем шәп дигән кеше бик сирәк. Безнең күршедә гәҗит укып, телевизор карап җенләнгән карт бар. Шул әйтә: илдә хәзер анархия башланды, тиздән монархиясе дә, булыр, ди. Ул анархия белән монархия дигәне ниндирәк әзбир икән, белмисезме, кызлар?

Кара чәч. Юк-бар сүзләр тыңлап башыңны катырма син, тетя Фая.

Фатыйма. Беренчедән, мин тетя Фая түгел, Фатыйма. Икенчедән, тыңламыйм дисәң дә, сүз колакка керә ул. Анархия дигәннәре берәр әшәке кеше булып, шул ил башына менеп утырса...

Сары чәч. И Фатыйма апа, синең өчен ил башында кем утырса да барыбер түгелмени?

Фатыйма. Менәтерә! Нишләп барыбер булсын. Мин бит әле яңа гына яши башладым.

Кызлар. Ничек яңа гына?

Фатыйма. Әйе, яңа гына шул. Нигә аңа гаҗәпләнәсез? *(Хискә бирелеп.)* Әле кайчан гына мин дә, сезнең кебек, бер кашык су белән йотарлык кыз идем. Егетләр башымны әйләндерерлек матур сүзләр сөйлиләр иде. Ә берсе, гүәрдиндәй таза гәүдәлесе, үзенең әфтәмәбиленә утыртып кара төндә мине урлап китте.

Сары чәч. Ой, нинди романтично!

Кара чәч. Ул вакытта нинди автомобиль булсын, юләр сатма.

Фатыйма. Ник булмасын? Барые. Хәзерге машиналар дүрт тәгәрмәчле булса, минем Әхмәтҗанымның машинасы дүрт аяклы иде.

Кара чәч. Сыер җигеп алып кайттымы әллә сине Әхмәтҗаның?

Фатыйма. Тач эзенә бастың. Минем Әхмәтҗаным колхозда үгез җигеп эшли иде. Бер көнне, дөресрәге, бер төнне урманга утын урларга барган бу. Утынын төяргә генә торганда, каравылчы килеп чыккан да, балтасын алып, үзенә ыштраф чәпәп кайтарып җибәргән. Кайтып килгәндә, мин очрадым. «Менә, әни, утын урынына килен апкайттым үзеңә», — диде Әхмәтҗаным. «Бу «утын» сине җылытса да, мине җылыта алмас шул», — диде каенана буласы кешем. «Җылытыр, әни, җылытыр», — диде Әхмәтҗаным. Һәм Әхмәтҗаным дөрес әйтте. Каенана белән утыз ел буе бер-беребезне җылытышып яшәдек.

Сары чәч. Ой, нинди романтично! Үгез белән урлау. Мине дә берәрсе үгез белән урласын иде.

Кара чәч. Элекке кешеләр яратышып өйләнешкәннәр дигән булалар тагын.

Фатыйма. Ә нигә? Без яратышмаган дип уйлыйсыңмы?

Кара чәч. Яраткач нигә соң ул төнлә үгез белән урлый?

Фатыйма. Һы, менәтерә, әйттең сүз. Кем инде көндез үгез җигеп килен төшерә? Ә бит мин Әхмәтҗаныма сугыштан соңгы авыр елларда кияүгә чыктым. Ул чакта колхозның җигәренә аты да юк иде. И-и, үтте инде, баштан әллә ниләр үтте.

Сары чәч *(сәгатенә карый)*. Бар, тетя Фая, эшеңдә бул, юкса Әхмәт Имаевич килер.

Фатыйма. Китәм, китәм. *(Китә башлый да туктап кала.)* Әй, кызлар, сездән бер сүз сорамакчы идем.

Кара чәч. Нинди сүз?

Фатыйма. Күрше карты әйтә: хәзер каты клизмалар чоры, ди. Ул нинди клизма икән, белмисезме, кызлар?

Сары чәч. Каты клизма түгел, катаклизма...

Фатыйма. Клизма булгач җүнле нәрсә булмас инде ул. Аллам сакласын. Бер тапкыр бүлнистә куеп карадылар аны миңа. Атна буе бәдрәфтән чыга алмадым.

Кара чәч. Бар, Фатыйма апа, бар. Безнең монда важный разговор.

Фатыйма. Ярар, ярар, сүләшегез. *(Эшенә керешә.)*

Сары чәч. Нәрсә турында иде әле безнең разговор?

Кара чәч. Сине күккә, фәрештәләр янына менгереп җибәрергә теләүче кавалерың турында иде.

Сары чәч. Ә, әйе. Сезгә йолдыз булып туасы калган, ди. Ә мин әйтәм: йолдыз булып тусам, күккә синең буең җитмәс иде бит, дим.

Кара чәч. Йә, йә, дальше...

Сары чәч *(хыялланып)*. Дальшеме? Аһ, Гүлечкә, аның кочагы, аның кочагы! Оҗмахта да андый рәхәтлек юктыр. Хисләрем дулкын-дулкын булып күкрәгемнән бәреп чыкты. Йөрәгем йолдызларга менеп китте.

Кара чәч. Өенә апкайттымы, кайда булдыгыз?

Сары чәч. Икәүләшеп йөзәбез оҗмах диңгезендә. Уңда дулкын, сулда дулкын. Әллә күктән, әллә җирдән илаһи музыка агыла. Диңгезнең ярлары күренми. Арып-талып хәлдән тайгач, җәннәт җимешләре үсеп утырган бер утрауга килеп чыктык.

Кара чәч. Өе утраудамыни?

Сары чәч. Андагы җимешләр, андагы җимешләр...

Фатыйма, сатучы кызларның «җимешләр» дигән сүзен ишетеп, болар янына килә.

Фатыйма. Нәрсә, кызлар, әллә берәр төрле ят җимеш кайттымы? Миңа да бер-ике кило өлеш чыгарырсыз инде.

Сары чәч. Хәзер бөтен төрле җимешләр тулып ята, тетя Фая. Акчаң булса, ике кило түгел, ике пот бирә алабыз.

Фатыйма. Акчага аны кем дә бирә. Сез миңа үзегезгә калдырган калыйм-шалыймнардан өлеш чыгарыгыз. Югыйсә соңгы вакытта бик саранланып киттегез.

Кара чәч. Башны катырма әле, тетя Фая. Бу дөньяда һәркемнең үз өлеше.

Фатыйма. Ничә тапкыр әйтергә инде сезгә, мин түте Фая түгел — Фатыйма. Сез дә үзегезне Гүлечкә дә, Сүнечкә дип йөрмәгез. Чеп-чи татар кызлары бит сез: Гөлсинә, Сания. Нинди матур исемнәр.

Кара чәч. Деревенщина! Миңа Гулечка диюләре ошыйрак төшә.

Сары чәч. Сонечка да шәп яңгырый. *(Хыялланып.)* Менә хәзер минем каршыма Филипп Киркоров килеп чыгар да: Сонечка, сезнең өчен бер җыр җырлыйммы, дияр кебек.

Кара чәч. Әй, синең Киркоровың да булдымы җырчы! Менә Майкл Джексон дисәң инде.

Сары чәч. Филипп Киркоровны тыңлап кара син.

Сары чәч магнитофон кабыза, Филипп Киркоров җырлый.

Кара чәч *(үз магнитофонын кабыза. Анда Майкл Джексон җыры)*. Менә ичмасам тавыш: импортный!

Ике якта ике магнитофон акыра. Фатыйма колакларына бармакларын тыгып эчкәрге якка кереп китә. Кибеткә бер ир керә. Өс-башы бик пөхтә, әмма гади киенгән.

Ир. Исәннәрмесез, кызлар!

Кызлар аны әллә ишетмиләр, әллә ишетсәләр дә сәламләвенә җавап бирмиләр.

Ир. Исәннәрмесез дим. Татарча аңламасагыз, здравствуйте!

Кызлар икесе берьюлы магнитофонны сүндереп, бөерләренә таянып ир кешенең каршысына килеп басалар.

Икесе берьюлы. Ни кирәк?

Ир. Кибетегез кирәк иде.

Сары чәч. Сезнең белән шаярып торырга вакытыбыз юк безнең. Йә, ни кирәк?

Ир. Кибетегез кирәк, сез кирәк. Сезнең белән якыннанрак танышып чыгасым килде дә кердем менә.

Сары чәч. Син нәрсә, господин абзый. Кибетне әллә авылыңның аулак өе дип белдеңме? Бу кызлар белән танышу урыны түгел.

Кара чәч. Һы, безнең белән танышасы килгән аның. Безнең белән кемнең генә танышасы килмәс! Безнең арттан «Тойота»лар, «Мицибуси»лар белән чабалар. Алай да бик тоттырырга тормыйбыз.

Ир. Шулаймыни?

Сары чәч. Шулай шул, Йолкышетдин абзыкай. Илнең асыл егетләре безнең бер карашыбыздан аварга тора.

Ир. Юк, кызлар. Сез мине дөрес аңламадыгыз. Минем ниятем бүтәнчәрәк иде.

Кара чәч. Бар, бар, юлында бул. Синең кебекләрне без насквозь күрәбез. Имеш, аның нияте бүтәнчәрәк.

Сары чәч. Бик яхшы аңладык без сине, господин бомж.

Ир. Бомж? Ни өчен бомж?

Кара чәч. Сорап тора тагын. Кереп җылыныр урын тапмаган алама бомжлар кибеткә җыела инде. Йоклабрак торсаң, берәр нәрсәңне чәлеп чыгалар.

Ир. Кыяфәтем шундыйга охшаганмыни?

Сары чәч. Кыяфәт, имеш. Алайга китсә, кесә караклары да импортный костюмнан йөри. Без беләгенә түгел, йөрәгенә карап таныйбыз кешене.

Ир. Алай, алай!

Кара чәч. Шулай шул. Авыл көтүеннән качып, шәһәрдә урын таба алмаган сарыкларны күп күрдек инде. Кемнең кем икәнлеге маңгаена язылган була.

Икәүләшеп көләләр.

Ир *(башын юри юләргә салып)*. Аңламадым. Минем маңгаема берәр нәрсә ябышканмы әллә?

Сары чәч *(аңа көзге суза)*. Мә, смотри, маңгаеңа авылың ябышып килгән.

Ир *(көзгедән үзен карый)*. Мин берни дә күрмим, кызлар.

Кара чәч. Аны күрер өчен маңгай күзе генә җитми шул.

Сары чәч. Аның өчен психолог булырга кирәк.

Ир. Сезнең кебек психологмы? Ай-яй! Психологияне нинди университетларда укыдыгыз икән сез. Сер булмаса, миңа да әйтегез әле, кызлар.

Кызлар аның соравын ишетмәгәндәй эчкә кереп китәләр. Каяндыр аралыктан, киштәләр сөртеп йөргән җиреннән Фатыйма килеп чыга.

Фатыйма. И-и, хәерлегә булсын. Иртүк безнең кибеткә дә кеше керер икән! Гадәттә, безгә бүтән кибетләрдән ипи тапмаганда аптырап кына керәләр.

Ир. Әйе, сезнең кибеткә кеше күп йөри дип булмый. Менә кайчаннан бирле беркем күренми.

Фатыйма *(як-ягына каранып)*. Безнең кибет гомер-гомергә хуҗалардан уңмады, энем. Директорыбыз ни Аллага, ни муллага дигәндәй, вакыт үтсенгә селкенеп йөри. Рәтле нәрсә кайтармагач, синең кибетеңә чуртым йөрсенме? Хәзер сәбит заманы түгел: чат саен базар, тыкрык саен магазин. Минекен ал да минекен ал дип, бишкә бөгелеп торалар. Ә безнең кибетнең, кызлар әйтмешли, модасы чыкты инде.

Ир. Кибетегез болай әйбәт кенә күренә. Сатучы кызларыгыз да чибәр. Тик телләре...

Фатыйма. Әйе, телләре үткен. Көн саен кайрап торалар. Әгәр кибеткә кешеләр озаграк килми торса, үзара булса да чәкәләшеп алалар. Ул якка мачтырлыклары бар.

Ир. Кызык, кызык. Нигә алай чәкәләшәләр икән соң?

Фатыйма *(белдекле кыяфәт белән)*. Эстерисне снимать итәбез, диләр. Ул эстерис дигәннәре нindирәк җендер, белмим. Күңелләренә хуш килердәй кеше белән эстерис снимать итмичә дә сүләшәләр алар.

Ир. Минем кай җирем ошамады икән соң аларга? Нигә минем белән алай дорфа кыландылар икән?

Фатыйма *(ир кешене төрле яклап карап)*. Минем кай җирем ошамады дисеңме?

Ир. Әйе, кай җирем?

Фатыйма. Кикригең шиңә башлаган шул синең. Иңнәреңнән бер ун-унбиш елны алып ташлап, магазин янына импортный машинада килеп туктасаң, алар синең муеныңа ефәк булып уралыр иде.

Ир. Кибеткә кем кермәс тә кем чыкмас. Алар һәркем белән әдәпле сөйләшергә тиешләр.

Фатыйма. Тиеш нәрсә күп инде ул. Хөкүмәт безнең пенсияләрне дә вакытында бирергә тиеш тә, әмма бирми бит.

Ир. Сезнеңчә бик кызык килеп чыга: әгәр сезне кемдер алдый икән — сез дә кемнедер алдарга тиешме?

Фатыйма. Су өстән болгана, энем. Көн саен теливизордан төрле жуликларны күрсәтеп торалар. Борын аслары да кипмәгән малайлар әллә нинди ялык-йолык итеп торган машиналарда чабалар. Ул ризыкларның ниндиләрен генә күрсәтмиләр. Табагыңны теливизорга якынрак тотсаң, ишелеп төшәрләр кебек. Кеше күңеленә бер кермәсә бер керә бит ул. Менә шуннан, безнең кай җиребез аларныкыннан ким, дип, төрлечә кылана башлыйлар. Бүтәннәрдән калышасылары килми.

Ир. Ай-һай, бер дә кылануга гына охшамый. Бу аларның чын йөзләре түгел микән?

Фатыйма. Әйттем исә кайттым дигәндәй, кешенең чын йөзен кем белә инде. Ничек кенә булмасын,

безнең кызлар сабрименный, культурный булып күренергә бә-әк яраталар. Мин аларны авылдан килгән чакларыннан ук беләм. Бик тәртипле, бик инсафлы кызлар иде. Дөньясы бозылды бит, дөньясы. Әле менә, дөрес булса, безнең кибетне дә бер жуликка саталар икән дип ишеттем. Ике кешегә бер жулик бит хәзер. *(Көрсенеп куя.)* Жулик кулына калырбыз микәнни?

Ир. Жуликка кибет нигә кирәк булыр икән?

Фатыйма. Мин ансын белмим инде, балам. Безнең күршедә бер карт бар. Көне-төне теливизор карый, гәҗит укый. Шул әйтә: хәзер жуликлар үзләренең пычрак акчаларын юарга кибетләр, рестораннар сатып алалар, ди. Ул пычранган акчаны өйдәге су белән генә юып булмый микәнни соң?

Ир. Белмим шул, апа, белмим. Пычрак акча күргәнем юк.

Фатыйма. Шунсы гаҗәп, ул акча нигә пычрак икән? Минем акчалар бер дә пычранмый, чип-чиста килеш кәшилүктән шуып чыгып китеп кенә тора.

Ир кеше көлә. Сатучы кызлар бу якка чыгалар.

Сары чәч. Тетя Фая, нәрсә анда ляса точит итеп торасың? Эшеңдә бул. *(Ир кешегә.)* Ә синең тоже алдыңнан артык яхшырак. Бу алкашлар җыела торган урын түгел.

Ир. Бәлки, мин берәр нәрсә алырга кергәнмендер. Мин бит сатып алучы, сезнеңчә әйтсәк — покупатель, ә покупатель һәрвакыт хаклы.

Сары чәч. Покупатель булсаң, покупай. Ничу монда окалачиваться итәргә!

Ир. Бигрәкләр дә культурно сөйләшәсез инде, кызлар. Сорбоннода укыдыгызмы әллә?

Кара чәч. Сорбаннодамы, Сармандамы — анда синең эшең юк. Кайда укысак та, синең ишеләрне бер сүз белән ега алабыз.

Ир. Бер шагыйрь әйтмешли: авызыгыз — капчык, телегез — без икән алайса.

Сары чәч. Нәрсә, син безне оскорблять итеп торасың әле. Ни кирәк сиңа монда?

Ир. Оскорблять итмим бит. Киресенчә, сезгә комплимент әйтәм.

Кара чәч. Комплиментларыңны башыңа капла. Юкса крышаң пеләшләнә башлаган.

Көлешәләр һәм икенче якка борылып сагыз чәйнәргә тотыналар. Ир кеше алардан читкәрәк китеп әйберләр караштырып йөри. Фатыйма җыештыру белән шөгыльләнә. Вакыт-вакыт Фатыйма белән ир кеше бер-берләренә карашып алалар. Кызлар өзелгән сүзләрен дәвам итәләр.

Кара чәч. Теге утраудагы җимешләр турында сөйлә әле. *(Киная белән.)* Җимеше шәпме?

Сары чәч. Җәннәт җимеше дә булсын, начар да булсын! Син бит әзрәк әдәбият укыган кеше, беләсеңдер: Анабыз Һава да җәннәттән шул тыелган җимешне татып караган өчен куылган.

Кара чәч. Их, ул тыелган җимеш. Гел үзенә тартып тора каһәр суккыры. Ярый әле гуродка килгәнбез. Монда свобода. Тыелган җимешкә үрелүеңне бөтен авыл күзәтеп тормый.

Сары чәч. Монда культура. Монда хисләрне аңлаучылар яши. Минем күңелем нечкә. Шәбрәк егет күрсәм, эмоцияләрем күкрәгемнән атылып-атылып чыга башлый.

Кара чәч. Хәзерге егетләргә синең эмоцияң кирәкми. Аларга өстән тотарга, астан йотарга булсын.

Ир кеше тамак кырып куя.

Ир. Кызлар-туташлар. Бәлки, сүзегезне өегезгә кайткач сөйләшергә калдырырсыз. Ялгышмасам, бу бит кибет, ә сез эш урыныгызда.

Сары чәч. Сиңа нәрсә кирәк соң, алкаш? Бездә бит аракы сатмыйлар, бәбәкләреңне ачыбрак кара. Бу — ашамлыклар кибете.

Ир. Бәлки, миңа ипи кирәктер.

Кара чәч. Алайса, нигә монда багана күргән милиция сыман акаеп торасың, ал ипиеңне.

Ир. Ипиегез бик каткан.

Сары чәч. Уф, прәме йөрәгемне кузгаттың. Ипиегез каткан, имеш. Йомшагын әбиеңнән сорарсың.

Кара чәч. Тешләрең атныкы кебек күренә әле, кимерерсең. Катысы озаккарак җитәр. Жуй себе на удовольствие.

Көлешәләр.

Ир. Но и лексикон сездә!

Сары чәч. Бездә бар нәрсә дә бар, Аллага шөкер. *(Бөтерелеп ала.)*

Ир. Сагыз чәйнәү дә кибетегезнең атрибутикасына керәме?

Кара чәч. Без ни теләсәк — шуны чәйнибез. Үзебезнең кибетебез.

Ир. Шулай үзегезнеке үкмени? Сатып алдыгызмы?

Сары чәч. Безнең кебекләргә бушка да бирәләр аны. Хөкүмәтнеке — безнеке, безнеке — үзебезнеке.

Ир. Кибетегезгә әйбәт имидж тудырасыз сез.

Сары чәч. Интеллигент булып кыланма. Андыйларны күргән бар.

Кара чәч. Ботыннан тотып селексәң, «а» хәрефе дә төшми инде үзенең.

Сары чәч. Ә беләсеңме, ботыннан тотып селексәң, нәрсә төшә моның?
Кара чәч. Нәрсә?

Сары чәч Кара чәчнең колагына нәрсәдер әйтә. Икәүләшеп көләләр.

Ир. Бик кызык булып китте әле сезнең белән, кызлар.
Кара чәч. Безнең белән всем кызык. Тик синең белән безгә не кызык.
Ир. Минем белән танышырга теләмисез инде алайса.

Кызлар мыскыллы кыяфәт белән ирне әйләнеп чыгалар.

Сары чәч. Ха-ха, танышырга? Безгә үрелгәнче кулыңны импортный сабын белән кырык кат юарга кирәк әле сиңа.
Кара чәч. Аннары әмрикәнский кәчтүм киеп, японский машинага утырырга...
Сары чәч. Аннары ике катлы дүрт балконлы коттедж салып куярга...
Кара чәч. Коттеджыңда диңгез суыннан ясалган бассейн булсын.
Сары чәч. Бассейн янында финский мунча.
Кара чәч. Менә шуннан соң үзеңнең визит карточкаңны безгә сузып карарсың.
Сары чәч. Әйе, бәлки, шуннан соң хисләребез кузгалып китәр.
Ир. Аппетитларыгыз ярыйсы икән үзегезнең. Тик вкусларыгызны бик үк хупламас идем. Американский кәчтүм дигәнегез джинсидыр, мөгаен. Ә бит ул джинсиларны Американың үзендә дә порт эшчеләре генә кия. Японский машина белән дә безнең юлларда ерак китеп булмый.
Кара чәч. Нәстә дип син бездән издеваться итеп торасың әле. Аласыңмы син бирәр нәрсә, юкмы?
Сары чәч. Бар, алкашчик, бар, карачкы шикелле монда кеше куркытып торма. Юкса кибеткә покупательләр килә башлар вакыт җитте.
Ир. Кыяфәтем шундый куркынычмыни?
Сары чәч. Үзеңне күрәсең килсә, әнә урамдагы җыелып торган суга кара, шунда күрерсең.
Ир. Ә нигә урамдагы суга?
Сары чәч. Көзгең юктыр.
Фатыйма. Чынлап та, энем, аласы әйбереӊ булмаса, чыгып китүең яхшырак. Идәнне юып алырмын дигән идем.
Ир. Хәзер, апа, хәзер. Менә бу гүзәл туташларга нәрсәдер әйтмәкче идем. Үзләрен күргәч, телсез калдым.
Фатыйма. Безнең Сания белән Гөлсинә ...
Сары чәч. Тетя Фая, сколько әйтергә була сиңа: Сания түгел — Соня.
Кара чәч. Ә мин Гөлсинә түгел — Гуля.
Ир *(гаҗәпләнгән булып).* Шулаймыни, кызлар? Сез татар кызларымыни? Мин сезне космостан төшкән затлар дип торам тагы. Ярый, танышыйк алайса, мин Сираҗи абзагыз булам.
Сары чәч. Безнең андый абзабыз юк.
Кара чәч. Деревня.
Ир. Булмаса булыр. Бәлки, берәрегез мине үзенә абзыйлыкка алыр, ә?
Сары чәч. Нахал!
Кара чәч. Нәрсә шуның белән сөйләшеп тел әрәм итәргә! Куып чыгарырга кирәк үзен. Тетя Фая, куып чыгар әле шуны.
Фатыйма. Бар, энем, яхшы чакта чыгып кит. Юкса безнең кызлар бик атчайный.
Ир. Күрәм, күрәм. Менә шушы атчайный кызларыгызның кайсын сайлап алырга икән дип тора идем.
Фатыйма. И-и, балакаем. Хатының ташладымыни?
Сары чәч. Ташламыйча! Мондый зануда белән кем торсын. *(Көлә.)*
Кара чәч. Еще безгә үрелмәкче, йонсыз алаша. Артык биек үрелсәң, чалбар төбең ертылыр.
Сары чәч. Чалбар төбең ертылыр да таушалган паспортың төшеп калыр.
Кара чәч. Күптән төшеп калгандыр инде аның паспорты.
Сары чәч. Паспортсыз алаша. Ха-ха-ха.

Кызлар үзләренең сүзләреннән тәгәрәшеп көләләр.

Ир. Кызык, кызык. Минем кем икәнне дә белдегез. Үземә бер менеджер итеп алырга инде әллә сезне?
Сары чәч. Катись отсюда, абзый пләшевич. Әкиятләреңне кайтып әбиеңә сөйлә. Безне менеджер итеп кенә түгел, министр итеп алырга torучылар җитәрлек. Бармыйбыз гына.
Кара чәч. Образауный булып, күзгә төтен җибәрергә тырыша ул.

Сары чәч. Без синең болай да кем икәнеңне насквозь күреп торабыз.

Ир. Алай-алай. Кем соң мин?

Кара чәч. Акылын сыер ялаган алаша дидек бит инде.

Сары чәч. По-моему, ул эчүен ташлаган алкаш.

Ир. Кызык, кызык. Нәрсәдән чыгып болай әйтә аласыз?

Сары чәч. Эчүен ташлаган алкашлар гына шулай бөтен нәрсәгә бәйләнүчән була.

Ир. Мин беркемгә дә бәйләнмәдем шикелле.

Сары чәч. Ипиегез каты дип бәйләнүеңне оныттыңмыни? Ул ипине өч көн сатабыз инде, беркемнең дә каты дигәне юк иде әле.

Кара чәч. Соня, Сонечка, минемчә, бу типның кесәсендә ике бакыр тиене дә юк. Психушкадан куылган бомж бу. Кая барыр урын тапмагач, монда вакыт үткәрмәкче.

Сары чәч. Берәр нәрсәне чәлдерергә йөри бу — күңелем сизеп тора.

Кара чәч. Кагылып кына карасын.

Ир. Нәрсә, әллә милиция чакырырсызмы?

Сары чәч. Уф, тәмам гарык итте.

Кара чәч *(ир кешенең җиңеннән тартып)*. Кая озатырга сине: психушкагамы, милициягәме? Икенең берсен сайла.

Ир. Мин үзем дә икегезнең берсен сайларга дип тора идем. Әллә икегезне дә сайларга инде. Бик ошыйсыз сез миңа.

Кара чәч. Бар, артык туйдырасың. *(Этеп чыгармакчы була. Ир карыша.)*

Ир. Хәзер-хәзер, кызлар. *(Торт янына килә, кайчан чыкканын карый.)* Бу тортны алырмын дигән идем. Срогы чыккан икән.

Сары чәч *(түземсезләнеп)*. Синең үзеңнең срогың чыккан. Күптән списать иткәннәр инде сине.

Ир *(аның тупаслыгын ишетмәмешкә салышып)*. Печеньегыз да онга әйләнгән.

Кара чәч. Чәйнәп торасы булмас. Наверняка хатыныңның теше юктыр. Рәхмәт әйтер үзеңә.

Ир. Йә, ярый, кибет эчендәге бар нәрсәне төреп бирегез алайса. Һәммәсен алам.

Сары чәч *(ахириенә)*. Озатыйк әле моны ераккарак. *(Телефонга ябыша.)* Алло, алло! Милицияме бу?

Ир кеше телефонның рычагын баса.

Ир. Туктагыз әле, тукта. Милиция белән шаярудан да курыкмыйсыз. Минем белән дә кайчаннан бирле шаярасыз.

Кара чәч. И-и, әйттерерсең әллә ни. Синең белән шаярып торырга безне әллә надан деревенщина дип белдеңме?

Ир. Ә-ә, сезнең чынлап сөйләшүегез шулаймыни?

Кара чәч. Бар, бар. Синдәйләрнең алдыннан арты матур. Без Сорбоннода укымасак та, кемнең кем икәнен күрәбез.

Ирне төрткәләп диярлек чыгара башлыйлар. Шул вакыт ишектә кибет директоры Әхмәт Имаевич пәйда була. Кызлар берберләрен бүлдерә-бүлдерә зарланырга тотыналар.

Сары чәч. Әхмәт Имаевич, менә бу кимерелгән сөяк...

Кара чәч. Бывший алкаш...

Сары чәч. Сөрсегән импотент...

Кара чәч. Бомж.

Әхмәт Имаевич. Туктагыз әле, кызлар, туктагыз. Сез нәрсә сөйлисез?

Сары чәч. Кибеттәге бөтен нәрсәне тотып карый, тикшеренә. Ыштансыз ревизор.

Кара чәч. Ипи алырлык акчасы булмаган килеш безне оскорблять итеп йөри.

Елаган булалар, күзләрен сөртәләр.

Әхмәт Имаевич. Ничек оскорблять итте соң ул сезне?

Кара чәч *(еламсырап)*. Ипиегез каткан, печеньегыз уалган дигән була, хәерче.

Сары чәч. Кайсыгызны алыйм икән дип издеваться итә еще.

Кара чәч. Бөтен кибетегезне төреп бирегез, ди, сасы танау.

Әхмәт Имаевич. Туктагыз әле, кызлар. Ул бит дөресен әйткән. *(Ипине тотып карый.)* Ипиегез чынлап та таштай каты.

Сары чәч. Соң, Әхмәт Имаевич, искергәнен сатып бетермичә яңасын чыгармагыз дип үзегез әйттегез бит.

Әхмәт Имаевич *(теге иргә карап)*. Күрәм, Сираҗи әфәнде, сез безнең кызлар белән танышып та өлгергәнсез.

Сираҗи. Әйе, кайчагында инкогнито йөрү файдалырак була шул.

Сатучы кызлар да, Фатыйма апа да берни аңламый: әле Әхмәт Имаевичка, әле Сираҗига карыйлар.

Әхмәт Имаевич. Безнең кызлар утта янмый, суда батмый торган сорттан дип әйттем бит мин сезгә.

Сираҗи. Күрдем, күрдем. Кызларыгыз бик культурный, бик образованный икән.

Әхмәт Имаевич. Ну, ничек соң, аласызмы?

Сары чәч. Что за шутки, Әхмәт Имаевич?

Кара чәч. Берни аңламыйбыз, Әхмәт Имаевич.

Әхмәт Имаевич. Ә-ә, мин сезгә әйтмәдеммени әле?

Кызлар. Нәрсәне, Әхмәт Имаевич?

Әхмәт Имаевич. Менә, кызлар, сезнең яңа начальнигыгыз Сираҗи әфәнде була.

Сары чәч. Как?

Кара чәч. Ә сез, Әхмәт Имаевич?

Әхмәт Имаевич. Минем җырым җырланды.

Сары чәч. Юк, без риза түгел, шулай бит, Гулечка?

Кара чәч. Шулай, Сонечка. Безгә яңа нәчәлник кирәкми. Без сине яратабыз, Әхмәт Имаевич.

Кызлар Әхмәт Имаевичка барып сылананалар. Берсе башын сыйпый, берсе аркасыннан кага.

Сары чәч. Без министрга барып җитсәк җитәрбез, әмма сезне җибәрмәбез.

Кара чәч. Әйе, без министрга гына түгел, президентка барачакбыз.

Әхмәт Имаевич. Мин сезгә бик үк дөрес әйтмәдем. Сираҗи әфәнде кибеткә яңа директор булып түгел, хуҗа булып килә. Ул кибетне аукционда сатып алды. Биш йөз миллионга! Хәзер монда министр да, президент та берни эшли алмый. Заман акчалылар кулына күчте.

Кызлар икесе берьюлы һуштан язып авалар.

Әхмәт Имаевич. Фатыйма апа, су китер.

Фатыйма. Хәзер, җаным, хәзер. *(Идән юа торган чиләген күтәреп Әхмәт Имаевичка суза.)*

Әхмәт Имаевич. Син нәрсә? Чиста су алып кил, стакан белән.

Фатыйма стакан белән су китерә. Әхмәт Имаевич авызына су алып кызлар өстенә бөрки. Әмма кызлар һушларына килмиләр. Әхмәт Имаевич кулындагы стаканны Сираҗи ала һәм ул да кызлар өстенә бөрки. Кызлар берәм-берәм башларын күтәреп карыйлар да каршыларында Сираҗины күргәч яңадан авалар.

Фатыйма. Әллә врач чакыртыйкмы, Әхмәт энем?

Әхмәт Имаевич *(кызларга күз ташлый)*. Болай да һушларына килеп маташалар бугай инде. *(Кызларга иелә.)* Ничек, кызлар, врач чакыртырга кирәкмиме?

Кызлар торып утыралар.

Сары чәч *(дорфа гына)*. Кирәкми, без предательләр ярдәменә мохтаҗ түгел.

Әхмәт Имаевич. Авызыгызны үлчәп ачыгыз, юкса мин сезне...

Кара чәч. Юкса нәрсә эшләтә аласың син безне? Списанный директор. Син җүнле кеше булсаң, алдан предупредить иткән булыр идең. Әхмәт Имаевич түгел, Ахмак Имаевич син.

Әхмәт Имаевич *(ярсып)*. Ә шулаймы? Күрсәтермен мин сезгә Ахмак Имаевичны!

Сары чәч. Безгә күрсәтәсе җирләреңне күрсәттең инде син. Хәзер әнә әбиеңә кайтып күрсәт.

Фатыйма. Туктагыз әле, кызлар. Сания, Гөлсинә. Нигә болай пырдымсызланасыз? Әле бит Әхмәт Имаевич дип үлеп тора идегез.

Сары чәч. Безгә списанный директорлар кирәкми.

Кара чәч. Без Сираҗи әфәнде белән генә сөйләшәбез.

Сары чәч. Әйе, безгә аның белән кызык.

Әхмәт Имаевич. Сөйләшегез, сөйләш. Билләрегез бөгелмәсә дә, телләрегез бөгелә сезнең. Ярый, кызлар, мин киттем. Калган гомерне Сәрби әбиегез белән чүкердәшеп яшик әле. Юкса сезнең богаудан ычкыну кыен иде.

Чыгып китә.

Фатыйма *(үз-үзенә)*. Минем дә эш бетте бугай. Бая бу адәмгә әллә ниләр әйтеп ташладым. Әй бу тиктормас телне! Ниндидер жулик кибетне ала, имеш. *(Сираҗига карый.)* Жулик булса да, әйбәт жуликка охшаган бу. Иншалла, картайган көнемдә чүпрәк белән чиләктән аермас.

Чыгып китә.

Сираҗи да ишеккә килә. Ләкин кызлар йөзләрендә елмаю балкытып аның каршысына килеп басалар.

Сары чәч. Ныклап танышыйк әле, Сираҗи әфәнде. Мин Сания туташ булам.

Кара чәч. Ә мин Гөлсинә туташ.

Сираҗи. Шулаймыни? Мин сезне Гуля белән Соня дип торам бит әле.

Сания. Соня үлде инде ул. Хәзер Сания генә калды.

Гөлсинә. Гуля да үлде. Гөлсинә генә калды.

Сираҗи. Танышыйк дисез инде алайса?

Сания. Әйе, танышыйк, Сираҗи әфәнде. Иркенләп, матур итеп. Уф, кинәт йөрәгем кузгалып китте.

Гөлсинә. Монда йөрәгең түгел, әллә кай җирләрең кузгалыр.

Сания. Сираҗи әфәнде, бәлки, сезгә кофе яки лимонлы чәй китерергәдер?

Гөлсинә. Бәлки, бер-ике йотым коньяктан авыз итәрсез, ә? Француз коньягы. Бик кадерле кунакларга гына тотабыз.

Кызларның берсе чәй, берсе коньяк чыгарып утырта. Кулларына күз дә иярми. Сагызларын да Сираҗи күрмәгәндә авызларыннан алып ташлыйлар.

Сираҗи. Мәшәкатьләнмәгез, кызлар-туташлар. Мин коньяк эчмим. Кофе да.

Сания. Алайса, шампанский ачам.

Сираҗи. Юк, юк, берни дә кирәкми. Минем вакытым юк. Мин хәзер китәм.

Кызлар. Ә без?

Сираҗи. Сезгә иртәгә расчет бирерләр.

Сания. Сираҗи әфәнде, без бит бая шаярдык кына. Егет кеше аны гына аңларга тиеш.

Гөлсинә. Әйе, сезне без бер күрүдә ошаттык та, бераз шаярып алырга булдык.

Сираҗи *(аларга ышанган булып).* Шулаймыни?

Кызлар. Ну конечно, Сираҗи әфәнде, сездәй егетләр белән кемнәр генә шаярмас икән. *(Кызлар бер-берләренең кулларын тотып Сираҗи әфәндене уртага алып җырлыйлар.)* Үзебезнең татар егете бит син. Без дә татар кызлары.

Сания. Алма биреп ашатырлар,
Ашама, җаныкаем.
Гөлсинә. Ташла, диеп, ташлатырлар,
Ташлама, җаныкаем.
Икесе бергә. Кошлар кунып сайрый икән
Әрәмә гөлләренә.
Сания. Беребез былбыл,
Гөлсинә. Беребез тургай,
Икесе бергә. Кунарбыз иңнәреңә.

Сираҗи аларның әсирлегеннән котылырга тырыша. Ләкин кызлар аны кул арасыннан чыгармыйлар.

Икесе бергә. Алма бакчасын чабыгыз,
Үткен булса чалгыгыз.
Сания. Беребез — алтын.
Гөлсинә. Беребез ялкын.
Икесе бергә. Безнең шундый чагыбыз.

Сираҗи кинәт кенә иелеп болардан котылмакчы була, ләкин кызларның берсе аны бот арасына кысып ала. Сираҗи бот арасыннан башын тартып алмакчы була.

Сираҗи. Җитте, шаярмагыз.

Сания. Синең кебек егетләрнең урыны шунда.

Сираҗи. Мин егет түгел, мин — импотент.

Гөлсинә. Ничего. Гормоннар эчербез.

Сания. Экстросенсларга йөртербез.

Гөлсинә. Өшкертербез-төкертербез. Егерме яшьлек егет итәрбез.

Сираҗи. Җибәрегез. *(Тыпырчына.)*

Сания. Тыныч кына ят, матурым. Егетләрнең иң зур мечтасы шул бит инде.

Гөлсинә. Оҗмах капкасына кысылып калдыңмыни, җаныем? Бәлки, гөнаһларың зур булгандыр.

Гөлсинә Сираҗиның артына сугып ала. Сираҗи кызның аягын тешли. Кыз кычкырып җибәрә. Сираҗи әсирлектән чыга.

Сания. Ай-вай, сыйрагым! *(Аягын уа.)* Тешләрең үткен икән әле. Болай булгач синдә өмет бар. Хисләремне дөрләтеп җибәрдең.

Гөлсинә. Синеке генә түгел, минем хисләр кайный башлады монда.

Тагын Сираҗиның ике кулыннан эләктереп алалар.

Сания. Аппагым дип назлармын.
Гөлсинә. Йомшагым дип назлармын.
Икесе бергә. Алда әле, алда әле
Ал чәчәкле язларың.

Сиражи *(кызларның икесен ике якка этеп җибәрә)*. Җитте! Туктатыгыз бу кәмитне. Барыбер куачакмын мин сезне. Миңа сезнең кебек кортлы алмалар кирәкми.

Кызлар. Ә-ә, шулаймыни? Ярар инде алайса. *(Кызлар бер-берсенә карашып нидер аңлашалар.)* Нишлисең бит, хушлашырга икән хушлашырга! Сау бул!

Сиражи. Сау булыгыз!

Сиражи чыгып китә башлый. Ул ишеккә юнәлгәч, кызларның берсе Сираҗиның арт чүмеченә нидер белән китереп суга. Сиражи идәнгә ава.

Кызлар. Менә шулай. Без сине бөкләп борыныбызга тыгабыз әле, бик кәперәймә. Современный кызлар без.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Пәрдә ачылганда Сиражи ялгызы гына. Аны урындыкка утыртып, он капчыгына аркасын терәп бәйләп куйганнар. Авызына чүпрәк тыкканнар. Ул ык-мык килә. Торырга маташа, ләкин авыр капчык аны җибәрми. Пәрдә артында «Их сез, матур кызлар» көе яңгырый. Җырның кайбер сүзләрен үзгәртеп җырлый-җырлый Сания керә.

Сания. Дус-ишләрем уйный-көлә,
Мин генә көлмим.
Уенның да ямен тапмыйм,
Ни булды, белмим.
Их, мин юләр кызый,
Нәрсә эшләдем.
Йөрәгемнән ташып тора
Кайнар хисләрем.

Хәлең ничек, кавалер, башың бик авыртмыймы? Катырак тондырырга туры килде, гафу ит. *(Сираҗиның авызыннан чүпрәген ала.)* Һаман шул эмоциональлегем аркасында инде.

Сиражи *(төкереп куя)*. Тфү! Шундый түбәнлеккә төшәргә кирәк бит. Каян килеп чыктыгыз сез?

Сания. Чыга торган җире бер генә инде аның, Сиразчик.

Сиражи. Чыккан җире бер булса да төшкән җире төрле булган, күрәсең.

Сания. Сиразчик, кемнең каян чыкканын, кая төшкәнен тикшереп утырмыйк әле. Син — егет, мин —кыз. Ә егет белән кызның сөйләшер сүзләре бардыр дип уйлыйм.

Сиражи. Мин егет түгел шул инде.

Сания. И-и, алайга китсә, мин дә кыз тү... тү... Ә, әйе, син ир кеше. Настоящий ирләр нәкъ менә синең кебек булырга тиеш. Мин гомерем буена синең кебек кешене очратырга хыялланып яшәдем. Бая кибеткә килеп кергәч тә хисләрем ташырга тотынды. Ә йөрәгем: «Бу синең өчен туган», — дип күкләрнең җиденче катына очына башлады. Йөрәгем бер төрле әйтә, телем икенче төрле сөйли. Тәмам башымны югалттым. Барсы да шул йөрәк аркасында: йөрәк уйный, йөрәк шаяра.

Сиражи. Йөрәгегез каты шаяра икән шул. Башыма да йөрәгегез белән тондырдыгыз бугай.

Сания. Син хатын-кызларны белеп бетермисең, Сиразчик. Без бит ирләрне күпме ныграк яратсак, шуның кадәр грубыйрак шаяртабыз.

Сиражи. Мәхәббәтләрен башка сугып белдерүчеләрне күргәнем юк иде әле.

Сания *(хискә бирелгән булып)*. Бәләкәйдән үк артык хисле бала идем мин. Тик торганда күңелем тулып еларга гына тора идем. Бервакыт шулай ишегалдында генералдай олы әтәчебезнең бер тавык өстенә менгәнен күрдем дә: «Әнкәй, тавыкны әтәч басып үтерә», — дип кычкырып җибәрдем. Әнкәй йөгереп чыкты. Эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлагач: «Ай, кызым, — диде, — бигрәк нечкә күңелле бала инде син, сиңа дөньяда яшәү авыр булыр», — диде. И бик дөрес әйткән булып чыкты. Чынлап та, нечкә күңелле кешеләргә авыр бит.

Сиражи. Нечкә күңелләләрнең авызында агач тел, кулында күсәк булырга тиешмени?

Сания. Бу минем тышкы кабыгым гына, Сиразчик. Шундый кабыклы булмасаң, дөньяда ничек яшәргә кирәк?!

Сиражи. Тышкы кабыгыгыз ничәү икән соң сезнең? Тышкы кабыгыгызны күлмәк урынына

алыштыра башласагыз, кабык җитмәс бит.

Сания. И Сиразчик, беләгемә түгел, йөрәгемә кара.

Йөрәгемдә минем утлар яна,
Мең кешене җылыта алам.
Күкрәгемдә оҗмах алмалары,
Алмаларны учларыңа салам.

Сираҗи. Сез шулай шигырьләр дә беләсезмени әле?

Сания. Без барсын да беләбез, Сиразчик. Кая, үзеңне йөрәк җылым белән җылытыйм әле. Бәлки, алмаларымнан да авыз итеп карарсың. *(Сираҗины кочаклап үбеп ала. Сираҗи каршылык күрсәтергә тырышып башын боргалый.)*

Сираҗи. Җитте, бая башка тондырып бик каты җылыттыгыз, тагын да җылытсагыз, дөрләп януым бар.

Сания. Барсы да минем артык хисчәнлегем аркасында. Миңа шагыйрь булып туарга калган да бит. Юк, язмыш бүтәнчәрәк уйлаган. Күңелем күкләргә ашкына — аягым җирдә. Нишләргә дә белмим. Әллә чынлап та бу эшне ташлап шагыйрь булып китәргә инде. Шагыйрьләргә акчаны күп түлиләр микән?

Сираҗи. Һәр юл өчен ничәдер мең бугай.

Сания. Чынлапмы? Бетте, бүгеннән ташлыйм бу эшне. Шигырь яза башлыйм. *(Уйланып.)*

Яна йөрәк, яна, яна, яна...
Тама акча, тама, тама, тама...

Кара әле, Сиразчик, «яна-яна», «тама-тама»ларны аерым-аерым юлларга язсам, һәр юл өчен фәлән меңне түләрләр микән?

Сираҗи. Белмим шул, шигырь язып караганым юк.

Сания. Чынлап тотынсам, шигырен дә, поэмасын да яза алырыма полный ышанам. Әмма аны язар өчен уйлап утырырга кирәк. По-моему, җырчы булу яхшырактыр. Җырчының эше җиңел — бер үк җырны көн саен чыга да җырлый. Әле күбесенең ни тавышы, ни моңы! Йөриләр шунда селкенеп. Үзем сәхнәгә чыксаммы?! О-о, миндәге хис, миндәге кайнарлык. Мин йөрәк белән җырлыйм. Тыңлап кара әле, Сиразчик. *(«Әгәр белгән булсам» җырын җырлый.)*

Кайгылар да баса алмас иде,
Йөрәгемдә ташкан шатлыкны.
Әгәр белгән булсам,
Әгәр белгән булсам,
Бу дөньяда синең барлыкны.

Алларыңа чыгып торыр идем,
Тик син булыр иде көткәнем.
Әгәр белгән булсам,
Әгәр белгән булсам,
Сукмагыңның кайдан үткәнен.

Йә, Сиразчик, йөрәк тавышым барып җиттеме сиңа?

Сираҗи. Мондый сәләтегез булгач, артистлыкка гына китәсегез калган.

Сания. И артистларның тормышы да эт тормышы инде. Дурак сыман көн саен бер җырны чык та җырла, чык та җырла.

Сираҗи. Төрлесен җырларсыз. Җырлар күп бит.

Сания. Юк, Сиразчик, миңа акча санау ошыйрак төшә. *(Сираҗиның башыннан сыйпый.)* Әйбәтем минем, акыллым минем. Мин йөрәгемдәге хисләремне шигырь итеп әрәм итмәм, бөтен назымны сиңа гына бирермен, Сиразчик.

Сираҗи. Миңа назлаучы түгел, эшләүче кирәк.

Сания. Эшне аны дурак та эшли. Аюлар да әнә циркта бер кисәк ит өчен ни генә кыланмыйлар. Ә мин ярата беләм, назлый беләм. Минем йөрәгем тулы наз.

Сираҗи. Сөйләшүләрегезгә караганда, ул назларыгыз күлендә бик күп кешеләр коенган булырга охшый.

Сания. Их, Сиразчигым минем, наз ул шундый нәрсә — кешеләргә никадәр күбрәк өләшсәң, шуның кадәр арта бара. Авылдан килгән чакларда минем күңелем буш сандык кебек иде. Хәзер ул сандыкта ниләр генә юк.

Сираҗи. Хисләрне коллекционировать итәсез инде алайса. Мәхәббәт сезнең өчен хоббига әйләнгән.

Сания. Йөрәк януларын хобби дип уйлыйсың икән, әйдә, уйлый бир. Тик шуны гына әйтәм: мин дөньяга иректә кош булып тудым. Мин очарга тиеш, очарга.

Сираҗи. Кибеттә бит очып булмый. Ерак китим дисәң — стенага килеп төртеләсең, югары очыйм дисәң — башың түшәмгә бәрелә.

Сания *(Сиражҗиның башыннан сыйпап)*. Юк, Сиразчик, син мине дөрес аңламадың.
Сиражи. Аңлатып карагыз алайса.
Сания. Әйе, мин очар өчен, очышта янар өчен яратылганмын. Әмма кошларның да үз оялары була. Очар кошлар да җиргә төшеп җим чүпли. Ә минем җим чүпли торган урыным — кибет.
Сиражи. Менә хәзер барып җитте. Кибеттә каласың килә алайса.
Сания. Килә, Сиразчик, килә. Кибеткә барып керү белән мин сәхрәгә чыккан кош кебек сизә башлыйм. Былбыллар агачтан агачка, чәчәктән чәчәккә кунып һәр тереклек иясен, һәр үсемлекне ничек назласа, мин дә кибеткә керүгә һәрнәрсәгә кагылып узам. Минем кулым кагылган ризык тагын да тәмләнеп китәдер кебек тоела миңа.
Сиражи. Ай-яй матур сайрыйсың. Хәтта ышанасы килә башлады.
Сания. Ышан, Сиразчик, ышан. Йөрәгем минем алдамый. Менә тыңлап кара әле. *(Сиражҗиның битенә күкрәге белән терәлә. Аннары хисләнеп җырлый башлый.)*

Агыйделдән агып килә
Агыйделнең бозлары;
Ялкынланып сөя белә
Безнең авыл кызлары.

Гөлсинә керә.

Гөлсинә. Хисләнәбезме?
Сания. Хисләнәбез, Гүлечка, хисләнәбез. Тыңлаучы булганда нигә хисләнмәскә? Бакчадагы сандугачлар да бит кешеләр тыңлап торганда матуррак сайрыйлар.
Гөлсинә. Каян беләсең аны? Кешеләр үзләре югында кошларның ничек сайравын ишетми бит.
Сания. Шуңа күрә кешеләр югында сайрамый алар. Кешеләр йоклаганда кошлар да йоклый.
Гөлсинә. Төнлә сайраучы кошлар да бар.
Сания. Димәк, төнлә кемдер йокламый. Ул кош шуның өчен сайрый. Дөньяны бит аны мәхәббәт җепләре уратып алган. Әнә шул мәхәббәт җепләрен бер күңелдән икенче күңелгә сузасы, йөрәкләрне йөрәкләр белән тоташтырасы гына бар. Ә без кайвакыт шуларны тоташтырасы вакытта үз кулларыбыз белән өзеп ташлыйбыз, тупасланабыз. Бая Сиражи әфәндегә дә нинди тупаслык күрсәттек. Шуның өчен үземне һич гафу итә алмыйм. Уф! *(Күкрәгеннән йөрәген йолкып алгандай итә.)*
Гөлсинә. Тупасрак килеп чыкты шул. Мин дә Сиражи әфәнде янына гафу үтенергә дип килгән идем. *(Күкрәгенә кулын куеп.)* Гафу итегез, Сиражи әфәнде, ычкыныбрак кителде.
Сиражи. Теге мәзәктәге шикеллеме?
Гөлсинә. Нинди мәзәк?
Сиражи. Бер патша, көннәрдән бер көнне үзен танытмас өчен сәләмә киемнәргә киенгән дә халык арасына чыгып киткән. Үзе турында кешеләр ни уйлаганын беләсе килгән аның. Йөри торгач, бер картны очраткан ул. «Әй картлач, — дигән патша, — син үзегезнең патшагыз турында ни уйлыйсың? Әйбәт кешеме ул, начармы?» «Тфү! — дигән карт. — Аның турында сөйләп тел пычратасым да килми». «Ни өчен?» — дип төпченгән патша. «Күрмисезмени? — дигән карт. — Бөтен җирдә хәерчелек, өстәвенә көчлеләр көчсезләрне талый. Халык ыңгыраша — патша халык зарын ишетми. Халык зар елый — патша халыкның күз яшьләрен күрми. Безнең патша сукырдыр, чукрактыр». Патшаның бу сүзләргә бик ачуы килгән һәм ул: «Менә мин патша. Сине бу сүзләрең өчен зинданга яптырам», — дигән. Шул чакта карт эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алган һәм күктәге кояшка күз ташлап: «Ә-ә, төш җиткән икән, төш җиткәндә минем ычкынгалап китә торган гадәтем бар», — дигән. Менә шундый мәзәк.
Сания. Гыйбрәтле мәзәк.
Гөлсинә *(Саниягә)*. Между прочим, анда сине бер кореец көтә.
Сания. Кореец?
Гөлсинә. Әйе. Кысык күзле, сары йөзле бер нәмәстәкәй шунда. Каян табасыңдыр шундыйларны. Вкусыңны әйтер идем.
Сания *(Гөлсинәгә усал карап)*. За то ул калтыравык «Запорожец»та йөрми. *(Чыгып китә.)*
Сиражи. Бер-берегезне чеметкәләргә яратасыз, ахры.
Гөлсинә. Үзебездән югарыларны чеметә алмыйбыз, түбәндәгеләрне чеметүдән кызык юк. Ачу килгән саен үзара чеметешергә генә кала инде.
Сиражи. Ә ачу еш килеп торамы?
Гөлсинә *(кул селтәп)*. Һи, аларны саный башласаң. Көненә йөз тапкыр дөньяның астын өскә әйләндерәсе килгән чаклар була. Бая сезнең белән тупас сөйләшкән кеше дә мин түгел идем бит.
Сиражи. Шулаймыни? Ә кем иде соң ул?
Гөлсинә. Минем җенем иде.
Сиражи. Кызык, кызык. Сезнең җенегез дә бармыни?

Гөлсинә. Безнең һәрберебезнең җене бар, Сираҗи әфәнде. Кайвакыт ул җен өскәрәк калкып чыга, кайчак эчтәрәк яшеренеп ята. Бары шул гына. Мин сезгә турысын әйтәм, Сираҗи әфәнде *(Сания киткән якка ымлап)*, кайберәүләр кебек хисләнеп маташмыйм. Бая сез минем җенемне чыгардыгыз. Үзегез беләсез, телдән бер тупас сүз ычкынса, икенчеләре көтеп кенә тора. Сүз артыннан сүз китә. Теләсәң-теләмәсәң дә үзең шул образга керә башлыйсың.

Сираҗи. Образга керергә — без бит сәхнәдә түгел, тормышта. Ә тормышта һәркем төрле образларга керә башласа, яшәү уенга гына әйләнеп калмасмы соң?

Гөлсинә. И Сираҗи әфәнде, тормышта бит без сәхнәдәгедән дә ныграк уйныйбыз. Бер кеше алдында бер төрле кыланабыз, икенче кеше янында икенче төрле. Менә безнең директорыбыз Әхмәт Имаевич ишәк кебек аңгыра, киребеткән бер нәрсә инде. Ә без аңа: «Сездән дә акыллы кеше юк», — дия идек. Шулай димәс идең, кешечә яшисе килә.

Сираҗи. Кешечә яшәргә тырышабыз шул, үзебезчә түгел.

Гөлсинә. Дөньяда беркем дә үзе теләгәнчә генә яши алмый. Туу белән безне әти-әниләребез үзләренчә тәрбияли башлый. Без карышабыз, тартышабыз. Кайчакта әти-әниләрнең хаксыз таләпләр куюын да беләбез, әмма буйсынабыз. Чөнки алар бездән көчлерәк. Мәктәпкә киткәч, мәктәп безне үз кагыйдәләренә буйсындыра. Урамга чыксак, көчлерәкләр, хәйләкәррәкләр көтеп тора. Бая Сания, дөньяны мәхәббәт җепләре уратып алган, дигән иде. Юк, мәхәббәт җепләре түгел, мәкер җепләре чолгаган дөньяны. Дөнья — үрмәкүч оясы, без — бөҗәкләр. Очкан булабыз, каядыр омтылган булабыз, һәм, көннәрдән бер көнне үрмәкүч пәрәвезенә килеп чорналабыз.

Сираҗи. Ярый, сезнең фәлсәфәне аңладык. Миннән нәрсә көтәсез?

Гөлсинә. Кумагыз мине, Сираҗи әфәнде. Кибеттә эшләү ошый миңа. Кибеттән кусагыз, мин кая барыйм?

Сираҗи. Ансы минем эш түгел.

Гөлсинә. Ничек сезнең эш булмасын? Без бит татарлар. Ә татарлар — бер-берсе белән туганнар. Әгәр без бер-беребез турында кайгыртышмасак, безнең өчен кем кайгырыр?

Сираҗи. Димәк, сез минем туганым булып чыктыгыз. Белми идем мондый туганым барын.

Гөлсинә. Сез көләсез, Сираҗи әфәнде, сезгә кызык. Чөнки сезнең кулда акча бар. Ә акча — патша, акча — хан. Хан булгач көләргә дә, боерырга да була.

Сираҗи. Ярый, сезнең кулда акча юк, ди, сез боера да, үзегез теләгәнчә эшли дә алмыйсыз, ди. Әмма тупас булмаска мөмкиндер бит?

Гөлсинә *(уйланып)*. Әйе, мөмкиндер. Ләкин без күп вакыт үзебездән начаррак булып күренергә тырышабыз. Яхшы булсам, миннән көләрләр дип куркабыз. Миннән куркып Сания, Синиядән куркып мин шулай кыланам. Әле дә хәтеремдә: шәһәргә килеп эшли башлаганда, мин бар нәрсәгә ышанучан авыл кызы идем. Унны бетерүгә шәһәргә килдем. Авылдагы гадәт буенча кайчак урамдагы кешеләргә «исәнмесез» дип эндәшәм. Кешеләр сәерсенеп миңа карый. Сания миннән кычкырып көлә. Мич башыннан төштеңме әллә, хәзер зуррак авылда да кешеләр бер-берләре белән исәнләшмиләр. Некультурный, ди. Аның шулай «некультурный» дип көлүеннән куркып тупасрак кылана башладым.

Сираҗи. Димәк, начарлыкка сезне Сания өйрәтте?

Гөлсинә. Юк, мин алай дип әйтергә уйламаган идем. Яманлыкны без бар кешедән дә җыябыз. Кешегә пычрак бик тиз йога, чистарыну гына авыр.

Сираҗи. Уф, кулларым оеды, чиш әле.

Гөлсинә. Чишәм, чишәм. Әллә кайчан чишәргә кирәк иде дә бит, үз кайгым аркасында онытып җибәргәнмен.

Сираҗины бәйләгән бауны чишә башлый. Шул вакыт Сания керә.

Сания. Нишлисең син, тинтәк?

Гөлсинә. Бер кулын ычкындырыйм дигән идем. Заявлениеләргә подписать итәргә кирәк бит инде.

Сания. Ә, әйе, заявлениеләр. *(Сумкасын актара.)* Менә, Сиразчик, шушында кулыңны куеп җиффәр дә күрсәт әле егетлегеңне!

Сираҗи. Әле һаман минем егетлегемә шикләнәсезмени?

Сания. Юк, Сиразчик, егетлегең синең әллә каян күренеп тора. Шуңа күрә безнең дә кызлыгыбызны күрсәтәсебез килә.

Сираҗи. Кызлыгыгызны? Юк, юк, кирәкми, күрсәтмәгез. Миңа һәр кешене елмаеп каршы алучы, рәхмәт әйтеп озатучы сатучылар кирәк. Бары шул гына.

Сания. И-и, елмаерга без булдырабыз. *(Авызын шакмакландырып үз-үзенә сөйләнә.)* Рәхим итегез, бабакай, сезгә ипинең йомшагы кирәкме? Менә бусы сеп-себижый. Ә сезгә, әбекәй, конфет кирәкме? Менә монсы чикләвекле шоколад конфет. Эчендә коньяклысы да бар. Коньяклы конфет белән сәйлүн чәе эчеп җибәрсәгез, кәефегез күтәрелер. Ә сез, апа җаным, сдачагызны алырга оныттыгыз. Алыгыз, ал. Безнең кибеткә керүегез өчен рәхмәт. Әйбер алу өчен генә түгел, болай гына булса да кибетебезгә

кергәләп йөрегез. Кешеләр белән сөйләшү — үзе олы бәхет бит ул.

Гөлсинә *(аны дәвам итә).* Тамагыгыз кипкән булса, самавырыбыз кайнап тора. Лимонлап берәр чынаяк чәй эчеп җибәрегез. Ә син, үскәнем, менә бу шоколадны ал. Авызда эреп тора. Рәхмәт, матурым. Әти-әниләреңә сәлам әйт.

Сираҗи. Булдырасыз икән. Ә ни өчен соң сез шулай азгынландыгыз?

Сания. Ни өченме?

Гөлсинә. Аның сәбәпләре...

Фатыйма керә.

Фатыйма. Анда ике нәмәстә сезне чакыра, кызлар. Ишекне дөбер-дөбер китерәләр. Безнең нәмәстәкәйләр чыксын әле, диләр.

Сания. Нинди нәмәстәкәйләр?

Фатыйма. Ансын чыккач үзегез күрерсез. Барыгыз, бар.

Кызлар чыгып китә.

Фатыйма. Алдалап чыгардым. Бераз эзләсеннәр әле теге нәмәстәкәйләрен. *(Сираҗины бер кат әйләнеп чыга.)* И энем, нишләттеләр сине? Кара инде бу эзбирләрне. *(Сираҗиның кулларын чишә.)* Тизрәк таярга тырыш моннан, энем.

Сираҗи. Юк, таймыйм. Бу бит минем үз кибетем.

Фатыйма. Карале, энем, хак дөресен генә әйт әле: син чын жуликмы?

Сираҗи. Нәрсә, жуликка охшаганмынмыни?

Фатыйма. Соң, ни бит, энем, биш йөз миллион акча бик күп була түгелме соң? Мин менә алтмыш җиде яшьтә. Шуның илле елын эшлим, биш йөз миллион түгел, биш йөз меңен дә күргән юк. Шуңа төшенә алмаганга гына соравым.

Сираҗи. Аны аңлату озак инде, апа.

Фатыйма. Безнең күршедә бер карт бар. Шул әйтә, бөтен акча марфияләр белән рәкитүрләр кулында, ди. Әллә соң, балам, син дә берәр рәкитүрме?

Сираҗи. Юк, апа. Мин пычрак кул белән акча эшли торган кеше түгел.

Фатыйма. И-и, мин сине чын рәкитүр дип торам тагын. Күрше картына чын рәкитүр күрдем дип мактанырмын дигән идем.

Сираҗи. Чыннарын күрергә язмасын диген, апа.

Фатыйма. Марфияләр белән рәкитүрләргә минем идән юа торган чүпрәк белән тутыккан чиләгем кирәкмидер әле.

Сираҗи тәннәрен язып әрле-бирле йөренә. Аннары Фатыйма янына туктый.

Сираҗи. Телевизорны күрше карты гына түгел, үзегез дә яратып карыйсыз, ахры. Мафиозниклар, рэкетерлар кинодан караганда гына кызык алар. Сезнең көтеп алган соңгы пенсия акчаларыгызны тартып алсалар яки гомер иткән фатирыгыздан куып чыгарсалар, бер дә аларны күрәсегез килмәс.

Фатыйма *(куркып).* Авызыңнан җилләр алсын, балам. Андый нәрсәне Ходай күрсәтмәсен. Әле минем, шөкер, бер бүлмәле фатирым бар. Пенсиям өстенә кибеттән дә бераз тамып тора. Тик кызларны бераз акылга утыртырга иде. Синең кулдан килә инде бу, энем.

Сираҗи *(аңламаганга салышып)*. Ни?

Фатыйма. Милициядән бик куркалар алар. Милиция чакыртам, диген, сез рәкитүрләр, диген. Бераз гына укаларын койсыннар. Аларның байлыгы юк түгел.

Сираҗи. Юк, апа. Мин һәр эшне үз көчем белән эшләргә яратам.

Фатыйма. Ярар инде алайса. Аларны да бераз биетәсе килгән иде. Шуңа гына әйткән идем. Юкса гел мине генә биетәләр.

Сираҗи. Ә сез биемәгез, горур булыгыз.

Фатыйма. Булмый шул, балам. Кибеттән китәсем килми. Монда эләгүләре бик кыен бит. Күрше карты әйтмешли, кибеткә ике «Б» белән генә кереп була.

Сираҗи. Нинди ике «Б» ул?

Фатыйма *(бармак янаган булып)*. Үзең дә беләсеңдер. Кибет тикле кибетне сатып алырлык кеше аны гына белми калмас.

Сираҗи. Юк, апа, бер дә ишеткән нәрсәм түгел.

Фатыйма. Син моңа чаклы *(югарыга күрсәтеп)* өстәрәк эшләдеңме әллә?

Сираҗи. Нигә алай дисез?

Фатыйма. Югарыдагылар халыкның ни сөйләгәнен ишетми бит. Нәрсә әйтә башлаган идем әле мин? Ә-ә, теге ике «Б» турында. «Б»ның беренчесе «блат». Ансы ир-атларга яки өлкәннәргә карый. Икенчесе... Икенчесе яшь кызларга карата әйтелә. Әй, ансын төшенгәнсеңдер инде. «Блат» сүзен бераз

нечкәртебрәк әйтсәң, икенчесе килеп чыга.

Сиражи. Алай, алай! *(Сәхнә буйлап йөренә һәм каядыр чыгып китә. Аның чыгып баруын күреп, Фатыйма кычкырып кала.)*

Фатыйма. Милиция чакыр, энем, милиция. Итәк асларына ут төртик әле шуларның, кызык итик.

Кызып сөйләшә-сөйләшә, Сания, белән Гөлсинә керә. Алар әле Сиражи утырган урындыкның буш икәнен күрмиләр. Керә-керешкә Фатыймага ташланалар.

Гөлсинә. Син нәрсә, карт карга, безне алдап чыгардың?

Сания. Йөрәгемне кузгатып...

Фатыйма. Теге нәмәстәкәйләрегез киткәннәрмени? И-и, бик ашыгалар иде шул. Икенче нәмәрсәкәйләре янына киткәннәрдер.

Гөлсинә. Башыңны юләргә салма, югыйсә юләр башсыз да калырсың. *(Фатыйма өстенә килә.)*

Фатыйма *(көлеп)*. Минем баш түгел, сезнең башлар тү-тү хәзер. Әнә күрәсезме? *(Сиражи утырган урындыкка күрсәтә.)* Сезнең көйсез киявегез милициягә шылтыратырга чыгып китте. Бу рәкитүрләрне үз кулларым белән богаулап милициянең иң сасы подвалына илтеп ябам, ди.

Сания. Уф, йөрәгем! Нишлибез инде?

Гөлсинә. Кыланма әле. Синдә генә йөрәк! *(Фатыймага җикеренә.)* Нәрсәгә ычкындырдың аны?

Фатыйма. Сез генә рәкитүр булырга димәгән, мин дә рәкитүр. *(Швабрасын автомат итеп кызларга төзи.)* Чыгарып салыгыз әле миңа бер-ике миллионны!

Гөлсинә. Ә-ә, шулаймы? Сиңа бер-ике миллион кирәкме? Тот, Сания. Хәзер бу карт карганы бәйләп подвалга ыргытабыз. Заложник итеп. Күрше бабаң түләп алыр. Бик бабай дип кенә торасың. Синең ул простой бабай түгел. Шухыр-мухыр килеп ятмагыз анда.

Сания белән Гөлсинә Фатыймага якынлашалар. Гөлсинә идәндәге чиләкне, Сания идән юа торган чүпрәкне ала. Фатыйма швабрасы белән селтәнә.

Фатыйма. Килмәгез, атып үтерәм. Күрше карты әйтмешли: елына бер тапкыр агач мылтык та ата.

Куышып йөрү башлана. Фатыйма швабрасын болгап әле тегеләй, әле болай боргалана. Куыша торгач, Сания Фатыйманы эләктереп ала. Гөлсинә Фатыйманың башына чиләк кидертәм дип Саниянең башына кидертә.

Сания *(башыннан чиләкне алып Гөлсинәгә ташлана)*. Аһ, бетле көчек! *(Чиләкне Гөлсинәгә ыргыта.)*

Гөлсинә. Мин ялгыш кына.

Сания. Ялгыш, имеш. Син вечно миңа завидуешь.

Гөлсинә. Әйттең сүз. Йоны коелган карт мәчегә завидовать итәргә кем дип белдең мине?

Сания *(ысылдап аның өстенә килә)*. Кем карт мәче? Кемнең йоны коелган? Менә синең йоның коелган ул! *(Гөлсинәнең чәченә ябыша. Тегенең чәч дигәне парик икән. Салынып чыга.)* Менә синең йоның. *(Сания парикны тибеп очыра.)*

Болар кычкырышканда, Сиражи керә һәм кызларны сүзсез генә күзәтә.

Гөлсинә. Ә, шулаймы? *(Ул да Саниянең паригын тартып төшерә.)* Хисле кеше, имеш. Хис дигән нәрсәнең «х» сы да калмаган инде синдә. Җитмәсә, кеше күзенә төтен җибәрмәкче булып йөрисең.

Сания. Синең төтенең дә калмаган.

Гөлсинә. Мин ичмасам артистланмыйм.

Сания. Артистлана белсәң, бик артистланыр идең дә...

Гөлсинә. Коры куык. Артистлансаң да, этем дә карамый сиңа.

Сания. Мин кайберәүләр кебек «Запорожец»ларга карамыйм шул.

Гөлсинә. Кысык күзле корееңларга гына карыйсыңмы?

Сиражи кул чабып килеп чыга.

Сиражи. Браво, кызлар, браво! Нәрсә бүлешәсез?

Фатыйма. Кибет бүлешәләр, энем, кибет. Ә мин ахтамат белән кибетне апкитмәсеннәр дип саклап торам. Мин рәкитүр.

Сиражи. Кызык икән сездә.

Гөлсинә. Авыз ерып торма әле, сөрсегән импотент. Юкса милицияләрең килеп җиткәнче капчыкка тыгып оннар арасына ыргытырбыз.

Сиражи. Нинди милиция? Разве егетләр кызлар янына милиция белән килә? Бигрәк тә сезнең кебек үзе кочакка алырга торган кызлар янына.

Кызлар ышанырга да, ышанмаска да белми торалар.

Сания *(бик тиз үзгәреп).* И Сиразчик, акыллым минем. *(Сираҗиның башыннан сыйпый.)* Син чынлап та бик акыллы бит, әйеме?

Сираҗи. Моңарчы үземне юләргә санамый торган идем.

Сания *(сумкасыннан бер кәгазь тартып чыгара).* Акыллы булсаң, миңа моңарга кулыңны куеп җибәр, Сиразчик.

Сираҗи. Нәрсә соң ул?

Сания. Гариза. Сания Гыйльманованы үз кибетемә эшкә алам, дип кул куеп җибәрсәң, чын егет икәнеңә ышанырмын.

Сираҗи. Кул куярга дисез инде алайса?

Сания. Әйе, кул куярга. *(Реверанс ясап, җырлый-җырлый кәгазен Сираҗига суза.)*

Күрсәт әле, егеткәем,
Бөркет икәнлегеңне.
Былбылларны күрә белгән
Егет икәнлегеңне.

Сираҗи аның гаризасын кулына ала.

Гөлсинә *(гаризасын сузып).* Мине дә үзегезгә алыгыз, Сираҗи әфәнде.

Фатыйма. Болар бер-берләреннән башка торалмыйлар, энем. Алсаң — икесен дә ал, алмасаң — берсен дә алма.

Сираҗи. Шулай бер-берләрен бик яратышалармыни?

Фатыйма. Бер-берләрен үтерердәй итеп, чәйнәп ташлардай итеп яраталар. Эт белән мәче дә алай ук яратышмас.

Сания. Син нәрсә, Фатыйма апа, болай да телгәләнгән йөрәгемне парә-парә китерәсең? Минем йөрәгем авыр сүзләр күтәрә алмый. Беләсең бит.

Фатыйма. Авыр сүзләр әйтмәдем ләбаса. Яратышалар гына дидем. Хәзерге дөньяда эт белән мәчедән дә дусрак яшәүче юк. Хәзер кайсы гына өйгә кермә, эт белән мәче кочаклашып ята.

Гөлсинә. Шулай шул. Мин җәй көне авылга кайткан идем. Җизниләрнең этләре балалаган да, болар эт балаларын туу белән суга батырганнар. Эт, мескен, нишләсен. Сөт тулы имчәкләрен үзе белән бер куышта йоклаучы мәче авызына төрткән. Шулай, Сираҗи әфәнде. Этне мәче, мәчене эт имеп ята торган заманда яшибез. Ач күзеңне, дөнья бу! Безне куып та әллә кемне таба алмассыз.

Сираҗи. Табылыр. Эшнең рәтен белеп, җаны-тәне белән булсынга йөрүчеләр кирәк миңа.

Сания. Мин эшли беләм, Сиразчик. Моңарчы гел мактыйлар иде үземне.

Гөлсинә. Мин дә эшли беләм, Сираҗи әфәнде.

Сираҗи. Моңарчы нишләп эшләмәдегез соң?

Икесе бергә. Без эшләдек. Ничек өйрәтсәләр — шулай эшләдек. Ни кушсалар — шуны үтәдек.

Сираҗи. «Ат» дисәләр — аттык, «ят» дисәләр — яттык, дисез инде алайса.

Сания. Нигә? Кушканны үтәү начармыни?

Сираҗи. Без хәзер яңа гасырга кереп барабыз. Яңа гасырда яңача яши башларга кирәк. Тоткынлык чорында тоткын булып күп яттык. Яңа гасыр, яңа кешеләр, яңача эш...

Гөлсинә. Кая соң ул яңа гасырда яңача яши торган яңа кешеләр? Дөньясы сөрсегән бит аның. Без дөньяда яшибез дип үз-үзебезне алдыйбыз гына бит. Безнең дөнья дигәнебез, күптән суы алыштырылмаган аквариум. Тончыга башласак кына аквариумның суын алыштыралар. Чөнки без тончыгып бетсәк, күзәтеп утыручыларга кызык калмый. Ә сез, Сираҗи әфәнде, яңа гасырга яңа кешеләр белән кермәкче буласыз. Юк инде, алдамагыз үзегезне. Юк ул яңа кешеләр. *(Саниянe култыклап.)* Әйдә, подружка, киттек. Кәкре дөньяны турайтырга теләүчеләр бар икән — турайтсыннар.

Сания. Яңа кешеләрне менә без тудырырга тиеш аларны. Хис белән, йөрәк белән. Ә сез хисне аңламыйсыз. Хуш, Сиразчик, бик яраткан идем, аерылышырга туры килә. Кәкре дөньяда берүзең кал. *(Китә башлыйлар.)*

Сираҗи *(уйланып).* Кызык, кызык. Кәкре дөнья. Аквариум. Логика юк түгел. Һәй, кызлар, туктагыз әле.

Кызлар чыгып барган җирләреннән туктыйлар.

Сания. Нәрсә, Сиразчик, әллә үбешеп аерылышабызмы? Әйдә, үбешик алайса.

Сираҗи. Мин үбешеп тормам инде.

Сания. Алайса, сугышабызмыни?

Сираҗи. Мин сезнең белән аерылышмаска булдым, кызлар.

Кызлар. Ничек? *(Алар ышанырга да, ышанмаска да белми торалар.)*

Фатыйма. Ничек дип акаешып торасыз тагын. Сираҗи әфәндегез сезне эшкә алам, ди. Белеп торыгыз: аңарга мин мактадым сезне. Шулай бит, Сираҗи энем.

Сиражи *(елмаеп).* Шулай, шулай, апа.

Фатыйма *(кызларга).* Тәк что, тәмле җимешләрдән миңа өлеш чыгарырга онытмагыз. Түлке бушлай.

Гөлсинә *(кул селтәп).* Әй, йомшак җәеп катыга утыртмакчыдыр әле.

Сиражи. Юк, кызлар, чынлап алырга булдым сезне. Беренчедән, сез тегенди-мондый рэкитерга гына бирешерлек түгел...

Фатыйма. Мин дә рәкитүр, энем. Мине дә эшкә ал.

Сиражи *(сүзен дәвам итеп).* Икенчедән, мин сезнең кем икәнлегегезне аңладым. Кайвакытта бит кемнең кем икәнлеген белер өчен бик күп еллар кирәк була. Ә сез көтмәгәндә-уйламаганда ачылдыгыз. Ныклап белгән кешеләр белән эшләргә яратам мин. Дөрес, сез, кем әйтмешли, не подарок. Ләкин мин әле сезнең матур якка үзгәрәчәгегезгә ышанам.

Сания. Без үзгәрәчәкбез, Сиражи әфәнде.

Гөлсинә. Әйе, әйе, үзгәрәчәкбез. Дөресрәге, үз халәтебезгә кайтачакбыз.

Сания. Дөрес әйттең, Гөлсинә. Чынлап та үзгәрү түгел, үз халәтебезгә кайту бу. Без авылдан килгәндә егетләр куены да күрмәгән саф кызлар идек. Монда килү белән һәркем безнең сафлыгыбызга үрелә башлады. Иң элек баштан сыйпап, кулга ияләштерделәр. Сыйпатмас идең — яшәргә кирәк. Тәмле ашыйсы, матур киенәсе, авылга кайтканда юньлерәк кыяфәт белән кайтасы килә. Шулай итеп әкренләп сазлыкка бата бардык. Сазлыкка өстерәүче күп булса да, тартып чыгарырга теләп кул сузучы булмады.

Сиражи. Менә мин сезгә шул кулны сузам. Таныш булыйк — Сиражи Әфләтунович!

Сания *(аның алдына иелеп).* Сания туташ булабыз.

Гөлсинә. Ә без Гөлсинә туташ.

Эре-эре атлап, Әхмәт Имаевич керә.

Әхмәт Имаевич *(күкрәген кагып).* Ә мин номенклатур работник Әхмәт Имаевич булам.

Кызлар. Син нишләп монда әле?

Әхмәт Имаевич. Сәрби әбиегез куып җибәрде. Номенклатурный работникны алай эштән куарга хаклары юк. Каравылчы булып булса да кибетеңдә кал, диде. *(Сиражига.)* Тәк што, Сиражи әфәнде, сезгә яңа тормышны иске материал белән корырга туры килер.

Фатыйма. Туктагыз әле, бөтенегез үзен кайгырта. Ә мин? Дөньяда самый глауный кеше — җыештыручы. Җыештырмасаң, дөнья бик тиз чүпкә бата. Шулай бит?

Сиражи. Әлбәттә, самый главный кешене калдырып булмас инде. Үзебез кәкрәйткән дөньяны үзебез турайтырга туры килер.

Барсы бергә. Турайтабыз, Сиражи әфәнде, турайтабыз.

Ал да булырбыз әле,
Гөл дә булырбыз әле.
Киләчәктә тагын шулай
Бергә булырбыз әле.
Бал тамар телебездән,
Нур тамар йөзебездән.
Кәкре дөньяны турайту
Тора бит үзебездән.
Тора бөтенебездән.

Пәрдә.

*1997*

## ШҮРӘЛЕЛӘР КАРГЫШЫ

*(Әкият-пьеса)*

**КАТНАШАЛАР:**

Карт шүрәле — алып баручы да шул ук.
Олавыз.
Мүкләкҗан.
Купшыбикә.
Сөрмәкүз.
Яшь шүрәле.
Урман иясе.
Камали.
Гөлҗамал.

Җамали.

Пәрдә ачылганчы сәхнә алдына Алып баручы шүрәле чыгып
баса.

Алып баручы шүрәле.

Мин — шүрәле, килдем карурманнан,
Әкият алып килдем еракта.
Әкият сөймәгәннәр гомер буе
Тормышында нидер югалткан.

Әкият кирәк шүрәлеләргә дә,
Һәм сезгә дә әкият бик кирәк.
Әкият — хыял, ә хыялда тормыш
Матуррак һәрчак, иплерәк.

Яшик әле әкият белән бергә,
Әкият белән чынлык үрелсен.
Безнең әкияттән соң җаныгызда
Якты уйларыгыз терелсен.
Таш бәгырьләр бераз йомшап китсен,
Елмаюлар артсын йөзләрдә.
Мин чакырам сезне үзем белән —
Әкият урманнарын гизәргә.

**БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Урман аланында учак яна. Учак янына шүрәлеләр җыелышып утырган. Аларның кайберләре чыбык башына гөмбә кадап, гөмбәләрен учакта кыздыра. Кайберләре бер-берсенең башын карый, бетен үтерә.

Берничәсе җыр суза.

Әй карурман, карурман —
Син бит безнең туган йорт,
Хәсрәтебез сыйган йорт,
Шатлыгыбыз сыйган йорт.

Әй карурман, карурман,
Безне бергә җыйган йорт,
Яшел чирәм өстенә
Тәүге яшьне койган йорт.

Әй карурман, карурман...

Җыр шушы урында өзелә. Чөнки Олавыз, җырны өзеп, көләргә тотына. Җырлап утыручы шүрәлеләр аңа сәерсенеп карыйлар. Яңадан җыр башламакчы булалар, ләкин алар җыр башлауга, Олавыз яңа көч белән көлә башлый. Чөнки бүтәннәргә күренми генә озын чыбык белән Яшь шүрәле Олавызның табанын кытыклый.

Олавыз. Уф, үләм! Ха-ха-ха!..

Олавыз көлүдән туктагач, җырлаучылар үзләренең җырларын дәвам итмәкче булалар. Әмма Олавыз үзенең кинәт көлә башлавы белән

яңадан җырны өзә. Олавыз нидер әйтергә тели, ләкин ул сүз әйтергә авызын ачканда гына Яшь шүрәле нечкә чыбыгын аның табанына тидереп ала. Олавыз, әйтер сүзен әйтә алмыйча, янә көләргә тотына. Моның көлүе башкаларга да йога. Башта Олавызга гаҗәпләнеп караган шүрәлеләр үзләре дә сизмәстән моңа кушылып көлә башлыйлар. Кайсы чирәмдә тәгәрәп көлә, кайсы сикереп торып кеткелди. Көлүгә кушылмый торган шүрәлеләрне көлүче шүрәлеләр кытыклап көлдерә башлый. Китә бер-берсен кытыклашу, бер-берсен куышу. Урман аланы көлү авазыннан шау килә. Учак пыр туза. Аның төтене, көле күккә күтәрелә. Мәтәлчек атуларга, кытыклашуларга, шаяруларга кәкре мөгезле Карт шүрәле генә катнашмый. Ул, бер агач ботагына таянып, боларны күзәтә. Ул — бу төркемнең башлыгы. Гәүдәсе шактый бөкрәйгән булса да, күзләрендә ялтыраган усал утлар аның әле гайрәте барлыгын һәм кирәк чакта төркемне берсүзсез үзенә буйсындыра алачагын күрсәтә. Карт шүрәле төркемнең бераз сүрелүен көтеп тора. Бераздан ул таягын каен тузыннан ясалган дәү барабанга китереп суга. Барабан гөрселдәп куя. Бар да шым кала. Күзләр — карт

шүрәленең юан таягында.

Карт шүрәле. Җитте, котырмагыз. Нәрсәгә шашынасыз?

Купшыбикә. И галиҗәнап ырубаш! Сез дә картаясыз, ахры. Әле кайчан гына култык астымны җил кытыклый дип тә көлә торган идегез.

Карт шүрәле. Һәрнәрсәнең үз вакыты.

Сөрмәкүз. Без бит, хөрмәтле ырубаш, Олавыз көлгәнгә генә көлдек.

Карт шүрәле. Бер җүләр көлә дип бөтенегезгә шаркылдарга димәгән. Һы, кара син аларны! Урман бетереп шаркылдашалар. Әгәр сезне ишетеп теге явыз Былтыр килеп чыкса?!

Олавыз. Былтыр да Былтыр дисең, бер күрәсе иде үзен.

Карт шүрәле. Синең олы авызыңнан гына куркып тормас ул. Аның балтасы билендә.

Сөрмәкүз. Галиҗәнап ырубаш! Сез ничек уйлыйсыз, хатын-кыз шүрәлеләргә ул ничек карый икән? *(Кыланып.)* Минем ни өчендер аңардан кытыклатасым килә.

Карт шүрәле. Оятларыгызны үзегез йоклаганда тычкан ашап киткән нәмәрсәләр! Олылар алдында әллә ниләр сөйли башладыгыз.

Купшыбикә *(хис белән).* Мине күрсә, ул урманга нигә килгәнен онытыр иде. Мин арагызда иң көязе. Матуррак булыйм, бүтәннәрдән аерылып торыйм дип, хәтта койрыгымны да кистердем.

Карт шүрәле. Син элек тә башкалардан аерылып тора идең анысы.

Купшыбикә. Нәрсә белән?

Карт шүрәле. Ахмаклыгың белән.

Купшыбикә. Дорфа! Карт пәри! Үзеңә карата алмаганга ачуың киләме әллә?

Олавыз *(шаркылдап көлә башлый).* Ха-ха-ха!

Карт шүрәле. Нәрсәгә көләсең тагын? Бер кызык та юк бит әле.

Олавыз *(көлүдән туктый алмыйча).* Үзең беләсең бит, галиҗәнап ырубаш, авызым зур, ул авызга тулып калган кызыкны чыгарып бетермичә ничек туктыйсың инде? *(Тагын көләргә тотына.)*

Карт шүрәле аның маңгаена чиртә, Олавыз чинап китә.

Карт шүрәле. Сезгә шаркылдарга гына булсын!

Олавыз. Рәхәтләнеп көлмәгәч тә, авыз нәрсәгә?

Карт шүрәле. Авыз ул — телне бикләп куяр өчен сандык.

Сөрмәкүз. Телне тый, кулны тый, тагын әллә нәрсәләрне тый. Тыела-тыела бөтенләй тыйнакланып беттек инде. Дөньясында бер кызык та юк.

Купшыбикә. Әйе, Сөрмәкүз дөрес әйтә. Безгә әле тыйнакланып утырырга иртә. Менә сезнең кебек комнарыбыз коелып беткәч тыйнакланырбыз.

Карт шүрәле. Әле шулаймы? Минем комым коелганмы?

Карт шүрәле Купшыбикәне куакка таба өстери башлый, шунда Мүкләкҗан белән Яшь шүрәле килеп чыга.

Карт шүрәле. Әйдәле, күрсәтим әле мин сиңа комымның күпме калганын!

Мүкләкҗан. Туктагыз әле, җәмәгать. Нишләвегез бу?

Купшыбикә. Менә ырубаш миңа үзенең комын күрсәтмәкче.

Мүкләкҗан *(аңламыйча).* Комын?

Купшыбикә. Әйе. Куак артына алып барып күрсәтәм, ди.

Мүкләкҗан *(Карт шүрәлегә селтәнмәкче була).* Ух, карт убыр!

Аның кулын Яшь шүрәле тота. Бераз шау-шу кубып ала.

Карт шүрәле. Ырудашларым, туктагыз әле. Кычкырышмыйк. Безнең бит бөтен матурлыгыбыз, бөтен көчебез — татулыкта. Болай да кешеләр безне төрле яклап кысрыклап киләләр. Урманыбызны кисәләр, җәнлекләребезне аталар. Үзара да ызгыша башласак, нәрсә булыр аннары?

Олавыз. Дөрес, урманнарыбыз кими. Элек, ичмасам, кул бик кычыткан чакта, кабан дуңгызының корсагын кытыклап та кызык таба идек.

Мүкләкҗан. Эшләр болай барса, үзебезне дә тота башларлар әле.

Яшь шүрәле. Ул яктан безнең кайгырасыбыз юк: ни итебез, ни тиребез. Ә кешеләргә матур тиреле яки тәмле итле җәнлекләр генә кирәк.

Карт шүрәле. Алай димә, дустым. Бер юләре шүрәле мөгезендә сәламәтлек өчен файдалы нәрсә бар, дисә, бармак кадәр мөгезебез өчен акыртып суярлар. Кайда кешеләр — шунда явызлык. Алардан һәрвакыт сакланырга кирәк.

Сөрмәкүз *(чытлыкланып).* Минем кебек сөрмәле күзләргә тимәсләр әле.

Мүкләкҗан. Иң беренче синдәйләрне каптырачаклар алар. Хәер, алар синең сөрмәле күзеңә карап тормаслар. Ерактан ут төкерә торган таяклары белән бәреп кенә егарлар.

Яшь шүрәле. Бетмәде инде шушыларның зарланулары! Мин туганнан бирле шул сүзләрне ишетәм: имеш, урман бетә, җәнлекләр бетә. Менә бит әле бетмибез, яшибез.

Сөрмәкүз. Яшәвен яшибез дә, кызык түгел.

Яшь шүрәле. Миңа кызык. Менә сезнең ише ялкауларны кытыклап биетү кызык.

Сөрмәкүз. Ә безгә кызык түгел.

Олавыз. Әйе, кызык түгел.

Мүкләкҗан. Ә беләсезме кемнәр кызык яши?

Тавышлар. Кемнәр? Әйт, кемнәр?
Мүкләкҗан. Кешеләр!
Карт шүрәле. И аңгыра, и тинтәк! Кешеләрнең кызык яшәгәннәрен каян беләсең син?
Мүкләкҗан. Беләм инде.
Карт шүрәле. Белсәң әйт алайса: нәрсә ул кызык?
Мүкләкҗан. Һы, шуны да белмәскә!
Карт шүрәле. Белсәң, әйт.
Мүкләкҗан. Көлә торган әйбер.
Карт шүрәле. Ә нигә көләләр, синеңчә?
Мүкләкҗан. Кызык булганга.

Карт шүрәле шунда үзенең шыр сөяк бармаклары белән Мүкләкҗанны кытыклый башлый. Тегесе үрле-кырлы сикерә-сикерә көлә. Карт шүрәле аның саен ныграк кытыклый.

Мүкләкҗан. Тук-тук-та, тук-тук... Хи-хи-ха-ха!
Карт шүрәле. Сиңа кызыкмы?
Мүкләкҗан. Юк, кызык түгел. Тук-та-ат!
Карт шүрәле. Димәк, кызыклыктан гына көлмиләр икән, шулаймы?
Мүкләкҗан. Шу-шу-лай ик-ән ш-шул! Хи-хи-хи!
Карт шүрәле. Инде үзеңнең аңгыра икәнеңә ышандыңмы?
Мүкләкҗан. Ышандым бугай...
Карт шүрәле. Әгәр ышанып җитмәсәң, тагын бераз ышандырып алам. *(Карт шүрәле кытыклый башлый.)*
Мүкләкҗан. Ышандым, ышандым, галиҗәнап төркембаш.
Карт шүрәле. Йә, кайсыгыз кызыкның ни икәнен әйтеп бирә ала? *(Сөрмәкүзгә төртеп.)* Әйдә, син әйтеп кара әле.
Сөрмәкүз. Кызык ул, минемчә... минемчә...
Карт шүрәле. Әйе, синеңчә.
Сөрмәкүз. Кызык ул. Кызык ул... Яшь шүрәле куенында яту.
Карт шүрәле. Тфү, җирбит! *(Купшыбикәгә.)* Синеңчә дә шулаймы?
Купшыбикә. Минемчә... Минемчә, кызык ул бер караш белән бөтен шүрәлеләрне һуштан яздыру.
Карт шүрәле. Тинтәк. Аңгыра. Гөмбәбаш. Сездән рәтле җавап көткән мин җүләр. *(Яшь шүрәлегә.)* Йә, дустым, синең уеңны да белик. Әйтеп кара.
Яшь шүрәле *(уйланып тора)*. Әгәр дә мәгәр кытыкламаганда да көләсең килә икән — кызык шул була, минемчә.
Карт шүрәле *(аның җилкәсеннән кагып)*. Менә, ичмасам, әйттең. Башың бар икән. *(Башка шүрәлеләргә.)* Ишеттегезме? Колагыгызга киртләп куегыз: киләчәктә төркем башы булып менә кем калыр.
Мүкләкҗан. И-и, аны гына мин дә белә идем. Кешеләр әнә бер дә берсен-берсе кытыкламый, әмма көләләр. Хәтерегездә микән, былтыр...
Карт шүрәле. Былтыр түгел, узган ел. Былтыр исемен телгә алмаска дип ничә әйттем.
Мүкләкҗан. Узган ел безнең түгәрәк аланга, сасы ис, әшәке тавыш чыгара торган нәмәрсәләргә атланып, бер төркем адәми затлар килгән иде. Шулар нәрсәдер ашап-эчкәннән соң урман яңгыратып көләргә тотындылар.
Сөрмәкүз. Әйе, минем дә хәтеремдә — берсе шунда күлмәк-ыштаннарын салып ташлап, агач ботагына менеп атланды да: «Ямайка, Ямайка», — дип җырлап җибәрде. Аңардан барысы да шырык-шырык көлде.
Олавыз *(көрсенеп)*. Кешеләр кызык итеп яши беләләр. Убырлы карчыктан да тизрәк чаба торган нәмәрсәләргә атланып йөриләр. Матур калай савытларга салынган ризыклар ашыйлар. Җырлыйлар, бииләр, бәхәсләшәләр, көлешәләр.
Купшыбикә.Аларның әллә нинди музыка уйный торган әйберләре бар. Кылларын бармаклары белән кыйнап, шуны дөмбер-дөмбер китерәләр.
Карт шүрәле. Дөрес, кешеләрдә әкәмәт нәрсәләр күп. Мин урман каравылчысының тәрәзәсеннән нindидер хикмәтләр күрсәтүче тартма күреп шаклар каткан идем. Соңыннан ул әкәмәт тартманың исемен белдем, «телебизыр» дип атыйлар икән аны.
Олавыз. Әйе, кешеләр шикелле кызык итеп яшәсәң иде.
Карт шүрәле *(корсагын кашып уйланып торганнан соң)*. Менә нәрсә, ырудашларым. Безгә кешеләрнең тормышын өйрәнергә кирәк. Әйе, әйе, хихылдашмагыз. Бездә дә баш бар. Өйрәник кешеләр тормышын. Нәрсә ашыйлар алар, нәрсә эчәләр. Нинди эшләр эшлиләр, нинди уеннар уйныйлар. Кай яклары белән көчле алар бездән, кай яклары белән көчсез.

Шүрәлеләр арасынданиндидер икеләнү.

Олавыз. Кешеләр, кешеләр дисең дә, әмма алар бик куркынычлар бит.

Карт шүрәле. Сүзең белән килешәм: әйе, кешеләр куркыныч затлар. Алар аюны өненнән тартып чыгара, бүрене ботарлап ташлый алалар. Әмма дә ләкин шуның өчен кешеләрне өйрәнергә кирәк. Юкса алар безне дә урманыбыздан куып чыгарырга күп сорамаслар. Шулай, ырудашларым, нәселебезне саклап калу өчен дошманыбызны белү кирәк.

Мүкләкҗан. Белү кирәктер, бәхәсләшмим, ләкин ничек?

Яшь шүрәле. И, моның нәрсәсе бар?! Берәр авылга барасың да нишләгәннәрен көне буе карап ятасың.

Карт шүрәле. Хак әйтәсең, яшь дустым. Кешеләрне белү өчен кешеләр арасына барырга кирәк.

Яшь шүрәле. Үзем барам.

Карт шүрәле. Юк, син бармыйсың. Беренчедән, синең әле буыннарың ныгып җитмәгән, икенчедән, миңа ул-бу булса...

Шүрәлеләр аның бу сүзләреннән соң җанланып шаулаша башлыйлар.

Карт шүрәле. Шатланмагыз, әле мин үләргә җыенмыйм. Кыскасы шул: син бармыйсың. Йә, кайсыгыз батыр? Синме, Сөрмәкүз?

Сөрмәкүз. Хатын-кызга бигрәк ихтирамыгыз юк инде.

Карт шүрәле. Кайсыгыз соң әле яңа гына кызык юклыктан зарланган иде? *(Мүкләкҗанга карый.)* Бәлки, син барырсың?

Мүкләкҗан *(куырылып китә)*. Минем бит бер дә баш эшләми. Өченче елгы җил вакытында башыма агач ботагы төшеп, мием селкенгәнне үзегез беләсез бит.

Карт шүрәле. Алайса, сиңа кала, Олавыз.

Олавыз. Соң, үзегез уйлап карагыз, мондый олы авыз белән кешеләр янына барып буламыни? Шундук минем шүрәле икәнемне белерләр.

Яшь шүрәле. Шобага тотарга кирәк, галиҗәнап төркембаш.

Карт шүрәле *(Яшь шүрәленең җилкәсенә кагып)*. Ай, баш та бар үзеңдә! Шобага тотышабыз. Килегез әле барыгыз да монда. Тотыныгыз минә бу таягыма. Кем өскә чыга — шул авылга!

Купшыбикә. Хатын-кызлар дамы?

Карт шүрәле. Әйе. Килегез, кил. Шүрәлеләр бар да тигез хокуклы.

Шүрәлеләр теләр-теләмәс кенә таякка тотына башлыйлар. Һәркем аста калырга тырыша. Әмма таяк шактый озын. Бер кат тотынып кына кем өскә чыгачагын ачыклап булмый. Шүрәлеләр һәммәсе таякка тотынып туктап кала.

Карт шүрәле. Йә, нигә туктап калдыгыз? Әйдәгез, әйдә.

Боларның һәрберсенең маңгаена чиртеп чыга. Шуннан соң шүрәлеләр шобага тотынуны дәвам итәләр. Өскә Мүкләкҗан чыга. Ул үзенең өскә чыгуын күргәч, һушсыз булып ава.

Карт шүрәле *(Олавызга)*. Бар әле, тиз генә су алып килеп өстенә бөрке.

Олавыз. Галиҗәнап төркембаш, әмерегезне үтәргә әзермен. Тик суны ни белән алып килим?

Карт шүрәле. И-и, аңгыра! Сорап торган буласың. Ул табак хәтле авызың нәрсәгә соң?

Олавыз. Төшендем, галиҗәнап төркембаш. Чаптым. *(Китеп бара. Мүкләкҗан сыңар күзен ачып, ул киткән якка карап кала.)*

Сөрмәкүз. Олавыз су апкилгәләгәнче, мин бераз өшкерә торыйм әле. Минем тыным бик файдалы. *(Мүкләкҗанның өстенә атлана да әфсен укый.)* «А» дигәндә, авызың ачылсын — әфсен-төфсен. *(Бармагын тыгып, авызын ачтыра.)* «Б» дигәндә, борының сызгырсын. *(Борынын кысып куя.)* «К» дигәндә, күзең тоз булсын — әфсен-төфсен. *(Мүкләкҗанның, керфекләрен тартып, күзләрен ачтыра.)* «Т» дигәндә, торып утырсын, «С» дигәндә, авылга сыпырсын — әфсентөфсен. *(Шулай ди дә Мүкләкҗанның касыгына нык итеп төртә, тегесе сикереп торып, Сөрмәкүзне сугып ега.)*

Мүкләкҗан. Нәрсәгә дип шулхәтле төртәсең?

Сөрмәкүз. Үзеңне өзелеп яратканга.

Мүкләкҗан. Яраткач нигә төртәсең?

Сөрмәкүз. Сине үтерәсем килми, матурым.

Мүкләкҗан. Кешеләр янына барганчы үлүең артык.

Ул арада Олавыз да авызына су тутырып килеп җитә. Мүкләкҗанның һушка килүен күргәч, «кемгә сибим» дигәнне аңлатып, Карт шүрәлегә карый. Карт шүрәле кулын селтәп китеп бара. Олавыз «ым-ым» дип суны кемгә сибәргә белми йөри. Шул вакыт Яшь шүрәле аның корсагын кытыклый. Олавыз пырхылдап авызындагы суларын барлык шүрәлеләр өстенә бөрки. Шүрәлеләр суны бик яратмыйлар икән. Олавызның бу эше өчен барысы да аның маңгаена чиртеп чыга.

Олавыз *(маңгаен уып)*. Хәчтерүшләр, бер тамчы судан курыктыгыз. Ә менә Мүкләкҗан авылга барудан да курыкмый.

Олавыз шап итеп Мүкләкҗанга суга. Тегесе бурычлы булып калмый. Көрмәкләшә башлыйлар.

Карт шүрәле. Җиттеме сезгә?! Хәзер Мүкләкҗанны авылга әзерли башларга кирәк.

Бар да бертавыштан. Ничек итеп?

Карт шүрәле. Иң беренче, аны кешечә киендерү мәслихәт. *(Яшь шүрәлегә.)* Бар әле, теге урман каравылчысының бакчасыннан алган карачкы киемнәрен китер.

Яшь шүрәле йөгереп китеп бара. Бераздан иске-москы киемнәр күтәрепкилеп җитә.

Яшь шүрәле. Шушыларны әйттеңме, галиҗәнап төркембаш?

Карт шүрәле. Шулар булмыйча! *(Яшь шүрәленең кулыннан киемнәрне ала.)* Болар әле бик заманча киемнәр икән. *(Иске-москыларны берәм-берәм тамашачыга күрсәтә.)* Мондыйларны хәзер кибеттән дә таба алмыйсың. Бәхетебезгә, өченче ел каравылчының карачкысын чишендереп алганбыз. Йә, ярый, ырудашларым, эшне озакка сузарга ярамас. Киендерә башлыйк!

Олавыз. Киендерәбез!

Сөрмәкүз. Киендерәбез.

Барлык шүрәлеләр Мүкләкҗанны уртага алалар. Җырлый-җырлый киендерәләр.

Башлап җырлаучы. Бигрәк матур чалбары ла, кем алган?

Хор белән. Кем алган?

Башлап җырлаучы. Катлы-катлы ямауларын кем салган?

Хор белән. Кем салган?

Башлап җырлаучы. Балаклары җитеп тора тезеңә.

Хор белән. Тезеңә.

Башлап җырлаучы. Үлчәп теккән диярсең лә үзеңә.

Хор белән. Үзеңә.

Башлап җырлаучы. Ә күлмәгең — анысы бигрәк килешле.

Хор белән. Килешле.

Башлап җырлаучы. Тишекләре, ертыклары чигешле.

Хор белән. Чигешле.

Башлап җырлаучы. Әйбәт, ныклы тимерчыбык путасы.

Хор белән. Путасы.

Башлап җырлаучы. Юктыр моны өзелер дип куркасы.

Хор белән. Куркасы.

Башлап җырлаучы. Эшләпәңнең чит-читләре чук-чуклы.

Хор белән. Чук-чуклы.

Башлап җырлаучы. Туфлиләрең әйбәт, биек үкчәле.

Хор белән. Үкчәле.

Башлап җырлаучы. Туры килеп тора үзеңә үлчәме.

Хор белән. Үлчәме.

Киендергәндә Мүкләкҗанны биек төп башына бастыралар. Ул үлемгә хөкем ителгән кешедәй битараф кыяфәттә басып тора. Чалбар-күлмәкләрне, туфлиләрне кидерткәндә аның әле аягын, әле кулын күтәрәләр. Берсе башын бора, берсе тырпаеп торган киемнәрен сыйпаштыргалый. Менә, ниһаять, киендерү тәмам. Шунда берсе консерв банкасы табып, аның төбен Мүкләкҗанга көзге итеп суза.

Яшь шүрәле. Үзеңне карап җиппәр әле. Кешеләрнең үзләреннән дә шәбрәк булдың.

Сөрмәкүз. Мөгезең булмау да ярап куйды.

Олавыз. Синең авыз да чамалы гына. Ха-ха-ха!

Карт шүрәле. Ә-ә, тагын бер нәрсәне онытканбыз бит әле.

Купшыбикә. Нәрсәне, галиҗәнап төркембаш?

Карт шүрәле. Кешеләр акчага табынучан.

Сөрмәкүз. Акчага? Менә миндәй матурларга дисәң, тагын бер хәл.

Олавыз. Акча нәрсә була әле ул?

Карт шүрәле. И-и, аңгыралар! Теге вакыт банкага салып күмелгән матур рәсемле кәгазьләр тапкан идек бит, шул акча дип атала инде. Сез шуның белән бәдрәфкә дә йөреп маташтыгыз әле, аннары кәгазе бик каты дип, тотмый башладыгыз. Тинтәкләр, мин булмасам, ни генә белер идегез сез. Бар, Олавыз, алып кил шул рәсемле кәгазьләрне.

Олавыз йөгереп китеп бара. Күп тә үтми зур бер пыяла банкага шып- лап тутырылган пачка-пачка меңлекләр алып килә.

Олавыз. Менә, галиҗәнаб ырубаш.

Карт шүрәле. Боларны берәр капчыкка салырга туры килер. *(Банкадагы акчаларны бер капчыкка*

*бушаталар.)* Син боларны кирәкле-кирәксез җирдә күрсәтмә, юкса кешеләр акчага бик хирыс. Акчаң күп икәнне белсәләр, хәтта үтереп тә ташларлар.

Мүкләкҗан. Алайса, мин боларны алмыйм.

Карт шүрәле. Ал-ал! Дөнья хәлен белеп булмый, бик кирәк булып куюы бар. Әле менә бу банка төбендә сары тимерләр дә бар. Аларын алтын диләр бугай. Аларын да бераз кесәңә сал. Минем бабай сөйли торганые: кеше затыннан булган җан ияләре шул сары тимергә бик кызыгучан, дип. Шундый тимере булган кешеләрне хөрмәтлиләр, зурлыйлар, дип әйтә торганые. Бер дә кадер-хөрмәт күрсәтмәсәләр, акчаңны яки шуларны биргәләрсең. Тик кара аны: бөтенесен берьюлы чыгарып селкемә. Кешеләр комсыз, бәдрәфкә дә йөрергә ярамаган кәгазьләреңөчен, Алла сакласын.

Мүкләкҗан. Алайса, мин бармыйм. Мин куркам.

Карт шүрәле. Дөньяда бөтен җан иясе дә нәрсәдән булса да курка. Төлкеләр — бүредән, шүрәлеләр — кешедән. Тик син курыкканыңны белдермә. Бик курыксаң, теге үзебезнең җырны җырлап җибәр. Яле, җырлап кара, онытмадыңмы?

Мүкләкҗан *(теләмичә генә җырлый).*

Туган йортым — кара урман,
Кара төн — тапкан анам.
Бүреләр — якын дусларым,
Карт аю — минем бабам.
Их, мин батыр, мин батыр,
Күргән-белгән шаккатыр!

Карт шүрәле. Тавышың моңлы синең, күңелем тулып китте.

Күзләрен сөртеп ала, башка шүрәлеләр дә мышкылдап куйган булалар.

Карт шүрәле. Йә, ярый, капчыгың җилкәңдә — инде юлга чыгарга вакыт. Кара аны, кешеләрнең сүзенә колак сал. Карышма. Тыңлаучан булсаң, беркем дә какмас-сукмас. Кешеләрнең эш-гамәлләрен, уеннарын, гореф-гадәтләрен өйрәнеп бетмичә кайтма.

Мүкләкҗан *(барлык шүрәлеләргә)*. Әгәр әйләнеп кайта алмасам, начарлык белән искә алмагыз. Хушыгыз! *(Үзен кызганудан чыккан яшьләрен сөртә.)*

Шүрәлеләр. Хуш, хуш! Әгәр безнең өчен шәһит китсәң, түгәрәк аланда синең өчен һәр көн учак ягарбыз. Хуш, безнең тугры дустыбыз.

Купшыбикә. Кешеләр күрдем дип, без барын онытма. Башыңны исән йөртеп алып кайт.

Пәрдә.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Авыл янындагы чирәмлектә Камали белән Җамали. Алар алларына газета җәйгәннәр. Газета өстендә яртылаш эчелгән шешә, чите ватылган стакан һәм бер балык башы ята. Җамали ни өчендер аягына басарга тели, әмма кире тәгәри. Камали китек стаканны тотып җырлап җибәрә.

Стаканым, стаканым,
Стаканым кулларда;
Эчтем, эчәм, эчәчәкмен —
Бар бәхетем шуңарда.
Их, алмагачлары,
Сайрый сандугачлары.

Камалига Җамали да кушыла. Ул яткан килеш сыңар аягын болгый-болгый җырлый. Җамалиның күтәрелгән аягына Камали аның җирдә яткан эшләпәсен кидереп куя.

Җамали *(җырлый).*

Стаканым, стаканым,
Стаканым зәм-зәмле;
Йөз шешә дә ега алмый
Безнең кебек адәмне.

Камали. Их, алмагачлары, сайрый сандугачлары.

Камали да Җамали янына ава. Ул Җамалиның эшләпә кидерткән аягын кочаклап үбә башлый.

Камали. Их, яратам синең шушы матур итеп җырлаган авызыңны. Әйе шул, яратам. Яраткач нишлим инде?

Болар әвәрә килеп ятканда, яннарына Мүкләкҗан килеп чыга. Ул китәргәме, калыргамы дип торган чакта, моны Җамали күреп ала.

Җамали. Камали дус, карале, безгә өченчегә берәү килгән түгелме?

Камали *(күтәрелеп карамый).* Ә без болай да өчәү.

Җамали. Ничек өчәү?

Камали. Синең белән мин — икәүме?

Җамали. Икәү!

Камали *(шешәне алып).* Менә бу безнең өченчебез. Бөтен дөньяның терәге шул. Нәрсә, әллә дөрес әйтмимме?

Җамали. Дөрес әйтәсең, дөрес.

Камали. Дөрес шул. Юкка чыгарып кара син моны. Дөньяда нәрсә кала? Менә моны бетерсәң, дөньяда ни кала? Әй, син, Карачкы, кил әле мондарак! Һәм минем соравыма җавап бир: менә моны бетерсәң, дөньяда нәрсә кала?

Мүкләкҗан дәшми генә болар янына килә. Ул сүзнең нәрсә турында барганын гомумән аңламый. Камали аның саен кыза бара. Ул шешә сен болгый-болгый соравын кабатлый.

Камали. Уйлап карагыз: мин хәзер шушыны ташка бәреп ваттым яки елга төбенә ыргыттым ди. Минем кулда ни кала?

Җамали. Дуракланып ташка бәрә күрмә тагын. Аның төбендә бар бит әле. *(Шешәгә үрелмәкче була, ләкин тегесе аны бирми.)*

Камали. Соравыма җавап алмыйча, шешәгә беркем кагылмаячак. Әй, Карачкы, бәлки, син әйтерсең, ә?

Мүкләкҗан. Аны ыргыткач, кулыңда берни дә калмый.

Камали. Менә-менә! Берни дә калмый шул. Вәт, ичмасам, акыллы баш икәнсең, кил әле, шуның өчен бер үбим үзеңне. *(Мүкләкҗанны кочаклап үбә. Аннары, фәлсәфәгә бирелеп, сөйләргә тотына.)* Дөньяның кулыннан менә шушыны тартып алсаң, аның учында бушлык кына калачак. Ә учы бушның башы да буш. Безне берләштерүче дә, серләштерүче дә, гөрләштерүче дә шушы.

Җамали. Оста сайрыйсың, дускай. Әйдәле, яңа дус белән очрашу хөрмәтенә калганын салып куйыйк.

Камали. Туктап тор, мин әле сөйләп бетермәдем. *(Уйлана.)* Мин кайда калган идем әле?

Җамали *(шешәгә күрсәтә).* Менә монда.

Камали. Ә-ә, әйе. Бу булмаса — дөнья бетәчәк. Бу безнең җырыбыз да, моңыбыз да. Юк, алай гына түгел, бу безнең атабыз, анабыз.

Җамали. Бераз авызыңа керсә, телең ни сөйләгәнне колагың ишетми башлый синең.

Камали. Әллә дөрес сөйләмимме? Шалиш, брат. Бик дөрес сөйлим. Беләсегез килсә, бу безгә ата-анабыздан да кадерлерәк. Кайсыбызның ата-анасын моның кадәр кадерләгәне бар? Ә моны куенда гына йөртәбез. Бер тамчысы өчен бугазга-бугаз килеп сугышабыз. Моның өчен соңгы акчабызны бирергә әзербез. Ә ата-анабыз акча сорап килсен әле... Шул-шул. Ишетмәгәнен ишетер.

Җамали. Уф, туйдым мин синең сүз боламыгыңнан.

Камали. Тукта әле, әйтеп калыйм. Юкса уйларым бутала башлар.

Җамали. Синең уйларыңның буталмаган чагы юк. Әйдә, калганын салып куйыйк әле. Уйлар буталсын өчен чыгаралар инде аны. Әйе, әйе, бөтен кешенең акылы саексын өчен. Акылсызларны буйсындыру җиңелрәк бит.

Камали. Менә монысын дөрес әйттең, моның өчен салып куярга була. *(Шешәдәге аракыны бераз тамыза да Мүкләкҗанга суза, тегесе нишләргә белми тора.)* Тукта-тукта, без синең белән танышмадык түгелме соң әле? Син кем? Син кайдан?

Мүкләкҗан *(урманга таба ымлап).* Тегеннән.

Камали. Ә-ә, күренеп тора шул аннан икәнлегең.

Җамали. Исемең ничек?

Мүкләкҗан *(ык-мык килә).* Ни бит... Исемне онытып җибәрдем бит әле.

Камали *(урман ягына йодрык янап)*. Ух, кабахәтләр! *(Мүкләкҗанга.)* Анда оныттыралар, туган. Бераз беләбез инде ул җирләрне.

Җамали. Син дә бит аннан кайткач үзеңне Камали Беренче дип йөри башлаган идең. Хи-хи-хи!

Камали. Ә нигә? Мин патшалар нәселеннән. Мин — Камали Беренче, ә син, сакал, Камали Икенче булырсың. *(Шүрәленең җилкәсенә сугып куя.)* Шәп исем таптым бит үзеңә, ә?

Җамали. Хәзер бу исемне юарга кирәк инде алайса.

Камали. Юабыз аны. Кил әле монда, Камали Икенче. Утыр. Исемеңне юабыз.

Мүкләкҗан. Исем күлмәк түгел бит ул. Аны ничек юасың?

Камали белән Җамали бер-берләренә карашып куялар.

Камали. Бу бичараны бөтенләй эштән чыгарганнар икән.
Җамали. Без аны кеше итәрбез әле. Кил мондарак. *(Стаканны аңа суза.)* Мә, тотып куй.

Мүкләкҗан «тотып куй» сүзен туры мәгънәсендә аңлап, стаканны тота да кире җиргә куя.

Камали. И бичара, бичара. Бөтенләй акылыңны алганнар бит синең.
Җамали. Ух, эзбирләр! *(Стаканны яңадан шүрәлегә бирә.)* Мә, салып җибәр.

Шүрәле, нишләтергә белмичә, тагын аптырап кала.

Җамали. Эч инде, эч!

Шүрәле шунда гына үзеннән нәрсә таләп иткәннәрен аңлап, стакандагы аракыны эчеп җибәрә, ләкин ул ут йоткандай сикереп тора. Авызын зур ачып һава сулый. Ул шулай тын ала алмый торган чакта, Камали аның авызына газета өстендә яткан балык башын каптыра.

Шүрәле балыкны шытырдатып чәйни башлый.

Камали. Ашап бетермә, убыр. Әле безгә дә кирәк ул. *(Шүрәленең авызыннан калган балыкны тартып ала.)*
Җамали *(шүрәленең якасыннан тотып үзенә табарак тарта*). Син хәзер Камали Икенче булдың, белдеңме шуны?
Мүкләкҗан. Белдем.
Җамали. Ә син мине хөрмәт итәсеңме?
Камали. Нигә ул сине хөрмәт итәргә тиеш әле? Мин аңа үземнең исемемне бирдем. Ул мине хөрмәт итә, шулаймы, Камали Икенче? *(Шүрәлене үзенә таба тарта.)*
Җамали *(ул да Мүкләкҗанны үзенә таба тартып)*. Йә, әйт, мине хөрмәт итәсеңме, юкмы?
Камали *(аны этеп, шүрәлене үзенә тартып).* Әйт әле шул тишек үкчәгә, мин Камали Беренчене генә хөрмәт итәм, диген.

Камали белән Җамали үзара тарткалаша башлыйлар. Мүкләкҗан аларның сугышканын күреп, үземә дә эләкмәгәе дип куркып, бер читкәрәк китә. Шул вакыт аның исенә Карт шүрәленең: «Курыксаң, үзебезнең җырны җырлап җибәр», — дигән сүзләре исенә төшә. Бая капкан аракысы да башына китеп өлгергән, ахры, ул җырлап җибәрә.

Туган йортым — кара урман,
Кара төн — тапкан анам.
Бүреләр — минем дусларым,
Карт аю — минем бабам.

Камали белән Җамали моның яшелле-зәңгәрле тавышын ишетеп, сугышып яткан җирләреннән туктап калалар.

Җамали. Тегеннән икәнлеге күренеп тора.
Камали. Әйе, анда мондый җырларны тиз өйрәтәләр.

Шүрәленең бу җырын ишеткәч, Камали белән Җамалиның аңа карата хөрмәте арта. Хәтта үзләре шүрәледән шүрләбрәк калалар.

Җамали. Мин сине үлеп яратам. *(Шүрәленең битеннән чупылдатып үбеп ала.)* Хәзер мин сине үзебезгә алып кайтам.
Камали. Нишләп әле ул сиңа кайтырга тиеш? Ул миңа кайта! Шулаймы, Камали Икенче?
Мүкләкҗан. Әйе.
Камали *(Җамалига).* Ишеттеңме? Минә!
Җамали *(чирәмдәге шешәне алып).* Ярар, син Камали Икенчене үзеңә алсаң, мин бу дусны алам.
Камали. Тукта! Тукта! Монда бит әле кимендә йөз тамчы нәрсә бар. Һы, кара син аны, йөз тамчы зәм-зәм белән үзе генә сыйланмакчы! Моның белән әле илле адәмне үлемнән коткарып була. Тамыз Камали Икенчегә егерме тамчыны.
Җамали *(карышмый)*. Яңа дус өчен дисәң, тамызабыз аны. *(Шүрәленең киеменнән бер җеп тартып алып, шешә эченә тыга, шул җеп буенча аракыны стаканга тамыза. Егерме тамчы тамгач, стаканны Мүкләкҗанга суза.)*
Камали. Җырлап бир.
Җамали. Әллә җырламас дисеңме? Җырлыйбыз аны. *(Җырлый.)*
Стаканым, стаканым,
Стаканым бизәкле;
Салган саен кими бара,

Шунсы өзә үзәкне.

Камали. Һай, дөрес әйттең! *(Стаканны Җамали кулыннан алып, шүрәлегә суза.)* Тегендә бу һөнәреңне оныттырган булсалар, без бик тиз исеңә төшерербез.

Җамали. Әйе, кеше итәчәкбез без сине. Әйдә, эч.

Мүкләкҗан эчә, ләкин пырхылдап кире чыгара.

Камали. Бөтенләй кешелегеңне бетергәннәр синең. Йә, ярый, кайгырма. Миндә бер өч көн торсаң, кеше рәтенә кертәчәкмен мин сине. Ә хәзер безгә кайтыйк. Гөлҗамалым зарыгып көтәдер. Син беләсеңме, Гөлҗамалым мине үлеп ярата. Әйе, әйе. Дөньядагы әллә нинди асыл егетләргә дә алыштырмыйм мин сине, ди.

Җамали. Камали үзенең Гөлҗамалын мактый башласа, минем күңелем болгана. Китим булмаса. *(Баягы җырының соңгы юлларын кабатлый-кабатлый китеп бара.)*

Камали. Бар, бар, кит! *(Шүрәлене кочаклый.)* Чынлап та, Гөлҗамалым шәп минем. Ах, шайтан! Бүген бит аның туган көне иде. *(Мүкләкҗанга.)* Ә беләсеңме, дус кеше, өйгә башта син керерсең.

Мүкләкҗан.Кешенең өенә керергә куркам мин.

Камали. Курыкма. Мин барында бернидән дә курыкма. Курыксаң, минем эшләпәне ки! *(Эшләпәсен Мүкләкҗанга кидерә.)*

Урамыбыз чокыр-чакыр,
Урап үтәргә кирәк;
Бу дөньяга елап килдек,
Җырлап китәргә кирәк.

Пәрдә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Камалилар өе. Гөлҗамал мич янында нидер пешерә. Аның йөзе кызарган. Үзе вакыт-вакыт сәгатькә күз салып ала.

Гөлҗамал*(тәрәзә янына килеп).* Теге чучка тагын Җамалиен очраткандыр, мөгаен. Борыны белән җир сөреп кайтып керер инде. Әнә кайта! Үзе кебек бер дуңгызны ияртkән. Ну күрсәтәм инде мин боларга! Керсеннәр генә. Бүтән авызыма да алмыйм, дип ант итеп чыгып китте. И, тукран тәүбәсе! Үтә бит гомеркәйләрем шушы бетле чучка белән. Башларымны алып качар идем. Юк бит аның җүнле кешесе. Кемгә карама — алкаш. Җыенысы аракы белән ирлекләрен эчеп бетергән хәчтерүшләр.

Ишек шакыйлар.

Гөлҗамал. Культурныйланып кайткан, ишек шакып маташа!

Гөлҗамал ишекне ачып җибәрә. Анда Мүкләкҗан. Башында Камалиның эшләпәсе. Җилкәсендә капчыгы. Ләкин Гөлҗамал моның кем икәнлеген абайлап өлгергәнче, табагач белән башына кундыра.

Гөлҗамал. Мә, өлешеңне ал. Әйттемме мин сиңа, дуңгыз булма, дип?! *(Тагын кундыра. Мүкләкҗан үрле-кырлы сикерә. Үзе, башына табагач эләкмәсен өчен, капчыгы белән башын-битен каплый. Ләкин Гөлҗамал кызганнан-кыза бара. Мүкләкҗан кая барып бәрелергә белми — әле караватөстенә, әле сандык өстенә сикереп менә.)* Кабыргаларыңны саныйм мин синең. Бусы сүзеңдә тормаганың өчен! Бу нәфесеңне тыймаганың өчен! *(Тәпәли.)*

Шүрәле кебек ишеккә таба китә, ләкин ишек ачылмый. Чөнки Гөлҗамалның кызуы басылганчы дип, Камали ишекне тыштан терәтеп тора.

Гөлҗамал. Алай җиңел генә качмый тор әле! *(Тагын шүрәлегә ташлана.)*

Мүкләкҗан. Үләм, үләм! Кая минем карурманым? Сөрмәкүзләрем, Купшыбикәләрем... Хушы...

Гөлҗамал. Әле синең сөрмәкүзләрең дә бармыни? Мә, бусы шулар өчен! *(Кундыра.)*

Мүкләкҗан. Сау бул, туган йортым — карурман. Сау булыгыз, җан дусларым!

Һушсыз булып идәнгә ава. Гөлҗамал аңа аягы белән төрткәләп карый.

Гөлҗамал. Әле үлгәнгә салышып мине куркытырга телисеңме? Ник шунда катмыйсың — куркырлыгым калмады инде.

Идәндә яткан Мүкләкҗан яныннан китеп бармакчы була, ләкин шунда аның аягына эләгеп, шүрәленең башыннан эшләпәсе төшә. Гөлҗамал Мүкләкҗанның саргылт чәчләрен күреп, куркып кала.

Гөлҗамал. Әстәгыфирулла, әллә күзләрем ялгыша инде? Кем соң бу? *(Иелеп карый.)* Юк, юк, Камали түгел. И Ходаем, кеше үтердем бит. *(Шүрәленең күкрәгенә ятып, тын алуын тыңлый.*) Әллә үз йөрәгем генә тибә, әллә анықы — аңларлык түгел. Һәй, Камали, син кайда? Икәү кайта идегез бит. Кер әле, кер тизрәк!

Камали керә. Үзе «Гөлҗамал» көенә шыңгырдый.

Камали. Шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлҗамал.

Гөлҗамал. Шәмдәлләрдә генә түгел, маңгаеңда утлар кабызам хәзер.

Камали *(хатынының халәтен төшенеп җитмичә, җырын дәвам итә).* Җиткән кызлар киндер җеп эрлиләр...

Гөлҗамал. Улама әле. Күрмисеңмени, кеше үтердем бит.

Камали. Үтердең?! *(Тынсыз-өнсез яткан шүрәлегә карап куя, айнып киткәндәй була.)* Әйе, барып чыккан бу. Болай булгач, сиңа төрмә инде.

Гөлҗамал. Син гаепле, мин аны син дип белдем.

Камали. Ә мине үтерергә ярыймы?

Гөлҗамал. Мылтыгым булса, бер түгел, өч кат атар идем инде мин сине.

Камали. Менә кадерлә хатын-кызны!

Гөлҗамал. Әйе, синнән күргән кадер-хөрмәтләр санап бетерерлек кенә түгел. *(Беләген ачып, кара көйгән урыннарын күрсәтә.)* Болары өченче көнгеләре...

Камали *(мыскыллап).* Итәгеңне дә күтәреп күрсәт инде.

Гөлҗамал. Кирәк булса, анысын да ачып күрсәтермен.

Камали. Ә-ә, шулаймы? Теләсә кемгә итәк күтәрергә торасыңмы? Мә шуның өчен! *(Гөлҗамалга селтәнә, ләкин Гөлҗамал аның кулын тотып кала.)*

Гөлҗамал. Бик күп селтәнсәң, кулыңны кыскартырмын. *(Камалиның кулларын боргычлап, башындагы яулыгы белән бәйләп куя.)* Менә шушылай әйбәтрәк булыр.

Камали *(телен чыгарып).* Ә монысын бәйли алмыйсың.

Гөлҗамал. Теләсәм, анысын да бәйләрмен. Тик әлегә телең кирәк булуы бар. Йә, әйт, нишләтәбез бу исерек дуңгызыңны?

Камали. Баш эшләми бит әле. Менә бер илле грамм салсаң...

Гөлҗамал. Өйдә аракы тотмаганымны беләсең бит.

Камали. Өйдә булмаса, өй алдындагысын алып кер. Шунсыз баш эшләми.

Гөлҗамал. Менә хәзер башыңны эшләтәм мин синең. *(Уклау күтәреп Камалига таба килә. Гөлҗамал селтәнгәндә, Камали көч-хәл белән читкә тайпылып кала.)* Тагын шул аракы турында авыз ачсаң, бәрәм дә үтерәм. Миңа хәзер барыбер. Берне үтердем ни дә, икене үтердем ни. Барыбер башым төрмәдә черячәк.

Камали. Мине дә үтерсәң, сиңа передачаларны кем ташыр?

Гөлҗамал. Җитте, мыскыллап утырма. Югыйсә телеңне дә бәйләп куям. Передачаң да кирәкми, үзең дә. Монда сине туйдырып ятканчы, төрмәдә бет туйдырырмын, ичмасам.

Камали. Андагы бетне туйдырып бетерерлек кенә түгел. Давай, чиш әле кулларны. Баш кычыта.

Гөлҗамал. Башыңны менә моның белән кашыйм мин синең хәзер. *(Уклау белән яный.)*

Камали. Ярый инде, сезнең уклау белән табагачыгыз бар, югыйсә нишләр идегез икән? *(Башын мичкә кашый.)* Кашынудан да рәхәтрәк нәрсә бар икән дөньяда?!

Гөлҗамал *(аның кулларын чишә).* Миннән булсын инде яхшылык.

Камали. Уф! *(Кулларын угалый.)* Эчкән аракыларым әрәм була. Айнып бетәм инде.

Гөлҗамал. Айнырга бик вакыт.

Камали. Шул арада айнырлык булгач, эчәсе дә юк аны. *(Хатынының ярсуы кимегәнен күреп, үзе һөҗүмгә күчә башлый.)* Чүпрәкбаш! Кеше үтерерлек итеп сукмасаң. *(Үзен-үзе кызганып.)* Сине төрмәгә япсалар, мин нишләрмен? Кем ашатыр, кем киендерер? Кем утын китерер, кем мичкә ягар? Үзең турында гына кайгыртасың син. Ярый ла син анда әзергә-бәзер барасың. Кеше үтерүче буларак, берүзеңә бер бүлмә бирерләр. Бөтен уңайлыклары белән. Туалеты, ягъни чиләге үзендә. Хатыннар эгоист шул. Мин лыкын булып эчкәндә дә сине онытмыйм. Бу мине ничек каршы алыр икән, кәефләре ничек икән дип уйланам. Ә син?..

Гөлҗамал *(аңа тибеп).* Тәпиенә сыер баскан эттәй шыңшыма әле. Бар әнә, көрәк ал да бакчага чокыр казы.

Камали. Анысы нәрсәгә тагын?

Гөлҗамал. Мин төрмәгә китәргә җыенмыйм. Бу адәм актыгын шунда күмәрсең. Мә, капчыгын да күм. *(Капчыкка тибеп җибәрә. Капчыкның бавы чишелеп, идәнгә акча төргәкләре коелып төшә.)* Әстәгыфирулла! Әллә сез берәрсен таладыгызмы?

Камали *(үзе дә бу хәлгә шакката. Акча төргәкләрен кулында сикерткәләп куя).* Менә кайда икән

байлык! Ә мин бер өтек җан дип торам. *(Капчыкны төбенә кадәр идәнгә бушата. Капчык төбеннән акчалар белән алтын кисәкләре дә төшә.)*

Гөлҗамал *(акча төргәкләрен ашыга-ашыга санарга тотына).* Берәү, икәү, өчәү, дүртәү...

Камали *(акча өемен үзенәрәк тартып).* Бишәү, алтау, җидәү, сигез...

Гөлҗамал *(аңа санап бетерергә ирек бирмичә).* Тугыз, ун, унбер...

Камали *(бер төргәкнең кәгазен ертып санарга тотына).* Берәү, икәү, өчәү... егерме биш.

Гөлҗамал. Аңгыра! Нигә аны санап маташасың? Бер пачкада йөз акча була инде.

Камали. Димәк, монда... Тукта, күпме була соң? Бер төргәк, биш төргәк, һәр төргәктә йөзәр мең. Уф, баш эшләми. Әй, ярар, ничә булса да, болар минеке хәзер. Бер яртыны меңгә алсаң да, менә бу пачкада йөз яртылык диган сүз. О-о, болай булгач эчәбез икән, хатын!

Гөлҗамал *(акчаларны тартып ала).* Эчми тор әле!

Камали. Син нәрсә? Шушының кадәр акчаны, эчмәгәч тә, нишләтмәкче буласың?

Гөлҗамал. Анысын үзем белермен. *(Акча төргәкләре янында аунап яткан алтын кисәкләренә яңа гына игътибар итә.)* Болары нәрсә соң? Алтын бит, чын алтын! *(Тешләп карый.)* Валлаһи, алтын. *(Шүрәлегә карап.)* Берәр касса баскандыр бу. Югыйсә моның кадәр акча каян килсен? *(Ярым пышылдап.)* Карале, Камали, моны бәреп үтерүем әйбәт булган бит, ә?

Камали. Тс-с! Шаулама, хатын. *(Пәрдәләрне тартып куя.)*

Гөлҗамал. Кем бу, ә? Каян килеп чыкты?

Камали *(мәгънәле генә итеп).* Тегеннән...

Гөлҗамал. Карале, Камали, моның безгә киткәнен берәр кеше күрдеме?

Камали. Җамали күрде. Аның белән чирәмдә бер яртыны сындырып ятканда килеп чыкты ул. Аны Җамали үзенә апкитмәкче булган иде...

Гөлҗамал. Үзенә? Бәлки, ул аның капчыгында ни барлыгын белгәндер?

Камали. Каян белсен? Өстенә генә кара син бу өтекнең. Хәерченең хәерчесе.

Гөлҗамал. Жуликлар алар юри шулай мескен булып күренергә яраталар.

Камали. Сөйләдең син дә. Тере жуликны күргәнең бармы?

Гөлҗамал. Ә мин күрдем дә, бәреп тә үтердем. Карале, Камали, Җамали бик исерек идеме?

Камали. Ха-ха-ха! Җамали да булсын, айнык та булсын.

Гөлҗамал. Моның сиңа ияреп киткәнен, бәлки, хәтерләмәс.

Камали. Һи, Җамали ул шешә төбендә калган биш тамчы аракыны да онытмый.

Гөлҗамал. Нишләргә соң инде?

Камали. Ярар, караңгы төшкәч, чыгарып күмәрмен. Җамали сорашса, китте, диярбез. Хәзергә өстенә берәр нәрсә каплап тор. Кеше күрмәсен.

Гөлҗамал караваттан җәймә алып каплый. Шул арада Камали, бер пачка акчаны кесәсенә шудыра. Ләкин аны Гөлҗамал күреп кала.

Гөлҗамал. Яшермә, мин сукыр түгел.

Камали. Син яшергәндә ярыймы?

Гөлҗамал. Минме яшердем? Күз яшедәй саф хатыныңа яла якмакчы буласыңмы әллә?

Камали *(урыннан торып, хатынының арт ягыннан килә дә ялт кына үрелеп Гөлҗамалның түшеннән бер төргәк акча тартып чыгара).* Бу ни, хатын? Әллә ул анда үзе кергәнме?

Гөлҗамал. И-и, кара инде, каян килеп кергән диген!

Камали. Белмим шул, хатын. Акча — аяклы, диләр.

Гөлҗамал. Ярар, көлеп утырган булма. *(Бөтен акчаларны сыдырып үз алдына китерә.)* Бу акчаларда синең бер дәхелең дә юк. Үз гомереңдә өйгә бер тиен акча алып кайтканың юк. Җитмәсә, боларга нәфесеңне сузасың.

Камали. Ярар, алайса. Моны *(шүрәлегә ымлап)* үзең күмәрсең. Мин Җамалиларга барып кайтыйм әле, анда шешә төбендә бераз калган иде бугай.

Гөлҗамал. Шушының серкәсе бигрәк тә су күтәрми инде. Йә, ярар, үпкәләштек, булды. Мә, эчкәрегерәк кесәңә салып куй. *(Бер меңлекне суза.)* Ә хәзер боларны кеше-кара күргәнче ышанычлырак урынга яшерергә кирәк.

*Гөлҗамал акчаларны кире капчыкка тутыра башлый, шул вакыт шүрәле кинәт төчкереп җибәрә. Гөлҗамалның капчыгы кулыннан төшеп китә. Ул лып итеп идәнгә утыра, ә Камали шүрәленең өстенә япкан япмасын ипләп кенә ачып карый.*

Камали. Һәй, Камали Икенче! Хәлләрең ничек?

Шүрәле башын тотып утыра. Гөлҗамалны күрә дә яңадан ава.

Камали. Тәмам котын алгансың син моның.

Гөлҗамал. Ныграк төште бугай шул. Кая әле, нашатыр спирты иснәтим үзеңә. *(Карават астыннан бер шешә тартып чыгара. Бөкесен ачып, шүрәленең борын төбенә китерә.)* Иснә, җаныем, иснә. Хәзер

кеше итәм мин сине. *(Шүрәле тагын төчкереп җибәрә.)* Менә шулай. *(Гөлҗамал аңа торырга ярдәм итешә.)* Әйдәле, матурым, торып утырыйк әле. Бәлки, синең карының да ачкандыр, ә? Мичтә бәлешем бар. Өстәл янына утырыша торыгыз. *(Кухня ягына кереп китә.)*

Камали. Нәрсә булды, дус кеше? Әллә егылдыңмы?

Мүкләкҗан *(башын уып)*. Нәрсә булганын һич хәтерләмим. Синең Гөлҗамалыңның бер юан таяк тотып куалап йөрткәне генә хәтердә.

Камали. Ә, таяк белән ул кайвакыт чебеннәр куа. Чебен куып йөргән чагына туры килгәнсеңдер. Әйдәле, утырыйк, хәзер Гөлҗамал бәлеш чыгарыр. Әкәмәт шәп кеше ул минем хатын. Аның яхшылыкларын син үзең дә күрерсең әле. Син бездән тиз генә китәргә җыенмыйсыңдыр бит?

Мүкләкҗан. Юк.

Камали. Дөрес эшлисең. Кунак бул. Ял ит. Тегендә эшләгәнең дә җиткән.

Гөлҗамал бәлеш чыгарып утырта. Өстәлгә тозын, борычын, горчи-
цасын куя. Гөҗләп торган самавыр да өстәлгә менеп кунаклый.

Гөлҗамал. Әйдәле, кадерле кунак, җитешә башла. Кирәк булса, менә борычын, тозын өстәрсең. Бик белеп килгәнсең. Бүген минем туган көнем.

Шүрәле комсызланып бәлешкә тотына. Авызын пешерә. Авызын пешергәч, нишләргә белмичә, аптыраганнан борычны каба. Авызы тагы да ныграк кызыша. Горчицаны каба — күзеннән яшьләр атылып чыга. Хуҗалар үзара карашып кына аның кыланышын күзәтәләр.

Мүкләкҗан. Сездә бик кайнар ашыйлар икән. Безнең тегендә мондый азык күргән юк.

Камали. И дускай, андагы хәлләрне бераз беләм инде мин. Анда бәлеш ашатмыйлар шул.

Гөлҗамал. И-и, хәтер диген инде миндә! Бик кадерле кунакларга гына дигән бер әйберем бар иде.

Гөлҗамал сикереп тора да Камалиның иске итек кунычыннан бер коньяк тартып чыгара. Камалиның, моны күрүгә, күзләре яна башлый.

Ул кулларын угалап куя.

Камали *(мутланып)*. Өйдә аракы тотмыйм, диген, ә?

Гөлҗамал. Аракы түгел бит бу, коньяк!

Камали. Минем хатыннан да шәп кеше юк дип әйттемме мин сиңа?! Шулай ул минем хатын. (*Стаканнарга коньяк сала.)* Әйдәле, дускай, күтәреп куйыйк әле берне. Аннан соң башың авыртмый инде. *(Үзенекен эчеп куя. Мүкләкҗанга карап.)* Әйдә, әйдә. Иснәштереп торма, йот та куй.

Мүкләкҗан бик кыенлык белән генә коньякның яртысын эчә.

Мүкләкҗан. Сасы да, кайнар да. Сездә бөтен нәрсә сасы, кайнар икән.

Камали. Әйе, тегендә коньяк эчермиләр шул. Күрәсең, сине анда шактый озак тотканнардыр. Ашау-эчүне оныткансың.

Гөлҗамал *(Камалига серле карап)*. Кунакка, бәлки, җырлап бирерсең, Камали?

Камали. Була ул. *(Җырлый.)*

Стаканым, стаканым,
Стаканым пыяла.
Шул стаканны күрсәм дә,
Аппетитым кузгала, их!

Гөлҗамал *(шүрәлегә)*. Ә хәзер, әйдә инде, матурым, тотып бетер. Бездә салганны калдырырга ярамый. *(Стаканны шүрәлегә тоттыра.)* Икәү чәкештереп эчәбезме?

Шүрәле Гөлҗамал сүзен кире кагарга курка, эчәргә мәҗбүр була. Шул вакыт Камали кесәсеннән папирос чыгарып, авызына каба һәм шырпы эзләп мич янына килә. Папирос кабызгач, ни өчендер пәрдә читен күтәреп урамга карый.

Камали. Җамали килә.

Гөлҗамал. Җамали? *(Өстәл өстендәге шешәне тиз генә алъяпкычына төреп куя.)* Бар әле, Камали, шул алкашыңны берәр сәбәп табып ераграк озат.

Камали. Керсен.

Гөлҗамал. Шушындый кадерле кунак янына утырта торган кешемени ул? Табынны ямьсезләп, аппетитны бозып утырыр. *(Гөлҗамал алъяпкычына төргән шешәсеннән бераз гына Камалига салып бирә.)* Ә хәзер, бар! *(Камалиның артыннан этә.)*

Камали. Кара аны, кунакны бик шәп сыйла, мин кайтмыйча беркая да җибәрмә! *(Бер төргәк акчаны ялт кына эләктереп чыгып китә.)*

Гөлҗамал. Юк инде, юк. *(Шүрәлегә.)* Ә син ашап-эчеп утыр. Үзеңне үзең кайгыртмасаң, безнең өйдә кыстаучы булмас.

Мүкләкҗан. Минем нишләптер кети-кети уйныйсым килеп китте. Менә бу сасы, кайнар нәмәстәне эчкәч, кети-кети уйныйсы килә икән.

Мүкләкҗан, *кулларын угалап, Гөлҗамалга таба килә. Гөлҗамал мутланып шүрәлегә бармак яный. Ләкин Мүкләкҗанның башына киткән. Ул Гөлҗамалны кытыклый башлый. Гөлҗамал шарыкшорык көлә.*

Гөлҗамал. Уф, үләм! Кытыклама шулхәтле. Шүрәле түгелдерсең бит?!

Мүкләкҗан. Мин — шүрәле. Хи-х, и-хи. Әйе, мин — урман сарыгы. *(Гөлҗамалны кытыклаудан туктамый.)* Мондый йомшак тәнле кешене күптән кытыклаган юк иде. Бармакларга рәхәт.

Гөлҗамал. Кытыклама, тукта! Үтерәсең!

Ләкин шүрәле кытыклаудан туктамагач, Гөлҗамал аның кочагына ук керә дә йомшак ак беләкләре белән Мүкләкҗанны муеныннан кочып ала.

Гөлҗамал *(пышылдап)*. Мин ошыйммы сиңа?

Мүкләкҗан. Синең тәнең йомшак.

Гөлҗамал. Әйдә, качабыз.

Мүкләкҗан. Әйдә. *(Гөлҗамалны мич артына сөйри.)*

Гөлҗамал. Анда гына түгел, ерак-еракка. Туйдым мин бу алкаш Камалидан. Алып кит мине үзең белән.

Мүкләкҗан. Ә бит мин урман шүрәлесе.

Гөлҗамал *(бармак янап)*. Шаярма! Синең бөтен кыяфәтең интеллигент икәнлегеңне әйтеп тора. Кара инде бу бармакларны. Бик шәп музыкантларда гына бардыр мондый бармаклар. Әйт әле дөресен: музыкантмы син?

Мүкләкҗан музыкантның ни икәнен аңламый, ләкин Карт шүрәленең, ни дип җавап бирергә белмәгәндә, «әйе», «юк», «әйе» дип әйтерсең» дигән сүзләре исенә төшә.

Мүкләкҗан. Әйе, юк, әйе.

Гөлҗамал. Синең башыңа киткән, ахры. Интеллигент икәнлегең шуннан да күренеп тора инде. Безнеке сыер урынына эчмичә исерми.

Гөлҗамал шүрәленең алдына утыра, аның чәчләрен бармаклары белән аралый. Шүрәле исә аның төрле җирен кытыклаштыргалый. Гөлҗамал кинәт-кинәт көлеп куя һәм шүрәленең бармакларын тота.

Гөлҗамал. Алай бик эчкәре кермә. Менә үзеңә алып китәрсең дә минем йомшак тәнемне тотып рәхәтләнерсең. Минем назым әле бик әйбәт сакланган. Их, минем наз!..

Мүкләкҗан. Наз? Нәрсә ул наз?

Гөлҗамал *(бармак яный)*. Шаярма! Ә назны чынлап оныткан булсаң, менә моннан башлана ул. *(Шүрәленең иреннәрен суырып үбә дә читкә китә.)*

Мүкләкҗан. Кара әле, бу наз дигән нәрсә шәп әйбер икән. Әйдә, тагын наз-наз ит. *(Гөлҗамалны тотарга килә.)*

Гөлҗамал аннан качып китә. Алар куышып йөриләр.

Гөлҗамал. Кара аны, Камали кайтып керсә, маңгаеңа күсәк белән наз-наз итәр. Бик көнче ул.

Мүкләкҗан. Тагын бер генә наз-наз ит инде.

Гөлҗамал. И, бу ирләрне! *(Шүрәлене үбә.)* Йә, ярый, булды, шаярдык. Ә хәзер киләчәк турында уйлыйк. Иң беренче шуны әйт: ошыйммы мин сиңа?

Мүкләкҗан. Әйе, синең наз-назың әйбәт.

Гөлҗамал. Мин сине гел шулай итеп һәм аннан да шәбрәк итеп назлап торырмын. Шәһәрдән бик шәп итеп фатир сатып алырбыз. Кайнар суы, салкын суы агып торыр. Ваннага утыртып мин синең аркаңны ышкырмын. *(Шүрәле аркасын кашып куя.)* Бу киемнәреңне утка ягарбыз. Юкса синнән бик үк хуш ис килми.

Мүкләкҗан *(бармакларын уйнаткалап)*. Кети-мети, наз-наз.

Гөлҗамал *(капчыгы белән акчаны күтәреп килә)*. Боларны алыйк та тайыйк без. Юкса теге дуңгыз кайтып керә башлар. *(Шүрәлене тарткалый.)* Әйдә, китик. Барыр җирең юк икән, беразга урманыңда торып торырбыз. Яратам мин урманны. Анда романтично!

Мүкләкҗан Гөлҗамал артыннан кузгалмакчы була да кире утыра.

Мүкләкҗан. Ә, юк әле. Миңа тиз генә кайтырга ярамый. Минем кайбер нәрсәләрне аңлап бетерәсем бар.

Гөлҗамал *(аның сүзен үзенчә аңлап)*. Эһе, төшендем. Бу хикмәтләреңнең *(акча капчыгына ымлап)* кызуы сүрелгәнче, сиңа яшеренеп ятар урын кирәк. Ярый, анысына да риза. Тик син кети-метиләреңне Камали барында туктатып тор.

Мүкләкҗан. Кети-мети. И-хи-х-и!.. Әйе, Камали юк. *(Капчыктан акчаларны ала да Гөлҗамалның алъяпкыч бавына да, түшенә дә кыстыра.)* Кети-мети, наз-наз кирәк. Акча синеке, кети-мети минеке.

Гөлҗамалның төрле җирләренә үрелә башлый.

Гөлҗамал. Их, шушы ир-ат халкы түземсез дә инде.

Мүкләкҗан. Кети-мети. *(Гөлҗамалны кочаклый.)*

Гөлҗамал. Әйдә инде алайса. *(Шүрәленең кочагыннан чыкмыйча гына назланып икенче бүлмәгә алып кереп китә.)*

Берничә минутка сәхнәдә ут сүнә. Бераздан ут кабына. Шул ук Камалилар өе. Ләкин берничә көн вакыт үткән. Мүкләкҗан инде монда тәмам ияләшкән. Ул хәзер аракыны шома гына эчә башлаган. Ут кабынганда, ул кәнәфигә кырын яткан. Тәмәке пыскыта. Өс-баш яхшы. Гөлҗамал аңа Камалиның әйбәт костюм-чалбарын кидерткән. Гөлҗамал, кәнәфинең култыксасына утырып, Мүкләкҗанны кочаклаган.

Гөлҗамал. Карале, ни... Ничә көн бездә торып, үзеңнең чын исемеңне дә әйтмисең. Әллә мине яратмыйсың инде? *(Иркәләнеп Мүкләкҗанга сыена.)*

Мүкләкҗан. Камали Икенче мин.

Гөлҗамал. Камали исемен ишетәсем дә килми иде бит минем. Әллә исемеңне алыштырабызмы, ә?

Мүкләкҗан. Алыштырырга да була, алыштырмаска да була. Кая, теге сасы суыңны китер әле.

Гөлҗамал. Бик күп эчә башладың түгелме син? Болай булсаң, яратмам бит үзеңне.

Мүкләкҗан. Күп эчәм, аны эчсәң, кети-мети, наз-наз уйныйсы килә. *(Гөлҗамалны кытыклап ала.)*

Гөлҗамал. Ташла әле шул шүрәле гадәтләреңне.

Мүкләкҗан. Мин бит шүрәле. Ха-ха!

Гөлҗамал. Һаман миңа үзең турында дөресен әйтергә теләмисең. Ирләр алар үз кирәген алганчы гына. *(Көрсенеп куя.)* Шүрәле булсаң, тизрәк урманыңа апкит. Романтикага чумыйк. Юкса монда бер дә кызык юк.

Мүкләкҗан. Урманга? Ярар, китәрбез. Җыена башла алайса. Синең Камалиеңнан да бик туйдым. Миңа гел акаеп карый.

Гөлҗамал сумкаларга әйберләр тутыра. Акча һәм алтыннарны иске капчыктан ышанычлырак чемоданга күчерә.

Мүкләкҗан. Әйберләрне бик күп алма. Без барасы җиргә аларның берсе дә кирәкми.

Гөлҗамал. О-о! Күз алдына китерәм мин синең йортыңны. Анда ялан кадәр бүлмәләр...

Мүкләкҗан. Әйе, яланнар зур...

Гөлҗамал. Ул бүлмәләр болындагы мең төрле чәчәк төсенә кертеп бизәлгән.

Мүкләкҗан. Дөрес сукалыйсың — чәчәкләр күп.

Гөлҗамал. Тәрәзәне ачып җибәрүгә, сандугач моңы өеңә ургылып керә...

Мүкләкҗан. Нәрсә, нәрсә — сандугачы булыр.

Гөлҗамал. Өебезнең бер ягында — урман, икенче ягында диңгез шаулар.

Мүкләкҗан. Урманы өйнең эчендә үк, анысына әллә кая барасы юк, ә менә диңгез дигәнең күл генә.

Гөлҗамал. Үзебезнеке булса, күле дә ярар. Күлендә коенырбыз, комында кызынырбыз.

Мүкләкҗан. Анысы дөрес. Безнең бөтен эш шул кызыну белән коенудан торачак.

Гөлҗамал. Һай, минем бәхетемә туган нәрсә! *(Шүрәлене үбеп ала, аннары икенче як бүлмәгә кереп китә.)* Мин хәзер, җаныем. Коену костюмымны гына алыйм.

Мүкләкҗан. Күпме көннәр кешеләр арасында яшәп, һич аңлап бетерә алмадым мин боларны. Ни өчен яшиләр болар? Менә шушы кайнар суны эчәр өченме? Алай дисәң, моны эчмәгән кешеләр дә бар. Иген чәчәләр, йортлар салалар. Урлашалар, алдашалар, кыйнашалар, хәрәмләшәләр, эчәләр, тарталар, тагы әллә ниләр эшлиләр. Күрәсең, дөньяның бөтен кызыгы шулардадыр. Ни генә әйтсәң дә, боларның кылган эшләренә безнең шүрәле башы гына җитәрлек түгел.

Гөлҗамал керә.

Гөлҗамал. Мин әзер, матурым. Әйдә, тизрәк китик, юкса Камали кайтып керә башлар.

Мүкләкҗан. Әйдә!

Әйберләр күтәреп чыгып китәләр.

Пәрдә.

**ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Беренче пәрдәдәге урман аланы. Мүкләкҗан чирәмгә сузылып яткан. Тәмәке пыскыта. Аның янына башка шүрәлеләр килеп-килеп китә. Үзенә иелүче шүрәлене күргәндә, Мүкләкҗан тегеләрнең йөзенә кинәт тәмәке төтене өрә. Тегеләр төтенгә тончыгып йөткерә-ютәлли башлый. Мүкләкҗанга кызык, ул шырык-шырык көлә.

Мүкләкҗан *(җырлый).*
Өсләремдә кәчтүм-чалбар,
Авызымда — тәмәке.
Эчәм, тартам, гүләйт итәм,
Кеше булдым бит тәки.
Әй, Гөлҗамал, син кайда. Шешәне чыгар.

Гөлҗамал урман эченнән килеп чыга. Алдына бер тире кисәге генә япкан.

Гөлҗамал. Нигә кычкырып ятасың? Нәрсә кирәк инде тагын?
Мүкләкҗан. Шешәләр кайда?
Гөлҗамал. Каймалы базарында.
Мүкләкҗан. Нишләп син минем белән болай сөйләшә башладың әле?
Гөлҗамал. Ачуымны китерсәң, бөтенләй дә сөйләшмәм.
Мүкләкҗан. Сөйләшмәсәң, хәзер мин Купшыбикәне чакырам. *(Кычкыра.)* Купшыбикә, кил әле монда!

Купшыбикә керә.

Мүкләкҗан. Телисеңме, Купшыбикә, мин хәзер Гөлҗамалны урманнан куам да синең белән кети-мети уйныйм.
Купшыбикә. Аны куарга күптән вакыт инде.
Гөлҗамал. Кумасагыз да китәрмен. Гарык мин сездән.
Мүкләкҗан. Кирәк чаклы теге сары тимерләрне, ялтыравык ташларны җыйдым, хәзер сезнең кирәгегез калмады, дисеңме? Без бит аларны алып та кала алабыз.
Купшыбикә *(Мүкләкҗанны башыннан сыйпый).* Башың эшли икән синең.
Гөлҗамал *(Купшыбикәне этеп).* Кит минем Камали Икенче яныннан!
Купшыбикә. Китми генә торыйм әле. *(Гөлҗамалны этеп җибәрә. Тарткалаш башлана.)* Мин Мүкләкҗанны сезнең ише азгын җаннарга бирмим.
Мүкләкҗан. Ярар, шаулашмагыз, минем шешәне кайсыгыз тизрәк табып китерә, шуны үземнең янымда калдырам.

Купшыбикә шешәләрнең кайда икәнлеген белми, Гөлҗамал куак арасыннан шешә тутырылган сумка тартып чыгара. Купшыбикә үпкәләп китеп бара.

Гөлҗамал *(Мүкләкҗанга назлы да, шул ук вакытта бераз шелтәле дә караш ташлап).* Бигрәк тә серкәң су күтәрми инде. Мин бит шаярган гына идем.
Мүкләкҗан *(күкрәк кагып).* Моннан болай минем белән тупас шаярма. Мин сиңа Камалиең түгел, мин — шүрәле! Ә хәзер, давай, үз өеңдәге кебек итеп аракы салып эчер. *(Гөлҗамал сала. Боларны шүрәлеләр агач артыннан күзәтә. Мүкләкҗан тамак кырып эчеп куя. Аннары авызын ачып, Гөлҗамалга карап тора.)* Каптыр тизрәк берәр нәрсә! *(Гөлҗамал ит кисәге каптыра.)*
Гөлҗамал. Күңелең булдымы инде?
Мүкләкҗан. Хәзер моннан бик матур итеп «пәп» итеп ал. *(Иреннәрен суза. Гөлҗамал теләр-теләмәс кенә аңа кагылып ала.)* Өегездә, үзеңнең бүлмәңдәге кебек итеп назла. Йә, йә, капчыктагы акчаларны күргәндәге төсле кайнар итеп үп әле. Юкса коры кул белән кудым-кайтардым. *(Гөлҗамал үбә.)* Ә хәзер, кил, алдыма утыр. *(Шүрәлеләргә кычкыра.)* Әй, сез, урманның аңгыра сарыклары, монда килегез. Мин сездән хәзер кеше ясыйм.

Шүрәлеләр кызыксыну белән Мүкләкҗан янына җыела башлый. Сөрмәкүз белән Купшыбикәнең нәфрәтле карашлары Гөлҗамалга текәлә.

Гөлҗамал. Әй, сез, сарыкбикәләр, нәрсәгә күзләрегезне тождрайттыгыз? Әллә көнләшәсезме? Көнләшерсез шул. Менә бит минем тәнем нинди ак.
Сөрмәкүз. Чебен гөмбәсе дә ак, әмма эче тулы агу.
Гөлҗамал. Мин хәтта сезгә үпкәләмим дә. Сөрсегән җаннар!

Сөрмәкүз белән Купшыбикә озын бармакларын төрлечә кыландырып Гөлҗамалга таба киләләр.

Купшыбикә. Аны бармаклар белән генә түгел, кычыткан белән кытыкларга кирәк. *(Кычыткан йолкып алып, Гөлҗамалны чактыра. Тегесе кычкыра, качарга омтыла.)*
Гөлҗамал. Камали Икенче, ник үзеңнең йомшак тәнле, кайнар назлы Гөлҗамалыңны

яклашмыйсың? Үтерәләр бит.

Мүкләкҗан. Китегез, тимәгез Гөлҗамалга. *(Шешә белән кизәнә.)* Кагыласы булмагыз, юкса минем кулдагы шешә маңгаегызга төшәчәк. Әгәр инде бер дә кызык тапмыйсыз икән, килегез, менә моны авыз итегез. Шундук ачуларыгыз басылыр.

Сөрмәкүз. Үзең эч сасы суыңны.

Мүкләкҗан. Үзем дә эчәм, сез дә эчәрсез. Кеше итәм әле мин сезне. Берүзең генә эчү күңелсез. Кешеләр дә аны ялгыз гына эчмиләр. Иң кызыгы бергәләп исәрләнүдә аның. Йә, кайсыгыздан башлыйбыз? Олавыз, синнәнме? Кил, кил, курыкма. Гөлҗамалны әллә кайчаннан бирле күзең белән ашап торасың, күреп торам. Әгәр менә шушыны эчсәң, Гөлҗамалның кулын тотып карарга рөхсәт итәм.

Олавыз. Чынлапмы?

Мүкләкҗан. Чынлап, чынлап. Мә, тот.

Мүкләкҗан стаканны суза. Олавыз эчә дә, нишләргә белми, эчен уа башлый.

Олавыз. Су сибегез миңа, су сибегез. Менә, корсагымда ут!

Мүкләкҗан белән Гөлҗамалга кызык, алар тәгәри-тәгәри көләләр. Сөрмәкүз белән Купшыбикә ачулы.

Купшыбикә. Нишләттең син үзеңнең ырудаш дустыңны?

Мүкләкҗан. Кеше иттем. Ха-ха-ха! Килегез, сезне дә кеше итәм.

Аракысын күтәреп хатын-кыз шүрәлеләр артыннан куып йөри, тегеләре шыр-шыр кычкырып кача. Шул вакыт урман арасыннан Карт шүрәле килеп чыга.

Карт шүрәле. Бу нинди шайтан туе? Нишлисез, ырудашларым?

Мүкләкҗан. Менә, үзләрен кеше итмәкче идем.

Карт шүрәле Мүкләкҗанның кулыннан шешәне ала. Иснәп карый да читкә ыргыта. Шешәне Гөлҗамал барып ала.

Гөлҗамал. Ыргытма, карт пәри! Аның ничә сум икәнен беләсеңме?

Карт шүрәле *(Мүкләкҗанга)*. Оятсыз, безнең саф урманыбызга пычрак җанлы кеше алып кайткансың. Без ни өчен сине авылга җибәрдек?

Мүкләкҗан. Кешеләрне өйрәнергә дип. Мин шуны үтәдем. Өйрәнеп кенә дә калмадым. Кешеләрнең барлык гадәтләрен җаныма сеңдереп кайттым. *(Стаканга аракы агыза да Карт шүрәлегә суза.)* Мә, менә бу сасы суны эчеп җибәр. Күңелне бик тиз күтәрә. *(Карт шүрәле аның стаканын этеп җибәрә.)* Юкка карышасың, картлач. Кешеләр бездән акыллы булсалар да, монсыз тора алмыйлар. Ике ир-ат очрашса, шуңарга ябыша. Әллә нинди котсыз бәндәләрнең дә шушыны бер стакан эчүгә чырайлары ачыла. Дошманлашкан булсалар, кешеләр шушыны эчеп дуслашалар. Эшләп арысалар, шушының белән хәлләнәләр. Кыскасы, кешеләрнең барлык сөенечләре шушы шешәгә тутырылган. Менә мин шул сөенечнең нәрсә икәнен үзебезнең шүрәлеләргә дә аңлатырга телим. Ха-х-а-ха! Бер шешә шатлык, бер шешә кызык! Бер-береңне кытыклап маташасы да юк. *(Шүрәлеләргә.)* Мәгез, эчеп карагыз әле шушыны. *(Стакандагы аракысын әле бер, әле икенче шүрәлегә суза. Ләкин шүрәлеләр аның стаканлы кулы якынлаша башлауга, куркынып артка чигенәләр.)* Мәгез, мә! Курыкмагыз, үтерми ул. Бәлки, сез бу картлачтан куркасыздыр? Юкка! Аның бармакларында сезне куркытырлык көч калмаган инде.

Карт шүрәле. Ялгышасың, Мүкләкҗан. Минем бармакларымда синең аңгыра башыңа акыл кертерлек куәт бар әле.

Шартлатып Мүкләкҗанның маңгаена чиртә. Мүкләкҗан артка чигенеп куя. Шунда ул үзенең кулында шешә барлыгын абайлап ала һәм, ике уйлап тормастан, Карт шүрәленең башына шешә белән тондыра. Карт шүрәле егыла. Бар да аһ итә. Ачулары кабара. Алар, йодрык ларын йомарлап, Мүкләкҗанга киләләр. Иң алда Яшь шүрәле.

Яшь шүрәле. Дуслар, канга — кан, үлемгә — үлем!

Тавышлар. Үлемгә — үлем!

Гөлҗамал чәрелдәп урманга кача. Мүкләкҗан шешәсе белән кизәнә. Ул кизәнгәндә шешәсеннән аракысы җиргә түгелә. Шүрәлеләрнең борынына аракы исе керә. Яшь шүрәле туктап кала.

Яшь шүрәле. Кардәшләрем, аңа якын бармагыз, сасысы йогар.

Сөрмәкүз. Хәшәрәт, бөтен урманны сасытты.

Шүрәлеләр читкәрәк таралмакчы була, ләкин бая эчкән аракыдан Олавызның каны кайный башлый.

Олавыз. Бу сасы су бик шәп нәрсә икән. Авызларым җәелеп китте. Ха-ха-ха, хи-хи-хи! Мүкләкҗан, тагын бер салып бир әле миңа.

Яшь шүрәле. Олавыз, нишлисең син? Син арада иң әдәплеләрдән идең.

Олавыз. Ә минем әдәпсезләнеп карыйсым килә башлады. Мүкләкҗан, син ничек җырлыйсың әле? *(Җырлый.)*

Стаканым, стаканым,
Стаканым пыяла.
Стаканнарын күрсәм дә,
Аппетитым кузгала.

Мүкләкҗан. Булдырасың, Олавыз. Мәле шуның өчен, җырың өчен. *(Аракы салып бирә. Олавыз эчә.)*

Олавыз. Хәзер Гөлҗамалның кулын тотып карасам ярыймы инде?

Мүкләкҗан. Ярый, ярый. Әй, Гөлҗамал, син кая олактың?

Урман эченнән Гөлҗамал чыга, Олавызның эчкәнен белеп, мактап куя.

Гөлҗамал. Менә молодец! Менә кеше булгансың!

Олавыз аның кулыннан тота. Урманга өстери.

Олавыз. Әйдә, җаныем, урманга, кети-кети уйнап алырбыз.

Гөлҗамал кулын аңардан тартып ала. Үзенә нәфрәт белән карап торган Яшь шүрәлегә дәшә.

Гөлҗамал. Синең кулымны тотып карыйсың килмиме? Мә, рөхсәт итәм.

Янына бара. Яшь шүрәле артка чигенә.

Яшь шүрәле. Сиңа кагылганчы, мин башымны агачка бәреп ярам.

Олавыз *(әтәчләнеп).* Үзеңне кем дип белдең? Әнә Карт шүрәлең дөмекте, хәзер сине яклаучы юк. Сине дә дөмектерәбез.

Гөлҗамал *(Олавызның башыннан сыйпап).* Алай дорфа кыланмыйк инде. Без аны дөмектермибез, кеше итәбез, шулаймы, Камали Икенче?

Мүкләкҗан. Дөрес сукалыйсың. Әйдә, эләктер үзен, Олавыз. Кеше ясыйк әле шуңардан.

Олавыз кинәт ыргып Яшь шүрәлегә ташлана, аны эләктереп ала. Тегесе тешләшә, тартыша, ләкин көчләр тигез түгел — бирешә.

Олавыз. Нишләтәбез?

Гөлҗамал. Менә моны эчерәбез. *(Яшь шүрәле башын агачка бәрмәкче була.)* Ярамый, матурым, ярамый. Без сиңа үләргә ирек бирмәбез. *(Олавызга дәшә.)* Кулларын артка каерып тот әле шуның.

Олавыз. Тотарга дисәң — тотам. Сытарга дисәң — сытам.

Яшь шүрәленең кулларын каера. Аңа Сөрмәкүз белән Купшыбикә каршы төшмәкче була, ләкин аларны Мүкләкҗан читкә этеп җибәрә.

Мүкләкҗан *(Яшь шүрәлегә күрсәтеп).* Аяк-кулларын каерып агачка бәйлә, Олавыз. Хәзер аның авызына сасы су коябыз.

Мүкләкҗан белән Гөлҗамал Яшь шүрәлегә аракы эчерәләр.

Мүкләкҗан. Хәзер моны чишәргә дә мөмкин. Бу кеше булды! *(Бауларын чишәләр.)*

Гөлҗамал *(хатын-кыз шүрәлегә).* Нәрсә, әллә сез генә шүрәле булып калмакчымы? Юк, без сезне дә кеше итәбез. Бөтенегездән кеше ясап бетермичә туктамыйбыз.

Һәрбарчасы бергәләп ташланып Сөрмәкүз белән Купшыбикәне эләктерәләр. Аларга да көчләп аракы эчерәләр. Урманда пәри туе башлана. Бииләр, җырлыйлар, котыралар. Гөлҗамалны Олавыз урман эченәрәк өстери.

Олавыз. Әйдә, теге сары тимерләрне мин сиңа теләгән кадәр бирәм. Тик минем белән бер кети-мети уйнап ал.

Гөлҗамал. Әйдә, матурым, әйдә. Сары тимер өчен кети-мети генә түгел, әллә ниләр уйнарга әзер мин.

Китә башлыйлар. Аларны Мүкләкҗан күреп, юлларына аркылы төшә.

Мүкләкҗан. Туктагыз, юкса икегезне дә үтерәм.

Шешә күтәреп килә башлый. Олавыз аның кулыннан шешәсен тартып ала.

Олавыз. Җитте. Гөлҗамалга бүтән кагыласы булма.

Мүкләкҗан. Ә-ә, шулаймы?

Үзара сугыша башлыйлар. Сөрмәкүз, Купшыбикә, Яшь шүрәле —һәммәсе төрлечә котыра. Ата — улны, ана кызны белмәслек хәлгә җитәләр. Шул вакыт кинәт күк күкри, яшен яшьни. Шүрәлеләр сискәнеп туктап калалар. Ешкынлыклар арасыннан кулына яшен чыбыркысын тотып Урман иясе килеп чыга.

Урман иясе. Әй, сез, балаларым минем, нишлисез? Туктатыгыз хәзер үк бу мәхшәрне!

Шүрәлеләр ишетмиләр. Алар бер-берсенең әллә кай җирләрен чеметәләр, егалар, бер-берләренең өсләренә атланалар. Болар котырганда каяндыр иләмсез музыка тавышлары яңгырап тора. Музыка әлеге тавышларны тагы да көчәйтә.

Урман иясе. Балаларым, аңыгызга килегез.

Ишетүче булмагач, Урман иясе кулындагы яшен чыбыркысын берничә мәртәбә шартлатып ала. Шуннан соң гына алан тына. Шүрәлеләр, Урман иясен күреп, куркудан айнып китәләр. «Хуҗабыз», «Урман иясе» дигән тавышлар ишетелә. Урман иясе, тынлыктан файдаланып, сүз башлый.

Урман иясе. Йә, кайсыгыз әйтә, бу нинди мәхшәр? Ни күреп акылдан язасыз?
Мүкләкҗан. Без шүрәлелегебездән ваз кичеп, кешегә әверелергә маташабыз.
Урман иясе. Йа Аллам! Йә Тәңрем! Нәрсә ишетә минем колакларым?!
Сөрмәкүз *(боргаланып)*. Ә нигә, Хуҗабыз, кеше булу начармыни?
Купшыбикә. Әйе, без кеше булуның иң беренче шартын үтәдек инде.
Урман иясе. Нинди шарт ул?
Олавыз. Менә, Хуҗабыз, шушы кайнар суны эчкән һәрбер җан иясе кешегә әйләнә.

Урман иясе шешәне алып исни дә агачка бәрә.

Урман иясе. Беләсезме, балаларым, Тәңре сезне кем итеп яраткан?
Тавышлар. Шүрәле итеп.
Урман иясе. Әйе, шүрәле итеп. Сезнең төп асылыгыз шүрәле булу. Ә шүрәлеләр урманның мәңгелек сере, мәңгелек әкияте. Сез шул мәңгелек сер, мәңгелек әкият булуыгыз белән матур. Кешеләр болай да бөтен нәрсәне үзләренчә итәргә тырышалар. Аюларны тотып кулга ияләштерәләр. Бүреләрдән ау эте ясыйлар. Буйсынмаганнарны аталар, кыралар. Сез үз иркегез белән шуларга охшарга телисезме? Алар безнең эчәр суларыбызны, яшәр урманнарыбызны корытып киләләр. Дөньяда үз асылыңны югалтудан да зуррак түбәнлек бармы?

Шүрәлеләр башларын түбән ияләр.

Урман иясе. Тәңре сезне шүрәле итеп яраткан икән инде — үлгәнче шүрәле булып калыгыз. Юкса сезгә Тәңренең олы каргышы төшәчәк.

Шүрәлеләр шаулаша башлыйлар.

Сөрмәкүз. Мүкләкҗаннан да бигрәк менә бусы явыз. *(Гөлҗамалга күрсәтә.)*
Купшыбикә. Аны урманнан кумый торып, безгә тынычлык булмаячак.
Тавышлар. Куарга, куарга!
Олавыз *(моңсу карап)*. Бәлки, Мүкләкҗанны гына куаргадыр?
Купшыбикә. Юк, монысын куарга. Мүкләкҗан үз шүрәлебез әле ул.
Гөлҗамал. Кумасагыз да китәм, сезнең ише урман сарыклары янында ни кызык бар миңа? Мин сездән аласын алдым инде.

Сумкасына алтыннар, акча һәм аракылар тутырып китә башлый. Яшь шүрәле аның сумкасын тартып ала. Аракыларны берәм-берәм сумкадан тартып чыгара.

Яшь шүрәле. Боларны нишләтәбез?
Тавышлар. Бәреп ватарга! Ватарга!
Урман иясе. Дөрес. Юкса алар тагын әллә кемнәрне аздырырлар.

Шүрәлеләр берәм-берәм шешәләрне агачка бәреп ваталар. Һәрберсе шуннан зур канәгатьлек ала.

Гөлҗамал. Алар сезнеке түгел, ватарга хакыгыз юк.
Яшь шүрәле *(аның сумкасындагы алтыннарга күрсәтә)*. Болар да бит синеке түгел, нигә алып китәсең?
Сөрмәкүз. Алып калырга бөтен нәрсәсен!

Шүрәлеләр сумканы пыр туздыралар.

Урман иясе. Туктагыз, балаларым. Алмагыз. Киресенчә, барлык елтыравык ташларыгызны, алтыннарыгызны аңа бирегез. Алар бары тик ызгыштыра гына. Кешеләр кебек сез да аларга табына башласагыз, сезнең шүрәлелегегездән ни калыр? Шүрәлеләр арасында хөсетлек, малга табыну, алдашу кебек нәрсәләр булмады һәм булмас та. Ягез, нинди ялтыравык таш бар — бөтенесен Гөлҗамалга китерегез.

Шүрәлеләр Гөлҗамалның сумкасына кыйммәтле ташлар, алтыннар тутыралар.

Урман иясе *(Гөлҗамалга).* Ә хәзер монда эзең булмасын.

Гөлҗамал. И аңгыра сарыклар! Моның кадәр байлык белән мине дөньяның асыл егетләре кулда гына йөртәчәк.

Урман иясе. Рәхәтен күр, гомер буе кулдан кулга йөр.

Гөлҗамал китә.

Мүкләкҗан *(мескен тавыш белән).* Гөлҗамал, мине дә калдырма. Мин монда нишлим?

Гөлҗамал. Теләсәң нишлә. *(Китә.)*

Мүкләкҗан аңа иярмәкче була, ләкин Яшь шүрәле аны тотып кала.

Яшь шүрәле. Синең әле ырубаш үлеме өчен җавап бирәсең бар.

Урман иясе. Ырубаш? Чынлап та, кая соң әле ул?

Олавыз. Әнә ята. Менә бу үтерде аны. *(Мүкләкҗанга күрсәтә.)*

Урман иясе ырубаш янына бара. Башын үзенең тезенә сала. Нindидер яфрак өзеп, Карт шүрәленең маңгаена куя. Шунда ырубаш күзләрен ача.

Шүрәлеләр. Үлмәгән, ул исән! Безнең башлыгыбыз исән! *(Сикерешәләр.)*

Карт шүрәле *(як-ягына карана).* Мин кайда, ни булды миңа?

Урман иясе. Синең ыруыңа яманлык килеп кергән. Син шул яманлыкның корбаны була яздың.

Ул торып баса. Барыгыз да исән-саумы дигәндәй, шүрәлеләргә карый.
Карашы Мүкләкҗанда туктала.

Карт шүрәле. Явызлыкны алып килүче менә бу!

Мүкләкҗан. Мине авылга үзегез җибәрдегез. Кешеләрне өйрәнергә куштыгыз. Мин кушканны гына үтәдем.

Карт шүрәле. Юк, син кушканны гына үтәмәдең. Кемне дә булса өйрәнү әле ул алар төсле булу дигән сүз түгел.

Яшь шүрәле. Мүкләкҗан иң каты җәзага лаек. Ул үзе өйрәнеп кайткан бозыклыкны безгә дә йоктырырга теләде.

Урман иясе. Үзең начарлык эшләү — бер гөнаһ, шуны башкаларга йоктыру — мең гөнаһ. Моның өчен җәзаның зуры тиешле.

Сөрмәкүз. Әйе, хак әйттегез, Хуҗабыз.

Купшыбикә. Ул азгынлыкның чигенә чыгып кайткан.

Олавыз. Шушы олы авызымны тутырып сасы су эчерде ул. Корсагыма ут капты дип торам.

Карт шүрәле. Әйе, мондый эшне җәзасыз калдырырга ярамый. Юкса яманлык һәрберебезгә йогар. Йә, нинди җәза бирәбез Мүкләкҗанга?

Олавыз. Кешеләр янына җибәрергә кирәк. Теге сасы суны эчеп тончыксын шунда.

Купшыбикә. Бу аңа җәза түгел, бүләк кенә булачак. Чөнки аның Гөлҗамалы шунда. Кешеләр арасында кеше булып йөрер.

Карт шүрәле. Юк, дөрес әйтмисең, карендәшем, кешеләр аны үз араларына кертмәячәк. Керткән очракта да, «менә без нинди акыллы, син аңгыра» дип көләр өчен генә кертәчәкләр. Чөнки үз йөзен югалткан зат башкаларның начар якларын гына үзләштерә. Аңа һәркем җирәнеп карый.

Яшь шүрәле. Нәрсә, кешеләр арасына җибәрәбезме?

Карт шүрәле. Юк, мин алай дип әйтмәдем. Җәзаны сез үзегез табыгыз.

Шүрәлеләр бер-берләренә карашып, шаулашып алалар.

Урман иясе. Мүкләкҗанның үзеннән сорыйк әле: ул үзенең начарлык эшләвен аңлады микән?

Карт шүрәле. Үзеңне яклап ни әйтә аласың, Мүкләкҗан?

Мүкләкҗан. Ни әйтә аламмы? Менә нәрсә, ырудашларым. Мин гаепле. Нигә дисәң, кешеләр янына бару белән мин шүрәле икәнемне онытырга тырыштым. Тизрәк алар төсле буласым килде. Минем хәтта урманга кайтмаска уйлаган чакларым да булды. Сез белмисез әле: бозыклыктан тыелып калу авыр. Чөнки ул йә Гөлҗамал кебек йомшак тәнле, кайнар назлы булып муеныңа урала, яки тәмле ризык, йә баш әйләндергеч эчемлек булып нәфесне котырта. Мин менә хәзер сезнең алда телем белән тәүбә итәм, ә күңелем шул азгынлыкларны тели. Мин ул яманлыкларны яңадан эшләмәм дип сүз бирә алмыйм. Мине теләсәгез ни эшләтегез.

Урман иясе. Дөресен сөйләвең өчен рәхмәт. Инде менә тагын бер сорауга җавап бир. Бәлки, кан кардәшләреңнең дә аңа җавап ишетәселәре киләдер.

Мүкләкҗан. Сорагыз, хуҗабыз.

Урман иясе. Ни өчен син башка шүрәлеләрне аздыра башладың?

Мүкләкҗан *(уйланып).* Кызык өчен. Юләрлекне күзәтү кызык бит. Аннары шунысы бар: кешеләр үзләре түбән төшсәләр, артларыннан бүтәннәрне дә ияртергә тырышалар. Мин дә аларга охшарга тырыштым. Ни өчен алар миннән әйбәт булырга тиеш?

Урман иясе. Түбәннәр фәлсәфәсе. Йә, балалар, нинди җәза бирәбез моңа?

Яшь шүрәле. Аяк-кулларын бәйләп упкынга ыргытырга.

Сөрмәкүз. Суга ыргытыйк. Агып китсен бездән еракка.

Карт шүрәле. Ярамый, суны пычратыр. Елганың түбән ягында яшәүчеләр безгә ләгънәт укыр.

Олавыз. Утка салыйк.

Карт шүрәле. Юк, безгә рәнҗеп, бердәнбер учагыбыз сүнәр. Ә безгә утны сүндерергә ярамый.

Яшь шүрәле. Үлем җәзасына хөкем итик.

Карт шүрәле. Безнең кавем болай да әз калып бара. Үз кулларыбыз белән кан кардәшебезне үтерү шүрәлеләр өчен зур гөнаһ.

Купшыбикә. Бәлки, хәтерен алыргадыр? Шунда ул явызлыгын да онытыр.

Карт шүрәле. Юк, безгә хәтерсез шүрәлеләр кирәкми. Юкса ул үзенең шүрәле икәнен онытачак.

Купшыбикә. Бәлки, ул төзәлер.

Мүкләкҗан. Юк, төзәлә алмам. Кулларымны бәйләсәгез — күзләрем, күзләремне бәйләсәгез — телем кала. Йә карашым, йә телем, йә күңелем белән барыбер начарлык эшләрмен.

Карт шүрәле. Ай-яй, ничек бозганнар сине кешеләр! Явызлык йогышлы чир икән шул. Үз арабызда калдырсак, бу чирне син башкаларга да йоктырачаксың.

Урман иясе. Әйе, күңелгә бер иблис керсә, аны куып чыгару кыен. Без болай итик, балаларым. *(Бар да аңа өмет белән карый.)* Без аны каргыйк!

Тавышлар. Ничек?!

Урман иясе. Үзегез беләсез, шүрәлеләрнең каргышы төшүчән. Мүкләкҗан кая гына барса да, куылуга дучар булсын. Аюлар янына барса — аюлар, бүреләр янына барса — бүреләр, кешеләр янына барса — кешеләр кусын. Беркайда да аны үз итмәсеннәр.

Купшыбикә. Бигрәк каты җәза уйлап таптың бит, урман иясе хуҗабыз.

Урман иясе. Үз кавеменә хыянәт итеп, башка затка әйләнү — иң зур җәзага лаек. Йә, әллә шулай түгелме?

Тавышлар. Шулай, шулай!

Урман иясе. Алайса килештек. Мүкләкҗанны бергәләп каргыйбыз. Күңелендә бер очкын кадәр дә явызлык калмагач кына сез аны үз арагызга яңадан алырсыз, ә хәзер башладык.

Урман иясе алдан әйтә, бүтәннәр аның артыннан кабатлый.

Күккә менсәң — күктән куыл,
Җиргә төшсәң — җирдән куыл,
Җилләр белән җилгәрел дә
Яңгырларда калып юыл.

Урман иясе кинәт үзенең яшен камчысын шартлата. Күк күкри, яшен яшьни.

Урман иясе *(Мүкләкҗанга).* Бар, гөнаһларыңнан чистарына алсаң, әйләнеп кайтырсың. *(Тагын чыбыркысын шартлата.)*

Күкрәү астында пәрдә төшә.
Пәрдә алдына Алып баручы шүрәле чыгып баса.

Алып баручы шүрәле.

Менә бетте безнең әкиятебез,
Без китәбез инде урманга.

Карурманда яңа әкият туар,
Без яшәрбез әкият булганда.

Әкият булсын, карурманнар булсын,
Шүрәлеләр булсын һәрвакыт.
Очар кошлар гөлдән гөлгә кунып,
Җиргә әкият йөрсен таратып.

Әкият туа җиргә гыйбрәт өчен,
Гыйбрәтләре аның тирәндә.
Дөнья серен һәркем гомер буе
Шул гыйбрәтләр аша өйрәнә.

Карурманда яңа әкият тугач,
Без килербез, көтеп яшәгез.
Безне хәзер урманыбыз көтә,
Сезнең белән саубуллашабыз.
Хушыгыз!

Пәрдә.

*1991—1993*

# КОЙРЫКСЫЗ САНДУГАЧ

*(Ике пәрдәле комедия)*

**КАТНАШАЛАР:**

Лилия — сатучы хатын, 38—40 яшьләрдә.
Ләйсән — аның кызы, 18 яшьтә.
Карчык — 65—70 яшьләрдә.
Илгизәр — 45—48 яшьләрдә.
Риза — яшь егет.
Шәфкать туташы.

Вакыйга төзелеп килүче яңа шәһәрдә, безнең көннәрдә бара.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шәһәр читенәрәк салынган кечкенә кибет. Пәрдә ачылганда, Лилия авыз эченнән ниндидер көй көйләп, прилавкаларын тәртипкә китерә:

киштәләргә консервалар тезә.

Лилия. Әллә кайдагы җәһәннәм тишегенә китереп тыктылар, хәзер үтә инде планны. Нәрсә белән диген әле? Шушы калай кәнсирбеләр белән бит. Кемгә кирәксен ул черегән балык. Эт тә ашамый бит аны. Их, бар иде заманалар, әйбердән киштәләр сыгылып тора иде. Хәзер бездән тычканнар да качып бетте. Кәнсирбе кимерми шул алар. *(Тирән итеп көрсенә.)* Юк инде, юк, үтте заманалар. Ичмасам, талашыр кеше дә юк. Китерәсе иде шушында безнең авылның пырылдык Мәхтүмәсен. «Бөтен нәрсәне итәк астыннан сатып ятасың», — дип пырылдап торсын иде. Монда хәзер итәк асты да шәрәләнеп бара. Их! *(Тагын көрсенә.)*

Илгизәр керә. Ул төз гәүдәле, интеллигент кыяфәтле.

Илгизәр. Керергә рөхсәтме?

Лилия.Рөхсәт булмыйча! Начальник кабинеты түгел бу, кибет.

Илгизәр. Нәкъ менә шул кибет булганга да теләсә кемгә ишеге ачылырга тиеш түгел аның.

Лилия *(сөйләшәсе килмичәрәк).* Ишеген ачмый гына сатарга өйрәнмәгән әле без.

Илгизәр. Әйе, күренеп тора: күп нәрсәне белмисез әле сез. Кибет ишеге ул — оҗмах ишеге. Ә

оҗмах ишеге һәркемгә дә ачылырга тиеш түгел.

Лилия. Туктале, син кем соң? Нишләш әле минем колак төбендә чикерткәдәй сайрыйсың?

Илгизәр. Чикерткә түгел мин, ханым. Сандугач! Ә сез кем?

Лилия *(көлеп).* Сандугач? Мин — Лилия.

Илгизәр. Әйе, Лилия. Кунарга гөл эзләүче сандугач.

Лилия. Сандугачның шундые да буламыни?

Илгизәр. Нindie?

Лилия *(башына сугып ала, Илгизәрнең пеләшенә ишарәли).* Менә мондые.

Илгизәр. Сандугачлар бик күп төрле була. Без аларны белеп кенә бетермибез. Чөнки алар чыпчык кебек өй кыегына ояламыйлар. Аларның оялары кеше күзеннән яшерен була.

Лилия. Кызык.

Илгизәр. Әйе, кызык. Сандугач горур кош. Аның бөтен тормышы серле.

Лилия. Тормыш анысы барыбызныкы да серле. Беркемнең дә күргәннәре маңгаена язылып куелмаган.

Илгизәр. Шулай, Лилия. Бик дөрес әйтәсез. Тормыш серле һәм әнә шул серле булуы белән матур да. Кешеләр бер-берләренең матурлыкларын яши-яши ачарга тиешләр. Менә сез үзегез кем? Гади бер сатучы гынамы? Юк! Һәм мең тапкыр юк. Сезнең күңелегез тулы сер. *(Лилия нидер әйтмәкче була, ләкин Илгизәр аны туктата.)* Юк, сөйләмәгез. Мин сезне үзем ачарга тиеш. Үзең ачкан дөнья кызыклырак була.

Лилия. Ачарга? Мин сандык мәллә?

Илгизәр. Сандык кынамы соң. Хатын-кызлар җир астында ятучы алтын, ә ирләр шул алтынны эзләүче геологлар.

Лилия. Әт-тәт-әт, кызык бу! *(Үз-үзенә.)* Пырылдык Мәхтүмәдән кызыграк булырга охшый әле бу абзый. *(Илгизәргә.)* Шул алтынны күптәннән эзлисеңме?

Илгизәр. Гомерем буе.

Лилия. Алайса, алтының бер капчыктыр.

Илгизәр. Иң кызыгы да шунда шул: аны җиде кат җир астыннан табып алып уч төбеңә саласың да бер сокланасың. Ә аннары...

Лилия. Ә аннары нәрсә?

Илгизәр. Аннары соклануың үтә. Ул салкын тимергә әйләнә.

Лилия *(уйланып тора).* Алайса, син, абзый кеше, рәтле бәндә түгелдерсең. Җүнле кеше кулында алтын тимергә әйләнмәс.

Илгизәр. Иң аянычы шунда, ханым, безнең алтын дигәнебез кайвакыт ялган алтын булып чыга. Ә дөньяда иң кыен нәрсә — ялганны чыннан аеру.

Лилия. Аракыга кушылган су кебегрәк икән. Чаманы югалтсаң гына сизәләр.

Илгизәр. Су кушылган аракыны алкаш та аера. Әмма кеше катлаулырак, кеше серлерәк.

Лилия. Әллә ниләр белән башымны катырма әле. Бәлки, мин артык серлеләрдән куркамдыр.

Илгизәр. Менә-менә, куркабыз шул. Безгә барысы да ташка басылгандай ачык булсын. Шул вакытта гына курыкмыйбыз. Безгә, ханым, артык гадилектән, артык примитивлыктан куркырга кирәк.

Лилия *(кул селтәп).* Тәмам каркылдадың. Сиңа нәрсә кирәк?

Илгизәр. Миңа кирәк нәрсә сезнең кибеттә бердәнбер экземплярда булырга охшый.

Лилия. Аракымы? Юк. Сандугач булып сайрамагаең, карга булып кычкырсаң да юк ул безнең кибеттә. Үт-үт андый вакытлар.

Илгизәр*(көлә).* Ха-ха-ха! Сез, ханым, үз эшегезне яхшы беләсездер, әмма күңелегезгә авыр алмагыз: сез психолог түгел. Йә, ныклабрак карагыз әле миңа: охшаганмынмы мин эчә торган кешегә?

Лилия. Эчә торган кешеләр дә мөгезле булмыйлар. *(Кулын селти.)* Күргән бар: сандугач булып сайраучысын да, эт булып өрүчесен дә. Хәтта дуңгыз булып мыркылдаучысын да.

Илгизәр. Юк, ханым, эчмим мин. Миңа дөнья болай да бик матур. Дөньяның матурлыкларын ачарга да ачарга кирәк әле.

Лилия. Алайса, нигә соң аны кибеттән эзлисең? Кибетләр хәзер ыштансыз малай кебек шәп-шәрә.

Илгизәр. Кемнең өлешенә тигән көмеше кайда ята бит.

Лилия. Монда килеп чыгуың да өлешеңә тиячәкне эзләүме?

Илгизәр. Әйе, Лилия җаным. Зур төзелешләрдә зур язмышлар языла. Берәүләр анда романтикага сусаган күңелләрен басарга килә, ә икенчеләр...

Лилия. Башлагач әйтеп бетер инде. Сүзнең тизрәк ахырын ишетмәсәм, бавырым чәнчә башлый.

Кибеткә Карчык керә. Илгизәр аны күрүгә үк тәрәзә янынарак китә.
Карчык таяк башына элгән төенчеген прилавка өстенә ташлый.

Карчык. Уф! Килә-килә хәлләрем бетте. Шәһәр димәсәң, хәтере калыр: ни трамбае юк, ни автабусы җөрми.

Лилия. Нәрсә кирәк, әби?

Карчык. Тукта, әзрәк суларга ирек бир. Милициядә дә килеп керү белән сораша башламыйлар.

Лилия. Милициядә булганың бармыни?

Карчык. Аллага шөкер, булмаган җирләрне дә беләбез без хәзер. Тилибизырыбыз бөтен дөньяны күрсәтеп тора. Әле кичәгенәк милиция турында бер кина карадым. Бигрәкләр дә әйбәт икән ул милиция дигәннәре. Утыр, әбекәй, дип урындык сузып торалар, мин сиңа әйтим.

Карчык белән Лилия сөйләшеп торган арада, сиздерми генә Илгизәр чыгып китә. Аның чыгып киткәнен беркем дә абайламый.

Лилия. Милиция ул, әйдә, утыр-утыр дип әйтә дә утырта да куя. Аның эше шул.

Карчык *(аның кинаясен аңламыйча).* Бар җирдә дә утыртырга тормыйлар. Әле менә унбиш чакрым җирне автабуста басып килдем. Урын бирмисең дип тотып сүгәриең, яшьләрне картлардан аерып булмый: барысы да сакаллы хәзер.

Лилия. Берәр әйбер аласыңмы, әби, юкмы?

Карчык. Алам, алам. Сездә индийски чәй бар дигәннәрие. Дөресме?

Лилия. Син күктән төштеңме әллә? Һинд чәе эчәсең килсә, әнә шунда кит.

Карчык. Алайса, нинди чәй бар соң?

Лилия. Төрек чәе.

Карчык. Бер дә ишеткән нәрсәм түгел, әйбәт микән?

Лилия. Әйбәттер, беркемнең дә төрек чәеннән катканын ишеткәнем юк әле.

Карчык. Алай бик мактагач, әллә алыйм микән?

Лилия. Ал, ал! Күпме кирәк?

Карчык. Күпмени?

Лилия. Сиңа җитәрлек.

Карчык. Алай күп булгач, җүнле нәрсә түгелдер, алмыйм. Беркөн Мәфтүхә ахири сөйләп утырганые аны. Хәзер, ди, әллә нинди атомлы чәй чыга икән, ди. Казан каласында шул атомлы чәй эчеп халык чебен урынына кырыла, дигәние.

Лилия *(читкә карап).* Кырырсың сезне. Чәй генә түгел, атом бомбасыннан да калырсыз әле сез. Дөньяда иң соңгы җан ияләре булып колорад коңгызы белән шушындый убырлы карчыклар гына калыр, мөгаен. *(Карчыкка карап.)* Йә, аласыңмы, юкмы берәр нәрсә?

Карчык *(уйланып).* Ниләр аласым барые соң әле? Ай, бу карт хәтерне! Ә-ә, Зөлхәбирә ахирәт оныкларыма лампачый апкайт дигәние. Лампачыйларың бармы?

Лилия. Бар. *(Ике савыт ыргыта.)*

Карчык *(аларны кулына алып).* Менә монысының савыты яньчелгән икән. Алыштырып кына бирче.

Лилия. Савытын ашамассың әле.

Карчык. Хикмәт ашаудамыни? Бала-чагага синең кәнфитеңнән бигрәк савыты матур булсын. Алар бит шуның белән уйныйлар.

Лилия. Уенчык кирәк булса — уенчык кибетенә бар.

Карчык *(аның тупаслыгына игътибар итмичә).* Уенчык кибетенә дә барырбыз, Алла боерса. Шәһәргә гел килеп торып булмый.

Лилия. Йә, тагын ни кирәк?

Карчык. Тагынмы? Тагын ни кирәк иде соң әле миңа? Әй бу тишек хәтерне! Онытып җибәрдем бит.

Лилия. Онытсаң, исеңә төшкәч килерсең.

Карчык. Шулай итәргә булыр инде. *(Ишеккә таба бара башлый да исенә төшеп туктала.)* Ә-ә, ни бит, Әсмабикә ахирәт солы прәнниген бик ярата торганые. Булса, шуны үлчәп бир әле, кызым. Шатландырыйм Әсмабикә ахирәтне.

Лилия. Солы сезнең кебек тешсез карчыкларга түгел, атларга да калмады хәзер. Һы, солы прәнниге кирәк булган аңа.

Карчык. Нәрсә, солы прәнниге дә юкмыни?

Лилия. Татарча әйтеп торам лабаса.

Карчык. Ярый инде алайса, хәерле булсын. *(Чыга башлый. Ишек турысына җиткәч борыла.)* Ә сиңа, кызым, докторга күренергә кирәк.

Лилия. Нәрсә? Нәрсә?

Карчык. Врачка барып эчеңдәге ачу ташыңны алдырырга кирәк, дим. *(Чыгып китә.)*

Лилия. Әй карт убыр. Шушы авыл карчыкларыннан мәңге котылырмын димә. Авылда ирләрне аздырып ятасың дип теңкәгә тияләр иде. Инде монда килеп җиткәннәр.

Карчык чыгып китүгә, Илгизәр кире Лилия янына керә.

Илгизәр. Сүзне бүлдереп йөри, убырлы карчык.

Лилия. Нәрсә, син аны күрү белән милиция күргән шыпанадай читкә тайдың?

Илгизәр. Яратмыйм мин карт-корыны.

Лилия. Аларны кем яратсын. Сөйләнеп буынга төшәләр. Солы прәнниге кирәк булган, һинд чәе эчәсе килгән аның. *(Усалланып көлә.)* Төрек чәе эчен тишәр дип куркамы.

Илгизәр. Менә-менә, Лилия ханым. Сез менә шушында ялгыштыгыз да. Сез аңарга күпме кирәк, дидегез. Күпме кирәк диделәрме, димәк, әйбереӊ күп дигән сүз.

Лилия. Акыл өйрәтеп маташмасана.

Илгизәр. Сез сатучы кеше, Лилия ханым, моны белергә тиеш. Кешеләргә сез һәрвакыт, бусы соӊгысы иде, сиӊа якын итеп кенә бирәм диегез. Үзеӊә рәхмәт кенә әйтәчәкләр.

Лилия. Кирәк кеше алай боргаламасаӊ да ала. Алмасалар да бик исем китми, үз әйберем түгел.

Илгизәр. Анысы шулай, Лилия ханым, ләкин сатып алучыларның психологиясен белү зарар итми.

Лилия. Мин андый песи-месиләрне укымадым шул.

Илгизәр.Сатучы өчен бик кирәк нәрсә ул. Шунсыз яшәп булмый. Хәзерге заманда бигрәк тә.

Лилия. Хәзерге заман нинди соӊ ул?

Илгизәр. Нindиме? Бик катлаулы ул хәзерге заман. Күзеӊә карап кесәӊдәгене күрәләр.

Лилия. Әстәгыфирулла! Әллә ниләр сөйлисеӊ син, абзый кеше. Әллә соӊ син берәр шпионмы?

Илгизәр. Шпионнан болайрагы.

Лилия *(пышылдауга күчеп).* ОБХССмы әллә?

Илгизәр. Тсс! Ханым, андый сүзләр сөйләшмик. Мин бары тик кешеләр күӊелен өйрәнүче бер психолог кына. Таныш булыйк — Илгизәр.

Лилия. Теләсә нинди илгизәр белән танышырга кем дип беләсеӊ мине?

Илгизәр. Сезне бер тол хатын дип беләм, ханым. Тагын шунысын да әйтә алам: сез Ык ягыннан.

Лилия *(тагын аптырап).* Каян белдеӊ?

Илгизәр. Монысы инде минем серем.

Лилия. И Ходаем, әллә нинди кешеләр бар икән дөньяда. Шуның кебек песи-меси гыйлемнәрен белсәӊ иде. *(Илгизәргә.)* Абый, син алай бик күпне белгәч, бәлки, миӊа ничек план тутырырга да өйрәтерсеӊ? Юкса директор куып чыгару белән куркыта.

Илгизәр. Куркыта диген, ә? *(Кәефләнеп.)* Ә план тутыруның юллары күп инде аның, ханым.

Лилия. Йә, йә?

Илгизәр. Бая әйтә башладым бит. Сез бөтен байлыгыгызны бервакытта да берьюлы ачып салмагыз. Кайчакларда алгы ишекне ябып, арткысын ачкалагыз. Кешеләр сезнеӊ кибеттә ни барлыгын белә алмый җәфа чиксеннәр. Кешене шул хәлгә куярга кирәк: синеӊ кибетеӊнән әйбер ала алган кеше үзен бәхетле санарлык булсын. Аннары елмаю дигән нәрсәне дә онытып җибәрмәскә кирәк, ханым. Сатучының елмаюы — акча ул.

Лилия. Алучының ике тиене дә юклыгын белә торып елмаерга әле... Их, үзгәрде халык.

Илгизәр. Әйе, заманалар үзгәрде. Менә үзем дә үзгәреп баручы заманның үзгәргән бер баласы.

Лилия. Кит аннан? Үзгәргән кешене беренче күрүем. Менә мин үзгәрә дә, тизләнә дә алмыйм. Һаман әйбәтрәк нәрсәләрне үземә күбрәк аласым яки, һичьюгы, берәр файдалырак кешегә бирәсем килә. Тизлегемнеӊ дә артканы юк. Өйдән кибеткә элек ничә минут килгән булсам, әле дә шулай киләм.

Илгизәр. Алай гадиләштерергә ярамый, ханым. Дөньяда бик катлаулы процесс бара...

Лилия. Син әллә нинди просесларыӊ белән минем башымны катырма, бик акыллы булсаӊ, шуны әйт: элек нинди идеӊ дә хәзер нинди булдыӊ?

Илгизәр. Яратам менә шулай маӊгайга бәреп әйткән кешене. Күӊелләре садә кешеләр генә турысын ярып сала алалар. Менә сез: «Элек нинди идеӊ дә хәзер нинди булдыӊ», — дип сорау бирдегез. Элек мин сукыр идем...

Лилия *(аның сүзләреннән куркып).* Әстәгыфирулла, сукыр идем дисеӊме?

Илгизәр. Курыкмагыз, Лилия ханым, туры мәгънәдә түгел. Үземдәге кимчелекләрне күрә белми идем, сукырлыгым шунда иде. Ә күрмәгәч төзәтеп булмый.

Лилия. Ирләр эчсәләр, берни күрми торганга әйләнә шул. *(Көрсенеп куя.)* Эчеп алдылармы — хатынын да күрми, балаларын да. Син дә шул шешәдән башка нәрсә күрми башлаган булгансыӊдыр.

Илгизәр. Яшермим, андый гөнаһым да булды.

Лилия. Әллә бөтенләй эчмисеӊме хәзер?

Илгизәр. Тамчы да.

Лилия. Шулайдыр дип уйлаган идем аны.

Илгизәр. Нәрсәдән чыгып?

Лилия. Телеӊ бик шома. Эчкән кеше бит ул аракы белән телен дә йота. Андыйларның сандугач булып сайрарлыгы түгел, күке булып күкелдәрлек рәтләре дә калмый.

Илгизәр. Менә, менә! Сез дә психолог икәнсез. Без, ике психолог, бәлки әле, килешербез дә. *(Тәрәзә аша кемнедер күреп ала да чыгарга җыена.)* Хушыгыз!

Лилия. Хуш, хуш! Алдыӊнан артыӊ яхшы. *(Уйланып.)* Ә шулай да бу бөтенләй буш бәндә түгел

бугай. *(Күңеле булып.)* Миңа да нинди матур итеп «Лилия ханым» дип тора. Их, дөньясын эт алгыры! Шундый культурный ир белән яшәргә насыйп булмады. Ә бәлки... *(Сәгатенә карап куя.)* Кибетне әбиткә ябарга да вакыт җиткән. План тутырам дип ач утырып булмас.

«Обед» дигән язуны кибет ишегенә элә дә эчкә кереп китә.

Пәрдә.

**ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Лилияләр өе. Зур, яңа өй. Җиһазлар төрлечәрәк, хуҗабикәнең бик үк зәвыклы түгеллеген күрсәтеп тора. Пәрдә ачылганда, Лилиянең кызы Ләйсән магнитофон «колагын» боргалап утыра. Аннан әллә нинди ачы тавышлар ишетелә, дөпе-дөпе каккан барабан тавышлары яңгырый. Кыз магнитофоны белән мавыгып утырганда, ашыгып Риза керә.
Аның нәрсәдәндер тәэсирләнгәне күренеп тора.

Риза. Ләйсән! Ләйсән, дим, киен тизрәк.
Ләйсән. Нәрсә, әллә берәр нәрсә янамы?
Риза. Яна, Ләйсән, яна.
Ләйсән. Янса, пожарник чакыр.
Риза. Менә шуңа дип килдем дә.

Ләйсән Ризаны беренче күргәндәй гаҗәпләнеп карап куя.

Ләйсән. Алайса, син адресны бутагансың, егетем.
Риза *(кыза башлап).* Ташла әле шул кылануыңны. Үзеңнең бит инде кызыксынудан эчең яна, үзең битараф булып кыланып маташасың.
Ләйсән *(кинәт артистлана башлап).* Ай, янам, үләм, коткарыгыз! *(Бөгелеп төшкән була.)*
Риза *(аның сүзләрен чынга ала, йөзендә борчылу).* Нәрсә, Ләйсән? Ни булды?
Ләйсән. Янам, бетәм. Кызыксыну уты эчемне яндыра. Уф! *(Бераз кылана да, Ризаның җитди кыяфәтен күреп, көлеп җибәрә.)* Соң, үзең әйттең бит, кызыксыну утыннан эчең янадыр, дип. Үлгәнче әйт инде: нәрсә яна?
Риза. Вагон.
Ләйсән. Вагон? Әллә миңа булган гыйшык утыннан йөрәгең янамы дигән идем. Вагон да булдымы әйбер.
Риза. Йөрәк турында әйтеп торасы юк инде.
Ләйсән. Билгеле бит инде Ходайгамы?
Риза. Ходайга да, сиңа да билгеле. Мин чынлап әйтәм, Ләйсән. Безнең Хәйбулла абзыйга фатир бирәләр. Шуларның вагоны бушый. Начальниктан сораганыем: өйлән әле, өйләнгәч карарбыз, ди.
Ләйсән. Оһо, вагон! Ничек романтично! Элек гашыйклар шалашта яшәгәннәр, ә без вагонда. Ул вагонның паровозы бармы соң, Риза?
Риза *(үпкәләп).* Мин чынлап әйтәм, ә син шаяруга борасың.
Ләйсән. Ә минем шаярасым килә, Риза. Миңа бөтен нәрсә кызык.

Магнитофонны кабыза, анда ламбада көе яңгырый. Ләйсән бии. Риза аның биеп туктаганын көтеп тора. Ләйсән сулуы кабып биюдән туктый.

Риза *(кул чабып).* Браво, браво! Шәп биисең икән, Ләйсәнем. Айлы төннәрдә вагоныбыз түбәсенә менәрбез дә ламбада биербез.
Ләйсән. Биербез.
Риза. Бөтен шәһәр татлы йокысын бүлеп безгә карар.
Ләйсән. Безгә карар.
Риза. Шуның өчен, Ләйсәнем, вагонны алып калырга кирәк. Йә, киттекме?
Ләйсән. Ә мин бармыйм дисәм?
Риза. Нигә бармассың икән?
Ләйсән. Миңа паровоз кирәк дисәм?
Риза. Бармасаң, мин сине урлап китәм.
Ләйсән. Мин эт баласы түгел шул, куеныңа гына сыймам.
Риза. Сыйдырырбыз. *(Колачын җәеп Ләйсәнгә таба килә башлый. Ләйсән, ул килеп җиттем дигәндә генә, икенче якка тайпылып кала.)*

Алар шулай куышып йөриләр. Көлеш, шау-шу. Ләйсән Ризаның юлына йә берәр урындык этеп җибәрә, йә кинәт иелеп өстәл астына кача. Риза колачын җәеп Ләйсән артыннан чабып барганда, ишек ачылып китә дә аннан Лилия керә. Риза, тыелып кала алмыйча, аны кочагына ала.

Лилия *(Ризаның кочагыннан тартылып)*. Әстәгыфирулла, нәрсә бу? *(Этә.)*

Риза *(каушап кала, шул каушавы аркасында Лилияне ычкындырмаска да, ычкындырырга да белми тора. Бераздан гына һушына килә)*. Лилия апа, ни... гафу итегез...

Лилия *(аны этеп җибәрә)*. Оятсыз!

Ләйсән кулларын чәбәкли-чәбәкли көләргә тотына.

Лилия *(кызына ачуланып)*. Нәрсә кешнисең, әниеңне мыскыл итәләр, ә син ыржаясың.

Ләйсән *(шаяру тонында)*. Юк, әни, Ризаның нияте бик изге. Икегезнең берегезне алып китәм, дип йөри ул. Йә, кайсыбыз барабыз?

Риза *(Ләйсәнгә үпкәле дә, кисәтүле дә караш ташлап)*. Лилия апа, ни бит... *(Ни әйтергә белми тора да кулын селтәп куя.)* Мин чынлап апкитәм.

Лилия. Нәрсә авызыңда ботка пешерәсең? Кемне апкитәсең? Кая?

Риза. Болай да билгеле ич инде кая икәне.

Ләйсән *(җырлый)*. Сөясеңме дип ник сорыйсың?

Билгеле бит инде Ходайга.

Лилия *(ачуланып)*. Җитте, кәмит куймагыз. Мин сезгә бала-чага түгел.

Ләйсән *(ярым шаян тонда)*. Без кәмит уйнамыйбыз, әни. Әнә Риза әйтә...

Лилия. Риза, Риза дип, син аның һәр сүзенә риза булып утырасыңмы?

Ләйсән. Шулай тыңлаучан итеп үзең тәрбияләгәнсең мине, әни.

Риза. Ләйсән риза, Лилия апа. Без китәбез.

Лилия. И-и, хәсрәт капчыгы! Кая апкитмәкче буласың аны? Дүрт адәм янына, тулай тораккамы?

Риза. Өйләнгән кешеләргә бездә вагон бирәләр. Начальник әйтте...

Ләйсән. Менә, әни, нинди романтично булачак. Вагонда торачакбыз!

Лилия. Вагон, вагон, имеш. Тормышка чыгуны сәяхәткә бару дип белдеңме әллә?

Ләйсән. Ә нигә? Бер сәяхәт итеп кайтсаң да ярыйдыр. Икебезгә бер вагон бирәбез дип торганда.

Лилия. Кыланмагыз. Сезгә әле алышлы-бирешле уйнарга иртә.

Ләйсән. Иртәнге эш хәерлерәк, дигәннәр борынгы бабайлар. Бабайлар әйтсә, бик-бик хак әйтә, әни.

Лилия. Башымны катырма юк белән. Әле курчактан аерылганыңа кайчан гына.

Ләйсән. Тормыш ул күз ачып йому гына, дип әйткән ди бер акыллы кеше.

Риза. Лилия апа, без Ләйсән белән...

Лилия *(аны бүлдерә)*. Юк! Юк булгач юк!

Ләйсән. Мин Ризаны яратам.

Лилия. Йөзне яратырсың әле. Дөнья бу.

Ләйсән. Яратмам!

Лилия. Яратмасаң бигрәк әйбәт. Яратмаган кешеләр яратышканнардан шәбрәк яши.

Риза *(Ләйсәнне җитәкли)*. Әйдә, Ләйсән, киттек. Мин сине монда калдырмыйм.

Лилия *(араларына төшеп)*. Тукта, тукта! Кая болай куырасың? Әллә аны кәҗә бәкәе дип белдеңме, җитәкләп кенә апкитәргә.

Риза. Урамда такси тотарбыз.

Лилия. Таксиеңа утыр да үзең генә сыпырт, егеткәй. Йә ачуымны китерә башларсың.

Риза. Мин Ләйсәнсез беркая китмим. *(Урындыкка утыра.)*

Лилия. Китмәсәң, утыр шунда. Өйдә тычканнар күбәя башлады, шуларны куып утырырсың.

Риза. Барыбер Ләйсәнсез китмим.

Лилия. Әллә нинди вагонда аунар өчен кыз үстермәдем әле.

Ләйсән. Вагон ошамаса, өебез бар. Хәзер кияүләрне йортка кертү модада.

Лилия. Кыланма!

Ләйсән. Мин бик җитди, әни. Кияүне йортка кертсәң, ул икеләтә контроль астында була. Аннары инде аның койрыгы бозга ката.

Лилия. Әниегез алдында шундый сүзләр сөйләнергә иртәрәк әле сезгә.

Ләйсән. Ә беләсеңме, әни, бер бик-бик чибәр кыз булган, ди. *(Шаярып.)* Минем кебек. Менә шул чибәр кыз унҗиде яшендә үлеп гашыйк булган да кайтып әнисенә болай дигән: «Әнием-бәгърем, мин берәүне бик-бик яратам, аннан башка бер минут та яши алмыйм, ризалыгыңны бирче?» — дигән. «Нинди ризалык әле ул, — дигән әнисе, — синең институтта укып чыгасың бар». «Ә мәхәббәт?» — дигән кыз. «Мәхәббәтегез чын булса, ул еллар үткән саен ныгый гына», — дигән синең кебек акыллы ана.

Лилия. Шамакайланма!

Лэйсэн. Әле мин сөйләп бетермәдем. Әйе, шуннан менә минем сыман сүз тыңлаучан кыз әнисенә каршы килмәгән, институтны бетергән, һәм тагын көннәрдән бер көнне: «Инде, әнием, рөхсәтеңне бирәсеңме?» — дигән. Теге акыллы ана көрсенеп куйган да: «И кызым, кызым, — дигән, — әле аспирантура бетерәсең, кооператив квартирага языласың бар. Ә мәхәббәт өчен бер дә кайгырма. Чын мәхәббәт искерми ул, еллар үткән саен ныгый гына бара», — дигән. Тыңлаучан кыз тагын анасына каршы төшмәгән. Башта аспирантура бетергән, аннары кооператив фатир алып җибәргән. Ә мәхәббәтләре боларның чыннан да ныгыганнан ныгый барган. Ныгый торгач, шулчаклы ныгыган, ди, йөрәкләренә таш булып утырган ди хәтта.

Лилия. Көл, әниеңнән көл. Соңыннан еларлык булмасын.

Лэйсэн. Үзе егылган еламас, диләр.

Лилия. Егылганда барыбыз да үзебез егылабыз, торгызырга әниләр кирәк.

Лэйсэн. Ә без, әни, егылмас өчен бер-беребезгә ныграк тотынырбыз. *(Ризага «кыюрак бул» дигән кебек күз кыса.)* Шулаймы, кияү балакай?

Риза. Ул болай да билгеле инде.

Лэйсэн. Ишеттеңме, әни? Риза, «ул болай да билгеле» дип әйттеме, бетте дигән сүз. Димәк, шулай булачак. Риза әйткән сүзеннән кайта торган егет түгел.

Лилия. Риза да Риза дип син үзең әллә нәрсә маташтырып ятасың бугай.

Лэйсэн *(әнисенә сырпаланып).* Синең тәрбияң, әнием! Ир-атка юл куймаска, яратсаң — яратканыңны белгертмәскә, гел шикләнергә, түбәләренә туктаусыз суккалап торырга, сүз әйттермәскә...

Лилия *(ачуланып).* Җитте! Карап карарбыз, ике-өч елдан үзең дә шул ук җырны җырлый башламассың микән.

Лэйсэн. Алма агачыннан ерак төшми, дип әйткән ди элекке картлар.

Лилия *(өстәлгә сугып).* Үртәмә, мин сиңа бала-чага түгел.

Лэйсэн. Бетте-бетте, әнием-җаным. Бүтән авызны ачтым юк. Без китәбез. *(Ризаны җитәкли.)*

Лилия *(бөтенләй югалып кала).* Кая?

Лэйсэн. Әлегә киногa гына. Гуд бай! Ә син уйлый тор: ничек итеп акчаны күп чыгармый гына бөтен шәһәр шауларлык итеп туй уздырырга! Ярый, әни, гуд бай!

Лэйсэн белән Риза өйдән чыгып китәләр. Лилия әрле-бирле йөренә. Ачудан чәчендәге кадагычларны алып ташлый һәм, көзге каршысына басып, үз-үзе белән сөйләшә.

Лилия. Менә үстер баланы! Менә авызыңнан өзеп ашат. Гуд бай! *(Йодрыкларын йомарлый.)* Гуд баегызның иманын укытырмын әле мин сезнең. Болай гына чыгып китәрмен димәгез. Гуд бай менә монда ул. *(Кукиш күрсәтә.)*

Пәрдә.

**ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Яңа салынып беткән зур йорт. Лэйсэн стеналар буйый. Өстендә комбинезон, башында зәңгәр косынка. Чәчләре, косынка астыннан чыгып, битен каплаган. Кулы буяулы булганлыктан, Лэйсэн башын артка ташлап еш-еш чәчләрен рәтли. Йомшак кына басып, Риза керә. Ул да эш киеменнән. Билендә чылбырлы монтер билбавы. Чылбыр чылтырамасын өчен, ул аны кулы белән тоткан. Лэйсэн югарыга карап мавы-гып эшләгәндә, Риза аның артыннан килеп күзен каплый.

Лэйсэн. Кайсы шаяра анда? Буяулы пумала белән битеңә чәпим.

Риза *(тавышын үзгәртеп).* Күк-күк! Киявең кем?

Лэйсэн *(Ризаның тавышын танып).* Күк-күк! Киявем — син.

Риза кулын ычкындыра. Икесе дә көләләр.

Риза. Төш, җитте, ташла эшеңне.

Лэйсэн *(пумаласын чиләгенә батыра).* Ташладык. Инде ни боерасың, хуҗам?

Риза. Ашарга!

Лэйсэн. Гашыйклар ашый димени?

Риза. Ашаган малда өмет бар, ди безнең әби.

Лэйсэн. Әбиең әйткәч, хактыр, алайса. *(Идәнгә газета җәя һәм аның өстенә ризыклар тезә.)*

Риза. Их-ма! *(Лэйсэн янына утыра, ашый башлыйлар.)*

Лэйсэн *(кефир шешәсеннән үзе эчә дә Ризага суза. Риза шешәне түгел, Лэйсэннең кулыннан тотып кефирны каба.)* Тәмлеме?

Риза. Дөньядагы барлык каймакларың бер якта торсын.

Лэйсэн. Алайса, мин сиңа каймак урынына кефир гына ашатырмын. Ә экономияләнгән акчага

беләсеңме нәрсә алабыз?

Риза. Автомобиль.

Ләйсән. Юк, белмәдең. Калган акчага тагын кефир алабыз. Кефирны бик тәмле дисең бит. *(Көлә.)*

Риза. Тәмле шул.

Ләйсән. Мин сатып алган бит аны.

Риза. Инде хәзер мин алганны ашап карыйк. *(Кесәсеннән бер плитә шоколад чыгарып Ләйсәнгә бирә.)*

Ләйсән. Ә үзеңә?

Риза. Балыкның башы ашаса, койрыгы тук була, ди безнең әбекәй.

Ләйсән. Алайса мин баш? *(Шоколадны тешли.)*

Риза. Син — баш, мин — койрык.

Ләйсән. Юк, син дә баш, мин дә баш. Мә, бер кап. *(Шоколад суза.)*

Риза *(Ләйсәнне кулыннан эләктереп).* Кулың белән бирдеңме?

Ләйсән. Йөрәгем белән киңәштем, кулым белән бирдем.

Риза. Шоколадын авызга, ә кызын кочакка. *(Кочаклый.)*

Ләйсән *(шаярып).* Ярамый, өсне пычратасың.

Риза. Ах, хәчтерүш! Минем өс-баш синеке янында кияү егетенеке кебек.

Ләйсән. Син үзең дә кияү егете бит. Тик бер нәрсә генә җитми.

Риза. Нәрсә?

Ләйсән *(уйнап).* Мыек. Менә хәзер сиңа сызылып киткән кызыл мыек ясыйбыз.

Риза. Кызыл мыек буламыни?

Ләйсән *(бармагына буяу ала).* Ясагач була ул. *(Ризага мыек сыза. Риза, карышып, башын артка тарта.)* Карышмаска! Менә нинди матур булды. *(Көлә башлый.)*

Риза. Миннән бик көлсәң, үзеңнең битеңә чабата хәтле миң ясап куярмын әле.

Ләйсән. Тоталмыйсың... *(Йөгереп китә.)*

Риза. Тотам да менә бу чылбырга бәйләп куям. *(Торып баса да ялт кына Ләйсәнне эләктереп ала.)* Менә, эләктеңме? *(Билендәге чылбыры белән Ләйсәнне бәйли.)* Хәзер ычкынып кара.

Ләйсән. Ә минем ычкынасым килмәсә?

Риза. Килмәсә, бигрәк шәп. *(Чылбырны ычкындырмыйча гына Ләйсәнне вальс әйләндерә.)*

Ләйсән. Ләйсәннең беренче балы!

Риза *(вальс көенә).*

Очрадың да миңа кулың суздың,
Мин тартылдым сиңа, тартылдым.
Кара төннәр йөрткән күкрәгемә
Якты йолдыз булып атылдың.

Ләйсән. Очраттым да сиңа кулым суздым,
Мин таяныч синнән эзләдем.
Бәхет безгә карап торды читтән,
Мөлдерәтеп яшьле күзләрен.

Риза. Карадым да синең күзләреңә,
Диңгез күрдем анда йөзәремә.
Башым белән чумдым дулкыннарга,
Карамыйча кеше сүзләренә.

Ләйсән. Карадым да синең күзләреңә,
Язмышымны күрдем, язмышымны.
Чишмә булып сиңа таба чаптым,
Башка якка борып агышымны.

Риза. Ике чишмә булып кушылыйк та
Чабыйк әле диңгезләргә карап.

Ләйсән. Диңгезләрдә, шаулы диңгезләрдә
Сөю җилкән булыр, яшьлек — кораб.

Биюдән туктыйлар.

Риза *(сокланып).* Көне нинди матур!

Ләйсән. Бөтенесе бүген синең өчен, бөтенесе бүген минем өчен. *(Хискә бирелеп сүзен шигырь белән дәвам итә.)*

Синең өчен саклап мин сафлыгымны,
Синең өчен саклап мин аклыгымны.

Риза. Аклыгыңны һичбер вакыт каралтмамын,

Миңа булган өметеңне таратмамын.
Лэйсэн. Синең өчен сакладым мин ялкынымны,
Ялкынымны — күңелемдәге алтынымны.
Риза. Ялкыныңны һичбер вакыт сүндермәмен,
Алтыныңа ятлардан кул тидертмәмен.
Лэйсэн. Синең өчен сакладым мин гөлләремне,
Гөлләремне — ай-йолдызлы төннәремне.
Риза. Гөлләреңне беркемнән дә өздермәмен,
Күңелеңне үземнән һич биздермәмен.
Лэйсэн. Синең өчен сакладым мин таңнарымны,
Хисләр белән мөлдерәмә җаннарымны.
Риза. Хисләреңнең тамчысын да түктермәмен,
Ятлардан күз яшьләреңне сөрттермәмен.

Вальс көенә әйләнәләр.

Пәрдә.

**ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Лилияләр өе. Пәрдә ачылганда, Лилия өстәл әзерли. Ризыклар табынга куелган, ул аракы шешәсен тастымал белән сөртә.

Лилия. Монысын нишләтергә инде? Куймасаң — кунак алдында кыен, куйсаң — кесәгә зыян. Ярар, торсын әле шунда. Чын булса, теге койрыксыз сандугач авызыма да алмыйм, ди бит. *(Өстәлгә шешәне куя.)* Әй, эчмәгән кешене кыстарга яратам да инде. Кыстыйсың, кыстыйсың, аракы да эчелми, үзең дә әйбәт булып күренәсең. *(Сәгатькә карап ала.)* Килерме бу, килмәсме?! Бигрәк икеле-микеле сөйли торган нәрсә. Ә шулай да шәп сайрый. Сандугач шул, сандугач. *(Көйли.)*
Сандугач, сандугач,
Син китәсең, мин калам.
Дусларыма җырлар өчен
Җырыңны отып калам.
*(Җырдан туктый да уйлана.)* Юк, юк! Җырын отар өчен генә кирәкми миңа сандугач. Үз читлегемдә, минем өчен генә сайрасын ул. Китмәсен. *(Ишек шакыйлар. Ул өстәлдәге ризыкларның өстен каплый.)* Ишек ачык, керегез!

Илгизәр керә.

Илгизәр. Сәлам бирдек матур йортка, гүзәл ханымга.
Лилия. Сәлам, сәлам! Мин инде бу койрыксыз сандугач алдады, килми, ахры, дип уйлый башлаган идем.
Илгизәр. Алдау ирләр эше түгел.
Лилия. Кемнәр эше соң?
Илгизәр. Алдакчылар эше. Ә минем җаным гел яхшылыкка омтыла.
Лилия. Бик алай омтылса, очып та китәр әле.
Илгизәр. Аның бер вакытта да очыштан туктаганы юк.
Лилия. Сандугачлар шулай буладыр инде. Минем очасым килми. Очкан кошларны күрсәм дә тотып читлеккә ябасым килә.
Илгизәр. Очар кошны читлеккә ябып булмый, Лилия ханым. Үзен япсаң да, хыялы белән ул барыбер күктә булачак.
Лилия. И, хыялы белән күккә генә түгел, ник җәһәннәмгә олакмый, анда минем ни эшем бар. Үзе читлектә булса, шул җиткән.
Илгизәр. Хыял өчен читлек нәрсә ул,
Киртәләр юк аңа дөньяда.
Ошый бит ул ярларын ишеп
Ургып-ургып аккан елгага.
Лилия. Карале, син әллә берәр әртисме? Ничә күреп, белеп бетерә алмыйм.
Илгизәр. Белмә дә. Юләрләр өчен генә бөтен нәрсә ап-ачык.
Лилия. Ә мин юләр, хәер, хатын-кыз акыллы буламыни? Юләр булганга күрә дә минем һәрнәрсәне ачыктан-ачык беләсем килә: кем син? Әллә кемнәр кулында сайрап, койрыгы йолкынып беткән

сандугачмы?

Илгизәр. Ни өчен койрык йолкынырга тиеш әле минем?

Лилия. Минем кебек юләрләр дөньяда әзмени? Барыбызның да сандугачны үз кулыбызда сайратасыбыз килә. Ә сандугач очарга тели, дисең бит. Без аны җибәрмәс өчен койрыгына ябышабыз. Сандугач безнең кулда койрыгыннан бер каурый калдырып икенче ояга очып китә.

Илгизәр. Карагыз әле, Лилия ханым, сез шагыйрь икән бит. Әйдәгез, ачыктан-ачык сөйләшәбез: сезгә нинди ир кирәк?

Лилия. Әйбәт ир.

Илгизәр. Әйбәтлекне кем ничек аңлый бит. Берәүләргә эчеп-сугышып, хатынын тукмап торган ирләр ошый. Өч-дүрт көнгә бер тукмамаган ирне иргә санамый андыйлар. Икенчеләргә эчми-тартмый, акча гына кайтара торганы кирәк. Өченчеләр даны-шөһрәте үзеннән алдарак йөрүчене әйбәткә саный. Дүртенчеләр теләсә нинди начальник кабинетына тоткарлыксыз керүчене хуп күрә.

Лилия *(көрсенеп).* Кем ошаса да хәзер сайланыр чак узган шул. Үзеңә кирәкне сайландыклар арасыннан эзләргә кала.

Илгизәр. Сез, Лилия ханым, алай бетереп ташламагыз әле. Дөрес, миңа берничә тапкыр оя корып карарга туры килде, ләкин моңарчы сезнең кебекләр очрамады.

Лилия. Мин нинди соң?

Илгизәр. Ир кадерен дә, үз кадерен дә белә торган кеше. Ә бит яшерен-батырын түгел, кайбер хатын-кызлар үз кадерен үзе белми. Ир өчен яши. Бар гомерен аңа багышлый. Ә сез үзегезне яратасыз һәм дөрес эшлисез. Яратыгыз үзегезне. Бала дип, ир дип нигә үзеңне чикләргә? Менә шундый ирекле кош булуыгыз ошый миңа.

Лилия. Элекке иремә минем шул якларым ошамады. Эчәсең, дип бәйләнде. Үзең уйлап кара: сатучы кешегә ансыз мөмкинме? Атналар буе, еллар буе гел күз алдында торган нәрсәгә үрелеп карамый ничек түзәсең? Бер кабып карыйсың, ике кабып карыйсың — аннан китә. Шуннан тәм таба башлыйсың, шул рәхәтлек бирә.

Илгизәр. Мин сезне бик аңлыйм, Лилия ханым. Һәм гаеп итмим. Ныклабрак уйлап карасак, кеше тормышта нәрсәгә омтылсын? Әнә шул рәхәтлеккә бит. Зур идеаллар, бөек максатлар артында да шул эгоистик рәхәтлек тора. Берәүләр аны яшерәләр, икенчеләр яшермиләр — бары шул гына.

Лилия. Минем кешедән яшерер нәрсәм юк. Дөньяда яшәп калырга кирәк.

Илгизәр. Дөрес, Лилия ханым. Уйларыбыз бик туры килә безнең. Бер яшьлектә, бер картлыкта, диләр бит. Нигә безгә идеаль гаилә корып җибәрмәскә? *(Җырлый.)*

Бәхеткә соң түгел беркайчан да,
Бәхетне тик кирәк эзләргә.
Чәчәкләрен күбрәк
Өзик бу тормышның,
Чәчәкләр бит үсә өзәргә.

Лилия. Син дә чәчәк түгел, мин дә чәчәк түгел! Кайчандыр чәчәк булсак та — без инде өзелгән чәчәкләр.

Илгизәр *(җырын дәвам итә).*
Чәчәкләрен өзсәң — тамыры кала,
Тамырлар бит була тирәндә.
Бер-беребезгә тотынып
Тагын күтәрелик,
Бәхет үзе алга килгәндә.

Лилия. Ике бәхетсезлектән бер бәхет ясап буламыни?

Илгизәр. Ай, Лилия ханым, кем әйтте әле безне бәхетсез дип? Бәхет бит ул бик томанлы төшенчә. Әгәр үзеңне мин бәхетле дип ышандыра аласың икән, димәк, син бәхетле. Бәхет ул мода кебек. Ә мода көн саен үзгәрә. Әйтик, бүген кызлар чалбар киюне матур дип саныйлар, ә иртәгә кем белә, бәлки, бөтенләй шәрә йөрүне матурлыкка санарлар.

Лилия *(көлә башлый),* Ну, әкәмәт тә кеше син. Ниләр генә сөйләмисең. Кешеләр ничек бөтенләй шәрә йөрсен ди?

Илгизәр. Ник йөрмәсен? Һәрнәрсә әнә шул матурлык, әдәплелекне ничек аңлауга бәйләнгән. Кешеләр дә, кешеләрнең карашлары да гел үзгәреп тора.

Лилия. Бик үзгәрми. Бер дә ике-өч тапкыр кияүгә чыккан кешене мактамыйлар бит.

Илгизәр. Вакыты җитәр, мактарлар. Эшендә үз нормасын икеләтә үтәгән кешеләрне газетага язалар. Тормыш кору планын да арттырып үтәргә ярамыймыни?

Лилия. Син ул планны берничә йөз процентка арттырып үтәгәнсеңдер инде.

Илгизәр. Анысы әһәмиятле түгел. Иң мөһиме, нинди генә сынаулардан соң да кешенең үзе булып, саф булып калуы.

Лилия. Синең сүзләрдән соң минем башым әйләнә башлады.

Илгизәр. Кешеләргә баш әйләнер өчен бирелә. Артык аеклык тормышта зарар гына китерә. Ясаган хаталарыңа, җибәргән ялгышларыңа үкенмәслек дәрәҗәдә горур булырга кирәк.

Лилия. Ай-яй-яй, Ходай сиңа телне биргән.

Илгизәр. Күп сүз сөйләсәм дә буш сүз сөйләмим мин. Әйтәм икән, конкрет әйтәм. Менә мин бүген сиңа, Лилия ханым, яңа тормыш башлыйк, дидем. Бу — чын күңелдән әйтелгән сүз. Миңа ышана аласыз.

Лилия. Мин артык акыллы кешеләрдән куркам. Аннары, тормышка чыккач, бернәрсә дә үзеңчә булмый инде.

Илгизәр. Барысы да элеккечә калыр, Лилия ханым. *(Лилиянең өен карап йөри. Өйдәге иркенлек, байлыкның аңа ошаганлыгы күренеп тора.)* Шәп! *(Кулларын угалап куя.)*

Лилия. Нәрсә шәп?

Илгизәр. Дөньясы шәп, Лилия җаным. Менә бит мине нинди кеше белән очраштырды. Язмышка рәхмәт укымый, ни дим.

Лилия. Әле мине бик мактамый тор, минем, бәлки, әллә нинди гадәтләрем бардыр.

Илгизәр. Булсын. Кешенең кимчелеге дә булырга тиеш. Бер-береңнең кимчелекләрен кичереп, берең бәхетенә икенчең куанып яшәргә кирәк.

Лилия. Менә бу сүз, ичмасам. *(Илгизәргә яңадан карап куя.)* Болай булгач, абзый кеше, син миңа ошый башладың бит әле. Әллә шуның өчен берәрне тотабызмы? *(Рюмкаларга аракы сала.)* Мә, агай-эне, кайнар килеш күтәр. *(Үзе эчеп җибәрә.)*

Илгизәр *(рюмкасын кире куя).* Кыстау — көчләүнең бер төре, Лилия ханым. Ә көчләү инде ул — ирекне буу дигән сүз.

Лилия. Ну, матур сайрыйсың, валлаһи! Каршымда гел сайратып торыр идем.

Илгизәр. Мин синең сандугачың булырга риза.

Лилия. Түлке озак сайрарсың микән? Сандугач бит тиз сакаулана.

Илгизәр. Анысы инде, Лилия ханым, җәйләрнең нинди булуына карый.

Лилия. Бик аңлап та бетмим бетүен, сайра әйдә, сайра.

Илгизәр *(радионы җибәрә, анда музыка уйный. Илгизәр әкрен генә шигырь сөйли).*

Үткән тормыш гел хата, гел хата,
Яшәгән саен хаталар арта.
Искеләреннән тәүбә итәсең,
Яңаларына кереп китәсең.

Лилия. Синең әллә нинди җырларың да бар икән.

Илгизәр. Җыр ул һәркемдә дә бар. Тик берәүләр эчтән җырлый, берәүләр тыштан. Аерма шунда гына.

Лилия. Бик хикмәтле кеше син. Ялгышларың да күп дисең. Әллә соң син берәр катыржанмы?

Илгизәр. Без бер-беребезнең үткәне белән кызыксынмаска тиеш. Тормыш ул менә бүгенгесе һәм иртәгесе белән матур. Без синең белән шундый гаилә корырбыз, Лилия ханым, ул гел киләчәктән генә торыр.

Лилия. Киләчәктән генә?

Илгизәр. Әйе. Киләчәктән генә. Без бит үзебез дә киләчәк шәһәре төзергә килгән кешеләр.

Лилия. Ләкин бит инде ул шәһәр төзелеп бара. Әнә төзүчеләр хәзер минем кибет янына килеп җиттеләр.

Илгизәр. Шәһәрләр алар кеше язмышы кебек, бервакытта да төзелеп бетми.

Лилия. Сүзләрең бик катлаулы, аңлап бетә торган түгел.

Илгизәр. Миңа калса, без инде аңлаштык төсле. Тормышка карашларыбыз берме? Бер! Ике ярты — бер бөтен диик тә кушылыйк та куйыйк.

Лилия. Шулай дисеңме?

Илгизәр. Шулай димен! Ирләр сүзе бер булыр.

Лилия *(кулын Илгизәргә суза).* Мә, алайса, бишне, килештек.

Илгизәр. Килештек. *(Җырлый.)*

Бер яшьлектә, бер картлыкта
Гөрләтеп калу кирәк.
Сүнеп барган йөрәкләрне
Дөрләтеп алу кирәк.
Күпне сөя белгән күңел
Бай була, тирән була.
Ялгыз үткән бер көнең дә
Җәл була, әрәм була.

Илгизәр җырлап бөтерелеп йөри. Лилия аны хуплап кул чабып тора.

Җырның соңгы куплетын бергәләп җырлыйлар.

Лилия *(кинәт туктап).* Чү, кемдер ишеккә кагылды түгелме?

Илгизәр. Кагылсын, безнең бит дөньядан яшерен эшебез юк.

Лилия. Кызым кайттымы әллә дим.

Илгизәр. Кызың?

Лилия. Әйе.

Илгизәр. Кызың да бармыни әле синең?

Лилия. Бар шул. Нәрсә, кикригең шиңдеме?

Илгизәр. Юк, үзең дә кызлар кебек бит әле син дип кенә әйтергә теләвем. Кызың булу бигрәк шәп. Кечкенә булса, интернатка бирербез, зур булса — кияүгә.

Лилия. Әйе, ул зур инде. Унтугызынчы яше.

Илгизәр. О, алайса, һич кичекмәстән кияү эзли башларга кирәк. Гомерен әрәм уздырмасын. Гомер кешегә бер генә бирелә.

Лилия. Бала гына бит әле ул.

Илгизәр. Унтугызга чыккан кешегә син бала гына дип әйтеп кара, ишетмәгәнеңне ишетерсең. Акселерация заманы, вундеркиндлар заманы хәзер. *(Уйланып йөри.)* Алай, алай, унсигезне узган кыз диген, ә.

Лилия. Кайгырма, мин сиңа тагылырга җыенмыйм. Ялгыз башым, тыныч колагым.

Илгизәр. Алай түгел ул, Лилия ханым. Синең әле бәхетле булып караганың юк, шуңарга мондый сүзләр сөйлисең. Ә минем сине бик бәхетле итәсем килә. Ошадың син миңа. Буйсынмас рухың белән ошадың.

Лилия *(яратып Илгизәргә карый).* Синең алда таш булсаң да уалырсың, боз булсаң — эрерсең, валлаһи!

Илгизәр *(аның сүзеннән канәгать кала).* Мине дөрес аңла, Лилия ханым. Миңа кызың артык түгел. Хәтта өчәү булсалар да йөрәгемдә урын җитәрлек. Мин бары синең өчен генә кайгырам. Бала-чага бит ул ата-ананың тормыш коруын бер дә хуп күрми.

Лилия. Анысы шулай инде.

Илгизәр. Шуңа күрә дә эшне гаҗәп оста эшләргә кирәк. Эт тә сөяксез калмасын, кәҗәгә дә печән булсын.

Лилия. Эшне үзем бозып ташладым шул. Беркөн кияүгә чыгам дип бик әсәрләнеп кайткан иде. Син яшь әле, дип сүгеп туктаттым. Кем уйлаган...

Илгизәр. Әйе. Бераз ялгышлык эшләгәнсең, Лилия ханым. Балаларның андый изге теләгенә һич тә каршы килергә ярамый. Хәтта унбиштә генә булсалар да. Индиядә уникедән чыгалар әле. Аңардан кешенең үлгәне юк.

Лилия. Хәзер үкенүдә ни файда!

Илгизәр. Бәлки әле, соң түгелдер? Егете белән аралары ничегрәк икән?

Лилия. Аларны ут белән дә, су белән дә аерырлык түгел.

Илгизәр. Алайса, әле хатаны төзәтеп була. *(Дәртләнеп.)* Дөньяда төзәтмәстәй хаталар юк, Лилия ханым. Дөресен әйткәндә, без үзебез дә кайчандыр ясаган хаталарны төзәтәбез түгелме?

Лилия. Әйе.

Илгизәр *(җырлый).* Язмыш безне таныштырды, инде кавыштырыр да...

Пәрдә.

# ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук Лилия ханымнар йорты. Җиһазлар элеккечә. Пәрдә ачыл-ганда, Лилия көзге каршында колакларына алка киеп маташа.

Лилия. Әҗәл белән кунак көтмәгәндә килә, диләр иде, бәхет тә көтмәгәндә килә икән. Кешесе нинди бит, кешесе! Лилия ханым, дип өтәләнеп йөри. Тик менә артык айнык булуы гына яманрак. Айныкларны алдау кыен. Ә ир-атка ничек инде дөресен сөйлисең? Тормышта нинди хәл булмас. Мин бит әле кеше карамаслык түгел, башымны югалтып алуым да бар. *(Боргаланып ала.)* Әй, аларын ничек тә җайлар идем, менә кыз белән эшләр шәп килеп чыкмады. Хәзер ул миңа үзең кияүгә чыгасың килгәнгә рөхсәт бирмәгәнсең икән, диячәк. Икебез берьюлы кияүгә чыга алмыйбыз бит инде без. Әй, аңа иртә әле. Егете дә әллә кем түгел. Электрик та булдымы һөнәр. Хәзерге вакытта эштән кайтканда берәр нәрсә ияреп кайта торган һөнәр кирәк. Ә электрикка аңар тимерчыбыктан башка нәрсә ияреп кайтсын! Их, бу яшьләрне. Баштарак күзләрен ачып карый белмиләр, аннары елап йөриләр. Хәер, үзләре яратышалар бугай, теләсә нишләсеннәр. Әйе, ризалыгымны бирәм дә куям. Югыйсә ул безнең

аякка тышау булачак. Минем дә ир кадерен күреп каласым килә.

Ләйсән керә.

Лилия. Кайттыңмы, кызым?
Ләйсән. Әйе. Риза килмәдеме?
Лилия. Юк. Нәрсә, килергә тиеш идемени?
Ләйсән *(көйләп).* Килергә тиеш иде, көтәргә тиеш иде.
Лилия. Вагоны беләнме?
Ләйсән. Ә нигә? Вагоны булгач, өй дә кирәкми, машина да. Берәр поездга тагыласың да әллүк ерак сәфәргә.
Лилия. И кызым, кызым. Берәү булса, шушы чибәрлеге белән әллә нинди палкауникларны аяк астына тәгәрәтеп яткырыр иде. Һичьюгы, берәр завскладны.
Ләйсән. Минем Ризам, әни, армиядә полковниктан да зуррак булган.
Лилия *(ышанмыйча).* Әй, булгандыр инде.
Ләйсән. Булган шул. Син аның чөйгә элеп куйган папахасын күрсәң дә һушыңнан язарсың. Полковниклар аның бүрегенә дә сәлам биреп керә.
Лилия. Йә, йә, палкауниклардан зуррагы кем була инде аның, кызым?
Ләйсән. Прапорщик, әни.
Лилия. Палкаунигын ишеткән барые, ләфрәйторын ишеткән барые, бусын кем диден әле?
Ләйсән. Прапорщик.
Лилия. Алай, палкауниктан олы прапорщик булгач, ни пычагыма урамда тимерчыбык сузып йөри соң ул?
Ләйсән. Урам якты булсын дип.
Лилия. Шаяртасыңдыр әле, каян килсен аңа палкауниклар башлыгы булу.
Ләйсән. Бәлки, шаяртамдыр!
Лилия. Ярый инде, ярый. Шаяр әниең белән.
Ләйсән. Ә нигә шаярмаска? Сиңа бит кияү түгел, ә мактаныр өчен ялтыравык бер уенчык кирәк.
Лилия. Кияүгә көн дә чыкмыйлар, бер чыкканда алдыңны, артыңны карабрак чыгарга кирәк.
Ләйсән. Көн дә чыкканнар да бар.
Лилия. Әниең синең турында кайгырта, ә син...
Ләйсән. Әниләр кайгыра торыр, кызлары кияүгә чыга торыр, ди.

Җиткән кыз ул — ачы бал,
Әйбәт чакта эчеп кал, —

дип тә әйткән ди бер шагыйрь.
Лилия. Мин тагын сине шатландырырмын дип торган идем...
Ләйсән. Шатландыр, алайса.
Лилия *(сандыгын ача).* Күзеңне йом.
Ләйсән. Күзеңне йом, авызыңны ач, нафталин каптырам дисеңме? Йә, йомдым, каптыр. Сандык төбендә нафталиннан башка ни булыр икән?
Лилия *(үпкәләп).* Син әниеңне дөньядагы иң начар кешегә санагач та.
Ләйсән *(күзен йомып, кулларын суза).* Мин болай озак тора алмыйм, тизрәк шатландыр.

Әнисе сандыктан алып аның кулларына ак туфлиләр тоттыра.

Ләйсән. Туфлиләр? Кара, нинди матурлар. *(Кия.)* Тап-таман.
Лилия. Таман булгач ки генә. *(Кызына карап тора.)* Кара инде, боларны да кигәч, бигрәк үсеп киттең. *(Көрсенеп куя.)* Без, аналар, баланың үскәнен күрми дә калабыз шул. Унтугызга чыктың бит.
Ләйсән. Мин бүген боларны киеп чыгам, әни.
Лилия. Ки, ки, кызым. Кияр өчен алынган инде алар. Әле менә монда тагын бер нәрсәм бар.
Ләйсән. Кая? Нәрсә?
Лилия *(шытырдавык кәгазьгә төргән әйбер бирә)*. Күлмәклек.
Ләйсән. Күлмәклек? *(Әнисе биргән төргәкне сүтә башлый.)* Син бит моны үзеңә дип алган идең, нишләп әле таштан юкә суелды?
Лилия. Суела ул. Кияүгә чыгам дисең бит. Туй күлмәге тектерерсең.
Ләйсән. Булмаган туйга, суймаган куйга.
Лилия. Куен суярсың.
Ләйсән. Син риза, әнием, әйеме?
Лилия *(көрсенеп).* Риза булмыйча нишлим соң? Гуд бай, дип куркытасың бит.
Ләйсән. Рәхмәт, әнием. *(Әнисен үбеп ала.)* Болай булгач мин тиз генә барып кайтыйм әле.

Лилия. Төнгә каршы кая барасың?
Ләйсән. Риза янына. Риза, әни риза диярмен.
Лилия. Иртәгә дә өлгерер идең әле.
Ләйсән. Иртәгәгә хәтле төн бар, ә төндә җен бар, дип әйтте ди берәү. *(Шаярып.)* Вагонын ала торсын, мичenә яга торсын.

Йөгереп чыга башлый, шул вакыт Риза белән маңгайга маңгай бәрелешә. Икесе дә маңгайларын уып торалар. Лилия, яшьләргә комачауламас өчен, икенче якка чыгып китә.

Риза. Ләйсән! Кая чабасың болай?
Ләйсән *(Ризаны үртәп).* Әй, әллә кая түгел лә, кияүгә генә.
Риза. Кияүгә?
Ләйсән *(юри битараф күренергә тырышып).* Әйе. Әни әйтә, Ризаң барыбер тынгылык бирмәс, ул вагоны белән килеп җиткәләгәнче, берәр полковникка чыгып кал, ди.
Риза. Полковникка?
Ләйсән. Әйе, безнең күрше абыйларга бер полковник кайткан. Шул үзенә кәләш эзли икән. Мине бик ошаткан.
Риза. Полковник тикле полковник ошаткач, бармый калырга ярамый.
Ләйсән. Үзем дә шулай дим шул. Квартирам да бик шәп, «Волга»м да бар дип әйтә, ди.
Риза. Мондый шансны кулдан ычкындырма инде алайса.
Ләйсән. Әни әйтә, карт кеше, ичмасам, кадереңне белер, ди.
Риза. Картмыни?
Ләйсән. Карт дип, хәзерге заманда илле җиде яшьлек ир картмыни! Әни әйтә, аны әле марафонга йөгертергә була, ди.
Риза. Патшабикә булып ятар көннәрең алда икән алайса.
Ләйсән. Әйе. Өй эшләрен эшләргә солдатлар китертермен. Тик менә «Волга»сын үземә йөртергә туры килмәгәе.
Риза. Полковнигың йөртер.
Ләйсән. Колагы бераз чукрак икән. Үземә өйрәнергә калыр инде. *(Куллары белән машина йөрткән хәрәкәтләр ясый.)*
Риза. Үзеңә йөртергә кыен булса, берәр солдат ялларсың. Полковникның акчасы күптер.
Ләйсән. Әни әйтә, бер кенәгәсендә генә дә илле мең, ди.
Риза. Рәхәт чигәсе көннәрең алда икән.
Ләйсән. Карале, Риза, туйга нинди күлмәк тектерим икән?
Риза. Полковник тикле полковникка чыккач, йөз кызарырлык итмәссең инде. Алып җибәрерсең патшабикәләр генә кия торганын.
Ләйсән *(әнисе биргән күлмәклекне күрсәтә).* Ә менә бу ярамасмы икән?
Риза *(кызның ачуын китерергә теләп).* Артык прастуй. Полковнигыңның дәрәҗәсе төшәр.
Ләйсән *(бераз күңелсезләнеп).* Артык прастуй дисең инде алайса? Ә мин ошар дип уйлаган идем.
Риза. Миңа, бәлки, ошар иде дә...
Ләйсән. Ярый, сиңа ошагач, полковнигыма да ошар, бәлки. *(Күлмәклек тукыманы җилкәсе аша салып, күзгә алдына килә.)* Матурмы? *(Ак туфлиләрен дә киеп куя.)* Йә, әйтеп җибәр, полковник кәләшенә ярарлыкмы?
Риза. Нәкъ үзе. Түр башына менеп боерыклар биреп утырасың гына калды.
Ләйсән *(диванның артына менеп утыра).* Боерам, туфлиләремне салдыр! *(Аякларын суза.)*
Риза. Юк инде, полковнигыңа боерырсың.
Ләйсән *(аягы белән шапылдатып.)* Боерам!
Риза. Хатынының аягын салдырган полковникка мин адъютант та булырга теләмәс идем.
Ләйсән. Соңгы тапкыр әйтәм, салдыр.
Риза. Боерыкны кат-кат әйтмиләр.
Ләйсән. Алайса, мин синең белән сөйләшмим. *(Икенче якка әйләнеп утыра.)*
Риза. Полковник кәләше белән мин дә бик сөйләшергә тормыйм әле.
Ләйсән. Үкенерсең.
Риза. Үкенсәм үкенермен. Беренче мәхәббәт үкенечле була, диләр бит.
Ләйсән *(Ризага таба борыла).* Мәхәббәт? Әллә син мине ярата идеңме?
Риза. Яратса, синең ни эшең бар?
Ләйсән. Тагын бер тапкыр әйт әле: яратам, диген.
Риза. Мин кеше кәләшенә яратам дип әйтә алмыйм.
Ләйсән. Ә син юри генә булса да, минем башымны әйләндерер өчен генә булса да әйт.
Риза. Синең болай да башың әйләнгән инде.

Ләйсән. И-и, Риза, әйт инде. Яратам, диген, синнән башка тора алмыйм, диген. Вагон белән сине алып китәргә килдем, диген. Әле бит мин полковникның кәләше үк булып җитмәгән.

Риза. Бик теләсәң, әйтәм алайса.

Ләйсән. Бик телим.

Риза. Яратам, яратам, яратачакмын.

Ләйсән *(диван артыннан сикереп төшә).* Чынмы? Болай булгач, әллә полковникка отставка бирим микән? Син нәрсә дисең, Риза?

Риза. Син шаярдың гына, әйеме, Ләйсән?

Ләйсән. Кияүгә чыкканчы шаярып кал, дип әйткән ди бер акыл иясе.

Риза. Уф, мин ышанып бетә яздым.

Ләйсән. И юләрем минем, шулай беркатлы булырга ярыймыни?

Риза. Бөтенләй котны алдың бит.

Ләйсән. Тагын бер котыңны алырлык сүз әйтимме соң?

Риза. Әйтсәң әйт инде, булгач булсын.

Ләйсән. Әни ризалык бирде.

Риза. Ура! *(Ләйсәнне күтәреп ала.)*

Ләйсән. Төшер, әни килеп чыгар. *(Риза аны төшерергә итә, ләкин Ләйсән аның муеныннан ныклап кочып ала да кочагыннан төшми.)* Менә, төшерә алмыйсыңмы? Хатын алу — муеныңа камыт кию, дип әйткән ди бер акыллы кеше.

Ләйсәнне күтәргән килеш пәрдә төшә.

**АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ**

Лилиянең кибете. Бер почмакта аракы шешәләре. Кибетнең ишегенә «Обед» дип язылган кәгазь эленгән. Ишек кагалар.

Лилия. Кем бар анда? Бәбәгеңне ачып кара, әбит дип язылган бит.

Илгизәр тавышы. Лилия ханым, Лилия ханым!

Лилия *(тавышына ягымлылык биреп).* Синмени әле, койрыксыз сандугачым? Мин кеше дип торам тагын. *(Ишекне ача.)*

Илгизәр керә.

Илгизәр. Сәлам бирдек гүзәл ханымга.

Лилия. Сәламеңне алдык, түш кесәгә салдык.

Илгизәр *(киштәләргә күз йөртеп).* Оһо, Лилия ханым, сездә зур үзгәрешләр бар икән.

Лилия *(горурлык белән).* Тәки үземнекен иттем. Аракысыз кибет ул — ирсез өй кебек бит.

Илгизәр. Дөрес, Лилия ханым. Өйне ирсез, кибетне аракысыз тотарга ярамый. Болай булгач, синең сәүдәләр гөрли?

Лилия. Әле бик гөрләми. Әллә белеп бетермиләр. Аптырыйм. Нәрсә булды кешеләргә? Нишләп ябырылмыйлар? Их, бозылды халык. Кибет төбендә кунып яталар иде бит. Син анда үзең белән эшләүчеләргә әйткәлә.

Илгизәр. Һичшиксез, әйтермен. Премия аласы көннәрең алда әле.

Лилия *(хәйләкәр елмаеп).* Премиясен алардан көтеп тормыйм ла! Кибет диләр аны.

Илгизәр *(бармак яный).* Кара аны, Лилия ханым, мине зур бәхеттән мәхрүм итмә.

Лилия *(аны аңламыйча).* Нинди бәхет? Әллә миңа да өлеш чыгар димәкче буласыңмы?

Илгизәр. Аллам сакласын, андый сүзне авызыңнан җилләр урласын. Язмыш миңа синең белән очрашу бәхете бүләк иткәнгә дә сөенеп бетә алмыйм. Премияләрне күбрәк каерып, үзеңне күрү бәхетеннән мәхрүм итмә, дим.

Лилия. Ну, болгавыч итеп сөйләргә яратасың, валлаһи. Безнең ише кеше генә аңлап бетерерлек түгел.

Илгизәр. Дөнья шулай яратылган инде, Лилия ханым. Берәүләр турыдан барып та адашалар, икенчеләр уравыч сукмаклардан да исән-имин чыгалар.

Лилия. Синең сукмагыңда йөри-йөри буталып бетәрсең.

Илгизәр. Киресенчә, Лилия ханым, без синең белән олы юлга чыгу алдында торабыз. Кешенең күпчелек гомере әнә шул олы юлга чыгу өчен әзерлек кенә.

Лилия. Моңарчы бик күпләрне олы юлыңа алып чыгып адаштырып калдырмадыңмы икән?

Илгизәр. Үземне гөнаһсыз санарга җыенмыйм, Лилия ханым. Вак-төяк гөнаһларым бар. Ләкин гөнаһларны кичерер кеше дә кирәк. Менә синең кебек киң күңелле, йөрәк җылысын таратып бетермәгән кешене очратуыма ышана идем.

Лилия *(күңеле булып).* Минем кочагымда тимер дә сары майдай эрер.

Илгизәр. Бик шәп, Лилия ханым. Инде шул кочакка тизрәк керергә кирәк. Әле менә минем монда килүем дә шуны тизләтү өчен иде. Артык сузарга ярамый безгә бу изге эшне.

Лилия *(мут елмаеп).* Изге эш дисең инде алайса?

Илгизәр. Изге һәм саваплы. Чөнки безнең иманнарыбыз бер-беребез өчен яратылган. Болай да без бер-беребезне артык озак эзләгәнбез.

Лилия. Анысы шулай да, тик менә, бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, кызым белән беркөнне иргә чыга алмыйм бит инде мин.

Илгизәр. Ул ягы җайсызрак килеп чыкты, әлбәттә. Алла бүрегә сөяк бирергә уйласа, башта тешен сындырыр, ди. Әмма, Лилия ханым, бер акыллы кеше әйтмешли: майлап булмаган кеше, җайлап булмаган эш юк. Җайларбыз.

Лилия. Ничек итеп?

Илгизәр *(уйланып).* Ничек итепме? Әгәр, мин әйтәм, шыпырт кына язылышып куйсак, ә?

Лилия *(кәефе китеп).* И-и, дөньясын шаулатып туй ясамагач та иргә чыгуның ни кызыгы бар?

Илгизәр. Вакыты җиткәч туен да ясарбыз. Хәзергә язылышып куйыйк без.

Лилия. Үзең бит, мәхәббәтебез иректә булырга тиеш, дип сайраган идең. Нигә язылышырга?

Илгизәр. Мәхәббәт иректә, әлбәттә, ләкин мәхәббәт каршында кешеләр иректә түгел. Әгәр без бүгеннән язылышып куйсак, кызың белән киявең алдында йөзебез ак булыр. Тормышны корабыз икән — нык нигезгә корырга кирәк.

Лилия. Нигезем минем нык.

Илгизәр. Әйе. Әле бүген өегезне карап киттем. Шәп йорт, каһәре! *(Кулларын угалап ала.)*

Лилия. Шәп булмыйча! Бөтен тапкан, табынган шунда кереп беткәч.

Илгизәр *(Лилия бармакларындагы йөзекләргә карап).* Бөтенесе дә түгелдер инде, Лилия ханым.

Лилия *(кулына күз төшереп).* И-и, аның хәтле генә...

Илгизәр. Юк, юк, Лилия ханым, мин гаепләп әйтмим. Алай уйлый күрмә. Хатын-кыз матур булырга тиеш. Хатын-кыз сокланыр өчен, бәхет өчен яратылган.

Лилия *(Илгизәрнең пеләш башын сыйпый).* Матур сайрыйсың да, валлаһи.

Илгизәр. Матур гөл күрсә, чыпчык та сайрамый түзми, ә мин бит сандугач.

Лилия *(чытлыкланып).* Шул сайрауларың белән күңелемне иләсләндереп бетердең инде. Унсигез яшьлек кыз кебек, сызгырганга йөгереп чыгарга торам.

Илгизәр. Синең кай җирең унсигез яшьлек кызларныкыннан ким? Ярый, билең бик үк өзелеп тормасын ди, ярый, атлап йөрүләрең бераз гына ана аюныкына охшасын ди...

Лилия. Син нәрсә? Пластинкаңны әйләндереп куйдыңмы әллә?

Илгизәр. Юк, юк. Сүз арасында гына. Аның каравы, мин әйтәм, сине рәхәтләнеп кочарга була.

Лилия. Кочаклаган кешегә билем дә җитәрлек, бүтәне дә, Аллага шөкер.

Илгизәр *(Лилияне кулыннан ала).*

Билләреңне кочар идем,
Өзелеп чыгар билләрең.
Алда әле билең кочып
Рәхәт чигәр көннәрем.

Лилия. Әй телләрең, телләрең шул,
Сүз түгел, бал тамадыр.
Сине күргәч, сандугачлар
Телсез-җырсыз каладыр.

Илгизәр. Ал итәрбез әле без,
Гөл итәрбез әле без.

Икесе бергә. Былбыллар кебек сайрашып
Көн итәрбез әле без.

Илгизәр. Димәк, Лилия ханым, иртәгәдән дә калмый язылышабыз.

Лилия. Бәхет өчен кайчан да соң түгел дисең бит үзең, нигә ашыгырга?

Илгизәр. Бәхет ул — канатлы кош, Лилия ханым. Тизрәк койрыгыннан бәйләп куймасаң, очып та китәр.

Лилия. Ярый-ярый, бәйләрбез. Әмма ләкин, бер бәйләгәч, минем кулдан ычкынырмын димә. Бүтәннәр сине койрыгыңнан эләктергән, шуңа каурыеңны йолкып булса да кача алгансың. Ә мин сине читлеккә койрыгыңнан түгел, тәпиеңнән бәйләп куячакмын.

Илгизәр. Бәйлә, Лилия ханым, синең алтын читлегеңдә җан бирү дә минем өчен бәхет булачак.

Лилия. Ай, валлаһи, сөйләп тә карыйсың инде.

Илгизәр. Мин түгел, мәхәббәт сөйли, Лилия ханым. *(Сәгатенә карый.)* Йә, ярый, Лилия ханым, мин китим әле. *(Чыгып китә башлый да кире борылып килә.)* Карале, гел шуны сорармын дим дә, сине күргәч онытам. Кияү балакай ниндирәк кеше, исеме һәм җисеме дигәндәй?

Лилия. Әй, авылдан килгән бер мокыт шунда. Риза дип исе китте Ләйсәннең.

Илгизәр. Риза?

Лилия. Әйе, Риза исемле.

Илгизәр *(нидер исенә төшерергә тырышкандай).* Риза, Риза... Кайсы авылдан икәнен белмисеңме?

Лилия. Нәрсәмә кирәк ул? Менә мин синең дә кайсы авылдан икәнеңне сорамыйм бит.

Илгизәр. Анысы шулай, Лилия ханым, әйе, шулай. Кешенең үткәнендә казынырга ярамый. Тик шулай да ул Ризаңны миңа күрсәтерсең әле. Ни әйтсәң дә, ул бит сиңа гына түгел, миңа да кияү буласы кеше.

Лилия. Бер түгел, биш күрерсең әле. Кайчан карама бездә ул.

Илгизәр. Ярый алайса, Лилия ханым, килештек. Бәхет кочагына атылырга санаулы минутлар гына калып бара. Ашыгыйк.

Лилия. Хуш, койрыксыз сандугачым.

Илгизәр чыгып китә.

Пәрдә.

**ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ**

Больница палатасы. Буйлы пижамадан, башын марля белән бәйләгән Илгизәр караватта утыра. Аның каршысындагы карават буш.

Илгизәр *(башын ике кулы белән тотып).* Ух, аңгыралар, ух, кабахәтләр. Нишләттеләр? Аракы парыннан айнып җитмәгән тинтәкләр. Егерме яшьлек егет белән мине бутасыннар инде. Дөньясы бит аның хәзер җыен аңкы-миңкедән тора. Ышанып эш кушар кешесе юк. *(Башын тота.)* Ух!

Йөрәге януга чыдый алмыйча сикереп тора, әрле-бирле йөренә башлый, шул вакыт Шәфкать туташы керә. Аның кергәнен күреп, Илгизәр тиз генә урынга ава.

Шәфкать туташы. Ну, абый, сезне нишләтергә инде? Тагын урыныгыздан тордыгызмы?

Илгизәр *(еламсырап).* Валлаhи дип әйтәм, тормадым.

Шәфкать туташы. Тормагач, нигә моны киеп куйдыгыз? *(Чалбарга күрсәтә.)*

Илгизәр. Соң, ыштансыз ничек ятыйм? Ояты бар бит.

Шәфкать туташы. Сезгә хәзер оят турында түгел, терелү турында уйларга кирәк.

Илгизәр. Ыштансыз ятып кына терелеп булса икән.

Шәфкать туташы. Була. Урыныгыздан кузгалмагыз, баш миегез селкенгән, дип әйтте бит врач.

Илгизәр *(башын тота).* Исерек ишәкләр, башка сукмасалар.

Шәфкать туташы. Бик авыртамы?

Илгизәр. Авыртмаган кая! Бөтен дөнья кара томан эчендә.

Шәфкать туташы. Кыймшанмыйча гына ятыгыз. Ә хәзер моны салабыз. *(Илгизәрнең чалбарын салдыра.)* Йомышыгыз булса, няняларны чакырыгыз, судно китерерләр.

Илгизәр. Судносы да, пароходы да кирәкми.

Шәфкать туташы. Яңадан врач сүзен тыңларга яхшырак булыр. Ә одеал астында ятарга ыштан кирәкми. *(Чыгып китә.)*

Илгизәр *(торып утыра).* Ну, бу врач халкын. Каберең якын булмасын. Кабердә дә дөрес ятмыйсың дип боргалап бетерерләр.

Шәфкать туташы күренә.

Шәфкать туташы. Тагын торып утырдыгызмы?

Илгизәр. Җан түзми бит. Больницада ятар көннәрмени?

Шәфкать туташы. Больницада ятар өчен аерым көннәр юк.

Илгизәр. Йөрәгегез булса, мине аңларга тиешсез. Минем менә-менә туем булырга тора.

Шәфкать туташы. Көмеш туегызмы?

Илгизәр *(тагын сикереп тора).* Сез нәрсә, мин бит әле егет кеше. Яңа гына үземә тиң кәләш таптым.

Шәфкать туташы *(аны яткыра).* Бик озак эзләгәнсез түгелме соң кәләшне?

Илгизәр. Бәхетне кеше гомер буе да эзли.

Шәфкать туташы. Инде бәхетегезне таптыгыз алайса?

Илгизәр. Таптым.

Шәфкать туташы. Тапкач тыныч кына ятыгыз, юкса гомерлеккә яңадан югалтырсыз. Сезгә тынычрак булсын өчен мин моны *(Илгизәрнең чалбарын күрсәтә)* үзем белән алып чыгып китәм.

Илгизәрне одеал белән каплый да чыгып китә.

Илгизәр *(башын калкыта).* Һичбер вакыт ыштанымны салдырырлар дип уйламаган идем. Их, дөнья! *(Башыннан каплана да ята.)*

Лилия керә. Өстендә ак халат.

Лилия. Алтынчы палатада, диделәр бит. Кая соң бу койрыксыз сандугач?

Илгизәр *(одеалын ача, торып утыра).* Лилия ханым...

Лилия. Әбәү, әстәгыфирулла, нишләттеләр? Карарлыгың калмаган.

Илгизәр. Исерек дуңгызлар эше. Башында акылы бар кеше исерек белән бәйләнәме соң?

Лилия. Сине «скурый помыш» белән апкиттеләр дип ишеткәч, котларым калмады. Минем җәннәт сандугачына кайсы җүнсезенең кулы күтәрелде икән дим. Утлар йотып чыктым төн буе. Йә, сөйлә, нәрсә булды?

Илгизәр *(ялт кына торып басмакчы була да, ыштансыз икәнен белгәч, простыня белән алдын каплый).* Нәрсәсен сөйлисең инде аның? Безгә кияү булачак егетнең йомшак кына итеп сыйрагын сындырыгыз дигән идем...

Лилия. Аның сыйрагы сиңа комачау иттемени?

Илгизәр. Безнең бәхетебезгә аяк чалучы һәрбер сыйрак сынарга тиеш, Лилия ханым.

Лилия. Син берәрсе белән бутыйсыңдыр. Нишләп әле Риза безнең бәхетебезгә аяк чалсын?

Илгизәр. Бутамыйм, бер дә бутамыйм. Үзебезгә кияү булачак кешенең кем икәнен бик яхшы белдем.

Лилия. Кем соң?

Илгизәр. Төрмәдән качкан бер бәндә.

Лилия *(куркып).* Әстәгыфирулла! Син нәрсә сөйлисең? Ризамы төрмәдән качкан?

Илгизәр *(бармагын иреннәренә куя).* Тс-сс, Лилия ханым, шаулама. Ул бандитның исемен дә кычкырып әйтергә ярамый. Төрмәдән качуы гына бер хәл, өстәвенә ике тапкыр өйләнгән нәрсә икән.

Лилия. Кай арада ике тапкыр өйләнсен әле ул, армиядән кайтканына ярты ел.

Илгизәр. Тс-сс, Лилия ханым, әкренрәк. Ул бандитның монда булуы да ихтимал.

Лилия. Монда?

Илгизәр. Әйе, чөнки аның кичә үзенә дә эләкте бугай.

Лилия. Монда булса бигрәк әйбәт, чыраена бәреп әйтермен. Нишләп әле ул бандит башы белән Ләйсәннең башын әйләндереп йөри?

Илгизәр. Юк, Лилия ханым, бандит белән бәйләнмәвең хәерле. Без аны синең кызыңнан бүтән юл белән биздерербез.

Лилия. Менә ышан кешегә!

Илгизәр. Ярый әле кияү-балакайның кем икәнен үзем тикшерергә булдым.

Лилия. Синең баш бар. *(Илгизәрнең башыннан сыйпый.)*

Илгизәр. Ой-ой! Башыма кагыла күрмә, чатный, ярыла.

Лилия. Ничава, туйга кадәр төзәлер.

Илгизәр. Туйны монда көтеп ятып булмый, Лилия ханым. Тизләтергә кирәк, хәзер заманы шундый.

Лилия. Ничек итеп?

Илгизәр. Иң беренче итеп миңа ыштан апкил. Ыштанны салдырдылар, оятсызлар. *(Алдына простыня урап әрле-бирле йөри.)* Качам мин моннан. Качам да тизрәк язылышабыз.

Лилия. И-и, язылышабыз дип саташтың инде. Нәрсәгә кирәк булды соң ул?

Илгизәр. Кирәк, Лилия ханым, һәрнәрсә законлы булсын. Хәтта бәхетнең дә закон белән ныгытылуы яхшы.

Лилия. Кулыма бер килеп керүен керсәң, законнан катырак каптырырмын мин. *(Йодрыкларын йомарлап куя.)*

Шәфкать туташы керә. Ул буш караватның мендәрен калкытып куя.

Илгизәр *(кыланып).* Туташ, әллә монда берәр кеше саласызмы?

Шәфкать туташы. Тормагыз, торма. Әйе, салабыз.

Илгизәр. Нindирәк кеше?

Шәфкать туташы. Сезнең белән бер көнне китерелгән егет. Ялгышмасам, сезне шул коткарып калган бугай.

Чыгып китә.

Илгизәр *(калкына да кире ята).* Аһ, каһәр суккыры. Шул гына җитмәгән иде. *(Одеалын бөркәнеп ята.)*

Ризаны җитәкләп, Шәфкать туташы керә. Ризаның уң кулы гипсланган һәм «самолет» итеп муенга асылган.

Шәфкать туташы. Менә шушында ятарсың. Монда бераз тынычрак.

Риза карават читенә утыра. Шәфкать туташы чыга башлый да, тукталып, Илгизәр караваты янына килә, һәм кесәсеннән дару шешәсе алып,

Илгизәрнең тумбочкасына куя.

Шәфкать туташы. Сезгә аш алдыннан менә моны эчәргә кирәк булыр. Апа, эчерерсез, яме. Ярты стакан суга унбиш тамчы тамызып.

Лилия. Ярар, ярар, тамызырмын.

Лилия, танытмаска тырышып Ризага аркасы белән тора, ләкин Риза аны тавышыннан танып ала.

Риза. Лилия апа, сез?

Шәфкать туташы. Менә танышларыгыз да табылды, бергә-бергә күңеллерәк булыр.

Чыгып китә.

Риза. Сез нишләп монда?

Лилия *(кырт кисеп)*. Тегендә булмаганга монда!

Риза *(аның дорфалыгына гаҗәпләнеп)*. Нәрсә булды, Лилия апа, җүнләбрәк аңлатыгыз әле?

Лилия. Бандитлар белән сөйләшер сүзем юк минем.

Риза берни аңламый, иңнәрен сикертеп куя да караватына утыра. Шул вакыт палатага Ләйсән керә. Ул ерактан ук Ризаны күреп ала һәм, Илгизәр караватына иелгән әнисен дә күрмичә, Ризага ташлана.

Ләйсән. Риза, нәрсә булды? Нишләттеләр?

Риза. Нәрсә булганын үзем дә аңлап җитмим әле. Сезнең тыкрыкта бер абзыйны кемнәрдер дөмбәсләп яталар иде. Араларга дип кердем.

Ләйсән. Йә, йә, шуннан?

Риза. Шуннан менә шул. *(Гипсланган кулын күрсәтә.)*

Ләйсән. Кемнәр икәнен таныдыңмы соң?

Риза. Каян таныйм инде аларны. *(Бераз уйланып тора.)* Әйе, танып булмады. Теге абзый гына күргән кеше иде бугай.

Ләйсән. Кем?

Риза. Лилия апа кибетендә күргәнем бар иде аны. Әйе, әйе, шунда.

Ләйсән *(Ризага кызгану белән карап).* И рыцарем минем! Батырым минем! Йә, ярый, бер акыллы кеше әйтмешли, туйга кадәр төзәлер. Ә хәзер мине үзеңнең самолет кулың белән кочакла.

Риза. Ләйсән, без монда үзебез генә түгел.

Ләйсән. Булса соң? Син бит минем киявем. Үз киявемнән кочаклатырга хакым юкмыни минем.

Кызының бу сүзләрен ишеткәч, Лилия утырган урыныннан сикереп тора.

Лилия. Ләйсән! Ни сөйләгәнеңне белеп сөйлә, нинди кияү ул сиңа, кияү түгел, бандит ул. Төрмәдән качкан нәрсә. Ике хатын аерган җулик.

Ләйсән. Әни? Нишләп әле син монда? Кем әйтте сиңа Риза турында андый сүзләр?

Лилия. Кем әйтсә дә барыбер түгелмени?

Ләйсән. Түгел! Риза турында мин хәтта үз әниемнән дә яман сүз ишетергә теләмим.

Лилия. Миңа гына ышанмасаң, менә Илгизәр абыеңнан сора. *(Илгизәрнең одеалын ача төшә. Илгизәр йөзен күрсәтмәскә тырыша, ләкин Лилия аның ай-ваена карамый.)* Йә, әйт, менә миңа әйткәннәреңне шул бандитның чыраена бәреп әйт. Кызым ишетсен.

Илгизәр башын тотып ыңгыраша башлый. Риза да, Ләйсән дә анны танып алалар.

Риза. Теге көнне миңа ябырылган хулиганнарга нидер аңлатып маташучы абзый шушы иде. Әйе, әйе, шушы иде.

Илгизәр телсез кеше кебек кылана.

Лилия *(Шәфкать туташы биргән даруны исенә төшерә).* И-и, онытып торам икән, сиңа бит менә даруны бирергә кушканнар иде. *(Графиннан стаканга су агызырга итә, ләкин анда су юклыкны күреп, сумкасыннан термос чыгара.)* Сиңа термос белән бик тәмле ширбәт апкилгән идем. Шуның белән эчеп җибәр әле даруыңны. Ачылыгы беленмәс. *(Термостан стаканга кызыл төстәге эчемлек агыза да Шәфкать туташы калдырган даруларны шуңа салып болгата, һәм Илгизәрнең башын калкытып эчерә башлый.)*

Илгизәр *(берничә йотым йоткач туктый).* Нәрсә бу, ә? *(Стаканны читкәрәк этә.)*

Лилия. Мә, мә, эч. Күрдең бит нәрсә икәнен. Үз күз алдыңда салдым лабаса. *(Даруның калганын да Илгизәрнең башын тотып авызына сала.)*

Илгизәр. Нишләп аракы исе килә моннан?

Лилия. Даруларны спирттан ясыйлар инде аны.

Илгизәр. Уф, яндыра... *(Күкрәген тота.)* Кая, бир әле термосыңны.

Лилия *(термосны ачып иң беренче үзе иснәп карый һәм шакката.)* И, Ходаем, бутаганмын икән. Бу термоста бит мин бик шәп импортный шәраб саклый идем. *(Үз-үзенә.)* Спиртка марганцовка кушып төс керткән «импортный».

Илгизәр. Уф, үтердең, җен хатын. *(Сикереп торып утыра.)*

Лилия. Сиңа торырга кушмадылар. Торма, миең болганыр.

Илгизәр *(чалбар урынына простыня урап).* Миңа хәзер барыбер. Мин үләм.

Лилия. Ярты стакан аракыдан үлгән кеше юк әле.

Илгизәр. Газраил, бәдбәхет. *(Лилиягә графин күтәреп селтәнә башлый. Шул вакыт Риза бер яктан, Ләйсән икенче яктан аның кулын эләктереп алалар.)*

Палатага беренче күренештә Лилия кибетенә чәй алырга килгән
Карчык керә. Ул як-ягына карана.

Карчык. Риза улымны шушында ята дигәннәрие.

Риза. Әби! Нишләп инде борчылып йөрисең? *(Ишеккә, әбисе каршына килә.)*

Карчык *(күзләрен сөртеп).* И балам, балам. Синең өчен мин дә борчылмагач, кем борчылыр? Әле менә синең бүлнискә кергәнеңне ишеткәч, колхозның сөт машинасына утырдым да... *(Ризаның гипслы кулына сак кына кагыла.)* Бик авыртамы?

Риза. Юк, әбекәй, авыртмый.

Карчык *(эчкәрәк үтә).* Аллага шөкер, янында иптәшләр бар икән әле. Болар да синең белән ятамы? *(Ләйсән белән Лилиягә күрсәтә.)*

Риза. Юк, әбекәй. Бусы Ләйсән. Бусы Лилия апа, Ләйсәннең әнисе була.

Карчык. Ләйсән бала шушы буламыни? Сөбханалла, сөбханалла, бигрәк сөйкемле бала икән. *(Ләйсәннең аркасыннан кага.)* Бәхетле бул, балам. Әнием дә бик яшь икән әле. *(Лилиягә карый.)* Иншалла...

Илгизәр танытмас өчен карчыктан читкә борыла.

Илгизәр *(ыңгырашып).* Уф, үләм, врачны чакырыгыз, врачны.

Карчык. Бу иптәшегезнең хәле бик мөшкел күренә. *(Йөзенә текәлебрәк карый.)* Тукта, тукта. Таныш кеше түгелме соң? *(Илгизәрнең җиңеннән килеп тота.)* Шул, үзе!

Риза. Әбекәй, нәрсә, әллә танышыңмы?

Карчык. Нинди генә танышым әле.

Илгизәр ыңгыраша, одеал астына кереп качмакчы була. Ләкин Карчык аның өстенә ябынган одеалын тартып ала.

Карчык. Качма, качма. Күп качып йөрдең, инде менә чыраеңны улыңа күрсәт.

Риза. Син нидер бутыйсың бугай, әбекәй.

Карчык. Мин бутыйммы? Бу бәдбәхетне мин җиде төн уртасында күрсәм дә таныйм.

Риза. Әллә ул сиңа берәр начарлык эшләдеме?

Карчык. Миңа гына начарлык эшләсә икән? Сиңа да начарлык эшләгән кеше ул.

Риза. Миңа да?

Карчык. Ул бит сиңа пычак күтәргән адәм. Ата тиешле кеше.

Риза. Атам?!

Ләйсән белән Лилия аптырашып Илгизәргә текәләләр.

Карчык. Атаң дип әйтергә телем чирканса да әйтәм: бик күп кешеләрне елаткан бәндә бу. Башта,

әниеңне куып чыгарып, өегезне сатып эчте. Аннары икенче бер хатынга йортка керде, аның каккан казыгын да калдырмыйча тормышын пыран-заран китерде. Оятсызлыкка башы эшли аның: тизрәк берәрсенә килеп керә дә язылышып куя.

Карчыкның бу сүзләреннән соң Лилия аһ итә.

Карчык. Язылышкач бит әйберләрне бүлешергә җайлы. Кайчандыр Казанда зур җирләрдә укып йөргән кеше бит ул. Яхшылыкка өйрәнә алмаса да, этлекне әйбәт белә.

Илгизәр *(күкрәген тотып).* Янам, буылам! *(Лилиягә.)* Кабахәт син, кеше үтерүче. Миңа юри аракы эчердең. Ә миңа аның бер йотымы да әҗәл.

Карчык. Ә, шулаймы? Синең дә әҗәлең якынлаштымы? Авыл саен ятимнәр арттырып йөргәндә үләрмен дип уйламагансыңдыр, мөгаен. Ятимнәр каргышы бер төшмәсә, бер төшә ул.

Илгизәр *(зәһәрләнеп Карчыкның каршысына килеп баса).* Әйе, рәхәтләнеп типтереп яшәдем. Ачыгавызларны төп башына утырту минем җаныма ләззәт бирә иде. Мин хәзер сезнең берегездән дә курыкмыйм. Күп булса бер-ике сәгать гомерем калгандыр. Мин үлем алдында да сездән өстен: чөнки хәзер дөресен сөйли алам. Ә сез, мескеннәр, бер-берегезне алдар өчен бу гөнаһсыз дөньяда каласыз. Күрә алмыйм мин сезнең кебек мескен җаннарны. Җир кортлары сез, бөҗәкләр.

Риза *(йодрыкларын йомарлап, Илгизәргә таба бара).* Тукта, югыйсә авызыңны мендәр белән томалыйм.

Илгизәр. Син көчекне ике тапкыр юк итәргә теләдем. Беренчесендә менә бу убырлы карчык кулымнан пычагымны бәреп төшерде. *(Ризаның әбисенә төртеп күрсәтә.)* Икенчесендә үзем яллаган исерекбашлар үземә кул күтәрделәр.

Лилия. Ә-ә, эш менә нәрсәдә икән? Тик шуны әйт әле: нәрсәгә Ризага кул күтәрү кирәк булды сиңа?

Илгизәр. И-и, аңгыра ишәк! Мин — сиңа, улым кызыңа өйләнсенмени?

Риза. Соң, Лилия апа, күрмисезмени, ул бит сезнең йорт-җирне кулга төшерергә уйлаган.

Илгизәр. Әйе, уйладым. Дөньядан киткәндә бары тик шул үкенечем генә калды: бер ачыгавызны төп башына утыртырга өлгермәдем. *(Лилиягә.)* Өеңә бер кереп утырсам, үзеңне алкоголичка дип таш капчыкка тыктыра идем. Хәзер анда синдәйләрне бик теләп алалар. Аннары инде шәп йортка яшь бикәч апкайтып куярга гына кала иде.

Лилия. Ах, кабахәт! *(Илгизәрнең өстенә бара.)*

Риза *(аны тотып).* Тынычланыгыз, Лилия апа. Нәҗескә кагылсаң, сасысы чыга.

Илгизәр *(ямьсез итеп көлә).* Ха-ха-ха-ха! Мескеннәр! Томаналар! Сезне бит башында аз гына акылы булган бөтен кеше алдый ала. Сез алданыр өчен генә яраклы.

Риза *(кискен итеп).* Җитте! *(Илгизәрне караватына төртеп җибәрә.)*

Илгизәр *(кычкыра).* Үтерәләр! Әй, сестралар! Кайсыгыз бар анда?!

Шәфкать туташы керә.

Шәфкать туташы. Нәрсә бар? Нигә шаулашасыз?

Илгизәр *(урыныннан сикереп тора).* Менә болар мине үтерергә килгән. *(Лилиягә.)* Менә монысы миңа көчләп аракы эчерде. *(Ризага.)* Менә монысы...

Шәфкать туташы. Туктагыз әле, тукта. Сезгә урыныгыздан торырга кем рөхсәт итте әле?

Илгизәр. Үзем рөхсәт иттем. Мин хәзер үземә үзем баш. Җитте, яшәгәндәге кебек матур итеп, горур итеп үләргә кирәк.

Шәфкать туташы. Үләргә? Нинди үлем турында сөйлисез сез? *(Илгизәрне яткырмакчы була.)*

Илгизәр. Туктагыз, тукта. Мәңгелеккә күзләремне йомганчы, бернәрсә әйтеп калыйм.

Шәфкать туташы. Сез саташа башладыгыз, ахры.

Илгизәр. Юк, саташмыйм. Менә бу кеше үтерүче. *(Лилиягә төртеп күрсәтә.)* Ул миңа көчләп аракы эчерде. Ә мин яңа гына аракыдан дәваланган кеше. Бер йотымы да миңа әҗәл.

Шәфкать туташы. Шулаймыни?

Илгизәр. Шулай, туташ. Монда барысы да бандитлар, кеше үтерүчеләр җыелган. *(Күкрәген тота.)* Уф, үләм, эчем яна. Сестра, нәрсә карап торасың, үләм бит!

Шәфкать туташы.Үлмисез, үтермибез. Хәзер без сиңа бер бик шәп укол җибәрәбез.

Илгизәр. Укол? Юк, юк, кирәкми! Укол кадамагыз.

Шәфкать туташы. Без сиңа яшәтә торган укол гына бирәбез.

Илгизәр. Кирәкми, кирәкми. Миңа хәзер яшәргә ярамый. Бөтен планнарымны ачтым.

Риза. Ә, шулаймыни? *(Илгизәрне кулыннан эләктереп тота.)* Ясагыз әйдә, сестра, бик шәпләп ясагыз уколны.

Шәфкать туташы Илгизәрнең арт ягына укол кадый.

Илгизәр. Үтерәләр, үтерәләр! Коткарыгыз!

Шәфкать туташы. Үтермибез, яшәтәбез. Өч доза җибәрдем.

Карчык. Кылган эшләрең өчен бу дөньяда җавап бир, тегендәгесен әллә күрәбез, әллә юк.

Илгизәр. Оятсызлар. Минем артыма укол кадаганны карап тормасагыз.

Карчык. Бүтәннәрдән күп көлдең, инде синнән көләр вакыт җитте. Менә шулай. *(Илгизәрнең арт ягына шапылдатып суга.)*

Пәрдә.

*1975*

# ЭЧТӘЛЕК

**Повесть**

Кыйбласызлар ........ 5

**Пьесалар**

Мәхәббәттән көчле дәва юк ........ 99
Язмышларны кабат язып булмый ........ 212
Кызлар күңеле — тирән сер ........ 276
Җимерелгән хыяллар ........ 316
Кызларның кызганнары ........ 352
Шүрәлеләр каргышы ........ 384
Койрыксыз сандугач ........ 422

Литературно-художественное издание

***Яруллин** Фанис Гатауллович*

**ПРОИЗВЕДЕНИЯ**

В трех томах
Том 2

Казань. Татарское книжное издательство. 2008
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Яруллин** Фәнис Гатаулла улы*

**ӘСӘРЛӘР**

Өч томда
2 том

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Л.З.Шиһапова, Р.Н.Нуруллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 14.01.2008. Форматы 84х108 1/32. Офсет кәгазе. «Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 24,36. Шартлы буяу-оттиск 24,78. Нәшер-хисап табагы 23,01. Тиражы 2000 д. Заказ С-1530.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

http://tatkniga.ru
E-mail: tki@tatkniga.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.